

Раул Мирхәйдәров

# Иртәләгән сагыш



Роман, повесть

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2002

УДК 820/89 (470)
ББК 84(2Рос=Тат)-4
М51

**Мирхәйдәров Рауль**

М51 Иртәләгән сагыш: Роман, повесть.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2002.— 447 бит.

Бу әсәрләрдә язучы бүгенге болгавыр заманның төзәлмәс яраларын бәян итә, чынбарлыкның иң кискен борылышларын оста итеп сурәтли.

ISBN 5-298-01229-9

© Татарстан китап нәшрияты, 2002

# ИҖАТ – ҮЗЕ ТОРМЫШ УЛ

## 1

Рауль Мирхәйдәровның иҗат биографиясе гаҗәеп кызыклы сирәк күренеш. Аның тормыш юлын белми торып, әсәрләренең тематик һәм стиль төрлелеген дә аңларга мөмкин түгел.

Рауль Мирсәет улы Мирхәйдәров Казакъстанның Актүбә өлкәсе Мартук шәһәрчегендә чыгышлары белән Оренбург татарлары булган гаиләдә 1941 елның 17 ноябрендә дөньяга килә.

Язучының әтисе Мирсәет немец фашистларына каршы Мәскәү тирәләрендә барган каты сугышларда атаклы Панфилов дивизиясендә була һәм, улын күрә алмыйча, шунда гомере өзелә.

1956 елда, җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, Рауль Актүбә тимерьюлчылар техникумына укырга керә. Хезмәт эшчәнлеген ул төзелештә прораб булып башлый — өзлексез эш стажы егерме ел тәшкил итә. Ул бик иртә музыка һәм рәсем сәнгате белән кызыксына, спорт белән шөгыльләнә һәм күп тапкырлар бокс буенча Актүбә чемпионы була.

1961 елда Рауль Мирхәйдәров Ташкентка күчеп китә, төзелеш институтында читтән торып укый, Үзбәкстан башкаласының мәдәни тормышына башы-аягы белән чума. Ул анда шагыйрьләр, рәссамнар, артистлар, музыкантлар белән аралаша, театрлардагы бер спектакльне дә калдырмый карап бара, музейларга йөри, Ташкентның иҗат әһелләре арасында үз кеше булып китә. Әнә шул мохиттә булачак язучының тумыштан килгән табигый зәвыгы-сәләте үткенләшә-чарлана.

Аның тормышындагы кискен иҗади үзгәреш очраклы бер вакыйгага бәйле. Бер танылган кинорежиссерның чираттагы фильмы турында фикер алышканда, кызу канлы яшь инженер Мирхәйдәров үткен-үткен тәнкыйть сүзләре ычкындыра. Хәтере калган кинорежиссер шаярткан булыбрак аңа: «Үзең башта юньлерәк берәр нәрсә

иҗат итеп кара, аннары тәнкыйтьләргә алынырсың»,— ди.

Төзүче инженер бу сүзләрне күңеленә салып куя һәм өч көн эчендә үзенең «Полустанок Самсона» дигән беренче хикәясен язып ташлый. Моңа кадәр кулына каләм тотып та карамаган Рауль Мирхәйдәровның бу хикәясе бик уңышлы килеп чыга, ул Мәскәүдә «Родники» дигән альманахта басыла да.

Шулай итеп, Р.Мирхәйдәровның иҗат биографиясенең башы 1971 елга барып тоташа. Шунысын да әйтеп үтү артык булмас, «Полустанок Самсона» хикәясе шуннан бирле утызлап мәртәбә кабат-кабат басылып чыга, чит телләргә тәрҗемә ителә, берничә мәртәбә радиоспектакльләр оештырыла. Яшь язучыда чын-чынлап иҗат дәрте кузгала. Р.Мирхәйдәров искиткеч тизлек белән хикәя арты хикәя яза, күңеленә җыелган бар тойгыларын әйтеп бетерергә, укучыларга җиткерергә ашыга. Өзлексез киеренке иҗади хезмәт, җөмләләр-образлар чарлап утыру инженердан язучы формалашуга этәргеч була.

1975 елда Р.Мирхәйдәров яшь язучыларның Мәскәүдә үткәрелгән IV Бөтенсоюз киңәшмәсенә чакырыла, танылган рус язучылары Николай Шундик һәм Лазарь Карелин семинарына йөри. Шушы ике язучы һәм Зәки Нури аны СССР Язучылар союзына әгъзалыкка тәкъдим итәләр. Семинарда югары бәя алган «Голубые самосвалы» хикәясе «Мы — молодые» дигән альманахта басыла. Мәскәүнең «Молодая гвардия» нәшриятында «Оренбургский платок» исемле китабы дөнья күрә. Соңыннан бу нәшрият зур-зур тиражлар белән аның әле тагын җиде китабын нәшер итә.

Әмма яшь авторның әдәбият мәйданына торкан юлы шома гына бармый, әлбәттә.

Хәзер «торгынлык еллары» дип тамгаланган, әле ерак калмаган чорыбызга әйләнеп карыйк та күрик: редакцияләрнең ишекләрен нииндирәк шәхес шакып йөрде икән?

Казакъстанда туып-үскән, рус телендә язып йөрүче төзелеш инженеры, Үзбәкстанда яшәүче бер татар кешесе ул. Кем әйтмешли, ни кияү, ни кода түгел, чиндәрәҗәләре дә юк — артыннан этеп торучы «йонлач куллар» да, «калын җилкәләр» дә күренми. Ниндидер бер килмешәк шунда. Ул еллардагы катып калган җәмәгатьчелек фикере буенча авторның бернинди үсеш киләчәге дә булмый.

Әмма яшьлек җегәре, табигый таланты һәм тиз үсә барган әдәби осталыгы бөтен киртә-каршылыкларны җи-

мерә — Рауль Мирхәйдәровның китаплары Мәскәү һәм җирле нәшриятларда бер-бер артлы дөнья күрә тора: «Полустанок Самсона», «Такая долгая зима», «Оренбургский платок», «Не забывайте нас», «Дамба»...

Язучының исеме башкаланың абруйлы журналларында ешрак яңгырый башлый. Махсус әдәби белеме булмау да комачаулый алмый, чөнки яшь авторның бай тормыш тәҗрибәсе бар — үзенчәлекле әдәби талант өчен иң төп, иң кирәклесе әнә шул.

Р.Мирхәйдәровның егермедән артык басма күргән танылган романы «Пешие прогулки»ның көче нәрсәдә соң? Әсәр шуны раслый: Мирхәйдәров иҗаты гади матур әдәбият кына түгел, сәхнәләштерелгән театраль күренеш кенә түгел, сәхнәдә һәлак булган герой пәрдә төшүгә яңадан терелә. Ә бу роман авторның бөтен тормышын тәшкил иткән яшәү белән үлемнең аерылгысыз бер өлеше булып әверелә. Әсәр басылып чыкканнан соң язучыны чын-чынлап үтерергә тырышалар, аны, әсәренең төп герое прокурор Азларханов белән берлектә гаделлек өчен көрәшкәнгә күрә, юк итмәкче булалар. Шул рәвешле, Мирхәйдәров ачы язмышка тара: әдәби әсәре өчен ул сәламәтлеге белән түли — аны бик каты кыйныйлар, умырткасын сындыралар. Әмма язучы үлемне җиңеп чыга, аның яшьтән спорт белән шөгыльләнеп чыныккан тәне дә, җинаятьчел бәндәләргә каршы көрәшкә күтәрелгән җаны-рухы, ихтыяр көче дә булыша аңа. Раульь Мирхәйдәровка оештырылган һөҗүм — җинаятьчел бәндәләрнең җитәкче даирәләр белән үрелеп-берегеп үскәнлеген ачык күрсәтүче бер дәлил дә ул. Бу күренеш, үзгәртеп кору елларында башланып, хәзер дә дәвам итә әле. Җәмгыять гаять зур куркыныч алдында тора...

Тормышыбыздагы үзгәрешләр әдәбиятка да нык тәэсир иттеләр. Танылган абруй-дәрәҗәле исемнәр төшеп калды, күпсанлы беркөнлек «әдәбият» сырлаучылар мәйданга чыкты, китап киштәләре зәвыксыз, секс-порно, үтерү-көчләү, талау-яндыруише иң түбән инстинктларга корылган китаплар белән тулды. Кайчандыр бербөтен булган ил-дәүләт юкка чыкты, аның урынында барлыкка килгән илләрнең һәммәсенең дә рухи тормышында бик яман күренешләр хасил булды. Хәзерге болгавыр, рәхим-шәфкатьсез, һәрнәрсәгә битараф заман берәүләрне баета, дан-шөһрәткә күмә, икенчеләрен бөлгенлеккә төшерә, һәлакәткә этәрә. Сәяси һәм социаль тормышыбыздагы җил-давыллар, гарасатка әверелеп, әдәбият мәйданындагы сүз осталарын да себереп түкте. Алар хәзер берән-сәрән генә калды.

Рауль Мирхәйдәров — шул берән-сәрәннәрнең берсе. Ул язучы буларак үз ватанында гына түгел, ерак төбәкләрдә дә танылу тапты. Мирхәйдәров бүгенге дөньяны, дөрес һәм хәтта тетрәндергеч итеп сурәтләп, укучылар күз алдына китереп бастырды, ул моңа социаль-сәяси романнар иҗат итеп иреште, шуның белән үзенә әдәби исем дә яулады. Бай фактик материал, тел-теш тидермәслек дөреслек аның әсәрләренең нигезе булды. Авторны фактограф яки хроникер дип әйтергә һич ярамый, аның әсәрләренең тәэсир көче социаль гомумиләштерүләренең нигезле һәм әһәмиятле булуында. Мирхәйдәровның үткен криминаль сюжетка корылган романнары күренешләрнең асылын һәм вакыйгаларның дөрес сәбәпләрен ачарга ярдәм итә. Аның үзенә танылу китергән әлеге әсәрләрендә көрәзәчелек итү дә көчле, шуңа күрә алар искерми, киресенчә, басылып чыгуларына дистә еллар үтүгә карамастан, тагын да заманчарак яңгырый, тагын да актуальрәк була бара. Димәк, язучының романнары җәмгыятебезнең иң тирән асылын чагылдыра дигән сүз. Мирхәйдәров әсәрләре халыкның холык-табигатен, хакимият башында утыручыларның психологиясен аңларга ярдәм итә. Язучының иҗаты — бүгенге көндә хакимият башындагылар белән җинаятьчел дөньяның бер йомгак булып чорналуын кыю күрсәтүче иҗат.

**2**

Рауль Мирхәйдәров иҗатының гаять мул җимешле булуы гаҗәпләндерә. 1988 елдан башлап язучының романнары һәр бер-ике ел арасында нәшер ителә тора. Күптөрле катламнарны колачлаган алты романның шундый кыска вакыт эчендә иҗат ителүе — әле махсус тикшеренүне сорый торган искиткеч күренеш. Бу кадәр гаҗәеп бәрәкәтле иҗатның бары тик авторның бөтен тормыш тәҗрибәсе белән генә әзерләнгән булуы бәхәссез. Иң югары дәрәҗәдә язылган бу әсәрләр язучының моңа кадәр булган барлык иҗаты нәтиҗәсендә туган. Алай гына да түгел, романнарындагы күп кенә уй-фикерләрне, фаразлау-күрәзәчелек итүләрне бары тик аның барлык әсәрләре белән танышканнан соң гына тулысынча аңлап һәм тиешенчә бәяләп бетереп була.

Еллар үтте, яманаты чыккан үзгәртеп корулар чоры артта калды, инде хәзер Россиядә «капитализм төзү» чорының да беренче ачы нәтиҗәләрен ясарга вакыт җиткәндер. Әгәр дә еллар вакыты җитмәгән булса, хәтер вакыты бик җитте, безнеңчә. Иске җинаятьчел эшләр йомар-

ланган-йомылган, тәмам онытылган, дәлилләр юкка чыккан, шаһитлык итүчеләр дә әллә бар, әллә юк... «Социалистик» җинаять дип саналган гамәлләр хәтта закон бозу дип тә кабул кылынмый инде. Үткәннәрдән күренгәнчә, Рауль Мирхәйдәровның ул еллардагы тискәре күренешләрне фаш иткән романнары әле чагыштырмача имин тормышның хәтердән юылмас сурәтләре һәм йөрәктәге яра эзләре булып уелып калды. Ләкин шунысы хак, ул романнар әле бүген дә бик әһәмиятле, гаять актуаль! Сәнгатьчә чын-камил әдәбият үзе чагылдырган тормыш чынбарлыгыннан озын гомерлерәк, тererәк булып калды. «Приватизация-прихватизация» дигән битлек астында ил-халык байлыгын йотыш-бүлеш заманы үтеп бара. Җәмгыятебез янә дә озын-озакка төрле катламнарга таркала тора, дөресрәге, таркалды инде. Тагын егерме-егерме биш елдан соң яңа буын кешеләре безнең бүгенге вазгыятебезне шулай булырга тиешле закончалык итеп кабул кылачак. Һәм йөрәк хәтере вакыйгаларны да, агымдагы ачы чынбарлыкны бар иткән үзебезнең ачы язмышларыбызны да океан суларыдай күмеп китәчәк, онытачак.

Ә Рауль Мирхәйдәров романнарындагы әдәби образсюжетларга төрелгән вакыйгалар, хәл-гамәлләр сакланып калыр, алар инде тарихка әверелде.

Авторның әсәрләре — офыкка мәңгелеккә кереп күмелгән кризис һәм дефолт чорларының чынбарлыгын чагылдыручы көзге иде. Һичшиксез, Россиядә социализмның һәлакәте һәм капитализмның өзлексез даими кризисы әле күп фәнни тикшеренүләргә бетмәстөкәнмәс азык булыр. Ләкин әле күптән түгел генә үтеп киткән тормышыбызның чынбарлыгы сулышы, шул чор рухы Рауль Мирхәйдәров романнарындагы җанлы образларда гомерлеккә сакланып калачак.

Россиядәге киң катлам укучыларга Мирхәйдәров романнарына нигез булып яткан Адылов һәм адыловчылык әле күптән түгел генә әллә кайдагы, ерак Урта Азиядәге күренеш булып кына тоела иде. Баксаң, һич тә алай түгел икән. Советлар Союзын таркалуга китергән астыртын сәбәпләрнең берсе мамык кырларында кол хәлендә эшләп йөргән үзбәк дехканнарының шул коллыктан котылырга теләгән яшерен омтылыш-хыялларында да булган. Кесәләрендә партия билеты йөрткән оятсыз басмачылар, үзләре бал-май эчендә алтын-көмешкә күмелеп яшәсәләр дә, хокуксыз, ач-ялангач халыкка бер тиен дә хезмәт хакы түләми килделәр. Һәм хәзер дә түләмиләр! Анда гына түгел — һәркайда! Ләкин гади халыкны бер-

кем дә: «Алда да сезне шул ук ачы язмыш көтә»,— дип искәртмәде. Халык азатлык исеннән исерде, җимерелеп барган Россия империясенең үз халкы да гомерлек исереклектә иде, аның да ришвәтчелеккә, караклыкка кереп баткан кыргый азиатлардан тизрәк котыласы килде. Әле күптән түгел генә Әфганстан тауларында кылган җинаятьчел гамәлләреннән әнә шул «кыргый азиат» илләренең чикләре белән ышыкланырга теләде Рәсәй. Шулай иткәндә, мул-имин Европага тизрәк кушылырга мөмкин булыр, бәхетле-бай тормышка җитәргә бик аз калган шикелле тоелды. Ай-һай ла!

Ә Мирхәйдәров романнарында ришвәтчелек-коррупциянең яман шеше һәрвакыт үзәктә — Мәскәүнең үзендә икәнлеге ачык сурәтләнде. Үзәктән читтә ул яман шешнең тәлинкә тотучы ялагайлары гына иде. Дәүләтнең таркалуына китергән төп сәбәп һәрвакыт бер генә — хакимият башындагы түрәләрнең сатлыкҗан булулары. Хезмәт хакы ала алмыйча иза чигүчеләр мамык кырларында гына түгел икән, моны аңлау өчен телевизорыңны кабызып карау да җитә — ач шахтерлар һәм укытучылар, галимнәр һәм табиблар күрер идең. Һәм, ниһаять, халык шуны күрде, аңлады. Рауль Мирхәйдәров әсәрләрендәге күрәзәчелекнең никадәр дөреслеген, ачы хәсрәтне әчкә йотып, соңлап булса да аңладык без.

## 3

Рауль Мирхәйдәровның иҗатын икегә бүлеп карарга мөмкин.

Беренче — башлангыч чоры 1971 елдан башлана да, хикәя-повестьлар яза-яза, бер унбиш елларга сузыла. Ул вакытта әле язучы үз башыннан үткән кичерешләрне сурәтләүдән узмый. Шулай да аларны сәнгатьчә яза-сурәтли белә һәм китаплары да басылып чыга тора.

Икенче чор — ул романнар чоры.

Эш һич тә романнарның күләмлерәк булуында түгел, ә аларның әдәби әсәр буларак сыйфат үсешендә һәм инде авторның дөньяга фәлсәфи карашы, аң-фикерләү дәрәҗәсе үсешендә дә чагыла. Хикәя-повестьлар, кечкенә әдәби жанр булганлыктан, алардагы эчтәлек-сюжетлар да бик шартлы һәм чикләнгән була. Р.Мирхәйдәров үз иҗатының икенче чорында менә шул тышаулардан котыла. Чөнки ул — чын иҗатчы, хәзер инде элекке кысаларга гына сыешып бетә дә алмый.

Киеренке эчтәлекле романнар, әлбәттә, бөтенләй башка — киң колачлы иҗатны сорыйлар. Аларда заман «на-

полеоннары»: һәртөрле мафиозилар, «тәгәрәтүчеләр», күләгәдә кара эшләрен башкаручылар һәм, билгеле инде, эреле-ваклы сәясәтчеләр хәрәкәткә килә. Бу прозаның архитектоникасы да үзгәрә — әсәрләрнең концепциясе, күптөрле полифоник яңгырашы, жанр синтезы башкача яңгырый. Ләкин шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, җинаятьчел-детектив сюжет автор өчен үзмаксат түгел, ул аның өчен бүгенге тормышның асылына — ерып чыга алмаслык «урам-чытырманнары» арасына үтеп керү чарасы гына. Романнар язу, сюжет-эчтәлекне катлауландырудан тыш, авторның иҗат мөмкинлекләрен дә киңәйтә, үстерә.

Язучының беренче ел иҗат җимешләре, алардагы төп тема һәм образлар, үзенчәлекле чагылыш кичереп, аның 1991 елда язып тәмамлаган «Иртәләгән сагыш» исемле тәүге романында тулысынча ачылды. Бу роман — әдәбиләштерелгән истәлек иде. Укучыны формасы белән дә, гаять авыр-катлаулы, тетрәндергеч сюжет белән дә алдый алмыйсың. Биредә — көндәлек тормыш чынбарлыгы, көнкүреш «вак-төякләре», алар һич тә тышкы мавыктыргыч «тәти кәгазьләргә» төрелмәгән. Р.Мирхәйдәров бу романында коллаж ысулын — төрле рәсем-күренешләрдән кисеп тулы бер яңа сурәт ясау ысулын оста файдалана: әсәрнең тукымасына элгәрге язганнарыннан тема һәм хиссияте белән аваздаш булырдай тулы кисәкләрне «эретеп» ябыштыра. Шуның белән роман тагын да тәэсирлерәк, үзәкләрне өзәрлек яңгыраш ала. Авторның бу алымы укучыны да активлаштыра, аның барлык иҗатын яңадан бер мәртәбә күздән кичерергә мәҗбүр итә. Шул рәвешле, укучының үз күргән-кичергәннәренә дә тәңгәл килерлек тулы бербөтен дөнья ачыла. Бәян итүнең әнә шундый «кәрәзле» тукымасы холык-табигатьләре, социаль дәрәҗәле, ә иң мөһиме — тормыш тәҗрибәләре төрле-төрле булган кешеләрнең язмышларын тулы итеп сурәтләп бирергә мөмкинлек калдыра. «Иртәләгән сагыш» романында уйлап чыгарылган әдәби образлар белән берлектә тормышта яшәгән чын шәхесләр дә байтак күрсәтелә, хәтта кайберләре турыдан-туры үз исем-фамилияләре белән бирелә. Ә инде географик атамалары белән әсәргә ипле генә кереп утырган кала-салалар — Степное, Скудное, Хлебодаровка, Мартук, Актүбә... Болар иксез-чиксез Казакъстан далаларының үзенә генә хас сулышын-тәмен укучыга түкми-чәчми китереп җиткерә. Мартук... Европа белән Азия чигендә күренер-күренмәс кенә булып утырган бу дала шәһәрчегеме-бистәсеме Р.Мирхәйдәров өчен «кечкенә ватан» гына түгел,

ул аның өчен үзенчәлекле олы бер дөнья, шунда аның җанына якын күп геройлары яшәгән, яши һәм әле яшәячәк. Атаклы бертуган Гонкурларның сүзләрен үзенчәрәк үзгәртеп, Рауль Мирхәйдәров бервакыт болай дигән иде: «Әдәби истәлекләргә кереп калмаган төбәкләр... алар тарихтан төшеп калырга, онытылырга хөкем ителгәннәр». Шул уңайдан берәр мартуклы: «Мин «Иртәләгән сагыш» романында сурәтләнгән атаклы Мартуктан»,— дип, бераз мактанып җибәрә икән, әдип өчен шуннан да артык мактау сүзләре кирәкме?

Үткән чорыбыз турында уйланганда автор, өметсезлеккә бирелеп, һәрнәрсәне кара буяуларга манарга, агымдагы сәясәткә яраклашып, беркемне дә «маңкорт» дип тә, «совок» дип тә гаепләргә ашыкмый. Юк, ул үткәннәргә мөкиббән китеп дан да җырламый, шулай ук хәзерге кайбер «ачы хакыйкатьне» ярып салучылар шикелле, пычрак өяргә дә теләми. «Иртәләгән сагыш» романындагы образлар — алар «җирдә кеше бары тик кылган эш-гамәлләре белән генә бәяләнә ала» дип яшәүчеләр. Бу роман, әйткәнемчә, үзәкләрне өзәрлек моңсу әсәр булып чыккан. Кешеләр арасындагы бердәмлекне дә, шул ук вакытта боздай салкын киртәләрне дә чын сәнгатьчә күрсәтә алуы белән Р.Мирхәйдәров зур фәлсәфи хакыйкатьне ачып сала: кеше гомере — Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән иң кыйммәтле бүләк. Тормыш чынбарлыгы шатлык-куанычларга никадәрле генә саран булмасын, кешеләр кеше булып кала, алар үзләренең кечкенә генә бәхет-шатлыкларын шушы кырыс тормыштан да таба белә, тарих һәм язмыш аларга шулай яшәүне насыйп иткән.

Романның герое Рушан Дасаевның кәттә-шәп квартирасы да юк, артык байлык-муллыгы да ташып тормый, хәтта калтырча гына берәр машинасы да күренми. Әмма ул яшь, аның рухи тормышы бай һәм тулы канлы. Яраткан эше, музыка, әдәбият-сәнгать, спорт — болар азмыни? Ул әнә иң беренче хезмәт хакына ниндидер рәсем сатып алып кайтып элә. Ул үзе өчен замандашлары Казаков, Распутин, Трифонов кебек рус язучыларын гына ачып калмый, аңарда ата-баба каны да уйный: ул Тукай, Такташ, Җәлил иҗатлары белән, тәрҗемәдә булса да, танышып барырга тырыша. Үз яшьтәшләре арасыннан иң алдан Фицджеральд һәм Дзюнпей Гомикава китапларын табып укыганына да куана ул... Тормышның матурлыгын күрә белеп, аңа сокланып яшәү — «Иртәләгән сагыш» романының төп асылы да әнә шунда. Күтәренке күңел белән яшәргә омтылу теләге һич тә кыйммәтле-затлы әйберләр

булдырудан тормый икән ич. Куаныч-шатлыкларның бәһасе юк аның. Бу бигрәк тә романның кырыс, хәтта фаҗигале тормыш-көнкүреш фонында ачык чагыла.

Рушан Дасаев үз буынының тарихтан төшеп кала барганына борчылмый, ул аның дөнья картасыннан юкка чыккан зур ил-дәүләтенең рухи тормышында лаеклы эз калдырып китә алмавы өчен борчыла. Рушанга әле илле дә тулмаган, ә «ул инде кешеләрнең өметләре-язмышлары җимерелүне генә күреп калмады. Аның күз алдында шәһәрләр юкка чыкты, яшьлегендә ул яраткан вокзаллар-биналар кая хәзер, казакъ авыллары кая?..»

Хәзерге вазгыятьтә кешеләрнең җәмгыять өчен кирәксезлеге — ул психологлар тырышлыгы белән генә чишелә торган мәсьәлә түгел, ул хәзерге дөньяның иң зур мәсьәләләреннән берсе. Эшсезлек хөкем сөрү бер хәл, үзеңнең кирәксезлегеңне тою, иске дегет чиләге шикелле, бу тормышның юл читендә тәгәрәп төшеп калу әллә нинди эчке кичерешләргә, фаҗигаләргә дучар итә хәзер кешене.

Р.Мирхәйдәров безнең бүгенге тормышыбыз алдына килеп баскан әнә шул үткен мәсьәләне инде дистә еллар алдан күреп, борчылып язган икән. Аның геройлары арасыннан алыгыз сез кайчандыр атаклы Пелегә тиңләп йөртелгән талантлы футболчы Камил язмышын... Искә төшерегез зур мәхәббәт көтеп, «әкияти принц» өмет итеп тормышлары ватылган Тамара Давыдычева белән Светлана Резникова язмышларын...

Ләкин, ни генә булмасын, тормыш дәвам итә. «Иртәләгән сагыш» романында бернинди искитәрлек вакыйгалар да юк: хәзерге телеэкраннардагы кебек, атышүтерешләр дә, секс-порно да юк, беркем беркемне кумый, беркемнең дә беркемдә дә эше юк... Шулай укмы соң? Һич тә түгел икән. Әнә чәйханәдә ике шалапай, башкаларга игътибар итмәстән, шар ярып сөйләшеп утыралар. Үзбәк карты аларга шундук кисәтү ясый: «Башкаларны хөрмәт ит — үзеңне дә хөрмәт итәрләр»,— ди.

Без менә хәзерге вазгыятьтә шул гади хакыйкатьне онытып бетереп киләбез түгелме икән?

Романдагы тагын бер тарихка тукталып китми ярамас. Яшьлегендә романтик күңелле, кызларга тиз гашыйк булучан Рушан Дасаевны әсәр азагында зур мәхәббәт, газаплы-татлы һәм... фаҗигале мәхәббәт көтә.

Роман, асылда, инженер Рушан белән архитектор кыз Глория мәхәббәте турында. Әсәр безне бар барлыгы белән шуңа әзерләде. Глория образы иң уңышлы образ, дияр идек без. Өзелеп яратышып та, өйләнешеп бәхетле гаилә

тормышы кора алмый бу гашыйклар. Ник, ни өчен? Әлеге дә баягы хәзерге каһәр суккан вазгыять... Искиткеч талантлы архитектор Глория Көнбатышка китеп барырга мәҗбүр була. Чөнки бу илдә — барлык биналар да шырпы кабыдай тимер-бетон блоклардан өеп куелган илдә — аның талантына урын юк...

Икенең берсен сайла, Глория! Мәхәббәтеңне яки табигать сиңа бүләк иткән сирәк талантыңны. «Иртәләгән сагыш» романының төп моңы-аһәңе дә әнә шунда.

Рушан белән Глория яратыша иделәр, алар музыка һәм футбол ярата, яшьлекләрен ярата иделәр... Әмма Глория икесе арасындагы сагыш-моңның чиреген генә алып китеп бара. Аңа үз талантын тормышка ашырырга кирәк. Ул үзенә кирәкле иҗат ирегең сайлады!

Ә Рушан, аны өзгәләнеп эзләп йөрсә дә, илдә калды. Аңарда сагыш-моңның өчтән дүрт өлеше өелеп калды. Әмма... «кеше үз елгасы өчен кайгырып яшәргә тиеш». Шуңа күрә дә без, саегып барсалар да, әле агып яткан «елгаларыбыз ярындагы» Рушан ягында.

«Иртәләгән сагыш» романы Рушан Дасаевның шәхси фаҗигасе белән тәмамлана шикелле.

«Көннәр үтә — күңелсез, авыр, сагышлы көннәр чиратларда торып, салкын фатирларда яшәп үтә, алда шатлыклар көтәренә ышану бик-бик тә кыен. Вакыты-вакыты белән гомер бөтенләй бушка үткәндер кебек тоела.

Әмма... әмма...

Күптән юылмаган, тузанланып беткән тәрәзәсе аша карап торганда, каршы яктагы йорттан кулына нота папкасы тоткан зәңгәр бантиклы кызчык чыгып килгәнен күргәч, Рушанның йөзенә елмаю куна: юк, бернәрсәгә дә карамастан, тормыш дәвам итә, чөнки әле Җир йөзендә мәхәббәт бар, әле хәтер тутыкмаган, тоныкланмаган.

Ә хәзергә, мәхәббәт һәм хәтер — кешене биеклекләргә аккошлар шикелле күтәрүче шул тылсымлы ике канат әле сындырылмаган-имгәтелмәгән вакытта, тормыш чишмәсе кипмәячәк, төтендәй эреп бетмәячәк, таңдагы томандай очып юкка чыкмаячак...

Кипмәс... бетмәс... юкка чыкмас...»

## 4

Ә ул арада тарих мәйданчыгындагы әлеге якты моңсагышлы авазлар тынып та калды. Комсызлык һәм оятсызлык авазлары дөньяны басты — бик бии алмассың! Кешелек кануннары тапталды. Уңышлар мәйданчыгында шайтан тантана итә...

Рауль Мирхәйдәровның атаклы тетралогиясе нәкъ менә шул озын-озакка сузылачак, очы-кырые күренмәс төсле чорның бар әшәке якларын сурәтли.

Тормышның кискен борылыш елларында вакыт яңабаштан санала башлый: йә ул нинди дә булса яңа икътисади закон белән, йә булмаса «макмырлы» указ-фәлән белән билгеләнә. Бүгенге тормыш-көнкүрешебез тамырыннан үзгәрде, җәмгыятьнең рухи-әхлакый нигезләре какшап, юкка чыгып бетте диярлек. Ләкин Рауль Мирхәйдәровның икътисади җинаятьләргә корылган детектив романнары әле дә булса актуаль булып кала килә. Инде дистә еллар элек мәңгелек чоңгылына төшеп юкка чыккан булырга тиешле социализм эшкуарлары, әйтик, романнан романга күчеп йөрүче персонаж Артур Шубарин кебекләр,— авторның әсәрләреннән гүя бүген генә, нәкъ менә бүгенге аяусыз вазгыятебезгә оятсыз рәвештә үтеп тә керделәр. Хәер, шулай булырга тиеш тә иде. Хәзерге кыргый капиталистик базар мөнәсәбәтләре шартларында социализмның «күләгәдә йөрүчеләре» уңган менеджерлар булып китәргә тиеш иделәр. Әлбәттә, исән калганнары. Чөнки, җәмгыятьне «үзгәртеп коручылар» фикеренчә, нәкъ менә аларны яктыга чыгарып, сәнәгатьнең һәм икътисадның үсешенә яңа этәреш биреп булыр кебек иде. Күпләр шулай уйлады: «идән асты» бизнесын законлаштырасың да, капитализм безне социализм сазлыгыннан колакларыбыздан тартып та чыгара. Әмма... тот капчыгыңны! Чыгарды ди сиңа!

Бу белер-белмәс көчәнүләр илне бөтенләй җимереп ташлады. Хосусый милекчеләр белән ялланып эшләүчеләр арасында капиталистик мөнәсәбәтләр барлыкка килмәде, чөнки җитештерүче көчләр мохите үзе юкка чыгарылды. Хәзер Россиядә гаҗәеп тарихи вазгыять килеп туды — буржуазия бар, ә капитализм юк. Гөрләп чәчәк аткан туймас тамак түрәләр аппараты әпен-төпен генә, арзанга гына «приватизация — прихватизация» үткәрде дә алынган табышны йотып бетерде һәм илнең милли байлыгын җилгә очырды. Үсеш-алгарыш концепциясенең булмавы өстенә азмы-күпме акыллы тоелган еллык планнарның да барып чыкмавы СССР таркалгач барлыкка килгән яңа бәйсез дәүләтләрне дә тулы икътисади бөлгенлеккә төшерде. Иртәгә, әйтик, нефть һәм газ бетсә, берсекөнгә барлык кибет киштәләре бушап калачак.

Хәзерге ана — улны, ата кызны танымаган болгавыр заманда ялганга һәм үз-үзеңне алдауга корылган вазгыять социализм чорындагы беркатлы алдашуларның бары

тик шушы көннәргә бер репетиция, бер сынап карау мәйданы гына булганын ачык күрсәтте. Р.Мирхәйдәров романнарындагы «күләгәдәгеләр» соңгы саннарны үзгәртү өчен өтерләрне генә алып ташлый иделәр. Хәзер исә финанс мәгълүматы беренче хәрефеннән алып соңгы ноктасына кадәр ялганга корылган.

Мондый үрнәк модель Р.Мирхәйдәров романнарында ачык күрсәтелгән иде инде. Хәзер Артур Шубарин варислары язылган һәм язылмаган барлык законнарны да таптап кына узалар. Чөнки законнарны да үзләре яза, бозуын да үзләре боза.

Р.Мирхәйдәров аерым бер зирәклек белән алдан күрә белде: коммунистик диктатура, ирекле базар мөнәсәбәтләре белән алмашынып, үзеннән-үзе генә үсеш-алгарышның иң камил-мөкәммәл юлына барып чыкмаячак, ул бары тик, хәтерен җуйган склеротик карт шикелле, анык кына кая таба юл тотачагын да белмәячәк. Хәзер инде ачыктан-ачык әйтергә мөмкин: илдәге коррупция-ришвәтчелек җәмгыять төзелешенең яңа бер күренешенә әверелде. Хәлсезләнә барган ил-дәүләтнең чималы да, табигый байлыклары да, валютасы да тыелгысыз ташкын булып Көнбатыш илләренә агыла тора. Әйе, череп таркалган социализм яңа икътисади үсешкә сәләтле түгел. Һәм Р.Мирхәйдәров үзенең сәяси-социаль романнарында моны бик дәлилле-нигезле итеп ачып бирә алды.

Р.Мирхәйдәров романнарының кыйммәте хокук саклау оешмаларының җинаятьчел мафия белән көрәшен ачып салуда, ул көрәшнең киләчәк перспективаларын күрсәтүдә генә түгел иде. Автор ул күренешнең төгәл психологик сурәтен тасвирлап бирсә дә, ул куркынычны һич тә киметмәстән, шул ук вакытта бөтенләй өметсезлеккә дә бирелми. Автор җәмгыятьне сизгер булырга чакырып чаң кага! Аның «Пешие прогулки», «Двойник китайского императора», «Масть пиковая», «Судить буду я» романнары нәкъ әнә шундый набат булып яңгырады да.

Әйтергә кирәк, бу романнар әле үзләренең татар укучысына да барып ирешүләрен көтеп торалар.

Юк, Р.Мирхәйдәров җинаятьчел дөньяның елъязмачысы түгел, ул аны фәнни дәрәҗәдә өйрәнеп тикшерүче. Бу әсәрләргә күп кенә юридик басмаларда басылып чыккан бәяләмәләрдә авторның җинаятьчел мохитне дә, хокук мәсьәләләрен дә бик яхшы белүе ассызыклап әйтелә килә. Шунысын да өстәргә кирәк, Рауль Мирхәйдәров, иң беренче чиратта, социаль күзәтүләр авторы.

Рауль Мирхәйдәров романнарындагы сюжетларга охшаш сюжетлар хәзер һәркөнне газет-журнал битләреннән төшмиләр, ә җинаятьчел-криминал хроника телетапшыруларның үзәк эчтәлегенә әйләнде. Димәк, язучының әсәрләре әле озак, бик озак, ә бәлки, һәрвакыт заманча яңгыраш табарлар.

Язучының әдәби геройлары соңгы елларда безнең арада яшиләр. Алар — прокурорлар һәм депутатлар, сутенерлар һәм банкирлар, сәясәтчеләр һәм эшмәкәрләр. Болар хәзер бербөтен еланнар йомгагы булып әверелделәр, бертуктаусыз бер-берсен тешләшәләр, шуны безгә телевизор экраннарыннан күрсәтеп торалар, ә көндәлек тормышта үзләренең кара эшләрен башкаралар. Җинаятьчел дөньяның авыр чүкече җәмгыятьнең баш очында эленеп тора һәм ул юлында очраган һәрнәрсәне сытып-изеп китәчәк.

Иң яманы шунда, әлеге төзәлмәс яман шеш социаль бушлыкта тумаган бит, кызганыч ки, ул халык тормышының күңелсез-хәерчел асылыннан үсеп чыккан. Без аны үзебез тудырган. Күрәшмәсәк, мафия барлык халыкларны һәлак итәчәк. Р.Мирхәйдәров романнарындагы төп фикер әнә шул.

## 5

Рауль Мирхәйдәровның соңгы романы «Һәрнәрсәгә — акчалата» дип атала һәм авторның яшьләргә хас бер җиңеллек белән инде ирешелгәннәрдән осталыкның яңадан-яңа үрләренә күтәрелә алу сәләте белән гаҗәпләндерә. Аның иҗат диапазоны тагын да киңәеп киткән, сәнгатьчә иркенлек, масштаблылык табигый рәвештә үрелеп бара. Романдагы вакыйгалар Төньяк Кавказдан башланып китә дә Мәскәү ташкала аша Европа шәһәрләренә кадәр барып тоташа. Бер-берсенә үрелеп килүче берничә сюжет сызыгы исә әсәрнең тукымасын да шактый катлауландырган. Ләкин роман — чынбарлыкның хроникаль күчермәсе түгел, язучының бурычы бүгенге вазгыятьне аңларга тырышудан, тормышның иң яшерен тирән серләрен төшенүдән гыйбарәт. Автор тәңгәлләштерергә мөмкин булмаганнарны да тәңгәлләштерә ала — көндәлек чынбарлыкның эстетик сәнгатьчә чагылышын таба, башка сүзләр белән әйткәндә, ул «көн кадагындагы» мәсьәләләрне көчәнмичә генә әдәбиләштереп укучы алдына ачып сала.

...Затлы спорт костюмы кигән бер ир кеше караңгы август төнендә Грозныйга илтә торган юлда машина тук-

тата. Бу тәвәккәл качкын чечен әсирлегеннән ычкынган, куа килүчеләрен дә эздән яздырган, ә авыр сумкасы йөз долларлык акчалар белән шыплап тутырылган. Атаклы Казан рәссамы Николай Иванович Фешин әле ерак 1923 елда ук Америкага чыгып киткән, анда танылып, академик булган. Ә менә бу юл читендә басып торучы ир заты аның оныгы, бабасыннан рәсем сәнгате сәләтен алып калган Константин Николаевич Фешин — иң оста ялган акчалар ясаучы җинаятьче. Берничә мәртәбә төрмәдә дә утырып чыккан. Аны төрмәдән чеченнәр урлап алып киткәннәр һәм ул өч ел дәвамында яшерен бер остаханә-лабораториядә, Дудаевның булачак азатлык армиясе өчен, ялган долларлар суга. Бик нык әзерләнеп, оста кача бу Тоглар кушаматлы адәм, Мәскәүгә барып урнаша, типтереп яши башлый.

Әсәр әнә шулай мавыктыргыч башланып китә. Һәртөрле авантюристлар байлыкка коенып яшиләр. Фешинның күптәнге «тамырдашы-корешы», кәрт уены шулеры аңа үзенең биш бүлмәле зиннәтле йортын күрсәтә. Биредәге байлыкка исләрең китмәле! Әмма... Зәвыксызлык та күзгә бәрелеп тора, шулай булмый мөмкин дә түгел. Крезлар, Ротшильдлар, Гобсеклар — элекке заманның байлыкка табынучы атаклы затлары! Баш иегез дә тыйнак кына читкә тибәрелегез! Күрәсезме, сезнең урынга кемнәр килде! «Яңа урыслар!» Рауль Мирхәйдәров бу «яңа урысларның» гаҗәп төгәл социаль портретын сурәтли. Атаклы «законлы караклар», эшләре пешкән бизнесменнар, бер сәгать эчендә миллиардларны кесәләренә салган банкирлар — болар барысы да бер өер, бер рулетка өстәле артындагылар. Чит ил машиналары «чироки», «мерседес», «джип»ларда гына җилдерүче бу «җеннәрне» тәмле телле демократлар ирекккә чыгарган һәм алар менә хәзер тормыш чынбарлыгыннан роман битләренә күчкәннәр.

Үрелеп бара торган сюжет авторга әле бер, әле икенче персонажны «сәхнә алдына» чыгарып бастырырга һәм аңа төп рольне бирергә мөмкинлек тудыра. Бу «акча кортларының» һәркайсы шулкадәр үзенчәлекле, аларның теләсә кайсысы теге яки бу әдәби әсәрнең аерым герое яки антигерое була алыр иде, мөгаен.

Уйлап чыгарылган, әмма бик таныш типлардан җыелма образ итеп тупланган персонажлар янына Рауль Мирхәйдәров, һич курыкмыйча, тормышта чын булган киллер Александр Солоник-Македонскийны да китереп кертә. Газет битләрендә елгыр каләм кыштырдатучылар һич тоттырмас Солоник турында «бунтарь, җәмгыятьнең

санитары, җинаятьчелеккә каршы көрәшче, үтерүчеләрне җан тәслим кылдыручы, җәза кылычы...» кебек легендаларны сибеп кенә тора иделәр. Солоник үзе турында үзе дә демократлар колагын иркәләрлек әкиятләр сөйләүдән тартынмый иде. Салкын канлы, рәхим-шәфкатьсез бу кабахәт җан үзен шулай яңа Робин Гуд яки Дубровский итеп күрсәтергә ярата иде. Ут эчендә янып яткан Чечня-Ичкериядән Фешинның алып чыккан ялган долларларын талап алып, ул оятсызларча болай ди: «Тоглар, миңа бу акчалар Ил-Ватанны коткарырга кирәк!» Шулай итеп, ялган ватанпәрвәрлек тагын бер кат чираттагы җинаятьне аклау өчен кирәк булып чыга. Акча, акча, акча — менә хәзер яңа һәм бердәнбер Алла шул. Һәм ул бер Солоник өчен генә шулай түгел, ә «намуслы алыпсатарлык белән шөгыльләнәбез» дигән булып, кычкыртып талау юлына баскан, шуны үзенең шигаре иткән барлык «яңа урыслар» өчен дә шулай ул. Хәзерге бу «патриотларның» колачы гына икенче — «Төмән нефте, газ торбаүткәргечләре, өч-дүрт банк, газет-журналлар, телеканаллар».

«Сары шайтан» — алтын шаукымы туймас тамак эреле-ваклы түрәләрне дә читләп үтмәде. Кәрт сугу шулеры аргентинлы үзенең тормышта дөрес юл сайлый алмаганлыгына үкенә: «Дәүләт хезмәте буенча үсәргә иде миңа,— ди ул.— Чын-чынлап зур акчалар шунда гына әйләнә бит». Үзенә күрә бертөрле үзара тәэсир итү бара — элекке һөнәрмәнд караклар тыштан караганда, «ак якалы, затлы» түрәләр булып күренсәләр, хәзерге түрәләр бар булмышлары белән «караклар өеренә» әйләнеп беттеләр. Алар берләштеләр, ил-дәүләтне, хакимиятне үз кулларына төшергән урыс мафиясе Россиягә генә сыймый башлады — чит ил паспортлары алып һәм чит ил гражданнарына әверелеп, ата караклар (Березовский, Гусинский, Смоленский ишеләр) «яңа урыслар» кыяфәтендә дөньяны яулап алырга чыгып киттеләр. Алар хәзер Лондон, Парижда да, Тель-Авив, Амстердамда да, Милан, Женевада да үзләрен бик иркен тоталар. Әле моңа кадәр дөньядагы бер генә мафиягә дә дәүләт башында утыручылар белән шулкадәр тыгыз үрелеп-берләшеп бетү мөмкинлеге юк иде. Байлыкка һәм хакимияткә хуҗа булып алган урыс плутократлары дәүләтнең барлык юридик нигезләрен оятсызларча аяк асларына салып таптадылар.

Хәзер инде Рауль Мирхәйдәровны элекке стереотиплар һәм моңа кадәр билгеле булган караклар атрибутикасы гына канәгатьләндерми. Язучы бүгенге җинаять-

чел мохитнең вакытыннан элек тышкы төс-кыяфәтләрен үзгәртүләрен бик төгәл тотып ала, алардагы сыйфат үзгәрешләрен гаҗәеп бер осталык белән фаш итә. Карден осталары теккән костюмнар кигән, алтын чылбырлар таккан, газетча-зыялыларча сөйләшергә өйрәнгән бу адәм актыклары бик укымышлы-белемле күренә, тегеяки бу җинаятьне оештыруны да алар «эшлекле сөйләшүләр» дип кенә атый. Әмма язучының үткен карашы аларны, нинди генә кыяфәткә керсәләр дә, тиз танып ала — акча кортына әйләнгән бу кемсәләр, ул акчаларны тир түгеп эшләп алмый бит, ә төрле хәйлә-алдашулар белән җәмгыять кесәсеннән, безнең кесәдән каера.

«Һәрнәрсәгә — акчалата» романының төп герое Константин Фешин-Тогларга әйләнеп кайтыйк әле. Ул бит бик катлаулы, гадәти булмаган язмышлы кеше. Аның образын сурәтләгәндә авторның хәтта аңа ниндидер теләктәшлеге — симпатиясе дә сизелә. Р.Мирхәйдәров аны юкка гына үзенең якташы — тамырлары белән Казанныкы булса да, Мартукта туып-үскән шәхес итмәгәндер. Фешин-Тоглар белән Артур Шубарин бер-берсенә охшашлар. Юк, бу — тышкы охшашлык түгел. Алар һәр икесе дә хәзерге күчеш-үзгәреш чоры кешеләре, икесе дә, сәләтле һәм искиткеч җегәрле-энергияле, эшлекле-булдыклы булуларына карамастан, җәмгыять өчен кирәксез-яраксызлар. Шуңа күрә дә алар җинаять юлын сайларга мәҗбүр булганнар. Сәләтле-талантлы шәхесләр өчен җәмгыятьтәге тарихи шартларның яраксызлыгын күрсәтү нияте белән Р.Мирхәйдәров үз әсәренә чынбарлыкта булган өченче бер шәхесне китереп кертә. Ул Фешин-Тогларның бабасы, искиткеч талантлы Казан рәссамы, академик Николай Иванович Фешин. Ул Америкада дан казана. Гаҗәеп язмышлы бу рәссам үз илендә дә, Америкада да күпсанлы гүзәл әсәрләр иҗат иткән. Аның язмышы гомерен кысыр чәчәк булып бушка үткәргән оныгының фаҗигасен ача да сала. Хәтта Фешин-Тогларның сугышта бер кулын калдырып кайткан әтисе дә рәсем ясау сәләтеннән мәхрүм түгел, сугыштан соңгы ач-ялангач елларда ул да, рәсемнәрен базарда сатып булса да, тамак туйдыра. Ә менә Константин Фешин-Тоглар бабасы һәм әтисеннән мирас итеп алган сәләтен ялган акчалар ясауга сарыф итә. Гомер көзе якынлашканын сизенеп, ул да үзен кулга алырга тели, менә дигән остаханә оештыра, аның да чын рәссам буласы килә. Әмма соң шул инде. Буяу-пумалалары да, сәләте дә бар, ләкин рухын җинаять сазлыгы суырып алган... Әйе, соң шул инде.

Үзенең романнарында Рауль Мирхәйдәров җинаятьчелеккә каршы аяусыз көрәшкә күтәрелә, укучы алдында гына түгел, хокук саклау органнары алдында да мафиянең социаль табигатен һәм асылын ачып сала. Язучы бер әңгәмәсендә болай ди: «Безгә тырышып-тырышып мафиянең үлемсез икәнлеген исбат итмәкче булалар. Ышанам ки, аның белән әле чынлап торып беркемнең дә һәм бер көн дә көрәшкәне юк».

Романның сюжеты бүгенге көн чынбарлыгы белән искиткеч тыгыз бәйләнгән!

Фешин-Тоглар чечен әсирлегендә йөз долларлык акчалар сугу эшен җайга сала, дидек. Чын доллардардан һич тә аерып алып булмаслык ул акчаларның күпләп таралуы америкалыларны борчуга сала, алар доллар клишеләрен алыштырып карый, төрле саклану билгеләрен: рәсем-сызыкларын катлауландыра. Әмма Фешин-Тоглар ясаган долларлар барыбер алардан калышмый, аларны бернинди катлаулы аппаратлар да аерып ала алмый. Фешин-Тоглар үз долларлары белән ирек яулап ала, менә дигән йорт-остаханәле була, хәтта мәхәббәтне дә сатып алмакчы була.

Ә нәрсә ул Фешин-Тогларның ялган долларлары?! Шул ук вакытта Вашингтоннан Россиягә хәрби транспорт авиациясе белән йөзләрчә тонна чын долларлар кайтаралар бит. Йөзләрчә тонна! Фешин-Тоглар ясаган долларлар алардан миллион мәртәбәгә кимрәк. Россияне доллар басып алды. Фешиннныкылар да, Вашингтонныкылар да, Ирак «супердолларлары» да һәркайда кулланышта — кибетләр, казинолар, кунакханәләр, банкларның алмашу пунктлары... Долларга хәзер Россиядә һәрнәрсәне сатып алып була: йорт-җир дисеңме, мебельме, чит ил маркалы машиналармы... Хәтта намусны да! Долларларга (ялганмы ул чынмы — барыбер, алар буталып беттеләр инде!) нефть ятмалары, завод-фабрикалар, төрле комбинатлар, телевидение каналлары, хәтта элекке үтә яшерен «почта ящиклары» дип йөртелгән объектлар да сатып алындылар инде.

«Һәрнәрсәгә — акчалата» романының иң мөһим идеясе дә шунда: ул долларлар кайда гына сугылып, ничек кенә килеп кермәсеннәр, алар Россиядә «юылалар» һәм Россия милке-мөлкәте белән тәэмин ителәләр. Шул рәвешле, илдә зур ялган һәм җинаять эшләнә. Бу — икътисади диверсия.

Хәзер инде Фешин-Тоглар долларлары да, Америкадан кайтарылганнары да, Якын Көнчыгыштан кергәннәре дә үз акчабызга әйләнде. Һәрнәрсәгә шул акчалар

белән түләп, долларларны үз тормыш-көнкүрешебезгә кертеп, үз-үзебезне сатканыбызны сизми дә калдык инде без.

Язучының бар байлыгы-мөлкәте — аның китаплары. Ул китаплар укучы тарафыннан сатып алынган очракта да, язучыныкы булып кала бирә — аның авторлык хокукы бар. Шуңа күрә дә китап товар буларак бәһаләп бетергесез милек ул.


Без Рауль Мирхәйдәровның бүгенге болгавыр заманның төзәлмәс яраларын бәян иткән, чынбарлыкның иң кискен борылышларын сурәтләгән китапларын сатып алабыз икән — автор белән бергә без дә аларның хуҗасы булабыз.

Язучыдан үзенеке дә һәм инде безнеке дә булган китапларына култамга-автограф язып бирүен сорыйсы гына кала.

*Сергей Алиханов, академик,*
*2001 ел, Мәскәү*

# ИРТӘЛӘГӘН САГЫШ

**Роман**



*Ренар улыма*
*багышлыйм бу әсәремне.*

*Автор*

Без, агым белән көрәшеп, һаман алга йөзәргә тырышабыз, агым исә безнең көймә-каекларыбызны һаман кирегә, үткәннәребезгә кайтара тора...

*Ф.С.Фицджеральд*

## I

Ни өчен шундый нәфис чәчәк исеме белән аталганы һич аңлашылмаган, шәһәрдә яманаты чыккан «Лотос» кафесы тәбәнәк кенә, зур гына бер пыяла гөмбә иде. Эчендә булсын, тышында булсын — ни өстәл-урындыклары, ни таяныр җире юк үзенең. Алай гынамы әле, килгән-киткән кешегә эчкә үтәргә дә мөмкин түгел, анда бу гөмбәнең хуҗабикәсе хакимлек итә. Бөтен тирә-ягы әрҗәләр, тартмалар, ватып боз тутырылган алюмин савытлар белән тулган булыр. Хуҗабикә бирегә йөрүчеләр белән саргаеп беткән пыялалы тар тәрәзә аша гына аралаша. Шулай булгач, «Лотос»ны уңайлылыгы яки эчке бизәлеше белән үзенә тарта дип һич әйтеп булмый.

Рушан Дасаев бирегә эшеннән туп-туры килә һәм тышкы кыяфәте белән даими йөрүчеләрдән аерылып та тормый диярлек: күпләренең кулларында — портфельләре, «дипломатлар»... Байтагының бу кафега шулай ук туры эштән-хезмәттән генә килгәнлекләре күренеп тора, шунлыктан Рушан да үзенең «кейсы» белән алардан һич аерылмый иде.

Кафеда синең теләгеңне бик тиз үтиләр: Рушан, бер сумын сузып, минераль су сорарга да өлгермәде, паригы бер якка янтая төшкән хуҗабикә, җитез-төгәл хәрәкәтләнеп, аның каршысында торган стаканны, башланган шәраб шешәсеннән, тамчысын да түкмичә, мөлдерәмә тутырып та куйды. Цирк артистының зур осталык белән башкарган номеры кебек бу эш-гамәл Рушанны сокландырды, ул, минераль су турында бөтенләй онытып, стаканны бер каршылыксыз кулына алды. Кулында гадәти стакан булгангамы, аңа беркем дә игътибар итмәде.

Бу кафеның ниндирәк урын икәнен белсә дә, Рушанның кызыксынуы кимемәде, ул иркенләп күзәтә башлады.

«Лотос» тирәсендә аңа бөтенләй таныш булмаган тормыш хөкем сөрә иде, биредә бары тик әчкечеләр һәм махмырдан интегүчеләр генә җыела, дисәң,— ашыгыч нәтиҗә ясау булыр, гәрчә андыйлары да, мондыйлары да бардыр, мөгаен.

Бирегә бик кызыклы халык җыела икән. Кара син: нефтедолларлар, «Уотергейт» һәм еврокоммунизм, экстрасенслар һәм тамил хирургиясе, агропромкомплекслар һәм компьютерлар турында нинди генә әңгәмәләр кормыйлар! Дасаев хәтта кемнеңдер Морис Бежар балеты турындагы фикерен дә ишетте, икенчесе аңа Джон Кранконың «Штутгарт» балетын мисалга китерде, әмма аннан соң икесе дә уртак бер фикергә килеп, сүзне Герберт фон Кароян оркестрына күчерделәр, аннары Карояннан Единбургтагы ел саен үткәрелә торган хәзерге заман сәнгате фестиваленә сикерделәр, сүз арасында гына композитор Бенджамин Бриттен белән дирижер Зубен Меттаны да телгә алдылар, аннары фестивальдән — Америкадагы Гугенхайм фондына һәм Рокфеллер үзәгенә... Чынлап та, зыялы джентльменнар клубы диярсең, әңгәмәләре дә Рушаннарның прораб бүлмәсендәгедән яки тресттагыдан күпкә кызыклырак — анда алар күбрәк көндәлек тормыш турында гына бәхәсләшәләр иде.

Дасаев элек үзе еракта гына күреп йөргән, көн дә шушында вакыт үткәргән халыкны күзәтә, ашыкмый гына күзәтә. Ул адәмнәрнең гомуми бер уртак билгеләре бар — берсенең-бер өстендә яңа кием булмас, әйтерсең алар кайсыдыр бер көннән башлап андый вак-төяккә сукыр тиен дә тотмаска сүз биргәннәр. Аларның киемсалымнарына игътибар беләнрәк караганда, андый «сүз бирү»нең кайчанрак булганын да чамаларга мөмкин иде.

Мәсәлән, дүрт төймәле, бер капламлы костюм кигән һәм балаларныкына охшаш кыска галстук таккан кеше күптән, әле Дасаев институтта укыган елларда ук шундый «сүз биргән» булгандыр. Аның янындагы ир кеше галәмәт киң якалы пинжәктән, аска таба киңәеп киткән клеш балаклы чалбардан, көязләнеп йөрергә яратучылар ун-унике еллар элек шулай киенәләр иде. Монда алтмышынчы елларда бик модалы булган, әмма күптән төсен җуеп, кыршылып беткән дакрон костюмлылар да бар.

Нейлон күлмәкләр, твид тройка костюмнар, тәүге вельвет пинжәкләр, мамык кытай пуловерлары, очлы башлы

мокасиннар, биек авыр платформа табанлы туфлиләр, төрле фасон эшләпәләр, туза белмәс габардин һәм бостон костюмнар, киң каптыргычлар һәм галстук булавкалары... Болар барысы да игътибарлы кешегә ул кием хуҗаларының язмышы турында күп нәрсәләр сөйли иде. Тузып-таушалып, кыршылып-шомарып беткән бу әйберләрнең һәммәсе кайчандыр, гади кием-салым гына булмыйча, үз заманы өчен купшы-нәфис, бик тә модалы булганнар бит инде. Алар үз хуҗаларының да модалардан калышмыйча матур яшәгән, җегәрле-көчле вакытларының телсез шаһитлары да иде.

Үткәннәр турында уйлана-уйлана, Дасаев әлеге төрле стильдә, төрле чуар төсләрдә киенгән бу кешеләрнең барысына да уртак бер үзенчәлеккә дә игътибар итте: аларның һәркайсысы киемен чиста һәм пөхтә йөртә иде, инде күптән искереп беткән әйберләргә ул кадәр җентекле пөхтәлек кирәкмәстер дә, бәлки. Дасаев тагын бер нәрсәгә игътибар итте: галстук болар өчен иң кирәкле әйбер, ул хуҗасының дәрәҗәсен билгеле, аны бөтенләй упкынга тәгәрәүдән саклый шикелле. Аның нинди булуы мөһим түгел: таушалып беткәнме, кыршылып шомарганмы, капронмы-йонмы, атласмы-ефәкме, күнме-башкамы, бәйләп куелганмы — резин шнурлымы, тармы-киңме, озынмы-кыскамы — анысы барыбер, бары тик галстук кына булсын.

Тагын Рушан шунысын да шәйләп алды: күпләрнең пинжәгендәге күкрәк кесәсеннән чиста-пөхтә кулъяулык та күренеп тора иде, аннары байтагының аяк киемнәре дә ялтыратып-шомартып куелганы күзгә ташлана. Әмма иң гаҗәбе шул: монысын игътибарсыз кеше дә күрми калмас иде — болар арасында бер генә кырынмаган кеше дә юк, барысының да чәчләре, бөртеге-бөртеккә дигәндәй, матурлап таралган булыр. Күрәсең, бу мохиттә үзенең язылмаган кануны, эталоны яки бер билгеле баскычы — дәрәҗәсе бар, шуннан түбән тәгәрәү әдәпсезлек санала булса кирәк.

Дасаевны бу «Лотос»ка мәгънәсез-буш кызыксынудан зуррак-мөһимрәк нәрсәдер тартып тора һәм ул бирегә, алдан әзерләп куелган бер сумын учлап, еш кергәли иде. Бер сумнан зуррак акча сузсаң, мондагыларның үзенә ышанмый башлаячакларын ул сиземли, тоя иде.

Ул килгән саен аның белән сүзсез генә, әмма әдәп саклап, ә кайберләре хәтта нәзакәтле итеп баш кагып исәнләшәләр, кагыйдә буларак Дасаевтан өлкәнрәкләр пеләшләнгән башларындагы эшләпәләрен джентльменча бер инсафлылык белән күтәреп куялар, төс-кыяфәтен

җуйган ул баш киемнәре мондый тәкәллефлеккә һич ятышмый — Рушан ирен читләренә кунарга торган елмаюны көчкә-көчкә генә басып кала иде.

Әмма аңа күрсәтелә торган иң зур хөрмәт,— ә ул, бәлки, һәр яңа кешегә булган гадәти игътибарлылык кынадыр,— анысын Рушан аңлап та бетерә алмады — башка нәрсә иде. Рушан тиз һәм оста итеп шәраб салып бирелә торган тәрәзә янында бервакытта да ыгы-зыгы, тәртипсезлек юклыгына, берәүнең дә чиратсыз керергә маташмавына игътибар иткән иде инде. Һәрвакытта да диярлек чират булса да, күрәсең, андый тәртипсезлек зур әдәпсезлек санала иде. Менә шунысы сәер дә шул: Дасаевны ни өчендер башкалардан аерыбрак куйдылар, аның тавыш-тынсыз гына чират койрыгына килеп басуы була, алдында чират торучы кеше, борылып, аны үзенең алдына басарга ымлый, икенчесе дә, өченчесе дә шулай эшли — кыскасы, Дасаев, рәхмәтләр әйтә-әйтә, күпләрнең тәкатен корыткан әлеге тәрәзә буена барып җиткәнче шулай итәләр иде.

Ни гаҗәп, аралашу-гәпләшү өчен шәһәрнең төрле почмакларыннан җыела торган бу халык арасында ябышкакбәйләнчек гамәлләр дә, тәкәллефсез дорфа тупаслыклар да юк иде. Ир-ат күбесенчә кечкенәрәк төркемнәр булып оеша, әмма ул төркемнәр ярты сәгать саен диярлек яңарып тора: берәүләр китә, икенчеләре килә. Аларны нинди мәнфәгатьләр берләштергәне Дасаевка һич аңлашылып бетми иде. Рушан шикелле үк, стакандагы шәрабын йотказалап вакыт үткәрүче ялгызлар да аз түгел иде биредә, андыйларның ялгызлык иркенә кагылмыйлар, җаны теләгән — елан ите ашаган дигәндәй,— рәхим ит, агай-эне — синең яныңа берәү дә килеп сырышмас. Шулай да Рушан сизеп тора: теләк белдереп, бер ым гына как — әңгәмәдәшөстәлдәшләр хәзер табылачак. Биредә беркем дә берәүне дә ашыктырмый, шулай ук беркемне дә ирексезләп тотмый, һәркем үз вакыты белән «өлгереп җитә», бер бөтеннең аерылгысыз кисәге булырлык дәрәҗәгә ялгызы ирешә һәм, «Лотос»ка тәүге тапкыр нинди кием-кыяфәттә килеп кергән булса, балавыз сыннар музеендагы шикелле, нәкъ шул кыяфәттә ахыргача катып кала.

Бу «пыяла гөмбә» тирәсендәге хәлләр, андагы вазгыять Дасаевка берьюлы гына ачылып-аңлашылып та бетмәде. Әмма үз күзәтүләреннән чыгып ясаган ачышлары аны таң калдыра иде. Ул шуны абайлап алды: «Лотос» янында, һич югында, ачыктан-ачык, башкаларга сиздереп, берәү дә беркемнән дә әҗәткә акча сорамый һәм алмый да.

Башка сыраханәләр тирәсендәге кебек, кемнәрнеңдер тиеннәр җыеп торганын күрүне күз алдына да китереп

булмый. Бер стакан портвейн өчен сузылган бер сумнан көмеш ун тиен сдача кайтарылырга тиешлеген һәркем белеп торса да, беркем дә сорап маташмый, күпләргә ул, күрәсең, әле теге, мул-иркен яшәгән элекке тормышында рестораннарда «чәйлек» калдырган шикелле юмарт бер гамәл булып тоеладыр. Бервакыт Рушан агачлар арасындагы күрше юл-сукмактан бөтенләй төс-кыяфәте калмаган бер исерекбашның «Лотос» ягына моңсу караш ташлап үтүен күреп калды. Әмма ул исерекбаш бирегә якын килергә базмады — ниндидер «ярамый», табу-тыю кебек нәрсә дә бар, ахрысы, биредә. Дасаевка монысы да аңлашылып бетми иде.

Шулай бервакыт өендә, «пыяла гөмбә» әһле-халкы турында уйланып утырганда, аның зиһене ачылып киткәндәй булды: «Лотос» — һаман да тормыш төбенәрәк тәгәрәүчеләр өчен бер чик, соңгы бастион лабаса! Үзләре өчен үзләре билгеләгән бер дәрәҗәне, билгеле бер статусны саклап, әле һаман да бирегә килеп йөри алганда, болар әле үзләрен хөрмәткә лаек кешеләр дип саный иделәр булса кирәк. Ә, бәлки, тагын да гадирәктер — алар үзләрен эчкечеләр арасында өстен катлам — элита итеп сизәләрдер? Әлбәттә, шулай: никадәр көлке һәм моңсу тоелмасын — элита! Шуның өчен — галстуклар, илтифатлы-әдәпле сөйләшүләр, башка кешеләр арасында күптән онытылган, табигый булмаган нәзакәтлелек, күптән юылмаган, коелып-сирәкләнеп беткән чәчләрне тырышып тарап куюлар, каешланып беткән пинжәкнең күкрәк кесәсендәге кыланчык кулъяулык... Һәм аларның югалган абруйларының шәүләсен булса да саклап тотарлык дөньядагы бердәнбер урын — шушы «Лотос», ул, батып баручы өчен салам шикелле, үзенә тартып тора. Үзенең бөгәрләнеп беткән, бәлки әле, кимсетелүләр белән эшләп тапкан бер сумына бер стакан шәраб алып эчкәндә, эчүче үзенең күпсанлы дошманнарына: «Күрегез, шул берлекне тотып, шешәгә дип, кибеткә йөгермим, капка төбендә өч борынга да чамалап тормыйм. Минем өчен эчү мөһим түгел, мин кафега кызыклы кешеләр белән аралашырга килдем — карагыз, кемнәр генә юк биредә!» — дип әйтәдер шикелле.

Сөйләп торасы да юк, «Лотос»ка кемнәр генә килми дә, нинди генә чуар халык җыелмый! Күпләр бирегә казна хезмәтеннән соң сугылып чыга, хуҗалары кебек үк таушалып беткән портфельләре шул хакта сөйли, шулай да ешрак күптән модасы чыккан, кулланылыштан төшеп калган күн папкалар худта. Ул портфель-папкаларның хуҗалары хезмәт баскычларыннан көннән-көн түбәнрәк тәгәрәүче, төрле дәрәҗә-вазифа үтәүче белгечләр иде. Алар

соңгы елларда бик үрчеп киткән ниндидер конторларда, ширкәтләрдә, җәмгыятьләрдә һәм тагын шундый әллә нинди урыннарда эшлиләр иде булса кирәк, чөнки аларны нинди дә булса җитди, абруйлы хезмәткәрләр итеп күзаллау кыен иде.

Дасаевның «Лотос» тирәсендәге әңгәмәләрнең бик күптөрле һәм зыялы булуы турындагы беренче тәэсирләре тиздән эреп таралды, юк, бирегә йөрүчеләр кинәттән генә еврокоммунизм яки Тибет медицинасы турында сөйләшүләрдән туктаган өчен түгел иде бу. Бу әңгәмә-сөйләшүләрнең төрлелеге аны һаман да гаҗәпләндерә, әмма ул икенче бер нәрсәне дә аңлап алды: сөйләшүләр очраклы гына, өстән-өстән, әпен-төпен генә була, алар, шул ук портфель яки галстуклар шикелле, бу кешеләргә үзләрен әле һаман да башка чын, рухи тормышка катнашлары бар кешеләр итеп тоярга ярдәм итә иде.

Кешеләргә хас булганча, яңаны белергә тырышу, нәрсә өчендер кайгыру-борчылу, кемнәрнеңдер кайгышатлыкларын уртаклашу кебек гап-гади хисләр болар өчен тормыш ихтыяҗы булудан туктаган инде. Аннары эштә дә,— әгәр чынлап та эш-хезмәт урыннары булса, әле портфельләр генә моңа мәҗбүри ышандыра алмый бит,— боларны кемнәрдер җитди кабул итәме икән, өйләрендә, гаиләдә дә, мөгаен, шулайдыр. Ә аларның һәркайсына да игътибар кирәк, ничек кенә кирәк әле! Бездә бит Америкадагыише Гайд-парклар юк, булыры да күренми, ә «Лотос» — менә ул, янәшәңдә генә, биредә сине игътибар белән тыңларлар, сүзләреңне хуплап каршы алырлар йә кире кагарлар, биредә син ялгыз түгел, син үз кеше. Менә шуңа күрә дә алар, газет-журналлардан алынган яки радио-телевидение аша ишетелгән тәэсирле өзек-төтек хәбәрләрне башларына дыңгычлап тутырып, үзләренең шушы «Гайд-паркларына» киләләр — хәзерге заманда хәбәрдарлык артыгы белән алып ашкан, ә боларның буш вакытлары күптин-күптин дә күп.

«Лотос»ка йөрүче бу бәндәләрнең күпчелеге үзен тыныч-ипле тота, ашыкмый-кабаланмый. Кайберләре хәтта куркып-өркебрәк, сак кылана — андыйларын тормыш бабай шактый тукмаган бугай, алар инде бер генә янмаганнардыр. Боларның күзләрендә өмет уты сүнгән, күренеп тора: ни-нәрсә өчендер көрәшү түгел, үзләре өчен дә көрәшерлек көч-җегәр калмаган аларда.

Үзләрен иркенрәк тотучылар иҗат кешеләре яки иҗат кешесе булып күренергә теләүчеләр. Яланаякка сандали кигән, кайбер җирләре тәмәке уты төшеп янгантишкәләнгән җиңел синтетик курткалы берәү шактый

шау-шулы иде. Таушалган кыяфәтле, сары чәчле бу кеше үзен һәркемгә журналист дип атый. Ул уңга да, сулга да атаклы журналистларның исемнәрен сибеп кенә тора, бик белдекле кыяфәт белән, сер итеп кенә, тиздән булачак нииндидер мөһим үзгәрешләр турында, кемнәрне кайдан «тәгәрәтәчәкләре», кемнәрне кайда күтәрәчәкләре турында сөйли. Имештер, бу хакта әле бик ышанычлы, тар даирәләргә генә билгеле. Аның үзен, имеш, әле бер, әле икенче абруйлы газетка эшкә чакырып кына торалар, әмма ул үзенең алтын каләмен коллыкка сатарга теләми, чөнки әлеге редакцияләрдә җыен ялагай, җыен сәләтсезләр утыра, ә ул исә үз таланты белән аларга уңыш китерергә теләми. Әле артык картаерга өлгермәгән бу адәмгә газета редакцияләренә түгел, рәтле-юньле башка берәр җиргә дә инде юллар ябык икәнлеген аңлау өчен, аңа аек күз белән бер карау да җитә иде. Моңа нинди дә булса эшне ышанып тапшырганчы, шактый озак баш ватарга туры килер иде.

Кафега йөрүчеләр ниндидер бер шагыйрьнең пәйда булуын аерым бер җанлылык белән каршы алалар, аны яратканнары сизелеп тора. Ул үзенең шагыйрь икәнлегенә, башкаларны ышандырырга теләүдән битәр, бигрәк тә үзе ышанырга теләгәндәй, буаз күседәй бүлтәеп торган иске портфеленнән әледән-әле таушалып беткән газетлар һәм тышлыгы төшкән бер журнал тартып чыгара. Күләме һәм форматына караганда, журнал һич тә әдәби түгел. Менә шуның бер битендә шагыйрьнең бер бәйләм шигырьләре басылган икән. Шигырьләре янында авторның фоторәсеме дә булган бу журнал шагыйрь өчен иң кадерле әйбер иде. Айныткычларга эләгеп, анда иҗат кешесе буларак аерым мөнәсәбәт таләп иткән очракларда бу журнал шагыйрьгә байтак игелекләр күрсәткән, дигән имеш-мимешләр дә йөри.

Болай карап торуга шагыйрь «Лотос»ка йөрүче башкалардан тышкы кыяфәте белән берничек тә аерылып тормый: шул ук ике якка ачып куеп, шомартып таралган классик прическа, каешланып-ялтырап торган костюм, елның теләсә кайсы фасылында аягында туза белмәс каучук табанлы кышкы ботинкалар һәм биредәге чуар халыктан аерып торучы иң абруйлы атрибуты — җыерчыклы нечкә муенындагы җете кызыл яулык. Шагыйрь дә беркайчан да портвейнга чират тормый — халык аны хөрмәт белән чиратсыз үткәрә. Эчеп алгач, ул бик тиз усаллана башлый, шуның белән башка ипле-тыныч кешеләрдән ямьсез якка аерылып тора, кычкырып-кычкырып шигырьләрен укырга тотына, аларны әшәке

сүзләр әйтә-әйтә шәрехли — мондый йөгәнсезлек бер аңа гына рөхсәт ителә. Мөгаен, кайчандыр аның Ходай биргән сәләте дә булгандыр, әмма эчтән буып алган усаллыгы-явызлыгы аңа чын шагыйрь булырга мөмкинлек бирмәгән — һәрхәлдә, Дасаевка шулай тоела. Шагыйрьнең шигырьләре дә рәхимсез һәм күңелсез-хәерсез иделәр. Еш кына Серж (аның исеме шулай иде) портфелен онытып чыгып китә, портфельне кадерләп кенә «пыяла гөмбә» хуҗасына тапшыралар һәм ул шунда, хуҗасын көтеп, берничә көн, ә кайчакта берәр атна да ята, бу вакытта шагыйрь, күрәсең, газет-журнал редакцияләрендәге мөхәррир түрәләр белән сугышып-талашып йөри.

Бирегә Серждан башка да берничә шагыйрь кисәге килгәли. Әмма аларның берсе дә эффектлы кызыл муен яулыклы мэтр кебек данлыклы түгел һәм портвейнга чиратта да гомуми нигездә басып торалар иде. Мөгаен, шуңа күрәдер алар «елгыр каләмдәшләренең» «Лотос»тагы популярлыгына ачыктан-ачык көнләшеп карыйлар, аны демонстратив төстә инкарь итәләр, аның белән сөйләшмиләр, үзара бик дус булып кыланалар һәм бик белдекле кыяфәт белән зыялы әңгәмәләр коралар — Морис Бежар балеты турындагы фикерләрне Рушан нәкъ менә шулардан ишеткән иде. Алар Серж өметсез искергән шагыйрь, аның рифмалары белән ерак китеп булмый, дигән гайбәтләр таратсалар да, «Лотос»ның беренче шагыйренең данына зыян китерә алмыйлар, әле киресенчә, данын гына арттыралар. Ни генә димә, аларның берсенең дә шигырьләр бәйләме белән рәсеме басылган журнал юк. Кыюлыклары да шулчаклы гына шикелле — берсебер, тәвәккәлләп, кычкырып үз шигырен укымас, юкса Серж булмаганда, җәмәгатьчелек, эстетик ачлык тоеп булса кирәк, «укыгыз әле» дип сорый да торган иде. Ләкин бер-берсенең шигырьләрен алар үзара укыштыралар иде — Рушан анысын берничә мәртәбә ишетте. Алар кайвакытларда үз араларына берничә музыкантны да алалар, гаҗәбе шул ки, музыкантлар бирәдә иң ишле халык иде.

Алар арасында үзләренең танылмаган композиторлары да бар, дирижерлары гына юк иде бугай, хәер, монысын Рушан тәгаен генә әйтә алмый. «Пыяла гөмбә»гә корсак үстергән бер юан гына адәм кергәләп йөри бит, аңа: «Иптәш прокурор...» — дип мөрәҗәгать итәләр.

Үзе «Лотос»ка сугылгалап йөргән арада, Рушан бу сәер упкынга килүчеләрнең төрлесен күрде. Инде күз ияләшеп беткән кайберәүләр яки хәтта тулы төркемнәр кинәт кенә юкка чыгалар да аларның урынын үзенә таныш булмаган, әмма «пыяла гөмбә»дә үз кеше саналган

башка кемсәләр ала иде. Дасаев «Лотос»тан шулай әледән-әле юкка чыгып югалып торганнарның кайларга барып эләгүләрен, кайларда вакыт үткәрүләрен күңеленнән генә исәпләп чыгарырга тырыша. Ул аларның язмышына һич тә битараф түгел, ул аларны ихластан кызгана, бигрәк тә әле кешелекләрен бөтенләй югалтып бетермәгән, соңгы көчләрен җыеп, көндәлек гадәти тормышка теше-тырнагы белән ябышып калырга тырышкан, ничек кенә көлке яңгырамасын, үзләрен әле кеше дип исәпләргә мөмкин булган, шушы «Лотос»ны котылып калырлык бер утрау итеп күргән, әмма ихтыярлары инде бөтенләй дә сынган бәндәләрне кызгана иде ул. Мондый фикер дә очраклы гына тумаган иде.

Рушан тагын ничектер Инженер кушаматлы урта яшьләрдәге бер кешегә игътибар итте. Аның турында «башлы мужик», кайчандыр зур начальник та булган бугай, дип сөйлиләр иде. Вакыты-вакыты белән нинди булса да хезмәттәдер, берәр шөгыле бардыр кебек тоелса да, хәзер Инженерга карап, аның даими хезмәт урыны булуы турында фараз кылырга мөмкин түгел иде шикелле. Кайдадыр нәрсә беләндер шөгыльләнгән чагында, бу кеше гаҗәп үзгәреп китә иде — моны бер Дасаев кына түгел, «Лотос»ка йөрүче башкалар да сиземли. Андый көннәрдә Инженер янында халык аеруча мыжлап тора, кызып-кызып сөйләшүләр башлана. Юк, Инженерның акчалы чагы булганга түгел, барыннан да бигрәк аның бик мавыгып үзенең хезмәте, планнары турында сөйләве, үзе эшли торган урында хуҗалык бик таркалган икән дә, шунда ул әллә нинди реформалар үткәрәчәк икән — менә шул хакта кычкырып-кычкырып аңлатулары кызык иде аның. Дасаев бу кешенең «туры юлга басуы» өчен дә, күзләрен очкынландырып, Инженерның сөйләгәннәрен ихлас көнләшү белән тыңлап торучы башкалар өчен дә сөенеп куйган иде.

Аннары Инженер кинәт юкка чыкты. Рушан үзе монда йөргән вакыт эчендә берәүнең булса да шәраб сөременнән котылганын күргән шикелле булган иде. Әмма күп тә үтмәде, Инженер, үзенең дә, башкаларның да өметләрен аклый алмаганлыктан, ничектер үзен гаепле сизеп, кыенсынып, тып-тын гына, кырын-кырын гына, бик күзгә чалынмаска тырышып, яңадан «Лотос»ка килеп керде. Аның таушалып беткән төс-кыяфәте күптән инде хезмәт планнарын онытканлыгын, кайда туры килсә, шунда кунып йөргәнлеген, ә соңгы көннәрдә вакытын, мөгаен, базар һәм вокзалларда үткәргәнлеген бик ачык күрсәтеп тора иде.

Инженерның «пыяла гөмбә»гә әйләнеп кайтуында башкалар аның гына түгел, үзләренең дә өмет-хыяллары җимерелгәнлеген күрделәр. Әмма шул ук вакытта аның бу юлы да үзендә упкынга бөтенләй үк тәгәрәмәслек көч тапканын, үзен азмы-күпме тәртипкә китереп, яңадан «Лотос»ка әйләнеп кайта алуын мөһим бер гамәл итеп бәяләделәр. Кафега йөрүчеләрнең һәммәсенең дә диярлек вакыт-вакыт шушы каһәр суккан юлны үткәнлекләренә Дасаев шикләнми иде инде.

Кайчандыр зур өметләр баглаган сәләтле-талантлы байтак кына кешеләр бирегә килеп сөртенә шул. Дасаев еш кына бер кызганыч бәндәне күрә, ул — элекке музыкант, пианист, инде унсигез яшендә үк симфоник оркестр белән концертлар куеп йөргән. Аңа гаҗәп матур киләчәк юраганнар. Ә хәзер, эчеп юкка чыккан бу маэстрога карап, Дасаев, бик теләсә дә, аның шундый данлыклы үткәнен күз алдына китерә алмый иде.

Бервакыт Дасаев бирeдәге еш алышынып торган төркемнәр арасында үз вакытында бик атаклы булган футболчыны күреп алды, ул йөз меңләгән футбол сөючеләрнең Алласы, аңа гашыйк-мөкиббән китүчеләрнең исәбе-хисабы юк иде. Матбугат аны кайвакыт Пеле һәм Беккенбауэрларга тиңләде.

Сәләтле һәм гаҗәеп оста уены белән бихисап кешеләрнең күңелен яулап алган, кайчандыр көч-җегәре ташып торган бу чибәр, яшь егетне күрү Дасаевны көтелмәгән бер фикергә китерде. Табиблар, им-томчылар гомер бакый кешенең гомерен озайту, аны яшәртү чараларын эзләгәннәр. Бу авыр, четерекле юлда кешелек дөньясы ниндидер уңышларга ирешсә дә, аның нәтиҗәләре бик кечкенә, шулай да ниндидер мөмкинлекләр барлыгы бераз өмет тә калдыра шикелле. Аның каравы кеше фән ярдәменнән башка да үз-үзен бетерү юлында гаять зур уңышларга ирешкән! Рушан әкренләп шәраб диңгезенә батып баручы әлеге футболчының хәрәкәтчән-җитез, сыгылмалы-көчле, искиткеч акыл-зиһенле, яшь-чибәр чакларын яхшы хәтерли әле. Ә хәзер...

## II

Рушанга инде илле тулып килә. Аз түгел... Хәтерли, Фадеевның «Тар-мар» романыннан ул шундый бер җөмлә укыган иде «Мунчада кырык яшьләрдән узган карт юынып утыра...» Әгәр дә инде кырык яшьтә үк карт икән — димәк...

Менә аңа да гомер йомгагын төенләргә иртәрәк әле. Әмма еш кына күңелен сагыш-моң баса һәм ул Ташкенттагы фатирында, күптән юылмаган тәрәзә каршында, озын кичләрдә отыры озаккарак калып басып тора, пычрак ишегалдында аңа әллә нинди сәер күренешләр күзаллана. Кайвакыт аңа башы-азагы булмаган бер үк китапны, бик күп геройлары чалынып-чалынып кына киткән бер романны үзе берьюлы яза да, укый да, экранлаштыра да шикелле тоела. Әмма ни өчендер ешрак полуторка машина әрҗәсендәге малай хәтеренә төшә...

1949 ел. Рушанга сигез яшь.

Бәйрәмчә кызылга төренгән, һәр җирдә транспарантлар балкып торган көнне ул яхшы хәтерли, фронтовик үги әтисе эшли торган җирле артельнең полуторкасын күрә. Менә машина аулак райүзәкнең күрше урамына парадка кузгалып китәргә җыена, әмма байраклар тоткан кешеләр белән дыңгычлап тутырылган машина әрҗәсенә иң соңгы мизгелдә теге малайны да күтәреп алалар. Әкәмәт малай ул — өстендә бугазына кадәр төймәләнгән яшькелт хаки төсендәге китель, пөхтә чалбар, тик лампаслары гына юк.

Лампаслар турындагы уй шунда ук күңелгә килә, чөнки кая карама, тирә-юньдә Юлбашчының төсле портретлары — алар менә дигән яхшы кәгазьгә басылганнар, фанер такталарга пөхтәләп ябыштырылганнар, кайберләре пыялалы рам эчендә, аларны һәр колоннаның башында күтәреп баралар. Малайның да бәйрәм костюмы Юлбашчыныкы төсле үк, ә сул як күкрәк кесәсе өстендә чит ил ордены балкый, күрәсең, әтисенекедер. Аксыл җитен чәчле малайны машинага күтәреп биргән ир кешенең күкрәге дә орден-медальләр белән тулган, алар атлап йөргәндә, алтын-көмешләрен, бакырларын балкытып, искиткеч матур чыңлыйлар.

Бәйрәм утренникгында бүләк алырга артель янына җыелган малайлар машина ягына көнләшеп карап-карап куя. Аларга бит «Кызыл мәйданга» — партия райкомы янындагы мәйданчыкка җәяү тәпиләргә туры киләчәк. Андагы тузанлы кечкенә бакча эчендә бер-берсенә каракаршы баскан кыска аяклы ике гипс юлбашчы һәйкәле тора, аларны бәйрәм хөрмәтенә алтынсу төскә буяп, яңартып куйганнар.

Генераллиссимус кебек итеп киендерелгән малай Рушанга таныш түгел, артельдәге утренникта да юк иде ул. Рушан янында торган иптәшеннән ул бәхетле малайның кем икәнлеген сорый. Арттан кемдер: «Женя Дудченко»,— дип пышылдый, ләкин бу исем-фамилия Ру-

шанга бер нәрсә дә сөйләми, аларның мәктәбендә андый малай юк.

Европа белән Азия чигенә терәлеп үк диярлек утырган дала поселогы Мартук зур да, бик кечкенә дә түгел, аның төп дәрәҗәсе-абруе шунда — ул тимер юл буенда. Ерактагы әкияти шәһәрләргә: Ташкент, Алма-Ата, Сталинабад, хәтта ниндидер Курган-Түбә яки Җәләлабадка ашыгучы поездларның һәрберсе биредә туктап ала.

Сугыштан соң поселок дәррәү үсә, зурая башлады, райүзәккә даладагы караңгы авыллардан һәм Урал аръягындагы ерак казакъ станицаларыннан кешеләр агылды, әмма күбрәге Көнбатыштан килгән качаклар иде.

Рушан Мартукның иске өлешендә яши. Ул Татар бистәсе дип атала, анда мөселманнар — күпчелеге татарлар, казакълар, башкортлар, ә соңгы елларда чеченнәр дә килеп төпләнде.

Күрәсең, аксыл җитен чәчле малай яңа күченеп килүчеләрдән һәм поселокның икенче башында яшидер, әмма ни өчендер хәтергә уелып калган — «Женя Дудченко». Шулай килеп чыкты, Рушан аның белән үз тормышында тагын бер кат очрашты әле. Ташкентка китәр алдыннан поселоктагы элеватор төзелешендә бераз прораб булып эшләп алганда булды бу хәл. Женя ул вакытта армиядән яңа гына кайтып төшкән һәм эш эзли иде, ә райүзәктә эш табу, ай-һай, җиңел түгел. Билгеле инде, Рушан аңа эшкә урнашырга булышты. Ул вакытта Женя төз-озын гәүдәле, гаять ягымлы егет иде, шулай булып истә калган да.

Озакламый Рушан туган якларыннан китеп барды, эти-әниләре янына кунакка сирәк-мирәк кенә кайткалап йөри башлады. Шундый кайтуларының берсендә җыелышып Илек буена бардылар, ул вакытта әле елга заводларның пычрагына батмаган, мул сулы иде. Баручыларның күпчелеге нигездә шоферлар иде, еракта калган яшьлек елларын искә төшереп барганда, кинәт кенә теге малайның фамилиясе калкып чыкты — ул хәзер шәһәр ГАИсында эшли икән.

Алар һичкайчан да дус та, дошман да булмадылар, тормышлары да, мәнфәгатьләре дә бервакытта да кисешмәде. Икесе дә тимер юл буендагы ярлы поселоктан чыккан якташлар — бары шул гына. Бу поселок Рушан өчен дә, Женя өчен дә — кечкенә Ватан, кайвакытларда үлеп сагынып шунда кайтасы килә.

Мөгаен, ул да вакыт-вакыт йокылы поселокның җәйге төннәрен исенә төшерәдер: биектәге ай яктысы ташландык пычрак урамнарның ярлылыгын яшерә, азиат эссе-

сеннән эреп төшкән, сулган сирень һәм чәчәк койган сәрби куаклары тузан баскан өйтүр бакчалар нindидер монда булмаган башка бер тормышның гүзәл күренешләре булып сурәтләнә. Ә бәлки, бурап яуган кар-бураннар, көрткә баткан урамнар, салкыннан боз-бизәккә төренгән тәрәзәләр артындагы җылы утлар, салкын күккә сызылып-сызылып күтәрелгән төтеннәре белән кыш күз алдына киләдер. Һәм, мөгаен, тормышында бер мәртәбә булса да, ул да Пушкинның «Ватан төтене» дигән гыйбарәсе нәкъ менә шушы — туган йортның җимерек морҗасыннан саркып кына чыккан көчсез төтендер ул, дип уйлап куйгандыр.

Кем белә, бәлки, бөтенләй алай түгелдер, аңа бернәрсә дә күзалланмый да, ишетелми дә, тимер юл буендагы поселокка да кайтасы килмидер, үткән еллар эчендә анда ни-нәрсә генә үзгәргәндер, һәркайдагы шикелле, анда да барысы да җимерелеп-таркалып барадыр...

Рушан бит ул егетне бөтенләй дә белми, аның белән күңелен ачып беркайчан да сөйләшкәне, мәҗлесләрдә янәшә утырганы булмады, аның хатыны кем, балалары бармы-юкмы икәнен дә белми. Ә, бәлки, Дудченконың хатыны Рушанның элекке сыйныфташыдыр яки Украина урамында яшәүче, кайчандыр үзе танцыдан озата кайтып, аны-моны уйламыйча, караңгы төндә үбешкән берәр гүзәл чыркылдык кыздыр. Аңа да, кызга да бернинди җаваплылык йөкләми торган яшьләрчә беркатлы самими үбешү... Вакытлар чылбыры өзелгән, туган йорт белән бәйләп торган җепләр черегән...

Яшьләр, туган ояларын ташлап, ни өчен икәнен дә төшенеп җитмичә, каядыр ерак якларга китеп барырга ашкыналар. Аңлашылмаган чит җирдәге кызларга, гыйшык-мәхәббәт тотып та тормастан, ашык-пошык өйләнәләр, кызлар исә шул килмешәк «принцларга» кияүгә чыгалар. Аннары кияүнең йә киленнең туганнарына кайту бер як өчен тәмам газапка әйләнә, чөнки һәркайсы үз йортын сагына, үз инеше, үз урамы, үз дуслары төшләренә керә. Еллар үтә тора, бер-берсен үпкәләтмәс, хәтер калдырмас өчен, алар ике якның да әти-әниләре, туган-тумачалары янына кайтмас була, мыжгып торган тәмугка — Сочига яки Ялтага йөри башлыйлар, шулай итеп, тамырлар бөтенләйгә өзелә. Бары тик сиздермичә, әкрен генә гомер кояшы баеп барганда, тормыш куа-куа үзең абайламый да калган җиде ачык көннәр эреп бетеп килгәндә генә, кинәт бугазыңа төер килеп утыра, полуторка машинадагы малайны исеңә төшерәсең, кайчандыр урам аша гына чыгып, күршеңнең янкапкасын киереп ачып:

— Исәнме, Женя! Ә хәтерлисеңме?..— дип сөйләшеп торыр чакларның узып киткәнлеген тоеп, эчеңнән сызланасың.

Бәлки, шуңадыр да дүртенче каттагы фатирыңның күптән юылмаган тәрәзәсе яныннан сәгатьләр буена китеп булмый, тәрәзәдән күңелсез-боек ишегалды гына күренсә дә, бөтенләй башка нәрсәләр күзаллана һәм, соңлап булса да, күңел күзе ачылып китә...

Шунда үлеп беләсе килә: үзең белән бергә тәүге адымнарын ясаган, бер мәктәптә укыган, бер партада утырган, бер урамда, бер кварталда яшәгән, бергә октябрят булган, аннары соңрак дулкынланып-шатланып пионерга кергән, сугыштан соңгы бишьеллыклар чорындагы ярлы гына җәйге лагерьларда учак якканда бергә җыелып утырган дуслар кайларда да, кайсысы кем булган, аларның язмышлары нинди икән?

Бергә бары тик ике генә кыш укып калган, җирән тиенгә охшаш Валечка Велигданованың сукмак-эзләре кай якларга китеп югалды икән — аның әтисе станциядә милиционер иде. Ә Диночка Могилева, райком секретаре кызы кайда хәзер? Ә сугыш азагында гына поселокка килеп төпләнгән һәм әтисе белән күрше урамдагы землянкада яшәгән Вилли исемле немец малае? Аларның ул землянкасын йорт йә алачык дип әйтергә тел дә әйләнми иде бит.

Ул Вилли белән нәрсәләр булып бетте икән? Үзенең тук-мул Гамбургында даладагы поселокны, үзенең футбол капкасын бар көчен кызганмыйча саклаган чакларын, шактый шома гына татарча да, казакъча да сөйләшергә өйрәнеп йөргән чакларын хәтерлиме икән? Вилли белән аның әтисе турында поселокта шактый озак сөйләнделәр, чөнки алар Көнбатыш Германиягә илленче еллар башында ук китеп барган иделәр. Имеш, аларның бик тә югары дәрәҗәле туганы табылган, әллә генерал, әллә банкирмы шунда, дигән хәбәрләр дә йөрде. Үзенең балачагы узган поселокка күңеле белән генә булса да тартыламы икән бай Германиядә яшәп ятучы ул кеше? Әллә инде ачлык-ялангачлыкны, салкын землянкада бетләп бетеп, кимсетелеп-рәнҗетелеп яшәгәнен тизрәк онытырга тырыштымы икән?

Бу сорауларга гомергә дә җавап табасың юк — Виллиның эзләре мәңгелеккә югалган... Шуңадырмы, сирәк кенә булса да, йөрәкне сагыш-моң кысып куя...

Аннары тагын ни өчендер сыйныфында икенче елга утырып калган Коля Верноквас искә төшә. Егерме еллар элек Верноквасны хөкемгә тартып, атып үтергәннәр —

мәктәпнең биш сыйныфын да ерып чыга алмаган, гомеренә «икеле»ләрдән башы чыкмаган ул кемсә Ростовта бер банданың атаманы булган, кешеләрне кычкыртып талап йөргән һәм күпләрнең җанын кыйган булган икән...

Дасаев әле бишенче дистәне дә тутырмаган кеше, әмма инде аңа пенсиягә дә күп калмаган. Прораб эше бик авыр хезмәт бит, ә ул төзелешкә утыз ел гомерен бирде диярлек. Менә шушылай уйланып утырырга хирыслыгын ул шактый соңрак аңлады, тик үзенең тормышка булган карашларын беркем белән дә уртаклашмады. Ул үзе өчен яңадан ачкан хакыйкать ачы иде, әмма алар барыннан да элек аның үзенә кагыла торган хакыйкатьләр иде...

Үзе ачышка тиң дип тапкан бу нәрсәләр күптәннән инде акыллы трактатларда чагылдырылган, ул хакта әдипләр вә фәйләсуфлар тау-тау китап язып калдырган, әмма алар бит чит-ятларның тормыш тәҗрибәсе, ә монда Рушан һәрберсенә үз акылы-зиһене белән, эчке сизенүе белән барып җитә. Әнә шул тәрәзә аша дөньяга багып торган хәлендә ясый ул үз ачышларын.

Әгәр дә башында кайнаган уй-фикерләрен кәгазьгә төшерергә тырышып караса, бик мөмкин — алар үтә беркатлы һәм игътибарга лаек та булмас иде. Әмма бөтен хикмәт тә шунда шул, ул ниндидер гомуми фәлсәфәләргә бирелә белми һәм аны теләми дә, ә һәрнәрсәне йә үз тормышына, йә үзе белгән, үзе яраткан, үзе аралашканнар мисалына күчерә. Шуның өчен дә хәтерендә Вилли дигән малай яки күрше сыйныфта укыган чибәр кызый Роза Хәмидуллина калкып чыга. Ул кыз Яңа ел бәйрәмендә «Төн» булып киенгән иде. Кара төскә манылган гап-гади марляга такта чәй төрә торган көмешсу фольгадан кисеп, йолдызчыклар тегеп куйган иде ул. Ярлылык-хәерчелек һәрвакыт шундый хыялларга, нәрсә дә булса уйлап табарга һәвәс була шул. Кызның башында шул ук фольгадан ясалган көмеш таҗ балкый, әйтерсең лә ул чын патшабикә иде! Таҗына шоколад конфетлардан калган алтынсу төстәге икенче фольга белән «1951 ел» дигән сүзләр беркетелгән.

Рушанның соңгы вакытларда шулай еш кына үткәннәргә әйләнеп кайтуының сәбәпләрен, аның һәркөнне диярлек балачагына, яшьлек елларына сәяхәтләрен ничек дип атарга да белмәвен хәзер инде аңлатуы да авырдыр. Нәрсә иде соң бу? Истәлек-хатирәләрме? Алай дисәң, истәлекләр үзеннән-үзе, синең ихтыярың-акылыңнан башка, күңел төпкелегннән һич көтмәгәндә калкып чыгалар иде. Юк, «истәлекләр» дигән бу кыска төшенчә

аның күңел халәтен чагылдырмый. Әйтерсең ул үзе, дуслары-сөйгәннәре, бик тиз шаулап узган яшьлек еллары турында мавыктыргыч китап укый кебек иде.

Йончыткыч, хәлдән тайдыргыч көндәлек авыр хезмәттә озак еллар әвәрә килеп, ул аларны үз вакытында юньләп аңламаган да, сизмәгән дә, ә менә хәзер соңлап, бик соңлап күптән онытылган кешеләрнең төс-кыяфәтләренә күңеленнән генә булса да бага, бүгенге тормыш тәҗрибәсеннән чыгып, шул чордагы вакыйгаларны яңадан аңларга, кичерергә тырыша. Әйтерсең ул башы да, азагы да булмаган мәңгелек бер китапны укый, ә китапка даими рәвештә яңадан-яңа сәхифәләр өстәлә тора: кайбер вакыйгалар вакыт-вакыт яңа төсмерләр ала, шунлыктан булып үткән хәлләрнең баштагы мәгънәсе кискен үзгәрә, күңелдә урнашкан образлар буталып бетә.

Аның, әлбәттә, ишеткәне бар: хәзер авторлары тарафыннан бик тә хәйләкәр уйланылган, еш кына башы да, ахыры да юк кына түгел, хәтта сюжеты һәм геройлары да булмаган китаплар аз басылмый — ничек теләсәң, шулай аңла син аларны. Андый китаплар елгыр тәнкыйтьчеләр өчен шатлык инде — тетмәсен тетеп кенә ташла! Әдип язганнардан да буталчыграк итеп теләсә нәрсә язарга була, бик горур кыяфәт, зур дәгъвалар белән мондый алымны «үземчә укуым» дип атарга була, теге яки бу әдәби агымнарга ачы-үткен, әмма үле туган төшенчә-билгеләмәләр: «параболик, интеллектуаль, спираль, синусоид проза, акыл агышы, дөньяны танып белү рәвеше» кебек сүзләр тезәргә була.

Ләкин болар барысы да шайтан коткысыннан, чит уй-фикерләрне чарпалаштыру-бәрелештерүдән, башкаларның тормыш тәҗрибәсен ботарлаудан килеп чыккан нәрсәләр — шулай булган һәм бар булганы да шул. Ә Рушан исә үз язмышына юньле-башлы үзе хуҗа да түгел, кая инде ул башкалар турында сөйләнеп торырга — ни Аллаһы Тәгалә, ни хөкемдар түгел бит ул... Кайвакыт аңа әлеге «мәңгелек китапны» үзе укый гына түгел, үзе үк язган да шикелле. Юкса үз гомерендә хезмәте буенча галәмәт озын, күңелсез исәп-хисап кәгазьләреннән тыш бернәрсә дә язганы булмады, ул «өлешенә чыккан көмешен» белә һәм хыялларында алай бер дә күкләргә ашмый, ул, гомумән, үз урынын, үз эшен белгән кешеләрне хөрмәт итә иде.

Гомер юлының күп өлеше үтелгәнлеген аңлагач, дусларын һәм якыннарын югалтып бетергәч, ул, ниһаять, вакытның гына түгел, үз буынының, җанга якын кешеләрнең китә баруын тойды — алар белән бергә шул чор-

дагы гореф-гадәтләр, йолалар, үз-үзеңне тоту рәвешләре, традицияләр, тел үзенчәлекләре, уен-көлкеләр, җырлар, хәтта табигать күренешләре, һава үзе һәм тормыш-көнкүреш — барысы да юкка чыгып бара иде. Бу күңелсез санап-барлап чыгуларны прораб чиксез дәвам итә алыр иде, бик күп нәрсәләр уйлап-нитеп тормастан һәм ашыгычлык белән тормыштан сызып ташлана, кысып чыгарыла шул. Шулай моңсу сагышка бирелгән мизгелләрендә аңа инде алардан соң килүче буыннар аларның ничек яшәгәнлекләрен, нәрсәләр турында хыялланганлыкларын (ә алар бит меңнәр вә меңнәр!) яңадан һичкайчан белмәс-аңламас кебек тоела иде.

Язмыш бер дә иркәләмәгән, инде китеп баручы үз буыны кешеләре кызганыч иде аңа, әмма тагын да авыррагы — илнең рухи тормышында яки тарихта үзләренең сизелерлек бер эз дә калдырмыйча китеп баруларын аңлау иде. Зыялылар, хәтта аларның иң юньсез, юлдан язган вәкилләре турында күпме китаплар язылган — алар шулай сөйгәннәр, янган-көйгәннәр, шулай газапланганнар, алар шундый бәхетсез булганнар, тормыш акыллы вә талантлыларга һәрчак шундый гаделсез булган...

Шундый чакларда Рушанның шәрран ярып кычкырасы, сорыйсы килә иде: «Ә без бәхетлеме? Безгә тормыш-язмыш рәхим-шәфкатьлеме? Безме яратмаган-сөймәгән? Безме хыялланмаган?»

Менә шулай күңеле тулышкан минутларында аның утырып бик зур китап язасы килә башлый иде. Ул китапта мәктәптән соң бер дә очрашмаган сыйныфташы Верочка Пейзюкның тормыш юлы да, шул Верочканы яратып йөргән Толик Чипигин турында да язылган булыр иде. Хәер, Чипигин күптән юк инде — ул гап-гади ангинадан вафат булган. Аннары, мөгаен, яшел күзле Томочка Солохо турында (аның абыйсы Толик, үзенә таныш булмаган бер кызны коткарам дип, күлгә батып үлде), күрше кызы чибәр Валя Панченко турында да язар иде ул. Станциягә практикага килгән һөнәр училищесы укучылары белән Алик Штайгер җитәкчелегендәге поселок егетләре шул кыз өчен чын-чынлап сугышкан иделәр.

Хәтерли әле, икенче көнне иртән алар мәктәптән хастаханәгә йөгерделәр, анда безнең егетләрнең яраларын бәйләгәннәр, ә башы марляга чорналган һәм күз төбе зур булып кара янып чыккан Толик Крицкий, ачуы килеп, әсәренеп, кемгәдер сөйләнә иде: «Ни пычагыма кирәк булды инде ул Панчуха миңа?!» Шунда ук авыруларны кабул итү бүлмәсендә шәһәрдән килгән ике тикшерүче шәйләнә һәм

бу вакыйга күпләр өчен шактый күңелсез тәмамланган иде. Бәлки, кем дә булса болар турында китап язар, ул китапта сөйкемле-гүзәл Панчуха һәм маңгай чәчләре күзенә үк төшеп торган, хәтта судта да Мартук кызларына елмаеп карап утырган гаярь егет, үзен герой итеп тойган һөнәр училищесы укучысы булыр иде дип уйлыйсызмы? Рушан моның буласына бер дә ышанмый иде.

Бәлки, шуңадыр да, хәтерендә кемне булса да яңартса, ул аның язмышын ачыкларга тели һәм, һичшиксез, аны үзе язарга теләгән әлеге «мәңгелек китабы»на теркәп калдырырга тырыша иде.

Шулай бервакыт, очраклы гына, ул үзен «Мәскәү — Ташкент» поездының вагон түбәсендә баручы ундүрт яшьлек малай итеп хәтеренә төшерде. Кулына кечкенә генә төенчек тотып, шәһәргә ул техникумга керер өчен документлар илтә иде. Матур җәйге көн. Каратугай күперен узуга,— күптән түгел генә шушы күпердә сыйныфташы Алешка Верещакның абыйсының башы өзелгән иде. Рушан, түбәдән түбәгә сикерә-сикерә, поездның койрыгына таба йөгерде.

Шул чагында ул үзен хәтәр оста-җитез, көчле һәм бәхетле итеп тойган иде — моны сүз белән генә әйтеп бетерешлеме соң?! Аңа төгәл дүрт ел буе шәһәр дә яшәргә туры киләчәк, әле үзе бер дә булып карамаган шәһәр исә әкәмәт ымсындырып, бик теләгәндә барлык уй-хыялларың тормышка ашарлык бер әкияти җир булып тоела иде.

Менә шушы шатлыклы тойгы, якындагы бәхет малайның күкрәк читлегенә генә сыеп бетмәде, ул кинәт кенә түбә уртасына басып туктап калды, төенчеген төтен торбасы янында калдырып, кулларын төшлеккә җитеп килгән кояшка таба күтәрде, ташыган хисләреннән әсәрләнеп кычкырып җибәрде: «Мин шәһәргә барам!..» Каршы искән җил аның кайнар иреннәреннән ургылып чыккан авазны йолкып алып китте, ә поезд исә инде өлгереп килүче алтын башаклы иген кырлары буйлап иксез-чиксез казакъ далаларыннан алга таба чаба да чаба иде, бодай басулары өстендә җиңелчә дулкыннар гына йөгерешә.

Бәхете ташудан һәм әсәрләнүдән дөп-дөп типкән йөрәге сикереп чыгар төсле тоелган иде. Кинәт аны көтелмәгән уй көйдереп алды: «Бу тормышта мин кем булырмын, минем йортым-җирем кайда булыр? Хатыным нинди булыр — чибәр, ягымлы, акыллымы, әллә хәйләкәр, усалмы? Зифа буйлы сылумы, әллә нәзберек кенәме, зәңгәр күзлеме, әллә соры күзлеме? Улым булырмы икән? Ул кем булып үсеп җитәр?»

Башына кинәттән генә әллә кайдан килеп кергән бу сораулардан аптыраштa калыпмы, ул кояштан кайнарланган вагон түбәсенә лып итеп утырды да алга таба үзенең киләчәге турында уйланып бара башлады. Аңа ул киләчәк бик ерак һәм томанлы булып, ә тормыш үзе «Мәскәү — Ташкент» поезды текелдәп барган күз күреме җитмәс казакъ далаларыдай иксез-чиксез булып күренде. Ә яшь акыл колачлап ала алмаслык, ярлары күренмәс тормыш диңгезе еш кына күз алдавыч мираж гына була икән — ул бер кечкенә дача-бакча кишәрлегенә дә сыеп бетә ала һәм карашың күрше коймасына килеп төртелергә дә бик мөмкин. Рушанның байтак чордашларының тормышы — моның ачык мисалы. Поезд вагоны түбәсендә башында кайнаган төп сорауларына җаваплар Рушанга хәзер инде билгеле булса да, тормыш бер дә күңеллерәк, рәхәтрәк түгел иде.

Еллар үтә тора, ә сораулар һич кимеми, киресенчә, ишәя генә бара. Теге чакта, менә ул — аңның-зиһеннең ачылып, киләчәкне алдан күреп барган мөһим сәгате — 1956 елның бәхетле җәе. Үсмер малайның әле татып карамаган яңа тормышка, шәһәргә китеп барган чагы. Ә туган якта яраткан кешеләр, алар белән бәйле якты балачак, беренче шатлыклар һәм күңелсезлекләр, мәхәббәткә охшаш тәүге хисләр калды...

## III

Аңа җидеме-сигезме яшьләр иде. Аларның ерак туганы тиешле Сафия апа кияүгә чыга. Аны әнисе белән сукыр әбисе тәрбияләп үстергән — алар исә Рушанның Мәскәү янындагы сугышларда ятып калган әтисе ягыннан туганнар.

Ярлы поселокта бу гаилә башкалардан шактый аерылып тора иде: калай түбәле зур гына йорт, бу якларда һич күрелмәгән, патша заманындагы Кузнецов заводларында эшләнгән тау-тау фарфор савыт-саба, Венеция пыяласыннан әкәмәт вазалар, көмеш чәнечке-кашыклар, залның биек түшәменә эленгән алтынсу кысалы бәллүр люстра... Гомумән, бу гаилә күпләргә билгеле иде. Сукыр әби чыгышы белән бик борынгы һәм бай татар ыруы Мәмлиләр нәселеннән булып, алар бу ерак, аулак якларга революциядән соң, Оренбургтагы табышлы йортларын һәм кибетләрен югалтып килеп төпләнгәннәр иде.

Кияү кәләшен алырга килгәндә, аны өйгә кертмиләр, хак таләп итәләр — мондый йола барлык халыкларда да

бар диярлек. Татарларда исә ул «ишек бавы» дип атала, аның хәтта шундый такмагы да истә әле:

Ишек бавы — бер алтын,
Безнең апай — мең алтын...

Кияү алдында әнә шул «ишек бавын» тотуны, иң якын туганнары, дип, Рушан белән аңардан бераз өлкәнрәк Мелис дигән малайга тапшырдылар. Кияү таза, базык гәүдәле Гали исемле егет иде. Кәләше янына керер алдыннан, ул малайларның һәркайсына искиткеч матур сөяк саплы пәке бүләк итте, пәкеләрнең берсе кызыл, икенчесе яшел төстә иде.

Бу туй Рушанның үз гомерендә күргән иң беренче туй иде, шунлыктан булса кирәк, ул һәр мизгеле белән аның күңелендә гомерлеккә уелып калды: җыр-биюләре дә, сый-нигъмәтләре дә, кунаклары да... Өстәл янында яшьләргә әйтелгән теләкләрне дә һаман хәтерли әле ул. Андый теләкләрне, бигрәк тә бүләкләр биргәндә, мулдан яудыралар, матурдан-матур сүзләрне тезеп кенә торалар икән. Туйның әнә шундый мизгеле җитте: залга зур поднос күтәргән бер кеше килеп керде, аның янәшәсендә кечкенәрәк подноска бер шешә шәраб белән матур итеп кискәләгән, балда катырылган чәкчәк куйган бер апа да бар иде. Кунаклар, көмеш подноска бүләкләрен салалар да, яңа өйләнешүчеләргә үзләренең матур теләкләрен әйтәләр, җавапка «рәхмәт» сүзе белән бергә бер рюмка махсус әзерләнгән шәраб һәм баллы чәкчәк алалар.

Кияү белән кәләш артында басып торган Рушан, авызын ачып, бераз исерешә башлаган кунакларның теләктостларын тыңлый һәм Сафия апасы белән Гали җизнәсенең, гомер буе бер-берсен яратышып-килешеп, картайганчы тигез яшәячәкләренә, аларның берсеннән-берсе матур, сәләтле балалары булачагына, үзләренә әле менә бу туй бара торган йорттан да мәһабәтрәк-гүзәлрәк йорт җиткерәчәкләренә ихлас ышана иде. Ул яшьләрнең киләчәк бәхетләре өчен шулкадәр нык шатланды, хәтта кайсыдыр бер мизгелдә күңеле кыбырсып, көнләшеп тә куйды: аның үзенең туена чаклы бик ерак шул әле, аннары кәләшлеккә Сафия апасы кебек чибәр, шундый да уңган, шундый да булган кыз, ай-һай, табылырмы икән әле? Ул хәтта Сафия апасын кияү җизнидән дә бераз көнләде бугай әле... Менә шулай...

Туган йортыннан читкә бик иртә чыгып киткән һәм Мартукка сирәк-мирәк кенә кайтып йөргәләгән Рушан, әгәр дә тагын кемнеңдер туенда яшь кияү белән киленгә әйтелгән шундый ук теләкләрнең сүзгә-сүз кабатлануын ишетмәгән булса, мөгаен, бу гаиләне бервакытта да

хәтеренә төшермәс иде. Ул, билгеле, соңыннан да төрле туйларда булды, ләкин һичкайчан күңелендә алдануга охшаш мондый ямьсез тойгы уянганы булмады. Бу вакытта ул инде ялгыз кичләрен әнә шулай тәрәзә буенда басып торырга күнегеп киткән һәм бер үк шәйдә үзе яза да, үзе укый да торган «мәңгелек китабы»ның беренче битләрен актара башлаган иде. Менә шул чагында көчле ихтыярлы сукыр әбисенең бердәнбер оныгын кияүгә биргәне, күптән булып үткән туй кылт итеп хәтеренә төште, Сафия апасы белән Гали җизнәсенең бөтен тормышлары күз алдыннан үтеп киткәндәй булды.

Аларның алдагы тормышында алтын-көмеш туйлар да булмады, үлгәнче яратышып-сөешеп яшәүләре дә барып чыкмады, имән кебек төптән юан, таза кияү җизни дә күптән вафат инде, армиягә киткәнче үзенең котырынкы холкы белән бөтен Мартукны дер селкетеп йөргән беренче уллары Хәлил дә бу дөньядан иртә китеп барды, кайчандыр бай булган йорт таркалып-бөлеп бетте. Исерек ызгыш-талаш, сугыш-тарткалашлар вакытында йорттагы Венеция пыялалары да, Кузнецов фарфоры да җил себереп алгандай юкка чыга торды, Мәмлиевләр монограммасы төшерелгән көмеш кашык-чәнечке, пычак-фәлән дә югалып, урланып бетте. Бары тик чебен пычратып бетергән бәллүр люстра гына түшәмдә ятимсенеп эленеп калды. Ә бит кайчандыр Рушанга үз күз алдында оешкан бу гаиләнең тормышы колачлап бетереп булмаслык шикелле тоелган иде, кояшлы көннәрдә үзенең ялтыр калай түбәсе белән үткән-сүткәннәрнең күзләрен сукырайтып торган, таза кызыл кирпечтән салынган бу сәүдәгәр йортының калын диварлары артында яшәүче һәркемнең язмышы әйтеп-сөйләп бетергесез серләргә бай булыр шикелле иде. Һәм ул серләр күз алдында диярлек шулай тиз, бик тиз ачылдылар да беттеләр, язмышлар язылды-укылды, тормыш китабының һәр бите актарылды. Чүп үләне басып киткән ташландык бакчага кыйшайган тәрәзәләрен чекерәйткән, яртылаш җиргә иңгән бу йортта хәзер Сафия исемле чал чәчле шапшак карчык ялгызы гына көн күрә. Кыршылып беткән паркет идәнле, күптән җыештырылмаган-каралмаган бүлмәләрдә элекке тәртип, чисталык-пөхтәлекнең эзе дә юк, ә карчыкны яшь, чибәр итеп, көнләшерлек бай бирнәле кәләш итеп күз алдына китерүе дә кыен. Ә бит Рушан бу йортның зиннәтле күркәм, бай чакларын хәтерли, Сафияны кар кебек ап-ак туй күлмәге кигән килеш күргән кеше!

Барысы да кырылды да бетте... Бу гаиләнең фаҗигале язмышы үзе бер роман түгелмени? Кем язар аны?

Мескен Мартук үзенең елъязмачысын кайчан күтәп ала алыр?

Әлбәттә, Мәмлиевләр ыруыннан булган туганнарның ачы язмышын Рушан үзенең «мәңгелек тормыш китабы»нда чагылдырып узмый калмады. Кешеләр хәтерендә нәрсә булса да сакланып кала барсын, күрсеннәр, гаҗәпләнсеннәр: Татар бистәсенең нәкъ үзәгендәге Украина урамында кислоталы яңгырлардан калай түбәсе череп төшкән ярым җимерек кызыл кирпеч зур йорт бармы? Бар. Ә бит ул йортның шаулап-гөрләп торган бәхетле көннәре дә бар иде, анда яшәүче сукыр әби исә динкардәш мөселманнарның әхлаклы-иманлы булуларына күз-колак иде.

Иртә таңнарның берсендә, бу йортның кыйшая төшкән янкапкасыннан әле хәрби киемнәрен дә салып өлгермәгән кыю десантчы Хәлил йөгереп чыга да туп-туры станциягә юл тота. Аның ярты сәгать буена диярлек буш перронда тыныч кына арлы-бирле йөренгәнен күргәннәр, берәү дә егетнең коточкыч хәвефле уйларын сизенмәгән. Алма-Ата экспрессы «Казакъстан», йөрешен әкренәйтмичә, Мартукта туктамый-нитми үтеп барган чакта, Хәлил кинәт кенә перроннан сикереп төшә дә хәтәр локомотивның алдына ташлана. Аның яшендәгеләр, ихтимал, сугыш вакытында дошман дзотының амбразурасына нәкъ менә шулай бер ыргылыш белән ташлана торган булганнардыр.

Перронда ярты сәгать буена арлы-бирле йөренгән соңгы минутларында ни-нәрсәләр уйлады икән Хәлил? Күңеленнән генә кем белән хушлашты икән? Ни өчен карап торуга бер сәбәпсез-нисез шулай җиңел генә, җан өшеткеч рәвештә тормышын корбан итте икән? Ә бит ул көчле ихтыярлы, тормышта үзенә тиешлене ычкындырмый торган сау-таза егет иде.

Күрәсең, ул бу дөньяның ялганнарын, шәфкатьсезлеген кабул итә алмастай, җиңел яраланучан, самими-садә күңелле зат булгандыр. Бу хакта хәзер бары фараз кылырга гына кала, барлык серләрен Хәлил үзе белән алып китте, аны инде кайгы-хәсрәттән кибеп корышкан Сафия карчыктан башка беркем дә хәтерләмидер дә.

## IV

...Рушанга унике яшь, ул инде күптән пионер, отличник. Әле Иосиф Виссарионович Сталин да исән. Шул язда бугай, аның шәһәр-авылларны яшелләндерү һәм урман полосалары утырту буенча галәмәт зур программасы

тормышка ашырыла башлады. Хәзер ни генә сөйләмәсеннәр — бөек һәм изге эш-гамәл иде ул, бүген инде шундый адымны кабатлау кирәклеге турында уйлаучы да юк. Шул язда Рушан утырткан зәгыйфь үсентеләр хәзер Мартукның Татар бистәсендә, туган йорты каршысында көчле карагачлар, колач җитмәс тирәк һәм өрәңгеләр булып шаулап утыралар — үсентеләрне мәктәп бушлай тараткан иде. Инде дала уртасындагы Мартук тирәсендә мәһабәт урман күтәрелде, хәтта кош-кортлары, киек җәнлекләре бар, гөмбә үсә, каралып карлыган пешә... Ул урманны Юлбашчы боерыгы белән кешеләр үстергәнне хәзер инде бик азлар гына белсә беләдер.

Әмма ул язны Рушан бер дә урман полосалары яки Юлбашчы исеме белән генә бәйләп искә алмый. Әлбәттә, Юлбашчы аның бөтен тормышы аша үтте, аның белән, теләсә-теләмәсә дә, беркем дә «очрашмый» кала алмады, әгәр дә хәзер инде кемнәрдер кимсетеп, аны бары тик Сосо дип кенә йөртсә дә, истәлек-хатирәләрдә Сталин исеме ары табан да калкып-калкып килеп чыга икән — бу бер дә модага иярү генә түгел, генералиссимусның күләгәсе ул елларда Мәскәүдән бик ерак булган Мартукка да төшә иде. Ул язда аларга әнисенең кайдадыр Ужгородта хезмәт итүче энесе Рәшит ялга кайткан иде. Менә шуның белән дә истә калган әле ул яз.

Рәшитне солдатка соңлап алганнар: ул тимер юлда башта кочегар, аннары, курсларда укып кайткач, паровоз машинисты булып эшли һәм аңа нindидер бронь тиеш була. Армиягә киткәнче дә бу абый Рушан өчен күпне күргән, дәрәҗәле кеше булып тоела, бигрәк тә яка һәм җиң очларына көмешсу билгеләре тегелгән ярым хәрби кителен һәм укалап чигелгән чалбарын да киеп җибәрсә — беттең инде! Ялга ул өлкән сержант дәрәҗәсендә кайтып төште. Аякларында Мартукның иң оста итекчесе Петерс тегеп биргән шыгырдавыклы фырт күн итек. Хәрби устав кагыйдәләренә сыеп бетмәгән кием-салымнан тагын шәп шарф һәм кәҗә мамыгыннан бәйләнгән ак перчаткалар. Мартукка ул март урталарында, әле кыш үз вәкаләтләрен язга тапшырыргамы-юкмы дип, йокымсырабрак яткан чакта кайтып төште. Әмма һавада инде яз исе аңкый, урам-тыкрык чатларында беренче су тибеп чыга, кар көртләре күз алдында чүгеп-кечерәеп баралар, көндезләрен тәбәнәк түбәләрдән тамчылар тама иде... Әйе, яз — борын төбендә генә!

Март ае ул елларда аерым бер дәрәҗәле ай санала иде: ни өчендер мартта һәрвакыт сайлаулар була. Ул елны да сайлаулар булып, ул мартның соңгы якшәмбесенә бил-

геләнгән иде. Ә бу инде, поселокта сайлауларга кадәр бер ай кала, агитпунктлар эшли башлый дигән сүз.

Ах, ул сугыштан соңгы елларда Мартук кебек җирләрдәге агитпунктлар! Алар, ихтимал, бик күп сайлаучыларның хәтерләренә сеңеп калганнардыр. Агитпунктта көн саен ярты төнгә кадәр ут яна, буфеты гөрләп эшләп тора, ә залда — аккордеон уйнавына кушылып, биютанцылар, танцылар... Шулай итеп, уңган-булган өлкән сержантыбыз ялы белән нәкъ менә шул көннәрнең үзәгенә үк туры китереп баскан иде, ә бәлки әле, махсус шуңа туры китереп кайткан булгандыр, сайлаулар турында алдан ук билгеле була иде бит.

Һәр кичне «Шипр» одеколоны сибенеп, шыгырдавыклы күн итекләрен көзгедәй ялтыратып алганнан соң, Рәшит, туганнарын күңелсезләндереп, өйдән чыгып югала һәм ярты төн үткәч кенә, тирә-юньдәге бөтен этләрне уятып кайтып керә иде. Ир-атларын сугыш шактый кырып салган поселокта солдат егетнең ялга кайтып төшүе эзсез калмады, әлбәттә. Мартук чибәрләре дә йоклап ята торганнардан түгел иде шул!

Рәшитнең ял алып кайтуы әлеге дә баягы сайлаулар белән генә бәйләнмәгән, нәкъ менә март аенда аның туган көне дә иде. Ул аны апасының өендә үткәрмәде, шуның өчен өйдә бераз үпкәләшүләр дә булып алды, ә станциядәге бер яшь кенә тол хатында үзенең яшьтәшләрен җыйды.

Рушанның әнисе белән Рәшит абый арасында бу туган көнне кайда үткәрү мәсьәләсендә каршылыклар чыкса да, әнисе пешеренде-төшеренде — бөккән-фәләннәре дә, зур кәстрүл белән винегреты да, шактый кыенлык белән каяндыр юнәткән галәмәт бер үгез башыннан ясалган дердерие дә әзер булды. Рушанга исә йөгертеп кенә кибеттән шәраб һәм консервалар алу эше ышанып тапшырылды. «Сельмаг» кибетендә консервалардан диңгез кысласы — краб кына бар иде, сатучы хатын алмаска киңәш итте, күрәсең, малайны консервалары-ниләре белән кире борып җибәрүләреннән курыкты. Туган көн итеп мул гына сый-нигъмәтле өстәл әзерләнсә дә, Рәшит абыйсы туганнары янында озак юанмады — Рушанның үги этисе белән чәкәшеп бер-ике рюмка шәраб эчеп куйды да станциягә китәргә ашыкты, мәҗлесне аннан башка гына дәвам итәргә туры килде.

Мөгаен, бу ялы, бу туган көне Рәшит өчен ни-нәрсәседер белән бик мөһим булгандыр, Рушанның әнисе аның армиягә киткәнче тимер юлда эшләп җыйган-туплаган акчаларын уйлап-нитеп тормастан туздырып бетерә ба-

руына борчыла иде. Ул заманнарда тимер юлда эшләү абруйлы санала, яхшы түләнә, әллә нинди льгота-өстенлекләре турында әйткән дә юк — илнең теләсә кайсы почмагына бушлай барып кайтудан алып бушлай күмер бирүләргә кадәр бар иде.

Гомумән, Рәшит абыйсы Рушанга бик юмарт, шаткөләч, ягымлы күренә һәм ул үзе дә аңа охшарга тырыша иде, ихтимал, апасының улына тормышта үз сукмагын табуда өлкән сержантның да йогынтысы аз булмагандыр.

Ә армиядән нинди бүләк-күчтәнәчләр алып кайткан иде ул! Рушанның әнисенә — соңрак авылларда гына түгел, шәһәр гүзәлләре арасында да бик модалы булган чәчәкле-чуклы искиткеч чегән шәле, үги әтисенә — Львов базарында сатып алынган чып-чын «Золинген» бритвасы, ә Рушанга — әкәмәт тә матур электр фонаре! Ул бүләккә балалар гына түгел, өлкәннәр дә исләре китеп көнләшеп карадылар, иллә дә шатланган, иллә дә горурланган иде Рушан ул чакта! Соңыннан, армия хезмәтен тутырып кайткач, Рәшит абыйсы аңа Горький заводында эшләнгән зурлар велосипеды да бүләк итте әле. Велосипедның көпчәк өстендәге кысалары хромланган, кул тормозы да, матур фарасы да бар, утыргычы күннән, звоногы, багажнигы, арткы көпчәге канатында кып-кызыл булып стоп-сигналы янып тора, хәтта чылбыры өстендә чалбар балагы уралмасын өчен куела торган тимер капкачына хәтле бар иде. Бигрәк тә рамы алдына беркетелгән завод эмблемасы — горур боланның матур башы әллә кайлардан күренеп тора, ул, күрәсең, көязлеккә һәм тизлеккә ишарә булгандыр инде...

Рушан ул заманнардагы әйберләрне, тормыш-көнкүрешнең вак-төякләрен юкка гына шулай тәфсилләп хәтеренә төшереп утырмый, чөнки алар да үз хуҗалары белән бергә кире кайтмаслык булып юкка чыга баралар. Һаман да бер урында таптанып, яңадан велосипед уйлап чыгарып тормас өчен булса да, бик күп нәрсәләр турында сөйләп калдырасы килә. Әгәр дә бүген Халык хуҗалыгы казанышларының бөтенсоюз күргәзмәсе — ВДНХ дигән ялган-ясалма күргәзмәгә Рушанның кырык ел элек булган велосипедын, әлеге кесә фонарен, шуларга өстәп бөтен Европага атаклы заводның сөяк саплы пәкесен дә китереп куйсаң, валлаһи, эталон-үрнәк, хәзергечә әйтсәк, дизайн могҗизасы булырлар иде, ә инде сыйфаты һәм бәясе турында сөйләп тә торасы юк.

Кайсыдыр бер карт әйтмешли, кабахәт начар заман иде, әмма Иделдә балык бар иде. Ә бит ялга кайткан

Рәшит абыйсы әле тагын бер банка хәлвә, шикәргә катырылган берничә кап мүк җиләге белән мармеладлы лимон кисәкләре һәм һинд чәе дә алып кайткан — болар солдат акчасы да җитәрлек арзан товарлар иде. Хәзер менә күңеле төшенкелеккә бирелгән минутларда Рушан бездә бөтен нәрсәнең җимерелә-кырыла баруы, юкка чыгуы, кыргыйлануы турында әрнеп уйланып утыра...

Мондый уй беренче тапкыр моннан ун еллар элек, төрек шәһәре Эфеста, дөньядагы җиде могҗизаның берсе дип йөртелгән борынгы Артемида гыйбадәтханәсе хәрабәләрен карап йөргәндә башына килгән иде.

Хәтта ярым җимерелеп беткән булса да, ул гыйбадәтханә үзенең нәфислеге-гүзәллеге белән, очып китәрдәй җиңел корылмалары белән таң калдыра иде. Алгы ягы белән диңгезгә караган да ул гүя дулкыннар өстеннән очып бара яки һавада тирбәлә төсле, борынгы төзүче осталар тарафыннан һәр миллиметрына кадәр уйланылган пропорцияләренең сере-тылсымы да әнә шунда аның.

Якыннан караганда гыйбадәтханә үзенең галәмәт зурлыгы белән һушыңны китәрерлек булса да, эченә кергәч, Рушанны ниндидер җиңеллек һәм нәфислек хисе чолгап алды. Чынлап та, дөнья могҗизасы! Рушан моны үзе төзүче буларак та, «Архитектура СССР» журналының егерме еллык нәзберек укучысы буларак та раслар иде. Союзда илле ел эчендә төзелгән иң әйбәт саналган биналарның барысын бергә алганда да, алар Эфес шәһәрендәге фәхешханә җимерекләренә дә тормыйлар, дип әйтергә була. Ул фәхешханәнең күрсәткеч тактасы бик яхшы сакланып калган: мәрмәргә уеп искиткеч гүзәл, гаҗәеп сылу ялангач хатын-кыз сыны ясалган, ә астарак — зур гына ир-ат аяк табаны һәм юнәлешне күрсәтә торган ук, мондый язуы да бар «Әгәр дә сез почмактан борылып керсәгез, сезне ягымлы-назлы вә дәртле-дәрманлы хатын-кызлар каршы алыр». Төрек гидлары шаярткан ча, ихтимал, бу язу дөньядагы беренче реклама-белдерү язуы булгандыр.

Шәһәрдән Артемида гыйбадәтханәсенә бик яхшы сакланып калган юл илтә, аңа безнең эрага кадәр яшәгән дипломсыз-нисез, без хәзер шапырына торган белемсез архитекторлар тарафыннан проектлаштырылган эре ак мәрмәр плитәләр түшәлгән. Бу юл совет туристларын үтерде дә салды, чөнки аларның һәркайсы белә: бездә берәр магистраль юл салып өлгермиләр, бер елдан анда инде машиналар «бөкесе» килеп тыгыла, файдалана башлап бер ай да үтмәстән, капиталь ремонт кирәклеген сөйләп тә торасы юк. Менә шул чагында Рушан үзебез-

нең цивилизация турында төшенке уйларга бирелгән иде, юкса хәзерге дөнья цивилизациясендә Советлар иленең үзенә аерым бер урыны бар барын...

Берничек тә тыеп, идарә итеп булмастай хәтере кинәт кенә үзен илтеп ташлаган борынгы Эфес шәһәреннән, гүзәл Артемида гыйбадәтханәсеннән, бөтен ихтыярын җигеп дигәндәй, Рушан янә дә ялга кайткан сержант абыйсының туган көненә әйләнеп килде.

Дөресен әйткәндә, туган көннең үзе турында Рушан бер нәрсә дә әйтә алмый — станциядәге тол хатын өендә үткәрелгән мәҗлес аның өчен сер булып калды. Әмма иртә белән уянгач, ул өстәл өстендә Рәшиткә бирелгән гади генә бүләкләрне күрде: портсигар, гәрәбә мөштек, тар гына ак атлас шарф, мамык перчаткалар, әмма алар элекке кочегар «фарсит» итәргә ярата торган ак төстә түгел, ә көрән иделәр, мөгаен, дөя мамыгыннан булганнардыр. Шунда ук куе зәңгәр тышлы калын гына китап ята.

Малайның карашы иң элек шул китапка төште. «Л.Н.Толстой. «Воскресение»,— дип укыды ул китап тышындагы язуны. «Воскресение...— бу нинди якшәмбе инде тагын?» — дип уйланды ул. «Воскресение» сүзенең асыл мәгънәсе «яңадан туу» икәнен аңларлык малай түгел иде шул әле ул. Анысы соңлап, шактый соңлап килде... Аннары сәерсенеп кенә китапның эчен ачты. Титул битенә матур хатын-кыз кулы белән *«Кадерле Рәшиткә егерме биш яше тулган көнендә. Бәхетле бул! Раилә.»* дип язылган иде.

Баксаң, аның Рәшит абыйсына егерме биш яшь тулган икән, Рушанга ул әллә кайда, хыял ирешмәслек ерактагы еллар булып тоелды һәм әле бик озак шул «егерме биш яшь» сүзләре үз язмышын исәпләүнең баш саны булып торды. Абыйсы китеп барганнан соң укып чыккан әлеге зәңгәр тышлы китап та аның хыялларын кузгатты, чөнки райпотребсоюзда эшләүче чибәр бухгалтерша язган сүзләрдә ниндидер тирән яшерен сер ята, дип уйлый иде ул.

Китап кибетләренең киштәләре китаплардан сыгылып торса да, ни өчендер егерме биш яшьлек ир-егеткә нәкъ менә «Воскресение» романын бүләк иттеләр икән? Малай шул турыда баш вата иде. Ә бәлки, «Воскресение» бүләк алучының түгел, бүләк бирүченең берәр серен яшереп саклыйдыр? Кыскасы, малай үз хыял-фаразларында тәмам буталып бетте. Раилә апаны урамда очратканда аның чибәр йөзенә текәлеп караштыргаласа да, бу табышмакны чишәрлек нәрсә күрә алмады. Малай-

лык чорында ул үзенә дә егерме биш яшь тулган көнендә нәкъ әлеге романны бүләк итүләрен теләи, бәлки, шул чагында Мартук бухгалтершасының серен ачар кебек тоела иде. Әмма бу балачак хыялы да тормышка ашмады — аңа Толстой томын бала чагында да, соңрак та бүләк итүче булмады.

Ул вакытта, мәктәптән кайтканда да, аяк астындагы суларга да, язгы тамчыларга да, авыл советы янындагы карт өрәңгеләрне сырып алган шау-шулы кара каргаларга да игътибар итми Рушан, тик аның башын бер генә уй бораулый: абыйсы райпотребсоюз бухгалтершасына өйләнерме, юкмы икән? Ул, Толстой томы, атлас шарф кына түгел, Рәшит абыйсын җитди адым ясарга этәрә торган бүләк дип, ихластан ышана иде.

Аларның өйләнешәчәкләренә иманы камил булган минутларда Рушан әлеге бухгалтершаның нәселе булган Сираҗетдиновларның малайларыннан кемнәр аның машинист абыйсы алдында «ишек бавы» тотып торачагы турында уйлана иде. Ә менә хәзер, инде күп еллар узгач, ул абыйсы турында бөтенесен дә белә, хәтта чибәр шәфталу йөзле, миндаль күзле бухгалтершаның да язмышы билгеле, ул аны бервакыт «мадам Баттерфляй» дип тә атаган иде әле. Әлбәттә, ул аларның тормыш-язмышларын махсус күзәтеп бармады, башкаларныкын да күзәткәнеөйрәнгәне булмады, әмма шулай да кирәкле хәбәрләр аңа ирешә торды, әйтерсең нииндидер югары илаһи бер зат аның кайчандыр үзе яраткан һәм белгән кешеләре турында «мәңгелек китабы»н язарга уйлаганлыгын күреп торган.

## V

Рәшит абыйсы Роза Гомәровага өйләнде. Моның бер дә гаҗәпләнерлек нәрсәсе юк — аларның әниләре бик якын ахирәт дуслар иде.

Гомәровлар гаиләсе Мартукта бераз гына яшәп алды да аннары көтмәгәндә генә шәһәргә күченеп китте. Рушан аларның йортында булгаласа да, бу гаилә турында әллә ни күп нәрсә белми — аларның нииндидер серләре бар шикелле, төгәлрәк әйткәндә, алар башкалар аңламый торган нииндидер яшерен тормыш белән яшиләр иде.

Рушан хәтерли әле: Рәшит абыйсы өйләнгәнчегә кадәр, хәтта ул ялга кайтып, станциядәге тол хатында туган көнен үткәреп киткәнче үк, Рушаннарның өендә Розаның энесе Исмәгыйль ике атналап качып ятты. Ул гитарада яхшы уйный, тыпырдатып чечетка бии, әнисе

дә Рушанны шул вакытта: «Уйнарга өйрән, биергә дә өйрән, шундый сәләтләрең булмаса, бәхетле дә була алмассың, кирәге чыгар»,— дип, ярты айлап игәүләде. Әмма, күрәсең, Ходай Тәгалә Рушанга бию сәләтен дә, гитара чиртеп, үзәк өзгеч төрмә җырлары җырлау һәвәслеген дә бирмәгәндер — ул тәки берсенә дә өйрәнә алмады. Соңрак, Рушан күрше шәһәрдә техникумда укый башлагач, аңа Гомәровлар гаиләсенең кайбер серләре бераз ачыла башлады.

Розаның ир туганнары — Шамил белән Исмәгыйль җинаятьчел дөньяда зур абруй казанган — «авторитет» егетләр булып чыкты. Рушан йә Тимерьюлчылар сараена — «Тимерлеккә», йә Пушкин паркындагы җәйге бию мәйданчыгына, кышларын исә бик тә модада булган өлкә мәдәният йортына бию-танцыларга йөри башлагач, күпмедер вакыт бу «даннары чыккан» туганнары белән горурланып та караган иде әле. Өлкә мәдәният йортында саксофончы Эдди Костакиның атаклы джаз оркестры уйный, купшы-фырт Исмәгыйльне шәһәрдә Исмәгыйль бәк дип кенә йөртәләр, үзе кайчандыр качып яткан йортта тыпырдатып биергә һәм гитарада уйнарга өйрәтеп азапланган егетне күргәндә, ул һәрвакыт: «Бу студент — минем туганым»,— дип кенә җибәрә иде. Рушан өчен бу сүзләр ышанычлы сак кына булып калмады, үзен дә ничектер таныттырды, аны кем белән булса да таныштырганда: «Исмәгыйль бәкнең туганы»,— дип таныштыра башладылар.

Әмма Шамилгә дә, Исмәгыйльгә дә бию мәйданчыкларында еш биергә туры килми, әйтерсең магниты бардыр — аларны төрмә дигәнең әледән-әле тартып ала тора иде. Иректә яшәү алар өчен авыр бер мәшәкать кебек иде бугай.

Рушанның яраткан абыйсы әнә шул гаиләгә барып капты. Инде өлкәнәйгәч, Рушан Рәшитнең Гомәровлар гаиләсе белән үрелгән тормышы-язмышы турында еш уйлана, җинаятьче бертуганнарга да шаккатмый — аларның әниләре Миңсылу апага таң кала иде.

Табигать менә кемгә ныклык, елгыр зирәклек һәм булдыклылыкны өеп биргән! Шул шыксыз-ямьсез генә, эре шадра йөзле, ябык кына надан хатын әлеге усалдәһшәтле гаиләне үз кулында биетеп тота иде. Республикада ул белмәгән судьялар, прокурорлар, адвокатлар, нотариуслар, суд башкаручылары, төрмә һәм тикшерү изоляторлары башлыклары, угрозыск башлыклары, гади тикшерүчеләр юк шикелле иде. Участок милиционерлары турында сөйләп тә торасы юк, ул хәтта лазаретлар

һәм психушкалардагы табибларга хәтле барысын да белә. Ул бөтен этапларны, күчерү-озату лагерьларын, Караганда, Акмулла, Чимкент төрмәләрен күргән, хезмәт белән төзәтү учреждениеләре өстеннән күзәтү-надзор алып баручы прокурорлар белән дә таныш. Ул теләсә нинди җинаять эшләре буенча адвокат контораларында да киңәш-табыш итә ала, чөнки законнарның камил түгеллеген белә иде. Әгәр дә бер улы инде төрмәдә утырып, икенчесенең эше судта булса, ул Себердә урман кисүче яки Күмертау рудникларында интегүче тоткыннар янында яки ниндидер район йә үз шәһәренең берәр суды арасында бәргәләнеп чабып йөрер иде.

Улларының берәрсе үз чиратында төрмәдән котылып кайтып керсә, ул гөрләтеп мәҗлес үткәрә. Шамилеме, Исмәгыйль бәгеме шунда ук паркта яки бию залларында пәйда була, өсләрендә — коверкот костюм, кунычына еш кына финка-хәнҗәр кыстырылган шыгырдавык күн итек, хәзер инде күпләрнең төшләренә дә керми торган шыштыр-шыштыр салкынча ефәк күлмәк булыр иде. Шул заманнарда ук һәркайда Кытай товарлары сатыла башлаган иде, бертуган егетләр аксыл-сары габардин чалбарлар, «Дружба» тамгасы сугылган күн табанлы, чия төсендәге очлы башлы туфлиләрдән генә, бик көязләнеп, артык талымчан булмаган кызыкайларның күзләрен кыздырып йөрерләр иде. Әле берсе, әле икенчесе беренче-икенче мәртәбә генә түгел, чираттагы әллә ничәнче туен шаулатып үткәрер, туганнары буларак ул туйларда Рушан да катнашыр иде. Әмма, егетләрнең иректәге тормышлары бик кыска булган шикелле, ул никахлар да озын гомерле булмаслар иде.

Костакиның джаз оркестры даңгыр-доңгыр уйнап торган җәйге парк ресторанында көн саен кәеф-сафа коручы бу елгыр бертуганнарның берәр көн генә кайда булса да эшләгәнлекләрен Рушан хәтерләми. Хет үтер менә! Ул шулай ук бу йортта бердәнбер мал табучы Миңсылу апаның нәрсә белән шөгыльләнгәнен дә әйтә алмас иде. Хәзерге тел белән әйткәндә, ихтимал, «бөтерелгәндер, тапкандыр, алгандыр, саткандыр»... Ә бәлки, хокук саклау органнарындагы үзенең күпсанлы дуслары-танышлары вә әшнәләре белән законнарга бигүк буйсынмый яшәүчеләр арасында арадашчылык иткәндер. Кем белә?..

Хәзер инде һәркемгә мәгълүм: ул «гадел хөкем сарайларында», олысы-кечесе дигәндәй, һәркайсы ришвәт алып утыра һәм елгыр-җитез арадашчыларсыз андый гамәлләрне эшли дә алмый. Монысы — Рушанның фаразлары гына, соңлап күзе ачылуы. Чынлап та, бертуган

Гомәровлар төрмәгә бик тиз барып та керә, бик тиз иреккә дә чыга иде. Хикмәте нәрсәдә булды икән аның?

Роза әнә шул «даны чыккан» абыйлары белән кайнашып үсте. Менә ул инде гитара да чиртә, тыпырдатып чечеткасын да бии, хисчән тыңлаучыларны елата-елата кызганыч-моңлы итеп «блатной» җырларны да җырлый иде. Булдыра иде кызый!

Бертуган егетләр аның сайлаган киявен өнәмәделәр — алар сүзе белән әйткәндә, сеңелләре ниндидер бер «пошига», «кочегарга» кияүгә чыккан, әмма шул ук вакытта бу никахка комачаулый да алмадылар, чөнки икесе дә чираттагы мәртәбә төрмәдә утыра иделәр. Җинаятьчел дөнья үзара меңнәрчә җепләр белән, шул исәптән туганлык җепләре белән дә бәйләнгән, ихтимал, бертуган Гомәровлар Роза аша үз дус-ишләренең берәрсе белән туганлашырга да теләгән булганнардыр. Роза чибәр генә түгел, ул җинаятьчел тормыш кануннарын да яхшы белә, шуның романтикасын тоеп-күреп үскән — кыскасы, бу эшләрдә хатын-кызларның катнашуы сирәк булса да, читтән килеп кысылган кеше булмас иде.

Бертуган егетләр иреккә чыккан чакларда, аларда күчмә коштай кунаклар еш була — кем утырып чыккан, кем утырырга җыена, ә кемдер, чираттагы «уңышлы эшен» майтарган да, бер типтереп алырга дип, махсус килеп чыккан. Бу гаиләдә аларны сатмаячакларын, бәладә калдырмаячакларын белеп, озаклап качып ятучылары да булгалый, ул егетләр арасыннан да кемнәрдер Кармен кушаматлы бу кызга шук-наян күз аткалагандыр — аны «кулына гитара тотып тугандыр бу» дип сөйлиләр иде. Әмма ни хәл итәсең, Карменның йөрәген элекке кочегар егет яулап алды шул... Соңыннан, гаилә ызгыш-талашлары чыкканда, Роза да Рәшитне, абыйлары шикелле кимсетеп, «поши» йә «алаша» дип кенә йөртә башлады...

Бу гайре табигый гаиләгә килеп капкан Рәшитнең дә язмышы бик четерекле булып чыкты.

Чирек гасырлап вакыт сиздермичә үтеп тә китте — Рушанның күз алдында бу кешеләрнең бөтен тормышы пыран-заран килеп бетте. Гаиләнең байтак кешеләре вакытсыз җир куенына керде.

Төрмәдән качкан чагында, Исмәгыйль бәк һәлак булды. Аның ул әвәрәгә ничек катнашып китүен һич тә аңлап булмый, юкса иреккә чыгарына да нибары өч ай гына калган булган. Кайвакытларда Рушанның күз алдына ниндидер Себер елгасының камышлы уйсу яры килеп баса, шул камышлар арасында күзе яраланган Исмәгыйль бәк качып яткан бит. Аның үле гәүдәсен шул

тирәдә яшәүчеләр сүнгән учак яныннан табып алганнар, дип сөйләделәр.

Кайдадыр Себер тайгалары уртасындагы бер авылның ярлы гына зиратында мәһабәт гранит һәйкәл — кабер ташы бар. Ватылмый торган пыяла астына бронза рамга беркетеп куелган фоторәсемнән чибәр генә яшь егет карап тора, ул бостон костюмнан, якалары пинжәк өстенә чыгарып куелган ак күлмәктән.

Әмма үлгәннән соң да улын кешеләр алдында әйбәт итеп күрсәтергә тырышмаса, Миңсылу апа Миңсылу апа буламы соң? Кабер ташындагы туган-үлгән елларын күрсәткән кайгылы язудан аскарак сәрхуш скульптор эре хәрефләр белән «инженер» дигән сүзне дә уеп куйган. Кабер ташын куярга килгәч, әнисе шул тирәдә яшәүчеләргә улының инженер булганлыгы, искиткеч бер проектны эшләгәндә җибәргән хаталары өчен хөкем ителгәнлеге, төрмәдән качуы да, аны көтеп ала алмыйча, кияүгә чыгып куйган сөйгән кызының туена кайтып керү ниятеннән генә булганлыгы турында сөйләгән, имеш. Сөйгән кызының туена кинәт кенә кайтып төшеп бу «инженер»ның нәрсә әйтергә теләгәне һич аңлашылмый, күрәсең, Миңсылу апаның шуннан артыгын уйлап чыгарырга башы җитмәгәндер. Әмма күз яшьләре белән сөйләнгән бу хикәят авыл халкы күңеленә сеңеп калган һәм хәзер өйләнешүче яшьләр загстан чыгуга шушы кабергә килеп чәчәк салалар, ул каберне тугрылыклы тирән мәхәббәтнең символы итеп саныйлар икән.

Әйе, Исмәгыйльнең үлеменнән соң килгән бу данына күп кенә азу ярган җинаятьчеләр көнләшеп карар, кызыгыр әле. Аны искә алганда шундыйларның кайсыдыр берсе, бик матур иттереп: «Ул бу тормышта җыр кебек яңгырап үтте, безнең хәтеребездә дә шулай җыр булып калыр әле...» — дигән, имеш. Ә бу кавем арасында андый «чәчәкле-чуклы» сүзләр бик кыйммәт бәһаләнә. Соң, һәркайда ялганга төренеп яшәгән заманда бандитларның кабер ташлары өстенә гади халык чәчәк сала икән, бу бер дә гаҗәп түгел. Картаеп барган Миңсылу апа моны яхшы белә һәм тоя, шуңа күрә дә үз вакытында кайсы якка борылырга кирәклеген дә яхшы чамалый иде.

Бер елдан соң, чираттагы туе вакытында, колакка катырак Шамилне дә үтереп ташладылар. Бу юлы инде кабер ташы тирәсендә әкиятләр сөйләп торырга кирәк булмады, чөнки шәһәр халкы «инженер» Гомәровларның кем икәнлекләрен бик әйбәт белә иде.

Улларының бер-бер артлы үлеп китүе Миңсылу апаның көчен-җегәрен шактый суырды, яше дә үзенекен

итте һәм ул калган бөтен бар булганын кызы белән киявенә күчерде. Рәшитне дә ул биләүдә чагыннан ук диярлек белә иде.

Рәшит тимер юл эшенә әйләнеп кайтмады — армиядә өч ел хезмәт иткән арада, паровозлар электровозларга алышынган иде инде, ә яңадан укып өйрәнү өчен урта белемең булу һәм тагын күпме еллар сарыф итү кирәк булыр иде. Аннары шунысы да бар: тимер юлда эшләү күз алдында үзенең абруен җуя бара иде. Каенанасы аны ит комбинатына урнаштырды, нindидер бик авыр һәм пычрак цехка. Анда ул һәрвакыт ит түшкәләреннән үз кулы белән иң шәп кисәкне чабып ала һәм курыкмыйча алып кайтып китә — чөнки проходнойдагы вахтерлар Шамилнең вә Исмәгыйльнең элекке дуслары яки Миңсылу апа үзенең органнардагы танышлыгы белән берәр бәладән коткарган кешеләр була иде. Озакламый Рәшит сугым цехыннан казылык цехына мастер булып күчте.

Ул вакытта инде Роза-Кармен тупырдап торган ике малай үстерә иде. Әмма бу балалар да гаиләгә иминлек-тынычлык китермәделәр. Һаман ызгыш-талаш, гаугасугыш белән, савыт-саба һәм гитаралар ватып яши бирделәр алар. Чакырып торсалар да, Рушан аларга барырга яратмый иде.

Рәшит тә еш кына өеннән чыгып югала. Хәтта бервакыт Мартукка кайтып, ярты ел чамасы Рушаннарда да яшәп алды. Бу ярты ел, мөгаен, Рушан күңеленә генә уелып калмагандыр. Хикмәт шунда: Рәшит поселок ресторанында казылык цехы ачып җибәргән иде. Ул җитештерә-пешерә торган искиткеч тәмле казылыклар, сосиска-сарделькалар һәркемгә дә җитә иде.

Әмма Мартук халкы ул казылыкларны ашап озак юана алмады — Кармен ирен яңадан үз йортына кайтарып утыртты һәм ысланган казылык исләре поселоктан гомерлеккә юкка чыкты.

Рәшит аннан соң да әле гаиләсен ташлап китеп йөргәләде, ераккарак, хәтта Ташкентка кадәр үк кыяклады — анда ул зур апасында бер елдан артык торды. Зиһенле, башлы һәм оста куллы ир шунда ук аякка басты, бик һәйбәтләп киенеп җибәрде, алтын тешләр куйдырды, ул вакытта бик модада булган юка гына «Полет» сәгате алып такты, анысы да алтыннан, хәтта браслеты-беләзегенә кадәр алтын иде. Ташкентның күптәннән, гомер бакый яшәп килгән «хезмәт биржасында» аны бик тиз шәйләп алдылар: ул газга көйләнгән тимер тартмалы түгәрәк мичләр ясый башлаган иде. Әлеге «биржага» ул беренче атнасында гына йөрде, аннары аны өенә ки-

леп машина белән алып китәләр, ә кичләрен тамагы тук кызмача останы шул ук машиналар китереп тә куя иделәр. Ташкент бервакытта да төзелүдән туктамады, шуңа күрә анда оста кулларны хәзер дә бик хөрмәт итәләр, югары бәһалиләр.

Рушан үзенең беренче хезмәт ялын Рәшит абыйсы әнә шулай «акча суккан» елны Ташкентта үткәрде. Якшәмбе көннәрендә алар икәүләп Комсомол күлендәге җәйге ресторанга йөриләр иде. Рәшит абыйсы әле яшь, чибәр, әйбәт киенә, шуңа күрә хатын-кыз халкы аңа сокланып карый иде. Ләкин Роза-Кармен аны Ташкенттан да йолкып ала алды — абыйсы һаман саен шуның янына әйләнеп кайтырлык булгач, күрәсең, ул хатынның да ниндидер хикмәти серләре-сихерләре булгандыр инде.

Шул җәйдә, кайчандыр атаклы булган «Регина» ресторанының куе йөзем куаклары һәм үрмә гөлләр белән уратып алынган верандасында кәефләнеп утырганда, Рушан берничә мәртәбә абыйсыннан ни өчен «мадам Баттерфляй»га өйләнмәгәнлеген сорарга талпынып карады, әмма кыюлыгы җитмәде. Бәлки, менә шул чагында ул аның егерме биш яшенә бирелгән бүләкнең серен, ни өчен Толстой, ни өчен «Воскресение» романы икәнлеген белгән булыр иде... Ләкин ул сер бүгенгә кадәр ачылмаган сер булып калды.

Рәшит абыйсын ул яңадан, бик күп еллар үткәч, үзенең үги әтисен җирләгәндә күрде, анда да күз кырые белән генә. Абыйсы нык картайган, авызындагы тешләре коелып беткәнлектән, яңаклары эчкә батып, йөзе ямьсезләнгән, элекке сөйкемлелегенең эзе дә калмаган иде. Кием-салымы да хөрт кенә, рәтләп кырынмаган да, ә бит яшьлегендә нинди көяз иде, әле соңрак, ресторанның казылык цехында мөдир булып эшләгәндә дә, тегендимондый гына егетләргә биргесез иде ул. Тавышы да, елмаюы да, нурсызланып калган күзләре дә — берсе дә элекке Рәшитне хәтерләтми, еллар аны бик нык талкыган икән...

Ташкенттан әйләнеп кайткач, Рәшит химзаводның иң зарарлы цехына эшкә урнашкан. Ул цехка зур хезмәт хакына кызыгып та беркем дә бармый, шуңа күрә кешеләрне ымсындырыр өчен, анда эшләүчеләргә күпмедер кишәрлек җир һәм йорт салыр өчен зур гына кредит бирә торган булганнар. Рәшит менә шуңа «чирткән» дә инде. Ул вакытта үзенә буйсындырып яшәтүче каенанасы үлгән, Карменның юлдан язган абый-энесе дә бу дөньяда юк, юкса язмыш кешечә яши башларга мөмкинлек

биргән булырга тиеш иде шикелле. Әмма бәхетле гаилә тормышы тәки барып чыкмады аларның.

Рәшит шәһәр читендәге химиклар поселогында әкәмәт бизәкләр төшереп, иң зур йортларның берсен җиткереп керде, аны кыйммәтле импорт гарнитурлар белән тутырды, хәтта Мәмлиевләрнең сукыр карчыгыныкы шикелле бәллүр люстра да элеп куйды, әмма йортка барыбер бәхет иңмәде. Дөрес, элекке еллардагы кебек дүрт кулдан бәллүр һәм фарфор савыт-сабаларны кырып салмыйлар иде инде, әмма шулай да...

Рәшитнең уллары үсеп җитеп, тиз аякка бастылар һәм туган йорттан бер-бер артлы чыгып та очтылар. Берсе кайдадыр Камчаткада балык тота, икенчесе Чуйский тракты буйлап еракларга машина куа. Монголиянең иң караңгы аймакларыннан йөк ташый, хәзер инде чәчләре чаларган Роза-Кармен Себер белән Камчатка арасында чәбәләнеп йөри иде. Шундый йөрүләренең берсендә ул, бик каты салкын тигезеп, Петропавел шәһәрендә үлеп кала, аны чит-ят кешеләр шундагы хастаханә зиратына җирлиләр. Диңгездәге улы әнисе үлеп утыз алты көн үткәч кенә кайтып төшә. Рәшит исә, хатынының үле хәбәрен алуга ук юлга чыкса да, һавалар начар тору сәбәпле, анда өч атнадан соң гына барып җитә. Шулай итеп, язмыш дигәнең бу гаиләне дә дөньяның төрле почмакларына таратып ташлады...

Кайчандыр сокланып, «мадам Баттерфляй» дип йөрткән Раилә апаның язмышын Рәшит абыйсы язмышыннан аерып карыйсы килми иде Рушанның. Ул бит Рәшит абыйсының райпотребсоюздагы шул чибәр бухгалтер кызга өйләнәчәгенә ихлас ышана иде. Раилә апаның да тормыш серләре ачылып бетте диярлек, аның да язмыш китабы укылды, аның тормышы шулай да тынычрак һәм иминрәк булды шикелле.

Раилә апа армиядән соң Караганда шахталарында «шактый күмер ашаган» башсыз-тәвәккәлрәк, шат күңелле бер егеткә — автолавка шоферына кияүгә чыкты. Шофер әле бик озак, кырык яшьләренә хәтле «Кооператор» командасында футбол да уйнап йөрде. Ихтимал, «мадам Баттерфляй» ире белән матур гына яшәгәндер дә — Миллиҗан эшчән, хәйләсез, әйбәт холыклы кеше иде. Әмма чибәр ханымнарга кайда бәхет елмаюын, аларның кем белән бәхетлерәк булганын кем белә бит әле? Шунысы кызганыч, бу шофер бик иртә үлеп китте, сәгате-минуты эчендә инфарктан дөнья куйды. Рушан аларның кызлары барын, ул кызның хәзер Ташкентта табибә булып эшләгәнен дә белә.

«Рәшиткә егерме биш яше тулган көнне...» дигән күңел дулкынландыргыч язулы, куе зәңгәр тышлы Толстой томыннан әнә шундый истәлекләр калган иде...

## VI

Алтмышынчы еллардагы Ташкент Рушанның күңеленә хуш килде һәм ул андагы тормышка бик тиз ияләшеп тә китте.

Сентябрьдә театр сезоны ачыла иде һәм Рушан еш кына концерт залларына китеп югала башлады. Гастрольгә килүче артистлар Ташкентны йомшак җылы көзе, мул җиләк-җимеше, халкының ачык йөзле, кунакчыллыгы, шәрекъчә ягымлылыгы һәм хәйләкәрлеге, ашыкмый гына үз көенә яши белүе өчен яраталар иде. Шунлыктан Рушан моңа кадәр газетлардан укып яки радиодан ишетеп кенә белгән кемсәләрне һәр атнада диярлек күрә торган булып китте. Ул еллардагы чиктән тыш арзанчылык аңа дуслары белән ресторааннарга йөрергә дә мөмкинлек бирә һәм ул үзе өчен исемнәре серле булган «Бахор», «Шәрекъ» кебек кызыклы урыннарны яратып та өлгергән, бигрәк тә әле революциягә кадәр үк булган күркәмлеген һич югалтмаган «Зеравшан» ресторанына йөрергә һәвәс иде. Күп еллар буена гел шунда кәеф-сафа коручылар аны искечә исеме белән «Регина» дип атыйлар, ә кинорежиссерлар «иске тормыш кыйпылчыкларының» ничек итеп типтереп яшәгәнлекләрен күрсәтергә мөмкин булганга күрә ярата иделәр.

Ул ерак калган еллар джаз музыкасының гөрләп чәчәк аткан чорында, Рушан «Регина»ның купшы-бай көзгеле иркен заллары, зур-зур кисмәкләрдәге яшел пальма гөлләре, өстәлләргә матурлап тезелгән зәңгәр бәллүрләре һәм авыр көмеш кашык-чәнечкеләре өчен генә йөрми иде. Анда Ташкентның иң әйбәт джаз секстеты уйный, тагын да төгәлрәге,— негр шикелле кара-кучкыл йөзле, озын гәүдәле үзбәк егете, саксофончы Хәлил сихерли иде аның күңелен.

Хәлилнең бөтен залны яулап, әсир итеп уйнавында нииндидер дәһшәтле хәвефлелек тә, шул ук вакытта искиткеч гүзәллек тә, күңелләрне айкап-айкап ала торган сихер дә бар иде. Ялгыз соло — импровизация башкарырга аның чираты җиткәндә, бөтен зал тынып кала. Егет торып баса да, күзләрен йомып, акыл томаланырлык транска бирелеп, чайкала-чайкала, тәмам хәлдән тайганчы уйный. Аның аскет дәрвишләрнекедәй бронза йөзе бөтенләй үзгәреп китә, изүләре ачык кызыл күлмәгеннән

муенындагы кан тамырлары бүртенеп чыкканы күренә. Хәлил һәр уйнавын, монысы соңгы мәртәбә, дигән кебегрәк онытылып уйный.

Күрәсең, үзенең гомере кыска буласын сизенгәндер, бахыр. Бер елдан соң, ресторандагы даны иң югары биеклекләргә менеп җиткәч кенә, шау-шулы бер мәҗлестә ярты төнгә кадәр уйный да, челпәрәмә китереп ваткан саксофонын һәм «китәм, берәүгә дә начарлык теләмим» дигән язуын калдырып, агуланып үлә.

Яшьлектә кешеләр белән җиңел танышып китәсең, җиңел аралашасың, бер-береңә тегенди-мондый юк-барларны гына сөйләмисең, ә бөтен йөрәк серләреңне ачып саласың. Рушан, әнә шул джаз яратуы аркасында, «Регина»да Камил исемле бер егет белән танышты. Камил дә төзүче иде. Күркәм генә, үз-үзенә нык ышанган, матур яши белүче бу егет Рушаннан бер дүрт яшькә өлкәнрәк иде. Алар әле якташлар да булып чыктылар: Камилнең туган җире Ак-булакта да, ул укыган Оренбургта да Рушанның булгалаганы бар иде.

Хәер, аларның биографияләре дә, тормышка карашлары да, мавыгу-һәвәслекләре дә бер-берсенә тәңгәл килеп тора. Бервакыт төнлә бик соңлап алар Лабзактан кемнеңдер туеннан Анхор суы буендагы Урдага җәяү кайтканнар иде. Камил шунда бер бүлмә алып тора икән (хәзер ул су буенда бер нәрсә дә юк инде, җир тетрәүдән соң андагы йортларны бетерделәр).

Кайткан чагында Рушан ул кич өчен бик табигый булган сорау бирде Камилгә:

— Синең туеңда кайчан биибез инде, Камил? — диде.

Камилнең җавабы кайсы ягы беләндер үзенекенә охшаш булып чыкты. Мәхәббәт турындагы хикәятләр чама белән шулай барысы да бертөслерәк буладыр инде. Ләкин Камилнең соңгы сүзләре исне китәрде: «Зур мәхәббәт — бәхет кенә түгел, ул зур газаплар да...» — дигән иде ул.

Камилнең сөйләгәне тәүге мәхәббәт турындагы һәр хикәят шикелле диярлек сагышлы-моңсу иде.

Ул туып-үскән Ак-булак поселогы да, тимер юл станциясе булганга күрә генә, поселок дип аталып йөртелә икән, тимер юл белән барганда — иң якын шәһәр Оренбург. Менә шул Оренбургта студентлык елларында Камил беренче курста укыганда ук шәһәр кызына гашыйк була. «Беләсеңме, ике бабасы да, ике әбисе дә исән иде. Мондый хәл тормышта сирәк очрый...» — дип сөйләгән иде Камил. Бу сүзләре белән ул мәгъшукасының никадәр иркә, өф-төф итеп кенә үстерелгәнлеген әйтергә теләде булса кирәк. Биш ел артыннан йөреп тә ул кы-

зыйны тәки үзенә карата алмаган Камил, юкса кызый белеп-күреп тора: егет бар, егет аңа үлеп гашыйк.

Институтны тәмамлаганнан соң, Камил Ташкентка эшкә җибәрелә һәм көтелмәгәнчә яхшы урнаша. Бер ел дигәндә, ул гади мастердан прораблыкка, аннары төзелеш идарәсе бүлекчәсе башлыгына кадәр күтәрелә, берике елдан хәтта баш инженер булырлык сәләте барлыгын да тоеп яши башлый. Ташкентта ул елларда йортлар да күп салына, промышленность биналары да күп төзелә һәм югары квалификацияле белгеч кадрлар җитешми иде. Бу вакытта Камил әнә шул Урдада яши, фатиры да, фатир хуҗалары да начар түгел, ә инде хезмәт хакы кичәге студент өчен галәмәт шәп, үзенең киләчәге — матур! Уңышларыннан канатланып, ул кинәт кенә Оренбургта калган мәгъшукасына кияүгә чыгарга ризалыгын сорап хат белән тәкъдим ясарга карар кыла. Чамалый егет: кызның артыннан йөрү — бер нәрсә, ә инде тәкъдим ясау — бөтенләй башка.

Җавап хаты гаҗәп тиз килеп җитә. Дөресен әйткәндә, хат салып җибәргәч, Камил шактый куркып, шөбһәләнеп тә калган була. Юк, кызны яратуы кинәт сүрелгәндер дип тә, гаилә тормышының авырлыкларыннан өркеп тә түгел, моның сәбәпләре башкада икән.

Ул, мәсәлән, сөйгәнен Ак-булакка, үзенең күпсанлы туган-тумачалары янына ничек алып кайтып керәсен күз алдына да китерә алмый. Аның туганнары надан, тәрбиясез, гаугалы, телләре тик тормас кешеләр бит... Ә дуслары?! Берәр төрле ахмак-ямьсез сүз яки сүгенү ычкындырмаслар дип ышанып, кызны алар янына бер генә минутка булса да калдыра алырмы соң ул? Юк, андый ышанычы юк иде аның.

Туганнары-дуслары бер хәл әле, Ак-булакка кайту үзе, ә кайтмый калып булмас иде, әнә шул кайту үзе сөйгәне өчен бер кимсетелү, мыскыл шикелле булыр иде: пычрак вокзал, озын кышлар буе тонналаган көл түгелгән, чокыр-чакырлы тузанлы урамнар, егетнең үзе туып-үскән кечкенә генә, тәбәнәк кенә, бернинди уңайлыклары булмаган туган йорты, баксаң, кыз күзләре белән караганда анда әле чисталык та бигүк җитеп бетми торгандыр. Менә шушылар барысы да егетне өметсез төшенкелеккә сала. Соң, ул кыз бала аның туганнары һәм якыннары белән ни-нәрсә турында гына сөйләшә алыр иде икән?

Камил инде алдан ук туган-тумачаларының, хихылдап көлә-көлә, кәләшнең бик юка-нәзберек икәнлеге, куллары хуҗалык итәр өчен яратылмаган, артык нәфис булуы турында гайбәт сатканнарын ишетеп тора шикелле.

Ә бер тутасы, һичшиксез, «мондый гәүдә белән бала табуга бик өметләнеп торасы юк» дип төрттереп тә куяр әле, ә бәлки, бөтен кварталга ишетелерлек итеп пышылдап кына тагын да әшәкерәк сүз әйтми калмас иде.

Ә туй? Туй турындагы уйлар Камилне бөтенләй бетереп ташлый. Ул сөйгәненең искечә зыялы, һавалы-тәкәллефле әти-әниләрен күз алдына китерә. Ә Камилнең әтисенең юньле-рәтле костюм-чалбары да юк шикелле, эш аңа гына калса, ул ягын Камил рәтләр дә иде әле, әтисенең күп эчүдән шешенгән йөзе, беренче рюмканы кәгеп куйганнан соң ук бар йортка ишетелерлек итеп сүгенеп җибәрүе, туй уртасында кем белән булса да эләгешеп-бәйләнешеп китүе... Ул катнашкан мәҗлесләр һәрвакыт сугыш белән, савыт-саба кыру белән тәмамлана, шуңа күрә дә бер ун ел инде аны беркем дә кунакка чакырмый иде.

Менә боларның барысы да Камилне оялта, аның җан тынычлыгын ала.

Хатны салып җибәргән көннәрнең берсендә ул төшендә үзенең туен күрә. Бу вакытта ул, саксофончы Хәлилнең уенын тыңларга дип, «Регина» ресторанына ияләшеп киткән һәм шунда бик күп туй мәҗлесләрен күргән иде инде.

Төшендәге туйда кунаклар ни өчендер «Регина»ның даими клиентлары булып чыккан — төрле кешеләр, әмма һәммәсе дә абруйлы-дәрәҗәлеләр, затлы киенгәннәр, үзләрен бик горур һәм тәкәллефле тоталар һәм бу Камилнең күңеленә бигрәк тә хуш килә, имеш. Иң гаҗәбе шул: үзенең әти-әниләре утырасы урында аксыл-коңгырт озын чәчләрен иңнәренә таратып салган калку-нәфис гәүдәле Софи туташ — оркестр җырчысы белән аның һәр кичне оркестрга якын гына килеп кунаклаучы сөяркәсе, мәһабәт кыяфәтле Марик Моленберг утыра, имеш. Туйга аеруча матур-көяз киенеп килгән һәм Голливуд фильмнарындагы ата-аналарны хәтерләткән Софи белән Марик бик матур тостлар әйтәләр, кияү белән киленне шундый ягымлы-назлы итеп кайгырталар икән дә, бу гүзәл яшь парның бәхетле булачакларына бераү дә шикләнми, имеш.

Камил бу төшеннән оялмаслык дәрәҗәдә үк юләр һәм миһербансыз түгел, хәтта таныш булмаган берәр атаклы кешене «туй генералы» итеп чакыруның да әхлаксызлык-оятсызлык икәнлеген аңлый, ә биредә — үз әти-әниләреңне мәһабәт күркәм кыяфәтле купшы-көяз кешеләр белән алыштыр әле! Аның кайдандыр укыганы бар: үз якыннары өчен оялган кеше бозык, бәгырьсез

кеше була икән. Ләкин моның шулай икәнен аңлау ничек кенә газаплы булмасын, кунакларның исерек этисенә карап, нәселдәнлек турында чыштын-пыштын сөйләшүләрен ишетеп утырганчы, шулер Марикның ялган эти ролендә булуы яхшырактыр, дип уйлый ул. Эченнән генә шулай алыштырып куюю белән килешеп, төгәлрәк әйткәндә — ялганга барып, ул үзенең бозыклыгын, күңеленең икегә аерылуын да таный...

Ул бит ничәмә-ничә еллар буе үзенең аңа булган мәхәббәтен кадерләп саклаган. Аның образын иркә-назлы, нәзакәтле итеп сурәтләгән. Хәзер инде ул аның, үзенең сөеклесенең, иренең пычрак күлмәкләрен юганын, күршеләре шикелле, иртән колонкага барып юынганын яки хуҗалардан калган шыгырдавык иске диванга үз янына килеп ятканын күз алдына да китерә алмый. Аның сөеклесе, әлбәттә, әйтеп тә, сөйләп тә бетермәслек гүзәл. Ул бары тик әкияти дөньяда гына яшәргә тиешле кебек. Камил ул гүзәл затка шундый шартлар тудыра алмаганына үкенеп, гомере буе үзен гаепле сизеп яшәр идеме? Менә шунда аның тәҗрибәсез акылы бик акыллы нәтиҗәгә килә: зур мәхәббәт — зур бәхет кенә түгел, ул зур газаплар да икән...

Шуңа күрә дә ул, кыздан кире җавап алгач, җиңел сулап куя, гүя күңелен басып торган авыр ташны алып ташлаган шикелле була. Шул көннән башлап ул кыз, егетнең күңелендә бер дә сүрелми-тоныкланмыйча, ничектер аерым бер якын кеше булып кала, аңа яшәргә комачауламый...

Аннары ике дусның юллары аерылды — Камилне көтмәгәндә генә Наманганга яңа төзелеш идарәсенә баш инженер итеп күчерделәр. Киткәндә ул Дасаевны да үзенә эшкә чакырган иде, ләкин Рушанның Ташкенттан китәсе килмәде — бу шәһәрне яратып өлгергән иде инде ул.

Наманганда Камил өйләнеп җибәрде, Рушан аның туенда кияү егете булып утырды. Камилнең хатыны Замирә Кырым татарлары кызы, чибәр генә табибә иде. Рушан аны ошатып калды. Дусты кияү булып барып кергән гаилә дә аның күңеленә хуш килде. Ташкентка берәр эш-йомыш белән килеп чыкса яки кая да булса ялга китеп барышлый, Камил һәрвакыт Рушанны эзләп таба торган иде. Шулай итеп, алар һаман да очрашып тордылар, аннары ничектер әкренләп аралары өзелде — тормыш шундый кырыс бит ул. Дасаев танышлары аша Камилнең малае белән кызы барлыгын да ишетеп белә, тормышын шулай көйләп җибәргән дусты өчен шатланып бетә алмый иде.

Җир тетрәгәнчегә кадәр яшьлегендә «Регина» ресторанында еш очрашып йөргән танышларыннан берсе моннан бер еллар элек аңа Камилне берничә мәртәбә Ташкентта, теге «Лотос» кафесы тирәсендә күргәнлеген әйтте. Бу хәбәр яшьлек хатирәләрен актарып ташлады, Лабзактагы күптәнге туй, шул туйдан кайтышлый Камилнең җавапсыз калган мәхәббәте турында сөйләгәннәре искә төште. Моның бер күңелсез ягы да бар — «Лотос»ның шәһәрдә начар даны таралган иде.

«Лотос» янында «Пахтакор» командасының атаклы һөҗүмчесен күргән көнне Рушан, ниһаять, Камилне дә очратты. Камил Рушан китәргә җыенганда гына, кафе ябылыр алдыннан гына килеп керде.

Әгәр дә Рушан аны, бу «пыяла гөмбә» янында ничә көннәр сагалап тормыйча, урамда гына очратса, бәлки, танымыйча узып та китәр, алар аймылыш булырлар иде. Элекке үз-үзенә ышанычлы матур-көяз Камилне тануы да кыен иде. Иң элек аның өстендәге костюмы күзгә ташланды, ул туйга алынган һәм аны алар икәүләп бик авырлык белән генә юнәткәннәр иде. Ике капламлы инглиз тройкасы иде ул, соры төскә кара-корым буй-буй сызыклар төшерелеп, бил тирәсен тарайткан пинжәк гомер тузмас шикелле иде.

Рушан үзенең элекке дустын бер ярты сәгать булса да читтәнрәк күзәтеп тормакчы булган иде, барып чыкмады: Камил аны шунда ук күреп алдымы, әллә күз карашын тойдымы шунда — баш какты. Көтмәгәндә шулай «пыяла гөмбә»дә очрашып, шактый вакытлар үткәч, Рушан күңелсез бер нәтиҗәгә килде: соңыннан килеп чыккан фаҗиганең сәбәбе, бәлки, шул көннән башлангандыр? Сәрхушлектән психикасы какшаган кешедән моны көтәргә бик мөмкин иде.

Күрәсең, Камил «Лотос» тирәсендә аны яшь, уңганбулган заманнарында белгән кешеләрне очратмасына ышанган, ике миллион халыклы Ташкентта эреп юкка чыгарга уйлаган булгандыр, мөгаен, шунлыктан да Рушанны ул бик тиз күреп алгандыр, аның үзен эзләп килгәнлеген аңлагандыр.

Юк, ул үзенең иске дустын танымаганга салынып, сиздермичә, тиз генә чыгып китәргә тырышмады. Андый чакларда, гадәттә, башка исерекләр кыланган кебек, тупас-әшәке сүзләр дә әйтеп тормады, гаепле елмаеп килде дә калтыранган кулларын як-якка җәеп: «Менә шулай килеп чыкты, туган, син гафу ит инде...» — дип мыгырданып кына куйды.

Рушан аны шул кичтә үк үзе белән алып китәргә

теләгән иде, әмма Камил киреләнде: «Теләсә кайсы башка көндә, ләкин бүген түгел...» — диде.

Аерылышыр алдыннан, Камил кинәт кенә әйтеп куйды:

— Хәтерлисеңме, кайчандыр яшьлектә без синең белән Лабзактагы туйдан тәрәзәләре Анхор суына карап торган минем бүлмәгә кайтып бара идек. Мин сиңа шунда яшьлегемдә өзелеп сөйгән Оренбург кызы турында сөйләгән идем, аның миңа кияүгә чыгарга теләмәгәнен белгәч, шатланганымны да әйткән идем. Хәтерлисеңме?

— Хәтерлим,— дип җавап бирде Рушан.— Синең ул кыйссаң ни өчендер минем күңелемә кереп калган, мин еш кына синең сүзләреңне кабатлый идем: зур мәхәббәт — зур бәхет кенә түгел, ул зур газап та...

Камил, керләнеп каткан җиңе белән кинәт кенә яшьләнгән күзләрен сөртеп алды да, күп газаплар аша үзе инанган сүзләрен әйтте:

— Аның миңа кияүгә чыкмавы зур бәхет! Мин моңа һаман саен шатланам... Аңлыйсыңмы, шатланам...

— Ни өчен? — дип аптырады Рушан.— Бәлки, син аның белән бәхетле булган булыр идең, тормышың да башкачарак көйләнер иде...

— Юк! — диде гаҗәп ышанычлы итеп Камил.— Минем белән булырга тиеш нәрсәләр барыбер булыр иде. Язмыш... Эчкечедән эчкече генә туа, күпләргә бу фикер ошамаса да, фән бу хакта үзенең ныклы сүзен әйтеп чаң кагарга тиеш...

Дустының үз сүзеннән кире чигенүенә ышанмаса да, Рушан: «Бу әле бәхәсле мәсьәлә»,— дигән булды.

Алар, шушы кечкенә бакчада бер көннән соң яңадан очрашырга сүз куешып, караңгы төшкәч кенә метро ишеге төбендә аерылыштылар. Кайтып барышлый Рушан һаман да Камил турында, Ак-булактан килгән ярлы студент егетне, ихтимал, инде күптән оныткан Оренбург кызы турында уйланып кайтты. Үзенең гүзәл һәм гел уңышлардан гына торган яшьлегендә шулай бәхетсез мәхәббәткә тарган Камил, ничектер инстинктив рәвештә, үзе дә сизмәстән, ул кызга бәлаләр генә китерәчәген аңлаган, күрәсең. Чынлап та, зур мәхәббәтнең серләре сөйләп бетергесез буладыр шул...

Билгеләнгән көндә Камил бакчага килмәде. Күңелендә ниндидер борчылу сизенеп, Рушан, аны эзләп, Куйлук дигән җиргә китте. Камил анда элекке бер буфетчы хатынга барып сыенган булган икән. Биредә Рушанны коточкыч күренеш көтеп тора: кайчандыр чибәркөяз, ә хәзер эчеп кешелектән чыккан Камил ул килергә ике сәгатьләр генә кала асылынып үлгән иде.

Рушан үзен бу ят һәм шапшак йортка ниндидер бер илаһи көч тартып китергәнен, дустын кешеләрчә җирләргә кирәклеген аңлады. Камилнең үлемендә үзенең дә күпмедер гаебе бардыр кебек тоелды аңа: теге көнне «Лотос»ка барып, аны сагалап торып очрашмаган, үткән тормышларын искә төшереп утырмаган булсалар, кем белә, бәлки, Камил әле һаман яшәр иде... Әлбәттә, аның бу тормышын яшәү дип атап булса...

Камилнең үлеме Рушанның хәтереннән бик озак китмәде. Ул аның Намангандагы тормышы турында тәфсилләбрәк белешергә теләде: бәлки, егетебез хатынынннан уңмагандыр? Бәлки, бу фаҗиганең төп сәбәбе гаиләдәдер? Әмма Камилне яхшы белүчеләр сәбәп бөтенләй Замирәдә дә, гаиләдә дә түгеллеген сөйләделәр. Элекке прораб алай кинәт кенә эчә башламаган, төзелештәге бик күпләр шикелле, эчүгә әкренләп эшендә тартылган булган икән...

Язмыш дигәнең үзенең шәфкате белән Оренбург кызын бәладән коткарып калса, икенче канаты белән бер гаепсез Замирәгә кайгы-хәсрәт салып киткән. Рушанның күз алдында шундый матур башланган тарихның шундый моңсу азагы... Дасаев өчен тагын шунысы да сер булып калды: ни өчен Камил тормышына чик куяр алдыннан да үзенең мәхәббәтен кире каккан кыз турында уйланды икән? Ни өчен үз балаларының әнкәсе булган бәхетсез Замирә хакында бер сүз дә сөйләмәде икән?

## VII

Үткән гомереннән кем яки нәрсә Рушанны әлеге «мәңгелек китап» турындагы уйларга этәргәндер, кичләрен сәгатьләр буена тәрәзә янында басып торырга дучар иткәндер, хәзер инде тәгаен генә әйтүе дә кыен. Шунысы бәхәссез: якыннарының-дусларының үзе белән тыгыз бәйләнгән язмышлары көн саен үткәннәргә әйләнеп кайтырга сәбәпче булды.

Рушан Дасаев үз хәтеренең мөмкинлекләренә таң кала, аның турыдан-туры үзенә кагылышлы булмаган, бары тик ишетеп кенә белгән, инде менә ничәмә-ничә еллар үткәч, күңелендә кинәт кенә яшен ташыдай чатнап-яктырып киткән әллә кайчангы вакыйгаларны саклый алу сәләтенә исе китә.

Менә әле дә бала чагында һәм яшьлегендә тормыш юлында очраган бик күп кешеләр арасыннан хәтере ни өчендер кинәт кенә чеченнәр белән немецларны аерып алды, аларның фаҗигале ачы язмышлары гыйбрәтле дә, кызганыч та иде шул...

Һай бу дөнья!..

Инде бишенче дистәсен ваклагач кына, Рушан даһи юлбашчы Иосиф Виссарионович Сталинның урман полосалары гына утырттырмаганын, ә бөтен бер халыкларны, туган җирләреннән тамырлары белән каерып алып, күчереп утырттырганын, генераллиссимусның бу явыз эшгамәлләре хәтта ерак даладагы Мартук шикелле тын почмакларга да килеп бәрелгәнен бар тирәнлеге белән аңлады.

Чеченнәрне туган җирләреннән кырык дүртенче елда сөргәннәр. Алар Мартукка, далалы кыргый бу якларга инде кыш иңгәч килеп чыкканнар. Бу вакытта Рушанга нибары өч кенә яшь булган әле.

Аның хәтерендә, тоныкланган-төссезләнгән кинокадрлар яки фоторәсемнәр шикелле генә булып, озын муенлы кызыл бакыр кувшин-чүлмәкләр күтәргән кара яулыклы хатын-кызлар, бу яклар өчен гайре табигый йонлач папаха бүрек кигән картлар гәүдәләнә. Алар «Казбек» папиросы тышындагы җайдакны хәтерләтәләр иде. Рушанның әбисе, әгәр дә даладагы бу поселокта чеченнәр белән бер үк диндә — мөселман динендәге казакълар белән татарлар булмаса, ул бахырлар зәмһәрир салкын кышта шул елда ук үлеп беткән булырлар иде, дип сөйли иде. Үзләре дә ач-ялангач, күшегеп-туңып яшәүче халык, сукыр Мәмлиева карчыкның — Рушанның әбисенең ихтыярына буйсынып, хәлсез-зәгыйфь чеченнәрне өй буенча таратып алып бетергән, ул беренче авыр кышны исән-имин чыгарга ярдәм иткән. Ә язын инде чеченнәр үз тормышларын җайга салырга тотынганнар. Мартукның тирә-юнендәге дала басуларына моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән кукуруз чәчкәннәр, дәррәү җыелышып, өмә ясап, йортлар күтәргәннәр — гаҗәп эшчән һәм нык-таза булып чыккан бу тау халыклары!

Җылы якларда яшәргә күнеккән, әмма Кавказда һәрвакыт иң биек папаха бүрек киеп йөрергә өйрәнгән чеченнәрне ач-ялангач килеш далада кышларга сөргән Юлбашчы, күрәсең, аларның исән калырларына исәп тотмагандыр. Кешеләрнең күңелләрендә әле кызгану хисе һәм шәфкатьлелек сакланып калганлыгын, әле ни тырышып та, маузерлар һәм төрмәләр белән генә кырыпсеберeп бетерелмәгән дин-иман исән икәнлеген дә күзаллый алмагандыр...

Чеченнәрне кайвакыт «чехлар» дип атап йөртәләр иде. Рушаннар сыйныфында да берничә чечен малае укыды. Шуларның берсе Гани Цупаев белән Рушан бер партада утырдылар. Ничектер бервакыт Рушан, ял көне балыкка

барырга сөйләшеп куярга дип, аларның өенә барып керде. Ишек шар ачык булганлыктан, ул шакып-нитеп тормаган иде. Кухня һәм өйалды хезмәтен үтәгән алгы бүлмәдә Ганинең әтисе, фронтовик-пулеметчы Мәхмүт ага утыра. Ул үзенең гаиләсен сугыштан соң шушы Мартукка килеп эзләп тапкан иде.

Эчкә батып кергән ябык күкрәкле һәм кайгылы карашлы бу кеше тупас кына каккалап-суккалап ясалган өстәл янында утыра. Алдында — өстәл өстендә исә таутау акча өеме — шулкадәр акчаның булырын Рушан күз алдына да китерә алмый иде. Ул чор балалары хәзергеләр шикелле мәми авыз түгелләр һәм ике йөз илле-өч йөз илле сум хезмәт хакы өчен эти-әниләренең таңнан төнгәчә бил бөккәннәрен күреп үсәләр, ә инде биш көнлек эш атнасы турында ул заманнарда берәү дә уйлап карамый иде. Бер мизгелгә күз карашын акчалардан Рушанга күчергән йорт хуҗасы, күрше бүлмәгә таба кычкырып, улын дәште. Өсләренә кайнар су сиптеләрмени, малайлар икәүләп урамга атылдылар.

Ишегалдына чыккач, һаман да әле дулкынлануын баса алмаган Рушан сорап куйды:

— Кайдан сездә шулкадәр күп акча?..

Гани аңа ничектер зурларча карап алды да кистереп әйтте:

— Безнең акчалар түгел ул. Иң яхшысы, син ул хакта оныт, яме! Юкса безгә бик зур күңелсезлекләр булырга мөмкин,— диде.

Рушан үзенең нindидер бер сернең шаһиты булганлыгын аңлады һәм бу хакта беркайчан да, беркемгә дә сөйләнеп йөрмәде. Юкса алар, мәктәптә Гани белән бергәләп, Павлик Морозов турында укыганнар иде инде...

Ярлы чеченнәр өендә күргән ул тау-тау акча өеме бервакыт хәтеренә килеп төште дә Рушан, соңлап булса да, аларның серен аңлаган-ачкан кебек булды. Әмма ул вакытта ул кем белән булса да үзенең бу ачышын, мөгаен, уртаклаша алмас иде, аннары кем дә булса аны аңлармы, ул вакыйгага Рушан салган тирән мәгънәне ачып биргән булыр идеме икән? Бүген андый гына түгел әллә нинди серләр ачылган заманда, аның хакында да сөйләргә ярар иде. Бигрәк тә яшь чечен егетләренең шул акчалар өчен нинди михнәтләр күргәннәрен белгәннән соң... Хәзер инде кемнән исәп-хисап сорыйсың? Иптәш Сталиннан сорасаң гына инде... Ә табышмакка җавап гел очраклы гына табылды...

Җитмешенче елларда совет матбугаты һәм телевидениесе һәртөрле милли-азатлык хәрәкәтләренә һәм сул

партияләргә зур игътибар бирә, теге яки бу партия өчен акча вә алтын-көмеш кебек кыйммәтле әйберләрне талап йә урлап алуны экспроприация дип атап, аны милли көрәшләрнең батырлык сәхифәләре итеп күрә килде. Гомумән алганда, бу тактика яңа түгел, аны анархистлар да, большевиклар да кулланган, бу эш-гамәлнең тарихка кереп калган үз каһарманнары да булган: Кропоткин, Камо, Савинков...

Телевидение Латин Америкасындагы милли-азатлык көрәше өчен акча юнәткәндә, гомерләрен дә кызганмаган яшь егетләр турында чираттагы тапшыруын күрсәткән чагында, Рушан Мартукта һәм бөтен өлкәдә бик еш булып торган судларны исенә төшерә иде — әле банк яки саклык кассасын басалар, әле берәр алтын-көмеш кибетеннән соңгы кашыгын да калдырмыйча талап чыгалар. Талаучыларны һәрвакыт диярлек тоталар, алар чечен егетләре булып чыга иде. Шунысы гаҗәп: акчалар да, алтын-көмешләр дә һичкайчан табылмый, егетләр озак елларга төрмәгә утыра — балигъ булмаганнарына да ун елдан кимне чәпәмиләр иде. Ул малайларның күбесен Рушан яхшы белә, бергә уйнап үскән малайлар иде бит...

Телевидение тапшыруларын карый торгач, ул Цупаевлар өендә үзе кайчандыр күргән тау-тау акчаларның кайдан килгәнлеген аңлап алды. Ул инде сөрелгән чеченнәрнең, үзләрен туган ватаннарына кайтаруны таләп итеп, Мәскәүгә даими рәвештә йөргәнлекләрен, вәкилләр җибәреп торганлыкларын белә иде. Теләсә нинди сәяси көрәш зур чыгымнар сорый. Ул акчаны чечен егетләре иректән мәхрүм булу бәрабәренә табалар икән. Себер төрмәләренә әле мыек та чыкмаган яшүсмерләр булып китеп, аннан чаларган ир-атлар булып исән-сау кайта алганнары ничек яшәп яталар икән хәзер?

Техникумда укыганда Рушаннар группасында Алга якларыннан килгән чечен егете Лом-Али Хәкимов укыды — бик акыллы, сәләтле, сәясәт белән кызыксына, һәрнәрсәне төбенә төшеп аңларга тырышучан иде ул. Аның кулында һәрвакыт төргәк-төргәк газет була. Аңа төрле политинформацияләр уздыруны тапшыралар. Хәкимовны белгән кешеләрнең берсе дә аның кайчан да булса дипломат яки берәр зур сәяси эшлекле булырына шикләнми иде. Лом-Али тулай торакка еш кына килеп йөрүче бер абзасы тәрбиясендә булды. Күрәсең, бу егеткә туганнары да зур өметләр баглаган булганнардыр.

Газетлар актарып утырганда, бу талантлы егетнең фамилиясен очратырмын, дип уйланган чаклары да булды Рушанның. Ул да Хәкимовның йә дипломатик, йә партия

баскычларыннан югары үрләячәгенә ышана — егеттә тегесенә дә, монысына да җитәрлек һәвәслек бар иде. Әмма егет, өметле бик күп яшьләр шикелле үк, кинәт кенә юкка чыкты, күзгә чалынмый башлады.

Бервакыт шулай тулай торак ишегалдында йөргәндә, Хәкимов Рушанга болай дигән иде:

— Ә беләсеңме, чечен телендә «әфәнде» дигән сүз юк. Димәк, «кол» дигән төшенчә дә юк. Менә шулай, дустым…

Мөгаен, дөрестән дә, шулайдыр — чеченнәр арасында Рушанның куркакларны, кыюсыз-йөрәксезләрне очратканы булмады. Соңгы мәртәбә перронда басып торганда, Хәкимовны Грозныйга алып китәргә тиешле тиз йөрешле поезд кузгалыр алдыннан биш минут кала станция чаңын суккач, егет хушлашып әйтеп куйды:

— Мин синең дусларың арасында берәр чечен егете булуын телим. Син беләсең бит, без чеченнәргә ышанырга була…

Гомер үтеп бара, әмма чеченнәрдән Рушанның Лом-Алидан башка дуслары тәки булмады. Кайчандыр тиз йөрешле «Москва — Ташкент» поезды түбәсендә дәртләнеп хыялланган егет үзенең дүрт елын матур итеп Лом-Али белән бер бүлмәдә яшәп уздырды. Шуның белән шул…

Аннары Рушан «кукуруз» сүзен ишетсә, Никита Сергеевич Хрущевны түгел, ә чеченнәрне исенә төшерә, чөнки далалы якларга ул гаҗәеп үсемлекне шулар алып килде. Казакъстан җирләрендә шулар тернәкләндереп җибәрде бит. Чеченнәрнең кукурузлары икешәр метрлы булып үсә, һәр нәрсәсе файдага китә: чәкәне — орлыкка, сабагы — малларга. Аларны ягып өй җылыталар һәм хәтта йорт түбәләрен дә шуның белән ябалар иде.

Мартукта Вавилондагы телләр буталышын белмәсәләр дә, анда ул елларда калмыгы да, нугае да, ингушы да, алманы-немецы да, яһүде дә үз телендә сөйләшә белә иде… һәм боларның күбесе иленнән, туган якларыннан сөрелгән халык иде…

Немецлар поселокка барысыннан да алдарак килеп төштеләр. Аларны төрле җирләрдән — кайчандыр әле Ленин мактап телгә алган үз республикалары булган Идел буеннан, Кубаньнан, Краснодардан, Ставропольдән сөргәннәр иде. Немецларны күп китерделәр, чеченнәрдән нык күп, шуңамы алар бик тиз тернәкләнеп киттеләр — ул заманнарда эмиграция турында, тарихи ватаннары булган Германиягә китү турында сүз дә булырга мөмкин түгел иде. Алар бик ныклап, озакка исәпләп төпләнделәр.

Аларны, мөгаен, туган-торган җирләреннән егерме дүрт сәгать эчендә җыеп алганнардыр, ә яңа урында бөтенесен дә яңабаштан булдырырга кирәк иде.

Рәсәй немецларының гаиләләре күп балалы. Югары уку йортларына, фән тирәсенә керү юлларына хакимият әллә нинди киртәләр корса да, ул балалар комсызланып белемгә омтыла иде. Бүген, совет немецларының Германиягә күпләп киткән бер чорында, кызганыч ки, кайчандыр аларның бабаларын чакырып китергән Россиягә ике йөз ел эчендә дә немецлар өчен чын ватан була алмаганын танырга гына кала. Ә бит немецларның илебез алдындагы хезмәтләре гаять зур булды. Алар Рушан яшәгән ерак дала поселогында да үзләренең игелекле эзләрен калдырып киттеләр.

Илленче еллар башыннан ук Мартук киңәеп-җәелеп үсә башлады. Ә немецлар әллә нинди әкәмәт йортлар төзиләр иде. Пыялаланган иркен верандалар, зур-зур тәрәзәләр белән, менә дигән сарайлар-мунчалар белән һәм бер йорт икенчесен һич тә кабатламый. Һәр хуҗа үз йорты өчен нинди дә булса бер хикмәтле үзенчәлек эзләп табар иде. Ул йортларны шунда ук «немец йортлары» дип кенә йөртә башладылар. Шуларга карап, җирле халык та бу архитектура яңалыкларын кулланырга тотынды — без кемнән ким, янәсе!

Немецлар килгәнче, бу тирәләрдә ни агач, ни чәчәк юньләп үсә алмый, дигән катгый фикер урнашкан иде, ә алар килеп, тормышларын көйләп җибәргәч, һәр ишегалдында чәчәкләр-гөлләр дә пәйда булды, хәтта алмагачлар гөрләп чәчәк атты, соңрак йөзем куаклары да күренде. Ә инде помидоры-кыяры, болгар борычы, иртә өлгерә торган кәбестәсе, башлы суганы-кыяклысы — һәммәсе хуҗалы һәр йортта үсә иде.

Күрексез-шыксыз дала Мартугын немецларның шулай гөрләтеп үзгәртеп җибәрүен беркем дә инкарь итә алмастыр. Алар килгәч, тирә-якта чиләк-чиләк сөт бирә торган голланд токымлы сыерлар һәм бекон дуңгызлары бихисап үрчеп китте. Дөрес, аларга кадәр дә һәр урыс ишегалдында чучка мыркылдый иде, әмма дуңгыз ыслау җайланмаларын немецлар гына булдырды. Кешеләр ысланган казылыкның исен-тәмен татыдылар. Поселокның иң зур предприятиесе — бөтен районның авыл хуҗалыгы техникасына ремонт ясала торган РТС озак еллар буена республикада алдынгы хуҗалыкларның берсе булып килде. Анда, нигездә, немецлар — техникага хирыс халык эшли, алар инде аннан-моннан гына эшләргә һич күнекмәгән иде.

Чираттагы төзелеш ыгы-зыгысы Мартукта яңадан алтмышынчы еллар башында купты, анда өлкәдә иң зурлардан булган элеватор сала башладылар. Халык төзелешкә дәррәү кузгалды — әйбәт түлиләр иде, иң мөһиме — төзелеш материаллары юнәтү җае чыкты. Җирле халык арасыннан Рушан биредә бердәнбер прораб иде, аның участогында немецларның комплекслы ике бригадасы эшләде. Алар мәктәптә бергә укыган малайларның әтиләре һәм абыйлары иде. Шулай итеп, бөтен дөнья таныган «немец хезмәте»нең ни-нәрсә икәнлеген Рушан ишетеп кенә белми, ә күреп тә белә, алай гына да түгел, үзе дә бик яхшы үзләштергән иде.

Ул заманнарда тактадан кормаштырган әрҗәләргә коела торган монолит бетон бик худта булды. Техник шартлар буенча, инде бер файдаланылган опалубка тактадары исәптән сызылып, яндырылырга тиеш, ә хуҗаларча карасаң, аларны әле теләсә кайда кулланырга була, кулың гына җитсен! Халык рәхәткә тиенде — сыпырталар гына шул такталарны! Такталарны йорт-кура төзелешенә алырга тәвәккәлләп, Рушан рөхсәт бирде. Хәтерендә, ул үзенә дә шундый бер машина такта кайтарткан — сарай түбәсен ябарга, күптән череп беткән кoйманы алыштырырга кирәк иде. Далалы Мартукта агач алтын бәясе иде бит. Әмма инде исәптән сызылган шул такталар гомере буена Рушанның күңелендә уелып калды.

Такта бушаткан «трехтонка» машина чыгып китәргә дә өлгермәде, гадәттә тын гына йөргән әнисе көтмәгәндә тавыш кубарды — бу такталарны хәзер үк яңадан төзелешкә илт булгач, илт, янәмәсе! Башта әнисенең шулкадәр хафага төшүен аңламады. Әнисе күрше урамда яшәүче немец Тилковскиларны мисалга китергәч кенә, күңелендә борчылу хисе кузгалды һәм яңадан төзелештән бер нәрсә дә алып кайтмаска вәгъдә бирде. Ул әнисенең йөрәгендә гомерлеккә уелып калган курку хисенең ни-нәрсә икәнлеген сизенде. Ул хисне һичничек тә юып ташлап булмасын да белә, хәтта вакыт та бу очракта көчсез иде.

Ә эш менә нәрсәдә иде.

Рушан Дасаев белән бер сыйныфта бик тыныч, тырыш немец малае Коля Тилковски укыды. Аның соңрак сәер генә рәвештә күлгә батып үлгән Юра исемле абыйсы һәм Ольга исемле сеңлесе дә бар иде. Хәзер Рушан белә инде: меңләгән совет немецлары бомбежкалар вакытында һәлак булган яки хезмәт лагерьларында үлеп калган заманнарда әтисезлек гадәти күренеш иде һәм ул беркайчан да Коляның әтисе кайда икән, дип кызык-

сынмады. Инде менә хәзер, соңлап булса да, сыйныфташының әтисе язмышын белде.

Сугыш елларында, немецларны Мартукка сөреп китергәч, Тилковскиның әтисе элеваторда грузчик булып эшләгән — ач-ялангач еллар, өйләрендә өч бала, аларны ашатып-эчертеп тотарга тыныч заманнарда да җиңел булмас иде һәм менә көннәрдән беркөнне Рушанның әнисе белән күрше хатынын Тилковскилар яшәгән землянкага «пүнәтәй» итеп чакыралар — такы-токы гына белемле әнисе бу сүзне гомеренә оныта алмады. Өлкән Тилковски эштән кайтып керүгә үк, аның артында НКВДдан килгән ике кеше дә пәйда була. Шунда хуҗаның кесәләрен туптуры шул «пүнәтәйләр» кулына бушаттыралар...

Әнисе, күз яшьләренә тыгыла-тыгыла, ул бичараның сырган фуфайка кесәләренең икесеннән чыккан бодайның бер кушучка да җыелмаганын әрнеп сөйләгән иде. Әнисенең кулына бушаттырылган әнә шул бер кушуч булыр-булмас бодай өчен немецка унбиш елны чәпәп тә куйганнар. Ул аны көнен көнгә, минутын минутка дигәндәй, тутырып утырып чыккан.

Бер кушуч бодай өчен — унбиш ел! Бу вакыйга Рушанны тетрәндергән иде һәм ул шуңа күрә дә әнисенең курку-өркүенең ни дәрәҗәдә булганлыгын төшенде.

Ярар, сугыш еллары, законнар кырыс-каты заман. Шулай унбиш елны чәпәсеннәр дә, ди. Ә ни өчен сугыштан соң, һич югы, бөек Җиңү көне уңае белән, шулай хөкем ителгәннәрнең эшләрен яңадан карамаганнар? Өйләрендә, елашып, өч бала утырып калган бит! Чын-чынлап кешеләрне кол дәрәҗәсенә төшергәннәр, алардан бары бер генә нәрсә — бушка эшләү генә таләп ителгән. Тилковскины, мөгаен, төрмәдән дә чыгарырга теләмәгәннәрдер әле. Немецлар бик намуслы һәм эштә ару-талуны белмәс халык бит...

Өлкән Тилковски Себердән 1959 елның ноябрендә генә кайтып, Рушан бригадаларының берсендә балта остасы булып эшли башлаган иде. Прораб бу сүз тыңлаучан эшчән немец алдында миһербансыз дәүләте өчен үзен ничектер гаепле итеп тоя һәм аны бервакытта да төнге сменага яки вагоннардан цементтыр-агачтыр бушатырга, авыр эшләргә куймый, немецның эшлисен тулысынча «тегендә» эшләп бетереп кайтканлыгын аңлый иде...

Тилковскилар гаиләсенең, картайган әтиләрен алып, Германиягә яшәргә китеп барганнарын Рушан туганнарыннан ишетеп белә һәм еш кына болай уйлый: «Шундый авырлыклар белән аларны соңлап булса да үзенә сыендырган тарихи ватаннары үзләренә ягымлы, шәфкатьле булсын! Бу якларда алар бер игелек тә күрмәделәр

бит. Инде беркем дә, беркайда да бер кушуч чүпле бодай өчен немец Гюнтер Тилковски түләгән хакны түләмәсен иде...»

Чеченнәр белән еш кына шау-шулы, гаугалы хәлләр булып тора — аларны спецкомендатура кешеләре дә, НКВД вәкилләре дә куркыта алмый иде. Алар үз абруй-дәрәҗәләрен кимсетергә бирәүгә дә юл куймыйлар, кергәндә бик җентекләп тентеп кертсәләр дә, чечен кешесе белән наганлы бер генә түрә дә кабинетында япа-ялгыз, күзгә-күз калырга тәвәккәлләмәс иде. Ул заманнарда түрә-башлыкларның өстәл өсләрендәге барлык авыр әйберләр: генераллиссимус Сталинның бронза яки мәрмәр сыны да, шулай ук тимер Феликс сыны да, ул елларда бик модалы булган, чуеннан коелган авыр язу әсбаплары да, хәтта сулы графиннар да җыеп куелган, дип сөйлиләр иде.

Ә немецлар бөтенләй башка кавем — тып-тыныч, законнарга буйсынучан халык, спецкомендатурага да артык мәшәкать тудырмыйлар.

Ләкин бервакыт гайре гадәти хәл — ЧП килеп чыга, бу вакыйгадан соң тау халыкларының барлык кыю гамәлләре дә тоныкланып кала. Немец егете Рубинның эше белән НКВДның Мәскәүдәге зур түрәләре һәм хәрби разведка үзе шөгыльләнгән, имеш, дип сөйләделәр. Рубин ул чагында әллә сигезенче, әллә тугызынчы сыйныфта укый һәм поселокның аргы башында яши иде, шуңа күрә Рушанның аның белән очрашканы юк, бары тик әнисе белән ялгыз яшәгәнен генә белә, әнисе исә мәктәптә мич ягучы һәм җыештыручы булып эшли иде...

Ерак калган балалык елларын хәтереннән үткәргәндә, Рушан Дасаев үз мәктәпләрендә җыештыручы булып эшләгән немец хатын-кызларын да, берничә сүз белән генә булса да, яхшы яктан искә алып китәргә кирәк тапты.

Аларның иркен һәм төзек мәктәпләрендәге һәр сыйныф бүлмәсе ул заманнарда күмер ягып җылытыла, ә балалар ике сменада укый, өлкәннәр өчен әле кичке өченче смена да бар — димәк, иртә таңнан караңгы төнгә кадәр егермедән артык мичкә ягыла дигән сүз. Җитез-эшчән җыештыручылар ул күмер төткәзеп булмаслык комсыз мичләргә ягып кына калмыйлар, дәресләр барган араларда һәр тәнәфестә мәктәпнең озын коридорларын да ялт иттереп юып чыгаралар иде. Хәзер, инде үзе өлкәнәйгәч, Рушан ул хатын-кызларның хезмәт сөючән тырышлыгы йөзләрчә балаларны туберкулездан саклап калганын яхшы аңлый.

Мәктәпләрендәге ул җыештыручыларны Рушан Рубинга бәйләп кенә искә алмый. Бервакыт ул, төзелеш эшләре белән Нукуска баргач, очраклы гына бер мәктәпкә барып кергән иде. Үзәктән ягып җылытышлы, заманча салынган мәктәптә аның тыны кысыла башлады һәм бу мәктәп бүлмәләренең-залларының, коридорлары-баскычларының айга бер мәртәбә дә юылмаганын-җыештырылмаганын күрде — өч сменага йөреп укучы балалар көн саен меңнәрчә аяклардан күтәрелгән тузанны сулыйлар икән. Бәлки, шуңадыр да Каракалпакстанда сәламәт кешеләр юк диярлек, алар бит мәктәптән үк зәгыйфь көчсез үпкә белән чыгалар. Немец хатын-кызлары белгәнне мондагы җирле түрәләрнең һәм табибларның белмәве-аңламавы кызганыч, әлбәттә...

Нинди дә булса романда алар турында, ай-һай, берәр мәгълүмат табарсыңмы икән, дип, мәктәп җыештыручыларына күңеленнән генә булса да «өлешенә тигән көмешен» биргәч, Рушан яңадан хәтере белән Рубинга әйләнеп кайтты.

Немецлар ул елларда, башка бирегә сөрелгән халыклар: калмыклар, ингушлар, чеченнәр шикелле үк, торган җирләреннән комендатура рөхсәтеннән башка беркая да чыгып китә алмыйлар, кулларында беринди документ-фәләннәре дә булмаганлыктан, тегендә-монда барып йөрү өчен мөмкинлекләре дә бик чикләнгән иде. Шуңа күрәдер дә ике ай элек югалган немец малае Рубин исемле укучының, көнбатыш чиген бозып, аргы якка чыгып китәргә маташканда тотып алынуы турындагы хәбәр гаҗәпләнерлек булды. Малайны өенә, әнисе янына кайтардылар — балигъ булмаган баланы нишләтмәк кирәк? Педсоветта укытучылар биргән сорауларның барысына да аның җавабы бер була: ул үзенең тарихи Ватанына кайтырга теләгән. Аны бертавыштан: «Синең Ватаның — Советлар Союзы: син шушында тугансың, шушында әти-әниләрең һәм хәтта бабаларыңның бабалары туып-үскән, шушында гына сиңа бөек Сталин Конституциясе тарафыннан хезмәткә, түләүсез белем алырга һәм дәваланырга, йорт-җирле булырга, ниһаять, ирекле совет гражданы булырга һәм тагын әллә нинди рәхәтлекләргә тулы хокук бирелгән»,— дип ышандырырга тырышалар. Әмма шул чакта ук Рубин инде, күрәсең, үзенең чын тарихи Ватанында нинди ирекләр көткәнен аңлаган булгандыр.

Башка малайлар шикелле, Рушан да, документсызнисез, бер тиен акчасыз килеш бөтен ил аша уза алган һәм бары тик чик сакчылары гына тотып калган егетне күрергә дип, өлкән сыйныф укучылары укый торган кат-

ка йөгереп менгән иде. Баксаң — моң-сагыш тулы карашлы, ябык кына гап-гади үсмер малай икән Рубин. Отличник, контроль эшләрдә мәсьәләләрнең һәр дүрт вариантын да шартлатып чишә, математиканы бик шәп белә икән. Аның дус-ишләренең берсе дә Рубинның шундый адым ясарын — Франкфурт-На-Майнедан бер-ике мәртәбә хат һәм тентеп актарылган бер посылка килгән ниндидер абзасы һәм туганнары янына барырга җыенганын күз алларына да китерә алмаганнар икән.

Мәктәпне тәмамлагач, Рубин яңадан качкан, әмма бу юлы аны чикне бозып чыгып барган чагында атып үтергәннәр. Әнисе аны җирләргә барган, ә соңрак, бердәнбер улының каберен карап-рәтләп торыр өчен, бөтенләй шул якларга күчеп киткән, аның башка беркеме дә калмаган — ире Чиләбедәге хезмәт лагеренда һәлак булган.

Рубинны бик каты гаепләп, мәктәптә җыелыш үткәрделәр — ихтимал, кайдандыр югарыдан шундый күрсәтмә килгән булгандыр. Әмма укучылар үзара бөтенләй башкача сөйләнеп йөрделәр: Рубин кызганыч, ул бит шпион түгел, укучы гына, Мартуктан нинди серләр-фәләннәр алып чыгып китә алсын инде ул — бетәшкән «Өченче интернационал» колхозы серләренме? Яшәсен иде үзе теләгән җирдә, без бит иң ирекле илнең — Советлар Союзының гражданнары...

Хельсинки киңәшмәсенә әле күп еллар кала кеше хокуклары турындагы декларациянең барлыгын да белмәгән Мартук малайлары кырык ел элек үк әнә шулай гади һәм ачык итеп уйлыйлар иде.

Хәзер инде Рубинның ашыга төшкәне билгеле. Ул бик яшь булган шул, заманны тоемлый алмаган, сөйләшер-киңәшер кешесе дә булмагандыр — хәтта әнисе дә, мөгаен, аның уй-хыялларын белмәгәндер. Ә заманалар үзгәрә, хәтта иң авыр дигәннәре дә үтә тора, әмма беркем дә кайчан җиңеллек киләчәген, күпме көтәргә туры киләсен белми, шуңа күрә дә ашыгалар, ялгышалар һәм һәлак булалар...

Мартук парикмахерскаясында чибәр генә ике бертуган кыз — Марта белән Магда эшли иде. Рушан алардан чәчен бөтенләй кырдырып алдыра — ул елларда түбән сыйныф укучыларына чәч тә йөртергә ярамый иде. Менә шул Тиссеннар гаиләсен Көнбатыш Германиядәге ниндидер туганнары эзләп тапкан да янә имеш-мимешләр куерып киткән: имеш, туган тиешле кеше әллә банкир, әллә генерал диме шунда. Тиссеннар юлга җыена башладылар...

Мартаның ул вакытта инде ярәшелгән егете Вольдемар бар иде — Рушанның иптәше Сегизмунд Вуккерт-

ның абыйсы (энесен дус ишләре, урысчалатып, Саня дип кенә йөртә иделәр). Немецлар тиз генә туй үткәрделәр, юкса Вольдемар-Володяның кәләшсез калуы бар иде, ә инде тегендә, ГФРда андый чибәр кызны, мөгаен, берәр бюргер шунда ук сугып алган булыр иде — Рушан белән Сегизмунд шулай фикер йөрттеләр.

Дөресен әйткәндә, Володя Көнбатышка китәргә бик ашкынып тормый. Сөеклесен югалту куркынычы гына аны бу адымга этәргән иде. Мартуктан ул елап китеп барды, монысын Рушан да раслый ала. Теге яктан килгән беренче хатлары да Россияне сагынып моңлану белән тулы булды — Рушан аларны үзе укыды. Ул заманнарда кешеләрнең бер-берләреннән яшерерлек әллә ни серләре юк. Абыйсының ГФРдан язган хатларын Саня һәрвакыт мәктәпкә дә алып килә иде.

Малайларны якташларының эшкә урнашканнан соң язган бер хаты шаккатырды. Володяның анык кына бер һөнәре дә юк. Кайда нинди эш туры килсә, шуны башкарып йөри, ә поселокта эш мәсьәләсе һәрвакыт кыен иде.

Ул тегендә үзенә җайлы гына урын тапкан: кухнялар, сыраханәләр, арзанлы ашханәләр өчен кирәкле гади генә табуреткалар ясый торган бер кечкенә остаханәгә эшкә урнашкан икән. Ничек, ни-нәрсә эшләргә кирәклеген күрсәткәннәр дә, кулына эш кораллары тоттырганнар моның, әйдә, эшлә, янәсе — хуҗаның күп сөйләшеп торырга вакыты юк. Володяны көнлек норма гаҗәпләндергән — көнгә нибары ике урындык ясарга кирәк икән. Һәм ул хуҗасына Рәсәй немецларының да төшеп калганнардан түгел икәнлеген исбатларга теләгән. Кыскасы, кичкә шалт итеп сигез урындыкны ясап та куйган, хәтта төшке ашка да барып тормаган.

Мактау көтеп торганда, хуҗасының аптырап калган йөзен күргәч, үзе дә пошаманга төшкән бу. Хуҗа, әлбәттә, бик абруйлы бер танышының тәкъдиме белән генә эшкә алынган яңа эшчесенең «тырышлыгына» тиешле бәяне биргән, әмма алга таба, артык та түгел, ким дә түгел, бары тик ике генә табуретка, ләкин аларны бер ел, ике ел, ун елдан соң да кибеп какшамаслык, шыгырдап тормаслык итеп ясарга кирәклеген аңлаткан. Бәлки, менә шуңадыр да, җитмеш елдан артык совет чорында яшәгәннән соң да, кайбер йортларда гап-гади генә итеп бөгеп эшләнгән, патша заманыннан калган венский урындыклар очрый әле — аларны Россиядәге Көнбатыш илләре белән уртак предприятиеләр эшләп чыгара торган булган. Чынлап та, алар шыгырдамыйлар да, кибеп какшап та бетмиләр, һаман да исән-саулар.

Яңа хуҗалары алдында үзләрен күрсәтергә теләп, артык «тырышып» җибәргән безнең элекке гражданнарыбыз турында бик күп әкәмәт хәбәрләр сөйлиләр. Шундый хәбәрләрнең берсе Рушанның да исен китәргән иде. Күптән түгел генә Израильгә «кыяклаган» Бохара яһүде белән булган бу хәл.

Ташкенттан китеп Тель-Авивка барып урнашкан яһүд үз һөнәре буенча бер ит кибетенә эшкә кергән икән. Әлеге Володя-Вольдемар шикелле, бу да бик тырышып эшли, көн саен кибет хуҗасына әйбәт кенә керем илтеп бирә. Күпмедер вакыттан соң, хуҗа үзе кибеткә килеп чыккач, бу яһүд, уңайлырак мизгелне көтеп алган да, хуҗасын арттагы бүлмәгә чакырган һәм шунда, як-ягына карангалап, бер төргәк акча чыгарып биргән.

Кибет хуҗасы аптырап калган: «Кайдан бу?» — дип сорый икән. Сатучы яһүд мактаныбрак кына кемгәдер үлчәп җиткермәгәнен, кемгәдер сдача биреп бетермәгәнен, кемгәдер итнең сортларын буташтырып сатып җибәргәнен сөйләп биргән. Бер сүз белән әйткәндә, бездә хуҗалары ничек таләп итсә һәм үзе ничек эшләргә күнеккән булса, шулай «мәтәштергән» икән. Һәм менә бер айга шушы кадәр акча җыелган, имеш. Аның «кадерен белмәгән» хуҗа үзен шунда ук эштән куган. Бу гаҗәпкә калып, бик озак аңлый алмаган: ни өчен? Ул бит «сулдан» кергән акчаларның бер тиенен дә үзенә алмаган, хуҗасына ярарга тырышкан. Анда исә ярарга тырышырга кирәкми — намуслы һәм сыйфатлы итеп эшләргә генә кирәк икән.

Ай-һай, безгә әле әнә шул гап-гади хакыйкатьләрне — «үтермә, урлашма» дигән дини кануннарны аңыбызга сеңдерергә дә озын-озак еллар кирәк булачак! Безгә һәммәсен дә яңабаштан башларга кирәк...

Кызганыч, чит илләргә ышанычлы, эшчән, әйбәт кешеләр чыгып китә тора. Шунысы юаныч инде, ичмасам, җитмеш елдан артык чор эчендә алардан «яңа совет кешесе» ясый алмаганнар. Дөнья халыклары гаиләсенә кушыла торсыннар соң әйдә! Аларның юлына аркылы төшәргә дә, аларга буш-ялган вәгъдәләр бирергә дә кирәкми. Алар бит җәмгыятьтә үзләренең хезмәтләре, тырышлыклары, сәләтләренә тәңгәл килердәй урыннарны озак эзләгәннәр, озак көткәннәр, озак өметләнгәннәр, әмма тапмаганнар. Турысын гына әйткәндә, алар «совет кешеләре» булмаганнар, булырга да теләмәгәннәр. Ә хәзер үз тарихи ватаннары аларның түземлелегенә һәм хезмәтенә тиешле бәяне бирсен, бәхетле булсыннар алар...

Рушан Дасаевларның борын-борыннан мөселманнар яши торган кварталында бер генә урыс гаиләсе — Козловлар гына бар иде, төгәлрәге, Козлов бабай белән Августина әбекәй. Украина урамы чатындагы таба-таба көнбагышлар үсә торган, читәненә балчык чүлмәкләр эленгән йорт-кура хуҗасының ни атлы икәнен Рушан белми дә иде, чөнки олысы-кечесе аны бик гади генә итеп, Козлов бабай, дип йөри иде. Козлов бабай Мартукка Рушанның әбисе — сукыр Мәмлиева карчык белән бер үк елда килеп төпләнгән һәм алар гомерләре буена дус булганнар. Сугыш елларында Татар бистәсендә бердәнбер ир заты булып шул Козлов бабай гына калган, барлык ир-атларны фронтка озатып бетергәннәр.

Козлов бабай инде күптән, беренче бөтендөнья сугышында ук сугышасын сугышкан — «ярманнарга» әсир төшкән, өч мәртәбә качып караган, соңгысында тотып алгач, яңадан качып йөрмәсен дип, аягын сугып сындырганнар, шунлыктан ул аксак калган иде.

Үз гомерендә күпне күргән, күпне эшли белгән ул, әсирлектә немец телен дә өйрәнгән һәм Идел буйларыннан сөрелгән, инде телләрен оныткан немецларга да үз телләрен, үз йолаларын бик теләп өйрәтә, шуңа күрә аны ихтирам итәләр һәм күпләр балаларына исем кушарга да аны дәшәләр иде.

Татар бистәсендә ни-нәрсә генә килеп чыкмасын, Козлов бабайга чабалар: ярдәм ит, киңәш бир, нишләргә, кая барырга? Һәркем өчен аның ягымлы сүзе булыр, оста кулы булышыр, кирәк икән — соңгы сыныгын да бүлеп бирер иде ул. Фронттан килгән һәрбер өчпочмаклы хатны тотып, хатын-кызлар аңа баралар: ул бит фронтовик, немецлар белән беренче сугышта ике Георгий тәресе алган, әсирлектә ниндидер бер бюргерда батраклык иткән — ул инде сугышның ни-нәрсә икәнен дә белә, киңәшен бирер, каһәр төшкән сугышның кайчанрак бетәрен дә әйтер. Ләкин фронттан хатлар килү беренче кышта ук шактый кимеде: Төркестан дивизиясендә булган күп кенә мартуклылар — шул исәптән Рушанның әтисе Мирсәет тә — кырык беренче елның кышында Мәскәү тирәләрендә ятып калды. Атаклы панфиловчылар арасында да мартуклыларның ике якташы бар. Хәзер аларның исемнәрен базар артындагы тузанлы, чокыр-чакырлы ике урам йөртә.

Сугыш елларында далалы бу якларда буеннан-буена зәмһәрир салкын кышлар торды. Бөтен Татар бистәсе халкының итекләренә бушлай олтан салып утыручы Козлов бабай сукрана иде, эх, урынын да билгеләгән иделәр

юкса, ирләр белән җыелышып, кварталда сугышка кадәр бер кое казып калдырып булмады. Суга станциягә хәтле үк йөриләр, якын ара түгел, анда да әле ачулары чыккан станция хатын-кызлары арасында үзләрен уңайсыз сизәләр, әллә ничек кешенекенә кызыгып килгән шикелле була иде... Татар бистәсенә килгән чираттагы һәр үлем хәбәре кое казыр ирләр калмаячагына ишарә — читтән кешеләр ялларга туры киләчәк иде.

Фронттан иң озак килеп торган хатлар күрше казакъ Сөләйман хатлары булды. Ул да кырык бернең җәендә казып өлгермәгән коены исеннән чыгармый, мескен хатын-кызларның салкыннарда-пычракларда интегеп су ташулары өчен уфтанып яза икән. Германиягә барып җиткәч, кое өчен, һичшиксез, бер егерме метрлап шәп чылбыр алып кайтырга вәгъдә итә — ул заманнарда үзебездә тутыккан кадак та табып булмасын шәйләгән, күрәсең, бахыр. Әмма кырык дүртенче елда Будапешт тирәләрендә Сөләйман да һәлак булды, «шәп чылбыр» алып кайта алмый калды...

Козлов бабай аңлады: мескен хатын-кызларның аңардан башка ышаныр кешеләре юк — госпитальләрдән дәваланып кайтырга тиешле ир-атлар исәпкә керми, кайсы кулсыз, кайсы аяксыз дигәндәй, ә кайберләре бөтенләй сукыр. Һәм менә, Җиңү елының җәендә, Козлов бабай, үзенең голланд токымлы бердәнбер сыерын сатып, шуның акчасына кое казытты.

Кое халыкка бик озак хезмәт итте, суы да эчеп туймаслык тәмле иде. Рушан аның суын күп эчте. Инде унбиш еллап булыр, кое юк хәзер — аны күмдерделәр, хаҗәте бетте аның. Һәр ишегалдында электр белән эшли торган колонка бар. Ә кое кызганыч...

Татар бистәсендә бүген яшәүчеләр ул коены һәм аның нинди бәягә төшереп казылганын хәтерләмиләрдер дә. Козлов бабайның үзен дә онытканнардыр. Казакъ Сөләйманның берәр оныгы, кызып китеп, урыс Козлов бабайның оныгының оныгына: «Сыптыр үзеңнең Рәсәеңә!» — дип тә кычкырса...

Боларны уйлаганда, тәннәр чымырдап китә. Бер юаныч кала: ни Сөләйман, ни Козлов бабай бу сүзләрне ишетми инде...

## VIII

Хәтереннән үткәннәргә сәяхәт ясап, Рушан хәзерге заман кешесенең иң юк дигәненең дә тормышы әллә нинди вакыйгаларга бай икәнлегенә төшенде. Ә кайлар-

га гына, нинди ерак араларга барып чыкмый хәзер кеше! Әле кайчан гына ил буйлап болай тиз йөрүне берәр кеч-кенә авылмы-поселокмы кешесе күз алдына да китерә алмый иде. Чын мәгънәсендә — космик гасыр, космик еракдыклар, космик тизлек...

Кәефе килгәндә Рушан еш кына кемнәрдәндер алын-ган иске хатларны яңадан укып утыра, үз гомерендә шак-тый күп җыелган, саргаеп беткән фоторәсемнәрне озак-лап, гаҗәпләнеп карый. Алар яшәлгән елларның шаһит-лары, бер бизәлеше кебек, әмма күбрәк бу рәсемнәр яңа хәтерләүләргә этәргеч була, күңел төпкеленнән әллә кай-чан онытылып беткән хәлләр-вакыйгалар калкып чыга.

Хәзер, егерменче йөз тәмамланып килгәндә, һәртөрле гайре табигый, аңлатып булмый торган серле «фәннәр» белән моңа кадәр күрелмәгәнчә кызыксыну барлыкка килде — һәртөрле күрәзәчеләр, экстрасенслар, шаман-нар, шарлатаннар, гороскоплар белән мавыга башлады ха-лык. Берәрсенең кулына кәрт килеп эләксә — шунда ук сезнең үткәнегезне һәм киләчәгегезне әйтеп бирергә то-тыначак. Ничектер шулай фоторәсемнәр карап утырган-да, Рушан янәшә яткан ике рәсемгә тап булды, менә шулар аны ерак аралар һәм язмышлар турындагы уй-ларга этәрде дә инде. Ул күңеленнән шул ике рәсем ара-сына сызык сызды — бер кыйтгадан икенче кыйтгага хәтле булды ул сызык.

Бер фотосурәт Рушан Находка портында командиров-када чакта, кызыл агачтан эшләнгән Вьетнам паркеты кабул иткәндә, Азиянең иң көнчыгыш ноктасында төше-релгән. Ә икенчесе — Португалиянең Язмыш борыны дигән җирендә, Европаның иң көнбатыш ноктасында. Бу билгеле географик төбәкләрнең һәр икесе дә биек текә яр өстенә урнашкан, ә аста ике бөек океан шаулый.

Рушан җәмгыятьнең иң яхшы, сайланган катламына — хәзергечә әйтсәк, элитасына кермәсә дә, байтак кына җирләрдә булырга өлгерде. Прораб эше авыр, җаваплы хезмәт, төзүчеләрнең тормышын матурлый-җиңеләйтә төшү максатыннан чыгып, югарыдагы түрәләр, бигрәк тә аларның тапшырыласы төзелешләргә күзәтчелек итеп тор-ганнары, ике сезон арасында үз эшчеләренә төрле юлла-малар бүлеп бирәләр иде. Рушан да шундый юллама белән баруларының берсендә әлеге Язмыш борыны дигән җирдә фоторәсемгә төште. Ләкин ул чагында, җилле апрель аен-да, кайчандыр планетаның икенче бер иң читтәге нокта-сында да фоторәсемгә төшкәнен хәтерләп тә карамаган иде. Менә хәзер, еллар үткәч кенә, бу ике фоторәсем, оч-раклы рәвештә мач яткан кәртләр кебек, янәшә торгач

кына, үзенә нинди ерак җир читләренә барып чыгарга туры килгәнлегенә төшенде. Ул эш бүлмәсендә эленеп торган картадан шул ике ноктаны эзләп тапты да аларның бер-берсеннән никадәр ерак булганлыкларына таң калды. Алар арасында кыйтгалар, дистәләрчә илләр, әллә ничә гасырлык тарихлары булган йөзләрчә шәһәрләр, меңнәрчә поселоклар һәм авыллар ята, хыял белән дә колачлап алып булмаслык ул киңлекләрдә төрле расадагы һәм төрле диндәге миллионлаган кешеләр яши — һәркайсының үз тормышы, үз язмышы...

Бәлки, шуңадыр да, үзен тәүге мәртәбә чүлдәге ком бөртегедәй, океан суындагы бер тамчыдай итеп тойгангадыр, Рушан үз-үзенә, үзенең тормышына, үзенең үткәненә текәлебрәк карый башлады.

Гаҗәп: бу хәтер дигәнең сине кайчандыр син булган атаклы-данлыклы җирләргә, әйтик, Парижларга алып китми, һаман да гомереңнең чишмә башы булган елларына, мәктәпкә алып кайта.

Ә бит күпме җилләр искән, күпме сулар аккан! Әле ул чакларда сәер генә Фасоль фамилияле мәктәп директоры да буйдак бер егет иде. Һәм менә бер кышта сыйныфлар өстеннән чыштын-пыштын гына бер хәбәр йөгереп узды: Фасоль өйләнгән икән, хатын алып кайткан. Ул заманда директор мәктәп йортында тора иде. Рушан бер тәнәфестә өстенә матур тиен тун, аягына ни өчендер «венгерка» дип йөртелә торган биек үкчәле, кыска кунычлы күн итек кигән зифа буйлы, тәбәнәк кенә кызны күреп алды. Салкыннан бит очлары алсуланып янып чыккан, кайсы төше беләндер шәһәрнең өлкән сыйныфта укучы кызларына охшаш бик сөйкемле һәм чибәр генә бер туташ иде ул. Рушан аның балалар табибәсе икәнен ишеткән иде инде. Ул әле аларның кызлары туганын да хәтерли, ул баланы көн саен мәктәп тирәсенә һава суларга алып чыгалар иде. Өлкән сыйныфта укучы кызлар тәнәфестә аның сиртмәле арбасы янына җыелалар, чиратлашып аны чәчәк атып утырган сәрби куаклары арасындагы мәктәп аллеялары буйлап этеп-тартып йөриләр — болары да хәтердә уелып калган. Сәрби куаклары, кызгылт ком сибелгән юл-сукмаклар, күбәләкләрдәй ак алъяпкычлы укучы кызлар, биләүгә биләнгән нәни кызчык...

Инде шактый еллар үтеп, үзенең чираттагы бер ялына кайткач, Рушан җәйге бакчада шул кайчандыр бәби булган, инде буй җиткергән сөйкемле кыз белән биегән һәм күптәнге истәлекләрен сөйләп көлдергән дә иде әле... Кыз ул вакытта Ленинградтагы югары уку йортларының берсендә укучы студент иде инде. Үтә гомер... Ру-

шан китеп барган шул ерак августта ул кыз өчен нинди-дер бер егет, сыйныфташы бугай, атылып та үлгән. Әйе, тормышта һәрнәрсә дә шулай тыгыз үрелгән — мәхәббәт тә, үлем дә...

Хәзер инде шахмат уйнарга үлеп ярата торган Фасоль фамилияле мәктәп директоры да исән түгел, перчаткалы туңган кулларын күкрәк турысындагы муфтасына яшергән, тиен тунлы булганлыктан, Рушанга өлкән сыйныф укучысы гына булып күренгән хатыны да күптән пенсиядә, ә кайчандыр мәктәп ишегалдында кечкенә арбада тартып йөргән сабыйдан сылу кыз булып үсеп җиткән гүзәл теге каһәрле төндә ау мылтыгының тәтесенә баскан малайны алай еш хәтеренә дә алмыйдыр әле. Вакыт дигәнең шулчаклы тиз үтә, яшьли үлгәннәрнең каберләре өстендәге фәкыйрь генә такталарга кагылган язулы калайлар шундый тиз тутыга, иң күңелсез-моңсу вакыйгалар да шундый тиз онытыла...

Соңгы вакытларда Рушан мәктәпне бик еш искә ала, ә дөресрәге, үз гомерендәге ике мәктәпне. Кайчакларда мәктәп елларын артык идеаллаштырып, гел матур, күтәренке, романтик еллар итеп караган шикелле. Чын хакыйкать сүзләре дөньяга чыга башлагач, илленче-алтмышынчы елларда совет мәктәпләрен тәмамлаучыларның хәзерге сиксәненче еллар азагы, туксанынчы еллар башындагы егет-кызларга караганда күпкә белемлерәк, өлгергәнрәк булганнарын күреп, Рушан горурланып та куйган иде. Әмма ул бу горурлану хисеннән оялды да бугай әле, соң, бер дә табигый хәл түгел ич: утыз ел эчендә безнең балаларыбыз гәүдәгә сузылып та, надан калгач, моның нинди яхшы ягы бар инде — шул рәтлеюньле белеме булмаган, начар тәрбиядә үскән буын җилкәсенә синең картлыгың да төшәчәк бит әле.

Ләкин инде бөтенләй килеп терәлгән картлык турында ни өчендер бик уйлыйсы килми, шуңа күрәдер дә, бәлки, һаман да яшь төшләр, төгәлрәге, яшьлек турындагы төшләр күрелә. Шунысы сәер: ул төшләрдә син яратып-сөеп йөргән затлар, гомереңә исеңдә калдырганча, һаман да шулай яшь булып, чибәр булып сурәтләнәләр. Син үзең дә үтеп киткән еллар авырлыгын җилкәңдә тоймыйсың ул төшләреңдә, еш кына шулай ук яшь буласың, әмма, зирәк ташбака Тортилла шикелле, үткән гомереңнең зарури ачы тәҗрибәсен туплагансың — сиңа хәзер һәммәсе дә ачык һәм аңлаешлы! Нинди искитмәле матур төшләр! Һәм ул төшләрдән соң уянып, чынбарлыкка кайтулар нинди газаплы, нинди әче хәсрәтле була... Гомерең буе күңелеңдә йөрткән, әле яңа гына

төшендә күреп, яңадан очрашырга сүз куешкан яки башка бервакытта да үпкәләшмәскә сүз биргән ул сөйкемле-гүзәл кызлар күптән юк бит инде. Язмыш аяусыз кыйнаган, авыр тормыштан арган-талчыккан, картаеп килүче хатын-кызлар гына бар. Берәүләре инде пенсиядә, икенчеләре шуның бусагасында, ул ханымнарның элеккеге матурлыкларыннан, нәзакәтле җиңел атлап йөрешләреннән җилләр искән. Яшьлекләрендә аларны белмәгән-күрмәгән берәр кешегә бу ханымнарның кыз чагында нинди чибәр, нинди гүзәл булулары турында сөйләп кара әле — кычкырып көләчәкләр генә! Миһербансыз-шәфкатьсез еллар барысын да талап ала: күзләреңдәге яшьлек очкыннарын да, күпереп-тузгып торган чәчләреңне дә, сихерле-серле елмаюларыңны да...

Мөгаен, кыз-кыркынның, кияүгә чыккач, кыз чактагы фамилияләрен югалтуында ниндидер хаклык та бардыр, шуның белән хакыйкать расланадыр: инде ни Галләмова, ни Давыдычева, ни Беккерт юк, бары тик Насретдинова, Астафьева, Зотовалар гына бар. Син кайчандыр күз атып, яратып-сөеп йөргән ул затларның яңа фамилияләре сиңа бер нәрсә дә сөйләми, алар үзләре дә таныш түгел, чит-ят ханымнар гына — кемнәрнеңдер хатыннары, кемнәрнеңдер әниләре, ә кемнәрнеңдер әбиләредер дә инде, бәлки...

Ихтимал, еллар салган чал чәчләрнең һәм йөздәге җыерчыкларның да үз өстенлеге бардыр — аларга ия булгач, һич югында, җиде кат күкләрдә гизмисең, үткәнеңә дә, бүгенгеңә дә, киләчәгеңә дә аек күз белән карый башлыйсың, «алсу күзлекләрең» бу вакытка инде йә ватылган, йә бөтенләй югалган була. Хикмәт, соңлап булса да, кайсы ишектән керергә кирәклеген аңлауда түгел, ә ни өчен икенче ишектән кереп киткәнеңне белүдә. Шулай да әле һаман да күп нәрсәләр аңлашылып бетми, бигрәк тә эш йөрәк мәсьәләсенә, гыйшык-мәхәббәткә барып терәлгәндә. Кызлар йөрәгенең бернинди мантыйкка, акылга сыймаслык гамәлләре турында тау-тау китаплар язылган, асылда, бөтен әдәбият кына түгел, бар тормыш шуннан тора — менә монысы Рушан өчен гомерлек сер булып калды, алга таба да шулай булыр, мөгаен. Хәтта дистә еллардан соң да хәтереңдә кинәт кенә сөеклеңнең әйткән берәр сүзе, берәр хәрәкәте калкып чыга, син аны теге чакта аңламагансың һәм хәзер дә аңлый алмыйсың, баксаң — ул шумер чөй язуларыннан да катлаулырак икән. Менә шуны тою бик газаплый да...

Чит кешегә, ул бигрәк тә яшь кеше дә булса, кемнеңдер кайчандыр берәр унынчы сыйныфта укучы яки берәр

студент кызның үзенә нәрсәдер әйткәнен яки ничек итеп караганын исенә төшереп, уйланып утыруы гайре табигый бер юләрлек булып тоеладыр. Әмма, ничек кенә гаҗәп булмасын, инде шактый гомер кичергән кайберәүләр өчен бу бик мөһим була. Шулай килеп чыккан ки, кешене мөстәкыйльлектән мәхрүм итеп, аның өчен һәрнәрсәне хәл итәргә омтылып, аның шәхси йөзен бөтенләй җуеп, һәр эштә бергәлек булсын дип тырыша торгач, җәмгыять бары тик йөрәк хисләренә генә үтеп керә алмый калган, шуңа күрә дә шәхси тормышыбызда тиз вә җиңел яраланучан безнең күңелләребез. Бер генә юаныч кала: мәхәббәттә, хәзергечә әйткәндә, инициатива һәм альтернатива рөхсәт ителә әле. Безгә башка өлкәләрдә үзебезне күрсәтергә мөмкинлек бирмәделәр, шунлыктан да без мәхәббәттә уңышсызлыкны, гаилә җимерелүне хезмәт юлындагы уңышсызлыкларга, үрләр яулап ала алмавыбызга караганда тирәнрәк, авыррак кичерәбез.

Рушан бала чагыннан ук бик тиз гашыйк булучан иде, бәлки, шунлыктандыр да аның хатирәләре романтик пәрдә белән өртелгән, һәрнәрсә артык хисчән тойгыларны уята иде. Ул бит, чынлап та, туйда чакта Сафия апасына да гашыйк булды, шәраб парлары башларына киткән кунакларның аны мактауларын ишетеп, үсеп җиткәч үзенә андый кыз тәтемәс шул инде, дип кайгырды. Соңрак ул нәфис шәфталу йөзле «мадам Баттерфляй»га гашыйк булды. Рәшит абыйсы юләр, тәки шуңа өйләнмәде бит. Хәтта мәктәп директорының хатыны табибә Юлияне дә яратып йөрде, аннары, бик озакка булмаса да, йөрәген пионервожатый кыз Наденька Кривцанова яулап алды.

Хыялларга чумып яшәү, дөньяга «алсу күзлек» аша романтик караш, чамадан тыш әсәрләнүчәнлек-хисчәнлек аның тормыштагы төп хезмәте — төзелеш белән һич бәйле түгел, һич ятышмый, андый сыйфатлар күбрәк иҗади һөнәр ияләренә, зыялы мохиттә үскән кешеләргә хас булырга тиеш, ә Рушан берничек тә алар исәбенә керә алмый иде. Югыйсә төзүчегә хас булмаган андый сыйфатларга ия кеше начар прораб булырга тиештер кебек, әмма бөтен хикмәт тә шунда шул — Дасаев үз эшенең остасы иде, әгәр дә бераз елгыррак та булса, ул инде күптән чит илләрдәге берәр зур төзелешне җитәкләр иде, тәкъдим ителгән илләре дә кызыгырлык иде бит: Куба, Марокко, Алжир, Һиндстан.

Бетәшкән Мартукта нинди дә булса гайре табигый сирәк һөнәрләр турында сөйләшүләр кешеләрдә аңлашыл-

мас ачу кузгата, үртәлү тудыра иде. Рушан хәтерли әле: башка сыйныфтан бер кыз белән үзе арасында гыйшык-мыйшыкка охшаш хисләр туып кына килә иде. Менә шул Валя Домарова ирекле темага язган иншасында үзенең балерина булырга теләвен ачып салган да, бу яңалык бөтен Мартукка таралып, бик тискәре яңгыраш тапкан иде. Хәтта Татар бистәсендәге кое янында да карчыклар, урысчасын-татарчасын бергә бутап, көлешә-көлешә берберсеннән сорашалар:

— Ишеттеңме әле, шуфир Вәскә Домаровның дучкасы бәлирунә булмакчы, ди?

— Ул теге нижнее бельедан гына — эчке күлмәктән генә кешеләр алдына чыгып, бот-чатларын күтәреп биюче буламы соң? Ха-ха-ха!

— Хи-хи-хи! Шул инде, шул...

Аннары инде бөтенләй кәгазьгә төшерергә ярамаган оятсыз сүзләр китә. Балерина булырга хыялланган кызны озак еллар эзәрлекләп килгән бу әшәкелек әдәбият укытучысы аркасында килеп чыккан иде. Әгәр ул кызның бу самими серен «тишмәгән» булсачы соң?..

Бу вакыйга ун-егерме елдан соң да онытылмады. Валяның әнисе күптән вафат инде, балерина булырга хыялланган кыз, мөгаен, үзе дә пенсия яшенә җитеп барадыр, ә менә аның әти-әниләре турында сүз кузгалса:

— Ә-ә-ә, теге кызлары балерина булып сикергәләп йөрергә җыенган Домаровлармы? — диярләр иде...

Ул вакытларда мартуклылардан кемнең дә булса дипломат яки журналист, композитор яки язучы, режиссер яки артист булу мөмкинлеге хакында берәүнең дә башына килеп карамагандыр. Имеш-мимеш гайбәт сүзләрдән куркудан түгел, мартуклылар андый һөнәр ияләренең кайдадыр башка җирләрдә генә туа алуларына ихлас ышанудан да иде бу галәмәт.

Шуңа күрә дә биредән дәррәү булып, тау эшләре техникумнарына һәм институтларына китәләр, чөнки ул елларда шул уку йортларында гына иң зур стипендия түләнә, бушлай кием-салым бирелә иде. Шундый ук сәбәп белән, бик теләп, хәрби һәм диңгез училищеларына агылалар, хәтта һәртөрле һөнәр училищеларын да чит итмиләр: һәркайсында бушлай ашаталар, бушлай киендерәләр иде бит. Болар инде күпләр өчен сәләт-омтылышлардан көчлерәк дәлил булып чыга иде. Рушан үзе тимер юл техникумының төзелеш бүлегенә китеп барды: анда да шул ук өстенлекләр, күп нәрсә түләүсез, ә иң мөһиме — илне күреп-йөреп чыгу мөмкинлеге ачыла. Кайсы малай сәяхәтләр белән хыялланмый?! Кабул

итү игъланында, ачык итеп, акка кара белән зур итеп, һәр елны Советлар Союзының теләсә кайсы почмагына бушлай барып кайту хокукы бирелә, диелгән иде. Тормыш юлын, һөнәр сайлауны менә шул хәл итте дә куйды инде.

Бала чагыннан ук Рушанның табигатенә артистлык хас һәм ул, ихтимал, нинди дә булса иҗат өлкәсендә дә үзен тапкан булыр иде. Әмма булмаган булмаган инде. Бәлки, менә хәзер, соңлап булса да, үзенең «тормыш турындагы мәңгелек романын» күңеленнән генә иҗат итеп, үзендәге әнә шул иҗади башлангычны тормышка ашырырга телидер ул.

Аңа һәм аның яшьтәшләренә фарт килде: сугыштан соң ук алар бик күп трофей фильмнар карап үстеләр. Ул заманда актер осталыгы, режиссура кебек нечкәлекләр турында сөйләнеп тормыйлар, әмма фильмнарның берсен дә калдырмыйлар иде. Хәзер менә, Голливудның чәчәк аткан чоры сугыш алды һәм сугыш еллары, дип саныйлар икән, ул фильмнарның күпчелеген Рушаннар күргән иде инде. Үзләре бөтенләй башка шартларда яшәп, совет фильмнарында тәрбияләнгән буын башка дөньяларны, кешеләр арасындагы башка мөнәсәбәтләрне йотылып карый иде. Ул чит ил фильмнарында барысы да бүтәнчә, Рушаннар карашынча, һич тә чын түгел иде.

Фильмнарны «Өченче интернационал» колхозының иске атлар сараеннан ашык-пошык кына «киношка» итеп әтмәлләгән залда күрсәтәләр. Зал шыгрым тулган була, малай-шалайга юл өстенә, идәнгә чүмәшергә генә кала иде. Залга ягылмый. Халык никадәр күп булса, шулкадәр җылырак була.

Рушан үзенең экран астында ук идәндә, маен сыгып алган көнбагыш түп-түберен күшәп утырган чакларын исенә төшерә. Ә экранда — үтә зиннәтле-купшы курорт. Әкәмәт пальмалар һәм чәчәк атып утыручы кактуслар утыртылган зур-зур кисмәкләр тезелгән кардай ак кунакханәнең иркен фойесында, кан төсендәге кызыл келәм җәелгән киң мәрмәр баскыч ягына карангалап, күз явын алырдай бер гүзәл кыз йөренә. Баскычтан пөхтәләп-майлап таралган кара-кучкыл чәчле яшь егет төшеп килә, өстендә — атлас якалы зиннәтле костюм, костюм эченнән ак пике жилет, муенына да ак күбәләк элгән.

Матур киенгән бу әкияти геройга карап дөньясын оныткан Рушан кулындагы түп-түбер кисәген ирексездән төшереп җибәрә, караңгыда аны эзләп тә тормый. Ул, комсызланып, әлеге бәхетле егетне күзәтә, әнә бит, аны нинди гүзәл кыз көтеп тора! Һәм кинәт, көтмәгәндә генә

малайның башына бер уй килә, үсеп, акча эшли башлагач, үземә дә шундый костюм тектерермен әле, ди ул.

Бер ун еллар үткәч, техникум тәмамлап, Кызыл-Орда тирәсендә тимер юл биналарын һәм корылмаларын карап-күзәтеп торучы булып эшләгәндә, бер получкасын алгач, ул шәһәргә барып, үзенә гомерендә беренче мәртәбә костюм тектерергә булды. Ательеның заказлар кабул итүче кызы, аның теләген белгәч, кулына бер төргәк мода журналлары тоттырды да үзе каядыр китеп югалды.

Менә шул журналларның берсендә Рушан кинәт кенә теге фильмда күреп хәйран калган костюм үрнәгенә килеп төртелде (ул могҗизаи кием смокинг дип атала икән). Рушан аңардан күзен ала алмый карап утырганда, аның янына тегүче яһүд килеп баскан иде инде. Яһүд, мыскыллы көлемсерәп:

— Әллә смокингка үрелмәкче булдыгызмы, егет? — дип сорады.

Нindидер ярамаган эш белән тотылган кеше шикелле кызарынган булса да, Рушан үҗәтләнеп җавап бирде:

— Әйе, мин менә нәкъ шушындый смокинг тектерергә телим! — диде.

Хәзер инде тегүчегә гаҗәпләнергә чират җиткән иде. Ул хәтта Рушан янына утырып, гафу үтенгәндәй, әйтеп куйды:

— Минем смокинг текмәгәнемә бер утыз еллар бардыр инде, шулай да тырышып карармын, элек әйбәт кенә килеп чыга иде,— диде.

Рушан тыны бетүдән сизелерлек җәфаланучы бу кешенең кайчандыр Ленинградның атаклы театрында костюмер булып эшләгәнлеген һәм теге каһәр суккан елларда Кызыл-Ордага сөрелгәнлеген белде. Аларның кайсысы — әллә тегүче, әллә смокинг тектерүчесе күбрәк шатлангандыр, кистереп әйтүе кыен. Ленинградлы карт Рушанга смокинг астыннан киярг ә ак пике жилет та тектерергә киңәш итте, ә тегәселәрен тегеп бетереп тапшырганда, дулкынлана-дулкынлана, аңа бүләк — муенга тагыла торган ак күбәләк тә сузды:

— Монысы шәхсән үземнән, картлык көнемдә мавыктыргыч эш белән шатландырганың өчен,— диде.

Рушан Кара-Үзәктәге бер кешеләрдә бүлмә алып яши иде. Бүлмәсенә кайтып, яңа киемнәрен киеп карагач, шатлыгын хуҗалар белән дә уртаклашырга булды. Әби карчык аны баштанаяк карап чыкты да өнәмичә әйтте:

— Күн итекләреңнең рәте юк, ә син театрга җыенган кебек киенгәнсең...— диде.

Балачак хыялы шулай көтмәгәндә генә тормышка ашкан иде. Хәзер аны искә төшерү дә көлке, ә теге чакта... Теге чакта Рушанга пальмалы кисмәкләр куелган ап-ак кунакханәгә дә, данлыклы әкияти курортка да ерак калмаган төсле тоелган иде.

## IX

Рушан Дасаев техникумда укыган шәһәр, тимерьюлчылар термины белән әйткәндә, «узел станциясе» дип йөртелә иде. Бирeдә поезд бригадалары алышына, вагоннар һәм локомотивлар депосы да, вагоннарны сортларга аеру өчен таучык та бар — кыскасы, иске һәм яңа локомотивлар өчен үзенә күрә бер порт яки гавань дигән сүз бу. Техникумда укыган чагында, Шәһрезадә әкиятләреннән калкып чыккандай матур вокзал бинасы Рушанны сокландыра, зур кызыксыну тудыра иде. Гасыр башында, Мәскәү — Ташкент тимер юлы белән бер үк вакытта төзелгән станция биналары, әгәр дә хәзер сакланып калган булсалар, архитектура истәлекләре итеп бәяләнерлек иде. Әкәмәт бизәкле биек түбәләре, шәрык стилендәге манаралары һәм гөмбәзләре, ук сыман очланып уелган тәрәзәләре һәм төсле витражлары булган, һәйбәт сары таштан салынган бу биналар озын юлның буеннан-буена шәһәр-авылларны бизәп торыр иделәр. Һәр станциянең, әлбәттә инде, су җыю каланчасы булыр, чөнки бу заманнарда бары тик паровозлар гына йөри иде әле. Янәшә-тирәдә йөк кабул итә торган урыннар, пакгаузлар төзелеп киткән... Болар барысы бер бөтен, матур бер архитектур чишелеш тапкан, шуның белән хәйран калдыра да иде...

Шактый вакытлар үткәч, үзе инженер булып ниндидер проект эшләгән чорында, Рушан архивларда бу тимер юл төзелеше турындагы документларга юлыкты, ә тимер юлны ул биш бармагы кебек белә — Мәскәүдән Ташкентка кадәр булган һәр чакрымын хәтереннән үткәрә алыр иде. Урта Азия белән Үзәкне тоташтыручы, әле һаман да икенче юлы булмаган бу төп тимер юлны, артык шаулап тормыйча гына, бик кыска вакыт эчендә, нибары ике төзелеш батальоны салган икән. Ә барлык станция биналарын гади архитекторлар проектлаштырып эшләгәннәр. Ул биналар шушы гомергә тиклем,— ә бит аларга, баксаң, бер гасыр гына түгел инде,— ремонтсызнисез сакланганнар, кайбер станцияләрдә исемсез төзүчесолдатлар сузган суүткәргеч торбаларга хәтле бар.

Рушан төзелеш эшләрендә шактый тәҗрибә туплаган кеше, әйтик, атаклы БАМ — Байкал-Амур магистра-

ленең нинди бәяләргә төшереп салынганын да белә, шуңа күрә дә, очраклы рәвештә генә табып алган архив материаллары белән танышкач, аның исе киткән иде. Соңрак, борынгы Артемида гыйбадәтханәсе хәрабәләрен карап йөргәндә дә, аны шундыйрак тойгы биләп алган иде. Әмма бу тимер юл, аның төзелү тарихы күбрәк хәйран калдырды. Ни әйтсәң дә гаҗәп түгел, бу бит һәрберебезгә кагыла: тимер юллар зур дөнья белән тоташтыра... Нәрсәләрне онытып, кайларга килеп төртелгәнебезне яхшырак аңлар-белер өчен, сирәк кенә булса да, архивларда казыну кирәк икән...

Үзе дүрт ел буена көн саен яныннан үтеп, шуннан дистәләрчә мәртәбә кайтып-китеп йөрелгән, һәр ташерен почмакларына кадәр таныш станцияне хәтеренә төшерүе очраклы түгел иде: үзенең тормыш юлында очраган күп кешеләр кебек үк, ул станция дә гомерлеккә юкка чыккан, әйтергә мөмкин — һәлак булган иде.

Онытканда бер туган якларына кайтуының берсендә, инде җитмешенче еллар башында, Рушанның Актүбәгә поезд белән барырга җыенуын белгәч, якын танышларыннан кемдер гади генә әйтеп куйды:

— Андагы гаҗәеп матур борынгы вокзал юк инде, аны җимереп ташладылар.

Тиздән Рушан моны үз күзләре белән күрде. Ерактан караганда гыйбадәтханәгә охшаш элеккеге мәһабәт бина урынында сәер генә бетон тартма кукраеп тора — ул галәмәт зур, уңайсыз-шыксыз, күрексез бер сарайны хәтерләтә иде. Шул да булдымы архитектура һәйкәле?! Хәзерге заман язучыларыннан кайсыныңдыр шундый юллары искә төште: «Яңаны шундый итеп төзергә кирәк ки, ул үткәннәрне сагынып-кызганып искә алырлык булмасын».

Соңыннан иске вокзалны ничек «кыйратканнары» турында сөйләделәр. Борынгы бинаны шартлатканнар да, танклар, авыр тракторлар белән кырып-җимереп тә бетергәннәр. Шәһәрнең бердәнбер күрке булган шул бинаны реставрацияләп, элекке хәленә кайтарасы урынга, җимереп ташлаганнарына Рушан бик үртәлгән, хәзерге заман Геростратларыннан кайсысының хәерсез эше икәнлеген бик беләсе дә килгән иде, булмады...

Гаҗәеп дөньяда яшибез без: моннан берничә мең еллар элек Эфестагы Артемида гыйбадәтханәсен яндырган Геростратны беләбез, ә ун еллар элек Мәскәүдәге Коткаручы Гайсә пәйгамбәр чиркәвен (Храм Христа-спасителя) яки әле күптән түгел генә Актүбәдәге шушы вокзалны шартлатырга боерык биргән түрә кисәгенең кем икән-

леген белмибез. Хәер, еллар үтү белән күп нәрсәләрне аңларга була. Менә хәзер, туксанынчы еллар башында, төрекләр, финнар, немецлар, шведларның Мәскәүдә Россия өчен изге, истәлекле саналган биналарны яңартуын күргәч, Рушан үзенең никадәр самими-беркатлы булганлыгын аңлады — гап-гади станция вокзалыише биналарның һәммәсен дә төзекләндерергә шулчаклы чит ил төзүчеләрен кайдан җыеп бетермәк кирәк? Аңа нинди акчалар җиткермәк кирәк?

Үзенең яшьлеге билгесе,— ә бит яшьлек тә гомерлек булыр шикелле иде! — әнә шул вокзал бинасы иде. Аны югалту кайгысыннан каңгырап, ул көнне Рушан Дасаев ирексездән тимер юллар буйлап станция биналары ягына китеп барган иде. Төн уртасында өеннән шәһәргә «Оренбург — Гурьев» почта поездына утырып кайткан чакларында ул шулай итә иде. Аның бу юлы да үзе утыз еллар элек яшәгән тулай торагын күреп китәсе бик килгән иде, әмма барып чыкмады.

Еллар буе чистартылмаган, мазутка буялып беткән рельслар аша атлый-атлый, Рушан, үзе дә сизмәстән, инде тузып-күгәреп беткән паровозлар саклана торган иске депога барып чыкты. Тимер юл эшеннән күптән киткән булса да, ул күңеленнән генә кайчандыр шул МПС (Министерство путей сообщения) кешесе булганы белән горурлана иде. Яшьлегендә хәтта «Локомотив» футбол командасында уйнап та йөрде бит әле. Кайчандыр паровоз машинисты, аннан соң казылык ясау остасы булган Рәшит абыйсы, ничектер бервакыт моңаеп: «Тимер юл ул — беренче мәхәббәт шикелле, гомерең буена онытылмый»,— дигән иде.

Тәрәзәләре ватылып, тимер ишек-капкалары каерылган иске депо бинасы эчендә җил генә йөри, күгәреп-тишелеп беткән түбәдән тамчылар тамып тора. Матур гына җиңел пассажир паровозлары, салкыннан һәм үтәли искән җилдән куырылып-бөрешеп, киң күкрәкле көчле йөк паровозлары «С.О» — «Серго Орджоникидзе»га елышканнар шикелле, ә җитезлеге өчен «чуртан» кушаматы алган, уенчыктай матур маневр паровозы ишек янында ук беренче булып тора, ул гүя бу каберлектән чыгып ычкынырга җыена. «Мөгаен, бу паровозлар иске вокзалны хәтерлиләрдер, аны һичкайчан да онытмаслардыр»,— дип моңаеп уйлап алды Рушан.

Төрлесе төрле дәрәҗәдә сакланган иске локомотивлар шактый күп иде биредә. Әмма барысыннан да бигрәк каралып беткән бакыр бандажлы, кызыл көпчәкле, апак торбалы, ерткычларча елгыр «И.С» — «Иосиф Ста-

лин» күзгә нык ташланып тора. Аны малайлар «бурзай» дип йөртәләр иде. Чынлап та, ерактан караганда ул матур бурзай этен хәтерләтә. Әле менә монысының да күкрәгенә Юлбашчының кызыл бакырдан эшләнгән профиле чекрәеп карап тора, нинди могҗиза белән сакланып калгандыр ул?

Рушан бу паровозга шундый бирелеп карап торды, ирексездән, үзе тирәсендә кайнар шлак түшеп көйдерелгән креозотлы шпаллар исен, йөгерек «бурзай»дан бөркелеп торган кайнар пар һәм машина мае исен тойгандай булды. Бу ис һәрвакыт күмере янып, суы кайнап утыручы, тукталышларда кочегар чистартып тора торган мич авызыннан да, өйдәге күнегелгән зур самовардан да килгән кебек иде.

Рушанны станциядә үсте дип әйтергә дә була, шуңа күрә ул бу күркәм паровозны бик җиңел генә Мартукта итеп тә күз алдына китерә ала. Паровоз тирәсендә өч ир-ат та булырга тиеш әле. Аларның берсенең кулында — озын саплы кечкенә җиңел чүкеч, икенчесендә — биш литр сыешлы шактый зур май савыты — масленка, ә өченчесендә — тукталышларда тендер белән мич арасында йөгергәләп йөрүче кочегар кулында көрәк белән кувалда булыр. Кечкенә чүкечлесе — машинист, әгәр дә паровозның түшендә Юлбашчы профиле булса,— ә ул бик күп йөк паровозларында бар,— машинист, чүкече белән суккалап, көпчәкләрне-фәләннәрне тикшергәнчегә хәтле, беренче эше итеп мыеклы генералиссимусның йөзен көзгедәй ялтыратып-чистартып куя, моны бик каты таләп иткәннәрен белә ул. Чибәр туташларның да һәрберсе бизәнергә-төзәтенергә ул кадәр үк вакыт сарыф итмидер, ә менә Юлбашчыны һәр тукталышта карап-кадерләп торырга кирәк.

Сагышлы-моңсу уйларга чумган Рушан юлын тулай торак ягына таба бормакчы булган иде, әмма аның игътибарын күрше юлда торган паровоз җәлеп итте. Паровоз зур, көчле, хәзер үк йөгертеп кузгалып китәрлек җегәре бар шикелле иде. Аның күкрәгендәге Юлбашчы профилен, ямьсез генә итеп, тимер кискеч зубилалар белән умырып-кисеп алганнар. Шулай булса да ул әле, парларын бөркеп, менә хәзер кузгалыр кебек. Рушан аның сулыш алганын, вакыт-вакыт пар чыгарып, станция дежурныеның соңгы командасын көтеп торганын ишеткәндәй булды.

Шул вакытта Рушанның күңелендә әле беркайчан да, беркемгә дә сөйләмәгән хәтәр бер вакыйга калкып чыкты. Хәтерләсәләр, аны бары тик Мартукның картрак кешеләре генә хәтерли торгандыр...

Аллага шөкер, даладагы Мартукның мәңгелек юлдашлары булган «ачлык» һәм «салкын» дигән сүзләр халык теленнән кире кайтмаслык булып төшеп калды шикелле инде. Ни урманы, ни әрәмәсе, ни куак-фәләне юк, өстәл өсте шикелле тип-тигез, такыр далада яшә дә, йортыңны нәрсә булса да ягып, җылытып кара! Сыерың булса, шул гына коткара — шуның салам катыш тизәге кушып сугылган тирес кирпечен ягарга була иде. Ләкин кыш бик иртә килә, соң китә, читәне дә, коймасы да калмый — һәммәсен комсыз мичләр ялмап кына ала. Соңгы чиктә станциягә йөгерәсең, анда, ичмасам, үтепсүтеп йөрүче поездлардан бушатып калдырылган, яндырылган ташкүмер шлагы Монблан, Эверест таулары хәтле булып өелеп ята. Хәлсез хатын-кызлар, әби-чәбиләр иртә таңнан барып шул тауларда казыналар, үтеп китәргә тиешле чираттагы паровоздан яңа шлак бушатканнарын түземсезлек белән көтеп торалар: андый чакта юлың уңарга бик мөмкин — янып бетмәгән зур-зур ташкүмер кисәкләрен дә табарга була.

Егетләрне әйткән дә юк инде. Үсә төшкәнрәк, елгыррак малайлар да паровозлар тирәсендә кайнашалар, кочегарга су тутырырга булышкан булып, берничә кисәк ташкүмер сорап яки урлап алырга өметләнәләр. Паровозлар белән бергә үлгән бу эш-гамәлнең үз исеме дә бар иде — ташкүмер сыптыру! Эшли-эшли арып хәлдән тайган кочегар һәрвакыт килешә, чөнки, паровоз миче белән тендер арасында чабып йөреп, икегә ярыла алмый, ә кыш көннәрендә су тутырганда, әз генә авыз ачып торсаң да, суың ташып чыга да, паровозның койрыгы бозланып ката. Әле аннан да хәтәре — ташкүмер бункерына су тулырга мөмкин, янә кочегарга бәла: җилдә-буранда юл буена кувалда белән шул бозланып каткан күмерне ват! Ул заманнарда бит хәзерге кебек автоматика юк иде.

Тимер юл рельслары арасында фил хортумы шикелле брезент торбалы галәмәт зур колонка — каланча булыр иде, менә шуны башта тендер авызына турылап куярга, аннары, төшеп, шулай ук бик зур тәгәрмәч-капкачын ачарга һәм су тулуга ябып та өлгерергә, брезент торбаны урынына этеп куярга кирәк — мескен кочегарга маймыл урынына әле өскә, әле аска чабып йөрергә генә кала. Ә паровоз мичен чистартырга күпме көч кирәк? Болар һәммәсе дә барган уңайга кулдан эшләнә бит, шунда ук мичкә ташкүмереңне дә ташлап өлгер! Менә шуңа күрә дә малайларның көне-төне станциядә кызык өчен генә кайнашмаганын белсәләр дә, кочегарлар аларның паровоз янына җыелуларына каршы килмиләр, ни генә әйтмә,

булышчылар бит. Моны станция башлыклары да, машинистлар да күрмәмешкә салына.

Өйдә бер тиен акча юк, казакъ авылларыннан бер арба тирес кирпеч сатып ала алмыйсың, нишләмәк кирәк — шундый зәмһәрир салкын кышларда ун яшьләреннән Рушан да станциягә «ташкүмер сыптырырга» йөри башлады.

Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: станция янындагы «кәҗүннәй» йортларда тимерьюлчылар яши. Аларның малайлары вокзал тирәләрен үз биләмәләре итеп саный, читтән килеп, паровозлар тирәсендә кайнашкан башка малайларны бер дә яратмыйлар иде. Әлбәттә, аларның Рушаннар шикелле күмер өчен кайгырасы юк — тимерьюлчыларга ташкүмер бушлай бирелә, аларга әле иске шпаллар да эләгә, ташкүмер мәктәпкә, хастаханәгә, райкомга, милициягә дә бар... Шулай булгач, яшәргә була. Әмма станция малайлары да барыбер «күмер сыптырырга» йөри һәм бу шөгыльнең осталары саналалар иде. Дөрес, алар ташкүмернең «михайловский» дигән сорты белән генә кызыксыналар, чөнки шундый күмер генә самовар куярга ярый. Ул заманнарда исә һәр мөселман йортында иртәдән кичкә кадәр самовар кайнап утыра, менә шулар өчен паровозлардан «ташкүмер сыптыралар» да инде. Күмернең үз хакы да бар: чиләге ике сум тора, ә чиләк зур — егермешәр литрлылар, күмерне чүмәкәйләп өеп бирәләр. Шулай эшләп тапкан акчаларына станция малайлары киногa йөриләр, көнбагыш чиртәләр, хәтта бер малай шулай итеп җәй буена үзенә велосипед алырлык акча да җыйган, дип сөйлиләр иде. Ә ул заманда велосипед — зур байлык инде ул.

Бик уңышлы башланып, бик зур фаҗига белән тәмамланган ул көнне Рушанның гомергә дә онытасы юк. Кышкы каникул көннәренең берсе иде. Ул үзенең дусты Диас Искәндәров белән иртән иртүк станциягә барырга сөйләшеп куйган иде: барып чыкса — «ташкүмер сыптырырга», юк икән — үтеп киткән паровозлардан ташлап калдырылган шлакны булса да җыеп кайтырга.

Чанасына чегәннәрдән калган, ямалып-яньчелеп беткән иске чиләк, зур гына капчык һәм җәй көне колхоз алачыгында ясатып алган тимер кисәү агачын салып, Рушан, Диасны ияртеп, бергә вокзалга төшеп китте. Диас үзе генә һич тә бармас иде, чөнки, бер мәктәптә укысалар да, станция малайлары соңгы вакытларда бик тә бәйләнә башлаганнар иде. Рушан күпне күргән, кыю малай санала, шуңа күрә Диас аңа ияргән дә иде инде.

Төн буена ябалактай мамык кар яуган, көн җылы, җилсез — каникул өчен менә дигән инде: шатлан гына!

Озакламый беренче юлга йөк поезды килеп туктады. Кочегары да әйбәт кеше булып чыкты, тендерга су тутырырга рөхсәт итте. Әле Рушанны аннан да зуррак шатлык көтеп торган икән: паровоз өстенә үрмәләп менсә, ни күрсен — бункеры кисәкле-кисәкле күмер белән шыплап тутырылган, иң өстә галәмәт зур кисәге ята, ватсаң, бер ун чиләкләп булыр һәм бөтенесе дә «михайловский» ташкүмере!

Су тутырып азапланган арада, машинист үзенең ярдәмчесе белән станция буфетына китеп барды, күрәсең, радио аша аларга озак торасыларын әйткән булганнардыр. Рушан, кочегарның паровоз мичен чистартып бетергәнен күреп, Диаска кул изәде, бу — паровозның теге ягына чык, дигән сүз иде. Авыр сөякле Диас мышныймышный вагон астыннан килеп чыкканны да көтмичә, үзе кар өстенә бер-бер артлы күмер ыргыта башлады — мондый бәхетнең тәтегәне юк иде әле. Диас башта күмер кисәкләрен ераккарак илтеп өя башлаган иде, Рушан аңа, вакыт әрәм итеп тормаска, шушында — паровоз янына өяргә кушты. Кочегар паровозның икенче ягында мич белән әвәрә килеп азаплана иде, Рушан байтак кына күмер ыргытып өлгерде, ә Диас аларга, оста гына итеп, кар сибә бара иде — бик күренеп ятмасыннар.

Рушан өстән кочегарга су тулып беткәнен әйтүгә, тегесе әлеге зур кисәк күмерне тәгәрәтеп төшерергә рөхсәт итте — юлда аның белән чиләнәсе килмәгәндер инде. Әмма Рушан, ничек кенә көчәнмәсен, зур күмерне урыныннан кузгата алмады, ә Диас паровозга үрмәләп менәргә курыкты, юкса бергәләп ничек тә төртеп төшергән булырлар иде әле. Кочегар бункерга үзе күтәрелде дә, әлеге күмерне юлның поселок ягына тәгәрәтеп төшерде. Шул арада машинист белән аның ярдәмчесе дә күренде, чөнки станциянең аргы башында, поездга юл ачылганын белдереп, семафорның яшел уты кабынган иде инде.

Рушан да тиз-тиз генә аска төште, Диаска күмер кисәген кар белән күмәргә булышты: машинист ярдәмчесе паровоз тәрәзәсеннән күреп алмагае дип курыкты, кочегарга да эләгергә мөмкин иде. Шулкадәр күп ташкүмергә хуҗа булган Рушан шатлыгыннан җырларга-биергә дә әзер иде. Диас белән икесе дә авызларын җыя алмыйлар: менә өйдәгеләр шатланыр инде, дип куаналар, әле күмернең бер-ике чиләген кибетче Кожемякина түтәйгә сатып та җибәрсәләр, әниләрдән акча теләнмичә генә, ике атналап кинога йөрергә дә буласы иде.

Кирәк бит, нәкъ шул вакытта, РТС ягыннан бер төркем станция малайлары күренде. Төрле яшьтәге сигез-тугыз малай. Рушан белән Диас әз-мәз кар сибелгән ташкүмер өеме янында кукраеп басып тормаса, бәлки ул малайлар аларны күрмичә үтеп тә киткән булырлар иде. Гөнаһ шомлыгына каршы, күрделәр шул, күмер өемен дә күреп алдылар. Бу кадәр күмерне станциянең иң елгыр малайлары — бертуган Чурсиннар да «сыптыра» алганнары юк иде әле. Гади күмер генә дә түгел бит, самовар күмере — «михайловский»! Малайларның атаманы Фаддей инде үзеннән өлкәнрәкләр арасында да кайнашкан, шуңа күрә күмер өеме янындагы бу ике өтек аның өчен чүп тә түгел иде. Ул күмерне тартып алырга уйлады — элек тә еш кына шулай итәләр иде. Бу кадәр шәп күмерне Татар бистәсенә илтеп сатсаң, кесәгә күпме акча керәсен дә чамалап алган иде бугай ул.

Станция малайларының өерелеп үзләренә таба килгәннәрен күргәч, Рушан белән Диасның котлары очты, аларның күңеле нindидер бәла булачагын сизенә иде. Бу очрашудан яхшылык көтеп тә торасы юк — күпкатлы кызыл кирпеч йорт малайларының холыклары билгеле. Әгәр дә табыш бер-ике чиләк күмер генә булса, кызганып та тормас идең, әмма гомергә бер килгән мондый табыштан үз иркең белән баш тартырга — юк, һичкайчан була торган эш түгел бу, талаш-сугышсыз гына бирәүнең дә үзенекен бирәсе килми.

Кыюлык өчен кычкырып сүгенә-сүгенә якынлашкан Фаддей, паровозлардан калган ташкүмер бары тик аларга — станция малайларына гына булырга тиеш, дип игълан иткәч, Рушан үзе дә, көтмәгәндә, тыныч кына аны күмер өеме яныннан авыр кисәү агачы белән этеп җибәрде. Фаддейны өркетү өчен: «Хәзер Хәмит белән чечен Солтан чана тартып килеп җитәчәк. Күмернең кемнеке икәнлеген менә шуларга аңлатырсың, яме!» — дип тә өстәп куйды.

Ул заманнарда Фаддей кебек ыбыр-чыбыр гына түгел, Солтаннан станциянең өлкәнрәк хулиганнары да курка, гомумән, поселокта чеченнәр белән бәйләнешергә берәү дә атлыгып тормый иде. Солтан Татар бистәсендә яши, ә Фаддей Рушанның әбисе сукыр Мәмлиева карчыкның мөселманнар арасында абруйлы булганын да белә, Рушанны да чеченнәр белән бергә еш күрә иде. Шуңамы, ул беразга шүрләбрәк калды шикелле.

Әмма беразга гына... Мәктәптәге укуына караганда, Фаддей зирәкләрдән түгел, авыр уйлый торган малай иде. Инде кулга кергән табыш шуып бара түгелме соң?

Аннары, малай-шалайлар алдында сынатасы да килми иде аның: шундый бай табышны маңка ике татар малаеннан тартып та ала алмады, дип көлеп йөрерләр иде бугай.

Шулчак Диас белән бер сыйныфта укучы кәтәнә генә бер малай, кыюланып китеп, бер күмер кисәгенә үрелде. Мондый оятсызлыкка хәтта Диас та түзеп тора алмады. Ул сыйныфташына киез итеге белән шундый итеп китереп типте — тегесенең бүреге нәкъ Фаддей аяк астына атылып барып төште. Бу хәл станция малайларын тагын да аптыраашта калдырды — ә бәлки, «татарчоноклар» чынлап та чеченнәрдән ярдәм көтәләрдер.

Күмер өеме китәргә торган поездның беренче вагоны янәшәсендә үк, ике юл арасында ята иде. Рушан белән Диас күмер янында тораташтай катканнар, ә станция малайлары төп тимер юл өстендә — ике рельс арасында таптаналар. Арырак станция башында тизрәк кузгаласы килгән паровоз әледән-әле куе пар бөрки, шунлыктан малайлар томан эчендә калган кебек була. Ә каршыга нindидер состав ажгырып килә — беренче юлдан китәргә җыенган поездны тыеп, тегесенә «яшел урам» ачканнар иде.

Ажгырып килгән состав бертуктаусыз гудогын кычкырта, кисәтә иде. Машинист юл өстендәге малайларны соңлабрак күреп алды, әмма тизлеген киметергә уйламады да, чөнки ул малайларның кайсысы булса да ажгырып-дөбердәп килгән составны ишетер-күрер дип ышана иде. Әмма бөтен бәла дә шунда: малайларның иң кечкенәсе дә бәрхеттәй җемелдәп яткан «михайловский» ташкүмере өеменнән күзен ала алмый, барысы да «сукыр-саңгырау» иде бу мизгелләрдә. Киеренке халәттә, бар көчләренә кычкырыша, акыра-бакыра — һәр ике як үзенекен даулый иде. Шунлыктан алар инде өсләренә менеп килгән составны абайламый да калдылар, юкса юлдан читкә ыргылып өлгергән булыр иделәр...

Паровоз малайларның өчесен шунда ук бәреп үтерде, Фаддейның ике аягы да киселгән иде, тагын ике бәләкәч юлдан читкә атып бәрелделәр — алары нindидер могҗиза белән, бәрелеп-сугылып кына котылып калды. Ә Касперов фамилияле бер малай исә ничек исән калгандыр: паровоз аны өскә чөеп ыргыткан һәм ул, бампер рәшәткәсенә барып төшеп, нәрсәгәдер тотынып калырга өлгергән иде.

Паровозның нindидер чыгып торган бер тимере Рушанга да тиеп узган иде, әле хәзер дә башында уң чигәсеннән өстәрәк биш тиен акча кадәрле түгәрәк пеләше

— тамгасы бар, чәче-ние белән бер кисәк тиресе умырып алынган булган, юкса ул бүрек тә кигән иде бит. Аннары, шул тимер кисәге тиеп киткәч, Рушан, күрәсең, егылгандыр, нindидер катыга — мөгаен, күмер өеменәдер бәрелеп, сул аягын нык кына авырттырган иде. Ул бик озак — ике айлап аксап йөрде.

Аңына килгәч, ул шунда ук нинди фаҗига булганын төшенеп алды: күпкатлы кызыл кирпеч йорттан болайга таба кешеләр йөгерешә иде. Рушан, беренче юлда яңадан тоткарланган составның вагоннары астыннан үрмәләп-мүкәләп чыкты да, авырттырган аягын сөйрәп, әкрен генә елый-елый, чанасыз-нисез килеш өенә таба титаклады. Җиңелчә курку белән генә котылып калган Диастан җилләр искән иде инде.

Өйгә кайткач, Рушанның курку-коты алынулары тышка бәреп чыкты, ул косып җибәрде, температурасы күтәрелде.

Бер өч сәгатьләрдән соң аларга НКВДның шәһәрдәге тикшерүчесе килеп керде, аңа поселок милиционеры Велигданов та ияргән. Рушан аның кызы Валюшка белән бер сыйныфта укый иде. Болар килеп кергәндә, малай тәки күмер көтеп ала алмаган салкын мич янындагы урын өстендә җансыз бүрәнә шикелле ята иде.

Өйдәге салкынлыкны тоеп, сыкылап-елап утырган юеш стеналарны күргәч, тикшерүче, мөгаен, малайның ни өчен станциягә барып чыкканын шунда ук аңлап алгандыр. Шулай да ул, нindидер кәгазьләр сырлап тутырды да, Рушанның әнисенә кырыс кына итеп әйтеп куйды: менә, янәсе, улыгыз өйдә китап укып кына утырса, йә мондый матур көндә, каникулына шатланып, уйнап кына йөрсә — бу бәла дә булмас иде.

Урысчаны ипи-тозлык кына белгән, тормыш изгән, тын-юаш әнисе елап җибәрде. Ләкин станциядә булган хәлләрне ишетеп килеп җиткән Мәмлиева карчык ярдәмгә килде. Үзенә каршы сүз әйтмәслек катгый тавыш белән:

— Сез хаклы түгел, егетем! — диде.— Бәла минем оныгым станциягә барганнан түгел, ә ул анда барырга мәҗбүр булганга килеп чыккан. Әлбәттә, ул менә шушы салкын өендә катып үлсә, сезгә борчылырга урын калмас иде. Мәшәкатьләгәнебез өчен гафу итәсез...

Шәһәр түрәсе алдында каушабрак калса да, сүзгә Велигданов та катнашасы итте, ни дисәң дә, аның шушында яшисе бар, ә ул сукыр карчыкның Мартукта күпчелек булган мөселманнар арасындагы абруй-дәрәҗәсен яхшы белә иде:

— Иптәш капитан, сез юкка гына... китаплар турында... Әйбәт малай ул, отличник, минем кызым белән бер сыйныфта укый...— диде.

Капитан, монда килеп чыккан фаҗига-бәладән үзенә әлләни-нәрсә таммасын аңлап, урыныннан кузгалды да, саубуллашмый-нитми генә, иске одеял элеп куелган тәбәнәк ишеккә таба атлады.

Шуннан соң Рушанны бимазалаучы булмады, хәер, югары сыйныфтагыларны бер укытучы апа «социалистик милекне урлаучы» малайны пионердан чыгарып ташлатырга тырышып шактый озак йөрде. Әмма педсоветта бу чарага бармадылар — бөтен авыл диярлек закон бозып яшәгән бер вакытта, андый шәфкатьсез әхлак була алмый иде...

Әле менә, иске ташландык депода басып торганда Рушанның исенә шул куркыныч вакыйга килеп төште дә кәефе кырылды, кайчандыр бәхетле елларын үткәргән тулай торакка кайтасы килү теләге юылды да бетте.

Шәһәргә ул бик күптәннән «Мәскәү» дип йөртелә торган тимерьюлчылар бистәсе аша кайтты. Шундагы Депо урамында аның беренче студентлар тулай торагы иде. Автобус тукталышына килеп чыккач, Рушан ерактан тимерьюлчыларның ашханәсен күреп алды, техникумнарында үз ашханәләре булса да, Рушан монысына да еш кына кергәләп йөри иде. Бу ашханә һәрвакыт пөхтәләп саргылт-алсу төскә буялган, текә түбәсе ачык яшелдән булыр иде. Ә хәзер... ишекләренә аркылы-торкылы такта сугылган, тәрәзә пыялаларын ватып-кырып бетергәннәр, урыны-урыны белән череп беткән түбә астыннан янтайган-кыегайган морҗалары тырпаеп тора... Нинди кызганыч, моңсу күренеш...

Кинәт кенә Рушанның йөзе яктырып киткәндәй булды, ул, вакытлыча булса да, авыр уйларыннан арынды шикелле...

## X

Үзәк станциядә поезд бригадалары алышына — рейстан кайтканнары да, рейска китәселәре дә шул депо ашханәсенә сугылмый калмый, анда аларны чиратсыз ашата-эчертә иделәр. Рейстан кайтканнары аш-су янына, әлбәттә инде, берәр кружка сыра да ала. Рушан яхшы хәтерли: тыны беткән кеше шикелле, авыр сулыш ала торган насослы капкорсак мичкә янында һәрвакыт башына челтәрле ак калфак кигән юан гәүдәле буфетчы хатын басып торыр иде. Паровозчылар һәртөрле салат-

тыр-каймактыр алалар, әле, җитмәсә, алар сузган биш сумлыктан күпмедер вак акча да кайтарып бирелә.

Күпмедер вагы белән бер сумлыгын учына кысып тоткан Рушан, шулай булырга тиешлеген белеп, көнләшминитми генә эченнән уйлый иде: «Менә, эшли генә башлыйм әле, мин дә биш сумга ашап йөрермен». Ул заманнарда һәркем үзенә бәхет килеренә ышана, өмет белән яши һәм көтә дә белә иде. Ул хәзер күптәннән биш сумга ашый, ә кооператив-забегаловкаларда кайвакытта унлыгын да кызганып тормый. Күптән түгел генә Мәскәүдә шундый бер ашханәгә кергән иде: анда токмачлы аш үзе генә дә биш сум тора, дөрес, инде бүгенге яңа акча белән, димәк, соңлап булса да, бу тормышта нәрсәләрдер чынга аша. Биш сумга тулы әбәт ашап чыгу — ул хәзер хыялый әкият, төштә булган кебек кенә, кызганыч ки, мәңгегә шулай булып калыр да шикелле.

Ниндидер билгеле бер яшькә җиткәч,— ә ул һәркем өчен үзенчә була,— кеше ирексездән (урынлымы-түгелме — анысы башка мәсьәлә) үткән тормышына йомгак ясый, югалтулары белән килешә, зур өметләренең җимерелгәнен таный һәм хәзер инде үзенең фаразларын-күзаллауларын елмаеп кына искә ала, ә бит ул аларны озынозак кайнар бәхәсләрдә яклый иде. Яңа буыннар аларның самими-беркатлылыкларына көлебрәк карасалар да, ә бәлки, кайбер вакытларда аларның зирәклекләренә гаҗәпләнерләр дә әле...

Бервакыт Тимерьюлчылар сараена — «Тимерлек»кә биюләргә баргач, ә Рушан анда, үзен Исмәгыйль бәк яклаганга гына түгел, Казакъстан тимер юлының бокс буенча җыелма командасына бик иртә кереп, хәтта бер тапкыр «Локомотив» составында Бөтенсоюз ярышларында да катнашканлыктан, үз яшьтәш-кордашлары арасында шактый билгеле егет санала иде,— менә шунда биюләргә баргач, гомергә истә калырлык тагын бер кызык кына вакыйга булган иде.

Ул заманнарда җирле патриотизм бик көчле, үз төбәкләрендә үсеп чыккан җырчыларны, музыкантларны, шагыйрьләрне, рәссамнарны, спортчыларны, хезмәт батырларын бик яраталар, хөрмәтлиләр иде. Сәләтле-талантлы кешеләр өчен игелекле, искиткеч ихлас-эчкерсез заман иде ул. Шуңа күрә аларның җәһәннәм артындагы тын шәһәрчекләрендә дә илленче еллар азагында джаз оркестрлары, үз эстрада җырчылары пәйда булды, концертларда заллар шыгрым тулы, рәссамнарның күргәзмәләре үткәрелә, ә инде шигърият кичәләре турында әйткән дә юк иде.

Ул көнне алар Лом-Али Хәкимов белән бергә иделәр. Җитди чечен егете иптәшенең джаз белән мавыгуын бик үк өнәп бетермәсә дә, йөрәк хисләре аны Рушанга ияреpгә буйсындырган — күрше факультетта укучы аның күзе төшеп йөргән кыз башка җиргә бармаса бармас, әмма Тимерьюлчылар сараендагы шимбә биюләреннән калмас иде.

Чытлык-кыланчык Эллочка Изместьеваны ул көнне биергә еш кына ниндидер таныш түгел бер егет чакыра, шунлыктан горур чеченебезнең борыны төшкән иде. Теге ят егетне кыздан аеру өчен Рушан Эллочканың дус кызына игътибар күрсәтә башлады. Рушан, биеп туктагач, шул кызны Эллочка янына китереп куйды да Эллочкадан:

— Кем ул синең белән биюче егет? — дип сорады.

Кыз горур гына җавап бирде:

— Ул булачак юрист, Алма-Атадан, университет тәмамлап килә. Хәзер безнең прокуратурада практика үтә,— диде.

Рушан белән Лом-Али рәхәтләнеп көлеп җибәрделәр һәм бертавыштан диярлек:

— Юрист? Үлеп-бетеп баручы һөнәр! Ике-өч бишьеллыктан соң эшсез калачак әле ул,— диделәр.

Бу сүзләр ихластан, нык ышанып әйтелде. Кыз Хәкимовның техникумда укымышлы, җитди егет саналганын, аның ил эчендәге һәм чит илләрдәге хәлләрдән һәрвакыт хәбәрдар икәнлеген дә белә иде. Димәк, егетләр шаяртып сөйләмиләр.

Беркатлы Эллочка булачак прокурорны шунда ук «онытты», ни әйтсәң дә, тимерьюлчы — гомерлек һөнәр ул!

Менә шулай, ул заманнарда алар, бер дә икеләнмичә, тиздән юристларның кирәге калмаячагына ышаналар, җинаятьчелек бетәчәк дип уйлыйлар иде. Бу самими ялгышу хәзер бигрәк еш искә төшә: җиңел генә кергән зур акчалардан һәм җәзага тартылмауларыннан башлары әйләнгән җинаятьчеләрнең бәхет сәгате сукты, аларны ишетеп кенә түгел, күреп тә белгән бик күпләргә хәзерге хәл коточкыч куркыныч, төзәтеп булмаслык өметсез булып тоела...

Тормышыңа йомгак ясаганда, артык һаваланып, борын күтәрмисең, тәкәбберләнеп, эреләнә алмыйсың, элекке шикелле юк-бар өчен дә бәхәсләргә кермисең, күп кенә хыялларыңның җимерелеп төшкәнен танырга туры килә. Бер генә юаныч кала — киләчәккә нинди ышаныч-иман, нинди өметләр белән яшәлгән бит! Аларны хәзер иң матур, иң татлы төшләреңдә дә күрә алмыйсың...

Әмма Рушанның өмете өзелеп, бик нык күңеле кайтуының сәбәбе — бүгенге болгавыр тормыш түгел, ә үз буыны иде. Теге, булачак юрист егет турында ихластан әйткән шикелле, яшьлегендә ул шулай ук чын күңеленнән бу әшәкелекләрнең бетәренә ышана иде: гаделсезлек, кабахәтлек, оятсызлык, наданлык, компетентсызлык, эчкечелек, ярлылык-хәерчелек, мәгънәсез-ятышсыз тормыш-көнкүреш — болар һәммәсе дә, Рушаннар буыны җитлегеп, җәмгыятьтә үз урыннарын алуга юкка чыгарга, бетәргә тиеш кебек иде. Рушан өлкәннәргә белем, зыялылык җитми, аларны каһәр суккан «караңгы иске тормыш калдыклары» изә, аларның эчке ирекләре юк, алар богауланган шикелле, дип уйлый иде. Ә менә яңа буын, егерменче съезд материалларын яттан үзләштергән яшьләр — алар бөтенләй башка: җәмгыятьнең бөтен хаталары-ялгышлары алар өчен уч төбендәгедәй ачык, алар башкача яшәячәкләр — чистарак, әйбәтрәк, гаделрәк, алар белән бергә бөтен дөнья үзгәрәчәк...

Яшьлегендә Рушан эчкечеләрне, ялкауларны, балаларын-гаиләсен ташлап китүчеләрне күңеле белән аңлый, гафу итә — шулай булырга тиеш, чөнки аларның тормышын тоталитар җәмгыять гарипләндергән, дип уйлый иде.

Алар буыны, нигездә, әтисез үсте, сәбәбе бер иде — сугыш. Үзе әтисез үскән егет бервакытта да сабыен ятим калдырмас шикелле иде... Кая ул! Тыныч тормыш, әтиәниләре исән, ә балалар йортларының саны сугыштан соңгы елларга караганда йөзләрчә мәртәбә артты.

Менә шушы тормыштан күңел кайту — иң авыры, иң кыены — ул йөрәкне гел әчеттереп, гомер бетмәстәй сызлатып, авырттырып тора. Кемнәрдер, бәлки, бу хисләрне шиккә дә алырлар: нинди беркатлы-наив булгансыз, заманны, аның киләчәген тоймагансыз, диярләр... Ничек карыйсың бит әле! Алар буынында һәммәсе дә бергә буталган — беркатлылык та, ышаныч-иман да, тормышка аек караш та. Рушан үз чорын бик яхшы хәтерли... Алтмышынчы еллар уртасы, ил башында — Брежнев, аз-маз гына төрлечә фикер йөртүләргә дә ирек куела.

Рушан бер ял көнен бик ачык итеп исенә төшерде: ул көнне алар «Пахтакор»ның футбол уенын карап утырган иделәр. Командада — атаклы бомбардир Красницкий (илле яшен дә тутыра алмады), аксыл-сары чәчле җитез Беляков (утыз яшен дә билгеләп үтә алмый калды), Пеле кушаматлы Хәмит Рәхмәтуллаев (кырык яшендә автокатастрофада һәлак булды). Их, заманнар...

Дуслар «Ташкент» ресторанының җәйге кафесы террасасында башланган әңгәмәләрен дәвам итәләр.

Рушан кайнарланып сөйли:

— Иманым камил, әле минем гомеремдә үк ике герман дәүләте кушылачак, Корея дә берләшәчәк... Вьетнам турында әйтеп торасы да юк...

Җавапка дуслары шаркылдап көлә генә — берәү дә аның сүзләрен чынга алмый, барысы да социалистик дөньяның берлегенә-бердәмлегенә һәм аның мәңгегә шулай буласына ышана. Ләкин Рушан инде шул чагында ук бу хәлнең табигый булмавын аңлый иде — ничек инде бер халык, бер милләт ике төрле дәүләттә яшәргә тиеш? Ниндидер бер система, бер идеология хакына милләтләрне аерып буламы соң?

Бүген халык, күпьеллык йокысыннан кинәт уянып киткән шикелле, теленә ни килсә, шуны сөйләү мөмкинлегеннән тәмам исергән-шашкан, кычкыра да акыра. Бигрәк тә яшьләр картларның тетмәсен тетә. Янәсе, сез ул үзегезнең теләсә нәрсәне дәшми-тынмый гына хуплап торуыгыз белән илне шушы хәлгә китереп җиткергәнсез!

Бәлки шулайдыр да. Әмма миллионлаган шахтерлар торгынлык елларында да көн саен күмерне Сталин заманнарындагыдан ким чыгармый иде, ә хәзерге хәбәрдарлык чорындагыдан күпкә артык та иде әле. Нефтьчеләр җитмешенче елларда илгә ике йөз җитмеш миллиард долларлык «җир мае» суыртып бирделәр. Ходай кушып, хәзерге яшь буын, алтынын-күмерен — бар булганын бергә исәпләп, хет алдагы гасыр башына шулкадәр сумманы эшләп бирсен иде әле! Торгынлыкмы-фәләнме, демократияме-фәсхетме, илдәге миллионлаган таксистлар машиналарына утыра һәм, нинди көн булуга карамастан, сменага үзенең 350-400 километрын әйләндерә иде. Чөнки халык акчалы иде!

Ә төзүчеләр? Рушан үзен белә-белгәннән бирле, аларның эшсез утырганнары булмас һәм кичке сигезсез өйгә кайтмаслар, ә иртән еш кына караңгыдан ук чыгып китәрләр иде. Бәлки, илнең таркалуына җаваплылыкны һәркемгә үзенә тиешлесен бүлеп бирергәдер? Илгә генә түгел, барлык социалистик дәүләтләргә мамык бәйсезлеге китергән үзбәк дехканының ни гаебе бар? Ул ни-нәрсә өчен кызарырга тиеш әле? Үзенең хәерче тормышы, ярлылыгы өчен кызарса гына инде...

Үз эшләрен намус белән башкарган, үзгәртеп кору чорына кадәр үк күзләре ачылган, тормышның кабахәтлекләрен алданрак күргән һәм аңлаган, үзләренең үткәне өчен йөзләре кызармастай кешеләр күп алар.

Моннан ун еллар элек, әле Брежнев заманында, ил «җиде чакрымлы адымнар белән коммунизмга якынлашып килгәндә», дәрәҗәсе буенча илдә икенче кеше, СССР Министрлар Советы рәисе Алексей Николаевич Косыгин вафат булды. Иң түрдә-югарыда утырган карт түрәләрнең үлемен халык фаҗига итеп кабул итми башлаган иде инде. Әмма Косыгин вакытсызрак вафат булган икән шул: аның үлеме кадерле Леонид Ильичның туган көненә туры килгән икән! Дөрес, үләр көнен иң зур түрәләр дә сайлап ала алмый анысы, әмма бәйрәмнәрнең, бигрәк тә үз бәйрәменең ямен җибәрергә яратмаган Брежнев партия һәм Политбюродагы иң якын көрәштәше-иптәше хакына да сүзен бирми. Шуңа күрә Косыгинның вафатын ил-халыктан өч көнгә яшереп торалар. Бу вакыйга күп нәрсә турында сөйли булса кирәк — иң әүвәл исәннәргә дә, үлгәннәргә дә кадер-хөрмәт булмаган заман һәм шул замандагы начар гадәтләр турындадыр. Ә без: «Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел!» — дигән булабыз.

Ничек кенә булмасын, әлеге кайгылы хәбәр кичкә таба Рушаннарның прораб бүлмәсенә дә килеп иреште. Инде кыш алды салкыннары тора, кибеп-корып баручы Арал диңгезе ягыннан котырынып тоз тәме катнаш әче җил исә. Инде күзгә төртсәң күренмәслек караңгы. Планерка азагында кемдер ике шешә аракы белән әллә ни бай булмаган кабымлыклар күтәреп керде. Стаканнарга салып чыккач, дәртләндерергә теләпме, кемдер:

— Нәрсә өчен эчәбез? — дигән булды.

Шунда кайсыдыр:

— Иптәш Косыгинның рухы өчен,— диде.

Җитди һәм урынлы әйтелде шикелле бу сүзләр, эчәр өчен берәр сәбәп кирәк бит.

Барысы да стаканнарына үрелделәр, ул көнне бик арыган һәм тизрәк кайтып урынга авасы килсә дә, Рушан тыштан караганда кирелеккә охшаш, әмма ниндидер эчке бер каршылык-протест белән, хезмәттәшләрен аптырашта калдырып, кинәт кенә кистереп әйтеп салды:

— Мин аның өчен эчмим!

Аракыны инде авызларына китергән халык өчен бу сүзләр шундый кинәт булды ки, хәтта берсе чак кына стаканын кулыннан төшереп җибәрмәде. Ул заманнарда әле сәяси бәхәсләр кухнялардан урамнарга бәреп чыкмаган һәм ил башлыклары өчен эчеп куюдан болай ачыктан-ачык баш тарту гадәте дә юк иде. Һәммәсе дә гаҗәпләнеп, җанланып китеп, төпченә башладылар: ни өчен дә, нишләп?

— Ә ни өчен әле мин Алексей Николаевичның рухы өчен эчәргә тиеш? — дип, тавышын күтәребрәк әйтте Рушан.— Ул хакимияттә кырык еллап утырды һәм кырык еллап җиңел промышленностька җаваплы кеше булды, дистә еллар министр иде. Ә шул вакыт эчендә халык өчен нәрсә эшләде соң ул? Нәрсә сатып алабыз, нәрсә киябез, ни белән мактаныйк? Франциядән китерелгән урыс кайры туннары, урыс күн итекләре беләнме?..

Хәзер шул күптәнге вакыйганы хәтерләп, Рушан көлемсерәп куйды. Моннан ун ел элек, ул заманны бит хәзергесе белән чагыштырып та булмый, кибет киштәләре товарлардан сыгылып торган заман иде әле ул...

Талчыккан прорабларның эчендәгесе тышка бәреп чыкты! Һәркем үзенекен әйтеп калырга ашыга, хөкүмәт башлыгы рухына эчәргә теләгән бер кеше дә калмады. Ә бит, дөресен әйткәндә, Алексей Николаевич Косыгин хөкүмәттә дә, Политбюрода да иң начар кешеләрдән түгел иде һәм моны, башкалар шикелле үк, Рушан да яхшы белә иде. Бөек илне бөлгенлеккә төшергәннәре өчен бөтен халык каһәр укыган бүгенге идарәче даирәләр аңлыйлармы икән шуны?..

Актүбәдәге борынгы вокзал җимереп ташланганнан соң, үзенең Мартукка кайткан шул ерак көннәрен искә төшереп, Рушан Дасаев бер фикергә килде, анысы да шул каһәр суккыры «михайловский» ташкүмеренә бәйле иде. Кешенең табигате бик сәер, дистә еллардан соң да аны әллә кайчан булып үткән хәлләр, шулар белән бәйле нәрсәләр дулкынландыра, дөньяда бөтен нәрсә дә үзара үрелеп берләшкән, дигән фикер кабаттан раслана. Бер шагыйрь дә бит: җирнең бер читендә кемдер суга таш ыргытса, икенче читендә ул туфан суы булып күтәрелер, дигән.

Теге вакытта, күмерсез-чанасыз килеш, авырттырган аягын көчкә сөйрәп, елый-елый өенә кайтып барган унбер яшьлек малай әле үзе дүрт елдан соң гына барып чыгасы бер шәһәрнең бер йортында «күбәләк» бантиклар ясатучы кыз үсеп килгәнен, соңыннан бер күрүдә үк шул кызга гашыйк булачагын, ә ул көнне әлеге йортта, аның исемен аерып телгә алмасалар да, Мартук станциясендә булган үзенә кагылышлы фаҗига турында сөйләшәчәкләрен фараз да итә алмый иде. Әмма ул вакытта ни Тамара исемле кыз бала, ни аның әти-әниләре бу фаҗигане аның исеме белән берничек тә бәйли алмаганнардыр. Ә менә дүрт елдан соң, ниндидер күренмәс җепләр Рушанның алдагы бөтен тормышын шул гаиләгә бәйләп тотачак иде.

Моның нәкъ шулай булганлыгына хәзер шикләнми инде ул. Чөнки кызның әтисе Василий Петрович — машинист һәм аның теге каһәрле көндә ике паровозның берсендә булуы бик ихтимал, әгәр дә юк икән, ул барыбер бу вакыйга турында кайтып сөйләгәндер: андый фаҗигаләр көн дә булып тормый бит. Һәм, мөгаен, соңрак почта тартмасыннан кызына адресланган хатларны алганда яки телефоннан сөйләшкәндә, ул беркайчан да Рушанның кайчандыр үзе кайтып сөйләгән Мартук малае икәнлеге турында уйлап карамагандыр.

Тормышта бөтенесе дә әнә шулай тыгыз үрелеп беткән, бу фикер дә аның башына әле генә килде. Хәзер инде Василий Петрович та вафат, «Тимерлек» янында үзе очраткан, кулына озын ефәк баулы ноталар папкасы тоткан купшы бантиклы кызчык та картаеп баручы хатындыр, ул да үзен гомере буе яратып йөрүче кеше турында әле очрашканчыга кадәр күп еллар элек ишеткәнлеген сизенмәгәндер. Югыйсә алар бәхетле яшьтә таныштылар: кызга — ундүрт, малайга унбиш яшь кенә иде әле. Кайтарып ала алмаслык, ерак калган заман...

Поезд бригадалары биш сумга ашап чыга торган тимерьюлчылар ашханәсен исенә төшергәч, Рушан тагын бер вакыйганы хәтерендә яңартты — анысына да ирексездән катнашы бар иде аның.

...Сафия апаның туенда кайчандыр икәүләп «ишек бавы» тотып торган, соңыннан эзе Ленинградка китеп югалган ерак туганы Мелис, егет булып җиткәч, кыска цигейка тун, хәзергечә әйтсәк, чын сарык мехлы пальто киеп йөрде. Бәхәстә ике бармагы белән бакыр биш тиенлекне бөгә ала торган Мелис төз-озын буйлы булып, тун аңа иллә дә килешеп тора иде. Ул вакытта инде сырган фуфайкаларны уңайлы мех якалы кыска бобрик пальтолар алыштырып бетергән, аларның күкрәк югарылыгында кыекча кесәләре дә бар, шунысы яшүсмерләргә тагын да ошый иде. Шул үсмерләр арасында көяз егет Мелис Вәлиевнең бердәнбер мех пальтосы, әлбәттә, күзгә нык ташлана, аның хакында авыз чайкамаган кеше дә калмаган булгандыр. Рушан хәтта бервакыт ул пальтоның бәясен дә ишетеп белде: 450 сум икән! Ул акчага ике бобрик пальто алып була иде.

Шулай килеп чыкты, инженер булып алгач, Рушанга камволь-постау комбинатын «химиягә» үзгәртеп коруда катнашырга туры килде. Комбинат синтетик тукымалар, кыскартып әйткәндә, лавсан эшләп чыгаруга көйләнде. Ул алтмышынчы еллар зур химия билгесе белән үтте: тормышыбызга могҗизаи химия үтеп кергәч, нинди

рәхәтлекләр булачак, дип, халыкка вәгъдәләрне юмарт өләштеләр. Иң мөһиме — барысы да бушлай диярлек, бик арзан булачак, йөге — бер сум, дигәндәй генә, ни әйтмә, химия бит, димәк, һавадан, төтеннән, газдан ясала.

Матбугатта габардин, коверкот, бостон, диагональ, шевиот, драп, бәрхет ише чын табигый тукымаларны китте яманлау, китте яманлау! Баксаң, алар кыйммәт тә, чыдамсыз да, тузанны да күп җыя, югач утыра, модалы да түгел икән — дөньяда иң алдынгы, иң прогрессив совет кешесенең хәзерге образына һәм бүгенге заманга, табигый ки, болар һич кенә дә җавап бирми. Кыскасы, аларның тамырын корытырга кирәк һәм эшне никадәр тизрәк тотсак, шулкадәр яхшырак булачак, имеш.

Кыргызстанның элекке Пешпек, хәзерге Бишкек, ә ул чагындагы Фрунзе шәһәрендә Рушан һәм аның хезмәттәшләре әнә шундый комбинатны кырып салды. Ә бит ул заманнарда Кыргызстанда йонның исәбе-чуты юк иде, чынлап та, йөге — бер сум, таулардагы көтүлекләрдә миллионлаган сарык утлап йөри иде бит.

Хәтерендә, әбәткә туктагач, ниндидер бер тукучы карт, үпкәсен белдереп, Рушанга әйткән иде: «Акылыгызга килегез, нишлисез сез?! Табигать үзе бар иткән тукымадан да яхшырагы беркайчан булмаган, булмаячак та. Әгәр дә инде дәүләтебез акчасын кая куярга белми икән, табигать могҗизасы — сарык үрчетүгә сарыф итсен». Менә шулай дигән иде ул карт. Ә Рушаннар, газетлардан кисеп җыелган мәгълүматларны укып күрсәтеп, синтетик тукымаларның нинди искиткеч сыйфатларга ия икәнлеген исбат итеп маташтылар.

Беренче совет лавсаны йон габардиннан ун сумга арзанрак тора иде, ләкин ике елдан аларның бәяләре тигезләнде, ә хәзер, асылда, үзебезнең йон тукымалар да юк, лавсан да каядыр югалды, ә бит шалкан бәясенә генә һәм күпме теләсәң, шулкадәр булыр, дип өметләндергәннәр иде.

Әле менә бу соңгы кышта Рушан, ничектер бер кибеткә кергәч, анда су буе чират күргән иде. Халык, сугыша-талаша дигәндәй, ясалма мех пальтолар ала икән. Ул моннан утыз еллар элегрәк Мелисның шундыйрак мех пальто киеп йөргәнен исенә төшерде, әмма ул чын мех пальто иде, ә болардан бер чакрымнан химия исе аңкып тора. Рушан арыш капчыгыдай саргылт шул нәрсәне кибеттә үк өстенә киеп куйган бер бәхетлесеннән бәясе ни хак икәнен сорады. Теге адәм, киң күңеллелек күрсәтеп, бәясе язылган ярлык кәгазен йолкып алып

бирде. Йа Хода! Булса булыр икән — нәкъ утыз ел элек ишеткән сан — 450 сум! Әмма яңа акча белән. Менә сиңа, йөге — бер сум!

Габардинсыз-бостонсыз, йонсыз-тиресез, итсез-сөяксез утырып калдык түгелме соң? Миллиард сумнарны җилгә очырдык, табигатьне химия белән пычратып бетердек... Әйе, Бишкектагы тукучы карт хаклы булган — акчаны сарык үрчетүгә тотасы калган, сарыкка, ә химиягә түгел.

Әгәр дә бүген кем дә булса илнең җитмеш ел эчендә мәтәштергән эре план-проектларын — авылларны колхозлаштырудан алып хәзерге азык-төлек программасына кадәр булганнарын тикшерә калса, без үзебезнең аңгыралыгыбызга һәм наданлыгыбызга шаклар катар идек, дөньяның һәм үзебезнең хәзерге тәҗрибәбез биеклегеннән карасак, ул проектларның күбесенең корткычлыкка, диверсиягә тиң икәнлеген күрер идек.

Соңгы вакытларга кадәр хөкүмәтнең халык тарафыннан һәрчак җитди кабул ителә торган төрле карарлары арасында вакытлыча дигәннәре дә була иде. Алар шулай башланып китә: «Шундый-шундый хәлләр аркасында вакытлыча бәяләр күтәрелә...» һәм башкалар. Әмма вакытлычадан да озаграк яшәгән бер нәрсә дә әлегә юк. Хөкүмәтнең шундый бер указы Рушанның хәтерендә гомерлеккә сакланып калды, ул аны һаман да оялып искә ала әле.

1961 елның иртә язы иде. Рушан Экибастуздан китеп барырга җыенып, вокзал перронында басып тора. Шушындагы төрмәдә әле күптән түгел генә Александр Исаевич Солженицын утырган, ә җирле ТЭЦның директоры Георгий Маленков үзе булган заман. Соңыннан Рушан аны Беренче май бәйрәмнәрендә энергетиклар колоннасы башында демонстрацияләрдә дә күргәләде.

Рушан Павлодардан киләсе поездны көтеп тора иде. Менә шул вакытта вокзал репродукторы телгә килде, хөкүмәт указын тапшыра башладылар: «Шундый-шундый тискәре хәлләр аркасында беренче апрельдән атланмайга бәяләр арта, вакытлыча, килограммы өч сум илле тиенгә кадәр булачак».

Рушанның янәшәсендә шулай ук соңарган поездны көтеп торучы бер төркем халык бар иде. Алар хөкүмәт белдерүен ачу белән, бер дә хупламыйча тыңладылар. Бигрәк тә җылы мамык шәл уранган юан бер хатын тузынды: «Аларның «вакытлыча» дигәне гомерлек була инде ул!»

Яшьлегендә Рушан, күпчелек халык кебек үк, рәсми пропагандага һәм ташка басылган һәр сүзгә ышана иде.

Шуңа күрә ул, әлеге усал төркемгә үз фикерен җиткерүне, комсомол буларак, хөкүмәт карарын аңлатып бирүне үзенең гражданлык бурычы итеп санады. Ул алар янына тәкәллефсез генә якынайды да, мәсхәрәле елмаеп, катгый гына аңлата башлады:

— Сез, иптәшләр,— диде ул,— бер бик мөһим сүзне ишетми калдыгыз бугай. «Вакытлыча»! Аңлыйсызмы — ва-кыт-лы-ча... Вакытлы авырлыклар үтәр, май да элеккедән арзанрак булыр. Мин үзем шулай булырына һич шикләнмим.— Үзенең шушы гамәленнән бик тә канәгать калып, ул алар яныннан читкәрәк китеп барды.

Бу вакыйганы аның һич онытасы юк — соңгы елларда май белән даими өзеклекләр чыгып тора, май җитми интектерә. Рушан кайчандыр үзе майларына чыдаша алмаган обывательләр дип санаган теге кешеләрдән, күңеленнән булса да, гафу үтенә. Нинди яшь һәм беркатлы булган ул!

Экибастуз, Солженицын, Маленков... Җәберләнгән юлбашчы белән җәберләнгән әдип... Безнең бу гөнаһлы җир йөзендә һәммәсе дә буталып беткән инде. Әмма, ни генә әйтмә — аларның һәркайсы, шул җөмләдән, билгеле, Рушан үзе дә бу шәһәрдән әлеге кечкенә перрон аша атлап китеп барган. Ә шәһәр ул заманнарда үзенең кырыс-усал төрмәләре һәм илдә беренче булып ачык ысул белән эшләүче руднигы белән танылган иде. Хәзер, Солженицын китаплары үз ватанында күпләп басыла башлагач, Рушан Дасаев аларның һәркайсын аерым бер дулкынлану белән кулына ала: соң, шулай булмыйни — кайчандыр бер перроннан киткән кешеләр бит...

Рушан үзенең Солженицынга якынлыгын тагын шуннан да тоя, «Рак корпусы» романын әдип Ташкент хастаханәсендә язган, дип сөйлиләр яки, аңа шул куркыныч авыру диагнозын куйгач, роман язу нияте Ташкентта туган, диләр...

## XI

Кеше язмышы югалтулар һәм табышлардан тора. Кайчакларда тегесе яки монысы йә күбрәк, йә азрак була, шуларның бер-берсенә нисбәтенә карап, мөгаен, тормышыңны бәхетле яки бәхетсез, уңышлы яки уңышсыз дип хисапларга мөмкиндер. Асылында язмыш — төпсез кое. Ахыр килеп, анда барысы да җитәрлек, теләгең булса, картлык көнеңдә үткәнеңне тыныч һәм гадел генә актарып баксаң,— чөнки ул инде синеке дә кебек, түгел дә кебек,— моны үзеңнән башка беркем дә

әйбәт итеп башкарып чыга алмас иде. Хәтта иң күренекле әдип тә.

Ихтимал, шуңадыр, Рушанның үзе турында да язып калдырасы килә, шунсыз ул заманны, безнең һәркайсыбыздан башка күрсәтеп булмаган шикелле, тулысынча күрсәтеп тә булмас иде бит. Бәлки, тормыш юлындагы ниндидер маяклар, синең яратуларың һәм мавыгуларың ни өчен теге яки бу вакыйгаларны, язмышларны, югалту-табышларны шулай кабул иткәнлегеңне аңларга булышырлар. Атлантиканың биек текә яр буендагы Язмыш борыны дигән җиреннән алып Тын океан буендагы Находка портына кадәр сузылган галәмәт чиксез киңлекләрдә Рушанга бик күп нәрсәләр белән очрашырга туры килде бит.

Ә нәрсә соң әле ул югалтулар? Югалту дип без еш кына берәр җисми әйбер турында сөйлибез: акча югалту, мәсәлән. Ә бит югалтулар күп төрле була, бөтенләй көтелмәгәннәре, ышанып булмастайлары, кайбер югалтуларны без, вакыты җитмичә, тоймыйбыз да.

Шундый югалтуларның берсе Рушанның тормышында шактый иртә, әле югалтуларга кеше күнекмәгән һәм аңа бик игътибар да итеп тормаган яшендә килде. Үз вакытында әһәмият бирмәгәнгә һәм хәзер генә ул югалтуның никадәр тирән мәгънәле булуын аңлагангамы, Рушан шул заманнарга әйләнә дә кайта, әйләнә дә кайта. Анысы да ярый: соңлап булса да, аңлавың яхшы, дип юкка гына әйтмиләрдер ич...

Ул, дүрт бишьеллыкка арткарак чигенеп, Мартугын исенә төшерә. Үткән тормышны шулай бишьеллыклап исәпләү безнең илгә генә хас, ул комга сеңгән су кебек аккан вакытны кискенрәк тоярга ярдәм итә. Рушан янә мәктәптә «Кем булырга телисең?» дигән ирекле темага язылган иншасында үзенең балерина булырга хыяллануын яшермәгән кызны исенә төшерә.

Бүген, әрсез кызлар иншаларында валютага эшләүче фахишә булырга теләүләрен оялмыйча язган заманда, ул кызыйның хыялы берәүгә дә сәер тоелмас иде. Ә теге чакта... И-и-и, теге чакта Мартук гайбәтчеләре беркатлы үсмернең бәллүр хыялын челпәрәмә китерделәр шул, гомер буена аңардан көлеп, уңышсызлыкларын күргәндә, «балерина» дип мәсхәрәләп кенә тордылар. Ә кемнең тормышы гел уңышлы гына була? Юктыр андыйлар, булса да, бик сирәктер.

Бәлки, балерина булырга бөтенләй өмете юклыгын Валя үзе дә белгәндер. Ул һөнәргә бит бик кечкенәдән, махсус мәктәпләрдә һәм студияләрдә аерым укытучылардан

өйрәнәләр. Билгеле инде, тузанга баткан Мартукта боларның берсе дә юк һәм, мөгаен, якын киләчәктә генә булмас та. Әлбәттә, ул хәтта өмет тә түгел, ә болай гына, иркә кыз баланың бер мизгеллек җиңел һәм тиз уалучан матур хыялы гына булгандыр. Өлкәннәр шул иң изге теләкнең ни-нәрсә икәнен белергә теләгәннәр. Белделәр. Һәм, кызны адәм көлкесенә калдырып, поселокка гайбәтен тараттылар...

Бервакыт Валя әрнеп әйтеп куйган иде: «Йа Хода! Безгә инде егерме сигез яшь!» Үзенең ничәнче яшеннән этәрелеп китеп әйткәне билгесез — әмма бу сан аның авызыннан бик кайгылы булып ишетелде. Рушан да үсеп җитүенең, җитлегүенең исәбен-вакытын күптән белә — дөрес, аныкы яшьрәк, егерме биш яшендә булды. Әмма алар икесе дә үз яшьләрен дөрес аңлап кабул итәләр иде инде.

Әгәр дә Рушанның сыйныфташларыннан үзе турында сораштырырга тотынсалар,— хәер, нинди уңай белән сораштырсыннар ди — кино йолдызы да, генерал да түгел, ә гап-гади прораб кына ич,— алар аның исеме белән янәшә Валя Домарова — «балеринаны» да телгә алырлар иде, үз вакытында ул бит аңарга күз дә атып йөргән иде.

Әмма беренче мәхәббәт хисе турында үзеннән сорасалар, Рушан, уйлап та тормыйча, башка берәүнең — «1905 ел» урамында яшәүче, кулына ноталар салынган папка тотып йөрүче кызның исемен атар иде: Тамара.

Алар бәхетле үсмерлек елларында таныштылар. Кайтарып алып булмас ерак заманнар. Ул чагында Рушан аны — чәченә купшы зәңгәр «күбәләк» кундырган, кулына озын ефәк баулы нота папкасы тоткан кызны Тимерьюлчылар сарае янында очраткан иде. Очратты да, артыннан ияреп тә китте. Тимерьюлчылар көне уңае белән яңа акшарланган-буялган диварлары, ялт итеп юылган тәрәзәләре белән балкып торган әкияти вокзал бинасы яныннан да үттеләр алар. Баксаң, кыз да Мәскәү бистәсендә, «1905 ел» урамындагы 28 нче йортта яши икән — кара син аны, хәтер шунысына кадәр саклап калган бит...

Хәер, Рушан белән Валяны да бер сүз белән генә аңлатып булмастай ниндидер хисләр бәйләгән иде — әле үзара сөйләшеп йөри башлаганчы ук, кыз, әлбәттә, Татар бистәсенең кара күзле бу малаена үзенең ошаганлыгын күңеле белән тоя, сизенә иде. Ә малай исә җәйге кинотеатрда ял көннәрендә була торган көндезге сеансларда күзләре белән гел аны эзли, күзләре очрашканда, кыз елмаеп та куйса, шатлыгы җиде кат күкләргә аша иде. Инде янәшә туры килсәләр, йә очраклы гына аның

күлмәгенә-мазарына, кулларына да кагылып китсә, малайның дулкынлануының чиге булмый. Рушан аны берничә мәртәбә велосипедта да йөртте бит әле! Хәзер аларның ул гөнаһсыз мөнәсәбәтләрен моңлы-сагышлы елмаеп кына искә алырга калды.

Йә, велосипедта йөртте, ди. Моның искитәрлек нәрсәсе бар соң? Хикмәт тә шунда шул, кызлар ул заманнарда теләсә кайсы малайның велосипедына утырмыйлар да иде. Кызлар альбомнарындагы «Үлсәң — үл, әмма яратусыз үптермә!» дигән язулар да, башка гөнаһсыз мөнәсәбәтләр дә хәзерге яшүсмерләр өчен тузанлы тарих булып кына тоеладыр, бәлки. Хәер, ул яшьтә әле Рушаннар буыны үбешүләр турында уйлап та карамый иде. Иң кызыгы, иң дулкынландырганы китапханәдәнме, кибеттәнме кайтышлый яки шунда ук «очраклы гына» очрашу яисә кызның каршысына берәр чаттан велосипедта атылып килеп чыгу, аңа коедан сулы чиләген күтәрешеп кайту яки ул мәктәпкә барганда, янә дә «очраклы гына» очрашу булыр иде...

Ул Валя белән җәй көне, пионер лагеренда ял итеп кайтканнан соң, кинотеатр янында танышкан иде. Легендар Джон Вейсмюллер уйнаган «Тарзан» фильмының чираттагы сериясен күрсәтәләр, билет кассалары янында — мәхшәр, ә Рушаннар Татар бистәсеннән бер компания булып җыелып килгәннәр, араларында теге башкисәр чечен Солтан да бар иде. Рушан кассадан ерак та түгел җирдә тыгыз итеп, ак тасма-күбәләк куеп үрелгән толымлы кызны шунда ук күреп алды. Кызның бу сеанска эләгергә өметен өзгәне күз карашыннан ук сизелә иде. Шунда Рушан үзе дә аңышмастан кыз янына килде дә бераз каушый төшеп сорады:

— Сиңа ничә билет кирәк?

Кыз шатлыгыннан балкып китеп:

— Бер, теләсә кайсы рәткә,— диде һәм учындагы тирләп беткән көмеш акчасын сузды.

Рушанның күңеленә ул гомерлеккә шулай учындагы егерме тиен акчасын сузган килеш кереп тә калды.

Бәлки, алга таба Валя белән аралары бөтенләй якынаеп та киткән булыр иде, әмма техникумда укый башлавының беренче көзендә үк ул алсу «күбәләк» бантиклы кызны очратты. Әгәр дә җәясендәге укны тартып торучы түгәрәк битле Амур дигән фәрештә бар икән, ул бер атуда ук Рушанның нәкъ йөрәгенә тигезде.

Валя белән дә, бер-берсенең күз алдында үскәнгәме, җәйге кинотеатр янында башланып киткән бер-берсенә тартылу хисе һаман да сакланып килә иде. Хәер, Валя —

чибәр, үзсүзле, үзенең үзгә йолдызы барлыгына инанган кыз — биредәге малайлар арасыннан кемне булса да үзенә тиң санадымы икән? Ул, һичшиксез, Мартуктан кайдадыр еракта үзен искиткеч Принц көтеп торадыр дип ихлас ышана иде.

Ә бит туган ояларыннан тизрәк очып чыгып китәргә ашкынган Мартук гүзәлләренең һәммәсе дә диярлек шундый хыял белән яшәгәндер. Шактый вакытлар үткәч, бер очрашканда Валя үзе шулай сөйләгән иде. Ул арада Валя инде Куйбышев шәһәрендә институт тәмамлаган, кияүдә булган, хәтта әле ике тапкыр бугай! Һәм, бераз тын алырга дип, әти-әниләре канаты астына кайтып сыенган чагы иде.

Рушан бу вакытта үзе дә институт дипломы алган, хәтта чак кына өйләнми дә калган иде, әмма туй дигәне һич тә аның гаебе белән сүтелмәде. Аның өстендә ниндидер кара язмыш бар иде шикелле — кайсы кызга гына гашыйк булмасын, алар һәммәсе дә шашкын-дәртле мәхәббәткә сусаган, хыялларында җиде кат күкләрдә йөзәләр, искиткеч Принцка өмет итәләр, бер мәшәкатьсез, кайгы-хәсрәтсез романтик тормышта яшәргә телиләр иде. Билгеле инде, Рушан әкияти принц була алмый, кызлар теләгән «бер мәшәкатьсез романтик тормыш»ны тәэмин итәргә дә кулыннан килми. Ул хәтта андый тормышны күз алдына да китерә алмый иде. Ләкин шунысы сәер, ничәнче кат авызы пешсә дә, ул янә шундый ук берәр кызга гашыйк була, кызлары да, күрәсең, бу егеттәге ниндидер сыйфатларны ошаталар, аңа кияүгә чыгарга бик ашкынып тормасалар да, бөтенләй үк читкә дә тибәреп бетермиләр иде.

Инде хәзер, картаеп барганда, берьялгызы калгач, кемнәрнеңдер күз алдында ул, бәлки, уңмаган бер бәхетсез адәм булып күренәдер. Әмма Рушан үзе һич алай санамый һәм үзенең үткән-кичергән тормышын һичкайчан да әйбәт хуҗабикәле тыныч, рәхәт тормышка алыштырмас иде шикелле.

Бервакыт ул, үзенең төзелеш эшләренә кагылышлы командировкадан кайтышлый, юл уңаеннан берничә көнгә генә Мартукка сугылды. Исәнләшеп-сөйләшеп туйгач, тегесен-монысын караштырып бетергәч, ул, бөек Сталинның яшелләндерү планын тормышка ашыру максатыннан, кайчандыр үзе утырткан һәм хәзер инде куәтле-зур булып үсеп киткән карагачларның, тирәкләрнең корыган ботакларын кисәргә булды. Шул эш белән шөгыльләнгәндә, аның янына велосипедка атланган кыю гына бер кыз бала килеп исәнләште дә бер язу сузды.

Рушан шакмаклы дәфтәр битен аптырабрак кына кулына алды, язучының кулын танып, ашыгып укый башлады:

*«Рушан, сөеклем! Кичә синең үзебезнең якларга кайтканыңны ишетеп бик сөендем. Очрашып сөйләшсәк, уртак дусларыбызны искә төшереп утырсак, ә Володя Колосов белән Толик Чипигин кебек иртә вафат булганнар рухы өчен берәрне тотып та куйсак, әйбәт булыр иде. Нинди яшь, беркатлы-самими һәм бәхетле булганбыз, шуны аңламаганбыз, әйеме? Мәктәпкә берәр кичәгә яки, әти-әниләрдән курка-курка, кача-поса гына паркка биюләргә йөрү, борылып карагач, синең ягымлы, ярату тулы карашыңны тою — нинди рәхәт, нинди матур чаклар булган ул!*

*«Минем тугрылыклы Рушаным» — синең исемеңне мин бик еш кына әнә шулай һәркем ишетерлек итеп, дус кызларымны көнләштереп, кычкырып кабатлый идем. Сөер бит, безнең арада берни булганы юк, хәтта бер үбешмәдек тә, ә барыбер, ни өчендер, мин сине һәрвакыт үземнеке санап йөрдем, сиңа хакым бардыр кебек тоела һәм минем өчен утка-суга керерең ә ышана идем. Ялгышканмын. Гомумән, тормышымда күп ялгыштым һәм күп мәртәбәләр авызым пеште.*

*Әмма, бигрәк тә шуңа күрәдер, бәлки, сине тормышымязмышымнан сызып ташлап булмый... Бихисап татар туганнарың үзеңә карап, сокланып туйгач, бүген кич соңлабрак, сәгать унберләргә килеп чык әле. Валя.»*

Рушан укып бетергәнче, велосипедлы кыз китми торды — мөгаен, язуга борынын төрткән булгандыр әле, хәзер, әнә, кызыксынуын яшермичә, кайчандыр Валя апасы ошатып йөргән бу абыйны күзәтә.

Рушанның уйларга бирелеп, үзен онытканын күргәч, кыз үҗәтләнеп сорады:

— Килерсезме?

Рушан, сискәнеп, уйларыннан айнып китте, таркау гына:

— Килермен...— дип җавап бирде, хәтере янә үткәннәргә кереп уралды.

Мартукның кичләре искиткеч була: җәен көндезләрен кырык градуслардан ашкан эсселек, вакыт-вакыт кайлардандыр көйдергеч-кайнар җилләр исә, ә кояш баюга бер могҗиза була — көтмәгәндә салкын төшә, һава сафлана, ә соңрак биектә, зәңгәрсу-кара төнге күктә бихисап якты йолдызлар кабына. Табигатьтәге бу сихри үзгәрешне хәтта күңеле катып беткән, бар нәрсәгә битараф кешеләр дә тоялар, юк-юк та берәрсе сокланып әйтеп куя: һай, кичләре дә кичләре, карап-сулап туйгысыз!

Ул көнне дә дала ягыннан түзеп булмаслык корыкайнар җил исте, кешеләрне әлсерәтеп, кояш рәхимсез кыздырды, ә зур утлы кызыл шар бакчалар артына, офыкка кереп югалуга, ниндидер тылсымчының кулы беләнме, бөтенесе дә үзгәрде дә куйды, хәтта бакча хуҗаларын кич су сибү мәшәкатеннән коткарып, бер ярты сәгать чамасы җылы яңгыр да явып алды.

Валяны Рушан соңгы тапкыр бик күптән, моннан җиде-сигез еллар элек күргән иде. Кыз әле — студентка, җәйге каникулга кайткан, ә Рушанның исә чираттагы ялы иде. Бию мәйданчыгында очраштылар, әмма юньләп сөйләшә дә алмадылар — кызны гел генә биергә чакырып торалар. Шәһәр Валяга үз йогынтысын ясап өлгергән: кыркылган-кистерелгән чәч, буялган тырнаклар, соңгы модалы купшы-көяз кием, үзен тотышында да ниндидер яңалык бар — дорфарак кыланчыклыкмы шунда. Егетләр белән үзен бик иркәле-иркен тотуын, биюләрдән туктап торган арада шулар белән бергә ачыктан-ачык тәмәке тартуын Рушан килештереп бетермәде шикелле. Ә менә күпләргә кызның шул кыланышлары ошый, хуплап: «Күрсәтә бу!» — диләр. Вакыт-вакыт Валя артык күп һәм артык каты кычкырып көлә, шуның белән башкаларның игътибарын тагын да ныграк җәлеп итә иде. Ләкин Рушан, авыз ачып, аңа: «Син үзеңне артык әдәпсез, артык вульгар тотасың»,— дип әйтә алмады. Кич буена шул сүзләр тел очында торса да, кыюлыгы җитмәде. Дуслары аңламас: «Балеринасын кулыннан ычкындырган ачудан сөйләнә»,— дип әйтүләреннән курыкты. Үз-үзеңне табигый иркен тоту белән тупас әдәпсезлеккә якын вульгарлык арасын кем сизә, кем сизми дигәндәй, шул чикне Рушан сизә-тоя, ә Валентина үзе чамалап бетерми иде, ахрысы. Аңа мөкиббән киткән поселок егетләре һәм кызлары турында инде әйтеп торасы да юк: алар Валяның үз-үзен тотышын заманга ятышлы иң яхшы үрнәк итеп кабул иткәннәр иде.

«Ниндирәк икән ул хәзер? Тормыш нәрсәгә өйрәтте икән үзен?» Шундыйрак сораулар Рушанны көне буе бимазалап торды. Купшы капрон «күбәләкле», тыгыз үрелгән толымлы кызның дымлы көмеш егерме тиенне үзенә сузып торган сурәтен соңгы мәртәбә күргән кыз — кистерелгән-буялган сары чәчле, әйтергә дә оят кыска мини итәкле, бармак араларына сигарет кыстырган кыз сурәте каплый да китә, каплый да китә иде.

Дөресен генә әйткәндә, командировкадан калган берничә көнен өйдә үткәрергә дип кайтканда, Рушан Валя турында уйлап та карамаган иде. Әле хәзер, чакыру ал-

гач та, әллә нинди планнар корып тормады. Асылда, аның очрашуга баруы яшьлегендә үзенең шул кыз өчен кем булуын һәм ни өчен алар арасында бернәрсә дә барып чыкмавын ачыклау өчен кирәк иде. Велосипедлы кыз артыннан биреп җибәргән язуында Валя матур сүзләр тезүен тезгән дә бит... Әйтерсең алар, Сиам игезәкләре кебек, гел бергә булганнар!

Әлбәттә, Рушан үзе дә нык үзгәрде. Ул бик яшьли, бөтен яңалыкны комсызланып йотардай вакытыннан ук шәһәр кешесе булып китте. Үзенең «авыл бәрәңгесе» икәнлеген аңлагач, ул үзенә чит күз белән карарга өйрәнде, шул аңа бик күп ярамаган гадәтләреннән арынырга ярдәм итте. Әмма барыннан да бигрәк, үзендә булган яхшылыклар өчен ул гыйшык тотып йөргән кызларына бурычлы — алардан саф яктылык бөркелә иде сыман. Ул кызлар Рушан ахырынача аңлап бетерә алмаган нindидер әкияти-хыялый дөньяларда, җиде кат күкләргә ашарга теләп яшәсәләр дә, аларның берсен дә кулларында сигарет белән, урынлы-урынсыз кычкырып-кычкырып көлүләре, буялган тырнак, каралткан-зәңгәрләндергән каш-күз, бөтенләй итәксез диярлек мини-юбкалар белән күз алдына да китереп булмый иде.

Ул кичтә элеватор янындагы тын урамда, кайчандыр утыртылган нечкә-зәгыйфь көмеш сыман тупылларның мәһабәт ябалдашлары арасына кереп сыенган өйдә алар икәүдән-икәү генә очраштылар...

Чынлыкта, бер-берсе турында бик аз белгән ике зат...

Әлбәттә, бу очрашу үзләренә бөтенләй башкача тоела иде...

## XII

Совет урамына Рушан билгеләнгән вакыттан алданрак килде: аның бу урамны азагына, кирпеч заводына кадәр карап узасы килә иде. Иң соңгы йортта Эмма Бобликова тора, бервакыт анда Октябрь бәйрәме кичәсенә җыелышып, Рушан белән аның дусларын кертмәгәннәр иде. Биек койма артында кәеф-сафа корып утыручы бәхетлеләргә нинди дә булса этлек эшлиселәре килеп, шул йорт тирәсендә бик озак бөтерелгәннәр иде. Ярый әле, ул хурлыклы адымнан кемдер тыеп калды. Урам беткәч, аерым утарда Генка Лымарь яши, теге ноябрь киченнән соң ике атна үткәч, шунда Яңа елны каршыладылар. Эммадан кала кызларның һәммәсе дә килгән иде, ә Эмманы, «хыянәтче» дип, чакырмадылар да, Рушанның ул тирәләрне дә күрәсе килә иде.

И, ул Яңа ел бик кызык булган иде! Валентина ул елны унны бетерә, Рушан исә Мартукка шәһәрдәге дуслары Роберт белән Рафаилны ияртеп кайткан иде. Алар, поездлан төшүгә үк, туп-туры мәктәпкә — Яңа ел кичәсенә киттеләр, ә шуннан соң инде, шау-гөр килеп, бергә — Мартук читендәге утарга килделәр.

Ике шәһәр егете дә булу кичәгә аерым бер ямь өстәгәндәй булды, аларның килерен алдан ишетеп белгән кызлар танымаслык гүзәлләр иде. Шунлыктандыр, мөгаен, «бал-кичәнең хуҗасы» Саня Вуккерт бер өстәл тирәсенә үзара көндәш булган бик күп кызларны рәттән тезеп утырта алды. Ә иртәнге якта Роберт яшькелт күзле Томочка Солохоны озата китте дә... үзен милиционер китерде. Егет адашкан икән дә, бик ышанып һәм гадәтләнгәненчә, милиция бүлегенә барып кергән — аның әтисе ул заманда өлкә прокуроры булып эшли иде.

Шунда Рушан гомерендә беренче һәм соңгы тапкыр кызыл «Цимлянское» дигән шампан шәрабы эчте. Биек бокал эчендә, ут яктысында ул искиткеч матур уйнап-балкып тора иде. Бары тик шул кызыл шампан шәрабы өчен генә дә ул ерак калган Яңа елны искә алырлык иде. Әмма ул кичәдән тагын бер нәрсә күңелдә уелып калган әле: «Цимлянское»дан тыш анда гади шампан да булып, анысы... гади ярты литрлы шешәләрдә иде. Үткен телле Вуккерт аңа шунда ук «Ике кешелек шампан» дигән исем дә биреп өлгерде, чөнки кайберәүләр, берәр шешә эләктереп, күзе төшкән кызы белән күрше бүлмәгә кереп шылырга ашыктылар...

Сүрән яктыртылган Совет урамына килеп чыккач, Рушан бераз югалып калды. Бакчалардагы куе-биек сирень куаклары караңгыга чумган йортларны каплап торганлыктан, ул каршыдагы өч йортның тәгаен генә кайсысы Валентиналарныкы икәнен абайлап бетерә алмый иде. Элекке билге — Домаровлар янкапкасы каршысындагы кое да күптән юкка чыккан икән. Ул, алдан ниятләгәнчә, урам буйлап китеп барырга булды, сәгать унберләргә борылып килгәч, кайсы капканы шакырга икәнен, мөгаен, чамалар әле. Әмма кинәт кенә бер бакча артыннан матур гына итеп гитара чирткән тавыш ишетелде, аннары — ниндидер тын, шатлыклы аваз, күптән кыркылмаган сирень куаклары кыштырдавы — янкапкадан ак күлмәкле, зифа буйлы кыз күренде, улерактан ук ясалмарак пышылдап:

— Рушан, минем кайда торганымны әллә оныткансың да инде? — дип сорады.

Рушан тиз генә юлны аркылы кисеп чыкты да, яңгырдан соң җыелган күлдәвек аша сикереп, кыз янына ки-

леп басты, үзенә сузылган салкынча һәм искиткеч ягымлы-нәфис кулны кысып алды.

— Исәнме, Валя. Бер дә онытмадым,— дигән булды ул, бераз каушый төшеп.— Алданрак килеп, Эмма Бобликовалар йортына кадәр барып килергә теләгән идем, сез анда, безне — Татар бистәсе малайларын кертмичә генә, Октябрь бәйрәме кичәсе үткәргән идегез.

— Ә син эчкерле икәнсең,— дип көлемсерәде Валя.— Ичмасам, бергә үткәргән Яңа ел кичәсен исеңә төшерер идең! Теге, синең дустыңны, Роберт иде бугай, иртәнге якта милиционер китергән кичәне, дим... Ә нинди шампан эчкән идек ул чакта, ә! Кызыл «Цимлянское»! Беләсеңме, шуларны сөйләсәм, миңа беркем дә ышанмый...— Кыз кинәт кенә күңелсезләнеп калды.

Менә шулай, капка төбендә үк, истәлекләр киче, «Ә хәтерлисеңме?..» сорауларына җаваплар уены башланып китте.

— Сезнең бакчада нинди гитарачы яшеренгән? — дип сорады Рушан.

— Мин байтактан гитара чиртәм бит, студентлык елларымнан бирле,— диде Валя.— Начар уйнамыйм, диләр.— Бераз тынып торгач, кинәт өстәп куйды: — Син бит минем хакта бернәрсә дә белмисең. Безнең бит хан заманнарыннан бирле күрешкән юк инде. Әйдә, рәтләбрәк күрим әле үзеңне,— дип шаяртып, биек багана башындагы фонарьдан төшкән сүрән яктылыкка табан — күрше йорткарак өстерәде.

Күршеләрнең кыйшайган коймасы буенда Рушанны әле тегеләй, әле болай әйләндергәләп караштырганда, Рушан үзе дә олыгаеп киткән Валяны күзәтү форсатын ычкындырмады.

Аллага шөкер, теге бию мәйданчыгындагы акшарлы сары чәчле кызыйдан берни дә калмаган икән. Хәзер Валя, гадәттәгечә, табигый: бернинди химиясез-бөдрәләрсез чәче шома гына итеп артка таба җыеп куелган, киң-биек маңгае да ачылып киткән, күз тирәләренә сизелер-сизелмәс кенә төс иңдергән, шунлыктан карашы да серлерәк, матуррак тоела. Бу серлелекне ул әле тагын үсмерлек елларында күргән Голливуд фильмнарындагы Грета Гарбо, Мерилин Монро, Элизабет Тейлорлар кылана торган алым белән дә көчәйтеп җибәрә: Валентина кинәт кенә, гел көтмәгәндә керфекләрен түбән төшереп, күз карашын читкә ала, аннары үзенең матур башын оста гына итеп бора да керфекләре яңадан күтәрелә һәм күзләре йолдызлар шикелле җемелди башлый.

Бу «җемелдәшкән йолдызлар» дигән мактау сүзен кызга биюләр вакытында ниндидер бер практикант егет

әйткән иде. Ә Мартукта ул практикантлар җәйләрен җитәрлек була: инженерымы, табибымы, ветеринары-фәләне дисеңме — буа буарлык! Ә Валя теге чакта шунда ук, түзмичә, Рушанга мактанасы итте: «Минем күзләрем, чынлап та, җемелдәшкән йолдызлар төслеме?»

Хәзер сокландыра белүнең бу ысул-алымын ул шулкадәр оста һәм җитез итеп, сәнгатьчә башкара, ул хәтта аның гадәтенә әйләнгән иде инде. Әле дә менә Рушанга әнә шул «җемелдәшкән йолдыз»лы карашын берничә мәртәбә бүләк итеп өлгерде.

Артка җыеп куйган чәче өстендә ялтыравык муар бант, ул ачык бизәкле эре тропик күбәләккә охшап тора. Менә шул «күбәләк» аны аеруча матурайтып-яшәртеп күрсәтә — зифа буйлы бу гүзәл инде ике мәртәбә кияүдә булып кайткандыр, дип берәү дә әйтә алмас иде шикелле.

— Кызганыч, яшьлегемдә сине бәяләп бетермәгәнмен,— дип көрсенеп куйды Валя.— Бик чибәр күренәсең: менә дигән ир-егет, тазарып-ныгып та киткәнсең. Ә мин сине еш кына иске велосипедка атланган йолкыш бер малай итеп искә төшерәм. Син һәрвакыт көтмәгәндә һәм бик еш килеп чыга идең... Ә соңыннан бөтенләй югалдың...— Аның холык-табигатендә әнә шундый шартлаучан кисkенлек бар иде.— Өстеңә элгәнең дә ярыйсы, башкалача...

Бу «элгәнең» сүзе Рушанның күңеленә тиеп узды — «1905 ел» урамында яшәүче кыз бер генә дә алай әйтмәс иде.

— Поселокныкылардан бик азлар гына чын шәһәр кешесе булып китә. Рухы, асылы белән, дим,— әле һаман да Рушанны тартынусыз-нисез әйләндергәләп, күңеленә үтеп керердәй карашлары белән бораулый-бораулый, ул сүзен дәвам итте.— Син моны булдыргансың бугай. Славка Афанасьевны хәтерлисеңме? Ну, теге, биегәндә уйнаткычтагы пластинкаларны алыштырып торыр өчен сез Яңа ел киченә чакырган егетне әйтәм. Ул, баксаң, «Караван» көен ярата икән, гел дә шул Эллингтонны әйләндереп торган иде...

— Әйе, хәтерлим,— дип елмайды Рушан, ул кичтә, чынлап та, шундый мәзәгрәк хәл булган иде бит.

— Менә шул Славик, мәсәлән, шәһәр кешесе була алмаган һәм була да алмас, мөгаен. Юкса синең шикелле үк, башкалада — Алма-Атада яши. Мин аны узган айда күрдем, әти-әниләре янына кайткан иде. Корсак үстергән, юньләп кырынмаган да, бик каты эчә бугай. Өстендә ниндидер «Мосшвейпром» костюмы капчыктай эленеп тора...

Ә син импорт кигәнсең, француз парфюмериясе исләре дә бар үзеңдә, бер сүз белән — джентльмен...

Карап-өйрәнеп бетергәч, ул Рушанны култыклап алды һәм кинәт, янә көтелмәстән әйтеп ташлады:

— Ярар, синеңчә булсын, Бобличихалар йорты яныннан әйләндереп алып киләм үзеңне. Бәлки әле хуҗабикә дә килеп чыкмасмы шунда — алар соң ята. Мине синең белән күреп, көнләшсен әле.

— Ә нигә көнләшсен? — дип аптырап сорады Рушан.

— Ә шуңа, без синең белән шундый яшь, төз-зифа буйлылар, көязләр, ә Эммочка, беләсең килсә, кадерлем, инде илле сигезенче размерга сикерде, эчке күлмәкләрен дә ательеда тектерә. Билгеле, Парижда түгел инде...— алар икәүләп ихластан көлеп җибәрделәр.

Әйе, Валя әле дәртен-ялкынын сүндермәгән, һаман да — ут...

Алар кирпеч заводы янына кадәр бардылар, Эмманың йорты яныннан да үттеләр: ишегаллары дөм караңгы, йомшак җил генә баудагы кипшенгән керләрне шыштырдата иде бугай. Ерак булмаган тимер юлдан дөбердәп состав үтеп бара иде, якындагы йортларның тәрәзә пыялалары зеңли башлады. Валя анда да үзенең элекке дустын мыскыллап алырга онытмады:

— Бу безнең кадерле Эммочкабыз йокысында көрсенеп, икенче ягына әйләнеп ятты...— диде.

Лымарьлар йорты янына да барып җиттеләр, анда хәзер башка кешеләр тора икән, ә Гена эти-әниләре белән Актүбәгә күченеп киткән, ниндидер автохуҗалыкта эшли икән. Янә дә теге, шәмнәр яндырып, Дюк Эллингтон, Элвис Пресли һәм хәзер инде бөтенләй онытылып беткән Джонни Холлидейларны җырлатып-уйнатып, төн уртасында фал ачып, күрәзәлек итеп үткәргән Яңа ел кичен исләренә төшерделәр. Яшькелт күзле Томочка Солохо бик оста күрәзәче икән, һәркемгә ерак юллар, буш мәшәкатьләр һәм иртәләгән сагыш юрады ул... Юраганы юш килә бугай шул...

Алар шулай култыклашып йокылы поселок урамыннан атладылар да атладылар, тынып калган төнге Мартук өстенә йолдызлы биек күктән үтә күренмәле нурбалкыш коела, хәтта этләр дә өрми — ни хуҗасызлары, ни һәр биек койма артында чылбырда булганнары, дигәндәй — тирә-юньдә тынлык хөкем сөрә иде. Бәлки, табигатьнең шул төнге тынлыгыннан сихерләнепме, Валя, ни өчендер пышылдап, әмма тавышындагы гадәти шаянлык белән кинәт әйтеп куйды:

— Безнең очрашуны билгеләп үтәргә вакыт җитте дип уйлыйм...— ул Рушанны кысыбрак култыклап, адымнарын тизләтергә мәҗбүр итте.

Капкалары янына кайтып җиткәч, Валя аны бераз артистларча кыланып ачып җибәрде дә, үзе янбакчага кереп югалды һәм аннан сабына кызыл бантик бәйләнгән гитара күтәреп килеп чыкты.

Шулай туры килгәнме, Совет урамында таза-нык хуҗалыклы халык яши, йортларны да «немец манерында» — төрле архитектур бизәкләр белән җиткезәләр иде. Валяның әтисе исә көчле-чыдам кеше — юл төзү идарәсендә шофер булып эшли, кирпечтер-цементтыр ишеләрне җиңел таба, шунлыктан йорт-җире, каралты-курасы гөлт итеп тора. Калай түбәле, биек болдырлы төп йорттан тыш, иркен ишегалдында җәйге кухнялары да бар — анысының чирәп түбәсе сыек яшелгә буялган, тәрәзәсез, киң-иркен верандасы ачык, ул җилләр иркендә.

Валя Рушанны шул җәйге йортка алып керде. Төрле җирләре зәңгәр төсләрнең әле куерагына, әле сыеграгына буялган ачык веранда һәр хуҗалыкта була торган яшелчә бакчасы ягына карап тора иде. Ләкин Совет урамындагы яшелчә бакчалары шуның белән аерыла, алар биек ярлы, тирән чокыр-ерымга барып терәлә, ул ерым, агач-куаклар үсеп, күптән инде кыргый бер бакчага әверелгән, кайберәүләр яр буйларына җимеш агачлары да утыртканнар. Домароваларның да шундый бакчасы бар иде...

Веранда дивары буенда тәбәнәк журнал өстәле, аның як-ягына тирән генә ике кәнәфи куелган, аларны, күрәсең, төп йорттан алып чыкканнардыр. Өстәл өстенә, аш өстәле рәвешен китереп, шикәрдәй ак ашъяулык җәелгән, шуңа күрәме, уртага куелган бәллүр вазадагы вак роза чәчәкләре аеруча җете күренәләр. Матур, зәвыклы итеп табын корылган, минераль судан тыш яхшы коньяк шешәсе дә кукраеп утыра.

Кунакны утырткач, Валя гитарасын бер читкә куеп, өстәлгә кабымлыклар, җиләк-җимеш, үлән-сәлән тезә башлады. Бу эшне ул ничектер бик җиңел, килешле-матур башкара, Рушан: «Мөгаен, уңган хуҗабикә булыр бу»,— дип уйлап та алды. Ә безнең заманда андый хатын-кызлар шактый сирәк очрый хәзер. Өстәлгә куясыларын куеп бетергәч, алда торган сугыш кырын караган генералдай, Валя аны янә бер тапкыр күздән кичерде һәм... утны сүндерде. Аннан соң, веранданың ишеге тирәсендәге суыткыч янында шырпы сызылды, хуҗабикә, өч җәпле шәмдәлнең шәмнәренә ут элеп, өстәлгә ките-

реп утыртты. Кунагы янына килеп, һаман да шулай артистларча каты пышылдап:

— Курыктыңмы? — дип сорады, аннары иелеп, тирәякка таныш түгел хушбуй исе бөркеп, Рушанны үбеп алды.

Шуннан шома гына юлдан истәлекләр кичәсе башланып китте. «Ә исеңдәме?» сүзе, пинг-понг шары кебек, бер кәнәфидән икенчесенә очып кына торды. Кайбер мизгелләрдә Рушан элекке Валяны — сокланучан, тиз ышанучан, Балерина кушаматы алган самими кыз баланы таныган да кебек булды. Әмма төтәсләп, эри-эри янган шәмнәрнең караңгылы-яктылы күләгәсендә нәфис ак күлмәкле, кырыс холыклы, таныш түгел ханым утыра һәм ул бик оста гына итеп Рушан турында һаман да күбрәк белмәкче була: үткән тормышы нинди, алдагы планнары?.. Ләкин Рушан да төшеп калганнардан түгел, маңгайга бәреп бирелгән сораулардан матур гына тайчанып, шәрыкчә сырлап-сырлап, озын-озаклап җавап бирә, нәтиҗәдә үзе турында сөйли дә кебек, сөйләми дә кебек килеп чыга. Ә ханымның нәкъ менә аның турында беләсе килә...

Андый озын-озак сүз боткасы куертырга күнекмәгән, күрәсең, ниһаять, ханым түзмәде, рюмкаларга коньяк койды да, шаярткандай итеп һәм бер үк вакытта үпкәләгәндәй кыланып:

— Мин аңа бар булганымны ачып салам, стриптиз биегәннән дә артык чишендерәм үземне, ә ул боргаланып утыра! — диде. Аннары тезә башлады: — Синең ихласлыгыңны Шәрык шулай кырып-көйдереп бетердеме? Ә мин бит синең хакта кайбер нәрсәләрне беләм... Күз алдыңа китер әле, мин хәтта син фәрештә күреп йөргән кызның өендә дә булдым. Минем хатын-кызларча аңлыйсым килә, ни өчен синең Томочка Давыдычева белән мөнәсәбәтләрең барып чыкмады? Син бит аны өзелеп сөйгән идең шикелле. Ну, минем белән булганы аңлашыла, мин үзем дә нәрсә теләгәнемне, кемне теләгәнемне белми идем, әгәр дә дөресен әйтсәк, мин сезне — мартуклыларны бер тиенгә дә санамый идем, минем арттан бер син генә чапмадың бит. Үз-үземә артык ышанганмын, тәкәббер һәм юләр булганмын, сездән мән чыккан, кайсыгызны алып карасаң да, үз юлыгызны тапкансыз, кеше булгансыз.

— Син Тамараны кайдан беләсең? Ничек син аның өенә барып керә алдың? — Рушан бу сорауларны тонык тавыш белән, дулкынлануын яшерә алмыйча бирде.

— Ниһаять, җан керде үзенә, кызыксына! — дип кычкырып җибәрде Валя һәм аңа таба рюмканы этте.

Эчеп куйгач, сорады:

— Дөресен генә әйт әле, мине алдаша дип уйладыңмы? Юкка. Синең пассияңнең — сөйгәнеңнең, дим,— исеме беркемгә дә сер түгел иде бит. Синең белән бер үк вакытта шәһәрдә Мартук кызлары байтак укый иде — кооператив техникумында, культура-агарту училищесында, медучилищеда һәм мединститутта. Соңлап булса да, үзеңә комплимент әйтим әле: ул кызлар синең белән горурлана, син анда шактый танылган, бокс буенча чемпион, шәһәрнең күзгә күренердәй егетләре белән генә аралашасың, дип сөйлиләр иде. Бервакыт Валя Белозерова белән Тома Ярошенко паркта хәтта син булып кыланып та күрсәттеләр. Дүртенче курста укыган чагында кичләрен Бродвейга чыкканыңны. Пөхтә үтүкләнгән киемнәрдән, көзгедәй ялтыратылган туфлиләрдән, кыл уртадан ачып, майлап-шомартып таралган чәчле син, имеш, үзең еш кына була торган кырык бишенче мәктәп яныннан башлап дөмбер-дөмбер джаз уйнаган паркка кадәр гел уңга-сулга баш иеп, сәлам биреп кенә киләсең икән — Бродвейда үз кеше булгансың инде. «Ә без,— дип сөйли иде Белозериха,— Карл Либкнехт урамындагы берәр тын почмактан карап-күзәтеп торабыз, дус кызларыбызга, горурланып: «Күз камаштырырлык елмаеп килүче ул чибәр егет безнең Мартукныкы, якташыбыз!» — дибез. Әмма безгә бик ышанып бетмиләр иде...» Менә шулай дип сөйли иде ул.

— Әйе, мин сине бераз шыттырасың, арттырып җибәрәсең, дип уйлаган идем. Анысы хатын-кызга хас нәрсә. Безнең Шәрыктә: «Матурлык белән мәкер янәшә йөри»,— диләр.— Рушан аны үпкәләтмәскә тырышып, шаяртыбрак шулай җавап бирде. Аның холыксызлыгын белә, шуңа күрә бу кичнең ямен җибәрәсе килми иде.

— Ну, бу юлы синең ирләрчә күзәтүчәнлегең сынатты. Ярар, шулай булсын, Томочкаңның өенә ничек барып эләккәнемне сөйләп бирим. Күзләреңнән күреп торам, юкса син гомерең буе шул серне уйлап газапланачаксың...

Валя, капылт кына кузгалып, чәчәкле ваза артыннан сигарет пачкасы алды һәм, гаепләмә инде, дигәндәй, кулларын як-якка җәеп, авызына сигарет капты һәм тартып җибәрде.

— Беренче ике курсында син һәр шимбә саен диярлек кайтып йөрдең, мәктәпкә кичәләргә яки клубка биюләргә килә идең һәм без еш очраша идек. Ул чакларда мин сиңа ошый идем, дип уйлыйм, әгәр дә синең хисләреңә җавап биргән булсам, син ул тимерьюлчы кызын

онытыр да идең. Ләкин мин теләсә кем белән теләсә ничек чытлыкланып йөрдем, нәрсә теләгәнемне үзем дә белмәдем. Ә төгәлрәге, мин көттем. Искиткеч Принцны көттем. Аны күреп, һәркем акылдан шашарлык булыр, ә ул бары тик мине генә сөяр, дип өмет иттем.

Әмма өченче курста сине инде поездда бушлай йөрү дә кызыктырмый, кайтуларың сирәкләнгәннән-сирәкләнә бара иде. Дусларың сине йә ярышларда, йә команда җыенында, йә бик күп сызым эшле проект белән утыра, дип сөйлиләр иде. Ләкин мин инде сине шәһәрдә нәрсәдер башка нәрсә тоткарлап торганын сизенә килдем. Һәм тиздән, бөтенләй очраклы рәвештә, синең ни өчен кайтмый башлавыңның сәбәбен белдем. Тормышта нәрсәләр генә булмый...

Күп кенә мартуклыларныкы шикелле, Актүбәдә безнең дә ерак туганнарыбыз бар. Шулай бервакыт әтинең туган көненә һәм яңа йортның салынып бетүе хөрмәтенә кунаклар җыйдык. Һәм, күз алдыңа китер әле, шәһәрдән әти-әниләре белән ерак кыз туганым Светлана Костылева да килде. Без, яшьтәшләр, билгеле инде, тегесен-монысын сөйләшергә тотындык, малайларны да онытмадык. Менә ул әйтә: «Беләсеңме, безнең мәктәп кичәләренә бер егет килеп йөри башлады,— ди.— Ул үзе студент, сезнең Мартукныкы икән. Шундый сөйкемле, кара күзле, Рушан исемле. Ул инде танылган кеше икән, бокс буенча чемпион, хәтта ярышларга Мәскәүгә дә барып кайткан... Син аны белмисеңме?» — ди.

Һушсыз-тынсыз калдым, әмма сиздермәскә тырыштым, җилкәләремне сикерткән булдым да: «Мартукта татар егетләре ярты поселок, барысы да сугыш чукмары — чемпионлыкка әзер кандидатлар... Бик кирәк булса, белешә алам...» — дидем. Ә Светлана тагын сөйли: шул Рушан аның сыйныфташы Томочка Давыдычевага үлеп гашыйк икән, шуны күрер өчен мәктәптәге бер кичәне калдырмый йөри икән. «Болай да ул аны көн саен күреп тора, чөнки мәктәп белән техникум янәшә — койма аша гына. Без физкультурага аларның спортзалына йөрибез»,— ди. Менә шунда мин синең нинди ярышларың, нинди проектларың булганлыгын аңладым...

Бәлки, шул мәхәббәтең сине бер зур бәладән коткарып калгандыр да әле. Син үзең аны белмисеңдер дә. Язын, мин тугызынчы сыйныфны түгәрәкләгәндә, Мартукка бер диңгезче офицер кайтып төште. Шул клубка туган-тумачалары белән бераз кызмача килгән бит. Шунда болар Татар бистәсеннән кем беләндер бәйләнешеп китәләр, Шурик Сәйфуллин белән бугай... Сүз уңаеннан,

төрмәдә утырып чыккач, армиядә хезмәт иткәндә бик серле рәвештә үлеп калды ул.

— Шурик Сәйфуллин үлгәнме? — дип әсәрләнеп сорады Рушан. Ул бу хакта ишетмәгән иде әле.

— Әйе, ул юк инде, поминкасында үзем булдым. Бик кыю, тәвәккәл егет иде... Менә шул, сугышып китәләр болар. Офицер үзенең матур кортигын суырып чыгара, шуның белән яна да. Бу вакыйга эзсез калмый, синең дусларың үзләренең беренче срокларын алалар, дөрес, күп түгел — кемгә бер ел, кемгә ике елны чәпиләр. Ләкин ярты елдан, ниндидер амнистиягә эләгеп, бөтенесе дә әйләнеп кайттылар — Толик Чипигин да, Витя Будко да... Әгәр дә ул кичне өйдә булган булсаң, син дә дусларың белән бергә китеп барыр идең. Мавыгып, читкәрәк кереп киттем шикелле, әмма сиңа моны белеп тору комачауламас...

Рушан кулындагы буш рюмканы әйләндергәләп утыра, рюмкада шәм яктысының нечкә нурлары чагыла иде.

— Үзенең туган көне үтеп, бер айданмы, әти шәһәргә машина белән мебель алып кайтырга җыенды, билгеле инде, мин дә барырга теләдем. Башымда күптән бер уй өлгереп җиткән иде: син гашыйк булган ул таныш түгел кызны күрергә тиешмен! Светка Костылева килеп сөйләп киткәннән бирле, ай буена үземә урын таба алмый йөрдем, хәтта ачуымнан бер тапкыр елап та алдым: синең йөрәгеңне яуларга ничек батырчылык иткән ул?! Мин инде шул чакта ук сине үземнеке генә дип хисаплыйм һәм сине ничек теләсәм, шулай боргалап йөртә алам, бер бармак ишарәмнән дә син минем өчен утка-суга керергә әзер, дип ышана идем... Гаҗәпләнмә, бу — һәр хатын-кызга хас һәм киң таралган хаталану. Мөгаен, синең Тамараң да шулай булгандыр...

Бакыр шәмдәлнең уртадагы шәме кинәт кенә төтенли башлады һәм Валентина аны сүндереп куярга мәҗбүр булды. Аның коньяктан һәм истәлекләрдән кайнарланган битен Рушан хәзер күрә алмый иде.

— Мин үземнең бөтен зирәклегемне эшкә җиктем,— дип сүзен дәвам итте Валя.— Син гашыйк булган ул кыз янына икәү барырга Светканы тәки күндердем. Алар, ни әйтсәң дә, сыйныфташлар бит. Билгеле инде, үземнең синең белән кызыксынганымны әйтмәдем, сине белгәнемне генә әйтергә туры килде, юкса Светка ышанмас иде.

Ул Мәскәү бистәсенә борынгы матур вокзал аша барганымны хәтерлим. Юллар аркылы салынган, тирбәлеп, даңгыр-доңгыр килеп торган асылмалы күпердән чык-

тык, аста тиз йөрешле Алма-Ата поезды тора һәм тирә-якка шулкадәр тәмле алма — апорт алмасы исе таралган иде. Минем бу шәһәргә беренче килүем, шуңадырмы, аның ул вакытларда Мартуктан бик аз аерылып торганын абайлап, гаҗәпләнгән идем. Хәтта ул кызларның йорты да — «1905 ел» урамында бугай — нәрсәсе беләндер безнең йортка охшаш иде шикелле. Шул ук янбакча, сиреньнәр, яшелчә бакчасы, шыгырдап торган дүрт басмалы биек болдыр, пыяла тәрәзәле веранда... Бәхеткә, кыз өйдә булып чыкты, әмма безне бик якты йөз белән каршыламады. Бигрәк тә, минем Мартуктан икәнемне белгәч... Ләкин аны-моны сиздермәде, сине дә искә алмады. Хатын-кыз сизгерлеге белән, интуитив рәвештә, минем үзенә көндәш икәнлегемне чамалагандыр, дип уйлыйм.

Миңа ул бер карауда ук ошады, бәрхеттәй коңгырт-кара зур күзләр, искиткеч матур керфекләр, ул аларны шундый сокланырлык итеп, әкрен генә әле түбән төшерә, әле күтәрә, күрәсең, егетләрне һуштан яздырырлык карашының көчен сизенә иде инде. Мин тагын шунысын да аңлап алдым — ул синнән күпкә өлкәнрәк егетләрнең дә күзен кыздырырга тиеш иде. Аңарда яшүсмерләргә хас килешсез-килбәтсез хәрәкәтләр юк, битендә күп кызлар газапланып кичерә торган бетчәләре дә күренми, үзен ышанычлы тота.— Валя көрсенеп куйды.— ...Әйе, шома нәфис бит алмалары, матур сызылып киткән кара кашлары, өске ирененнән бераз югарырак, сул якта сөйкемле миңе... Бу аңа сокланырлык аерым бер мөлаемлык бирә иде. Мин шунда ук ачуымнан ул миңнең зур сөял булып үсүен теләп куйдым. Бик матур уелган авыз, дәртле-сизгер иреннәр, Мерилин Монроныкы шикелле, һәркемне көнләштерерлек тигез ак тешләр... Дөрес, алгы тешләренең берсе әз генә аерылыбрак тора иде шикелле. Анысы инде мин бик тырышып берәр кимчелеген эзләгәнгә күрә генә күренгәндер. Мин синең аңа бер карауда ук татарларга хас кайнар дәрт белән гашыйк булганлыгыңны аңладым, күрүгә үк артыннан ияреп киткәнсеңдер...

Аннары мин шунысын да аңладым: тышкы чибәрлек кенә җитми, аңарда күп кенә хатын-кызларда булмаган сыйфатлар бар, ул да булса — үзенә генә хас үзенчәлекле, бердәнберлеген тою хисе. Аңарда Актүбә кебек кечкенә шәһәрләрдә үскән башка кызларга хас авылча провинциальлекнең исе дә юк. Ул үзенең ирләрне исертерлек сoклангыч гүзәллеген тоя, аның тавышы да һәркемне дулкынландырырлык ягымлы иде. Ул әле мәктәп уку-

чысы гына булса да, тормышка үз карашлары булган хатын-кыз булып өлгереп җиткән, Светлана белән миңа яшьтәш кыз, акылы белән бездән күп өлкәнрәк, сыйныфташларын гына түгел, вакытны да узып, алга китебрәк яши шикелле... Менә ул рояль янына барып утырды, инде бер минуттан безнең барлыгыбызны да онытып, үзе өчен генә уйный башлады.

Әгәр дә башыма көтелмәгән бер уй килеп, җиңеллек китермәгән булса, мин бөтенләй көнләшеп шашыр идем. Кинәт шуны аңлап алдым: син бу гүзәл һәм тәкәббер кызның йөрәген һичкайчан да яулап ала алмаячаксың, чөнки ул да табигате белән миңа тартым, кан-кардәшләрдәй, без бер үк токымнан, ул да үзенең искиткеч Принцын эзли, шуны көтә. Ул бары тик мине генә сөяр, дип өмет итә.

Без дуслашып диярлек аерылыштык...

Дөнья тар, кайвакытларда Куйбышевтан кайтканда мин аны поездда очрата идем — ул Оренбургта укыган чагында. Иске танышлардай, озаклап сөйләшәбез, ләчтит сатабыз. Шунысы сәер, ни ул, ни мин бер мәртәбә дә синең хакта сүз кузгатып карарга тырышмадык. Юкса өчебезне ниндидер уртак бер язмыш бәйләп торганын ул да сизенә иде, дип уйлыйм. Беренче курсларда укыганда, мин аны бер-ике тапкыр чибәр генә, озын-төз буйлы, алтынсу-салам төсендәге сирәк очрый торган чәчле бер егетнең озатканын да күргәләдем. Зәңгәр күзле, кызларныкыдай озын, куе керфекле ул егеткә кысан вагон эчендә дә кызлар ирексездән борылып карыйлар иде. Мөгаен, күпләр әнә шундый Принц турында хыялланганнардыр... Мин алар арасында роман булганлыгын аңладым, әмма үлеп гашыйк булган бу чибәр егетнең дә аның йөрәген яулап ала алмаячагын күңелем белән тойдым. Аннары мин Тамараны бер-ике елга күздән югалтып тордым, шуннан соң гына поездда яңадан очраттым. «Теге, зәңгәр күзле чибәр егетең кайда?» — дип сорагач, ул: «Аны армиягә алдылар, Черновцы шәһәре тирәсендә хезмәт итә»,— дип җавап бирде. Бу сүзләрнең ничек әйтелешеннән мин аның тагын бер егетнең тормышын ватканын аңладым...

— Ул егет Ленечка иде, минем танышым. Чынлап та, чибәр егет... Син дөрес әйтәсең, ул аның тормышын бозды,— дип тонык кына әйтеп куйды Рушан һәм кинәт.— Әйдә, мәхәббәттән уңмаган барлык бәхетсезләр өчен дә эчик әле! — дигән тәкъдим ясады.

Валя риза иде, ләкин кистереп өстәде:

— Димәк, синең белән минем өчен дә...

Алар сүзсез генә эчеп куйдылар.

Утыруларын җеназаны хәтерләтә башлады, чөнки алар үлгән, һәлак булган дуслары — Шурик Сәйфуллин, Володя Колосов, Толик Чипигин рухына да коньяк уртладылар.

Валентина кулына гитарасын алып:

— Ә хәзер мин синең өчен генә уйнап-җырлап бирим әле,— диде.— Мөгаен, Тамара кайчакларда рояльдә этюдлар уйнап та иркәләгәндер әле сине.— Аннары сискәндерерлек итеп, кинәт кенә җырлап җибәрде, әйтерсең фонограмма уйната башлады. Җыры ниндидер бик җилле, кабак җыры шикелле тупас иде. Гитара сабындагы кызыл бант, җилдә җилфердәгәндәй, бер өскә, бер аска сикергәли башлады.

Рушанның әллә кәефе шундый булды, әллә Валентина әйбәт уйнап матур җырлый идеме, әмма аңа ошады шикелле, шуны сизенгәндәй, ханым кызганнан-кыза барды.

Менә ул көтелмәгән рәвештә, башта гитарада озак кына кереш көй уйнап, романслар җырларга тотынды. Гитарада яхшы уйный белүе күренеп тора иде. Бераздан ул, җырлый торган романсын ярты сүздә өзеп:

— Әйдә, бакчага төшик, җырга иркенлек кирәк,— диде.

Яндырылган кызыл кирпеч тезеп ясалган яшелчә бакчасы аша бормалана-бормалана ерымга таба сузылган тар сукмактан төштеләр. Төнге бакча аларны сизелерлек салкынча һава белән каршы алды. Ул шактый зур икән, хәтта ай яктысында да яхшы уйланылган, тәрбияле бакча икәне күренә иде. Бакчаны күрсәтеп бетергәч, Валя Рушанны, кулыннан җитәкләп, караңгы аллея буйлап беседкага таба алып китте. Анда да романсларын дәвам итмәкче иде дә, нишләптер, бер сәбәпсез тавышы бозылды һәм ул гитарасын бер читкә куйды. Рушан янына якынрак елышып, гадәтенчә, кинәт кенә дулкынланган тавыш белән:

— Кич буе аңлый алмыйм, синдә нинди үзгәрешләр бар соң? Шул миңа тынгы бирми...— диде.

Рушан шаяртып котылырга тырышты. «Акыллыландым, өлкәнәйдем», дигәнрәк сүзләр тезде. Әмма Валя һаман да тынмады, нәрсәнедер үҗәтләнеп аңларга, ниндидер үзе өчен бик мөһим бер әйберне аңлатырга тырышты. Һәм, капылт кына Рушанның кулыннан тотып, йөзен аңа якын ук китерде:

— Исемә төшердем... таптым...— Аның тавышы калтырый иде.— Син элек бик матур итеп көлә идең, ихлас-

тан, чын күңелдән... Мин синең ул көлүеңне бик ярата идем. Аны хәтта Татар бистәсеннән, станциядән, Вуккертлар ишегалдыннан да ишетеп ала идем... Син шундый итеп мавыктыргыч көлә идең... Мин сине шул көлүеңнән теләсә кайдан эзләп таба идем, син миннән беркайда да качып котыла алмый идең... Котыла алмавың да көләргә яратуыңнан иде... Ә хәзер, Рушан сөеклем, син ул көлүеңне югалткансың һәм мин сине эзләп таба алмыйм. Нинди коточкыч хәл...— ул, башын Рушанның күкрәгенә салып, үкси-үкси, кычкырып елый башлады.

Бөтен тәнен калтыраткан үксүләре аша: «Син көлүеңне югалткансың... Ничек яшәрсең көлүсез?.. Коточкыч... коточкыч...» — дигән сүзләре генә ишетелеп тора иде. Рушан башта югалыбрак калды, аннары үзен кулга алып, Валяны бик озак тынычландырырга тырышты, әмма ханым сулкылдавыннан тыела алмый, елап шешенгән, яклаучысыз сабый балаларча күңелне йомшатырлык йөзен күтәреп карый да, янә сулкылдарга керешә иде. Рушан аерым бер наз белән аның күзләрен, муенын, чәчләрен үбә, әмма ул һаман тынычлана алмый иде. Көтмәгәндә ул бөтен тәне белән тыелгысыз калтырана-дерелди башлады, ерымда шактый салкынча һәм дымлы иде — бәлки, туңгандыр дип, күп уйлап тормастан, Рушан аны күтәреп алды да, өскә — җәйге йортка алып менеп китте. Анда, караңгы верандада эреп аккан шәмнәрнең төпчекләре дә янып бетеп килә иде.

Валя өстәл әзерләп йөргәндә ярым ачык калган ишектән бер бүлмәгә кереп, кәгазь салфеткалар алып чыккан иде һәм: «Җәйләрен мин шунда яшим»,— дип әйтеп куйган иде. Рушан аны шул бүлмәгә күтәреп керде. Керә-керешкә ут яндырырга теләгән иде, Валя, көйсезләнеп: «Кирәкми... Елап шешенгән йөземне күрүеңне теләмим...» — диде.

Егетнең күзләре караңгыга тиз ияләште һәм ул дивар буендагы җәеп куелган урын-җирне абайлап алды — Валяны шунда илтеп салды. Туфлиләрен дә салдырып алгач, крахмалланган салкынча чиста җәймәле җылы одеялны өстенә ябып, янына утырды. Һаман саен тропик күбәләккә охшаш муар бантка төртелә-төртелә, Валяның чәчләреннән сыйпый-иркәли башлады.

Валя аны кинәт кенә үзенә тартып, кайнар пышылдады:

— Рушан, бәгырем, мин сине бүген беркая да җибәрмим! Син минеке булырсың...— ул, урыныннан күтәрелә төшеп, егетнең иреннәреннән суырып үбеп алды.

Рушан аңарда янә үзе аңлап бетерә алмаган ниндидер истерика башланадыр, ахрысы, дип уйлады. Чөнки

Валя аңа шундый көтелмәгән дәрт-теләк, тыелгысыз наз белән бирелде ки, әйтерсең лә үткән тормышындагы бөтен уңышсызлыклары, күңеле кайтулары өчен барысын берьюлы алырга тели һәм иркәләү-назлауларны алдагы кара көннәренә дә җыеп калырга тырыша кебек иде...

Рушанның моңа кадәр тойган-кичергәннәре, татыганнарының берсе дә бу төндә Валя бүләк иткән рәхәтлек белән тиңләшә алмый иде. Валя, саташкандай итеп, туктаусыз пышылдый: «Рушан, бәгырем, мин шундый бәхетле... Мин сине таптым... Син минеке... Без бергә... бергә... бергә...» Аннары сүзләрнең күпчелеге сизелмичә йотыла һәм ул, Рушанны үбә-үбә, бер генә сүзне кабатлый: «Минеке... минеке... минеке...» Рушан да аңа шундый ук иркәләү-назлау белән җавап бирә, аның дәртен сүндерүдән куркып, кысып кочаклый иде. Әмма кинәт кенә ул Валяның гүя ниндидер акыл томаланырлык дәрәҗәдәге трансга булуын шәйләде, ханым янә үз уйхисләренә бирелгән, аның үзен дә, теләкләрен дә тоймый шикелле иде...

Йа Хода, тормыш нинди мәрхәмәтсез! Әгәр дә элегрәк, яшьлегендә Валентина аңа шушы татлы сүзләренең, кайнар куеннарының, сөйкемле карашларының бер мыскалын гына бирсә дә — Рушан нинди бәхетле булыр иде, ул аны фәрештәсе-алиһәсе итеп кулларында гына йөртер иде бит! Шул рәнҗештән, шул бәхетнең үзен читләп үтүен тоюдан, инде бернәрсәне дә кайтарып алып булмаслыгын аңлаудан күңеле тулып, күз яшьләрен яшереп тә тормыйча, Рушан елап җибәрде. Әмма үз теләге-дәрте белән мавыккан Валя аның елаганын сизмәде дә...

Рушан китеп барганда, Валентина абайламый калган, әмма егет күңеленә озакка уелып калган тагын бер нәни генә хәл булып алды.

Җәйге кухня белән төп йорт арасында, калиткага бара торган сукмак өстендә кечке яңгырдан калган кечкенә күлдәвек җыелган, кергәндә алар аны әйләнеп үткәннәр иде, ә хәзер, саубуллашканда, ирексездән шуның янында тукталдылар. Валяның Рушанны иртәнгә кадәр җибәрәсе килми иде һәм ул, адым саен кочаклап, ниндидер дулкынландыргыч сүзләр бытылдый иде. Биектән тулы ай яктырта, бер-берсенә иркәләнеп-назланып сыланган икәү әлеге күлдәвектә көзгедәгедәй чагылып күренә. Рушан шуны күрсәтмәкче генә булган иде, Валя кинәт кенә шул суга китереп басты да, су-көзге чәлпәрәмә килеп ватылды, сурәт юкка чыкты. Рушан моны начарга юрады...

Капка төбендә соңгы кат үбешкәч, Валя ничектер ятимсенеп, кызгандырып сорады:

— Бүген кич килерсеңме? — Элек Рушан, очрашу сорап, аңа шулай ялвара иде.

Рушан аның үбешү-кочышу араларында бер якка кыйшайган муар бантын төзәтеп куйды, иркәләүчән шат тавыш белән:

— Әлбәттә,— диде.— Мин бу очрашуыбыздан бик бәхетле.

Бу минутта ул хәйлә-мәкерсез иде, бу таныш та, таныш та түгел ак күлмәкле ханымга карата күңелендә, мәктәп елларындагы кебек, ниндидер ихлас, ягымлы хис барын тойды ул...

## XIII

Валя белән булган кичәге төн һәм бүген буласы очрашу турындагы уйлар иртәдән кичкә кадәр Рушанның башыннан чыкмады. Җәйге озын көн дәвамында ниләр генә уйлап бетермәде ул. Үзенең бөтен үткән тормышын төбенә хәтле актарып чыкты. Кайсыдыр мизгелләрдә ул вакытны ашыктыра, тизрәк кич җитсен иде, дип тели, Валяның кайнар сүзләрен яңадан ишетергә алгысый, аның иркә кулларының үз тәненә кагылганын тоя, дәртле пышылдавын ишетә: «Минеке... минеке... минеке...»

Әле балалар гына килеш бер-берсенә тартылган бу ике җанны, бәлки, язмыш шулай яңадан бергә кушкандыр, өмет өзелү, югалтуларның ачысын төбенә кадәр эчеп, хәзер икесе дә бәхет һәм рәхәтлек тапсын, дигәндер.

Күңеле йомшарып тәэсирләнгән Рушанның Валяга берәр куаныч ясыйсы килде, поселок универмагына барып, бер флакон француз хушбуе сатып алды. Алганда «Клима», «Фиджи» һәм «Кара магия» дигән хушбуйларның кайсысын алырга белмичә, озак сайланды, сатучы кыз аңа «Шанель № 5»не тәкъдим итте.

Фантастика! Зур шәһәрдә аны көндез чыра яндырып эзләсәң дә таба алмыйсың, ә биредә — кемгә кирәк ул? Әле хәзер дә, бүләкләр турында уйлый башласа, кулында беренче һәм соңгы мәртәбә тоткан шул «Шанель № 5»нең тыйнак кына ак тартмасы күз алдына килә.

Гастроном кибетенә дә сугылды ул, «Ахтамар» дигән затлы әрмән коньягы сорагач, аны күреп белмәгән яшь кенә сатучы кыз, елмаеп, Мартукта мондый кыйммәтле коньякны бик сирәкләр генә алганын, алай да бүген Рушаннан алда гына инглиз теле укытучысының нәкъ шундыйны алып киткәнен әйтеп куйды. Моны Рушан яхшыга юрады һәм кичәге яңгырдан калган күлдәвек көзгесендә ватылган сурәт турында онытты.

Билгеләнгән сәгатьтә, бүләкләрен күтәреп, ул Совет урамына ашыкты. Валя аны янә янбакчаларында гитара чиртеп көтеп утыра иде. Ләкин бүген ул җете кызыл күлмәк кигән, башындагы кичәге ялтыравык кара муар бантын да кызылга алыштырган.

Рушан бүләкләрен биргәч, ул бик куанды, аның муенына ташланып, туктаусыз үбәргә тотынды. Ул бүген ничектер сәер әсәрләнгән иде. Рушан, ике арадагы мөнәсәбәтләрдә, бәлки, нindидер үзгәреш буласын сизенеп, шул дулкынланудан Валя ул килгәнче эчеп куйган, ахры, дип тә уйлады. Ә нигә? Әгәр дә аңа — ир кешегә шундый бәхетле үзгәреш турындагы уй башына килә икән, хатын-кызга, мөгаен, киләдер дә киләдер, Рушанның үзеннән нинди канатланып-очынып кайтып киткәнен күреп калды бит ул.

Аның алдан эчеп куюы турында шаяртмакчы булып, Рушан үзе аңа иелде дә иреннәреннән үпте, әмма шәрабфәлән исе сизмәде, гаҗәпләнә калды. Ләкин соңыннан ул аның артык әсәрләнүен, күзләренең сәер елтыравын дулкынланудандыр, дип уйлады.

Алар шулай кочышкан килеш, инде кибеп өлгергән күлдәвек яныннан узып, җәйге йортка барып керделәр. Анда инде өстәл әзерләнгән иде, алар кара-каршы кәнәфигә утыруга, өч яңа шәм дә шунда ук кабынды.

Кичәге сөешү-яратышудан соң алар беркавым үзләрен уңайсызрак тойдылар, Валя ничектер борчулы күренә — ни өчен икәнен аңлата алмаса да, Рушан моны сизенә иде. Ханым кичәге кебек үк ягымлы да, шундый ук рәхәт дулкынландыргыч сүзләр дә сөйли, әмма Рушанда ниндидер сәер тойгы — алар икәүләп һаман да каядыр упкынга очалар, ычкыналар шикелле. Бу авыр уй-хисләрдән үзен дә, аны да арындырырга теләп, Рушан Валяның җырлавын үтенде.

Валя, аның «җыр тынычландырыр» дигән уен белгән шикелле, гитарасын теләп кулына алды, ләкин аның борчылулы киеренке халәте җырларында да чагылды — ул ни өчендер тоткыннарның төрмәдә генә җырлый торган җырларыннан башлады.

Рушан шунда ук Рәшит абыйсының Актүбәдәге йортын исенә төшерде, ул анда берәр бәйрәмдә яисә Исмәгыйль бәк белән Шамилнең туган көннәрендә барып чыккалый иде. Аларның туган көннәре, бернәрсәгә дә карамастан, хәтта туган көне булган кеше үзе төрмәдә утырса да, изге бер көн итеп билгеләп үтелә — йорттагы бу йоланы Миңсылу апа бик нык саклый иде...

Верандада үтәли җил йөри, шәмдәлдәге эреп агып утырган өч шәмнең дә зәгыйфь ялкыннары Валя ягына авыша, шунлыктан Рушан аның гитара өстенә иелгән йөзен яхшы күрә иде. Кайбер мизгелләрдә Рушан аны Карменга охшата, юк, Мериме иҗат иткән гүзәл, ут борчасыдай испан кызына түгел, ә Рәшит абыйсының хатынына, аңа да бертуган егетләрнең дуслары шундый кушамат такканнар иде бит. Ул Карменның да кызыл күлмәге бар, яраткан гитарасының сабын шушындый ук зәвыксыз бант бизи, уйнау рәвеше дә шушындыйрак була иде. Кармен бары тик башында мондый «күбәләк» кенә йөртми, Рушан анысын яхшы хәтерли, ә җырлары исә нәкъ шушы җырлар иде — әйтерсең лә Валя Гомәровлар өенә барып өйрәнеп йөргән, диярсең!

Мондый юньсез җырларны Рушан бервакытта да яратмады — яшьлегендә дә, хәзер инде бигрәк тә — шуңа күрә, Валя, туктап, кылларын тарттырып маташкан арада, гитараны аның кулыннан алды да:

— Әйдә әле, эчик, кичәгедәй сөйләшеп утырыйк...— диде.

Ләкин ханым аның эчке кичерешләрен сизенеп алды һәм каһкаһә белән җавап бирде:

— Син, Дасаев, сноб икәнсең. Борының бик югары икән...— диде.— Мин менә шундый инде — төрмә җырларын яратам, алар хәзер бик тә популяр. Мартукта инде минем җырлавымнан үлеп китәләр...— Аннары кинәт кенә мыскыллап әйтеп куйды: — Ах, онытып җибәргәнмен, синең бит утырып чыкканың юк, тормышны да юньләп белмисеңдер...

Рушан бу сүзләргә артык игътибар итмәде — Валяның холкын белгәнгә күрә: «Үз сүзен сүз итәргә уйлый»,— дип кенә фараз кылды.

Гитарасын ишек янындагы кадакка элеп куеп, Валя өстәл янына борылып килде һәм Рушан каршысында көтелмәгән нәзакәтле пируэт ясап, шукланып аның чәчләрен чуалтып ташлады:

— Типтер, Рушан сөеклем! Ярат, рәхәтлән, әлегә мин синеке...

Рушан, ул яңадан аңлаешсыз кыланчыклана башлады, дип уйлап, аңа эчемлекне гадәттәгедән азрак салды. Әмма ялгышты: Валяның борчылуы эреп юкка чыкты, ул кичәге шикелле үк ягымлы, назлы-сөйкемле булып калды. Рушан да тынычланды.

Алар янә кара-каршы утырдылар, төтенләп янган шәм ялкыннары аларның өстәл аша бер-берсенә ташланган яратулы карашларын тагын да кайнарландыра кебек —

алар үзләрен кайчандыр нык бәйләп торган, әмма күптән онытылган хатирәләрне исләренә төшерәләр иде бугай. Ханым бүген дә тарта — яшел каплы «Салем» сигареты белән зажигалкасы каршысында ята — әмма сирәгрәк тарта иде.

Бу кичтә Валя Рушанны тагын гаҗәпкә калдырды. Бөтенләй тынычланып беткәч, ул салкын су алып килергә сорады, Рушан ишегалдындагы колонкадан кувшин тутырып су алып кергәндә, ул яңадан тартып утыра, әмма авызында ментоллы «Салем» түгел иде. Анысының исенә Рушан күнеккән иде инде, үзе тартмый торган кеше буларак, ул бу яңа исне дә бик тиз сизеп алды. Валяның кулында хәзер сирәк очрый торган папирос күреп, исе китте: «Нишләп әле тупас «Беломор»га күчтең?» — дип сорамакчы булды, әмма тыелып калды: Валяның сәер көйсезләнүләрен белгәнлектән, яңадан кәефен җибәрүдән курыкты.

Валя ничектер күнегелмәгәнчә тарта, матур башын артка ташлап, кәнәфинең биек аркасына терәгән, ниндидер эчке бер ләззәтләнүдән күзләрен йомган, ә Рушан исә, кичәге шикелле, янә аның өч рәт итеп тезелгән ясалма энҗе муенсалы нәфис муенын, хатын-кызларга гына хас ымсындыргыч түгәрәк ачык иңнәрен сокланып күзәтә. Валяның күлмәк корсеты белән кысып, күтәртеп куелган ярым ачык калку күкрәге папиросын суырган саен күңелне дулкынландырып күтәрелә, Рушанга аның шулай тартып утыруына карау да рәхәтлек бирә иде. Ханым озын, матур бармаклары белән папирос көлен көллеккә, карап-нитеп тормыйча, илтифатсыз гына кагып төшереп, бик килешле итеп тарта иде...

Тартып бетергәч, Валентина күзләрен, гадәтенчә, ялкау гына ачып җибәрде, егетнең үзен сокланып күзәткәнен сизенгән шикелле, күкрәктән чыккан дулкынландыргыч тавыш белән пышылдап кына үтенде:

— Рушан бәгырем, син мине кичә шундый күңелләрне эретерлек итеп күтәреп йөргән идең, бәлки, бүген дә шул рәхәтлекне кабатларсың, ә?

Ул әйтерсең егетнең уйларын укыды — Рушан нәкъ менә Валяның папиросны ташлавын гына көтеп тора иде. Ул аны күтәреп алды да веранда түрендәге бүлмә ишегенә таба атлады, ләкин ханым, аның муеныннан каты итеп кочаклап алган килеш, колагына пышылдады:

— Йә инде, ишегалдыннан бер генә булса да әйлән, миңа шулкадәр рәхәт, ышанычлы...

Ишегалдында аны күтәреп йөргән бәхетле мизгелләрнең бер мәлендә берме-икеме тапкыр Рушан аңа үзенең

гашыйк икәнлеген һәм мәңге тугрылыклы булачагын чүт кенә әйтми калды, ләкин һәрчак ханымның берәр шуклыгы яки үбеп алуы бу уйларын читкә тибәрә торды. Моңа аның һич тә кәефе китмәде — алда татлы төн көтә иде.

Аннары алар җәйге йорттагы бүлмәгә кайтып керделәр. Бүген анда бер почмакта тонык кына сүрән утлы торшер янып тора иде, Рушан шул яктыда хатын-кызларча пөхтә-уңайлы бүлмәне күздән кичерергә өлгерде, алсу обойлар бүлмәгә аерым бер күркәмлек биреп тора иде. Егетнең почмактагы торшерга аптырабрак карап торганын күргәч, Валя аның йөзенә ягымлы карап:

— Минем синең белән рәхәтләнеп ләззәтләнәсем генә килми, сине күрәсем дә килә,— диде. Аннары иркәләнеп өстәп тә куйды: — Каршы түгелсеңдер бит?

Ул, билгеле, каршы түгел, аның да Валяның гүзәл йөзен күреп торасы килә иде.

Әмма бүген, Валентина аңа кичәге кебек үк дәрт-теләк белән бирелсә дә, нәрсәдер шулай да, шулай түгел дә төсле иде. Баштарак Рушан, ут яктысы комачаулыйдыр, дип уйлады, әмма, аны-моны әйтеп тормастан, Валя утны үзе сүндерде.

Ханым үз дәртендә ничек кенә ашкынып кабаланмасын, ничек кенә ярсынып-комсызланып назламасын-иркәләмәсен, Рушан шул ук вакытта аның бик тиз хәлсезләнә баруын, битараф төшенкелеген тоеп алды — гашыйк кешедән үз хәләтеңне яшерү мөмкин түгел, ә бу очрашуга Рушан гашыйк буларак килгән иде бит. Бүлмәдә ут янып торганда, ул берничә мәртәбә аның үз өстенә бик якын иелгән күзләрен күрде — ул күзләр бүген бөтенләй башка, алар каядыр читкә карыйлар кебек, үзләрендә куркытырлык бушлык чагыла иде. Инде үзякын, ягымлы-сөйкемле ханым кинәт кенә аңа ниндидер аңлашылмас ягы белән ачыла бара иде. Һәм Рушан яңадан, инде урын өстендә яткан көйгә, аның очрашкач та башланган борчылу-тынычсызлануын, нәрсәгәдер хафалануын сизде.

Валя кинәт кенә изрәп-мәлҗерәп төште, егетне үзеннән тибәреп, көйсезләнеп боерды:

— Рушан, өстәлне бире керт тә икенче шешә «Ахтамар»ны ач әле! — диде.— Сине шат күңелле итеп күрәсем килә, җитди кыяфәтең уңайсызлый мине...

Егет каршы килмәкче булды, ләкин Валяның күз карашына төртелгәч, уң кулын шәрыкчә итеп күкрәге өстенә куйды һәм, башын буйсынучан иеп, шаяртып җавап бирде:

— Баш өсте, сез боерганча булыр, мин сезнең колыгыз...— диде.

Үзе бу гамәлләрнең ниндидер чишелешкә тәгәрәгәнен, әмма, үзенә кагылышлы булса да, моңа берничек тә тәэсир итә алмаячагын аңлады, ул янә үз язмышына үзе хуҗа түгел иде инде.

Валя көтмәгәндә аның белән брудершафтка эчәсе итте һәм коньякны су сала торган зур бокалларга койды — мөлдерәмә тутырмаса да, ярты шешәне бушаткан иде. Рушан, монысын эчкәч вакыйга ниндидер гаугалы-җәнҗаллы төс алыр инде, дип уйлаган иде, әмма тагын акылга сыймас хәл килеп чыкты — буш бокалларны читкә этәреп куйгач, Валентина, комсызланып, аның иреннәренә сөлектәй ябышты, Рушан янә аның кичәге кебек дәртле-ялкынлы сүзләрен ишетте: «Минеке... минеке... минеке...»

Аның кайнар кочагында тыннары кысылган Рушан, елмаеп, үзенең хатын-кызларны, мөгаен, беркайчан да аңлый алмаячагын уйлап куйды. Валяның нәфис тәнен үбә-үбә, иркәли-назлый, ул янә күкнең җиденче катында иде.

Ниһаять, ул, бәхете һәм куанычы тулышып, тынып калды, күңелендә көтмәгәндә яңадан кузгалган мәхәббәт хисләрен инде әйтергә дип кенә җыенганда, Валя кинәт аның өстенә иелде, әллә шаяртып, әллә чынлап сорады:

— Дасаев, синең кайчан да булса хатын-кызларны шампан шәрабында коендырганың бармы, аларга миллионлаган алсу розалар яки саф энҗе һәм бриллиантлар бүләк иткәнең булдымы?

Егет җавап бирүдән шаяртып котылмакчы иде, ләкин ханым үпкәләп, үҗәтләнеп кабатлады:

— Мин бит синнән чынлап сорыйм,— диде.

Вакыйганың мондый юнәлеш алуыннан айнып китеп, Рушан:

— Бу бит блатнойлар иҗаты...— диде.— Хатын-кызга нигә шампанда коену кирәк? Мин аны хәтта зарарлы дип уйлыйм, иң яхшысы — сабын...

Валентина шартлап китте, дары мичкәсе, диярсең:

— Их син, сабын... Зарарлы түгел. Мин коендым, бер генә дә түгел әле...

Рушан, аның кычкырып җибәрүен ахырынача аңлап бетермичә, һәм, билгеле инде, сүзләрен җитдигә алмыйча:

— Ә юынгач-коенгач, ул шампан шәрабын нишләтәләр инде? — дип ычкындырып ташлады.

Валентинаның шуннан соңгы җавабы бу ярым тиле сөйләшүнең җитдилегенә ышанырга мәҗбүр итте:

— Әйе, мин шампанда коендым, ә дусларым һәм миңа шул күңел ачуны оештырган кешем шәрабны ваннадан бокаллары белән чумырып алып эчтеләр һәм миңа саулык-сәламәтлек теләделәр — шундый йола, матурлыкка һәм гүзәллеккә, хатын-кыз тәненә шулай соклана беләләр алар. Ул искиткеч! Ләкин, күреп торам, син моны гомер аңлый алмаячаксың, синә бирелмәгән ул! Гомереңбуе получкадан получкага яшәгәнсең инде... Шулай яшәрсең дә...

— Син чынлап сөйлисеңме? Кем була инде ул хатын-кыз матурлыгын шулай нечкә бәяләүче һәм ваннадан шампан чөмерүче кеше? — дип сорады Рушан, җавап алырга өметләнмичә генә. Чөнки һаман да әле монысы да Валяның чираттагы шаяртуы-уены гынадыр дип уйлый, егетләрдән аның соңгы еллардагы әкәмәт сәер кыланмышлары турында ишеткәне бар иде.

Ләкин Валентина ачу китерерлек горурлык белән җавап бирде:

— Дато Гвасалия. Мине чын-чынлап яраткан-иркәләгән кешем. Аның кушаматы юкка гына Лорд түгел иде: чәчәкләрне ул кәрзине-кәрзине белән, хушбуйларны дюжиналап бүләк итә иде, менә бу саф энҗе муенса да аның бүләге...

Ә Рушан аның муенындагы ул энҗе муенсаны ясалмадыр яки әле чех пыяласыдыр дип кенә уйлаган иде... Ләкин боларның берсенең дә әһәмияте юк иде инде. Рушан бөтенләй айныды. Үзенә чит һәм җирәнгеч бу ханымны җиңелчә генә читкәрәк тибәрде, аның сыгылмалы ымсындыргыч тәненә карата бернинди кызыксыну хисе калмады, ул урындык аркасына эленгән күлмәгенә үрелде.

— Син кая? — дип гаҗәпләнеп сорады Валя.

Рушан җавап биреп тормады. Киенә-киенә уйлады — әйтергәме, әйтмәскәме? Әмма соңгы мизгелдә әйтергә булды:

— Беләсеңме, Валя, мин бүген сиңа тәкъдим ясамакчы идем...

Төнге салкынча һава аны суындырды, барыбер йоклап булмасын чамалап, ул өенә кайтырга ашыкмады, төнге Мартук урамнарын гизеп, уй-хисләрен тәртипкә китерергә булды — тагын бер көннән ул китеп барырга тиеш иде. Паркка барып җиткәч, моннан сигез ел элек Валяны шушында буялган сап-сары чәчле итеп күргәнен хәтерләде һәм капылт көлеп җибәрде, бу көтелмәгән көлү аның кәефен күтәрде. Ул кинәт кенә кысан ванна бүлмәсен, төссез-ямьсез сантехниканы, заводтан ук шад-

раланып чыккан кафель плиткаларны, ванна тирәсендә бокал тоткан карактыр-фәләндер әтрәк-әләмнәрне һәм шәраб эчендә, мәгънәсез көлеп, чупырдап яткан Валентинаны күз алдына китерде... Тамаша, чынлап та, көлке һәм хәтта кызганыч күренеш булгандыр, әгәр дә санузел дигәне ванна бүлмәсендә булса, бигрәк тә... Йа Хода!..

Һәм бөтенесе дә анык-ачык булып үз урыннарына утырды: Валяның өф-төф итеп тәрбияләп тоткан бармак араларына кыстырылган тупас папирос та, әллә кая читкә карап, пыялаланып калган күзләре дә, шунда ук битараф ваемсызлыкка әверелүчән дәрт-теләге дә, сәер төрмә җырлары да, энҗе муенсасы да һәм хәтта шампан шәраблы ваннасы да...

Сигез ел элек үк, ул әле «1905 ел» урамында яшәүче кыз белән мавыгып йөргән заманнарда ук, Куйбышев шәһәрендә очучылар училищесында укучы бер егетнең әйткән сүзләрен Рушан колагына да элмәгән иде. Ул егет Валяның мыштым гына наркотиклар тартуын, энә кадаулардан да тайчанмавын, шәһәрдәге юньсез егетләр белән чуалуын һәм хәтта ниндидер бер җинаять эше буенча шаһитлык кылып йөрүен дә сөйләгән иде. Ул чагында башында башка уй-исәбе булган Рушан ул имешмимешләргә игътибар итеп тормаган иде, ә менә хәзер һәммәсе дә бер логик чылбырга тезелде...

Инде бүген, егерме еллап вакыт үтеп киткәч, Мартукта Валя Домаровага өйләнергә аздан гына тәкъдим ясамый калган ул гаҗәеп кичне хәтереннән үткәреп утырганда, Рушан аңлый: ул заманнарда, башка бик күп нәрсәләр турында кычкырып сөйләнмәгән төсле, наркомания турында да ачыктан-ачык сөйләү юк иде, әйтерсең ул безгә кагылмый. Әмма аны теге чакта да, хәзер дә таң калдырганы — юк, наркомания үзе түгел, ул ямьсез күренеш белән мавыккан, авыруга сабышкан егетләрне Рушан күп очратты,— ә шул кармакка капкан, үзе күргән бердәнбер ханымның кайчандыр үзе яратып йөргән, кайчандыр мәктәп иншасында балерина булырга хыяллануын язган кыз булуы таң калдырды...

Бүген ул белә инде, үзе аңа «Шанель» бүләк иткән теге җәйге төннән соң, ике ел үткәч, Валя яңадан Мартукка әйләнеп кайткан. Кайдадыр механик булып эшләүче, әмма күбрәк хастаханәләрдә һәм даруханәләрдә наркотиклар даулап гауга чыгаручы наркоман ире белән кайткан. Мәгәр аның үзенең дә ул вакытта инде «энәдә утырганын» күпләр белеп торгандыр. Андый начар гадәтләр белән, өстәвенә, җәмгыятьтә үзенә ниндидер аерым өстен урын дәгъвалап, кечкенә поселокта яшәве

кыен шул. Озакламый алар бер җәйге төндә Рушан чын-чынлап бәхетле булган Совет урамындагы йорттан китеп барганнар һәм шуннан соң Валентина турында Рушан бүтән беркайчан да ишетмәде. Язмышы ничек булып беткәндер ул бәхетсез ханымның?..

Хәер, бервакыт, берничә ел үткәч, Мартуктан меңнәрчә чакрым җирдә Рушанга энҗе муенсаны да, шампан шәраблы ваннаны да исенә төшерергә туры килгән иде.

## XIV

Валя белән очрашу, шәхсән, Рушанның үзенә түгел, ә Рәшит абыйсына бәйле, әмма барыбер аның да тормышына кагылышлы тагын бер ачыш ясарга ярдәм иткән иде. Һәрхәлдә, йөз кырык ике килограмм ук түгел, ә нибары йөз егерме алты килограмм гына булган Эмма Бобликовадан ишетеп белде: Рәшит абыйсының кайчандыр егерме биш яшен билгеләп үткәргән атаклы туган көне Эмманың әнисе йортында булган икән — шулай итеп, балачактагы тагын бер сер ачылды.

Ә ул кичтә Валя әле аңа, ачусыз-нисез генә, Славик Афанасьевның һичкайчан да шәһәр кешесе булып китә алмаячагын сөйләгән иде, көзгегә баккан, диярсең — хак әйткән икән. Бер-ике елдан Славик Алма-Атадан әйләнеп кайткан, баеп киткән якташларына алтын тешләр куеп, зур акчалар суга башлаган. Безнең Рәсәй халкы шешә биреп рәхмәт әйтүдән башканы белми бит, шулай туктаусыз эчә торгач, тәки айный алмыйча, үлеп киткән Славик. Очрашканда кайгырып искә алынучыларның исемлеге шактый зурайды, аларны хәзер, сайлаулардагы кебек, гомуми бер исемлек белән генә искә алып куя башладылар.

Бүген Рушан үз югалтуларының барысын да диярлек белә инде, әмма элек бервакытта да егерме сигез яшьләренә, ә бәлки, аннан да иртәрәктер әле, үзенең ихлас күлә белүен югалтуы турында сизми дә, уйламый да иде. Хәзер ул Валяның теге кичтә ни өчен елаганын аңлый инде: Валя аның һәм үзенең әле ахырына барып җителмәгән тормышын алдан ук кызганып елаган. И бу хатын-кыз сизгерлеге...

Күптән түгел генә Рушан, газетлардан укып, шаккатыргыч саннар белде. Ә бит аның танышларыннан берсе дә — ни эштә, ни өйдә булсын — моңа игътибар да итмәгән, ул хәтта бер-ике көн автобус-троллейбусларда да колак салып, тыңланып йөрде, бәлки, кемдер: «Нинди коточкыч!» — дип әйтер төсле иде. Ләм-мим, ник берсе

бер бу хакта үз фикерен әйтсен, әсәрләнеп сөйләнсен — күрәсең, битарафлыкка күнеккәннәр инде. Бәлки, газетфәлән дә укымыйлардыр? Ә газеттан Рушан менә нәрсәләр укыды: илдәге җинаятьләрнең алтыдан берсен хатын-кызлар ясый икән, бер ел эчендә ике мең биш йөз хатын-кыз яңа туган баласын үтергән өчен суд җаваплылыгына тартылган. Бу санны әле, милиция күзенә чалынмый калганнарын да кертеп исәпләсәң, мөгаен, тагын унга тапкырларга кирәктер, бары тик шунда гына чын дөресе килеп чыгар. Димәк, җәмгыятьнең күпмиллионлы җинаятьчел катламыннан үз тормышында бары берсенә — Валяга гына тап булып, Рушан җиңел котылган.

Юк, Валя Домарованы, аңа чак кына өйләнешергә тәкъдим ясамый калса да, Рушан һич кенә дә үзенең беренче мәхәббәте дип атый алмый, әмма ике арада булган мөнәсәбәтләрне, теге җәйге ике бәхетле кичне дә тормышыннан сызып ташлый алмый: булганы булган инде.

Күрәсең, ул хәлләрне мәхәббәткә кереш — прелюдия дип санарга гына каладыр...

Үткәннәрен барлаганда, Рушан үзенең ихлас көлүен югалтуы, туганнары-дуслары үлеме, Актүбәнең борынгы вокзалы һәлакәте һәм Ташкентта бер-бер артлы юкка чыга баручы чәйханәләрне генә түгел, тагын байтак нәрсәләрне искә төшерде әле. Үткән гомердә бик күп җисми серләр дә ятып калган икән. Ул, мәсәлән, язгы төн уртасында соңлап кына Орджоникидзе урамыннан кайтып барган чагында, бер мизгелдә күзләрен сукырайтып, каршысына килеп чыккан машинадан бер кыз кул изәп — Светланка Резникова иде ул кыз,— шул кул изәүнең нинәрсәгә ишарә икәнен еллар үткәч тә һаман да аңларга тырыша әле. Резниковалар «Волга»сы Тимерьюлчылар сарае чатыннан борылып, каршыдагы тыкрыкка кереп югалганчы, үзенә генә изәп барган шул кулны күреп торган иде ул. Нәрсә аңлата иде икән ул кул изәү? Яңа ел кичәсендә дәррәү кабынып киткән хисләре мартта ук өзелгән иде бит юкса...

Яки ни өчен Ниночка Новова аннан бик үтенеп, «Рапсодия» дигән Америка фильмын каравын сорады икән һәм ни өчен ул, аңа әйтми-нитми генә, чыгарылыш кичәсеннән соң ук Ленинградка китеп барды икән? Юкса ул китәр алдыннан алар икәүләп Ниночкаларның Кызыл урамындагы алма бакчаларында таңга чаклы йөргәннәр һәм таң аттырганнар иде бит... Сәер, нишләп хәтер шундый вак-төякләрне дә саклый икән?

Әмма хәтердә әле үз вакытында җавап таба алмаган, һаман да күңелне бимазалап торучы сораулар тулы нин-

дидер анык вакыйгалар гына сөзелеп калмаган, бөтенләй аңлатып булмаслык нәрсәләр дә гомер буе табышмак булып ияреп килә...

Бервакыт Рушан үзләре Бродвей дип йөрткән урамда Жорик Стаин белән бергә,— Жорик турында аерым сүз булыр әле,— искиткеч гүзәл бер кызны күргән иде, әмма хәтергә уелып калганы шул: Сашенька Садчикова үзе түгел, ә аның тегелеше белән дә, төсе белән дә гадәти булмаган күлмәге булды. Сөйкемле Садчикованың шул күлмәге төсе Рушанны ни өчендер гомере буе эзәрлекләп килде, югыйсә ул аның нинди төстә икәнлеген дә ачык кына әйтеп бирә алмый иде. Һәм менә хәзер, утыз еллап вакыт үткәч, көтмәгәндә генә, үз иленнән сөрелгән Тибет далай-ламасын әле кайчан гына үзе дә диссидент булган, ә хәзер шул илнең президенты Вацлав Гавел кабул иткәнне телевизордан күрде дә исе китте. Теге табышмакка җавап табылды бит: аксыл-сары чәчле Сашеньканың күлмәге төсе бер дә әфлисун төсе түгел, ә будда далай-ламасының кызгылт-сары хитоны төсендә булган икән.

Яки, бер карасаң, Рушанны атаклы Ницца белән нәрсә бәйләп торырга мөмкин? Әйе-әйе, зәңгәр диңгез буендагы гүзәл шәһәрчек белән. Хәер, бу диңгез буендагы курортның үзе белән дә түгел әле, ә бары тик колакларны иркәләп торучы исеме белән.

Ницца...

Ул да, Рушанны еш кына бер сәбәпсез сагышка салып, бик озак аның хыялында йөрде. Мөгаен, Ницца аның хәтеренә теге, май ахырындагы бөтенләй дә язга охшамаган төксе бер көндә уелып калгандыр, алар ул көнне Ниночка Новова белән Тимерьюлчылар сараендагы ниндидер бер концертка очраклы гына барып эләккәннәр иде: концерт программасы әллә ни ис китәрлек түгел, артистлары да вак-төяк шәһәр-авылларда гастрольләр өчен генә җыелган, кайчандыр өметле генә булып, соңыннан эчкечелеккә бирелгән, тормыштан күңелләре кайткан, бар яшәү чыганагы шул үзләре сөймәгән авыл сәхнәләре булган әтрәк-әләмнәр иде.

Еракта калган ул май аенда Ниночка мәктәп, ә Рушан техникум тәмамлап киләләр һәм, тиздән аерылачакларын сизенеп, көн дә очрашалар иде. Киләчәктә тормыш юллары гомерлеккә аерылачагын тойгангамы, ул очрашулар ничектер комсыз, шашкын, ярсулы булды, юкса телдән, әлбәттә, галәмәт зур планнар коралар, күз алларына китергән хыяллары өсте-өстенә өелә тора иде...

Концертка алар соңладылар, борынгы сарайның яңгырап торган ярым буш залына килеп кергәндә, сүрән генә барган концерт бераз җанлана төшкән һәм кайсыдыр бер җырчы сыек кына кул чабулар ишетү бәхетенә дә ирешкән иде. Алар кереп урыннарына утыруга, сәхнәдә бер хатын-кыз күренде, аның җыры Рушанның күңелендә бик озакка, дистә елларга сакланып, һәрвакыт шул еракта гы Ницца турындагы тормышка ашмас хыялларын кузгата торган булып калды.

Юаная башлаган, озын гына буйлы җырчы хатын үкчәләренә үк төшеп торган чия төсендәге озын бәрхет күлмәктән, авыл җирләре өчен артык кыю ачып куелган декольтесы зифа муенын, хатын-кызларга хас мәрмәр ак җилкәләрен, каты корсет белән күтәреп куелган тулы күкрәкләрен күзгә бәрелерлек матур итеп күрсәтә. Ул кулына шушы дала якларында үсә торган фарсы сиренесенең коела башлаган чәчәген тоткан иде, үзе үк җырның исемен әйтте: «Ниццадан килгән чәчәк».

Бу җырчы Рушанга шактый карт, талчыккан йөзле булып күренде, бәлки әле кырыкны да тутырмаган булгандыр, әмма үзенең унҗиде яшьлек каланчасыннан Рушан шулай күрде, ирексездән аның эченә җыелган сагышын тойды, ни өчен шушы шәһәрчекнең ярым буш залына килеп чыкканын аңлады. Җыр, күрәсең, җырчының күңеленә якын, ул үзе дә, мөгаен, Ниццаның буй җитмәс, тормышка ашмас хыял икәнен күптән аңлаган иде. Җырдан да, җырчыдан да бөтен дөньяларны биләп алырлык тирән сагыш саркый, бәлки, бу бинаның диварларына әллә кайчан эленеп калган сагыштыр ул, инде менә шул сагыш Рушанның да күңеленә иңеп калды. Бәлки, башкалар аны бераз гына сагышлы гади җыр итеп тыңлаганнардыр, әмма егет өчен ул бүтәнчәрәк яңгырап ишетелгән иде. Әйтерсең Рушан еракта гы алгы көннәргә, үзенең әле яшәлмәгән тормышына йөгерде дә, тормышка ашмас өметләре һәм бәхетсез мәхәббәте өчен алдан ук хәсрәтләнеп, тирән сагышка батты. Мөстәкыйль тормыш бусагасына аяк басарга җыенган, җитмәсә әле янында чибәр чытлык Ниночка Новова булган унҗиде яшьлек егет өчен бик сәер тойгы иде бу.

Күрәсең, җыр икесендә дә бертөслерәк хисләр кузгаткан иде, чөнки Ниночка Рушанга ничектер моңсу гына карап алды да, аңа сыена төшеп, караңгыда кулын капшап тапты һәм аны сыйпый-иркәли башлады, ниндидер көтелмәгән хәвеф-борчылу сизде бугай.

Әле яшәлмәгән тормышы өчен шундый ук кайгыру-борчылу хисен ул тагын ун ел үткәч, балерина булырга

хыялланган Валентинаның, аңлап та җитмәстән, үзләренең уңмаган, барып чыкмаган язмышларын елап искә алганда кичерде...

Концерттан кайтып барганда Рушан ирексездән офтанып куйды: «Ниццадан килгән чәчәкләр...» Зәңгәр диңгез яры буендагы сагышлы мәхәббәт турында сөйләшергә әзер булган Нина: «Кирәкми, Ницца чәчәкләре безнең өчен түгел...» — дип җавап кайтарды.

Ул чагында Рушан аның сүзләренә әһәмият биреп, бәхәсләшеп тормаган иде. Ләкин бүген ачынып икърар итәргә туры килә: хәтта уйсыз-башсыз яшьлек елларында, мөстәкыйль тормышка аяк басар алдыннан да алар ни Ницца, ни Венеция, ни Монте-Карло, ни Фиджи яки Мальорка утраулары турында хыяллана да алмыйлар иде — алар баштан ук бүтән тормыш өчен, күз камаштыргыч коммунизм үрләренә бару юлындагы мәңгелек киртәләрне җимерер өчен әзерләнгәннәр иде. Бүген Рушан, соңлап булса да, моңаеп уйлана: аның туган иле, халкы егерменче гасыр цивилизациясеннән — мәдәният казанышларыннан гына аерылмаган, ул, гомумән, табигый кешеләр тормыш-көнкүрешеннән дә мәхрүм, кая инде монда Ниццалар...

Әмма Тимерьюлчылар сараеның ярым буш залында күңеленә кереп калган Ницца аның хыялларын озак ымсындырып торды әле. Бервакыт Ялтада, шаулап-гөрләп торган субтропик яшеллек арасында ул уттай кызыл тактадан әллә кайларга кычкырып торган реклама күргән иде: «Ниццага барыгыз!» Троллейбус бик тиз чапканлыктан, ул астарак тагын бер сүзне абайламый калган, анда исә «ресторан» дип язылган иде, шундый реклама белдерүенә башка бер урында яңадан килеп төртелгәнче, өч көн рәттән башыннан шул Ницца чыкмады. «Ницца» дигәннәре гап-гади бетон идәнле «пыяла тартма» икән, башка шундый урыннардан варьете биюле кечке ресторан хисапланып йөртелүе белән генә аерылып тора иде. Залының мескен фәкыйрьлеген яшереп, пыялаларын чия төсендәге ковралон белән каплаганнар — мөгаен, «Ницца» яныннан үтеп йөрүчеләр аның эчендә гаять бай, күңелле кәеф-сафалы тормыш бардыр, дип уйласыннар өчен дә шулай эшләгәннәрдер. Кыршылып беткән өстәлләре, өстәл өстендәге пластик савытлары һәм чатан тимер урындыклары белән күзгә бәрелеп торган бу фәкыйрьлекне залның ярым караңгы булуы һәм сәхнәнең оста гына итеп яктыртылуы яшереп тора, сәхнәдә исә ашык-пошык кына аннан-моннан җыелган кызлар варьете бии, кечкенә бер оркестр уйный иде. Нәрсә генә ма-

таштырмаганнар: чыршы бизи торган ялтыравык укалар, зәвыксыз гына ясалган рәсемле, еш алышынып торучы сәхнә дисеңме, сәхнәдә дә, залда түшәмнән дә асылынып төшкән, ялык-йолык килеп әйләнүче көзгеле шарлар дисеңме — берсе дә калмаган. Алар, күрәсең, атаклы диңгез курортларында сезон вакытында була торган ниндидер үтә зиннәтле, бай һәм күңелле тормышка кагылышлары барлыкны аңлатырга тиештер инде.

Рушан залның фәкыйрьлеген дә, варьетенең мескенлеген дә күрде. Әлбәттә, «Ницца» дигән купшы исемле бу «пыяла тартма»ның ул озак еллар хыялланып йөргән гүзәл Ницца белән бернинди уртаклыгы да юк иде, тонык яктыртылган Ялта урамнары буйлап төн уртасында күңелсез генә кайтып барганда, ул янә бер кат алдану хисләре кичерде.

«Ни өчен бездә һәркайда әшәкелек, зәвыксызлык, фәкыйрьлек, аларны караңгыга төреп тә, оста яктылык белән дә яшереп булмый бит...» — дип, моңаеп уйланды ул. Яктыртып куелган реклама тактасындагы «Ялта — дөнья курортларының энҗесе» дигән язу мәсхәрәләп көлү кебек тоела иде.

Шаулап үткән елларын, китап битләрен актарган кебек актарып, дусларын хәтеренә төшереп утырган мизгелләрдә ул үз шәхесенә бик якын килергә базмый иде шикелле, юкса үз-үзен тулысынча ачып бетермичә, заман җирлегендә үз фотосурәтен булдырмыйча, бу истәлекләрнең кыйммәте бик аз булуын да тоя иде. Мөгаен, аның үз тормышы ул сөйлисе килгән вакыйгаларга яңа төсмер бирер, димәк, яңадан артка, илленче елларның икенче яртысына, бөек казакъ далаларыннан җил китергән ком баскан шәһәрчеге Актүбәгә кайтырга, «1905 ел» урамындагы йорт яныннан берничә мәртәбә үтеп китәргә яки тәрәзәсе каршысында басып торырга кирәктер. Кулына нота папкасы тоткан зәңгәр бантиклы гүзәл кыз шунда яши иде бит. Рушан аны Тимерьюлчылар сарае янында очратып, сокланып-хәйран калып, артыннан ияреп киткән иде. Кайчакларда аңа әле хәзер дә һаман аның артыннан атлый төсле тоела...

Ул кызны искә төшерүе рәхәт, кызый аның төшләренә дә бик еш керә. Төшләрендә ул күптән үткән елларының исен-төсен тоя, аны шул замандагы тормыш-көнкүреш шау-шулары, шул чаклардагы музыка чолгап ала, ул яңадан яшьлегендәге парк-бакчаларда йөри, кинотеатрларга керә. Иң кызып, яшьләр белән тулышып торган «Бродвей»ны, мәктәп кичәләрен һәм Тимерьюлчылар сараендагы дәртле биюләрне күрә... Аның төшләре

үзе катнашындагы ретрофильмнар алар. Бик кыен, түзә алмаслык мизгелләрдә, бер сәбәпсез-нисез күңелен сагыш-моң басканда, ул кешеләрнең язмышлары белән идарә итүче югарыдагы нindidер илаһи заттан ялварып сорый: «Төшләремә яшьлегем керсен!» — ди. Ә яшьлек — мәхәббәт ул.

Үз вакытында абайламый, аңламый калган күп нәрсәләрне утыз елдан соң күрергә, аңларга мөмкин булган гүзәл төш-фильмнар... Дөрес, аларның берсен дә ахырына кадәр күреп бетереп булмый, алар, детектив сериаллар шикелле, иң кызыклы җирендә өзеләләр дә, ничек кенә ырымласаң да, дәвамын күрә алмыйсың. Ул төш-фильмнар бер тамашачы өчен генә, бер тапкыр гына күрсәтелә, алардан соң көндәлек тормышка яңадан кайту бик кыен була. Ләкин Рушан алардан һич кенә дә баш тарта алмас иде.

Аның техникум янәшәсендәге мәктәптә укучы кызга булган җавапсыз мәхәббәтеннән йомшак кына көлеп, дуслары кайчандыр: «Моңайма, тәүге мәхәббәт — кызамык кебек ул, авырырсың да терелерсең, икенче берәүне очратырсың, үзеңнең тәкәббер музыкантшаңны онытырсың»,— дигән иделәр. Бүген инде яшисе яшәлгән дип исәпләнә шикелле, ә ул аны барыбер онытмады, хәер, теге чакта ук ул бу ярату хисенең җитди һәм озакка булырын тоемлаган иде инде.

Прораб бүлмәсендә хезмәттәшләре арасында үз балаларының беренче мавыгулары, тәүге ярату хисләре турында сүз чыгып, аларны җитдигә алмауларын ишеткәндә, Рушанның йөзеннән моңсу елмаю йөгереп уза. Ул үзе андый бәхәсләргә катнашмый — аның яралы күңеленең ачы сабаклары кемгә кирәк? Аның үзенә — тормыш йөген туйганчы тарткан ялгыз прорабка карап, аны да кайчандыр дәрт-теләкләр газаплагандыр, ул да кайчандыр көйдергеч мәхәббәтнең тылсымлы ялкынын татыган-тойгандыр, шул турыдагы истәлекләре үзе өчен сакланып калган иң кадерле әйберседер, ул шулар белән генә яшидер, дип уйларга мөмкинме соң?

«Истәлекләр — безне куып чыгарып булмый торган бердәнбер оҗмах ул». Бу тирән мәгънәле сүзләрне ул кайчандыр кайдандыр укыган һәм гомере буена хәтерендә калдырган иде.

Күңеле белән кулына нота папкасы тоткан кызга әйләнеп кайтканда, соңгы көннәргә кадәр аны бернәрсә газаплый, аның язылмаган әлеге «гомер китабы»на кемдер күз төшерер дә сорап куяр шикелле: «Әллә син Глорияне яратмадың? Ә Светланка Резникованы? Ниночка

Новованы? Ниһаять, Валя Домарованы?.. Аның белән үткәргән ләззәтле төннәрең?..» Үз эш-гамәлләре өчен үзе җавап бирергә күнеккән, беркайчан да башка кешеләр артына кача белмәгән Рушан менә шушы, әле беркем дә бирмәгән сораулардан куырылып килә. Бәлки, үзен кеше алдында тулысынча ачып бетерү мизгелен дә шуңа күрә кичектереп киләдер әле...

Мөгаен, гади прораб кына булмыйча, сизгеррәк күңелле бер кеше — әйтик, рәссам, язучы яки артист-фәлән булса, хәзер инде анык кына бернәрсә дә дәгъва итми торган, күптән булып узган мөнәсәбәтләрен җиңел генә шәрехләп, аңлатып бирер дә иде, ләкин Рушан өчен бу — мөмкин булмаслык эш: ул үзенең истәлекләрендә үзен дә, сөйгәннәрен дә, үзенә кадерле булган башка кешеләрне дә түбәнсетергә теләми иде. Шуңа күрә дә ул «күңел китабы»ның сәхифәләрен шәхси тормышындагы һәр мәгъшукасына лаеклы урын табылган вакыйгалар белән тутырырга ымсына иде. Һәм ул әнә шул күптәнге үзен һәм үзенә кадерле башка нәрсәләрнең асылын танып белү юлын тапты шикелле...

Бервакыт, бөтенләй очраклы гына, бер китапта аның күзенә Жан Кокто турындагы истәлекләр чагылды. Күптән булып үткән вакыйгаларны аңларга менә шул ачкыч булды да инде. Язучының вафатыннан соң, биографлары аның фронтка китәр алдыннан язган мәхәббәт һәм иркәләү сүзләре тулы дүрт хатын табып алганнар — ул хатларны мәхәббәт лирикасының иң югары үрнәкләренә тиңлиләр икән. Ләкин... иң кызыгы шунда: ул хатларның барысы да, копирка аша язылган кебек, бертөсле, үзләре исә дүрт хатын-кызга адресланган икән. Һәм тагын да сәеррәге шул: озын һәм бәхетле гомер кичергән ул гүзәл ханымнар, соңрак хакыйкатьне белгәч тә, берсе дә «үзенә генә» язылган хаттан баш тартмый, киресенчә, хатта белдерелгән мәхәббәт хисләре бары тик үзенең Кокто белән булган мөнәсәбәтләренең чын асылын ачып сала дип бара икән...

Дасаев, әлбәттә, француз Кокто түгел, биредә турыдан-туры охшашлык була да алмый, әмма танылган драматургны һәм аның мәхәббәт хатларына ихластан дәгъва кылучы мәгъшукаларын аңларга тырыша торгач, ул үзенең ерак үткәнендәге кайбер вакыйгаларның чишелешен тапты шикелле.

Рушанның шәһәрдә яхшы билгеле бер «буй җитмәс» төркемдә йөргән сыйныфташ кызлары — Светлана Резникова һәм Ниночка Новова белән булган кыска, әмма бик шашкын «мәхәббәт уены» үзе техникумның дүртен-

че курсында укыган чагында, инде диплом проектына тотынгач, соңгы ярты ел эчендә булып алган иде. Хәзер Рушан ул чагында әлеге кызларның ниндидер мәкерле-хәйләле гамәлләрен башкару өчен генә «бик вакытлы» туры килүен аңлый инде, һәм, ни хикмәт, ике мәртәбә шулар кармагына капкан иде бит, ә барыбер ул хәйлә-мәкерләрен ахырына кадәр һаман да әле ачып бетерә алганы юк. Бары тик шуны гына белә: кызлар аңа махсус тозак кормаганнар, ул алар кул астына очраклы гына килеп кергән һәм, үзе дә аңламастан, алар уйлаган рольне башкарырга бик кулай булган. Һай, бу кызлар!.. Әмма хикмәт тә шунда шул: җиңел генә уйланылган хәйлә-мәкерләре үз йөрәкләренә дә кагылып узар һәм, соңыннан ачыкланганча, озакка яндырып торыр, дип кызларның берсе дә көтмәгән — монысын да Рушан хәзер яхшы белә.

Әлбәттә, бу «мәхәббәт уеннары» турында искә төшермәскә дә, аларны яшьлектәге юләрлекләр дип кенә үтеп китәргә дә булыр иде. Бигрәк тә ярты ел эчендә ике мәртәбә гашыйк булу — җитди эш түгел, мәхәббәт турында сөйләгәндә аларны искә алып торырга да кирәкмәс иде. Әмма вакыт дигәнеңнең бу очракта бер әһәмияте дә юк, Рушан, китаплардан укып, кешеләр өчен кайчагында көннәр һәм хәтта сәгатьләрнең дә бик мөһим булган мисалларын белә, ул көн вә сәгатьләр кешеләрнең язмышларын хәл иткән яки гомерләре буена рухи таяныч булган. Тагын да ныклы дәлил бар — һәркайсында тамга тора: «Вакыт тарафыннан сыналган».

## XV

Тимерьюлчыларның кырык бишенче мәктәбе. Яңа ел кичәсе. Шунда көтмәгәндә генә Рушанның Светланка Резникова белән «мәхәббәт уены» башланып киткән иде. Аңа кадәр Рушан инде өч ел ярымлап Томочка Давыдычеваны яратып йөри һәм, әлбәттә, кечкенә генә шәһәрчектә бу хакта күпләр белә иде. Һәммәсе дә күз алдында, кызыксынучан карашлардан качып та котыла алмыйсың. Хәер, Рушан качып йөрмәде дә, шундый чибәр кызга гыйшык тоту күзгә аеруча ташланып тора бит ул.

Ул заманнарда укучылар хәзерге балаларга караганда җанлырак, кызыклырак яшиләр, атна саен теге яки бу мәктәптә яхшы уйланылган шау-шулы кичәләр оештырыла, аларга башка районнардан да өлкән сыйныф укучылары чакырыла иде.

Андый кичәләргә гел генә бер үк егет-кызлар диярлек дәшеләә, шулар арасында — Тамара, ә инде ул кайда булса, Рушан да шунда. Кичә хуҗалары кунаклар арасыннан Тамараны шунда ук искәреп алалар һәм биергә бертуктаусыз чакырып кына торалар, әмма ничектер бик тиз, үзеннән-үзе кыз белән аңа яңа табынучылар арасында киртә барлыкка килә — зал буйлап бер дулкын тәгәрәп уза: «Рушанның кызы». «Тимерлек»тә дә, җәйге бию мәйданчыгында да, өлкә мәдәният сараенда да шулай була иде. Тамара моны белә, Рушанның үзен болай кайгыртып-күзәтеп йөрүен кайбер көннәрдә ошатып та куя.

Унҗидедә без барыбыз да кемгәдер гашыйк, ул еш кына җавапсыз мәхәббәт була, яшьлек эгоизмы белән без кемнең кемне яратканын абайлап та бетермибез, ә инде күп еллар үткәч тә шуны хәтердә тоту... Ай-һай ла! Әмма Рушан белән Тамара арасындагы мөнәсәбәтләр кемнәрнеңдер күңелендә калган, ун елдан соң, Актүбәгә кайтуларының берсендә Рушан моңа раслау тапты.

Бу юлы ул «Казакьстан» кунакханәсендә тукталган һәм, үзенең «Бродвей» дигән купшы-яңгыравык исемен күптән җуйган Карл Либкнехт урамына еш кына йөрергә чыга иде. Көнгә берничә мәртәбә Пушкин паркыннан кырык бишенче мәктәпкә кадәр күтәрелә, мәктәп янгын сүндерүчеләр бинасы каршындагы тау башында, Рушан үзен яшь, дәртле, уңга-сулга баш иеп, елмая-елмая сәлам биреп баручы егет итеп күрә — ул бит «Бродвей»да үз кеше иде. Шулай хатирәләренә бирелеп йөрүләренең берсендә аны ике кулына ике букча тоткан яшь бер ханым туктатты да уңайсызланып кына сорады:

— Гафу итегез, әйтегезче, Тамара белән араларыгыз ничек булып бетте?

Рушанның гаҗәпләнүен күреп, ханым бөтенләй югалып калды, өстәп:

— Белмим, ни өчендер мин сезне бик еш искә төшерәм. Мәктәптәге кичәләрдә аны күзегез белән гел эзләгәнегезне һич онытасым юк, күз карашыгыз аның янына бару юлындагы һәр нәрсәне көйдереп үткән кебек була иде. Ышаныгыз, бу минем хыял җимешем генә түгел, дус кызларым да шулай сөйлиләр иде, без сезнең өчен борчыла-кайгыра идек, Рушан,— диде.

— Рәхмәт! — дип җавап кайтарды күңеле йомшап киткән Рушан.— Нишлисең бит, ул башка кешегә кияүгә чыкты, хәзер Черновцыда яши.

Ханым бер чаттан кереп югалганчы, ул аның артыннан карап торды, хәзер дә хәтерендә бик ачык сакланган

мәктәп кичәләрендәге кызларның кайсысы икәнен чамаларга тырышты, әмма... юкка гына... Ул үзе таный алмаган бу ханымның таушала төшкән төссез генә күлмәктән, үкчәләре тапталган туфлидән булуына, бәрәңге тутырылган авыр букчаларыннан уңайсызлануын сизде, аның соравын да ни өчен кыенсынып кына биргәнен аңлады — күренеп тора: ханымның үз тормыш мәшәкатьләре дә башыннан ашкан, ә менә кирәк бит...

Гомумән, Рушан кайда гына бармасын, аның үз вакытында кемгә гыйшык тотуын беләләр, аның турылыклы булуы күңелләренә хуш килә иде. Хәер, ул заманнарда турылыклы булу батырлыкка саналмый, ә үзеннән-үзе шулай булырга тиешле гамәл итеп кабул ителә, шулай бәяләнә иде. Әмма ул чагында Рушанның үз хәле хәл иде. Ярты елдан техникум тәмамлап чыгасы, ә юл эшчесен нәрсә көтә? Берәр разъезд яки берәр кечкенә тимерьюл станциясе — полустанок. Тамараның шунда барып яшисенә ышану бөтенләй файдасыз, хәтта хатлар алышуга өмет тә бик аз иде. Тамара аның барлыгын, үзен яратканлыгын да белә, моны шулай булырга тиеш, дип кабул итә иде бугай: кайчакларда мәктәптәге кичәләрдән үзен озатып куярга да рөхсәт итә, аның белән бии, ара-тирә чытлыкланып та ала, көтмәгәндә Рушанның бокс ярышларына да килеп чыккалый һәм бик дәртләнеп аның җиңүен теләп утыра. Ләкин боларның берсе дә Рушан көткәнчә түгел, ул бит үзенең дуслары Валька Бучкин, Ленечка Спесивцевларның, шул ук Робертның ничек итеп кызлар белән яратышып йөргәннәрен күреп тора. Аңа күз төшергән кызларга да дуслары шунда ук әйтә иделәр: ташла, аны Давыдычевадан башка беркем дә кызыксындырмый, өметсез берсөяр ул, диләр. Ул елларда аның абруе менә шундый иде.

Теге Яңа ел кичәсе Актүбәдә соңгысы булды. Җәен ул эшкә юллама алып китеп барырга тиеш һәм ваемсыз студент тормышыннан аерыласын аңлый иде. Ул инде, мәсәлән, юл мастерының, үзен кайдан табарга мөмкин булганлыгын әйтми торып, төн булсын, бәйрәм булсын — участогын ташлап китәргә хакы юклыгын белә иде. Һөнәренең үзенчәлеге шундый. Шуңа күрә, мәктәптәге кичәдән соң Жорка Стаин бер кызыклы компаниядә утырырга чакырса да, әлеге бәйрәм кичендә ул моңсу-күңелсез булды.

Жорик, үзен мәхәббәт язулары белән күмеп ташлаган «14»ле саны артына кем яшеренгәнен белергә тырышып, залда әрле-бирле йөренә, ә Рушан, Тамараны биергә чакырырга кыймыйча, уйга чумып, зал колоннасына терә-

леп басып тора, Тамара исә ул көнне ни өчендер аеруча көйсез-капризлы иде. «Ак бию» игълан иттеләр дә Рушанны Светлана Резникова чакырды. Аны егетләр үзара «Леди» дип йөртәләр иде. Светланка үткен телле, тәкәббер кыз, шәһәрдә билгеле гаиләдән булып, күпләргә ошый һәм ул үзе моны белә иде.

Аны байтактан бирле күрмәгән Рушан, «һөҗүм итеп килүче» Яңа ел белән котлады да:

— Ә Славик кайда соң? — дип сорады.

Ул мединститутта укучы егет белән бу кызның күптәнге ныклы мәхәббәтләре барлыгын белә иде. Светланка, аның иңнәренә ике кулын да салып,— элекке биюләрдә бу рөхсәт ителә иде,— шукланып әйтеп куйды:

— Ә ул мине ташлады...

— Синеме, гүзәл Леди? Моңа ышануы кыен,— дип, Рушан аның шаяртып сөйләшүенә яраклашырга тырышты.

— Чынлап әйтәм. Минемчә, без синең белән менә дигән пар. Син Давыдычевага кирәкмисең, мин — Мещеряковка, кире кагылган ике бәхетсез җан без. Йә, Рушан, ничек, гыйшык-мыйшык башлап җибәрикме әллә? — Кыз аңа елмаеп карый һәм муены тирәсенә бармакларын ныграк батыра иде. Аның тәненең якынлыгы, кулларының кайнарлыгы, хушбуй исләре Рушанның башын әйләндереп җибәрде.

Әллә шаяртып, әллә чынлап сөйләгәнен Рушанның төшенеп җитмәгәнен күреп, Светланка чыршы тирәсендәрәк вальска бөтерелүче парга ымлады: Славик аның күптәнге көндәше Верочка Осадчая белән бик мавыгып бии иде. Бию тәмамлангач, Светланка Рушанны култыклап алды да колонна янына китеп, аның белән торып калды. Әле моңарчы бер кыз да алай карамаганча сөйкемле карап, ул Рушанның галстугын төзәтеп куйды, егет югалып китәрлек итеп, сокландыргыч елмайды да тәвәккәл генә әйтте:

— Телисеңме-теләмисеңме, Рушан, мин сине бүген әсир итәм. Кичәгә килгәндә, радиодан ишеттем: «Мәхәббәттә кимсетелгәннәр — берләшегез!» — диделәр.

Рушан, үзен шаяртумы бу, әллә җитди сөйләшүме икәнен аңламыйча, уңайсызланып елмаеп тик тора. Ярый әле, яннарына килеп чыккан Жорик коткарды — Светлана аларның бу кичәдән соң кайдадыр җыеласыларын белеп алган икән, аптырап калган Стаингa әйтеп салды:

— Жорик, Рушанга өметеңне сузма, ул бүген минеке,— диде.— Мин аны урларга карар кылдым. Бокс бу-

енча чемпион булган егетне үземә Яңа ел бүләге итеп ала алмыйммыни мин?

Шунда гына Рушан Светланканың шаяртмаганын аңлады. Стаин кызга гаҗәпләнеп карап тора иде, үзсүзле Резникова кәефе килгәндә әле болай гына да кыланмаска мөмкин, аңа күп нәрсәләр гафу ителә. Жорик бик һаваланып: «Светлана җәмгыятьтә үзенең тоткан урынын белә»,— дип бер генә әйтмәгәндер һәм юкка да түгел: кайчандыр бу кыз артыннан байтак чабып йөрде ул, тик эше генә пешмәде.

— Курыкмыйсыңмы? Ачуы килгәндә, Славик бик усал кылана бит.— Жорик кызга сокланып карый һәм аны бераз үртәргә тели иде бугай.

— Курыкмыйм. Рушан Давыдычеваны Мещеряков ишеләрдән хәтәррәкләрдән дә саклап йөрде әле,— дип җавап бирде Светланка һәм кыланчыкланып Рушанга сыланды.

— Ну, алай булгач, мин киттем, үз йөрәк мәсьәләләрем дә бар. Яңа елны күңелле каршы алыгыз! — диде Стаин, аннары Рушанны кочаклый төшеп, өстәде: — Онытма, Татар бистәсенекеләр үзенекеләрне кыерсытырга бирмәс,— диде. Славикның Курмышта яшәгәненә ишарәләде бугай, анда да, Татар бистәсендәге шикелле үк, җыен башкисәрләр яши иде.

Яңа ел кичәсе отыры кызганнан-кыза бара, шаулашу көчәя, иркенәеп киткән егет-кызлар, курантларның төнге сәгать уникене сукканда кемнең дә булса өендә каршыларга җыенып, соңгы төркемнәргә оешалар. Әлбәттә, көтелмәгәндә барлыкка килгән Резникова — Дасаев парына игътибар итми калмадылар, әмма ул кичтә аларның мөнәсәбәтләрен кем дә булса җитди кабул иттеме икән? Резникова Славикны үртәргә тели, ә Рушан рәхәтләнеп аңа кушылып, үз ролен уйный, дип кенә уйладылар булса кирәк.

Тышта кар ява, бизәлгән чыршы әкрен генә әйләнеп тора, залда халык күзгә күренеп кими. Вакыт тыелгысыз рәвештә төн уртасына якынлашып килә, Рушанны кич буена үз яныннан җибәрмәгән Светланка боеручан итеп:

— Әйдә! — диде.— Безгә дә Яңа елны һәм «мәхәббәтебез» башлануын каршы алырга вакыт.— Шундый сүзләр белән, Рушанны гардеробка төшә торган баскычка таба йөгертеп алып китте.

Рушан Светланка аны берәр компаниягә чакырыр дип уйлаган иде,— Стаинга шатланган шикелле үк, Ледига да һәркайда шат булыр иделәр,— әмма кыз, күптән хәл ителгән кебек, кинәт кенә:

— Ну, хәзер безгә кайтабыз, анда әзер өстәл безне көтеп тора...— диде.

Рушанның йөзендә гаҗәпләнү күргәч, елмаеп аңлатты:

— Әйе-әйе, әзер өстәл. Яңа елны синең белән каршы алачагыма ышандым, син минем аңлы рәвештә һәм күптән сайлап алган корбаным! Кызганмыйсыңмы?

Рушанның каушап калуыннан тәм табып, өстәде:

— Вөҗданың газапланмасын өчен әйтеп куям — төгәл беләм: Давыдычеваның Яңа ел планнарында сиңа урын юк. Шушы көннәрдә ул миңа шалтыраткан иде, бер сәгать буе сөйләштек. Дөрес, мин аңа Славик белән ачуланышканыбызны да әйттем, әмма үземә кирәклесен дә сөйләштем. Хәзер аның җен ачулары чыкканын күз алдыма китерәм — сине бит әле беркемнең дә алып китә алганы юк иде. Әмма безне мәктәптә: «Тормыш — көрәш ул»,— дип өйрәтәләр бит. Син мине гаепләмисеңме, Рушан? — Шул сүзләрдән соң, ул салкынча куллары белән аның башыннан тотып алды да кайнар итеп үпте.

Резниковлар мәктәптән ун минутлык юлда торалар иде, болар, Карл Либкнехттан Орджоникидзе урамына борылып, вокзал ягына таба түбәнгә ашыктылар, шунда «Тимерлек» каршысында, бернәрсә дә күренмәслек биек коймa артыннан күзгә бәрелерлек аерым бер йорт күтәрелеп тора. Искиткеч Яңа ел төне — бераз салкын да, йомшак кына кар да ява, Светланка юл буе шаярып кайтты: Рушанны әле көрткә төртеп аудара, әле кар атыша башлый, әле кардан кеше сыны ясарга азаплана. Һәр агач яны саен диярлек туктап үбешәләр, үбешкәндә Рушанга кызның газетка төрелгән лаклы биек үкчә — «шпилька» туфлиләрен кар өстенә куеп торырга туры килә. «Тимерлек» ишегалдындагы шугалакта бизәлгән чыршының аллы-гөлле утлары балкый, төрле төстәге матур-матур спорт костюмнары кигән үсмерләр төркеме шуның тирәсендә ипле генә итеп тимераякта шуа, бу күренешкә бары тик музыка гына җитми, әмма үсмерләрнең шатлыклы көлү тавышлары, чыркылдашулары, якынлашып килүче Яңа ел куанычыннан әсәрләнеп кычкырынып куюлары ерактан ук ишетелеп тора иде...

Яңа ел төнендәге шул матурлыкны-рәхәтлекне Рушан йөзләрчә мәртәбә исенә төшерә, төшергән саен яңадан-яңа ваклыкларын ача. Кайвакытларда кешенең барлык гомере берничә минут эчендә күз алдыннан үтеп китә икән, дип сөйлиләр — бәлки, шулайдыр да, әмма Рушанга шул унбиш минутлык юл әкренләп бөтен гомере озынлыгына сузылган шикелле тоела иде.

Ул саташкан кеше төсле атлый, кайчагында Светланкага әйле-шәйле җавап кайтара, бу иркәләүчән-ягымлы сүзләрнең, кайнар үбүләрнең үзенә икәнлеген ахырынача аңлап та бетерми иде бугай. Ул бервакытта да мондый гамәлләрдән баш шулкадәр әйләнер, йөрәк кагар, дип уйламаган иде, вакыт-вакыт аңа болар барысы да матур төш кебек тоела: тәкәббер Светланка, күпләр хыялланган, буй җитмәс Леди аның белән бит...

Кыз, ишекне үзендәге ачкыч белән ачып, аны өйгә керергә чакырды. Рушанның ишек төбендә югалыбрак торганын күреп, әйтте:

— Без ялгыз. Әти-әниләр кунакта, иртән генә кайтачаклар, Яңа елны бабайларда каршы алу — гаилә гадәте. Үт әйдә,— дип, ул залның пыяла ишеген ачып җибәрде.

Рушанның каршысында, нәкъ бизәлгән чыршы турысында биек түшәмгә эленгән авыр люстра балкып кабынып китте. Түшәмдәге меңләгән бәллүр кояшлардан чыршы өстенә җем-җем нурлар коела шикелле иде — тәүге мизгелдәге бу сихри күренеш тә аның хәтерендә озакка уелып калды.

Гаҗәп, диварлардагы шәрыкчә авыр келәмнәре, карала төшкән кызыл агач корпуслы галәмәт зур идән сәгате,— ул тавышсыз йөреше белән, мөгаен, бу йорттагы ритмны озак еллар саклап тора торгандыр,— үзенә таныш булмаган сирәк китапларның алтын хәрефле төпсәләрен ялтыратып утырган китап шкафлары, ике тәрәзә арасында бәллүр бокал һәм фужерларда люстра утларын һәм җиңел чыршы уенчыкларының елтыравын чагылдырып, чәй сервизы көмешенең тонык җемелдәвен үзенә җыйган серванты булган бу залны Рушан минут эчендә тулысы белән күздән кичереп өлгерде.

Чыршыдан бераз арырак крахмалланган ак эскәтер ябылган өстәл өстенә матур итеп табын әзерләнгән, анда салаттыр-кабымлыклардыр тезелгән. Әмма Рушанның күзенә иң элек биек ике ваза ташланды: берсендә — эре-эре алтынсу мандариннар, икенчесендә — Алма-Ата апорты, шулай ук эреләр, кып-кызыллар! Шуннан бирле Рушан Яңа елны гел алма исенә охшатып күзаллый. Ул инде дүрт ел буе Депо урамындагы тулай торакның сигез кешелек бүлмәсендә тора, шәһәрдә ул барып йөри торган бердәнбер йорт Почта урамындагы 72 нче йорт — анда аның дусты яши иде. Шуннан башка йортларга аның кереп караганы да булмады.

Беренче минутлардан ук ул Резниковлардагы ямьлелек-уңайлыкны, җылыны һәм ышанычлылыкны тоеп

алды, Светланканың нәкъ менә шундый тормышта, сирәк очрый торган нәфис чәчәктәй, сөелеп һәм кайгыртучанлыкка төрелеп яшәгәнен алдан фаразлаганда үзенең ялгышмаганын күреп, куанып куйды. Ул заманнарда үзең яратып йөргән кызның өендә булу яхшы гамәлләрдән санала — кечкенә шәһәрнең гөнаһсыз элекке гадәтләре иде ул. Рушан үзенең бәхет сәгате сукканын аңлады, аны бит «1905 ел» урамындагы ялгыз йортка беркем дә, беркайчан да чакырмады һәм бу хәл әлеге төн өчен шактый әһәмиятле иде. Бу бәхет бик кинәт, көтмәгәндә һәм күз ачып йомган арада бик тиз ишелеп төште, чынлап та — Яңа ел сюрпризы!

Ул әле барысын да күздән кичереп, ияләнеп тә өлгермәгән иде, Светланка кинәт кенә әйтеп куйды:

— Залның иркенлеге дә, бу галәмәт зур өстәл дә минем эчемне пошыра. Әгәр дә без минем бүлмәгә күченсәк, син каршы килмәссеңме?..

Әле һаман да аңына килеп җитмәгән Рушан, зиһенсез калгандай, баш кагып кына куйды һәм утырган кәнәфиеннән кузгалды.

Кызның бүлмәсе дә шактый зур, тәрәзәсе ишегалдына карап тора икән, ул зал белән тоташкан булып, ярым ачык калган ишектән караңгыда гирляндаларын җемелдәтеп балкып утыручы матур бизәлгән чыршы бик яхшы күренә иде. Тәрәзә каршындагы диварны биләп торган китап шкафлары арасына уңайлы почмак итеп күн тышлы ике тирән кәнәфи һәм яшел постау белән тышланган тәбәнәк өстәл куелган. Борынгы кәнәфиләрнең берсенең баш очында бронза торшерның гаҗәеп нәфис пыяла абажуры бөгелеп төшкән. Рушан шунда ук Светланканы шул иркен кәнәфигә, кулына китап тотып, аякларын бөкләп менеп кунаклаган һәм хәтта тәбәнәк агач караватына ябылган авыр шотланд шәленә төренгән итеп күз алдына китерде.

Әмма Рушанны ниндидер бер эчке сиземләү сагаерга мәҗбүр итте. Кызның күпертеп-кабартып ике мендәр куелган урын-җиреннән үзенең хәвефле карашын өскәрәк күтәргәч, ул шунда елмаеп торган Мещеряковның диварга кнопка белән генә кадап куелган зур фоторәсемен күреп алды. Ул шулкадәр югалып калды ки, күзләрен фоторәсемнән һич ала алмый торды, шул минутта бүлмәгә эскәтер тотып килеп кергән Светланка, аның каушап калуын күргәч:

— Анысы әни эше, аның мәкерле гамәле. Кайдандыр үзе яраткан Славикның рәсемен табып алган бит. Күрәсең, миңа Яңа ел сюрпризы ясарга теләгәндер

инде,— дип аңлатырга кирәк тапты һәм, фоторәсемне шунда ук йолкып алып, ерткалап ташлады.

Аннары, Рушанның иңнәреннән кочып, хәйләкәр генә елмаеп карады да:

— Синең шундыйрак фоторәсемең булмавы кызганыч, юкса мин дә әнигә җавап сюрпризы ясаган булыр идем,— диде.

Кыз теләсә нинди киеренке хәлне йомшарта белә иде һәм Рушан ул әйткән сүзләрнең дөреслегенә тамчы да шикләнмәде — Леди ихлас туры сүзлелеге белән аерылып тора, аның ягымлылыгы да шунда иде. Алар бит еш аралашалар, бер-берсен яхшы беләләр һәм Светланканың Рушанны сайлап алуы да минутлык каприз гына булмагандыр әле, бәлки.

Биек идән сәгатенең саңгырау-тонык итеп сугып куюы Яңа ел җитәргә чирек сәгать кенә калганын искәртте, Светланка Рушанның үзенә булышуын үтенде. Алар икәүләп залдагы бәйрәмчә өстәлдән сый-нигъмәтләрне тиз-тиз генә кызның бүлмәсенә ташыдылар, унике туларга биш минут кала Светланка торшер кебек үк авыр бронза шәмдәлдәге шәмнәрне кабызып җибәрде, күзләре белән шампан шәрабына ымлап, дулкынланып:

— Моннан бер атна элек мин нәкъ шушылай булыр дип уйлаган идем, хыялым тормышка ашканына шатмын. Яңа ел котлы булсын, Рушан! — диде.

Алар бокалларын чәкештергәндә, бәллүр чыңына караңгы залдагы сәгать суккан тавыш кушылды.

## XVI

Ул Яңа ел төне, Резниковлар йортына кайту юлы еллар аша Рушан тормышының зур һәм мөһим бер өлеше булып кабул ителә. Үзенең анда алты сәгать булганын хәтерләсә дә, әмма бусагадан атлап кергәннән алып чыгып киткән минутына кадәр ул кичне истәлекләрендә Светланка белән үткәрә алмый интегә ул. Барыбер ул очрашуны тасвирлап бирү өчен бөтен бер роман кирәк булыр, ул бернинди телесериалларга да сыймаячак, чөнки ул төннең сүзләре, төсләре һәм төсмерләре, ымнары һәм карашлары, тавышы һәм кыштырдаулары, исләре һәм музыкасы хәтердә еллар аша калкып чыга тора. Ләкин кем дә булса берәр вакыт гүзәл Леди йортында үткәргән Яңа ел төненең хронологиясен язарга мәҗбүр итә башласа, Рушан булдыра алмас иде... Тик ни өчен? Бөтен вактөягенә кадәр хәтерли, ул сихри очрашуны гомере буе күңелендә йөртә икән, ни өчен яза алмый? Нәкъ менә

шунысы сер дә инде, мәхәббәтнең теләсә кемгә ачылмый торган тылсымы, шул мәхәббәтнең сихри сулышын тоярга насыйп булса да, Рушанга да ачылмады ул. Күңеле каткан берәрсе, мөгаен, әйтер: агуланган бу, дияр. Гел шулай булсын. Яки алай булмасын. Яки бөтенләй алай түгел...

Ничектер бер җыелышып утырганда мәхәббәт турында сүз чыкты, Рушан бу сөйләшүгә катышмады. Әмма кайтып барганда, күрәсең, әле кайнар бәхәстән суынып җитмәгән булгандыр, иптәше кызыксынып сорады:

— Ә синең тәүге мәхәббәтең нинди иде?

Рушан шунда ук «1905 ел» урамындагы яшәүче кызны исенә төшерде һәм уйлап та тормыйча:

— Матур. Бик матур! — дип җавап бирде.

— Җавап түгел бу, артык гомуми,— дип көлеп җибәрде иптәше.— Аяклары нинди иде аның, күкрәкләре?

Рушанның озакка тынып калганын күргәч, иптәше, Дасаев үпкәләде, ахрысы, дип уйлады, әмма Рушан үпкәләмәгән, ә бөтенләй башка сәбәп белән җавап бирмәгән иде.

Рушан ул кызның аяклары, күкрәкләре нинди булганлыгын әйтә дә алмый, ул турыда бервакытта да уйлаганы да булмады. Дөрес, ул аның зур, дымлы назлы күзләрен хәтерли, тагын матур авызы читеннән аз гына өстәрәк, уң яңагындагы мөлаем миңе турында әйтә ала, аның ничек көлгәне, карашларының нинди уйчан булганы, кашларын ничек итеп җыерганы, нинди серле елмайганы турында озаклап сөйли ала, әмма аяклары, күкрәге турында... Юк, ул аларны хәтеренә төшерә алмый, «Тимерлек» каршындагы ялгыз йортта үткәргән төнне дә тулысы белән хәтерли алмаган шикелле, хәтеренә төшерә алмый — монысы да мәхәббәтнең серләреннән берсе булса кирәк.

Һәркем Яңа елдан уңышлар, шатлык-куанычлар, күптәнге теләкләренең үтәлүен көтә, бигрәк тә мөстәкыйль зур тормыш бусагасында — Рушан ул елны диплом, Светланка аттестат аласы иде. Шулай килеп чыкты инде, нindидер сихри серлелек төсмере булган һәм кешеләр өметләрен баглый торган шул бердәнбер бәйрәм төне алдыннан алар икесе дә, Светланка әйткәнчә, «кире кагылган ике бәхетсез җан» иделәр. Әйе, ничек кенә сәер тоелмасын, шулай килеп чыкты, юкса Рушан белән дә, Светланка белән дә танышырга, дуслашырга тырышып йөрүчеләр күп иде. Юк, Резникованың ул төнне Рушанны сайлавы да очраклы түгел, Яңа ел кичен Леди

белән үткәрүдән, аңа әсирлеккә төшүдән баш тартучы бер генә егет тә табылмас иде.

Светланка Резникова бер генә нәрсәне исәпкә алып бетермәгән бугай — Давыдычевага өметсез гашыйк булган Рушан Дасаевның әле моңа кадәр бервакытта да андый дулкынландыргыч сүзләрне ишеткәне, үзенә төбәлгән ягымлы күз карашларын тойганы булмады, әле бервакытта да кайнар кулларның иркәләвеннән кызлар кебек кызарынганы, татлы иреннәрнең үбешеп алуыннан тынсыз калганы юк иде.

Кыз күңелендә озак өлгергән, инде артык саклап булмый торган ул сүзләрнең, үбешү-кочышуларның үзенә түгел, ә бөтенләй башка берәүгә багышланган булуын Дасаев бер мизгелдә дә уена китерә алмый иде. Башкаларга бәхет һәм мәхәббәт вәгъдә иткән бу бәйрәм кичендә сагыштан һәм ялгызлыктан кызның йөрәге өзгәләнә иде, шунда менә Рушан килеп юлыкты — таныш, кайгылы-моңсу, ялгызы. Мөгаен, аның белән булган бу «мәхәббәт уены» төрле сүзләр китереп чыгарыр һәм Светланканы кызганудан туктарлар... Бәлки, бу хәлләр бөтенләй алай да булмагандыр, әмма Рушан хәзер, нәкъ менә шул сәбәп Резникованы үзенә этәргәндер, дип уйлый.

Светланканың сүзләрен, ым-хәрәкәтләрен, үбү-кочуларын барыннан да бигрәк озак һәм мул яуган карлы тауларда кычкырып җибәргән тавышка яки кайнап торган мартен мичен кисәү тимере белән бәреп ачуга тиңләп булыр иде — һәр ике очракта да ташкын хасил була: кар ташкыны яки ут-ялкыннар бөркеп торган кайнар металл ташкыны, аларны беркем дә тыя-туктата алмый. Рушан белән дә шундый хәл булды: еллар буе җыелып, чыгар урын тапмый яткан теләк-дәрт, татлы наз, сөю хисе шул төндә бәреп чыкты, йөрәге яралы Светланка сызланган күңеле ишетергә-тоярга ашкынган сүзләрне ишетте, хисләрне тойды. Кыскасы, мәхәббәт өчен ачык ике йөрәк очрашты.

Алар шампан шәрабыннан исермәделәр, ул төбенә кадәр эчелеп тә бетмәде бугай әле, аларны бер-берсенең ягымлы сүзләре, эчкерсез карашлары, ым-ишарәләре, саф уй-теләкләре, күңелләренең көтелмәгәнчә якынлыгы исертте. Мөгаен, моңа музыка да ярдәм иткәндер. Ул Яңа ел төнендә караңгы чия төсендәге шотланд шәлле, кайнарланып эреп аккан шәмнәр белән генә яктыртылган бүлмәдә төрле музыка яңгырады, әмма ешрак минор-моңсу музыка иде, алар яраткан Элвис Пресли ул кичтә кирәк булмады.

Ул төннең иң асыл моң-аһәңе дә табылды: ул кыш тормыштан иртә киткән легендар Батыр Закировның атаклы «Гарәп тангосы» кышы булды. Алар залдагы җем-җем итеп торган чыршы тирәсендә әнә шул күңелләрне өзгәләндерерлек сагышлы тангога кушылып биеделәр, мәхәббәт алиһәсе Афродита үзе аларга елмаю бүләк итә шикелле иде, ул төндә, мөгаен, алардан да бәхетлерәк гашыйклар булмагандыр.

Һәммәсе дә, махсус сценарийдагы шикелле, алар арасындагы мөнәсәбәтләрнең бик тиз тирәнәеп үсүенә булыша, күтәренке бәйрәм хисе әле бик озакка сакланып калган иде. Мәктәпләрдә каникуллар башлана, димәк, ике атна рәттән «Тимерлек»тә, Өлкә мәдәният йортында, бертуган Лариннарның джаз-оркестры уйнап торган «Большевик»та, һәрбер мәктәптә Яңа ел бал-кичәләре дәвам итә, дигән сүз. Алар бөтен гыйнварны диярлек бәйрәм итеп, җырлап-биеп, күңел ачып уздырдылар, чөнки әле өч-дүрт туган көнгә дә чакырулы иделәр, Стаин да үзләрендә үткәргән мәҗлесләргә ике мәртәбә дәшеп алды.

Алар һәр көнне күрешеп, бик озак сәгатьләрен бергә үткәрделәр. Кайвакытларда тулай торакта телефон шалтырый, Светланка дулкынланып: «Кил, сагындым...» — ди. Рушан, диплом эшен бер якка ташлап, яшел такта коймалы ялгыз йортка чыгып чаба. Сүз уңаеннан әйтеп үтик, үз гомерендә ятлап алган беренче телефон номеры Резникованыкы иде, ул аны хәзер дә хәтерли әле: 3-32.

Ул чагында Рушан өчен күп нәрсәләр беренче булды. Февраль башларында аларның шәһәренә беренче мәртәбә Азәрбайҗанның Рәүф Гаджиев җитәкчелегендәге Дәүләт эстрада оркестры гастрольләргә килде. Артистлар килеп бик узындырылмаган шәһәрнең халык күп йөри торган урыннары ачык төсле буяулы матур афишалар, оркестрның, җырчыларның, биючеләрнең, ул заманнарда танылган конферансье Лев Шимелев һәм Гаджиевның фоторәсемнәре белән бизәлде. Концертка эләгеп булмас шикелле иде, әмма Роберт ярдәм итте — аларга билетлар табып бирде, әле җитмәсә беренче рәткә үк, ә ул үзе инде дүрт концертка да барып, оркестрантларның барысы белән дә танышып беткән иде.

Рушан телиме-юкмы, Резникова белән булган «мәхәббәт уены» аның хәтерендә гел бәйрәм генә булып яңара — шулай килеп чыккан инде. Алар Өлкә мәдәният йортының концерт залында беренче рәттә утыралар, ә каршыларында сәхнәдә ярым түгәрәкләнеп, түшәмгә кадәр үк диярлек дүрт катланып зур оркестр урнашкан — бәйрәм түгелмени бу? Бик оста яктыртылган сәхнә, ка-

раңгыда юпитерларның җемелдәве, көмешсу трубалар, оркестрантларның күз явын алырлык жилетлары һәм кара фраклары, саксофоннарның алтынсу авызы, иң югарыдагы уен коралларының елык-елык килеп торган җизе һәм барабаннарның утлы перламутр кысалары. Һәр бүлектә алышынып торган пәрдәләре, һәр яңа артист чыккан саен шулай ук алышынып торучы матур рәсемнәр, концерт программасындагы чын театраль декорацияләр — дөнья эстрадасы йолдызлары аларга бүген генә иреште әле.

Фантастикамы? Хәзерге бөтен нәрсәне артык гадиләштереп-примитивлаштырып бетергән заманда, әйе, шулайдыр. Әмма Рәүф Гаджиев оркестры, аннан кала тагын соңрак Рушан үзе тыңлаган, үзе күреп белгән берничәсе, мәсәлән, Әрмәнстаннан Орбелян, Тбилисидән Гобискерия, Мәскәүдән Лундстрем, Ленинградтан Вайнштейн оркестрлары, Кроллның теләсә кайсы джазы профессионаллыкта, осталык-маһирлыкта Поль Морианың иркә артистларыннан, ай-һай, калышырлармы икән?

Бу шулкадәр күптәнге хәл, әле ул чакларда хәзер инде байтак еллар элек таралып юкка чыккан «Гойя» вокаль квартеты да юк, ә Тимур Мирзоев, Рәүф Бабаев, Левка Елисаветский, Ариф Гаджиевлар бары тик бергә җырлыйлар иде. Ул вакытта әле, мөгаен, Лева да үзенең җырларында данлаган, яраткан Бакуын кайчан булса да ташлап китәчәге турында уйлап та карамагандыр. Ә хәзер оркестрның төп җырчысы Октай Агаевның лирик тенор тавышын кем генә хәтерли икән?

Ләкин Рушан һич оныта алмый: ул вакытта Михаил Винницкий, сәхнә кырыена ук якынаеп, залга таба аз гына иелде дә, туп-туры Светланкага карап, моңлы җырның кушымтасын кабатлады: «Килерсеңме син?.. Килерсеңме син?..», ә кыз үзе дә белештермәстән Рушанга сыенды, җырчының партердагы тамашачылар арасыннан нәкъ менә аны аерып алып җырлавы дулкынландырган булгандыр...

Дасаевның студентлык елларындагы соңгы кышы шулай тәгәри бирде һәм ул, ниһаять, бәхетле иде. Март башында ике атналык диплом алды практикасы башланасы һәм ул җәйдән үк аны үзләрендә, Мартукта үткәрәсен белә иде. Хәер, шәһәргә ул бер атнадан кайтырга тиеш — Казакъстан тимерьюлчылары җыелма командасы составында Мәскәүгә, «Локомотив» беренчелегенә бокс ярышларына китә иде.

Китәр алдыннан сөйләшенеп-килешенеп куйдылар: Светланка һәр кичке поезд белән хат биреп җибәрәсе

булды — ул заманнарда һәр пассажир поездында почта вагоны бар һәм түземсезләр шуннан файдалана иде.

Дымлы март ае, тып-тып тамган тамчылар, күзгә күренеп басыла-иңә барган кар көртләре, урамда хат ташучыны көтеп торулары хәтеренә уелып калган. Почтальоншаны ерактан ук күреп алып, ул аның каршысына йөгерә, озак көтелгән хатны бер минут булса да алданрак алырга тели иде. Әмма... әмма...

Ничек сөйлим ерак калган,
Онытылган ул язымны?
Ничек онытыйм синең йөзне?
Онытып булмас ул назыңны...
Язгы сулар ташып агар,
Шатланышып кошлар кайтыр...
«Синең дә язың кайтыр», — дип,
Миңа инде кемнәр әйтер?
Белмим инде, белмим, нигә
Салкын бу яз? Юеш, төксе
Яз булса да, миңа әле
Һаман озын кышлар төсле.
Хәтерлимен паровозның
Озын, моңсу тавышларын...
Без ул язда сөешсәк тә,
Үкенеч шул — кавышмадык...

Ә Рушан үзе, килешенгәнчә, көн саен төнге поездга йөгереп бара, йокылы почта вагонының ярыгына хатын төшереп җибәрә дә паровозның салкын төнге караңгы күккә очкыннар сипкәнен карап тора.

Төн, буш перрон, кешесез урамнар, әкрен генә кузгалып киткән поездның якты тәрәзәләре... Шул төнге сәгатьләрдә нәрсәләр генә уйлап бетермәде икән Рушан!

Шәһәргә китәр алдыннан соңгы көнне ул, гадәтенчә, почтальоншаны көтеп тора иде, тегесе, аны ерактан ук күреп, кулындагы ак конвертны болгады. Рушан сикерәнә-сикерәнә аның каршысына чапты. Түземсезлек белән көткән хат дигәне телеграмма бланкысы булып чыкты — «Локомотив» аны ашыгыч рәвештә үз байрагы астына чакыра, Мәскәүгә китү өч көн алданрак буласы икән.

Мөгаен, Мәскәүгә китеп барганчы, шәһәрдә берничә сәгать буш вакыты табылу яхшы да булгандыр — Светланка белән телефон аша сөйләшеп, ул аның тәки Мещеряковка кияүгә чыгачагын белде. Кинәт кенә башланган «мәхәббәт уены» шулай ук көтмәгәндә генә өзелде дә куйды...

Бүген Дасаев үзе саксыз үпкәләткән бик күп кешеләрдән, «Локомотив» беренчелегендә чемпион булып,

үзе рингта җиңгән егетләрдән, соңлап булса да, гафу үтенер иде. Тимерьюлчыларның спорт сараенда үткәргән ике атна эчендә аңа усал кушамат тактылар: «Кансыз»... Ярый әле, бәхеткә, ул кушамат шунда Мәскәүдә үк үлеп калды. Ул бит анда һәркемгә дә йөрәге өзгәләнгәнен сөйләп йөри алмый иде инде... Кемдәдер аның турында «тумыштан рәхимсездер бу» дигән тәэсир калган булса, бик кызганыч.

Алар Мәскәүдән апрельдә генә әйләнеп кайттылар. Инде яз тулы хакимлек итә, «Бродвей»га җан кергән, шунда һәр көнне Стаин Никанор атакай белән һава суларга чыгып йөри иде.

Аның «Локомотив» беренчелегенә уздырылган ярышлардагы уңышын шәһәрдә инде беләләр, Резникова белән кинәт башланып, көтелмәгәндә өзелгән гыйшык-мыйшыклары да онытылган, күләгәдә калган иде. Рушанны беркем дә юатмады, кайгысын уртаклашкандай кыланып маташмады, барлык танышлары да ул «мәхәббәт уенын» Резникованың капризы яки Мещеряковны үзенә кайтару өчен ясалган бер адымы дип кенә кабул иткәннәр, күрәсең. Ә бәлки, Светланканың булачак табиб белән ике арадагы мөнәсәбәтләренә дә, Рушанның Давыдычева белән булган дуслыгына караган кебек, җитди караганнардыр. Гомумән, һәммәсе дә бу хәлне бернәрсә дә булмаган шикелле кабул иттеләр. Ә Рушанның мәхәббәт сулышын тойган йөрәге сызланып өзгәләнә, әле шуның өстенә ул, яшьлеккә хас югары таләпләрдән чыгып, үзен Тамарага хыянәт иткән кебек тә сизә иде. Кыскасы, Рушан бөтенләй буталып бетте, бервакыт тулай торакка кайтып барганда, уйларына батып, онытылып, ул хәтта яңадан «1905 ел» урамындагы йортның тәрәзәсе каршысына барып чыккан иде...

Вакытны «бишьеллыкны — өч елда», «бер ел — ике елга» дип исәпләү дөньяда беркайда да юктыр, мөгаен. Беренче очракта бу гыйбарә идеологик мәгънәгә, ә икенчесендә — җинаятьләргә карата әйтелсә дә, совет кешеләре өчен асылы ачык иде. Ул язда Рушан белән аның дуслары өчен дә шундыйрак хәл туды: алар бик тыгыз, тулы тормыш белән яшиләр, һәр көн ниндидер ачышлар китерә, кайбер көннәрне айга тиңләргә дә булыр иде. Алар үзләре өчен дөньяны да, үз-үзләрен дә ача торалар һәм ул вакытта барысы да тәүге тапкыр иде.

Светланкадан бер сыйныф түбән укучы Тамара көтмәгәндә Резникованың сыйныфташы Наил Сафин белән очраша башлады. Наилнең — бик тыныч-ипле, чирләшкә, «йорт куяны»ның кинәт кенә Тамараны мәктәптән оза-

та кайтып йөрүен сәгате-минуты белән Рушанга җиткерделәр.

Әмма хәзер, Резникова белән булган «мәхәббәт уенын»-нан соң, ул үзен, моңа кадәр кыланган шикелле, алар арасына тыкшынырга хаклы түгел дип санады, аннары Наилне дә җитди кабул итү көлке булыр иде, монда да, мөгаен, Резникова белән булган очрактагы кебек, берәр төрле сер, табышмак булгандыр.

Вакыйгалар бик тиз үзгәреп тора, ул бары шуны гына абайлап алды — Светланка Рушан булырдай компаниялардән бик оста гына кача белә, ул үзе дә ни өчендер кыз белән очрашудан курка иде. Аның кәефе бик начар, «гүләйт итеп» йөрерлек түгел, шунлыктан, тырышып-тырышып диплом эшен эшли, бокс буенча шәһәр беренчелегенә ярышларга әзерләнә, финал уеннары, элекке күп еллык гадәт буенча, парк ачылган көнне үтәргә тиеш иде.

Шәһәр боксчылары җиңү яуларга омтылган мондый ярышлар башка юк. Теләсә кайсы данлыклы спорт җәмгыятенең — «Спартак»ныңмы, «Динамо»ныңмы чемпионы бул, республикада һәм хәтта илдә призлы урыннар яула — барыбер, шәһәр бары тик үз чемпионнарын гына таный. Җиңүчеләр бөтен җәй буена кумирга әйләнәләр, ә парк администрациясе һәр җиңүчегә бию мәйданчыгына сезон беткәнче бушлай кереп йөрү хокукы бирә торган жетон тапшыра. Оркестр аларның күңеленә хуш килгән көй-музыканы кабатлап уйный, ә кырыс вахтерлар, жетон иясе уңайсызланып кына: «Бу кыз — минем белән...» — дигәндә, кунакчыл елмаеп каршы алалар иде...

## XVII

Әйе, ул язда һәртөрле вакыйгалар күп булды — шатлыклылары да, моңсулары да, кирәге дә, кирәкмәгәне дә.

Бервакыт Рушанга шәһәр уртасында көпә-көндез бер сугышта катнашырга туры килде. Кирәк бит, нәкъ шул чакта алар өстенә тыкрыктан Тамара белән Наил килеп чыкты. Соңыннан, куркуыннан катып калган кызый Наилгә: «Шушы бандит минем арттан йөреп маташты бит әле...» — дигән, имеш.

Рушан үзен гаепле итеп тоймаса да,— чөнки сугышмыйча булмый иде,— Тамараның күзенә күренергә бик озак куркып йөрде. Шулай да...

Ул елны урысларның Пасха бәйрәме апрель азагына туры килгән иде. Ә аннан бер ел элек кенә аларның

мәхәлләсенә — урысча әйтсәк, приходларына яңа поп билгеләгәннәр иде, монысы элгәренә караганда яшь һәм чибәр генә түгел, бик эшлекле дә булып чыкты — шәһәр приходына җан керде, әлеге дини бәйрәмне беренче мәртәбә шулай зурлап үткәрделәр. Ул якшәмбедә Рушан «Тимерлек»тәге китапханәгә кереп чыккан иде, шуннан Орджоникидзе урамыннан «Бродвей»га күтәрелергә булды. Менә шунда ул бертуган Дроголовларны очратты, аларны «дроголята» дип кенә йөртәләр, Мәскәү бистәсенең башкисәр ышпаналары инде, Рушаннарның тулай торагы да шул төбәктә бит. Билгеле, алар бер-берсен яхшы беләләр иде.

«Дроголята» инде иртәдән үк дуслары һәм танышлары белән бераз төшереп өлгергәннәр, кәефләре әйбәт. Рушанның кая юл тотканын белгәч, үзләре дә «Бродвей»-дан бер әйләнеп кайтырга булдылар — ни әйтсәң дә, бәйрәм ич!

«Дроголята»ларның ике өлкәне инде берничә мәртәбә утырып та чыккан, аларны Рушанның Гомәровлар өендә дә очратканы бар, еш кына җәйге ресторанда Шамил һәм Исмәгыйль белән утырганнарын да күргәли иде, алар шәһәр халкына да яхшы ук билгеле. Ә «данлыклы» абыйлары канаты астында үскән кечкенәләре үз урыннарын белә һәм барыннан да бигрәк абруйларын — «репутацияләрен» саклыйлар, вак-төяк белән чуалып маташмыйлар иде.

Кичәге футбол уенында Стаин «Локомотив»ка җавапсыз өч туп керткән, шуның шатлыгыннан Татар бистәсе егетләре төне буе гөр килеп йөргәннәр иде. Шул турыда кызып сөйләшә-сөйләшә, болар Яңа ел төнендә Рушан Светланка белән үбешеп торган агачлар яныннан үтеп, Орджоникидзе урамыннан менеп баралар иде. Каршыларына, вокзалга таба төшеп килүче дүрт егетне Дасаев ерактан ук күреп алды. Егетләрнең, кулларын бутыйбутый, шаулашып сөйләшүе, кычкырып-кычкырып көлүләреннән пасханы билгеләп «авыз ачканнары» күренеп тора. Үзләре шактый өлкән дә күренәләр.

Әгәр бер-береңә юл сапмасаң, тар тротуардан үтеп китәрлек түгел, әмма Рушаннан кала ни теге яктан, ни бу яктан берсе-бер андый адым ясарга уйлап та карамады, алай гынамы әле, әллә ялгыш, әллә юри тегеләрнең берсе Дроголовларның кайсынадыр җилкәсе белән төртеп тә узмакчы булды. «Дроголенок»ның усал ялтыраган күзләрен күреп, әлеге егет мәсхәрәле итеп, теш арасыннан сыгып чыгарды:

— Нәрсә, козел, карап каттың? Өлкәннәргә юл бирә алмыйсыңмы?

Әгәр дә җинаятьчел дөньяда иң мыскыллау сүзе булган «козел» сүзе урынына теләсә нинди башка сүз әйтсә дә, бәйләнешеп китмәсләр иде шикелле. Әмма мондый сүзне үткәреп җибәрергә, әйтүчесен җәзасыз калдырырга мөмкин түгел иде.

Шулай да, эшне зурга җибәрмәскә теләп бугай, Дроголов сорап куйды:

— Кабатла әле, ишетеп җиткермәдем...

Теге егет, төшереп алган дусларының гайрәтләндерүен сизенеп, «козел» сүзенә басым ясап, әйткәнен кабатлады. Дроголовларга гына түгел, Рушанга да ачык иде: бу мәсхәрәле җавап сугышчан быргы сигналы булып яңгырады — мондый мыскылны, әле җитмәсә кешеләр алдында, алар күтәрә алмадылар.

Нәкъ менә шул, сөйләшеп-нитеп тормастан, үзләрен мыскыл итүчеләр өстенә ташланган минутта гына чаттан Тамара белән Наил килеп чыкты...

Сугыш тротуардан юлга күчте, сан ягыннан да артык булып, бу маңка малайларны тиз генә акылга утыртачакларына ышанган таза егетләр хурлыклы төстә бик каты кыйналдылар.

Бөтенесе дә бик тиз, берничә минут эчендә булды.

Дроголовларның берсендә күзгә ташланмый торган җиңел плексиглас кастет бар икән, шуның белән китереп суккач, тегеләрнең берсе дә аягында басып кала алмый. Тротуарга һәм урам чатына җыелып, авыз ачып карап торучылар үтә күренмәле тар гына кастетны абайлый алмаганнардыр, ләкин Рушан андый көчле сугуның сәбәбен шунда ук аңлап алды.

Аларга теләктәшлек белдереп торган кемдер: «Атас! Милиция!» — дип кычкырды. Рушаннар күрше ишегалдына кереп югалдылар.

Сугышкан чагында Рушанның күзенә Тамараның курыкынган йөзе чагылып китте, ә аның үзен таза гәүдәле егет кысрыклый иде, Рушан аны, сугып, бер-бер артлы егып торса да, һич кенә дә нокдаунга җибәрә алмый интекте. Ә якын килеп сугышырга,— анысына үзе бик тә маһир булса да, теләмәде — бәйрәмнәр алдыннан берәр җирен күгәртеп чыгарырлар дип шикләнде.

Ул көнне «мәскәүнекеләр» алдында аның абруе күтәрелде, аңа әле моңа кадәр сагаебрак карыйлар иде — ул бит һәрвакыт үз ишләре белән генә йөри, Исмәгыйль бәккә дә туган тиешле, Стаин белән дә дус. Шикләнерсең дә...

Җинаятьчел тормыш романтикасы Рушанны кызыктырмый, Исмәгыйльнең үз итүе яки Дроголовлар белән

дуслык аның өчен Давыдычеваның бер елмаюына да тормый иде. Кыз алдында бөтенләй дәрәҗәсе төшкәнен аңлап алды ул, кызның «бандит» дип әйткәнен Рушанга шул кичтә үк җиткерделәр...

Кайвакытларда Рушанның башына юләр уй да килә, бәхетенә, ул аны беркем белән дә уртаклашмый: Светланканы «урлаган» Мещеряковка барып «аңлашырга» тели, «1905 ел» урамына юлны гомерлеккә онытылырлык итеп Наил Сафинны да өркетеп куймакчы була... Әмма мәхәббәткә сусаган җаны балигъ була, акыл керә, күзе ачыла бара иде инде.

Менә әле Мещеряков белән дә... Рушан үзенең чит кешенекенә нәфесен сузганын аңлый иде. «Сталин чоры балалары», ни әйтсәң дә, күңелләренә иманлы әби-бабалары салган, әле «КПСС Программасы» битләренә язылмаган «Үтермә», «Урлашма», «Күршеңнекенә кызыкма», дигән васыятьләрне хәтерләрендә тоталар, мораль кодекс аларның каннарына сеңгән иде...

Наил белән дә шул ук хәл. Резникова белән «мәхәббәт уены» булмаса, гәрчә яшь акылы көчләп яраттыра алмаганын аңласа да, Рушан аны, бәлки, кыйнап та ташлар, өркеткән дә булыр иде.

Гомумән, ул үзендә ниндидер бер күңел китеклеге тоя һәм кайвакытларда хәтта үзенең мәхәббәт хыяллары тормышка ашмаган бу шәһәрдән ике ай ярымнардан китеп барачагына шатланып та куя, яңа урында бөтенесен дә яңабаштан башларга өметләнә иде... «Күзең күрмәсен — йөрәккә кермәсен»,— диде ул, үз-үзенә һәм башы-аягы белән диплом проектына чумды, хәер, шуны-сын да билгеләп үтәргә кирәк — ул җиңел укыды һәм, аның карашынча, диплом эшенә вакыт артык күп бирелгән иде.

Ул яз, әйтеп киткәнебезчә, гомумән, сәерлекләргә бай булды. Әгәр дә мәхәббәттә бөтенләй эше уңмаса һәм ул моны берничек тә аңлый алмаса, ул менә-менә спорт мастеры булырга тора, үзенә боксның күп кенә яңа серләрен ача килде.

Моның башы Пасха бәйрәме көнне урамда сугышуга барып тоташа иде. Теге егетләрнең берсен сугып еккан-да, ул кече «дроголенок»ка ярдәм итеп тә өлгерә. Рушан үз дошманын бәреп ега да, икенчесенә кыска һәм кискен итеп китереп кундыра, егет сыгылып төшә, әмма үҗәтләнеп яңадан аягына баса, янә, үгез кебек, алга ыргыла. Егетләр таза-тазасын, ләкин миңгерәүләнгәч,— бокста ул «грогги» дип атала,— куркыныч түгел иделәр. Хәер, бөтенесе дә бик тиз эшләнә, Рушан салкын канлы-

лык белән чамалабрак кына суга — бармак сөякләрен бирттерүдән саклана. Элек болай саклану башына да килмәс, мавыгып-кызып китү акылны томалый торган иде. Әле ул гынамы: ул ике егетне дә күз уңында тота һәм, инде бөтенләй аңлатып булмастай хәл — юл чатындагы Тамараның куркынган йөзен дә һәрвакыт диярлек күреп тора. Аның көче дә, үҗәтлеге дә, техникасы да бар, шунлыктанмы, кинәт кенә боксның асылын тирәнтен аңлап алды: үзендә ышаныч, салкын канлылык һәм уйлап-исәпләп суга белү барын тойды, күрү сәләте, голография шикелле, күләмлегә әверелде — ул бөтенесен дә үтәдән-үтә күрә башлады һәм дошманының хәйләле уйланган һөҗүмен кире кага барды. Үзендәге шушы сыйфатларны ул, шәһәр ярышларына әзерләнгәндә, беренче күнегүләр вакытында ук аңлады...

Рингка чыккач, көтмәгәндә үзенә килгән ышанычтан рухи тынычлык тойды, күңеленә җиңеллек тапты. Ә бит әле Пасха бәйрәме иртәсендә генә, «Тимерлек» ишегалдында Резниковларның йорты каршысында басып торганда, ул тыкрыктагы биек яшел койма ягына борылып карарга да курыккан иде — юксыну-ямансулаудан йөрәге сызлана иде.

Аның рингта үзгәреп китүен, кызмыйча, салкын канлылык белән уйлап-исәпләп кенә, үзен иркен тотып сугышуын шунда ук күреп алдылар, әмма моны «Локомотив» беренчелегендә туплаган тәҗрибәсе дип кабул иттеләр: башкалада мастерлар белән аралашканнан соң, өлгергәнлек килгән дип уйладылар булса кирәк. Моның чынлыкта нәрсәгә бәйле икәнен үзе генә белсә дә, гәрчә ул аны башкаларга аңлатып тормады. Дөрес, бу көннәрдә моңаеп үз-үзенә әйтеп тә куйды: «Дүрт ел эчендә бары тик рингта гына уңышка ирешүем кызганыч...»

Әйе, бары тик рингта гына ул үз язмышына үзе хуҗа була ала, көндәшләрен үз ихтыярына буйсындыра, үз алымнары белән сугыша, ләкин болар Рушанны артык куандырмады — кызыктырырлык тәкъдимнәр булса да, ул үз тормышын спорт белән бәйләргә теләми иде.

Шулай итеп, бөтен шәһәр парк призына буласы ярышларны көтә, бигрәк тә җиңел үлчәүдәгеләр ярышын: анда катнашучылар иң күбе — ул заманнарда тәвәккәл егетләр җитәрлек. Илнең җыелма командасының чиреге казакъстанлылар. Казакъстанда бокс озак еллар буе спортның беренче төре булып саналып килде.

Рушан исә шәһәр тормышы инде үзен читләтеп ага, ул монда кирәксез хәзер, дип уйлый иде. Ул иләп кенә хәрби учеттан да төшеп куйды, үзендә булган китаплар-

ны һәм спорт инвентарен илтеп тапшырды, үз катнашыннан башка үтә алмый торган ике генә эше калды: диплом яклау һәм шәһәр беренчелегенә бокс ярышларында катнашу. «Бродвей»да һәркемнең телендә бокс кына иде.

Ләкин язмышка шулай кирәк булгандыр: калган шул ике ай эчендә Рушанның тормышын яңача яктыртып җибәргән хәлләр килеп чыкты һәм, теге Яңа ел кичәсеннән алып аннан соңгы барлык көннәр бергә кушылып, еллар үткәч, аның гомер юлында рухи терәк булып калдылар. Хәзер, дистә еллардан соң, һәрнәрсәгә: «Вакыт сынавын үткән»,— дигән юылмас мөһер сугылгач, ул аңлый инде: очраклы, вакытлы, үтеп китәрдәй тоелган, онытылган нәрсәләрнең һәммәсе дә илаһи мәхәббәт балкышы белән өретелгән бүләк булган икән, кешеләр бу дөньяга сөяр һәм сөелер өчен килә икән.

Бәхетле заман...

Кызганыч, тылсымлы оҗмах кошының янәшәдә генә,— башыңны гына бор! — кул сузымы гына җирдә булганлыгы ул вакытта аңланмаган. Ә бәлки, сөю бәхете шуны белмәү, аңламаудадыр, оҗмах кошының тоттырмас булуындадыр?

Парк ачылырга бер атна кала башланып киткән бокс ярышларында катнашу Рушанга җиңел бирелмәде. Бигрәк тә беренче сугышы. Аны карарга гаҗәп күп халык җыелган, чөнки җиңел үлчәүдә чемпион исеменә дәгъва кылучы төп ике боксчыны — Дасаев белән Кружилинны сукыр шобага беренче сугышта ук очраштырган иде. Ул елларда судьяларның беркетмәләрендә бу пар еш кына финалда катнашучылар буларак билгеләнә иде.

Беренче раунд бетәргә берничә секунд калганда, Рушан рингка иң якын урыннарда утырган тамашачылар арасына Тамара белән Наил килеп кергәнен күреп алды. Ул хәтта күңеленнән генә баш кагып кыз белән исәнләшкәндәй дә булды һәм шул мизгелдә Кружилин аңа бик көчле итеп уң яктан китереп тә сукты. Рушан чак кына нокаутка егылмый калды, ярый әле, гонг коткарды: беренче раунд тәмамланган иде. Ул ант итеп әйтә ала, аңа турылыклы табынучылар шул чагында Тамарага дәррәү карап алдылар: алар нәрсә булганын аңлаганнар иде. Ләкин калган ике раундта ул инде бүтән андый ялгышлыклар җибәрмәде.

Тамашачылар күңеленә аның яңача сугышу алымнары хуш килде, ә Кружилин өчен бу көтелмәгән хәл булды. Аны-моны уйлап тормастан, һәрдаим һөҗүмгә ташланучы үҗәт һәм усал Дасаев кая киткән диярсең... Аның

урынына рингта мәче кебек йомшак кына басып, фехтовальщикны хәтерләткән җиңел-хәрәкәтчән боксчы йөри. Аның сугулары яшен тизлегендә һәм төгәл, алар кинәттән генә булалар, аларны күреп-чамалап бетерергә дә мөмкин түгел шикелле, ә үзе көндәшенең һәр һөҗүмен алдан күрә, алдан сизенә һәм әле читкә тайпылып, әле кинәт кенә иелеп суктырмый кала, көчле сугып, тегенең һөҗүмен өзә. «Мәче-тычкан уены кебек булды бу»,— дип бәяләде Стаин Рушанның бу беренче җиңүен.

Дасаев ул язда чемпион исемен яулап, әлеге кадерле жетон иясе булып кына калмады, бик оста техникалы боксчы призын да алды. «Шәһәребездә «матур» бокс аңардан башланды»,— дип сөйлиләр икән хәзер Актүбәдә. Әмма Актүбәдә Рушанның ул соңгы чыгышы булды.

Грамоталар, жетоннар, бүләкләр тапшырган тантана беткәннән соң, башкалар сизми дә калган бер вакыйга булып алды, Дасаевның тагын бер яңа мәхәббәте башлануын шуннан башлап исәпләргә кирәктер, мөгаен.

Юан арканнар тарттырып ринг ясалган җәйге биек сәхнәдән төшүгә, аны таныш һәм таныш булмаган тамашачылар урап алды, ләкин аңа иң якында тимерьюлчылар мәктәбендә укучы егетләр-кызлар булып чыкты, Рушан алар өчен икеләтә үз кеше, чөнки аларга «Локомотив» командасы да кадерле иде.

Әйе, җирле патриотизм ул заманнарда буш сүз генә түгел иде шул. Шуңа охшашрак күренеш соңгы дистә елларда Америкада да шәйләнә, әмма андагы патриотизм илне сөюгә генә кайтып кала — АКШның дәүләт флагы эленмәгән бер генә йорт та юк анда. Мәгәр ил сөючәнлек, мөгаен, гап-гади шәһәр беренчелеген яулап алган үз егетләреңне менә шулай яратудан башланадыр да инде.

Егет-кызлар аны тыгыз боҗра белән уратып алгач, үзенә иң якын торган Ниночка Новова аның финал сугышында каралып-күгәреп чыккан күз төбенә ягымлы бармаклары белән сак кына кагылды да дулкынландыргыч кайгыртучанлык белән:

— Авыртмыймы? — дип сорады.

Рушан җавапка елмаеп кына куйды һәм, уйлап та тормастан, кинәт кенә аңа үзе алган призны — зур бәллүр вазаны сузды. Ул заманнарда, күрәсең, муллык-байлыктандыр — җиңүчеләрне шулай бәллүр әйберләр белән юмарт бүләклиләр, ул бәллүрләр бары тик Гусь-Хрустальныйныкы гына була торган иде.

— Ә бу минем иң гүзәл тамашачыма бүләгем...— диде Рушан.

Кемдер җыелышып истәлек өчен фоторәсемгә төшәргә тәкъдим ясады, Ниночка вазаны Стаингa тоттырып, кечкенә сумкасыннан матур кершән савыты чыгарды һәм Рушанның кабарып янып чыккан күз төбен кершәнләп тә куйды. Яшереп торасы юк, аның шулай кайгыртуын тою Рушанга бик рәхәт иде...

Чемпион белән фоторәсемгә төшәргә теләүче дуслар-танышлар шулкадәр күп булып чыкты, фотограф аларны рәтләп утырта-тезә башлады, Рушан белән Нина иң уртада калдылар.

Кемне кайда утыртырга, кайда бастырырга дип, мәш килгән арада Мещеряков белән янәшә басып торган Светланка, бер җай табып, Рушанга сирень чәчәге ыргытты — аның бу ишарәсен үзләреннән башка берәү дә сизмәде шикелле. Паркта инде бөтен көченә джаз-оркестр дөмберди иде. Сезонның беренче бию кичәсе башланып килә, күпчелек тамашачылар җәйге эстрада театрының бию мәйданчыгына күчтеләр. Зур вазаны кысып кочаклаган Ниночка кинәт кенә Рушанга:

— Синең бүләгең миңа Троя атын хәтерләтә,— диде.— Ышанам, берәр төрле уй-ният белән бирелмәгәндер бит? Мин синең яныңа көч-хәл белән генә үтеп керә алдым, кызганыч, парк ачылган көнне чемпион жетоны белән, үз гомеремдә бер генә булса да, биюгә керергә тырышып, ничек этешкән-төртешкәнемне күрмәдең. «Бүген — яки һичкайчан»,— дидем. Менә шундый инде мин, Дасаев, дан яратучан.

Алар заманында шулай читләтеп, кинаяле-шаян манерада сөйләшергә остарганнар, әйтергә теләгән сүзнең мәгънәсен шактый купшы-кабарынкы төсмерләргә төреп аңлата беләләр иде. Сөйләшүнең мондый төрен Рушан соңыннан беркайчан һәм беркайда да очрата алмады.

— Ни өчен әле ваза синең теләгеңә комачау ясар дип уйладың? — диде Рушан.— Без аны, бөтенесенә күренерлек итеп, музыкантлар янына куеп торырбыз. Ә сине, көтелмәгән шәфкатьчем, бик теләп биергә чакырам...

Нина елмаеп, тагын шаяртып әйтте:

— Биергә кергәндә генә — анда бүген галәмәт чират, сине күргәч, мөгаен, юл бирерләр, контролерга кычкырыбрак әйтерсең әле, яме: «Вазалы кыз — минем белән!» — диярсең.

Яннарында торучылар аңлап көлеп җибәрделәр. Бер атна элек кенә шәһәрдә Феллининың гомерлеккә данлыклы булып калган «Кабирия төннәре» фильмын күрсәткән иделәр. Анда шундый күренеш бар: Джульетта Мазинины ниндидер бер танылган артист ресторан

яныннан үзенең өсте ачык зиннәтле машинасына утыртып алып китеп барганда, кыз, куанычыннан йотлыга-йотлыга, калган кызларга кычкырып уза: «Күрегез, күрегез әле, мин кем белән барам!» Истә калырлык мизгел. Ниночка шул күренешне бераз үзгәртеп кабатлагандай итеп, башкалар алдында Рушанның дәрәҗәсен тагын да күтәреп җибәрде.

Биюләр беткәч, финал сугышлары турында сөйләшә-сөйләшә, алар бер зур төркем булып тимерьюлчылар бистәсенә кайтып киттеләр — Ниночка Новова шунда, Кызыл урамында тора иде.

Ниночка белән Рушанның дуслары-танышлары, Стаинның күпертеп әйтүе буенча, «күренекле» бер үк кешеләр — хәер, бу төшенчә аларның кечкенә шәһәрләрендә телдә киң таралган — һәм алар, әлбәттә, бер-берсе турында барысын да беләләр иде.

Аннары ул заманнарда яшереп-нитеп тору юк, һәммәсен дә эчкерсез, ачыктан-ачык сөйләп бирү бик табигый сыйфат иде.

Билгеле, Ниночка Рушанның Давыдычевага өметсез гашыйк булганлыгын да, Резникова белән «мәхәббәт уены» уйнап алганын да белә — алар беренче сыйныфтан ук дуслар һәм күптән укмашкан бер үк кызлар төркемендә иделәр. Рушан да Ниночка турында шактый мәгълүматлы: Стаин шикелле үк, аның да Ленинград белән хыялланганын белә, табибә булырга теләгәнен дә ишеткән. Аның икенче мәктәптә укучы, борыны бик югары Ренат Кутуевка гыйшык тотып йөргәненнән дә хәбәрдар, ә ул малайның бар яратканы — джаз, төгәлрәге — саксофон икән. Аны хәтта кайсыдыр бер атаклы оркестрда уйнарга да чакырганнар, имеш, дип сөйлиләр иде. Чытлык-чибәр, кешедән көләргә яратучан Нововага бик күпләр күз төшереп, яратулы караш ташлап йөрсәләр дә, ул әле үзе беркем белән дә очрашмый-йөрешми, әмма мәгәр соңгы мәктәп язы иде бит инде. Берәр айдан Ниночка, үзе хыялланганча, Нева буйларына бөтенләйгә китеп барырга ниятли иде.

Әгәр дә икенче көнне тулай торакка Стаин шалтыратмаган булса, парк ачылган көндәге ул кич, мөгаен, шулай бәллүр ваза һәм Нովованың күңелне эретерлек игътибарлы булуы белән генә бәйле бер вакыйга булып калыр иде. Жорик унөченче мәктәптә укучы Галочка Старченконың Рушанны туган көненә чакыруын хәбәр итте, барудан баш тартмавын бик үтенде, анда кызыклы кешеләр җыелачагына ышандырырга тырышты.

Беренче Май бәйрәме киче булса да, Рушанның аерым планнары юк иде һәм ул барырга ризалык бирде. Андый мәҗлесләргә Стаинның борыны бик сизгер аның. Сөйләп тә торасы юк, Жорик күңел ачарга бик маһир: шәһәр яшьләренең «асыл затларча» тормышы аның тирәсендә генә кайнап-гөрләп тора да инде.

## XVIII

Дулкынландыргыч, күңелле туган көннәр, алар туган көн үткәрүчеләргә дә, кунакларга да әллә ничаклы шатлык-куанычлар китерә иде. Хәзер, үткәннәр белән бүгенгене ирексездән чагыштырып, Рушан ул вакытларда бәхетле гаиләләрнең никадәр күп булганлыгын аңлый инде, ызгыш-талашлы, низаглы җирләргә кунак чакырмыйлар бит. Игътибарлы ата-ана мәхәббәте белән чолгап алынган, Стаин әйтүенчә, шулай ук «күренеклеләр»дән булган бер гүзәл кыз үсеп килгән Старченколар гаиләсе дә шундый бәхетле-имин гаиләләрдән иде.

«Күренеклеләр» төшенчәсенә күп сыйфатлар керә: яхшы уку, спортта югары уңышларга ирешүдән алып үзеңчә матур итеп киенә белү, үткен сүзләр әйтү, биюләргә кадәр — кыскасы, үз йөзең булу. «Күренеклеләр» үз буынының «катализаторы»,— ди Стаин. Алар яшьләрне үзара якынайтып-аралаштырып тора, алар йогынтысында мәктәпләр арасында дуслык күпере салына. Юкка гынамыни, икенче мәктәптә — борыны югары, әмма талантлы Ренат Кутуев, кырык дүртенчедә — чибәр акыл иясе Давыдычева белән шәһәрдә иң танылган шагыйрь Валька Бучкин укый, ә яшьләрнең модаларын канунлаштыручы һәм бөтен яхшы гамәлләрнең башында торучы кырык бишенче мәктәпнең лидеры Жорик Стаин, шул ук мәктәпне Светланка Резникова белән Ниночка Новова тәмамлап килә, ә ул язда, Галочка Старченко булганга күрә, унөченче мәктәп тә танылып өлгергән иде инде. Рушанга хәзер үзе берьюлы тимерьюлчыларның ике мәктәбен — кырык дүртенчене дә, кырык бишенчене дә тәмамлаган шикелле тоела — аның мәнфәгатьләре, күңеле ятып, яратып йөргән кызлары шул ике мәктәп белән бик тыгыз бәйләнгән иде бит.

Ул заманнардагы Актүбәнең дүрттән өч өлеше төрле-төрле шәхси йортлардан тора иде. Стаин шаяртып: «Безнең шәһәр инглизләр манерында — гел хосусый биләмәләр»,— дия иде. Старченколар да икмәк заводы артындагы үз йортларында яшиләр икән.

Гаҗәпләнерлек бар: Рушаннарны Галочканың әтисе үзе каршы алды, ул спорт уеннарын карарга бик хирыс икән — Стаин уйный торган «Спартак»ның бер уенын да калдырмый карап бара, кичә паркта Дасаев өчен дә янып-көеп утырган, егетләрнең бүген кызының туган көненә киләселәрен белгәч, бик шатланган.

Рушан белән Жорик иркен бүлмәгә килеп кергәндә, кунаклар «П» хәрефе шикелле итеп куйган өстәлләр тирәли утырыша башлаганнар иде инде. Һәр тарафтан аларны чакырып, исемнәрен атап торсалар да, күбесе Стаинга да, Рушанга да таныш түгел иде — күрәсең, җай чыкканда, Галочка үзенең унөченче мәктәбендәге дуслары белән иркенрәк таныштырырга ниятләгәндер. Кинәт кенә бер читтән Рушанны дәшкән таныш тавыш ишетелде. Борылып караса — Ниночка Новова икән!

— Синең бирегә чакырулы икәнеңне белгән минуттан бирле бу урынны синең өчен саклап торам,— дип елмайды Ниночка.— Син бу турыда кичә бер сүз дә әйтмәгән идең бит. Старченко өчен генә сюрприз түгел бу дип уйла...

Шулай шаяртып сөйләнә-сөйләнә, ул Рушанга шундый ягымлы итеп төбәп карады ки, егет ирексездән Яңа ел кичен, колонна янында басып торганда Резникова әйткән сүзләрне исенә төшерде: «Син минем әсирем, без бүген кире кагылган ике бәхетсез җан...» — дигән иде ул.

Күп еллардан соң, Мәскәүнең эстрада театрында Аркадий Райкинның «Светофор-2» дигән программасы премьерасында булган иде Рушан, шунда аны бөек артистка хас булмаган мизансцена — сәхнә күренеше таң калдырган иде. Сәхнәдә, ярым караңгыда чиратлашып ун кеше басып тора: ир кеше — хатын-кыз, ир кеше — хатын-кыз, ләкин аларны парлылар дип әйтеп булмый, юкса барысы да бер-беренә гашыйклар, әмма ялгышып гашыйклар — бу хакта аларның хатлары, телефоннан шалтыратышулары, сөю, наз, дәрт-теләк тулы ялварулары, үзләрен корбан итәргә әзер торулары сөйли. Аларны башкача тезеп, телефоннарын алмаштырып ялгап куйсаң, һәркайсы бәхетле булыр төсле иде, аларның һәркайсы мәхәббәткә сусаган, мәхәббәткә лаек, газаплана, ләкин бөтен фаҗига да шунда шул, бу хәлне үзгәртерлек көч юк — һәм алар унысы да бәхетсезләр.

Берсенев яр буе урамындагы театрның ярым караңгы залында утырганда, Галочка Старченконың күптән үткәрелгән туган көне искә төшеп, шундый ук бер рәт тезелгән иде: Ниночка Новавага гашыйк Наил Сафин Та-

мара Давыдычева белән очрашып йөри, ә Давыдычеваның күңелен яулый алмаган Рушанга Ниночка мөкиббән китеп карый. Язмыш аларның урыннарын алыштырып куйса, барысы да менә дигән булыр иде, Рушанның Нововага кирәге булмаган кебек, Наилнең дә Тамарага кирәге юк бит. Ләкин бөтен бәла шунда, бер нәрсәнең дә, беркемнең дә урыннарын алмаштырып куеп булмый — менә шунда ахырына кадәр ачылып бетмәгән тагын бер сер...

Еллар үткәч, инде яшисе яшәлгәч, әлбәттә, Рушанга барысы да ачык шикелле, ә теге вакытта...

Телгә оста Стаин нинди матур тостлар әйткән иде! Беркемне дә игътибарыннан читтә калдырмады шикелле: туган көн хуҗабикәсен дә, кешелекнең гүзәл яртысын да, Дасаевның кичәге җиңүен дә, бокска, бокстан бигрәк чемпионга ихлас мөкиббән Ниночканы да — һәммәсенә дә җылы һәм ягымлы, шаярулы һәм купшыкүперенке сүзләр әйтелде. Читтән карап торганда, бу, бәлки, ясалма боргалау-сыргалау, кылану булып та күренгәндер, әмма яшәү рәвешләре шундый — аларның ул чагында ничектер башкачарак тормышта гомер кичерәселәре килә иде...

Җылы май киче. Киереп ачып куелган тәрәзәләрдән кергән фарсы сирене белән шау чәчәктәге алмагачларның исе шәрабсыз да исертә иде шикелле. Яшереп торасы юк, кызыл аракысын да, шампан шәрабын да эчтеләр. Ихтимал, бу көнне өстәл тирәсенә бары тик гашыйклар гына җыелган булгандыр, өстәл өстендә дә, залда да, Галочканың йокы бүлмәсендә дә кайнар мәхәббәт сулышы тирбәлә, күптән вәгъдә ителгән үбешүне алыр өчен кемнәрдер әлеге бүлмәгә шыпырт кына кереп югала да иде инде. Егетләрнең күзләре яна, кызларның яңаклары матур алсуланып чыккан!

Берьюлы һәркемне дә чолгап ала торган нindидер хистойгылар барлыгын фән күптән исбат иткән. Әлеге шул май кичендә андый халәт бары тик сөю хисеннән генә була ала иде, сөю хисе сихерле, хәтта әле үзенең канаты кагылмаган егет-кызларны да өметләндерә иде. Элвис Пресли рок-н-ролларыннан алып Джонни Холлидей бугивугиларына кадәр төрледән-төрле музыка яңгырый; аларны ни өчендер моңсу-минор көйләр алыштыра, ә соңыннан залга танго аһәңнәре агыла. Һәм янә, Яңа ел төнендәге шикелле, Батыр Закировның моңлы-сагышлы җыры ишетелә, аның атаклы «Гарәп тангосы» бу.

Әле ярый залдагы утны күптән сүндергәннәр иде, Ниночка, Рушанның дулкынлануын, тәне калтырануын сизенсә дә, бу минутларда аның күзләрен күрә алмый,

һәммәсе дә әле кайчан гына булып узган иде бит, Батыр Закировның җыры кабат-кабат шуны Рушанның исенә төшереп тора иде...

Рушанның кәефе китте, биюләр туктап торган арада ул Стаинга инглизчә югалырга, ягъни сиздерми генә чыгып сызарга тәкъдим итте. Әмма Жорик ул кичнең ачышы булган ниндидер Зиночка яныннан һич китә алмый. Ул кыз өчен бу кичә, Наташа Ростованың беренче мәртәбә балга килүе кебек үк, егетләр-кызлар арасына беренче чыгуы иде һәм кинәт кенә шундый уңыш — егетләрнең күбесе аңардан күзләрен ала алмый.

Әмма Стаин, дустының төшенке кәефен чамалап алып, әйтеп куйды:

— Китәрбез, ләкин берәр сәгатьтән, кичәнең шигъри бүлеге беткәч,— диде. Бучкинның, яңа шигырьләрен укып, тыңлаучыларны таң калдырырга җыенганын ишеткән иде ул. Кичәләрдә шигырьләр уку күптән гадәткә кергән, һәр төркемнең танылган үз шагыйрьләре бар, алар арасында Валентин Бучкинга тиңнәр юк иде. Башка шагыйрьләрнең шигырьләрен уку да гаепкә саналмый, әмма автор лирикасына өстенлек бирелә, бу мизгелләрне бигрәк тә кызлар түземсезләнеп көтә, чөнки кайвакытларда шигырьгә яшерен мәхәббәттә аңлашулар да салынган була иде...

Шигърият өчен гаҗәеп игелекле заман иде ул. Хәтта Стаин да танылганлык ягыннан Бучкин белән ярыша алмый — шигъри сүз, рифма тылсымлы көчкә ия иде. Валентин ул кичтә Старченколарга Верочка Фролова белән килгән иде, аның белән дуслашып йөрүе әллә ничек шаушулы, борчылулы кичерешләр тулы, юкса, араларына кереп, бозылыштырырга тырышучылар да күренми иде кебек. Бучкин Верочканы үзенең Беатричесе дип атый, кайда гына барса да, башка кызларның үзенә төбәлгән сокланулы карашларын күрми дә, ул бит мәхәббәт турында шундый матур шигырьләр яза — башкаларны күрерлек дәрәҗәдәме соң монда?

Ул кичне Валентин моңсу күренә иде, әмма хуҗабикә, кинәт кенә радиоланы туктатып: «Шигърият сәгате сукты!» — дип игълан иткәч, Бучкин шигырьләрен сөйләп кунакларны куандырудан баш тартмады. Гадәткә кергән тәртип буенча, беренче булып ул сөйләде, аның моңлы карашы ярым караңгы зал аша Верочкага төбәлгән, ә кыз, ни өчендер ачык бизәкле чегән шәленә төренеп, голланд миче тирәсенә елыша төшеп утырган иде.

Моңлы Валентин кунакларга дөрестән дә искиткеч матур шигырьләр бүләк итте, ә Верочканың ачык тәрәзәдән

кергән ай яктысы белән яктыртылган йөзендә ни сөю, ни шатлык чагылмады. Дасаевка бу күренеш чын түгелдер кебек, сәер тоелды, аның: «Сез бит бергә, нигә моңаясыз, нигә бу күзләрдән яшь китерерлек сагышлы шигырьләр?» — дип, кычкырып сорыйсы килде. Монысы да Рушан өчен гомерлек сер булып калды. Валентин белән алар бүтән беркайчан да очрашмадылар, озак еллар газет-журналлардан аның исем-фамилиясен эзләсә дә, Бучкинның басылган шигырьләре дә күзенә чалынмады. Ул кичне Валентин аңа үз һәм кадерле иде — бәлки, шигырьләре, бәлки, суынып беткән мич янындагы кызга төбәлгән моңсу карашы моңа сәбәпче булгандыр.

Бу елларда без күп сөйдек,
Безне генә сөймәделәр...

Залдагы бердәнбер кәнәфине биләп алган Ниночка ишек уемына каршы утыра, коридордан төшкән яктылык аның йөзен бик ачык яктыртып тора иде. Кыз, вакыт-вакыт әсәрләнеп, чәчләрен төзәтеп куя, нечкә җепкә тезелгән энҗе муенсалы озын муеныннан аларның авырлыгын алып ташларга тели кебек иде. Валентин шигырь укый башлагач, ул бөтен гәүдәсе белән алга таба авыша төште, аның бар игътибары шигырьдә — сылу гәүдәсеннән нәфислек, гүзәллек, яклаучысыз гаҗизлек бөркелеп тора иде. «Аккош,— дип ирексездән уйлап алды Рушан.— Аккош-кәләш...»

Рушанга аны күзәтеп утыру рәхәт иде, әмма кыз һәр шигырь саен урынына сеңгәннән-сеңә төшә, хәрәкәтләре борчылуын сиздерә, сокланулы карашы күз алдында тоныклана-сүнә бара иде. Бу минутларда Рушан шигъри сүз сәнгатенең тылсымлы көчен җаны-тәне белән тойды. Моңсу шагыйрьнең тыңлаучылар белән уртаклашкан хисләре кызга да таныш, аңлаешлы һәм ул хиснең үз исеме бар — җавапсыз мәхәббәт.

Валентин соңгы шигырен тәмамларга җыенганда, Ниночка кәнәфиенә бөтенләй сеңеп беткән иде, Рушан аның дулкынланудан агарып калган бармаклары белән кәнәфигә чытырдап ябышканын күрде. Аның янына барып, ниндидер ягымлы сүз әйтәсе, өметләндерәсе, нәфис муеныннан үбеп аласы килде. Эх, әгәр дә ул, Стаин кебек, дулкынландыргыч сүзләр әйтә белсә икән! Мисал өчен шундыйрак сүзләр: «Бүген нинди гүзәл сез, мадемуазель Новова!» яки: «Матур ягымлылыгыгызның серләре белән уртаклашыгыз әле, сылу Нина, сез һәрвакыт шундый сөйкемле...» Ләкин Рушан андый сүзләрне әйтә алмый, әйтә дә белми, кая инде башка берәүнең күңелен

күтәрү, бу мизгелдә сагыштан аның үзенең дә күзләре дымланган иде. Юкса, Нововага карата сөйләп биргесез якынлык тоеп, аның гүзәл йөзендәге сагышны юып алу өчен теләсә нәрсә эшләргә әзер иде ул.

Дивар буенда Зиночканың артында басып торган Жорик, вакыт-вакыт кызга таба иелеп, аның колагына нәрсәләрдер пышылдый, әмма Нинадан кул сузымы гына ераклыкта утырган Зиночка Стаинның кайнар пышылдауларын ишетми дә иде бугай. Ул да мәктәп кызлары арасында данлыклы булган шагыйрьдән күзләрен ала алмый, аны ошатканлыгы күренеп тора. Күпләрнең йөрәген яндыручы Стаин аны бу тылсымнан араларга тели, ләкин хәтта Жорик та шигърият белән, шагыйрь белән ярыша алмый иде шул.

Валентин шигырь сөйләүдән туктагач, залда беркавымга каушап-аптырабрак калган шикелле булдылар. Стаин тиз генә коридорга чыкты да Рушанга ымлыйишарәли башлады, ул Старченколардан шыпырт кына чыгып китәргә җыенганнарын исендә тота иде. Шул чагында көтелмәгән бер хәл булып алды, Рушан аны соңыннан гомере буена аңларга тырышып караса да, хәтта бүген — «хризантемалары чәчәк койгач» та — аңлап бетерә алмады — монысы да, мөгаен, мәхәббәт серләренең берсе булгандыр.

Әле күптән түгел генә, март аенда көн саен хат ташучыны көтеп торган һәм Светланкага хат салыр өчен төнге поездга йөгереп төшкән көннәрдә аның кулына ничектер Лермонтов томы килеп кергән иде. Шул еллардагы дус-ишләренең күпчелеге шикелле, ул да шигъриятне яратып өлгерде, гомерлеккә шигъриятькә гашыйк булып калды һәм бүген ышаныч белән әйтә ала: «Шигъриятне яратыгыз, ул, чынлап та, күп кенә бәлаләрдән, авырлыклардан качарга булыша. Коръәндәге шикелле үк, шигърияттә дә тормышның барлык сорауларына да җавап табарга була, бары тик үз шагыйрегезне, үзегезгә ярашлы шигырьләрне генә эзләгез, алар бар...» Шуңа күрә, Светланканың Мещеряковка кияүгә чыгарга җыенуын белгәч, шунда ук кайдандыр тирәннән күңеленә шигырь юллары килүе бер дә гаҗәп түгел иде:

Шундый озын кыш булды бу,
Шундый озак аерылу.
Кар астында калдык бугай,
Карасак та каерылып...
Гафу сорап кул сузудан
Җиңелрәктер, мөгаен,
Кирегә бер борып кую
Озын-озак кыш аен.

Гореф-гадәт диеп торма,
Җыештыр фатирыңны...
Себереп түк кар өстенә
Сагышлы хәтереңне...

Китапның ахырына таба беренче ачылган биттә үк Арбенинның «Маскарад» поэмасындагы таныш монологы Рушанның күзенә ташланды:

Тыңла, Нина, көлке мин, билгеле,
Сине үлеп сөю көлке түгелме?..

Бу юллар шулай ук Рушанның шул вакыттагы кәефен тулысынча чагылдыра иде, бары тик Светлана исеме генә шигырь ритмына ятмый-ябышмый, ә болай — әйтерсең күңеле кушып язылган, дөресрәге, үз шигыре кебек яңгырый иде ул юллар. Һәм алар үзеннән-үзе бик җиңел генә хәтергә сеңеп калган, ятланган, Рушан аны, очрашкач, ничектер бер җаен китереп, Резниковага укырга да җыенган иде, әмма аралары көтмәгәндә өзелде дә... бу шигырь юллары яңадан бервакытта да кирәк булмастыр төсле иде инде. Һәм менә...

Кызлар, этешә-төртешә, Валентиннан соң бер-берсен шигырь сөйләргә кысташкан арада, Рушан Стаинга ымлады да ишеккә юнәлде һәм, кинәт бусагада тукталып, борылып карады. Нина аның чыгып китәргә җыенганын сизенде шикелле, моңсу күзләре белән аңа күтәрелеп карады, ул күзләр: «Син дә мине ялгыз калдырып китәсеңмени инде?» — дип үтенәләр төсле иде. Шуннан ул тәкәллефле итеп капылт кына артка чигенде, яктыртылган ишек уемында һәркемгә дә яхшы күренеп торган килеш, бары тик Нинага гына карап, Лермонтовның шул атаклы шигырь юлларын сөйли башлады:

Тыңла, Нина...

Рушан ниндидер бер сәер халәттә иде — рингта каты китереп сукканнан соң оста саклана белү хәрәкәтләре үзен нокауттан коткарып калган шикелле, шигырь юллары да бер-бер артлы аңа ышаныч өсти, үзен тынычландыра һәм чынбарлыкка кайтара иде.

Шулай ук рингтагы шикелле, тирә-юньне күләмле итеп күрү сәләте кинәт кенә ачылып китте. Ул әүвәле, нәрсә булганын аңламыйча, авызын кызык кына итеп ачып катып калган Стаинны күреп алды — тегесе мыштым Дасаевтан, әлбәттә, моны көтмәгән иде. (Соңыннан Жорик Рушан булып кыланып, бу күренешне бик озак кабатлап күрсәтеп тә йөрде әле.)

Әмма бер мизгелгә генә күзенә чалынган Стаин өчен Рушанның исе китми, ул Нованың могҗизаи рәвештә

күз алдында үзгәрүен күрә. Кыз кәнәфидән күтәрелә төште, матур канатларын кагып очып китәргә әзерләнгән аккош төсле, ягымлы карашы белән егеткә тартылды, йөзенә сөйкемле алсулык таралды. Җанланган моңсу иреннәре нәрсәдер пышылдый, Рушанны хуплап дәртләндергән шикелле иде.

Барлык кунакларның да шигърият сәгатенең иң югары ноктасы, сюрпризы, шигырь белән аңлашу мизгеле шушы икәнен төшенеп, тын да алмыйча үзләренә карап торганнарын сизенсә дә, шушы минутларда кыз өчен бу дөньяда башка беркем дә юк, алар икәүдән-икәү генә кебек иде. Ул, кичә башлангандагыча җиңел генә матур хәрәкәт ясап, калын-авыр коңгырт чәчләрен янә муеныннан алып, артка чөеп җибәрде — үз бәясен белгән бу иркен хәрәкәт: «Менә мин нинди! Миңа менә нинди шигырьләр багышлыйлар!» — дигәнне аңлата иде.

Хәзер, еллар үткәч, Рушан ул гамәленең гүзәл Ниночка белән мәхәббәттә аңлашу булып яңгыраганын кире какмый инде, ләкин теге чакта булса...

Лермонтов шигыренә ул барлык газапланган күңел авыртуларын, мәхәббәтенә җавап ала алмаган йөрәгенең өзгәләнүен салган иде. Бу аның менә-менә гомерлеккә аерыласы дус-ишләренә соңгы хушлашу сүзе кебек булды. Юкса ул үзе кунакчыл Старченколар йортында бу матур май кичендә Нина белән икесенең бер үк төсле бәхетсез һәм ялгыз икәнлекләрен генә аңлатырга теләгән шикелле иде.

Әмма хисләрне, бигрәк тә менә шундый көтелмәгән гамәлләрне тикшерү — катлаулы эш. Рушан хәзер дә берничек тә аңлата алмый һәм аңлату кирәкмидер дә.

Кинәт кенә бәреп чыккан шигырь юллары шулай ук көтмәгәндә генә бетеп тә куйдылар, Рушан, ни үзен ишек янында көтеп торган Стаингa таба атларга, ни артка чигенергә, ни Нинага кулларын сузарга кыймыйча, аптырап калды. Биек түшәмдәге люстраның балкып кабынып китүе һәм урыннарыннан күтәрелгән кунакларның көтелмәгән кул чабулары коткарды.

Шуннан ары беркем дә шигырь сөйләргә базмады. Элеккечә тирә-юнендәге берәүне дә күрмичә, Ниночка аңа таба күтәрелгәндә генә залда яңадан ут сүнде, шул мизгелдә үк «Гарәп тангосы» яңгырады. Кыз, Рушанның иңнәренә ике кулын куеп, дулкынланган йөзен аңа якынайтты һәм әкрен генә пышылдады:

— Мин шундый бәхетле, рәхмәт, сөеклем...

Рушанның яңа мәхәббәтен,— юк, бу юлы «мәхәббәт уенын» түгел,— ә нәкъ менә мәхәббәтен Галочка Старченконың шул туган көненнән башлап исәпләргә кирәктер дә.

## XIX

Май ае алар ягында, һичшиксез, иң матур ай. Дала киңлекләренә яз соңлап килә, табигать май аенда гына көч-куәт ала, агачлар яшелләнеп яфрак яра, һәр түрбакчада сирень-сәрби куаклары чәчәк ата, ә Кызыл урамындагы кечкенә бакча, шау чәчәктәге алмагачлар чатырыннан төтенгә уралгандай, ап-ак булып утыра. Соңрак, тормыштан иртә киткән җырчы композитор Евгений Мартыновның «Алмагачлар чәчәктә» дигән мәгълүм җыры килеп чыккач, Рушан күптәнге шул май аен еш кына хәтеренә төшерә иде.

Шул май ае ахырларында бит инде, бервакыт Нина аңа:

— Без синең белән хөкем ителгән кешеләр шикелле,— диде.

Рушан аның нәрсә әйтергә теләгәнен аңлап алды.

Әйе, хөкем карарын белгән тоткыннар ирексездән көннәрен санап барган кебек, үзләренең китәсе көннәрен белгәнлектән, алар да аны киртләп-билгеләп торалар иде. Ул вакытта инде Рушан Ходай каргаган Кызыл-Ордага эшкә билгеләнгән, ә Нинаны, Стаин сүзләре белән әйткәндә, Төньяк Пальмирасы — Ленинград көтә иде.

Шуңа күрә алар, кулдан ычкынган элекке көннәрен кайтарырга теләгәндәй, һәр көнне күрешеп тордылар. Ничектер зурларча теләк-дәрт белән, ярсып-өзгәләнеп, бер генә күңел ачудан да баш тартмыйча, очраша иделәр. Алар үзләрен «дроголята»лар арасында да, парктагы җәйге ресторанның верандасында Исмәгыйль бәк һәм аның дуслары янында да, Стаинның нәзакәтле-зыялы дусишләре белән дә иркен хис итә иделәр. Ул язда аларның сөйләп аңлатып булмастай ниндидер тарту көчләре бар иде, алар тирәсенә һәрвакыт дус-иш, таныш-белеш, спорт сөючеләр, аларга табынучылар җыела, ваемсыз-чая күңел ачулар башлана, шаяртулар, уен-көлке ишетелә. Мөгаен, күпчелек егет-кызларның да бер-берсе белән һәм Актүбә белән гомерлеккә хушлашачакларын күңелләре тояңлый иде.

Күңел ачуларда Ниночка тыелгысыз булып чыкты, дәрт-җегәре ташып тора, фантазия дигәндә, Стаиннан кала һәммәсе дә аңардан калышалар. Парктагы биюләрдән кайтып килешли, берәр тын скверда яки берәрсенең түрбакчасында кинәттән нинди генә уен-көлкеләр оештырылмый, уйлап чыгарылмый да гитарага кушылып нинди генә җырлар җырланмый иде! Элекке мыштым, уйчан Нcovoваны беркем дә таный алмый, мәсәлән, берва-

кыт ул бию мәйданчыгына билет тикшереп торучы контролерны үртәп:

— Бу яшь егет — минем белән,— дип, гәүдәсен нәкъ Дасаевча хәрәкәтләндереп, аныңча кыланып куйды, керергә чират көтеп торучылар дәррәү кул чаба башладылар.

Кыскасы, алар тәүлекләрне озынайтырга тырышып, иртә таңга кадәр аерылышырга куркып, күңел ачып йөрделәр, ә вакыт дигәнең ага, йомшак күндәй кыскаракысыла торды. Һәм менә Ниночканың Ленинградка китәренә дә өч кенә көн калды.

Рушан, эшсезлектән бөтенләй гаҗиз булып, тулай торактагы караватында аунап ята иде. Диплом яклау артта калган, бер атнадан аларның чыгарылыш кичәсе, шуннан соң ул да хыяллары тормышка ашкан һәм ашмый калган бу шәһәрне ташлап китәчәк.

Һәм ул, моннан нәкъ дүрт ел элек техникумга керер өчен документларын Актүбәгә китергәндә, шушындый ук эссе июньнең көн уртасында, тиз йөрешле Ташкент поездының вагоны түбәсендә барганын исенә төшерде. Авыл малаена бу шәһәр нинди зур, серле, ымсындыргыч булып күренгән, уку әйтеп бетермәслек кадерле булып тоелган иде — һәм менә барысы да бер генә көн шикелле үтте дә китте, янә тормышның яңа йомгагын сүтәргә, янә бөтенесен дә яңадан башларга кирәк.

Комнарга күмелеп утырган Кызыл-Ордада аны ниндәрсәләр көтә? Нинди дуслар табылыр, нинди күңел ачулар булыр? Бу сәгатьтә аның күңелен шундый моңсу уйлар биләп алган, әмма шулай булса да, ирексездән вакыт-вакыт Нина белән алда торган очрашуны күзаллап, йөзенә елмаю да куна иде.

Соңгы көннәрдә җәйге төн аларга шундый кыска тоела, бигрәк тиз яктыра башлый, Алма-Ата экспрессының озын-озын гудок тавышлары очрашуларны өзә. Ниночка авыр көрсенеп әйтеп куя:

— Хушлашырга вакыт, сөеклем! Июньдә соң караңгыланып иртә яктыруы бик кызганыч, әмма без синең белән табигатьне буйсындыра алмыйбыз...— ди.

Рушанның алдагы күрешү турындагы татлы уйларын алар бүлмәсенә болай гына башын тыккан күрше егете бүлдерде. Рушанны күргәч, ул гаҗәпләнеп сорады:

— Нишләп ятасың, Ниночкаңны озатмыйсыңмыни? Мин әле генә вокзалдан кайттым, аны перронда әти-әниләре белән күрдем, китеп бара...

Рушан караватыннан ничек атылып торганын сизми дә калды.

— Ничек китеп бара? — дип кабатлап сорады ул, көтелмәгән хәбәрнең асылына төшенеп җитә алмыйча.

— Бик гади генә,— дип көлемсерәде күрше егет.— Сигезенче купе вагонында. Ашык, Мәскәү поезды кузгалырга әле ун минут бар, мин вокзалдан велосипедта...

Рушан, аның соңгы сүзләрен тыңлап та бетермичә, ачык тәрәзәгә ташланды һәм күз ачып йомганчы урамга сикереп төште. Юлда очраган ялгыз кешеләрне куркытып, әлсерәткеч эсселекне дә тоймыйча, юл буендагы карагачлар күләгәсенә дә ышыкланмыйча, бар көченә йөгерде ул, аның шашкан йөзенә карап, кемнәрдер, берәр бәлаказа бардыр, дип уйлаганнардыр.

Тимер юлга йөгереп килеп җиткәч, ул вокзалга таба тәгәрәгән так санлы составны күреп алды. Егылып төшү куркынычын да уйлап тормастан, йөгергән уңайга нефть цистернасының баскычына сикереп менә алды. Товарнякны әй ашыктырды да соң! Пассажир поездының соңгы вагоны артындагы сигнал утларын бик яхшы күреп алды — экспресс кузгалмаган иде әле.

Товарняк, йөрешен әкренәйтеп, йөк составлары куела торган ян юлга борыла башлагач, Рушан юл арасына сикереп төште һәм яңадан йөгереп китте, перронга барып җитәргә берничә дистә метр гына калган иде.

Ул ничек тә өлгерергә тиеш! Кызның йөзен, күзләрен күрергә тиеш, булдыра алса: «Ни өчен әйтми-нитми китәсең? Ни өчен шундый рәхимсез, кешелексез адым ясыйсың?!» — дип сорамакчы була. Әйтерсең шушы сорауларның үзен гомер буе газаплаячагын шул вакытта ук тойган...

Рушан перронга йөгереп менгән иде инде, койрыктагы вагон калтыранып тартылып куйды да кузгала башлады, егет соңгы көченә алга ыргылып уникенче, унберенче, унынчы вагоннарны артта калдырды. Бу сәгатьләрдә вокзалда озатучылар күп иде, аларны аралый-аралый йөгергән Рушан тизлеген киметте. Тыны кысыла-кысыла, ул тәгәрәп барган тугызынчы вагон янәшәсеннән йөгерә һәм ачык тәрәзәдән башын тыгып, кул болгаучы Ниночканы да күрә иде. Кемгә кул болгый ул? Рушан һич югында аның күзенә чалынырга теләп, бар көченә алга ташланды, әмма тугызынчы вагон аны узып бара иде инде, аннары унынчысы, унберенчесе... Һәм ул, әле һаман да кемгәдер кул болгап баручы кызның нечкә кулларыннан күзен ала алмыйча, хәлсезләнеп туктап калды.

Нинаның әти-әниләре аны шунда ук күреп алдылар һәм, мөгаен, поездның тизләгәннән-тизли баруына шат-

ланганнардыр да әле. Бу башсыз егетнең китеп баручы поездга сикереп менүеннән дә курыкканнардыр, бәлки. Ләкин ул минутларда Рушанның башына андый уй килмәгән иде шул.

Соңгы вагон күздән югалгач, Рушан борылып карады һәм үзенең Ниночканың әти-әниләре янында басып торганын күрде. Елаган йөзен күтәреп карарга оялып, картларча бөкрәя төшеп, ул әкрен генә китеп барды. Ул аларга нәрсә әйтә ала иде соң? Алар үзләре дә барысын да күреп тордылар бит.

Шул кичтә ул гомерендә беренче мәртәбә Стаин һәм Татар бистәсе малайлары белән исергәнче эчте. Парктан тулай торакка кайтып барышлый, Бучкин белән Фролованы очратты.

Валентин көндез вокзалда булган хәлне ишеткән иде инде, станция янәшәсендә яшәүче Верочка, Мәскәү поездына китерелә торган яңа пешкән ипи алырга дип, перронга килгән икән дә барысын да күреп торган. Валентин Рушанны үзләренә алып китте, алар төне буе сөйләшеп чыктылар. Иртән кухняда чәйләп утырганда, Валентин кинәт әйтеп куйды:

— Синең бу тарихың шигырь сорый, тыңла әле, менә:

Үбешүләр тәмен татыдым мин,
Бәхетем чиксез ташып тора иде...

Ләкин Рушан кул гына селекте:

— Тукта, кирәкми, синнән башка да эчем поша...

Хәзер, күп еллар үткәч, Дасаев шагыйрьне ник туктатканына үкенә. Алга таба нинди шигъри юллар булды икән? Чишелеше табылмаган сер. Ә шигырьнең теге ике юлы гомергә истә калган: үбешүләр тәмен татыдым мин...

Диплом тапшырыласы чыгарылыш кичәсенә кадәр калган көннәрен ул, шәһәргә чыгып та тормыйча, тулай торакның сәгать саен бушый барган бүлмәләрендә бер эшсез-максатсыз буталып тик йөрде. Ниночка киткәндә күз алдыннан вагоннар ничек тиз йөгереп узса, көннәр дә шулай тиз уза торды: биш, дүрт, өч... Ә ул исә аларны һаман да ашыктыра — биредәге тормыш аңа хәзер түзә алмаслык булып тоела иде.

Әгәр дә Резникова белән аралары өзелүне ул әле үзенә ничектер аңлатырга тырышып караса, Нованың качып китеп баруын ул котылгысыз явыз язмыш, үзенең... хыянәтенә җәза дип кабул итте. Ул бит кайвакытларда, барыбер йоклый алмасын белеп, төн уртасында үзе өчен куанычсыз «1905 ел» урамына әкрен генә барып чыга иде дә Тамараларның йокылы йорты тәрәзәләре каршында озаклап басып тора иде... Күңеленнән кыздан гафу үтенә,

йөрәгендә нинди утлар кайнаганын аның сизенмәвенә офтана. Ул көннәрдә нинди дә булса берәр җирдә кемнәрдер, кыз күңеленә тияргә, аны чәнчеп алырга теләп, кайчандыр аңа турылыклы булган Дасаевның хәзер бик еш гашыйк була башлаганын телгә алсалар, Тамараның горур гына:

— Әгәр дә бу шәһәрдә кемне дә булса яраткан икән, ул бары тик мине генә чынлап яратты. Бу хакта ялгышмагыз...— дип җавап биргәнен дә белә иде Рушан.

Кайвакытларда ерактан күзәтеп йөрсә дә, ул аның күзенә чалынырга базмый иде. Аның караңгы тәрәзә төбен саклап торган төннәрнең берсендә Рушанның башына бер уй килде: Тамара белән хат аша булса да саубуллашырга кирәк, араларында ни мәхәббәт, ни дуслык барып чыкмаса да, бу шәһәрдә аларның исемнәрен яшьләр гел янәшә куеп йөрттеләр ич, уен-муен түгел бу сиңа!

Көтмәгәндә күңеленә килгән карар аның тормышын вакытлыча гына булса да мәгънәле иткән иде. Ул, көннәр буе өстәл яныннан кузгалмыйча, ачык почеркы белән өч дәфтәрне язып тутырды, әмма аларны хат дип әйтүе кыен иде, дөресрәге — газапланган, буталып беткән күңелен яшермичә ачып салу иде ул. Кызның үзе өчен кем булганын һәм хәзер дә кем булып калганын аңлатырга тырышу иде. Димәк, тормышының кояш баешы алдыннан бүген тәүбәгә килергә, барысын да чын күңелдән әйтеп бирергә теләве — беренче генә түгел...

Ул заманнарда иске акча белән биш сумга сыра алып әбәт ашарга мөмкин булган һәм әле күпмедер көмеш тиеннәр дә кайтарып бирелә торган депо ашханәсенә ашарга барган арада гына Рушан Давыдычевага язган «хатларыннан» өзелеп тора иде.

Беркөнне әбәт ашап кайткач, ул Моряк кушаматлы бүлмәдәше Юрий Калашниковка тап булды, тегесенең күзләре елаудан шикле рәвештә кызарынып чыккан иде.

Тулай торакта бу егетне Рушанның адъютанты дип кенә йөртәләр, ул аңа мөкиббән киткән егетләрнең берсе иде.

Рушан:

— Кем рәнҗетте? — дип сорады.

Моряк борынын мышкылдатып читкә борылды да өстәлдә яткан дәфтәргә ымлады:

— Син Томканы шулкадәр яратасың икән... Синең язганнарыңны укыгач, тәннәрем чымырдап китте, кызгандым үзеңне. Беркайчан да шулай өзгәләнергә мөмкиндер дип уйламаган идем. Укыганым өчен гафу ит инде,

өстәлдә ачык килеш ята иде бит...— дип, аптырашта калган Дасаевны кочып алды.

Күңеле бигүк йомшак булмаган Моряктан Рушан мондый гамәлне һич көтмәгән иде.

— Әйдә, мәхәббәт өчен, Тамара өчен эчәбез! Мин инде бер шешә дә алып кайтып куйган идем,— дип, көтелмәгән тәкъдим ясады Калашников.

Шәраб эчеп утырганда Моряк кыз янына хушлашырга Рушанның үзенә барырга, билгеле инде, хатны да үз кулына тапшырырга кирәклегенә ышандырды.

Рушанның Актүбәдәге соңгы киче, чигенер урын юк — иртәгә кич белән ул бу шәһәрне бөтенләйгә ташлап китәчәк. Әбәттән соң, язылган дәфтәрләрен кыстырып, ул «1905 ел» урамына китте.

Кыңгырау тавышына Тамара үзе чыкты һәм шунысы сәер, Рушанның килүенә бер дә гаҗәпләнмәде. Гүя көтеп торган шикелле, елмаеп, өйгә керергә чакырды, әмма Рушан кереп торырга кыймады. Кичә диплом алганын, бүген үзенең соңгы киче икәнен, иртәгә бөтенләй китеп барачагын әйтте һәм үзе белән хет бер кинога баруын үтенде. Дәфтәрләрен сузып, өстәде: «Ә монысы минем сиңа әллә кайчаннан бирле әйтәсе килгән сүзләрем...» — диде. Тамара дәфтәрләрне илтифатлы гына кабул итеп, аның үзен кич кино-фәләнгә алырга кайчан килерен сорады.

«Өнемме бу, төшемме?» — дигәндәй, моның чынбарлык икәненә һаман да әле тулысынча ышанып җитмәсә дә, күңеленнән акыллы киңәше өчен Морякка рәхмәтләр укый-укый, ул килер вакытын билгеләде. Моряк аның «хатларына» күз төшермәгән булса, Дасаев Тамара янына килергә базыр идеме икән? Ай-һай!..

Тулай торакка кайтып барышлый, юлда ул Наил Сафинны очратты, тегесе Рушан әле генә китеп барган йорт ягына таба атлый иде. Рушан аның белән баш кагып кына исәнләште, үзенең шатлык-куанычын сиздереп тормады.

Мескен Наил, Рушанның Резникова яки Новова өчен кирәге шулкадәр генә булган шикелле, Тамара өчен аның да кирәге шулкадәр генә булганлыгын аңлый идеме икән? Алар икесе дә, әлеге кызларның ниндидер хәйлә-мәкерле уеннарында билгеле бер роль башкарганнан соң, кызларга кирәкләре калмагач, сәхнәдән куылып төшерелмәделәрме? Моның шулай булганлыгын Рушан әле шул чагында ук аңлаган иде.

Билгеләнгән сәгатьтән күп алда килеп, кыз йортының каршысында, инде чәчәген койган сәрби куаклары

күләгәсендә басып торганда да, ул әле, янкапка ачылыр да аннан Тамара килеп чыгар дип, бөтенләй ышанып бетми иде. Шунда ул кинәт кенә теге ерактагы кызны хәтерләп алды: шәһәргә килүенең беренче көнендә үк Рушан бит, кулына ноталар папкасы тоткан ул кызны «Тимерлек» янында очратып, сихерләнгән кебек, аның артыннан ияреп китеп барган һәм нәкъ менә шушы урында, ачык тәрәзәдәге челтәр пәрдә артында кыз шәүләсе күренүгә өметләнеп, бик озак басып торган иде. Һәм менә бүген — беренче сүз куешып очрашу, бу очрашуга юл бик озын — дүрт елга сузылган булып чыкты.

Тамара билгеләнгән минутның минутында күренде, ерактан ук сокландыргыч елмаеп, инде күптәннән очрашып йөргән шикелле итеп, табигый гына сорап куйды:

— Йә, бүген без кая барабыз, Рушан?

Рушан парк янындагы «Культфронт» кинотеатрына билетлар алган иде, «Адские водители» (татарчасы «Тәмуг шоферлары» буладыр инде) дигән инглиз фильмына керергә тәкъдим итте, ә аннары, кәефләре булса, бию мәйданчыгына да сугылып чыгарга мөмкин. Шул җәйге кичтән соңгы бөтен гомере буена Рушан ул мавыктыргыч фильмны кайчан да булса бер яңадан экранда күрергә хыялланды, Тамара белән бердәнбер очрашып, аның янында утырганда, кызның кайнар кулларын үзенең кайнар учларына алып тотканын, кызның исә аларны тартып алырга тырышмаганын — икесенең дә бармаклары кушылып-үрелеп, бер-берсен танып иркәли-иркәли, ниндидер тылсымлы сүзләр сөйләшкәнен яңадан кичерәсе килә иде. Ул әлеге фильмны да, шул ук вакытта, кызның үзе янында икәнлегенә һаман да ышанып җитмичә, аның гүзәл йөзеннән күзен ала алмыйча диярлек утырганын да яхшы хәтерли иде.

Кинога кадәр дә, кинодан соң «Бродвей»да икәүләп йөргәндә дә, ул кичтә Рушанның кайчандыр Феллини фильмындагы Кабирия шикелле:

— Күрегез, мин кем белән барам! Мин Давыдычева белән барам! Тамара минем янымда! — дип, шар ярып кычкырасы килә иде.

Әлбәттә, җәйге кичтә аларның бергә күренүләрен шәйләми калмадылар — мәктәпләрдә чыгарылыш кичәләре шаулап үткән генә, студентларның имтиханнары тәмамланган чак, озын-озак җәйге каникулларны алдан ук сизенеп ләззәтләнгән-кинәнгән яшьләрдән урамнар гөрләп тора, алар да үзләренең күп кенә дус-ишләрен һәм таныш-белешләрен очратып йөрделәр. Рушан беркемнең дә гаҗәпләнмәгәненә яңадан таң калды: аның

«Бродвей»да Тамара Давыдычева белән күренүе, әйтерсең, көн дә була торган бер эш иде.

Кинодан соң паркта йөргәндә Рушан кыздан биергә керергә теләге юкмы икәнен сорады. Тамара:

— Билгеле, биисем дә килә,— диде.— Ләкин бигрәк тә синең белән буласым килә, син бит иртәгә китеп барасың. Аннары без ике авыз сүз дә алыша алмаячакбыз, егетләр бер-бер артлы килеп, синең белән хушлаша башлаячаклар. Безнең бердәнбер кичебез моңсу-күңелсез үтмәсен иде, һаман да синең китеп барачагыңны искә төшереп торуларын теләмим. Иң яхшысы, әйдә, бакчадан чыгып китик тә тын урамнарда йөрик, безнең сөйләшер сүзләребез байтак бит...

Тамара белән бергә үткәргән бу кичен дә Рушан һәрьяклап җентекләп күз алдына китерә алмас иде, ул кич, дистәләрчә вак кисәкләргә бүлгәләнеп, аның хәтерендә аларның һәркайсы ниндидер сагышлы, аерым-аерым нәрсәләр булып тезелә, бөтенесен дә бер төнгә сыйдырып бетереп тә булмый иде бугай.

Алар Тамара белән таң атканчы, Алма-Ата экспрессының гудок тавышларын ишеткәнче йөрделәр. Икесе өчен дә соңлап килгән бу очрашу Резникова белән үткәргән Яңа ел төненә бик охшаш иде: шул ук кочелмәгәнлек, шул ук мәхәббәттә аңлашу, көтелмәгән үбешүләрдән шулай ук тетрәнү-калтырану һәм хәтта шундый ук күз яшьләре...

Саубуллашканда алар үз бәхетләренә чынлап ышанганнар, әйтелеп-сөйләнеп бетмәгән сүзләр, аңлашылмаулар һәм бозылышулар артта калган дип өметләнәләр иде.

Шактый вакытлар үткәч, шигърият белән мавыгуы рәсем сәнгатенә китереп чыгарып, ул үзе өчен импрессионист рәссамнар дөньясын ачканнан соң, Рушанны Клод Моне хезмәтләре таң калдырыр. Мәсәлән, бу рәссамның, көн яктылыгы үзгәреп торуына карап, бер үк ноктадан торып, тәүлекнең төрле мизгелләрендә Нотр-Дам күренешен сурәтләгән рәсемнәре. Менә шунда Рушан үзенең сокландыргыч өч кыз, гүзәл затлар — Светланка Резникова, Ниночка Новова һәм Тамара Давыдычева белән мөнәсәбәтләренә кагылышлы билгеләмәләр табар, чөнки анда да, Клод Моне рәсемнәрендәге шикелле, бер үк башлангыч нокта булыр, ул да булса — мәхәббәт. Чикләнмәгән саф композицияле һәм көтелмәгән ракурслы ул рәсемнәрдә Нотр-Дам иртән дә, көндез дә, кичен дә нинди гүзәл һәм кабатланмас бер иҗат җимеше булса, Рушанның хисләре дә бер яктылык, бер нур белән өртелгән — ул мәхәббәт нуры иде. Ул үзе онытылып-мавыгып йөргән

әлеге кызларның берсен дә, беркайчан да начар итеп хәтерләмәде, хәтта кайчандыр йөрәгендә мәхәббәт очкыны кабызган «1905 ел» урамында яшәүче кыз белән үткәргән бердәнбер кыска төн дә хәтерендә язмышының иң бәхетле бүләге булып калды. Болар берсе дә арттырып әйтү түгел иде...

Яшьлегендә мәхәббәт үзенә мәңге килмәс кебек тоелган, бөтенләй өмете өзелгән бер мизгелдә аның башына хәтта: «Әллә бу тормыштан китәргәме?» — дигән ямьсез уй да килгән иде. Ләкин ул үзе сөйгән кызлар белән хушлашмыйча китеп бара алмый иде, шуңа күрә, һәрберсенә хатлар язды, хатларында алар белән кичергән, алар биреп өлгергән шатлыклы-бәхетле минутлары өчен рәхмәт әйтте, алардан башка бу дөньяда яшәүнең бер мәгънәсе дә калмаганлыгын бәян итте. Һәр хаты, күчергеч кәгазе куеп язган шикелле, бер үк сүзләр белән тәмамланган иде: «Хушыгыз, мин Сезне яраткан идем...» Аның кул астында бер адрес юк булып чыкты, Давыдычеваның яңа адресы. Ул аны эзләп-белешеп маташкан арада, үз-үзенә кул салу уе да үзлегеннән юкка чыкты. Димәк, тормышы белән дә ул «1905 ел» урамында яшәүче кызга булган мәхәббәтенә бурычлы иде. Шунысы гаҗәп, бу вакытта ул әле атаклы Жан Коктоның мәхәббәт хатлары белән таныш түгел иде...

Алга таба тормыш үзгәрде, илленче еллар азагында тимерьюлчыларның ике мәктәбенә дә кичәләргә йөрүчеләрдән Актүбәдә берсе дә калмады. Язмыш аларны ил буйлап чәчеп-сибеп бетерде, күпләренең туган-тумачалары да күченеп китеп беттеләр. Туган якларында Рушан гына, мөгаен, ешрак була торгандыр. Кайткан чакларында, ул джаз яратучы мәрхүм прокурорның каберен зиярәт итә, искереп барган «Бродвей»дан үтә, моңсу «1905 ел» урамына һәм Кызыл урамына барып чыга, анда инде күптән чит кешеләр яшәсә дә, Рушанны бик теләп йортка үткәрәләр. Әлбәттә, анда хәзер ерак калган бәхетле көннәрне бернәрсә дә искә төшереп тормый, тәрәзә каршындагы колач җитмәс чал тупыллар белән кыргыйланып беткән фарсы сирене куаклары булса гына инде.

Кайчагында ул үз-үзенә: «Җитәр, соңгы мәртәбә»,— ди, әмма һәр кайтуында, йөрергә чыккач, «1905 ел» урамындагы шул йортка барып төртелә. Нәрсә бу — йөрәк хәтереме?

Бервакыт Валя Домарова аңа үзенең студентлык елларында бәйрәмнәргә кайтып йөргәндә төнге поездларда һәрвакыт бер сары чәчле егет белән Тамараны очратканын сөйләгән иде. Рушан Тамараның Оренбург педин-

ститутында укыганын, хәтта аның Совет урамы, 100 нче йортта фатирда торганын да белә иде. Бер шулай ул әлеге фатирга да барып чыкты, хуҗабикә үзендә кайчандыр фатирда торган чибәр кызны бик тиз исенә төшерде.

— Ә сезне мин хәтерләмим,— диде ул, кинәт күңелсезләнеп.

Рушан үзенең биредә беркайчан да булмавын әйткәч, хуҗабикә моңсу гына өстәп куйды:

— Димәк, сез дә аны яратып йөрдегез, Тамараны, дим...

Ялгызлыктан туйган булгангамы, әллә башка сәбәп беләнме, ул Рушанны чәй эчәргә утыртты. Аннары сөйләп китте:

— Беләсезме, ул һәрвакыт үзен яраталармы-юкмы дип шикләнә, борчыла торган иде. Аңа табынып йөрүчеләр күп булды, һәммәсе дә менә дигән егетләр иде, әмма ул ниндидер аңлашылмас мәхәббәт көтә: үлгәнче бары тик аны гына сөюләрен тели иде... Шулкадәр вакыттан соң менә сез килеп чыктыгыз, ә бит ул миндә биш ел торды, беркем дә аны искә төшереп яңадан килеп күренмәде, димәк, сез аны барысыннан да ныграк яраткансыз...

Байтак еллар элек үзенең сөеклесе яшәгән бүлмәне күздән кичергәч, Рушан дөресен әйтүне кирәк тапты:

— Әйе, мин аны бик ярата идем...

## XX

Тормыштагы бөтен хәлләрне дә алдан күреп бетереп булмый, кайбер серләр хуҗалары белән бергә гомерлеккә китеп баралар, ә кайберләре, әйтик, Рәшит абыйның туган көне шикелллеләре, соңлап булса да, ачылалар.

Бервакыт, эш белән Кавказга командировкага баргач, Дасаев үзен борчып торган тагын бер тарихның серен көтмәгәндә генә ачкан иде, дөресрәге — шуңа дәлилләү тапкан иде.

«Баку — Тбилиси» поездында барганда, бер кызыклы маҗарага тап булды ул. Тбилисидә ул Гобискерия джаз-оркестрын, ә Бакуда шул елларда джаз музыкасын аранжировкалаучы атаклы Кальварский эшләгән Рәүф Гаджиев оркестрын тыңларга өметләнгән иде. Поездга алданрак төште — кузгалып китәр алдыннан була торган ыгы-зыгыны яратмый иде, йомшак урынлы буш вагон купесыннан ашыкмый гына үз урынын эзләп тапты да коридордагы тәрәзә буена чыгып басты.

Вагон әкренләп тула торды, тәрәзә буендагы Рушан берәүгә дә комачауламый иде. Поездга ул туп-туры кон-

церт залыннан чыгып килгән һәм эш белән командировкага баручы инженерга бик аз охшап тора иде.

Перронны, шәһәрне артта калдырып, поезд кузгалып китте...

Эңгер-меңгер караңгылана-куера барганлыктан, коридорда ут кабыздылар. Пассажирларның кайберләре ресторанга юл тотты, кайберләре купедагы өстәлчеккә ашамлыклар тезә башлады, ә Рушан, кешеләр ниндидер кабатланмас, шул ук вакытта һәммәсе өчен дә бер төрлерәк тормыш белән яшәп яткан авылларны игътибар белән күзәтә-күзәтә, тәрәзә буенда басып тора бирде, фараларын кабызып, авылга ашыгып кайтып баручы ялгыз машинаны да искәрде, мөгаен, шоферны гаиләсе, балалары көтә торгандыр, ә бәлки, сөйгән кызы белән очрашасы бардыр, ул кызның таныш булмаган йорты берничә минуттан тәрәзәләрендәге якты утларын балкытып күренер дә менә-менә төн караңгылыгында эреп югалыр.

Рушанның юлдашлары шунда ук кичке ашка утырдылар. Вагонга кофе, кыздырылган тавык, яңа пешкән хачапури һәм ләваш исләре таралды, кайдадыр инде җырлаган тавыш та ишетелде.

Алар купесы белән янәшәдәге купеда чуар публика иде: яшь кенә бер егет, чәчләренә чал төшсә дә, яшь чырайлы бер карт, берничә ир кеше һәм хәтта бер сөйкемле генә кыз. Кыз, Рушан кебек үк, гел генә тәрәзә янында басып тора, әмма, аннан аермалы буларак, үз теләге белән тормый иде шикелле. Карт, ихтимал, урыстыр, яшь егет белән кыз — әрмәннәр, калганнары — грузиннар яки осетиннар. Аларның киемнәре дә бер-берсеннән аерылып тора: ике ир кеше һәм, мөгаен, карт та Тбилисинең Руставели проспектында борын чөеп, кыланып йөрүче көяз-тәти егетләрдән калышмаслыклар, ә калганнары йомшак урынлы вагон пассажирлары дип кабул итәрлек тә түгел иде.

Поездга бернинди багажсыз, хәтта сумка-портфельләрсез дә утырган бу төркем шулай ук кичке аш дип мәш килә башлады. Яшь егет белән кыз ресторанга барып килергә теләделәр һәм купе эченнән кемнеңдер хуплау сүзен ишеттеләр. Дасаев яныннан үтеп киткәндә, яшьләр аңа кызыксынып карап уздылар, ә кыз хәтта елмайган сыман да булды әле.

Тәрәзә артында бөтенләй караңгыланды, шуңа күрә басып торуның кызыгы калмады. Аның юлдашлары күптән ашап туйганнар, Рушан исә купега кереп утырыргамы, әллә ресторанга барыргамы дип, уйланып тора иде, шунда кинәт кенә әлеге күрше купедан берсе, Ру-

шан осетин дип чамалаганы, әдәпле генә, хәтта бары тик Кавказ халыкларына гына хас дип әйтерлек түбәнчелек белән аны үзенең тыйнак табынын уртаклашырга чакырды. Рушан да әдәпле генә итеп рәхмәт әйтте, аппетиты булмау, башы авырту һәм ялгыз каласы килүне сылтау итеп, сыйдан баш тартты.

Бер минут та үтмәгәндер, тегеләрнең икенчесе күренде һәм шулай ук әдәпле, әмма катгыйрак итеп чакырды. Аларның бәйләнчекләнеп дәшүләренә Рушан үртәлә башлаган иде, шуңа күрә, үз купесына кереп китәргә ашыкты. Ул кереп утырырга да өлгермәде, ишек ачылып китте дә яшь чырайлы картның чал чәчле башы күренде, ул Дасаевның бер генә минутка коридорга чыгып керүен үтенде.

Карт теләсә кайсы грузин тамадасына биргесез тасма телле булып чыкты. Ул кунакчыллык кануннары турында, юлда барганда яңа кеше белән шәраб уртлап сөйләшеп утыруның күңеллелеге турында сөйли башлады. Кыскасы, Рушан үзенең бу картның көчсез, әмма каты кулларыннан ычкына алмасын аңлады,— карт, чынлап та, әле аның пинжәк төймәләрен бөтерә, әле җиңеннән тотып тарткалый иде,— Рушан бирелде. Георгий Павлович белән — карт үзен шулай дип таныштырды — күршеләргә барып кергәч, анда ихластан куанып, шундый итеп кычкырып җибәрделәр, мөгаен, бу тавышны күрше вагоннарда да ишеткәннәрдер. Рушанны тәрәзә янынарак, Георгий Павлович каршысына утырттылар. Өстәлдә оста гына ботарлап куелган күркә ите өелеп тора, янәшәсендә — үлән-сәлән, әче борыч, помидор, әрмән сыры, грузин брынзасы һәм йомшак Баку чурегы иде.

— Нәрсә эчәбез? — дип сорады карт, Рушан ак абхаз шәрабы «Бахтриони»га ымлады.

Кемдер юллар уң булсын өчен тост тәкъдим итте, мәҗлес башланып китте. Стаканнарны бер дә буш тотмадылар, өстәлдән бик оста гына итеп, сиздермичә генә кирәкмәгән нәрсәләрне алып, әле ветчина, әле кыздырылган ит, әле тиз бетә барган үлән-сәләнне өстәп кенә тордылар, Рушан икенче каттагы киштәдә зур бер кәрзин шәйләгән иде, сый-нигъмәтне шуннан алалар, аның бетәсе юктыр, ул кәрзин тылсымлыдыр төсле тоела башлады.

Баштарак сүз һич тә ялганып китә алмады. Бер-бер артлы тостлар әйтелә, «сал», «алып бир», «капкалап куй» кебегрәк сүзләр ишетелә, аннары урыс һәм грузин телләрендә рәхмәт сүзләре яңгырый иде. Ләкин шушы аз сүзле әңгәмәгә хуҗалардан бары тик өч кенә кеше катнаша: Дасаевны башта чакырган икәү белән Георгий

Павлович кына, картның болар өстеннән аксакалларча хакимлек иткәне күренеп тора. Калган икесе, юньләп кырынмаган йөзләренә тавыш-тынсыз соклану төсе чыгарып, өстәл өстен карый, стаканнарны бер дә буш тотмый, бик оста гына итеп теге тылсымлы кәрзиннән сыйнигъмәт ала тора. Көтмәгәндә генә сүзләр тынып калды, әллә махсус шулай эшләнде, шул арада карт:

— Кая барасыз, нәрсә белән шөгыльләнәсез, яшь кеше? — дип кинәт кенә сорап куйды.

— Инженер мин, Тбилисигә командировкага барышым,— дип, сүрән генә җавап бирде Дасаев. Ул, аның гади инженер гына икәнлеген белгәч, тегеләрнең кызыксынуы шунда ук юкка чыгар дип уйлаган иде.

— Инженер?.. Командировкагамы?.. Мин бит сезгә әйткән идем,— Георгий Павлович үзенең юлдашларына карап сөйли башлады.— Өйрәнегез: менә нинди мәктәп, югары пилотаж, мин аның яшендә андый данны белми идем әле. Ә коридорда ничек басып торды ул! Сокланырлык бит: турист, артист инде, чын менә... Пейзаж, кояш баешы, пленэр... Ә Дато һәм Казбек белән ничек сөйләште, әйтерсең аларны үз гомерендә бер дә күргәне булмаган! Бу бит искиткеч! Станиславский! Әгәр теләсәгез — Мейерхольд!..

— Минем, чынлап та, ни сезне, ни сезнең юлдашларыгызны бервакытта да күргәнем юк,— дип, картның сүзен бүлдерде Рушан.

— Бөтенләй күргәне булмаган,— дип елмайды Георгий Павлович, купе эче бер биш минут көлү тавышларыннан тетрәнеп торды.

Дасаев, бернәрсә дә аңламыйча, табындашларын күзәтә, бу сәер юлдашлары аның һәр хәрәкәтен хәтерләрендә калдырырга тырышып, үзенә сокланып карап торганнарын күрә иде. Мондый илтифатны ул әле беркайчан да тоймаган иде.

— Әйе, Марсель Марсель шул инде, аның турында зонада да, иректә дә юкка гына легендалар йөрми,— дип сүзгә кушылды Дато дигәне.

— Сез нәрсәнедер бутыйсыз, мин — Дасаев, Ташкенттан инженер,— үзен әллә шаяртканнарын, әллә, чынлап та, ниндидер Марсель белән буташтырганнарын аңламыйча, айный төшеп җавап бирде ул.

Купе тагын шырык-шырык көләргә тотынды. Георгий Павлович, яшьләнгән күзләрен юка батист кулъяулыгы белән сөртә-сөртә:

— Бәлки, ксиваңны күрсәтерсең, Дасаев...— дип сорады.

Мартукта яшәгәндә үк Рушан җинаятьчел жаргонны яхшы ук белә иде. Пинжәгенең эчке кесәсеннән паспортын алып, аны өстәл аша Георгий Павловичка сузды.

Купеда тынып калдылар, картның паспортны остаҗитез бармаклары белән әле тегеләй, әле болай әйләндергәләгәнен игътибар белән карап тора башладылар. Георгий Павлович паспортны хәтта борынына якын китереп, җентекләп иснәп карады — тешләп караса да, беркем дә елмаеп та куймас иде шикелле.

— Һәйбәт ксива, исе дә чын,— диде, ниһаять, Георгий Павлович, паспортны кайтарып биреп.— Димәк, кәгазьләрең тәртиптә, тиз булдыргансың... Дато сине ксивасыз дип уйлаган иде. Ул бит соңгы мәртәбә синең белән бер зонада матавыкланды. Исеңә төшер әле, аның кушаматы — Лорд, ә фамилиясе — Гвасалия. Ул хәзер әнә нинди франт, нәкъ сиңа ярдәмче булырлык, «интеллигент». Ярдәмче кирәкмиме, Марсель?

— Гафу итегез, арыдым мин, иртәгә минем мөһим эшләрем бар, мин сезнең шаяртуларыгызны аңламыйм,— дип, Дасаев урыныннан күтәрелә башлады.

Карт аны йомшак кына, әмма таләпчән итеп кире урынына утыртты.

— Утыр, Марсель. Безнең белән аралашырга телисеңме-юкмы, анысы синең эш. Әйе, дөрестән дә, син хаклыдыр, синең кебек җитди кошка биредә таныш түгел йөзләр артык күп. Син мин картны гафу ит инде, шатлыктан бит — синең хакта күп ишеттем, Дато да синең ничек юкка чыгуыңны сөйләгән иде. Димәк, зур эш майтарырга барасың, уңышлар сиңа. Әгәр ярдәм кирәк булса — акчамы анда, хазамы... Менә Тбилиси һәм Орджоникидзедагы адреслар, телефоннар...— карт оста хәрәкәт белән Рушан пинжәгенең күкрәк кесәсенә алдан ук әзерләп куелган кәгазь кисәген тыкты.

Алар шулай аерылыштылар.

Иртә белән поезд Тбилисигә килеп туктаганда, әлеге сәер юлдашлар юк иде инде — әллә төрле вагоннарга таралганнар, әллә башкалага җитәрәк төшеп калганнар. Ләкин алар әле үзләрен тагын бер кат искә төшерделәр...

Тбилиси кунакларына Мтацминда да булырга киңәш итәләр, аннан аста җәйрәп яткан шәһәр манзарасы бик матур күренә, шунда ук — искиткеч гүзәл бакча, җәйге кинозаллар, ресторан. Йөреп арыгач, таулардан искән җилдә туңып калтырана башлаган Рушан Мтацминда да ашап чыгарга булды.

Залда һәм ачык верандада шаулашып кәеф-сафа корып утыралар иде. Ул яраткан «Регина» ресторанны-

кыннан ике мәртәбә зур оркестр уйнап тора, ике җырчы, берсен-берсе алыштырып җырласалар да, төрле яктан ишетелеп кенә торган заказларны башкарып бетерергә өлгерә алмыйлар. Һавада кыйммәтле хушбуй, затлы сигарет һәм өстәлләрдә кукраеп утыручы шәраб исләре эленеп тора, дәртле бәйрәм хисе ташып чыккан иде. Рушан үзе шикелле үк командировкага килгән кешеләр җыелышып утырган өстәл яныннан көч-хәл белән генә бер буш урын тапты.

Официантның бөтен кыяфәте дамаларсыз ялгыз гына килгән кунаклардан риза түгеллеген аңлата — үз ихтыярында булса, ул Дасаев һәм аның ишеләрне бусагадан да үткәрмәс иде. Тулышып торган тук яңакларын ялкау гына тартыштыргалап, ул заказны, ни өчендер авыр күрсенә-күрсенә, теләр-теләмәс кенә тыңлый, сүзләрен дә теш арасыннан кысып кына чыгара:

— Юк... юк... бетте... булмый... бервакытта да булмаячак...

Рушан, каршы килеп, көйсезләнеп азапланса, үзенең ышанычсыз чакырылмаган кунак хәлен тагын да катлауландырачагын аңлый иде, шуңа күрә, буйсынып ризалашты:

— Ярар алайса, нәрсә калган булса, шуны китерегез,— диде. Аннары: — Бер шешә ак шәраб та...— дип өстәде.

Официант шактый озак югалып торды. Шиңеп беткән үлән-сәлән, кипшенгән сыр кисәге, салкын хачапури белән бер шешә шәраб китерде. Шашлыкны соңрак китерәчәген мыгырданып кына әйтте дә икенче өстәлдә шау-гөр килеп типтерүчеләр янына китеп барды.

Кирәгеннән артык әчегән шәрабка авызын тигереп тә өлгермәде, әйтерсең, җилләр ташлады, Рушан янына метрдотель белән теге официант килеп җитте — әле генә үзе белән шактый озак һәм бик «эчтәлекле» сөйләшеп торган официантны башта Дасаев танымый да торды, тегенең йөзе төче елмаюдан шулкадәр үзгәреп киткән иде.

— Гафу итегез, хаталык килеп чыкты,— дип, официантка усал караштыргалап, сөйли башлады метрдотель, ә тегесе, бер гөнаһсыз кеше кыяфәтендә корсагын җыя төшеп, шундый үкенгән төс белән басып тора иде, аны кызганудан елап җибәрерсең, билләһи!

Алар Рушан кулындагы фужерны көчләп диярлек тартып алдылар, эчендәге эчемлекне чәчәкләр куя торган вазага җирәнеп, чырай сытып кына түктеләр, әйтерсең ул шәраб түгел, агу иде.

— Бәлки, аерым өстәл әзерләргәдер? — дип Рушанның колагына пышылдады зал хуҗасы, аның күршелә-

ренә карана-карана, ләкин Дасаев бу тәкъдимне кире какты.

Күз ачып йомган арада арба белән тәгәрәтеп җиләк-җимеш, сусыл үлән-сәлән, чикләвекле лобио, сулугуни һәм Рушанга таныш булмаган башка грузин ашамлыклары китерделәр, метрдотель әллә каян гына килеп чыккан авыр бәллүр бокалга үз кулы белән алтынсу «Твиши» салды. Циркка тиң булырлык бу тылсымлы үзгәрешне күргәч, өстәлнең икенче башында утыручылар Рушанга кызыксынып караштыра башладылар.

Дасаев бу кадәр сый-нигъмәтнең үзе уйлаганнан бер биш тапкырлар артыграк бәягә төшәсен чамалап алды, әмма шәраб искиткеч, азыклары менә дигән булып чыкты, оркестр да шәп уйный, Рушанның күңеле күтәрелеп китте. Әллә башына шәраб йөгергәнлектән, әллә күңелендә кузгалган шуклыктан, әллә залның аргы башында бер өстәл тирәсенә утырган Казбек белән Датоны күреп алганлыктан, ул ниндидер бер кызны биергә чакырды да үзен... Марсель дип таныштырды.

Бәлки, кыз аны ошаткандыр, ә бәлки, исемен яраткандыр, ул кич буе: «Марсель... Марсель...» — дип сайрады. Ят исемгә Рушан үртәлмәде, исем вакыт-вакыт хәтта ягымлы булып та ишетелде, әллә нинди гайре табигый хәлләрсез генә үтеп киткән бу кичтә чит исем белән яшәп кенә калмады, үзен алдына юмарт өстәлләр куела һәм илтифатлы-ягымлы йөзле официантлар күз ачып йомганчы хезмәт күрсәтә торган шул серле Марсель итеп тә тойды...

Иртәнгә кадәр кайнап-гөрләп тора торган Руставели проспектына фуникулерга утырып төшкән чагында ул, гел урынсыздан гына, кинәт Валя белән Мартуктагы күптәнге очрашуны хәтерләп алды. Менә сиңа — Лорд!..

Тирә-якта төнге Тбилиси шаулый, гөлт итеп яктыртылган проспекттан Рушанның каршысына матур киенгән кешеләр килә, алар әледән-әле үзләренең танышбелешләре белән нәзакәтле генә баш иеп исәнләшеп узалар, шәһәр гел шул дус-ишләрдән, таныш-белешләрдән генә тора, диярсең, Рушанның бер генә дә сагышлы-моңсу уйлар уйлыйсы килми иде. Әмма сабына ачык кызыл ефәк «күбәләк» куелган гитарасын тоткан Валя башыннан чыкмый гына бит! Ул хәтерендәге бу күренешне тырышып-тырышып куып җибәрмәкче була, ләкин булдыра алмый, Валя сурәте, күз алдыннан китмичә, һаман комачаулап, күңелне борчып тора.

Кинәт кенә һәммәсе дә урынына утырды. Дато Гваса-

лия... Дато Гвасалия! Валяны шампан шәрабында коендырган, аңа энҗе муенса бүләк иткән Лорд!

«Булмас!» — дип, үз уйларын кире какты Рушан. Әмма хәтере, ялагайланып, Георгий Павловичның тавышын яңгыратты: «аның кушаматы — Лорд, ә фамилиясе — Гвасалия...» Юк, хата булу мөмкин түгел иде, һәммәсе дә туры килә.

Рушан Мтацминдага кабат барырга дип, кире борылып, фуникулерга ашыкты — грузин ресторанннарыннан кунакларның иртә таралмаганнарын белә иде ул.

Ул әйләнеп килгәндә, залда әле күңел ачу дәвам итә, ләкин Лорд үзенең дуслары белән кәеф-сафа корып утырган өстәл буш иде инде.

Әлеге таныш метрдотель, кунакның дулкынланган йөзен яңадан күреп алып, шунда ук аның янына килеп җитте, илтифатлы итеп сорады:

— Нинди ярдәм кирәк?

— Лорд күптән киттеме? — дип, игътибарсыз гына сораган булды Рушан.

— Юк, күптән түгел, сез, мөгаен, фуникулерда аймылыш булгансыздыр. Әгәр берәр проблемагыз булса — биредә Датоны яхшы белүче кешеләр бар, алар Марсельнең дә һәр теләген үтәргә әзерләр. Дато үзе дә миңа сезне һәрвакыт патшаларча каршы алырга кушты...

— Рәхмәт, миңа Лорд кына кирәк иде,— Дасаев инде саубуллашып чыгып китәргә җыенган иде, ләкин метрдотель, әгәр дә кунак кичтән булган хөрмәтсезлекне кичерсә, үзе белән берәр шешә шәраб эчүен үтенде. Эчәргә туры килде.

Фуникулерның ярым буш вагонында кайтып барганда, Рушан уйлап куйды: «Әгәр дә Лорд кушаматлы Дато Гвасалияне залда очраткан булсам, нәрсә әйткән, нәрсә сораган булыр идем икән? Минем яшүсмер чагымдагы мәхәббәтем булган Валя Домарованы шампан шәрабында коендырдыңмы, аңа энҗе муенса бүләк иттеңме, дипме?» Бу уйларының мәгънәсезлегеннән ул кинәт эчкерсез көлеп җибәрде, кайчандыр Мартукның төнге тын урамында, санузелы да шул кысан бүлмәдә булган пычрак ваннада шәраб эчендә чупырдап ятучы Валентинаны күз алдына китереп тә шулай көлеп җибәргән иде ул...

Хәзер инде Валентинаны сирәк искә төшерә, күңелендә аңа карата нәфрәт тә сакламый, гаепләми дә. Тормыш тәҗрибәсе биеклегеннән карап, һәркемнең үз юлын үзе сайлаганын аңлыйсың. Ләкин Рушан шунысын һич төшенә алмый: йөз миллионлаган кешеләр арасыннан кайчандыр балерина булырга хыялланган кызны җина-

ятьчел романтика белән мавыктыра алган ниндидер Лорд кушаматлы карак белән үзен очраштыру язмышка нигә кирәк булды икән? Ихтимал, әлеге сорау да аны гомеренең соңгы көннәренә кадәр бимазалап торыр әле...

## XXI

Бала һәм яшүсмер чагындагы, аннары үсеп җиткәч тә, үзе күргән-белгән кешеләрне хәтеренә төшергәндә, Рушан еш кына күңеле белән туган йортына, димәк, әтиәниләре янына әйләнеп кайта. Хәтерендә, гадәттә, ике вакыйга яңара. Берсе — алар гаиләсенә Исмәгыйль абый әле килеп кермәгән чагында әнисе белән булган хәл, икенчесе — гомер кояшы баеп барган үги әтисе Исмәгыйльгә бәйле вакыйга.

Ул кышта Рушан әллә беренчедә, әллә икенче сыйныфта укый иде...

«Поезд соңлагандыр»,— дип, Рушан бозланып каткан тәрәзә пыяласын сулышы белән өреп эретмәкче була, әмма күпме генә тырышмасын, бозны эретерлек түгел. Суык бабай булдырган, хәтта ике рам арасына да боз таулары күтәрелгән, иске одеял кисәкләре белән ярыкларын, шадра бусага тирәләрен ничек кенә тыгызласаң да, һаман салкын кереп тора, тәрәзәдән дә шундый ук салкын бәрелә иде.

«Кертеп тутырган»,— дип уйлады малай, «ишекне юньләп карамагансың, землянканы суытып бетергәнсең», дип, әнисе ачуланудан куркып, ул җир идәндәге карны себереп алды. Мич җылымса гына иде, ләкин Рушан тирес кирпечен өстәргә кыймады: ягар әйбер бөтенләй юк диярлек иде. Сентябрьдән үк җилләп, яңгырлар явып торды, хәзер инде ярым җимерек сарайның бер почмагында гына бераз тирес кирпече калган иде.

Сәкегә менеп утырып, мичкә елыша төшкәч, Рушан мамык тутырылган төенчекне үзенәрәк тартты һәм, әнисе кушканча, мамыктагы йон кисәкләрен чүпли башлады. «Тизрәк мәктәптән Сания кайтсын иде инде»,— дип, күңелсезләнеп уйланды ул, юкса сигезенче сыйныфларның икенче сменасы бөтенләй караңгы төшкәч кенә беткәнен дә белә үзе.

Чистартылган мамык тавы бик әкрен үрчи-үсә, малай, тәҗрибәле күзе белән карап, бу төенчек белән әле тагын берәр атна чиләнәсе барын чамалый.

«Синең, улым, күзләрең яшь, үткен,— дигән иде әнисе.— Мартукта беркем дә мамыкны синең кебек әйбәт

итеп чистарта алмый»,— дип мактап та куйган иде әле. Кем инде мактаганны яратмасын?!

Кышкы озын төннәрдә алар, зур керосин лампасы тирәсенә сырышып, сәкедә утыралар, һәркем үз эше белән мәшгуль. Сания җеп эрли — әнисе: «Аның бармаклары мамыкны әйбәт тоя, аңардан менә дигән шәлче чыгачак»,— дип, кызын да мактарга онытмый. Чынлап та, кызның эрләгән җебе тигез, нечкә була. Әнисе улы чистарткан мамыкны ике рәтле, биек-озын энәле куркыныч тарак аша тарап үткәрә, ни өчендер аны «чегән тарагы» дип йөртәләр. Әнисенең куллары тарак өстеннән очынып-очынып китә, Рушан һәрвакыт тарак тешләренә тиеп, аның кулы җәрәхәтләнер дип курка.

Әнисе балаларын «оста-җитез ярдәмчеләрем» дип ничек кенә мактамасын, үзеннән дә остарак, уңганрак шәлче Мартукта юк иде. Һәр өченче кеше шәл бәйләү белән туенып торган Мартукта Гөлсем апага тиңнәр, дөрестән дә, юк иде шул, аның шәлләре тиз һәм җиңел мамыкланалар, озакка чыдыйлар, каймалары күз явыңны алырлык киң, берсе икенчесенә биргесез тигез тешле, һәр шәлнең кабатланмас үз бизәге булыр иде.

Мамык тутырган төенчек хуҗабикәсе, кызыл битле юан кибетче Кожемякинага шәл бәйләп бирүдән Мартукта берәү дә баш тартмас иде — Нюрканың талканы коры, пай книжкәсенә тиешле әйберләрне дә ул үзе ничек теләсә, шулай гына биреп җибәрә. Поселокның иң беренче фырт киенеп йөрүчесе булса да, ул да Гөлсемгә килгән.

Рушан аларның сөйләшүләрен тыңлап утыра.

— Нюра, мамыгыңның төсе бик матур,— ди әнисе.— Минем аңа яраклы җепләрем дә бар, ләкин йоннары бик күп икән, ике атнада гына чүпләп бетерешле дә түгел. Әле өч шәлне бәйләп бетерәсем дә бар, рәхмәт яхшы кешеләргә — акчасын күптән биргәннәр иде.

— Гөлсем апа, мине вакыты борчымый — Аллага шөкер, бәйләп йөреремә бар. Узган ел бәйләп биргән шәлегезгә күпләр кызыгып карый, минем менә кара-кучкыл төстәге шәлле буласым килә...

Әнисенең «яхшы кешеләрне» телгә алуы тикмәгә түгел — Кожемякина да Мартукта төшеп калганнардан саналмый бит.

— Сезгә аванс итеп бер пот он әзерләп куйдым,— ди кибетче. Аннары почмаклары сыкыланып торган дымлы землянканы күздән кичереп чыккач: — Кичләтеп Рушанка сельмагка кереп чыксын әле. Сабыннан бушаган әрҗәләр булыр, кызганып тормам, биреп җибәрермен,— дип өстәп куя.

Кожемякинаның юмарт булмаганлыгын белгән әнисе:

— Бер ярты кило такта чәй белән шикәр дә өстә инде, Нюра,— ди.— Йоның бик тә...

— Ярар, ярар, килештек. Онга хәзер үк барасыңмы?

— Хәзер, хәзер,— дип, кабалана башлады әнисе, чыгып киткәндә улына елмаеп карап та алды.

Алар артыннан ишек ябылуга, шатлыгыннан Рушан биеп җибәрде: ул инде кайнар көлчәнең исен тойгандай булды.

Кожемякинаның заказ алып килгәненә куанган әнисе ялгышкан булып чыкты — менә өченче атна инде Рушан Нюрка түтинең мамыгын чистартып изалана.

— Нюрка булсын да, оттырсынмы?! Ул бит бу мамыкны безнең авыл казакъларыннан чәй белән хәлвәгә алмашып алган! — дип тузына хәл белешеп чыгарга кергән Науша апа.

Әнисе авыр көрсенеп кенә куя, дәшми. Тиктормас Науша апа озакламый чыгып китә, әнисе, аның артыннан ишекне ныграк ябып, мич янына килеп утыра. Аның кулындагы бәйләү энәләренең ялт та йолт итеп җитез йөргәннәренә Сания сокланып карап тора: «Мин дә кайчан да булса шулай әнием кебек тиз һәм матур итеп бәйләргә өйрәнә алырмынмы икән?» — дип уйлый, ахрысы.

— Тагын картлар шикелле бөкрәйгәнсең. Кара аны, кызлар яратмас үзеңне,— дип, улын ачусыз-нисез генә кисәтеп куя әнисе.— Ие, яратмаслар...

Рушан, кызарынып, күпмедер вакытка арка-җилкәләрен турайтып ала, ләкин күп очрап торган вак йоннар аны яңадан лампага таба иелдерә.

Менә хәзер дә әле ул, җилкәләрен турайтып, борылып карады: начар ягылган тәбәнәк землянка эчендә эңгер-меңгер куерып килә, әнисе исә һаман да юк әле.

«Дәресләрем дә әзерләнмәгән...» — дигән уй чагылып үтте дә югалды. Әнисе өчен борчылып, әледән-әле урамга йөгереп чыга-чыга, землянканы бөтенләй суытып бетерде ул. Башына әллә нинди куркыныч уйлар килде.

«Әгәр дә поезд соңга калып, туктап тору вакытын кыскарткан булсалар, әнисе вагоннан-вагонга шәлен күрсәтеп йөри-йөри, алдагы станциягә чаклы ук китеп барса... Әгәр кулындагы шәлен тартып алсалар?..» Сугыш күптән беткән булса да, җылы Ташкент якларына һәртөрле ышпананың бик теләп җыелышканын Рушан ишетеп белә иде инде. «Ә бәлки, милиция алып калгандыр. Ничек әле, теге... консиф... конфис... кон-фис-ка-ци-я...» Бала

теле өчен әйтергә авыр булган ул сүзне дә белә иде Рушан. «Станциядә бүген Велигданов абый дежур торса гына ярар иде»,— дип ялвара ул. Рабига әби шикелле итеп, кулларын бергә кушып күтәрә дә, гадәттә йоклар алдыннан укый торган кыска гына догасын укый: «Сөбхан Аллаһы вә әлхәмдел иллаһи...»

Күптән түгел генә, Велигдановны эштән куалар икән, дигән сүзләр дә таралган иде — имеш, станциядә спекуляция таралуга юл куйган. Кем инде хәзер Рушанның әнисен дә, башка әби-апаларны да: «Облава булачак, шәлсез, мамык перчаткаларсыз яки берәр дистә йон оекбашсыз каласыгыз килмәсә, берничә көнгә түзеп торыгыз, станция тирәсендә чуалмагыз»,— дип искәртер? «Ә бәлки, әнине эләктергәннәрдер? Аны бит поездларга шәл күтәреп кереп йөргәне өчен кисәткәләгәннәр иде инде...» Рушанга бик куркыныч булып китте, ул елап җибәрде.

— Улым, нәрсә булды? — Ниндидер төенчекләрен ишек янында калдырып, әнисе аңа ташланды.

Рушан, әнисенең шыңгырдап каткан кыска сырмасына борынын төртеп, салкынны да сизмичә, кычкырып елый башлады.

— Йә, җитәр, син зур бит инде, өйдә бердәнбер ир кеше. Эшләрең уңдымы дип сора, ичмасам...— Әнисе аның күптән алдырылмаган чәченнән сыйпап куйды.— Хәзер лампаны кабызырбыз, мичкә ягып җибәрербез, чәй куярбыз. Кара әле, нәрсәләр алып кайттым мин...— Ул идәндә таралып яткан төенчекләрен җыештырырга тотынды.

Капкачын шыңгырдата-шыңгырдата, плитә өстендә чәйнек кайный, әнисе казанда сарык маенда гына бавырсак кыздыра. Муенына кадәр керосин салып, яңа филтә куелган лампаның яктысы землянканың иң ерак почмакларына кадәр төшә. Мул итеп тутырып ягылган мичтән җылы бөркелә.

— Саттыңмы? — дип сорады мәктәптән кайтып кергән Сания, бусагадан атлап керә-керешкә үк.

— Саттым, кызым, саттым. Чишен, бар нәрсәм дә әзер.

Сания тиз генә киез итекләрен салып, мичкә терәтеп куйды да Рушан янына сәкегә менеп утырды.

— Син бүген озак кайтмадың, мин сагынып беттем,— диде Рушан әкрен генә, үзе апасына сырышты.

Әнисе сәкегә эскәтер җәйде.

— Йә, әни, сөйлә,— дип ашыктырды аны Сания.

Телеңне өтәрдәй кайнар бавырсакларны агач савытларга сала-сала, әнисе сөйләп китте:

— Перронда басып торабыз шулай, бер сәгать, ике сәгать торабыз, ә Мәскәү поезды юк та юк. Шулкадәр туңган идем, китәргә җыенган идем инде, шул чакта еракта, семафор янында ук паровоз гудогы ишетелде. Безнең колаклар сизгер бит. «Пассажир поезды»,— дип уйлап та бетермәдем, килеп тә туктады. Вагоннардан ник бер адәм заты күренсен! Күрше урам Нәгыймәсе әйтә: «Әйдә, Гөлсем, алдагы стансыга кадәр утырып барыйк, вагоннарның яртысын йөгертеп узарга өлгерербез»,— ди.

Шунда кинәт кенә безнең каршыдагы вагон ишеге ачылып китте дә бер яшь кенә хәрби кеше миннән: «Шәлеңне күпмегә бирәсең, анакай?» — дип сорады. Аның җилкәсе аша чибәр генә бер туташ карап тора, ул минем шәлемне тәрәзәдән үк күреп алгандыр, мөгаен. Мин арзан гына хак әйттем, шәлемне тотып поездлар каршысында бер атна йөрим бит инде.

— Ә сез бире күтәрелә алмыйсызмы? — диде чибәр туташ, ә хәрби кеше шундый илтифатлы, вагонга менәргә ярдәм итеп, хәтта кулын сузды. Туташ шәлне иңнәренә салды да ишекне тутырып торган көзгегә капланды. «Нинди нәфис! Нинди матур!» — дип соклана үзе, сайрамый гына инде менә! Ә шәл, дөрестән дә, үзенә бик килешеп тора. Аннары, поездның кузгалып китүен уйлапмы, исенә килеп, гаҗәпләнеп сорады: «җиде йөзме?»

Мин каттым да калдым. Сатулашыр микәнни? Ә миңа бер тиен дә киметергә ярамый. «Җиде йөз»,— дидем дә шәлемне төрә башладым. «Вадим, сигез йөзне түлә әле, зинһар, шәле бигрәкләр дә әйбәт! Апа да безне онытмасын»,— дип, мине кочаклап алып, матур итеп көлеп җибәрде туташым. «Рәхмәт, кызым,— дим.— Рәхмәт!» Күзләремә яшь бәреп чыкты, Вадимы санаган акчаны да күрмим. Карап та тормыйча, алып кесәмә тыктым. Инде чыгып бара идем, мине әлеге Вадим куып җитте дә бер тартма сузды. «Ал әле, анакай,— ди.— Минем паегым бу. Галетлар, тушенка...»

Ул галет дигәннәре сохари икән, Рушан аларны бик яратты.

— Ә тушенка салып иртәгә мин сезгә аш пешерермен. Нинди матур, бәхетле кешеләр, Ходаем, үзең сакла аларны!

Әнисе сырмасының яшерен кесәсеннән төенчеген чыгарып чиште дә эскәтер читенә бер төргәк акча куйды.

— Поезддан сикереп төшүем булды, иптәшләрем йөгерешеп килеп җиттеләр. Бигрәк тә мин әҗәткә акча алып торганнары кабалана-түземсезләнә иде. Бер-ике унлыкны бурычка да биреп торырга туры килде. Бүген бер миңа

гына мач килде бит. Якшәмбе көнне, Алла боерса, Рушан белән базарга барырбыз, казакълардан берәр йөк тирес кирпече алырбыз,— дип, әнисе булган акчаларының яртысын бер читкә алып куйды.— Ә монысы сезгә киногa,— әнисе өчлекне Рушанга суздьі.— Хәзер үк аерып бирмәсәң, соңыннан бер сумны да арттырып булмый...

Рушан шатлыгыннан чак кына чәен түгеп җибәрми калды.

— Монысы — керосинчыга, монысы — радиога түләргә, монысы — Матвей бабайга итекләр өчен, инде өч мәртәбә акча алмыйча гына олтан салып бирде, ә монысы — Нюркага иске бурыч, бигрәк кырын карый башлады, кибетенә бармассың, валлаһи...

Өелеп торган акча төргәге эреде дә бетте: әнисе алдында бөгәрләнеп беткән берничә берлек белән вак акчалар гына торып калды.

— Ә болары вак-төяккә.

Рушанның ашыга-ашыга өчлекне кесәсенә яшерүен күргәч, әнисе елмаеп куйды:

— Борчылмагыз, балалар. Куллар исән, аяклар сау, ничек тә яшәрбез. Сезнең кебек ярдәмчеләрем булганда, югалмабыз...— дип, улының башыннан сыйпап алды да табынны җыештыра башлады.

Кич белән яңадан лампа тирәсенә түгәрәкләнеп утырыштылар да Нюрканың төенчегенә тотындылар. Әнисе әкрен тавыш белән генә «Кара урман» җырын көйли:

Кара да гынай урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк үтәргә...
Заманалар авыр, еллар ябык,
Дус-иш кирәк тормыш көтәргә...

Вакыт-вакыт ул тынып кала: шәл бәйләгәндә күзләрен төгәл санап барырга кирәк бит. Санап-барлап алгач, янә җыр башлый:

Агыйделкәй алкын, суы салкын,
Каз-үрдәкләр каршы йөзәлми...
Шатлыкларга гына, һай, түзсә дә,
Хәсрәтләргә кеше түзәлми...

— Әни, инде икенче чирек бит, ә минем укуым өчен түләнмәгән әле, мәктәптән кумаслармы икән мине? — дип кинәт кенә сорап куйды Сания.

— Кайгырма, юләркәем. Кузнецов директор чагында, андый хәлнең буласы юк. Әле җәй көне дә, мине урамда очратып: «Гөлсем апа, Саниягез бик сәләтле кыз, унны бетергәч, үзегезгә бер ярдәмче, бер таяныч булыр, укы-

ган кеше беркайда да югалмас. Кием-салым белән булышырбыз, мәктәп фондыннан нәрсә булса да юнәтербез. Сугыш бетте инде, хәзер җиңелрәк булыр»,— дип сөйләп торды. Дөрес әйткән бит. Сиңа җидене бетерсәң дә, бик җиткән — шәл бәйләргә күп акыл кирәкми, түземлелекосталык дигәндә, Аллаһы Тәгалә сине өлешсез калдырмаган, дип уйлана идем. Мәктәпкә нәрсә киеп йөрерсең, дип тә баш вата идем.

Формасын да, йон күлмәген дә, пәлтә-итекләрен дә бирделәр мәктәптән. Кузнецов үз кабинетына чакырып алды да: «Менә, Гөлсем апа, киемнәр — кызыгызга болар»,— диде. Урындыкларда башка укучылар өчен дә киемнәр ята, төрле төстәге, төрле фасондагы пәлтәләр... Директорыгыз бик сизгер кеше, бөтенесен уйлап-исәпләп эшләгән, мине кызыксынып күзәтүчеләрдән һәм усал телләрдән саклаган. Бүләкләрен пөхтәләп төреп, бәйләп бирде дә сезгә бу киемнәрнең «кәҗүннәй» икәнен әйтмәскә кушты: «Балалар күңеле — бик нәзберек... Исегездә тотыгыз»,— диде. Шулай булгач, тынычлап укы, кызым, сезне бер мин генә кайгыртмыйм. Ә укуың өчен ничек булса да түләрбез.

Әнисе мичнең төннек тишеге эшермәсен ябып куйды да сүзен ашыкмый гына дәвам итте:

— Әтиегез өчен сезгә тиешле пенсия аз-азын, шул ук Кузнецов йөреп алып бирмәсә, анысы да тәтемәс иде әле. Аңа елап бардым. «Ярдәм итегез, Юрий Александрыч,— дидем.— Собеста буташтырмак булалар: иремнең үле хәбәре турындагы кәгазь андый булмаска тиеш, имеш. Ничек инде андый булмасын? Мартуктан киткән ир-атның бөтенесе дә диярлек Мәскәү тирәсендәге сугышларда бер көн эчендә ятып калган. Почта безнең барыбызга да ул кайгылы кәгазьләрне бер үк көнне китереп тоттырды. Ул кичтә елашкан авазларыбыз Оренбургның үзенә хәтле ишетелеп торгандыр әле»,— дидем. Директор аны белмиме инде: икенче көнне үк мәктәптә матәм митингысы үткәргән иделәр бит. Безгә килгән бердәнбер кара кәгазьгә «Хәбәрсез югалды» дип язылган икән. Ә кайда югалырга тиеш сезнең әтиегез? Мартук ир-атлары гел аның тирәсендә булган бит. Әтиегез бик уен-көлкечел, һәр эштә башлап йөрүче кеше иде, өстәвенә партиянный да иде әле. Поселокта бер сәгать торып киткән эшелонда да әтиегез вагонда башлык булган.

Шунда ук директорыгыз белән собеска киттек. Дөрес, мин ишегалдында калып тордым: инде тәмам гаҗиз булган идем, сугыша башлармын, дип курыктым. Бер сәгать көтәм, ике сәгать — кинәт кенә Юрий Александрыч аты-

лып чыкты да, чыга-чыгышына борылып, тиргәнергә тотынды: гел дә укытучыларча түгел инде: «Кабахәтләр! Бюрократлар!» — дип кычкырына. Аннары бераз суынгач, миңа әйтә: «Син, Гөлсем апа, түземлегеңне җый да көт инде,— ди.— Ә мин Мәскәүгә язармын» ,— ди. Ярты ел көттем, ә Кузнецов шул вакыт эчендә әллә кайларга язып бетерде, тәки пенсияне юллап алып бирде бит. Игелекле эш-гамәлләр, игелекле кешеләр белән яши дә инде бу дөнья дигәнең, бервакытта да шуны онытмагыз, балалар...

## XXII

Кар күмеп киткән Мартукка декабрь, юнәлешен көнгә берничә мәртәбә үзгәртә торган, кешеләрне аяктан егардай көчле салкын җилләре белән килде. Күз ачкысыз бураннар башланды, мәктәптә укуларны туктаттылар.

Җил морҗада улап, землянкага бәреп керергә тырыша, әйтерсең аны астын-өскә китереп, туздырып ташларга тели иде. Тәрәзә артындагы җәя кереше шикелле тартылган, бәскә төренгән электр чыбыклары тынмый, көн-төн гүләп торалар. Мичнең туймас корсагына тирес кирпече тутыра-тутыра, Рушанның әнисе борчылып сөйләнә: «Бу якшәмбедә базар булмас инде, мондый буранда юл йөрергә кемнең кыюлыгы җитсен?»

Рушан белән сатып алып кайткан тирес кирпечләре көнләп түгел, сәгатьләп, күзгә күренеп кими. Әнисе, өстенә сырмасын элеп, күрше-тирәләргә йөгерә: сатып алып булмаса, әҗәткә биреп тормасlармы, берәр дистәсен генә булса да берәр әйбергә алмашмаслармы? Кайвакытларда эше уңып та куя.

«Якшәмбегә бураны гына тынсын иде, Ходаем!» — дип ялвара әнисе, бер йөк үк алырлык акчасы булмаса да, казакъларның беренче генә ярдәм итүе түгел, бу юлы да бурычка бирерләр әле, дип өметләнә.

Ишектән башны тыгып карарга да куркыныч булган шундый кичләрдә кунак килеп керә. Ул һәрвакыт көтмәгәндә килә, шыгырдавык ишек тавыш-нисез генә ачыла. Башта ачык ишекне тутырып, иләмсез пычрак капчык күренә, аңа ямаулыклар салып бетергәннәр, аны кунак шунда ишек төбендә калдыра да, үзе өйалдына чыгып, кайры кыска туны белән малахай тумык казакъ бүреген озаклап кага, аларны шунда элеп, землянкага гимнастеркадан гына килеп керә.

— Гыймай абый, авылның аргы очыннан, станция артыннан ук киләсез, буранда адашудан курыкмыйсызмы?

Ишекне шулай тавыш-тынсыз оста итеп ничек ача беләсез? — дип сорый Сания.

— Мин, кызым, сугышның беренче көненнән башлап дивизия разведкасында булдым, ә сугышны дошман тылына йөреп тәмамладым.

— Ә нигә этине дә үзегез белән алмадыгыз? — дип, Рушан кунак янынарак елыша.

— Сугышта, Рушан батыр, кемнең кем белән барырга теләвен сорап тормыйлар. Мине эшелонда ук ниндидер бер майор искәреп алган, мин Мәскәүгә дә барып җитмәдем, Мирсәет белән, этиегез белән, дим, аерылыштым.

Әниләре дәшми-тынмый гына мич янында кайнаша. Чәй эчәргә утыргач, кунакка ул:

— Гыймай, син ул капчыгың белән бер бәлагә тарырсың әле,— дип куйды.

Гыймай чапайча мыегын сыпыргалап көлде генә:

— Сиңа күпме аңлатырга була, миндә эшкәртелгән тире генә бар санала, ә вагоннарга төяп безгә йоны кыркылмаган тире җибәрәләр. Безнең заводның исеме генә — кожзавод, чынлыкта ул — кустарь әртиле генә. Йонын кырку түгел, тиресен иләп тә өлгертә алмыйбыз. Йонлы килеш кайнап торган зур чаннарга ыргытабыз, ә каустик сода ашаган йон бернигә яраксыз була. Аны чаннардан сәнәк белән сөзеп ала-ала эчләр төшеп бетә... Дөресен әйткәндә, сиңа кыркыганың өчен түләргә дә кирәк иде әле: кыркылган тиреләр чанга икеләтә күбрәк сыя, чан чистартасы да юк — бер көн янга кала, сода эретмәсен дә саклыйбыз. Барысы да файдага дип исәплә.

— Шулаен шулай да...— дип ризалаша әнисе, үзе һаман үз сүзен тукый: — Ә йон барыбер дәүләтнеке.

— Шуңа күрә, бураннарда гына йөрим дә бит, кешеләрне котыртмыйм, дим. Ә куркыр нәрсәм юк. Каракугыры түгел, мошенник түгел, фронтта да башымны югары тотып йөрдем...

Гыймай бер талпынуда капчыгы янында була, аның көчле куллары землянка уртасына бер-бер артлы тиреләр ыргыта башлый.

— Шушындый байлыкны әрәм итеп буламы соң? Кара әле, менә берничәсе кәҗәнеке, йоны мамык кына. Шәлгә баруын бармас, әмма пирчәткәләргә — үтергән инде!

— Меринос...— ди әнисе әкрен генә. Ул идәндәге тиреләр өстендә үрмәләп йөри, җае килгән төшләреннән берәр учма йон йолкып ала.— Пәрәвез челтәрләр бәйләргә була...

— Ә мин ни сөйлим?! — Гыймай соңгы тиреләрен алып ыргыта, буш капчыгын кайры туны эченә фокус-

чы кебек оста гына итеп яшереп куя. Кай арада туны кереп җиткән, диярсең! — Менә, кайрадым, әйткәнемчә...

Тун кисәсеннән ул чүпрәккә төрелгән үткен авыр кайчы чыгара. Икенче кесәсеннән бер зур кисәк ябышкак сабын алып, кулъюгыч янына бара. Сабынны да шул ук кожзаводта кайнаталар икән.

Гыймай кулын сабынлап юа-юа:

— Сабынны гына кызганмаска кирәк,— ди.— Юкса бу тиреләрдән теләсә нинди шакшыны йоктыруың бар.

Үз эшеннән канәгать Гыймай тиреләр өстеннән атлап туп-туры самовар янына килә...

Ничек кенә котырынмасын-шашынмасын, кыш көтмәгәндә генә тынып калды, морҗаларына кадәр карга күмелгән кечкенә Мартукны җиңә алмасын аңлады шикелле. Туздырып ташланган бозлы печән кибәннәре, кешесез урамнардагы учма-учма саламнар, юеш-дымлы салкын землянкалар, үтәли җил уйнап торган сарык абзарларында бер көн дә яшәми катып үлгән бәрәннәр, ачлангач станцияләрдә төртелеп туктап калган поездлар өчен гафу үтенгәндәй, поселокта шундый тын матур көннәр урнашты. Андый көннәрне карт-карчыклар бары тик бик күптән, сугышка чаклы имин заманнарда гына күргәннәрдер.

Һавада гына түгел, тормышта да ниндидер җылы үзгәрешләр булды шикелле, инде онытылып бетә язган «өмет» сүзе ешрак ишетелә башлады.

Дөрестән дә, озакламый килеп җитәсе Яңа елга юл ачып дигәндәй, Нюрканың кибете янында игълан-белдерү пәйда булды: беренче гыйнвардан күп кенә товарларга бәя төшәсе икән! Авыл кешеләренә кирәклесен дә, кирәксезен дә санап, шул товарларның озын исемлеген элгәннәр.

Кояшлы бер көндә Мартук буйлап тагын да шатлыклырак хәбәр йөгереп узды: өйдә утырып бәйләүчеләр әртиле ачарга вәгъдә биргәннәр, ди! Авансын да, хезмәт хакын да түләүле, ди! «Авансы да, хезмәт хакы да! Авансы да, хезмәт хакы да!» Бу сүзләр йорттан-йортка кереп йөрде.

Салкын бураннарда туктаулып торган мәктәп ачылды, киез итекләренә тимераякларын боргычлап бәйләгән малайлар авылның аргы башыннан да, бирге башыннан да дәрескә чабыша башладылар. Тәнәфес вакытларында мәктәп ишегалды шау-гөр килде. Бәс-бозлары эрегән электр чыбыклары гүләүдән тынып калды, кышкы ачлыктан вә салкыннардан исән чыккан чыпчыклар чыркылдашырга тотынды. Шундый күңелле көннәрдә Ру-

шанның күптәнге хыялы тормышка ашты: әнисе аңа станциягә, поездлар тирәсенә күмер калдыгы җыярга барырга рөхсәт итте.

Әнисе бөтен поселокны ашатып-эчертеп торучы станцияне үзенең буш ишегалды кебек яхшы белә иде: ул күмер шлагы дигәнең дә тимерьюлчыларның, яшь булсалар да, ертлач-бердәм малайларыныкы санала, алар шунда, станция янындагы кызыл кирпеч йортларда торалар, йортлары исә ут сулап утырган галәмәт зур тау-тау күмер шлагы артында.

Рушан кайнарланып-ышандырып әнисенә сөйли: тимерьюлчыларның Кожедуб атлы иң башкисәр малае минем белән бер сыйныфта укый, ди, алар һәркемгә дә тими, күмерне комсызланып күп җыючыларга гына бәйләнәләр, ди. Ә Рушан буржуй түгел, аңа башкалардан артык кирәкми. Аның соңгы сүзләре әнисенә кызык булып тоелды, ул рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

— Без буржуйлар түгел, дисең инде?

— Буржуйлар түгел...

Мәктәптән кайткач, Рушан чанасына нык-таза кәрзин беркетте, аның эченә яньчелеп, чегәннәр ямап бетергән иске чиләген салып, вокзал ягына ашыкты.

Станциянең үзенә генә хас кабатланмас исе бер квартал кала ук сизелә, Мартукның саман кирпечләрдән салынып, җиргә чүккән йорт-куралары белән чагыштырганда, янган күмер таулары чын-чынлап мәһабәт булып, һәр ишегалдыннан күренеп тора. Ул таулар эчендә көйрәп-төтәсләп яткан шлак, паровоз, топкаларын чистарткан төшләрдә өтелгән креозотлы шпаллар, икеләп тоташтырган паровозларның машина исләре, алар тирәсендә бөтерелеп-ургып торган пар болыты — болар барысы да Рушанны һәрвакыт дулкынландыра, ымсындырып тора иде. Ул белә: шушыннан нечкә ике җеп булып сузылган тимер юллар кайдадыр еракка, башка дөньяларга алып китә. Шул яклардан, шул дөньялардан җылы җәй, кызыл апорт алма, сары мандарин исләре аңкытып поездлар килә; ул поездларда, әнисе сөйләвенчә, ишекләре көзгеле һәм идәненә чын келәм җәелгән коридорлы вагоннар икән, шул вагоннарга әдәпле хәрбиләр, чибәр туташлар һәм тагын әллә кемнәр утырып йөри икән.

Эше булган кеше килеп туктаган состав янында төртелеп, вагоннар янындагы сәүдәне күзәтеп, җете ачык түштәге кытай халатлары өстеннән җилкәләренә авыр тун салган юан-юан хатын-кызларның сокланулы: «Нинди матур бизәк! Нинди нәфис челтәр! Ә мамыкла-

нып ничек очып тора!» — кебек сүзләрен тыңлап торамы соң?!

Үтеп барышлый, Рушан, шаян балаларны күзләп узган аксакал карт шикелле, елмаеп, ачусыз-нисез генә уйлап алды: «Мамыкланып очып тора... Мамыкланмыйча тагын!» Шәлнең берәр калтыранып туңып торган хатын-кыз иңенә менеп кунаклаганчы нинди озын-авыр юл үткәнен беләшул ул. Ул казакъ авылларында нәни шук кәҗә бәтиләрен карап үстергән үз яшьтәшләрен күрә, җәен-кышын әче җилле, үлән-үсемлеккә ярлы далаларда көннән-көн, елдан-ел, салкында да, чилләэссесендә дә көтү көтеп, күченеп йөргән чабаннарны күрә иде. Ул матур, очып торган шәлләргә күпме балаларның, хатын-кызларның, кырыс ирләрнең кул җылысы иңгәнен, күз нурлары түгелгәнен ишетеп кенә белми, үзе эшләп-татып белә; ул салкын абзарларда яки керосин лампасы янында шул шәлләр өчен күпме күз яше түгелгәнен дә белә — менә шуннан соң гына сезнең иңнәрегезгә кунаклый ул шәлләр, чибәр апалар-туташлар...

Тиз йөрешле Ташкент — Мәскәү поездыннан бушатылган шлакны хатын-кызларның носилкалар белән ташып бетергәнен көтеп, Рушан шлак тавы өстеннән аста яткан Мартукны беренче мәртәбә күздән кичерде. Еракта мәктәп күренә, аның янәшәсендә — яшел калай түбәле авыл советы йорты, аның кыегына беркетелгән кызыл флаг шәлбәрәеп тора. Калган йортларны нечкә генә сызылып чыккан төтеннәреннән генә шәйләргә була, ул төтеннәр туп-туры кар астыннан ук сузыла шикелле. Тимер юл буенда еракта бер өркәчле дөягә охшаш элеватор калкып тора. Аның каралган цинкланган калай түбәсенең сыртында ямьсез итеп кыек-мыек язылган язуы да бар: «1927 ел».

Элеватор күренешен пар болыты белән каплап, Мәскәү ягына таба тиз йөрешле поезд чаптырып узып китте. Болыт таралгач, Рушан тимер юл эшчеләренең рельслар өстенә мадерон — махсус юл эшләре арбасын күтәреп куйганнарын күрде, күтәреп куйдылар да шул арбага үзләренең авыр эш коралларын — лом, кәйлә, чүкеч, кувалда ишеләрен төйи башладылар.

Рушан тимер юл эшчеләрен һәрвакытта да башка кешеләрдән аерып куя, чөнки һөнәрләре ни ел фасылларына, ни һава хәлләренә, ни авыл советына, ни башка бер нәрсәгә дә бәйле булмаган бердәнбер шул һөнәр кешеләрен генә белә иде.

Үзен хәтерли башлаганнан бирле, авылдагы һәр тимер юл эшчесен танып белә, аларның һәрвакыт эшләре

бар, димәк, аванс һәм получкалары да һәрвакыт бар. Ул әле тагын шунысын да белә: аларга чын ташкүмер тиешле, алар иске шпалларны үзләренә яздырып ала алалар һәм шулардан таза-нык җылы сарайлар төзиләр. Ә иң мөһиме — анысы инде Рушанга бөтенләй тылсым булып күренә! — аларның һәркайсына ел саен Советлар Союзының теләсә кайсы почмагына түләүсез билет бирелә, кайту өчен дә инде, билгеле. Теләсә кайсы почмагына! Шуларны уйлаганда малайның күз алдында һәрвакыт иске генә мәктәп глобусы җанлана иде.

Әле менә хәзер дә: «Үскәч, тимер юл эшчесе булам!» — дип уйлап куйды Рушан һәм рельслар буйлап йөгертеп ерагая барган мадерон артыннан карап, озак кына елмаеп торды...

## XXIII

Икенче вакыйга үги этисе белән бәйле иде, төгәлрәге, ул аларның соңгы очрашулары булды.

Әнисенең хаты ялга китеп барыр алдыннан гына килеп төште, юллама Рушанның кулында һәм билетка заказ да бирелгән иде инде. Бервакыт диңгез буеннан ялдан кайткач, картларга телефон куйдырткан иде, шуннан бирле әнисеннән хат-хәбәр алмады. Авылда телефон куйдырту шәһәргә караганда да авыррак, әмма аңа җай чыкты: телефон үзәгенең башлыгы аның күптәнге сабакташы икән.

Кичкә кадәр Рушан хатны ачып укымады. Башына хәтта: «Әллә ашыгыч сөйләшүгә чакыртып сорыйммы икән — хатында ни-нәрсәләр язганын?» — дигән юләр уй да килеп китте.

Әнисе үги этисенең пенсиягә китәргә җыенганын язган икән, ә хезмәт кенәгәсендә ниндидер язулары җитенкерәми, ди, этисенең исемен бутаганнар диме шунда. Татар исемнәрен буташтыру урыслар өчен һич кыен эш түгел, шундый исем-фамилияләр очрап куя — хәрефләр бутау гынамы соң, телеңне сындырырсың, валлаһи! Үги этисе йөргән-йөргән дә,— бер ишектән икенчесенә куалар, бер контордан икенчесенә озаталар икән үзен,— үпкәләгән карт. «Кирәкми миңа пинсәгез, кул-аякларым исән-сау булганда — югалмам, ниндидер язулар җитми, имеш, минем эшем — хезмәт, ә кәгазьләрне башкалар язып тутырган бит, мин түгел»,— дигән.

Әнисе ул кәгазьләр-документларның инде ничәнче ай хәрәкәтсез ятканнарын язган, ә үги этисе аның эшенә тыкшынмаска, гомумән, пенсия турында сүз кузгатмас-

ка кушкан икән. «Ә карт кызганыч бит, улым, үз гомерендә күпме эшләгән кеше, күреп торам: бик тә рәнҗи инде...» дип тәмамлаган әнисе үзенең ашыга-ашыга язган хатын.

Гөлсем апа улының ялга өйгә кайтуын сораган, ял итеп алгач, шул пенсия мәсьәләсен кузгатып җибәрүен үтенгән — ни әйтсәң дә, улы укыган кеше бит, законнарны белә, начальниклар, бәлки, картка ярдәм итәрләр, гомере буе халык күз алдында булды бит, качып-посып йөрмәде, шушы Мартукта эшләде дә эшләде, дигән.

Авылга кайтуны кичектереп тору турында сүз дә булырга мөмкин түгел иде. Берәр атнада, ну, күп дигәндә, ун көн эчендә үги әтисенең эшен җайлап, аннары диңгез буена китәргә дә өлгереп булыр шикелле тоелды. Шундый уйлар белән Рушан туган якларына юл тотты.

Вагон тәрәзәсеннән эссе кояш көйдереп бетергән иксез-чиксез казакъ далаларына карап бара-бара, Рушан уйларында әледән-әле үги әтисенә әйләнеп кайта. Ул бер дә алда торган пенсия мәсьәләләре турында уйламый. Менә хәзер генә, вагон көпчәкләренең тек-тек текелдәүләрен тыңлап барганда гына, ул кинәт кеше гомеренең бик кыска булуын тоеп-аңлап алды. Аның кыска икәнен ул, билгеле, белә иде, әмма менә шушылай үзәк өзгеч итеп, дулкынлану кичереп тоюы хәзер генә булды.

Ничек болай соң әле? Әле кайчан гына яшьләрчә төз буй-сынлы бу ир-егет станция өчен, тимерьюлчылар өчен волейбол уйнап йөри, Рушаннарга хромы-никельләре ялтырап торган трофей «Диамант» велосипедына атланып килә,— сугыштан соңгы елларда велосипед күз күрмәгән, колак ишетмәгән зур байлык! — әнә шул кеше хәзер пенсиягә дә чыксын, имеш. Тагын да аңлашылмаганы шунысы: уңган-булган, көчле-кыю, авылда барысыныкыннан да күбрәк орден-медальле үги әтисе хәзер Рушанның ярдәменә мохтаҗ. Ничек инде?..

Ә бит кайчандыр, малай чагында, ул өметсезлеккә бирелеп, үзенең бәхетсезлеге турында уйлана, үги әтисе шикелле тормыш сөючән, шат күңелле, дуслары да, дошманнары да хөрмәт итәрлек гадел булуны гомерендә дә булдыра алмас, бу мөмкин түгел кебек тоела иде. Ул вакытларда үзенең кайчан да булса Исмәгыйль абыйга ничек тә ярдәм итә алачагы турында уйлый ала идемени ул? Әлбәттә, юк! Хәтта хәзер дә, инде ничә еллар үткәч, Дасаев вагонның буш коридорында үз-үзенә ык ышанган көчле кешенең шатлыклы көлү тавышын ишеткәндәй булды — шулай яңгыратып әле һаман да зәңгәр «Диамант»ына атланып йөрүче үги әтисе көлә иде.

Аны әнисе каршы алды. Рушан аны бер биш еллап күрмәгән иде инде, ә Гөлсем апа соңгы елларда бик бирешкән икән...

Рушанның әнисе үзенең матурлыгын-сылулыгын бик озак саклады, һәр йортта теләсә нинди яшьтәге кәләш булырлык чибәрләр табыласы булса да, күрекле кияү Исмәгыйль юкка гына ике балалы Гөлсемне алмагандыр инде. Сугыштан Мартукка бары өч, нибары өч кенә ир-ат әйләнеп кайтты. Ә киткәннәре... Иң яхшысы — исәпләп-санап, йөрәкләрне әрнетмәскә генә кала.

Рушанның дөньяга аваз салган туган йорты юл буенда ук булып, тәрәзәләренә тикле җиргә иңгән иде, шуның ишегалдына үзенең «Диамант»ына атланган Исмәгыйль абый җилле генә килеп керер иде. Хәзер бу урында кыргыйланып үскән роза куаклары күтәрелгән, ул элек бакча иде, аны мартуклылар розалар белән мавыккан бер заманда ясаганнар иде, аннары ул мавыгу узды да, бакчаны караучысыз калдырдылар. Ни хикмәттер, шуннан соң анда һәрнәрсә иркенәеп гөрләп үсеп китте, куаклары җәй саен аллы-гөлле шау чәчәк була. Чәнечкеле куакларга терәлеп үк кызыл-ак-зәңгәр төсләре чиратлаштырып буялган тәбәнәк рәшәткә койма тора. Аны үги әтисе һаман шулай чиратлаштырып буйый иде, хәзер дә шулай икән әле. Бу койманың һәр ике ягына да җиргә беркетелеп утыргычлар куелган. Алар урталай гына ярылган бүрәнә — яркадан ясалган, аларга кемнәрдер сөйгәннәренең исемнәрен тырнаштырып язган булган, хәзер ул язулар каралып тоныкланган, танылмыйлар да, ә бер ярка бераз ярылып-чатнап та киткән. Дасаев бу утыргычларны бик яхшы хәтерли. Алар да, розалар, ә соңрак фарсы сиреньнәре кебек үк, мавыгучан Мартукның берзаман мавыгып алуының нәтиҗәсе иде. Һәр йорт янында, һәр өйтүр бакча алдында шундый утыргычлар-эскәмияләр булыр иде. Әгәр язын син ясап куйган ояга сыерчыклар ояласа, сезнең утыргычны берәр гашыйк пар үз итсә — бу яхшы фал саналыр иде. Рушанның да шундый истәлекле утыргычы бар иде. Комсомол урамында, итекче Вася дәдәй йорты янында.

Рушаннарның яңа йортын кеше яллап эшләттеләр. Саман кирпечне чегәннәрдән сатып алдылар, алар җәйләрен шул авыр эш белән шөгыльләнә иде. Үги әтисе әле ул чакта әйбәт кенә күренсә дә, авыр эшкә ярамый иде инде. Аның каравы, архитектор, прораб, бригадир, тәэминатчы сыйфатында аңа тиңнәр булмады. Кешеләр яллаганда да, кемнең нәрсәгә сәләтле-яраклы икәнен яхшы белә иде. Балта эше сыңар аяклы Гани абый Ка-

дыйров өстендә булды. Беркайчан да күңел төшенкелеген белмәс, күкрәп торган тавышлы, бөтен авылга бердәнбер бу башкортның эшли-эшли җырлаганын тыңлап торсагыз икән! Вәт җырлый тек җырлый иде! Рушанның әнисе, кайчакларда аның җырлаганын онытылып тыңлап, ашын йә артык тозлы итә, йә токмачлары куерып бетә иде.

Ярый әле вакытында өлгертеп калганнар ул йортны. Юкса хәзер сатириклар әйтмешли, атаклы сынчы Бенвенуто Челлини үзенең бер һәйкәле өчен дә бүгенге балта остасы бер ишек яңагын каерган хәтле хак ала алмагандыр. Ә Гани абыйның челтәр-челтәр, кәрәз-кәрәз ишектәрәзә йөзлекләре, өй түбәсенә бастырып куйган күңелле-шаян этәче истәлек итеп кенә тотарлык иде. Әле хәзер дә алар йорты янынннан үтеп-сүтеп йөрүчеләр тукталып сокланып карап торалар, ә бит үги әтисе җырчы башкорт белән «архитектур бизәкләр» ясату турында сөйләшмәгән дә иде...

Улына әйтеп бетергесез шатланса да, Гөлсем апа вокзалдан кайтышлый, аны нигә чакыртканына үкенә дә башлаган кебек булды, Рушанны өйдә пенсия турында бер кәлимә сүз дә ычкындырмаска дип, кисәтеп куйды, ә инде ул эш белән йөрисе була-нитә калса, сак булсын, үги әтисе берүк белә күрмәсен! Сизенмәсен...

Алар ишегалдына кайтып кергәндә, җылы, тын, кичке шәфәкъ, иртәгәге көннең аяз булырын вәгъдә итеп, бәрәңге бакчалары артындагы күкне яртылаш алсуга манган иде инде. Рушанның үги әтисе, күрәсең, әле генә яшелләкләрне, чәчәк түтәлләрен, кыргыйланган роза гөлләрен шлангтан су сиптереп коендырудан туктаган гына булгандыр. Озын көн буена эссе кояш астында ятып кызган асфальт сукмактан пар күтәрелеп тора. Һавада җир исе, бакча исе, мондый тәмле исләр авылда бары тик яңгыр явып үткәннән соң гына була. Үги әтисе, соскыдагы көйрәп торган кызыл күмерләрне сикерткәләп, самоварга өстәп тора — Рушан кайтып кергәндә җиз чибәркәй җырлап утырсын, дип, мөгаен, әнисе кушып калдырган булгандыр әле, чөнки шунда ук җәйге ачык веранданың бер почмагына өстәл дә әзерләп куелган, сыйнигъмәтләр өстенә чебен-мазар кунмасынга ике катлап марля ябылган иде инде.

Үги әтисе болай беренче карап торышка артык үзгәрмәгән, гомере буена гел бертөрле йөртә торган «керпе» чәчләре тагын да чалара, тагын да сирәгәя төшкән — бары шул гына шикелле. Әмма Рушан бары тик хәзер генә аның ябыгып, яшүсмер малайлар шикелле кечерә-

еп калганын шәйләп алды. Аннары үги әтисенең чыраенда, сөйләшүендә дә ниндидер сизелмәслек кенә үзгәреш бар иде, Рушан моның хикмәтен шунда ук аңлады: ниһаять, үги әтисе ясалма тешләр куйдырган икән.

Алар ничектер уңайсыз гына, бер-берсеннән тартынган кебек кенә итеп кочаклашып күрештеләр, Рушан аның җылы бумази күлмәге астындагы очлы калак сөякләренең ябыклыгын тойды. Әнисе ул арада өстәлдән тиз генә нәрсәнедер алып, нәрсәләрнедер өстәде дә аларны чәйгә чакырды.

Исмәгыйль абый, килешли, су колонкасы янындагы чиләктән салкын тир бәреп торган кечкенә бер чәкүшкә аракы эләктереп алды. Рушанның кайтуы хөрмәтенә берне тотып куйдылар да тозлы кыярдан авыз иттеләр. Тelләре языла төште, сүз арты сүз, дигәндәй, үги әтисе сорап куйды:

— Озаккамы соң? Әллә элеккечә бер-ике генә көнгәме?

— Озаккарактыр,— диде Рушан һәм үзе дә көтмәгәндә: — Йорт сагындырган...— дип өстәде. Болай әйтүендә бернинди алдау да юклыгын, дөресе шулай икәнен үзе дә аңлады.

Аңа әнисенең яратып карап торуларын, үги әтисенең дә күзгә бәрелмәстәй игътибарлы карашын тоеп утыру рәхәт иде. Көйрәп-сүнеп барган самоварның онытыла төшкән күмер исе белән тәбәнәк сарай түбәсенә киптерергә җәелгән яңа чабылган печән исе бергә кушылып, тагын шуларга авыл мае, авыл сөте хуш исләре дә өстәлгән шушы туган йорт һавасын сулавы әйтеп бетергесез бер куаныч булды. Кайчандыр берара бөтенләй кайтырга җыенып та кайтмый калынган, хәзер инде сирәкмирәк кенә сугылгалап кителә торган үз йортында озаграк торасы килә иде аның.

Элек Мартукта мондый йортлар юк иде, дип әйтергә була, немецлар килгәч кенә шундый иркен-зур, пыялаланган верандалы йортлар төзелә башлады. Дөрес, хәзер инде тагын да арттырып җибәрделәр: верандаларны җылытыла торган иттеләр, йортлар эченә суын да керттеләр, кайбер таза тормышлы хуҗаларның йортларын пар белән җылытулары да сирәк күренеш түгел.

Картлар Рушанны өйнең «аныкы» саналган ягына — матур фикус гөлле зал белән караңгырак йокы бүлмәсе булган якка керттеләр, ул як баштан ук шулай уйланылып төзелгән, чөнки Рушан, укып бетергәч, өйгә кайтыр, киленнәрен дә яңа йортта каршы алырлар, дип өметләнгәннәр иде. Диңгез буеннан ял итепме булсын яки командировкадан кайтышлыймы, бер-ике көнгә кереп

чykканда Рушан гел уйлана иде: әгәр дә ул Мартукка бөтенләйгә кайтса, тормышы ничегрәк булыр иде икән? Һәм кайчакларда ул тормыш әкияткә охшаш тыныч, бер кайгысыз, рәхәт булып күзаллана иде. Әмма Рушан үзен мондый уй-хыяллардан тиз айныта, чөнки әти-әниләренең җайлы-уңайлы таза тормышында аның өчен иң мөһиме — һөнәренә ярашлы эш юк иде. Шуннан егет тынычланып кала.

Әлбәттә, Мартукка кайтырга да булыр иде, берәр эше дә табылыр иде әле. Ләкин ул чагында Рушан диңгезсез капитан яки зәңгәр күксез очучы хәлендә калыр, ә ир-ат өчен яраткан һөнәр-шөгыль кирәк, моны ул бала чагыннан ук үзләштереп үсте.

Әмма дүрттән өче, Дасаев шикелле үк, кечкенә авыл-поселоклардан килеп укып чыккан дипломлы белгечләр белән шыплап тутырылган Ташкентта ул кайвакытларда бу инженер кисәкләрен кызганып та куя иде: бахырлар күпсанлы төрле бүлек-бюроларда, өсте-өстенә өелешеп дигәндәй, бушка гомер уздыралар — ыштан туздыралар бит. Үз туган җирләрендә, бәлки, аларның белемнәренә, сәләтләренә тиң килердәй эш-шөгыль табылган булыр иде. Асылда зур эшләргә сәләтсез бу кешеләр кечкенәрәк урында, мөгаен, үзләрен күрсәтә алыр иделәр, илнең кай ягына барма — һәркайда төзелешләр бит, чат саен кран манаралары калкып тора. Тик юк, белем ягы да такыррак бу инженерлар шулай күнеккән, зур шәһәрләрдә чын-чынлап шәһәр кешесе булып китә алмыйча, шулай ышкынып яши бирәләр һәм еш кына тирән сагышка баталар — кышлагы-утары, авылы-поселогы, кыскасы, туган яклары сагындыра...

Рушан иртән уянганда, үги әтисе өйдә юк иде инде — Исмәгыйль абзый утыз елдан артык гомерен биргән промкомбинат сигезенче яртыдан ук эшли башлый.

Чәйне тәрәзәләре бакча ягына киереп ачып куелган верандада эчтеләр. Дасаевның кәефе күтәренке иде, әйбәт йоклады, хәтта матур төшләр — малай чакларын күрде. Моны сизенгән әнисе дәртләнебрәк китте, юкса, кичә вокзалда каршы алганда, улы йөрәк кушуыннан битәр бурыч үтәр өчен генә кайткан шикелле тоелган иде аңа. Хәзер ул күреп тора: улы бакчаны нурга күмгән кояшка да, җырлап утыручы самоварга да шат, сагышлы карашы койма аша күрше ишегалларын капшый, әледән-әле казакъ Мостафа агайның ишегалдында уйнаклап йөргән колынга күз ата.

Алар озаклап-тәмләп сөйләшеп утырдылар, Гөлсем апа көзгедәй ялтыратылган, сигез литр сыешлы самоварның

җыры тынмасын өчен аңа соскы белән ике рәт күмер дә өстәде.

Улының сораулары, әнисенең җаваплары гел дә бетмәс төсле иде — һәр сорау, һәр җавап кемнеңдер тормышына кагыла, ә ул, үз чиратында, Рушанның ерак үткәннәренә барып тоташа. Әмма, ике казакъ хатыны кереп, аларны бүлдерделәр, әнисе ул хатыннарны шунда ук чәй эчәргә утыртты. Өлкәнрәгенә, үз яшьтәшенә карап, горурланып:

— Минә Ташкенттан улым ялга кайтты әле, ул анда бәк зур инженер булып эшли,— диде.

Казакъ хатыны исә Рушанны кечкенә чагыннан ук белгәнен әйтте, башка малайлар белән бергәләп Гает бәйрәме белән котларга кергәч, аларга күчтәнәчне бик мулдан бирә алмавын исенә төшереп, көрсенеп:

— Ә хәзер, рәхим итсен, тәкә суярбыз, кунак булыр. Аллага шөкер, тормыш безгә дә битен күрсәтте,— диде.

Дасаев алар белән дә тагын бер пиала чәй эчте дә урыныннан кузгалды. Аннары алсу бәрхет камзул кигән бу пөхтә казакъ карчыгы көне буе башыннан чыкмады: кем ул? Утары кайда, кайсы якта икәнен тәки исенә төшерә алмады, ә бит аның балачактагы Мартугы ул кадәр зур да түгел иде.

Соңгы биш елда күп нәрсә үзгәргән: Украина урамына асфальт түшәлгән, иске йортлар беткән диярлек, барысы да яңа йорт җиткереп кергән. Анда-санда калган саман йортларны да яндырылмаган кирпеч белән тышлап куйганнар — урам күңеллеләнеп, матураеп киткән. Бала чагында бакчаларына кыяр-фәләнгә төшкәләгән, үсеп җитәрәк кача-поса гына кызлар өчен чәчәкләрен өзгәләгән күршеләренең ишегалларын таный да, таный алмыйчарак та тора торгач, Рушан түбәсе күгәреп беткән собес йортын үтеп тә киткән икән, аңа шунда керергә кирәк иде бит. Бу йортның ике кечкенә бүлмәсендә элек ул белә-белгәннән бирле районо иде. «Ярар, өлгерермен әле»,— дип уйлады Рушан, кире борылып тормыйча гына.

Промкомбинат яныннан үткәндә Дасаев адымнарын әкренәйтте, аннары, хатирәләргә бирелеп, бөтенләй туктап калды. Юл аша чыгып, сарыга буялган такта белән тышланган күрекле йорт буендагы сәрби куаклары күләгәсенә чүгәләде.

Мартукның төп туендыручысы булган промкомбинат бик озак, чирәм җирләр көч алып киткәнче, поселокта эш табып була торган бердәнбер урын иде. Рушан аның ул чагында галәмәт зур булып күренгән ишегалдына керерчыгар барлык ишек-капкаларын, хәтта койма тишекләренә чаклы белә, чөнки үги әтисе төн уртасына хәтле тот-

карланган көннәрдә ул аңа кичке эңгер-меңгердә, аз-маз булса да, ашарга илткәли иде. Ә бәйрәмнәрдә инде әйбәтләп юынып, киенеп-ясанып бирегә утренникка килә. Промкомбинатны халык «артель» дип кенә йөртә, менә шул «артель» балалар өчен әкәмәт матур чыршы бәйрәмнәре үткәрә иде. Ә «чып-чын» Кыш бабайның кучтәначләре-бүләкләре хәзерге белән чагыштырганда да әйбәт Яңа ел бүләге булыр иде, чөнки, балаларны ничекләр итеп куандырырбыз икән, дип, ике-өч ай алдан баш вата башлыйлар, бу эштә бер генә туң йөрәк тә булмый, балалар өлешенә кереп, катып беткән пәрәннек-конфет тутырып, яхшысын үзенә умырырга сәләтле кешеләрне бу күңелле бәйрәм тирәсенә якын да җибәрмиләр иде.

Дасаев комбинатның өч-дүрт катка күтәрелеп үсеп киткән яңа цехларына караштырып алды. Ул әнә теге ерак почмактагы бинаның икенче катында үги әтисенең мамык юрганнар сырганын белә, чәчәкле ситсы һәм төрле төстәге атласларны матур чигешле җөй белән атлатып сырылган ул юрганнарның нинди йомшак, җылы булганын да белә, кичә дә шундый юрган ябынып йоклады. Юрганнар әйбәт сатыла, хәзер инде башка өлкәләр дә сорыйлар, сырып өлгерт кенә. Цехка менеп, үги әтисенә комачауламыйча, беркая ашыкмый гына аның янәшәсендә утырасы килеп китте Рушанның. Аннары урам буйлап бергә кайтырлар иде — әбәткә күп калмаган бит инде. Әмма янә ул, монысына да өлгерер әле, ашыгасы юк, дип хәл кылды.

Кинәт кенә башына бер уй килде: әгәр комбинат парторгына кереп, үги әтисенең пенсиясе белән килеп чыккан буталчыклык турында сөйләшсә — үги әтисе, партийный булмаса да, хезмәт кенәгәсе чуарланып беткән шаталак адәм дә түгел, ветеран, өстәвенә — фронтовик, күкрәге тулы орден-медальләр.

Дасаев урыныннан күтәрелде дә элек заманнардан үзгәрешсез калган цинк калай түбәле бердәнбер бинага — бер катлы флигельгә юл тотты. Элек-электән комбинат җитәкчеләре — администрация шунда була торган иде. Әмма партком ишеге бикле булып чыкты, ә кемнән булса да ни өчен бикле икәнен сораштырасы килми, хәзер Исмәгыйль абзыйга җиткерерләр: улың парторгны эзли, диярләр.

Ул инде караңгы тар коридордан урамга чыгып бара иде, кинәт кемдер артыннан эндәште. Борылып караса, элек үзләренә каршы гына яшәгән Катя түти икән. Беләбелгәннән бирле ул шушы комбинатның бухгалтериясендә эшли иде.

Катя түти Рушанны кочып алды, ишегалдына бергә чыктылар.

— Сине күрмәгәнгә ни гомер... Өй туена Төньяктан ялга кайтканың истә, ул чакта мин әле биюче дә, җырчы да идем. Алексей (ул Рушанның үги әтисен шулай урысчалатып, исемен бозып атый) бик шәп йорт җиткезде, сине өйләндерәм, озакламый бу бүлмәләрдә оныклар чабышып йөрер, дип мактанган иде... Ничек соң, балаларың бармы?

— Юк, буйдак әле мин...

— Безгә бит тимер юл аръягында казна йорты бирделәр, без-картларның үзебез йорт җиткезерлек көч-жегәребез дә, акчабыз да юк. Ә балалар, синең кебек үк, очып, таралышып беттеләр. Синнән ешрак күрмимдер үзләрен... Әниең ни хәлләрдә? Аны да байтактан күргәнем юк, йә Хода, бер поселокта яшибез, диген инде. Элегрәк мин сездә еш була идем бит, самоварыгыздан чәй эчүнең кирәген бирдем инде! Шикәрләп тә, корылай гына да — булды инде, булды. Кайчагында искә төшерергә дә курыкыныч хәтта. Аллага шөкер, картайган көнебездә без дә кешечә яши башладык. Үзең соң «артель»гә ничек килеп чыгасы иттең әле?

— Менә, парторгны күреп сөйләшмәкче идем, сез инде, Катя түти, зинһар, бу хакта әтигә әйтә күрмәгез!

— Ә-ә-ә, аңлыйм-аңлыйм. Алексейның холкы чакматаш кебек шул аның. Ике сорамас. Собеска үпкәле, дип ишеткән идем. Картка булышырга алынуың яхшы булган, хәзер кәгазь заманы шул инде: һәр белешмәгә тагын белешмә кирәк, ә кайбер кәгазьне алу өчен ялварып, билгә кадәр бөгелсәң дә таман гына. Ә синең үги әтиең яшьлектән үк шундый: ачка үлсә үләр, түбәнсенеп мескенләнмәс. Аның холкыннан әниең дә интегәдер инде, ә? Яшәвен дөрес яши ул, башкалардан да шуны таләп итә, тик кешеләре төрле бит аның. Картка ярдәм ит инде син. Ә мин аңа тиешлесен күптән санап-исәпләп куйган идем инде, дөрес, әллә ни күп чыкмый чыгуын, әмма бөтенесен тиенен тиенгә хәтле кырып-себереп җыйдым, өч рәт санадым, бер нәрсәсен дә онытып калдырмадым. Безнең якларда элек акчалы эш юк иде бит, җиде кат тир түксәң дә, юк иде, хәер, аны син үзең дә беләсең булыр...

Дасаев ризалашып, баш кагып куйды.

— Мин сиңа, Рушан, аның кәгазьләре салынган папканы биреп торыйм, үзең кара, үзең сана, дигәндәй, авыр эш түгел. Тиеш булмаса да бирәм. Алексей белән бәйләп торган җепләр бар бит, аның белән бергә сугышка китеп,

аның күз алдында һәлак булып, аның кулы белән җирләнгән Дмитрием бар иде бит, киявем буласы кешем... аерылмас дуслар, районда бер волейболчылар иде алар Алексей белән... Егет чакларында...

Катя түти көрсенеп куйды:

— Син үзең кәгазьләрен карап чык инде...

## XXIV

Тасмалары бәйләп куелган юка гына папка эчендә үги әтисенең пенсиясе күләмен билгеләү өчен кирәкле кәгазьләр — күп еллык боерыкларның күчермәләре, хезмәт хакы ведомостьлары һәм башка шундый документлар гына түгел — бу кәгазьләрдә алар гаиләсенең бөтен тарихы саклана иде. Исмәгыйль абзыйның утыз елдан артык гомер юлы шунда, шул саргайган кәгазьләр Рушанны бала чагына, үсмер чагына алып кайтып киттеләр. Язу өстәле янында ул шуларны караштырып утырган бүлмәгә сиздерми генә ара-тирә әнисе килеп керә дә, аз белемле кешеләргә хас бер саклык белән, рәсми кәгазьләр арасыннан берәрсен кулына ала, үзләренең элекке күршесе Катя Панченконың почеркын таный, нечкә генә итеп шәмәхә кара белән сырланган язуларның әле төсе дә уңмаган.

Әнисенең моннан егерме еллармы элек ире эшләп алган тиеннәр-сумнар язылган берәр кәгазьгә каравы була, укып та тормастан, Исмәгыйленең ул вакытта нинди эш башкарганын шунда ук исенә төшерә — Рушанның баштарак моңа исе китә иде: менә хәтер тек хәтер икән! Әнисе исә, әгәр берәр эше көтеп тормаса һәм кәефе килсә, шул ерак калган еллардан берәр истәлекле вакыйга сөйләп ташлый. Сөйләгәндә, күрсәтмәскә тырышып кына, башындагы яулык чите белән яшьле күзләрен сөрткәләп ала, ә Рушан күз алдына онытылып беткән диярлек ул вакыйгалар аша үз гаиләләренең тарихы гына түгел, ә артель тарихы, бөтен Мартукның тарихы килеп баса.

Әнисенең хәтеренә искитәрлек тә бар шул: гел шул бер промкомбинатта күп еллар эшләсә дә, үги әтисе дистәләрчә һөнәр алыштырган икән — исеңдә тотып бетереп кара әле! Юк, Исмәгыйль абзый шаталак яки һөнәр белмәс адәм булмаган. «Алтын куллы, алтын башлы»,— диләр иде аның турында, мондый сүзләрне Рушан да бер генә ишетмәде. Эш башкада: «артель» озак еллар хәлсез-көчсез булып килде, дөресен әйткәндә, эшләренең дә рәте-чираты юк иде, ел саен диярлек бер цех ачыла, икенчесе ябыла, дигәндәй. Урысча әйтсәң — чехарда...

Эшчеләр туплап, аларны өйрәтеп, көч-хәл белән планны үти генә башлыйлар, халык инде әйбәт хезмәт хакы булыр дип өметләнә генә — «артель»нең алыштыргысыз рәисе Ильяхин күңелсез хәбәр алып кайта: өлкәдә фәлән цехны ябып, төгән цех ачарга боерып җибәргәннәр икән. Ә бер ел үткәч, эшчеләрне һәм эш коралларын таркатып бетергәч, узган ел ябылган цехны ашык-пошыктан яңадан ачарга кирәк була. Ул еллар эчендә нинди генә цехлар ачылып ябылмаган да, ябылып ачылмаган, диген: каеш сбруй цехы, тегү цехы, кондитер цехы... Хәтта бөтен өлкәнең колхоз рәисләре утырып йөри торган җиңел-җитез кошевой чаналарга хәтле ясыйлар иде Мартуктагы бу «артель»дә. Бай да инде безнең җиребез оста куллы, зиһенле халыкка! Шул зур да булмаган поселокта итеген дә басалар, тунын-толыбын да тегәләр, пәрәвездәй җиңел-очалак шәлләрен дә бәйлиләр — нәрсәгә генә тотынмасыннар — булдыралар, тел шартлатып карап торырга гына кала. Ул заманнарны һаман да искә алып сөйлиләр шул... Ә цех ябулары исә кешеләрне эштән чыгару белән башлана иде. Әмма Исмәгыйль абзыйны бу афәтләр читләп үтә торды: теләсә нинди эшкә кулы ята иде аның, үзе тагын сүз тыңлаучан, кушканнарын бер карусыз үти, шуңа күрәдер, бәйрәмнәрдә һәрчак урыны түрдә — президиумда түше тулы орден-медальләрен балкытып утырыр иде. Шундый уңган-булган фронтовикны ничек эштән кусыннар, ди инде. Яхшы булмас иде ул. Күзен идәнгә текәп яки читкә карап кына Ильяхин әйтер иде: «Син, Алексей, гаеп итмә инде, кабаттан яңа цехка өйрәнчек итеп җибәрергә туры килә үзеңне, син булдырырсың». Шуңа күрә дә кайбер ведомостьларның битләренә әтисенә шул замандагы акча белән нибары 280-320 сум гына язылган, ә бит юкса, шимбә-ялсыз гына түгел, еш кына якшәмбесен дә эшләтәләр иде әле.

Ләкин әнисе күңелсез хәлләрне генә түгел, кинәт кенә башкаларын да исенә төшерә, менә ул, шул ук кәгазьләргә карап, гел уйламаганда, шул айда сайлаулар булганын әйтеп куйды. Аның йөзе яктырып китте, якты киләчәктән башканы вәгъдә итмәгән, үзенә бер яхшылык та китермәгән, хәзер инде онытылып беткән яки онытыла язган юлбашчыларны исем-фамилияләре белән җылы итеп телгә алды. Ә Рушан, әнисенең сүзләрен тыңлар-тыңламастан, Мартуктагы бәйрәмчә күңелле сайлау көннәрен күз алдына китерде.

Сайлау мәктәптә үткәрелә, шунлыктан, төп агитпункт та шунда, сайлауларга бер ай кала ул инде кичләрен балкып тора, шаулатып радиола уйный иде. Ә сайлау көнне

эти-әниләре әче таңнан ук сайлап кайтырга китәләр, Рушан әле йоклап калган була. Алар дуслары, хезмәттәшләре, туган-тумачалары белән бер-ике рюмка төшереп,— бөтенхалык бәйрәмендә анысы да гаеп эш түгел,— әнисе әле урысча хромкага «барыня»ны, кыңгыраулы татар тальянына «әпипә»не дә биеп, күңелләләнеп кайтып керерләр иде. Буш кул белән кайтмыйлар, нинди дә булса сайлау күчтәнәче — тәмле әйбер күтәреп кайтырлар иде: әфлисун, хәлвә, арыш перәннекләре, йә булмаса ысланган корбан балыгы — анысы инде бигрәк сирәк эләгә торган азык, шуңа күрә истә калган да...

Шулай истәлекләргә бирелеп, аналы-уллы икәү — алар кайчакларда сәгатьләр буе утыралар, ә беркөнне әбәткә кадәр утырганнар, янкапкадан этиләре кайтып кергәнне күргәч кенә исләренә килделәр. Рушан югалып калды, өстәлдәге кәгазьләрнең бөтенесен дә яшереп тә бетерә алмады, ярый әле, Исмәгыйль абзый аларга игътибар итмәде.

Өстәл янында булсын, соңрак кичләрен үги этисе белән бакчага су сипкәндә яки берәр хуҗалыкта кирәкле әйбер ясаганда булсын,— һәр йортта эш җитәрлек була,— Рушан аның белән ара-тирә бер-ике сүз генә алыша, сөйләшсәләр дә, кирәклесен генә сөйләшәләр иде.

Дасаев шуны шәйләп алырга өлгергән иде: еллар үткән саен ир балаларга этиләре белән сөйләшү-гәпләшү кыенлашканнан-кыенлаша, катлаулана бара шикелле, ә менә кыз балаларга әниләре белән сөйләшү һич тә алай түгел. Аларның киресенчә була: кызлар елдан-елга әниләренә якыная баралар, чөнки үз балалары үсә, ана мәшәкатьләрен үзләре дә күтәрә башлыйлар.

Рушанның һәм аның яшьтәшләренең бала чагы аерым иркәләү-назлау күрмичәрәк, ташбаш малайларның шуклыкларына эти-әниләре «ах-вах» килмичәрәк үтте. Ата-аналарның кайгысы башка иде — ничек ашатырга да, ничек киендерергә кирәк ул балаларны? Ул заманнарда төп хәсрәт шул иде. Эшкә таң белән чыгып китәләр, караңгы капкач кына кайтып керәләр, әмма эшләгәннәре көчкә-көчкә генә очын-очка ялгап, җан асрарга җитә. Кая инде анда иркәләп-иркәләнеп торулар?! Менә Рушан да, әле үзенә алты яшь кенә тулган булса да, үги этисенә «эти» дип әйтә алмады, чөнки үз этисенең танкист булганын, Мәскәү тирәләрендә ятып калганын белә иде инде. Соңрак, үсә төшкәч тә, үги этисенә ул бары тик «абый» дип кенә эндәшә торган булып калды, «эти» дип әйтергә теле әйләнмәде. Юкса, баштарак Исмәгыйль

абый, малайны үзенә ияләштерергә теләп, күп вакыт сарыф иткән иде. Хромнары ялтырап торган «Диамант»-ын да ватар-җимерер дип курыкмады, аны велосипедта йөрергә башка малайларга караганда иртәрәк өйрәтте. Рушанның чанасы да, тимераяклары да үги әтисе ясап биргән әйберләр иде, ә инде ул ясаган чаңгы авылда бер генә иде, ләкин барыбер Исмәгыйль абый улыннан үзе көткән «әти» сүзен ишетә алмады.

Хәзер шуларны исенә төшергәндә, Рушан үзенең бала чактагы ул кирелеген һаман да аңлый алмый әле. Бик күп балаларның әтиләре бөтенләй юк иде бит, ә аның, үги булса да, бар, шундый әйбәт, шат күңелле, җитмәсә әле ул орден-медальләре генә дә ни тора! Рушанга бөтен малайлар көнләшеп карый, Алексей дәдәйне Мартукта иң көчле кеше дип санийлар, юкса үги әтисе Петька Васятукның әтисеннән күпкә тәбәнәгрәк тә инде. Ә менә тәки бер генә мәртәбә дә Рушан аны «әти» дип атамады...

Әнисе өйдә юкта Рушан аркылы-торкылы җиз калайлар сугып эшләнгән иске кытай сандыгын ача, анда кайчандыр әбисенең бирнә әйберләре сакланган. Сандыкның тар гына ян бүлемтегендә Исмәгыйль абыйның орден-медальләре ята. Сугыш исен татымаган, бер нәрсәгә дә ышанмаучы хәзерге скептиклар күзлегеннән караганда да, үги әтисенең бүләкләре шәп иде, алар, чынлап та, күп — тугыз. Беренче орденын Исмәгыйль абый әле утыз тугызынчы елда ук, Хәсән күле өчен сугышларда алган. Бала чагында үзен магнит кебек тартып торган орденнарны яңадан караганда, Рушан ул заманнарда ярлы яшәсәләр дә, еш кына кунаклар чакырганнарын, бәйрәмнәрдә үги әтисенең орденнарын тагарга онытмаганын исенә төшерде.

Аракы дигәнең зур бәйрәмнәрдә генә өстәлгә менә, бер-ике шешәне иң дәрәҗәле, иң кадерле кунаклар алдына гына куялар, шуннан артыгын мартуклыларның кесәсе күтәрә алмый иде. Ә кунак көтүче хуҗалар бәйрәмнәргә берничә атна кала әче бал куялар. Бу әчемлек алай каты түгел, әмма исертә, аны һәр йортта үзләре белгәнчә ясыйлар. Андый әчемлекне сатуга ясаучылар юк иде, шунлыктан, хакимият кешеләре «үзе өчен генә» әче бал ясаганнарга бармак аша гына карый иделәр. Рушан, орден-медальләрне берәм-берәм караштырганда, үги әтисенең кунак җыйган көннәрдә хәрби кителенә, гадәттә, ике генә орден — икесе дә «Дан ордены» — такканын хәтерләп алды. Хәзер инде Рушан ул орденнарның бәһасен белә. Әмма бу хәлләр бик күптән, Исмәгыйль абый үз әнисе Зәйнәп әби белән икәүләп Рушаннарга күчеп

килгән, Исмәгыйль абый «Диамант»ына атланып йөргән һәм «Локомотив» командасының бер генә волейбол уенын да калдырмаган заманнарда ук булган иде инде. Үги әтисе ул команда данын яклап әле сугышка кадәр үк уйнаган икән.

Элек,— моны Рушан яхшы хәтерли, чөнки ул хакта малай-шалай да, күрше хатыннар да сөйләнә иде,— орден-медальләр өчен күп булмаса да, акча түлиләр иде. Үги әтисенең бүләкләре байтак, Мартукта һәр тиен исәптә, аны эшләп алыр җире дә бик күренеп тормый. Шулай булгач, шул аз акча да ярап куя иде. Әнә шул бүләкләре өчен бирелә торган акчага Исмәгыйль абый кайчакларда гаиләсен дә сыйлаштыра иде. Ләкин озакламый ул түләүләрне ни өчендер бетерделәр. Дөрес, Мартукта бу хәл үги әтисеннән башкаларга кагылмады да диярлек, әмма Исмәгыйь абыйның моңа бик эче пошты. Ул түләүләр гаиләгә бераз ярдәм генә түгел, авылдашлары алдында аның абруен да күтәрә иде бит. Гади фронтовик кына түгел, ә кирәгенчә сугыша да белгән, шуңа бүләкләре дә күп, хөрмәте дә зур иде — һәм менә шуны кистеләр дә куйдылар.

Үги әтисе әле тагын шуңа да гарьләнә, кайберәүләр аны юри үртиләр, орден-медальләрен «тимер-томыр» дип кенә җибәрәләр иде. Рушан аның Оренбургтан вак-төяк сатарга килгән берәү белән Октябрь бәйрәмендә шуның өчен сугышып киткәнен хәтерли.

— Провокатор, сволочь! — дип кычкыра котырынып киткән Исмәгыйль абый, аның җирән сипкелләре үлектәй агарынган йөзенә чәчрәгән кан тамчылары төсле янып тора иде.— Синең ишеләрне мин баскан җирендә атып үтерер идем, гнида, спекулянт...— дип тагын да кыза ул, дусты Васятукның көчле кулларыннан ычкынырга талпынып.

Ә теге бәндә, арты белән ишеккә чигенә-чигенә, кәҗә тоягы күрсәтеп, усалланмакчы булып маташа:

— Хәсрәт сугыш чукмарлары... Казакъ хатыннары шикелле, түшләренә тимер-томыр такканнар да, монда да фронт тәртипләре урнаштырмакчылар... Үзегезнең намусыгыз, дөреслегегез белән кайгы шулпасын эчәрсез әле... Еларсыз, ыштансыз генераллар...

Шул вакыйгадан соң үги әтисе сандыктан орден-медальләрен сирәгрәк ала, сирәгрәк тага башлады. Әмма ызгыш-талашлы, сүгенү-сугышлы башка мәҗлесләрне Рушан хәтерләми.

Аларда күбрәк бер үк кунаклар була иде. Васятук, күрше Панченколар, үги әтисе туган Оренбург якларын-

нан берничә татар, әнисенең ахирәт дуслары — бер-ике тол хатын-кыз һәм һәрвакыт Гани абый, аның сул аягы урынына үзе әтмәлләп куйган агач аяк булыр, үзе мәҗлесләрдә беренче җырчы һәм гармунчы булыр иде. Ә ул мәҗлесләрдә нинди генә җырлар җырламыйлар — татарныкы, башкортныкы, казакъныкы, урысныкы, украинныкы, немецныкы — һәммәсе дә җырланыр иде. Рушанның күңелендә иң калганы Гани абыйның көр, күкрәктән чыккан тавыш белән җырлавы, хәтта кайбер сүзләре дә истә әле:

...Кыңгыр бога, һау-һау,
Кыңгыр бога, һау-һау...

Күп еллар үткәч, Рушан белде: бу «бога» үгез дигән сүз икән, шуннан урысларга да кереп киткән дә, «бога» сүзе «бугай»га, аннары «бык»ка әйләнгән икән! Бугай — иң усал, иң сөзгәк үгез инде ул. Хәзерге урыс үгезе...

Рушан кунакларны әнә шул җырлары өчен ярата да иде. Ә кайвакытларда кунак ир-атларның күпчелеге үзләре үткән солдат юлларын искә алалар, ул заманнарда әле яңарак кына булып узган сугыш һәрдаим үзен сиздереп тора иде. Гадәттә, «Ә менә Германиядә...», яки «Ә Польшада...» дип сүз башлыйлар да, аннан китә инде! Шулай да күбрәк тыныч тормышны ничек көйләү, малтуар, игеннәр, хуҗалык итү, гореф-гадәтләр һәм башкалар турында гәпләшәләр... Әмма юк-юкта, янә канкойгыч каты сугышларга барып төртеләләр. Соң, шул ук «Ә менә Германиядә...», «Ә менә Польшада...» күпме гомерлек дус-ишләр, якташлар башын салган, ятып калган ич... Онытырга мөмкинме шуларны?..

Ничек кенә сәер тоелмасын, үги әтисе андый әңгәмәләрдән качарга тырыша, әмма мәҗлестә һәрвакыт берәр яңа кеше була һәм ул аның бүләкләрен сораштыра башлый: бу орден нәрсә өчен бирелгән дә, бу медаль ни өчен тагылган? Исмәгыйль абый бер-ике сүз белән саран гына җавап бирә: мөһим махсус бурыч үтәгән өчен, ди. Бетте китте! Әмма, сирәк кенә булса да, кәефе килепме, әллә дусты Васятукның хатирәләреннән кабынып китепме, үзе дә кайбер нәрсәләрне сөйләп ташлый иде ул.

Шул сөйләшүләрдән әкренләп Рушанның аңында үги әтисенең сугыш елларындагы сурәте-образы ачыкланды. Хәзер инде яшенә караганда артык картаеп киткән, аз сүзле, тын гына кыштырдап йөрүче бу картка карап, кайчандыр аның кыю солдат булганлыгын күз алдына китерүе дә кыен иде. Дасаев хәзер, аның орден-медальләрен карый-карый, бала чагында хәтерендә калган солдат образына әйләнеп кайтты.

Исмәгыйль абый сугышта разведкада, ә төгәлрәге — разведчикларның элемтәчесе булган. Дошман тылына үтеп керә икән дә, немецларның телефон чыбыгына ялгана икән, ә немец телен яхшы белгән безнең бер офицер тегеләрнең бар сөйләшкәнен тыңлап тора икән. Билгеле инде, шундый шартларда немецлар белән күзгә-күз очрашулары бер генә булмаган, ул бит бөтен сугышны дошман җирләрендә, бик күп чакрым нейтраль җирләрне дә артта калдырып,— ә аларны үтүе җиңел булганмы? — сугышып йөргән. Үги әтисе ут кебек җирән һәм, чынлап та, немецка охшаган булгандыр. Полк тегүчеләре бик пөхтәләп тегеп биргән вермахт солдаты формасы киеп йөргән ул. Бу кием елның барлык фасылларына да яраклы булган, хәтта көндез дә, төнлә дә аерылмас автоматы да немецларның «шмайссер»ы икән.

Бала чагында үги әтисе авызыннан ишеткәннәреннән Рушанның күңеленә аеруча берсе сеңеп калган... Исмәгыйль абый немецларның борын төбендә генә баганага менеп, тегеләрнең телефон чыбыгына үзенекен ялгап азаплана икән. Кием-салымы, коралы, наушниклары — барысы да немецныкы, койган да куйган немец элемтәчесе инде менә! Ә ерак та түгел куаклыкта — иптәшләре, сержантның багана буйлап сиздерми генә чыбык сузып, җиргә төшкәнен, аны немец телен белгән офицерга хәтле сузганын көтәләр. Кирәк бит, нәкъ шул чакта бер унбишләп немец солдаты килеп чыкмасынмы! Багана башындагы элемтәчене күреп, алар үз телләрендә нәрсәдер кычкырыналар, көлешәләр. Сержант, алардан уздырып, бердәнбер мөмкин булганны эшли — чыбыкларның ике очын да ашыга-ашыга авызына каба да, шулай ук күңелле елмаеп, тегеләргә кул изәп җавап бирә. Җиңнәре терсәгенә кадәр сызганылган, бит-куллары җирән сипкелле — яз бит. Шат күңелле, батыр «Ганс», нечкә муенына «шмайссер» автоматы асылган, ә багана төбендәге бозау тиресеннән тегелгән ранецында, кем дә булса карый-нитә калса — һәр нәрсә немецныкы, хәтта авыз гармунына чаклы бар. Разведкада һәммәсе дә уйланылган, әмма төп ышаныч — түземлек, салкын канлылык, ихтыяр көче...

Хәтта еллар үткәч тә Рушан үги әтисенең аякларының, менә-менә «тырнаклары» ычкынып китәрдәй булып, хыянәтчел калтырануын, кулларының авыраеп калган «шмайссер»га ирексездән ябышуын күргәндәй була, әмма ярамый, ул, бөтен тәненә салкын тир бәреп чыккан килеш, озын-озаклап үзен үзләренеке итеп таныган немецларга елмая һәм кул изи...

## XXV

Үги әтисенең пенсия мәсьәләсен хәл итәргә атна да, ун көн дә җитмәде, ләкин, дөресен әйткәндә, бу вакыт эчендә Дасаев Алушта ял йортына юлламасы барлыгын исенә дә төшермәде. Берсекөнгә ул Оренбургка барырга ниятләде, юк, яшьлеге үткән шәһәрне күрү өчен түгел, хәер, бу бару ул ягы белән дә күңелле иде, ә иң мөһиме — үги әтисенең метрикә язуына әтисенең исемен төзәтеп язарга һәм собес өчен туган елын ачыкларга кирәк иде.

Собестагы яшь кенә кызлар һәм аларның башлыгы — шулай ук шактый яшь бер марҗа белешмәләр актарып утырырга да, Дасаевның дәлилләрен тыңларга да теләмәделәр. Рушан аңлап алды: биредә, гомумән, беркемне дә юньләп тыңлап тормыйлар, көнгә әллә ничәшәр кабатлап торган яраткан әйтемнәре бер генә: «Мәскәү күз яшьләренә ышанмый». Дасаев берсендә тыелып кала алмады: «Мартук Мәскәү түгел әле»,— дип бәреп әйтте. Мондагы хәлне тиз генә төшенеп, бу ваемсыз битарафлыкны бәреп ватып булмаслыгын, ниһаять, аңлады ул, һәр очракта да бу марҗалар хаклы булып калачак, зарланып шикаять язсаң — шелтә алырлар да котылырлар, ә ул шелтә алар өчен, марҗаларча әйтсәң, «до лампочки». Рушан буйсынырга мәҗбүр булды һәм Исмәгыйль абзыйның әтисе исемендәге «в» хәрефен «ф» га, ә метрикә язуындагы «5 март» урынына «9 март» дип алыштырылган рәсми документлар алып кайтып бирергә карар кылды. Үги әтисенең утыз елдан артык күрше урамнан бер үк промкомбинатка эшкә йөрүе исә беркемне дә кызыксындырмый иде.

Ул иң иртәнге поезд белән юлга чыкты. Поезд Оренбургка элекке шикелле биш сәгать түгел, ә алты сәгать бара икән, хәзерге тизлек заманында бөтенләй аңлашылмаслык хәл иде бу. Ул вагонга үтеп тормады, юкса буш урыннар да бар, бер-ике сәгать черем итеп алырга да булыр иде, яшь кенә проводница кыз да керергә кат-кат үтенеп карады, әмма Рушан тәки шалтыр-шолтыр бәргәләнеп-суккаланып бара торган тамбурда басып калды.

Күптән юылмаган тамбур тәрәзәсен кулъяулыгы белән ышкып сөртеп, Рушан каршыга йөгереп килгән станцияләр, разъездларны күзәтеп бара башлады. Бу юлдан аның күп тапкырлар үткәне бар, кайчандыр ул Мартуктан Оренбургка кадәрге юлдагы һәр станцияне, һәр разъездны берсе артыннан берсен, ялгышмыйча, балалар санагычындагы шикелле итеп санап чыга һәм шуны ук тиз-

тиз генә кире тәртиптә дә әйтеп бирә ала иде. Ә менә хәзер ул аларның кайберләрен генә таный: Яйсан, Акбулак, Сагарчин... Боларны татарча төркиләштерсәң, ничек булыр иде икән? Таныш җирләрнең күп кенә исемнәре хәтердән чыккан, җилгә очкан, аннары, үзгәрешләр дә бик күп, киңәйгән-үскәннәр, бары тик исемнәре генә сакланып калган шул. Тамбурда басып торганда, аның күңеленнән кичә булып узган вакыйга һич китмәде, юкса әллә ни-нәрсә дә түгел иде инде.

Иртән әнисе, орден-медальләр саклана торган шул сандыктан мең тугыз йөз кырык җиденче елгы бер төргәк заем облигацияләре тартып чыгарды да улына шуларны саклык кассасына кереп тикшертеп алырга кушты: кем белә, отмасалар да, бәлки, кире кайтарылган — погашение акчасы чыгар, хәзер күпләргә чыга икән.

Рушан бер-ике сәгать китап кибетендә юанды, гаҗәбенә, анда аңа кирәкле бик күп техник китаплар һәм белешмәләр табылды. Үзләренең трест китапханәсе өчен дә дип, һәркайсысын берничә данә алды, шунда әнисенең гозере исенә төште, саклык кассасына сугылган иде, бәхетенә, утыз сум акча отып чыкты. Аның әбәткә кайтырына өметләрен өзгән карт белән карчык инде чәйгә утырганнар иде, шунда Рушан кайтып керде, тантаналы кыяфәттә елмаеп, әнисенә шытырдап торган өч яңа унлык тоттырды. Сәер, кинәт килеп кергән бу акчаларга ни әнисе, ни үги әтисе шатланмады. Дасаев гаҗәпләнеп, шаярткандай итеп сорап куйды:

— Бик баедыгызмы соң, инде утыз сум да акча түгелмени сезгә? — диде.

Әмма аның шаяртуы урынсызрак булып чыкты. Рушанның тамагыннан ризык үтмәде, ашаса ашады, ашамаса — юк дигәндәй булды. Әле менә хәзер дә, бер кешесез буш тамбурда басып торганда да, шуны исенә төшергәч, оятыннан йөзенә кызыллык йөгерде.

— Их, улым,— дигән иде әнисе, авыр сулап.— Кырык җиденче елда бу кәгазьләрнең һәркайсысы этиеңнең чирек эш хакына тиң иде, ә хәзер аңа нибары бер шешә аракы тия. Ул заманнарда йөз сумы түгел, ун сумы да алтын бәясе иде безгә, хәтереңә төшер әле...

Вагон көпчәкләренең текелдәвен тыңлый-тыңлый, иртәнге салкыннан куырыла төшеп, Рушан хәтере белән кырык җиденче елга кайтып китте. Кыш азагында үги әтисенең әнисе Зәйнәп әби үлде. Ул, ничек тавыш-тынсыз яшәгән булса, шулай сизмәгәндә генә, кинәт дөнья куйды. Аны мөселманча итеп, ак кәфенгә төреп җирләргә кирәк иде. Өйләрендә дә, таныш-белешләрендә дә бер мет-

рлык та яңа ак ситсы-фәлән табылмады, алай гынамы соң, урын җәймәсе дә юк иде — ярлылык чиктән ашкан булгач, анысы да ярап торыр иде әле. Кибетләрдә дә чүпрәк-чапрак бик аз була, булганы да пай книжкәләренә генә, ә Рушаннарның андый книжкәләре юк, иң зур бәла — өйдә бер тиен акча да юк чак иде. Кыш бик салкын булып, тирес кирпеченә генә дә Исмәгыйль абыйның ярты эшләп алганы китә, җитмәсә әле, ай саен заемга басып калалар... Әнисе кемнән нәрсә сорарга да белми, аптыраштa калды, ә үги әтисе... Улмы соң кемнән булса да берәр нәрсә сорар кеше? Күрше Васятуктан сораса гына инде, алай дисәң, анысы болардан да хәерчерәк...

Исмәгыйль абый пошаманга төшеп, кашларын җимереп, бик озак уйланып утырды, аннары кинәт кенә торды да тиз-тиз киенде, кышлыкка әйбәтләп майлап, бүлмәдә үк элеп куелган, йортның бердәнбер бизәге һәм горурлыгы булган, сугыштан трофей булып кайткан «Диамант» велосипедын күтәрде дә буран эченә чыгып югалды. Берәр сәгатьтән соң ул төргәге белән әйберләр күтәреп кайтып керде, өйдә бер чеметем чәй, бер шакмак шикәр юк чак иде. Үги әтисе ике шешә аракы да кыстыра кайткан, калган акчаларын ул сүзсез-нисез генә хатынына сузды. Рушанны шул буранда, өйдән-өйгә йөреп, әбиләренең үлгәнлеген хәбәр итәргә чыгарып җибәрделәр. Һәм шул күз ачкысыз буранда зиратка барырга яше-карты кузгалды, күпчелеге эшсезлектән интегүчеләр иде. Ничек кенә сәер тоелмасын — зыкы салкын булуга да карамастан, каберне тиз һәм җиңел казып куйдылар. Әнисе исә, кулында акча була торып та, егерме метр марляны бары тик көн уртасында гына таба алды. Зәйнәп әбине шуңа төреп, кәфенләп җирләделәр.

Күп еллар үткәч, Дасаевка ишеттерделәр: кемнеңдер купшы-бай җеназасы вакытында кемдер орденлы батыр Исмәгыйльгә төрттереп, әнисен марляга төреп күмде, ун метр бәзгә дә акчасын кызганды, дигән, имеш. Үги әтисе бу юлы сугышып тормаган — буласы булган, туны тузган, дигәнмедер, ояты-хәсрәте дә басыла төшкәндер, бәлки. Ә язын Рушан кемнәрнеңдер малайларында көнләшеп тә, уңайсызланып-оялып та «Диамант»ны күрермен, дип йөрсә дә, шуннан соң Мартукта ул велосипед юк булды...

Тар һәм кысан тамбурда таптангалап торган Дасаев үги әтисе белән бәйле тагын бер вакыйганы исенә төшерде. Ул вакытта инде ни Зәйнәп әби, ни зәңгәр «Диамант» юк иде, Рушан үзе әллә икенчедә, әллә өченчедә укып йөри иде.

Яз башында «артель»нең итек басу цехын яптылар. Анда итек кенә түгел, бик тыгыз зур-зур киез тулалар да басалар иде. Җилле-далалы бу якларда казакълар аны бик яратып ала һәм келәм урынына кулланалар иде. Исмәгыйль абый шуларны да баса, киез итекләргә дә кулы җитә, ап-ак меринос сарык йоныннан, нигездә, хатын-кызлар өчен җиңел-нәфис «чәсүнкә» итекләрне дә коеп кына куя иде. Бу һөнәренә ул башкаларына караганда озаграк өйрәнгән — итек йә тула басу гади генә, җиңел генә эш түгел икән ул. Көннәр буена тавыш, гөрелте астында күзләрне әчеттерә торган тузанлы, түбән сортлы йон арасында утырып кара әле! Иң авыры шунда: түшәлгән йонның ни калынлыгын, ни тыгызлыгын-тигезлеген үлчәгеч нәрсәләр юк, барысын да бармакларың белән капшап чамаларга туры килә. Кулың тоймый, сизми икән — димәк, брак китә, ә бернинди эшнең рәтен-чиратын белмәгән һәм эшләргә яратмаган, колакка катырак Шәйхи ОТК, ягъни техник тикшерү бүлеге «башлыгы» бигрәк явыз, шул явызлыгы белән генә урынында утыра да. Исмәгыйль абый бу һөнәрне дә үзләштерә, шул кышта әнисенең аяклары күз явын алырдай «чәсүнкә» итеккә тиенә, ә Рушанга — йомшак, җылы кара киез итекләр. Менә шул цехны ни сәбәптәндер япканнар бит. Бик күп эшчеләрне шунда ук эштән чыгарып ташлыйлар, дөрес, Рушанның үги әтисен калдыралар калдыруын, ләкин бер эш тә тәкъдим итмиләр, бу юлы «өйрәнчек булырсың» дигән коткаручан сүз дә ишетелми...

Исмәгыйль абый көн саен эшкә бара, анда нәрсәләрдер майтара — кыскасы, һәрвакыт түрәләр, башлыклар күз алдында була. Менә шулай йөргән көннәрнең берендә кожзаводның,— «кожзавод» дип шул «артель»нең бер кечкенә цехы атала,— тире иләүчесе Гыймай абый Рушанның үги әтисенә сабын кайната башларга тәкъдим итә. Тиреләрдән кырып алынган әшәке майдыр-ярыдыр артыгы белән җитеп ашкан, ә каустик сода һәм башка химикатларны табу «артель»нең көченнән килмәслек эш түгел икән.

Поселокта эш таба алмый йөрүчеләр арасында да «төнге алтын» түгүче яки сабын кайнатучы булу иң соңгы һөнәрләрдән санала иде, әмма утыз тулып кына узган яшь ир, уйлап та тормыйча, бу эшкә риза була, юкса, мөгаен, белгәндер: моннан соң ни волейбол мәйданчыгына, ни кино-фәләнгә йөреп булмаячак, сасы сабын исе әллә кайлардан аңкып торачак бит.

Ул елны өйләренә тулган сабын исен Рушан бик озак оныта алмады, хәзер дә, кер сабыны күрсә, күңеле болгана башлый.

Үги әтисе шул сабын кайнату фикере белән Ильяхинга да барып керә. Җавап кыска була: өлкәдә дә күрсәтерлек бер әрҗә сабын ясап бир, калганы — минем өстә, ди. Директор, үз җаваплылыгына алып, тәвәккәлләп, кожзаводның ике бүлмәсен боларга бирә, кайнату казаннарын, күмерен, содасын да кызганмый — складта бу эш өчен яраклы ни-нәрсә бар, һәммәсен дә яздырып алырга рөхсәт итә. Юкса тиеш эш тә түгел инде. Әмма...

Сабынны Мартукта кайнатып та карамаганнар, өйрәтер-күрсәтер кешесе дә юк. Бу фикерне биргән Гыймай абый үзе дә эшнең нечкәлекләрен белми, Оренбургка барырга киңәш итә, анда сабын кайнатучы татарлар бар, алар киңәшләрен кызганмаслар әле, ди, алай-болай кирәк булса, дип, бер тире иләүченең адресын да тоттыра.

Күңеле күтәрелеп киткән Исмәгыйль абый шул көнне үк, саубуллашып, вокзалга төшеп китә. Урамда инде май ае, җылы, рәхәт. Исмәгыйль абый, вагон түбәсендә генә оеп, тиздән Оренбургка да барып җитә. Бары тик вокзалга җитәрәк «Меновой двор» дигән тирәдә сикереп төшеп калырга гына кирәк була — вокзалда билетсызларны милиция тотып ала икән.

Үги әтисе бу шәһәрдәге эшләрен тиз башкарып чыга. Шадра битле, пеләш сабын кайнатучы: «Күрәсең, тормыш бик тә китереп кыскандыр, юкса шушындый яшь һәм уңган кеше сабын эшенә алынмас иде»,— дип әйткән, ди. Ә Исмәгыйль абыйның фронтовик һәм үзенә якташ икәнен дә белгәч, сабын кайнату серләрен яшереп тормаган, сөйләгән дә биргән. Башлап җибәрергә кирәк булыр, дип, бер ярты капчык төрле химикатларын да кызганмаган әле, отставкадагы җирән сержантның «хәлләнә төшкәч, түләрмен» дигән сүзләренә ышанып калган.

Үги әтисе, ничек килгән булса, шул ук юлдан кайтып та киткән, бары тик тиз йөрешле поезд түбәсенә бер потлы капчык белән менеп утыру гына кыенгарак килгән. Һәй, юкка разведчик булганмыни ул? Йокы вагоннарының баскычлары ул заманнарда эчкә батырып эшләнгән булган. Үги әтисе, бара-барышлый, капчыгын бер вагон баскычына ыргытып өлгергән, янәшә икенче вагон баскычыннан үзе сикереп менгән дә, түбәсенә үрмәләп, шуннан капчыгын үрелеп алган, үз уңышына куана-куана сызгырынып кайтып та бара икән.

Бар иде заманнар: Урта Азиянең җылысына һәртөрле этрәк-әләм, угрысы-фәләне тартыла-елыша иде. Алар да, Рушанның үги әтисе шикелле үк, вагон түбәләренә утырып киләләр, юл уңай, станцияләрдә авыл, калаларга су-

гылып, берәр төрле «гамәл» дә кылып өлгерәләр, әмма аларның төп максаты — ерактагы икмәкле Ташкент каласы була иде.

Менә берзаман шундый башкисәрләрнең бер төркеме кайсыдыр станциядә Исмәгыйль абый барган поезд түбәсенә дә үрмәли бит. Үги әтисе аларны тиз генә абайламаган — очраклы гына әйләнеп карагач, вагон түбәләрендә халык сирәгәйгәнен күргән: тегеләр, үзләрен яклап кала алмастай кешеләрнең барлы-юклы төенчек-фәләннәрен талап, үзләрен куып төшереп киләләр икән. Үз вагонына бер дүрт вагон кала Исмәгыйль абый, тегеләр күзенә чалынмаска уйлап, поездның баш ягына — паровоз тирәсенә үк елышырга ниятли, анда, торбадан чыккан төтен-корымнан бик пычрак булгач, берәү дә ул тирәгә утырырга тырышмый. Инде көймәсе бик комга терәлсә, ревизорларга эләгү куркынычы булса да, түбән төшеп, вагонга керергә чамалый ул.

Үги әтисе, шәһәргә барып кайтырга дип, Гыймай абзыйдан алып торган өр-яңа таза сүс капчыгы өчен борчыла. Теге башкисәрләр, капчыктагы бөтен бар булганын селкеп ташлап, бернәрсә алмасалар да, пычрак, каты вагон түбәсендә аска җәеп куяр өчен бу капчык менә дигән инде. Исмәгыйль абыйның, урыныннан кузгалып, ашыга-ашыга поездның аргы башына китеп барганын тегеләр шәйләп тә алганнар, шәп капчыгын да күргәннәр һәм, куып тотарга исәпләп, артыннан чаба да башлаганнар. Үз әйберләрен югалтасы килмәгән Исмәгыйль абый да йөгерергә тотынган. Шунда кинәт исенә төшергән: бер йөз метрлардан соңгы борылышны үткәч, Илек суы аша сузылган озын Каратугай күпере буласы бит. Ул, капчыгын ташлап, үзен куып килүчеләргә таба борыла да, кулын болгый-болгый: «Күпер! Күпер! Күпер!» — дип акырырга тотына. Үзе түбәгә ятып өлгерүгә, состав күпергә барып та керә.

Күпернең ике торыгын үтеп, аргы якка барып чыккач, Исмәгыйль абый башын күтәреп караса, теге чукынмышлар да өс-башларын каккалап, аякланып азапланалар икән. Барысы да агарынып калган. Исмәгыйль абый янына килеп, папирос тәкъдим иткәннәр.

— Нәрсәң бар, абзый? — дип сорый икән аны «Казбек» папиросы белән сыйлаганы.

— Алтын,— дигән Исмәгыйль абый, ваемсыз гына итеп.

Егетләр дәррәү көлеп җибәргәннәр, йөзләрендәге агарыну-курку билгеләре дә юкка чыккан, ә тегесе атаманнарыдыр, күрәсең, тагын сорый икән:

— Миллионер булгач, кызык өчен вагон түбәсендә кайтып барасыңмы?

— Йокы вагонында бөркү,— ди Исмәгыйль абый.

— Кая, капчыгыңны карыйк әле.— Шул капчык аркасында чак кына үлемнән калган егетләргә шулай да кызык бит.

— Ә син, абзый, җебек түгел икәнсең, куркудан һушың китмәгән, күпер турында искәрттең. Гомер онытмабыз, рәхмәт! — дип, Исмәгыйль абыйга үзләренең киселеп-тырналып беткән, рәтләп юылмаган каты-кытыршы кулларын бирәләр.

Капчыкны актара башлаганы:

— Фу-у-у, исе! — дип, борынын җыера.

Исмәгыйль абыйга үзенең тормышы-көнкүрмеше турында да, Оренбургка ни өчен килгәнлеге турында да сөйләп бирергә генә кала.

— Әй, ташла бу мәшәкатьләреңне, сабының белән сасып кына бетәрсең, рәтле акчасы да булмас, киттек безнең белән. Башлы абзый күренәсең, Ташкентта берәр җаен табарбыз әле,— ди атаманнары.

Ләкин Исмәгыйль абый, рәхмәт әйтеп, ул тәкъдимнән баш тарта.

Поезд барган уңайга тегеләрнең берсе, вагон-ресторанга төшеп, аракы-шәраб, төрле кабымлыклар алып менә, Исмәгыйль абыйның андый затлы ризык-нигъмәтләрне күрмәгәненә дә биш былтыр була инде. Шулай итеп, вагон түбәсендә тегеләр белән кәеф-сафа корып, өенә кайтып җитә ул. Саубуллашканда, тегеләр аңа бербөтен ак күмәч белән утыз сумлык кызыл акча тоттыралар.

## XXVI

Оренбургта Рушан дүрт көн булды. Исмәгыйль абый туган Заһид хәзрәт мәхәлләсендәге архив кәгазьләренең бер өлеше гражданнар сугышы елларында, әлеге кварталда ак генерал Дутов гаскәрләре торган чакта ук юкка чыккан, калганнары да, бер бинадан икенчесенә күчерелә-күчерелә, шактый сыекланган-сирәгәйгән. Юкка гына: «Ике күчену — бер янгынга тиң»,— дип әйтмиләрдер инде. Кая ул әллә кайчангыларны эзләп табу! Әнисенең моннан өч ай элек язган ике үтенеч хаты җавапсыз калган булган, шулары да көчкә-көчкә генә табылды. Ләкин биредә Дасаев төрле ишекләрне шакып кына калмады, күп кенә кабинетларда өстәлгә суга-суга да сөйләште.

Оренбург бик нык үзгәргән, бу тирәләрдә газ чыгару эшләре башлангач, халкы да икеләтә арткан. Шәһәрнең кайсы башына гына барып чыкма, шул ук бер калыптан сугылган шөкәтсез йортлар тырпаеп утыра — Ташкентта да, Тулада да шулар ук. Үз йөзе, үз төсмере булган тагын бер борынгы шәһәр юкка чыккан, аның урынына «индустриаль гигант» калыккан дигән сүз. Дасаев бик ярата торган Җаек суы да саеккан, яр буендагы ямь-яшел урманнарына карарга да кызганыч. Рушанның бердәнбер юанычы бик кыенлык белән алынган ике белешмә кәгазе булды.

Ял көннәре эреп югалгандай кимеп барса да, Дасаев, үзенең уллык бурычын үтәгәннән генә түгел, ә үз туган тамырларына, үз ыруына якынлыгын тоюдан, үз ягы, кешеләре, йортлары, елга-күлләренең шушы өч атна эчендә үзенә тагын да кадерлерәк булуларын аңлаудан күңелендә бер рәхәт тынычлык хасил булганлыгын сизде. Күптән инде аның мондый халәттә булганы юк иде.

Алып кайткан кәгазьләрен собеска илтеп биргәч, ул, еш кына велосипедка атланып, йә җәяү генә Илек суы буена төшеп китә: су коена, кызына, балык тотып маташкан була иде. Әмма юмарт итеп җим сибеп торсаң да, хәтта иң симез суалчаннарга да вак-төяк маймычлар гына каба — балыкларны да агулап-нитеп бетергәннәр икән инде.

Кичләрен ул өйдә булырга тырыша, озын көннең көн буена эшләп арыган үги әтисе белән ашыкмыйча гына ашап-эчеп, сөйләшеп утырырга ярата иде. Шуннан соң алар бакчага су сибәләр, берәр кирәк-яракны ясап йә төзәтеп-рәтләп куялар, аннары, бер-берсенә булыша-булыша, самовар үрләтеп җибәрәләр.

Катя түти биргән кәгазьләрдән укып, Дасаев үги әтисенең озын-озак хезмәт елларында җәйгелектә кепка, кышлыкта колакчынлы бүрек, күн итек теккәнен, камыт-ияр ише сбруй әйберләрен дә оста әтмәлләгәнен, сабын гына түгел, конфет та кайнатканын, ә бер җәйдә «артель» бакчаларында су сиптерү буенча механик та булганлыгын, аннары тегермәндә эшләгәнен, һәм, хәтта бер ярты ел түрә булып, авырып киткән кладовщик урынына эшләп йөргәнен дә белә иде. Үги әтисе бары тик такта яру һәм балта эшләрендә, аннары кое өчен бетон боҗралар коюда гына катнашмаган икән. Дасаев аңа карап болай дип уйлый иде: «Мартукта шахта булса — үги әтисе шахтер, завод-фәлән булса — завод эшчесе булыр иде. Әнә бит, ул үзе дә бу якларда берәр зуррак завод-фабрика булмаганга уфтана, анда аның зиһенле башына һәм оста кулларына яраклы эш табылмый калмас иде әле...»

Су буенда йөргәндә Рушан үги әтисенең тормышы турында озаклап уйланды. Исмәгыйль абзыйның тормыш юлы аллы-гөлле чәчәкләр сипкән юл булмаган, күбрәк чәнечкеле-тырнаулы булгандыр, әмма иң өметсезлеккә бирелерлек көннәрдә дә үги әтисе берәүне дә тиргәмәгән-каргамаган, хакы булса да: «Без ни өчен сугыштык соң?» — дип күкрәк какмаган. Мондый сүзләрне ул аек баштан гына түгел, бераз төшереп алганда да әйтмәгән.

Элегрәк, йә Ялтадан, йә Сочидан кайтышлый гына, Рушан әти-әниләре янына бер-ике көнгә сугылып чыга иде. Тегеләр инде, билгеле, ул Сочи вә Ялта дигәннәрендә нинәрсәләр бары белән кызыксыналар. Ул шәһәрләрне алар шул Рушан җибәргән открытка рәсемнәреннән һәм кинолардан гына күреп беләләр бит. Ләкин ни әнисе, ни үги әтисе бервакытта да үзләренең, гомер буе баш күтәрми эшләп тә, беркая да бара алмаулары, бер җирне дә күрмәүләре турында авыз ачып сүз әйтмәсләр иде. Бу хәлне Рушан үги әтисенең пенсия өчен исәп-хисап кәгазьләрендә егерме бер мәртәбә «файдаланылмаган ялы өчен компенсация» дигән сүзләрне укыганнан соң исенә төшерде. Баштарак ул бу еш очрап торган сүзләрне игътибарсыз гына укып киткән иде, аннары аңына килеп җитте: үги әтисе егерме бер ел буена ялсыз-нисез эшләгән бит! Аның, әтисеннән ничек шулай булганын сорыйсы килде. Әмма шунда ук үзен тыеп калды — нигә кирәк ди инде картларны ул күңелсез заманнарга кайтарырга?

Үз ачышыннан үзе әсәрләнеп, Рушан әлеге кәгазьләрне берничә мәртәбә кире кайтып укыды, шик юк иде — егерме бер ел! Рушан туган йортына кайткач, чәй янында үзенең бик арыган-талчыккан булганлыгын, икенче ел инде ялсыз эшләгәнлеген әйтеп, зарланып утырганын исенә төшерде. Ә алар, ягымлы вә кайгыртучан карт белән карчык, ник берәр мәртәбә аңа каты сүз әйтсен, үз тормышларын мисалга китереп, төрттереп куйсын, юк, алар бары аңа теләктәшлек белдереп, көрсенеп кенә утыралар иде.

«Нинди пижонлык! Нинди ахмак тәти егетлек! Кемнәр алдында бит әле? Үз әти-әниләрең алдында!» — дип, оялып уйланды хәзер Рушан.

Кичләрен ул кайбер көннәрдә су буена атка атланып килә иде. Күрше Мостафа агайның Мукаш исемле улы колхозда бригадир булып эшли, һәр казакъ шикелле, ат ярата, хәтта бәйгеләрдә катнашу өчен дә үз чабышкы юртагы бар иде. Өлкә ат чабышларында аның Каракүзенә чабаннар, теләсә кайсын сайлап ал, дип, «Жигули» машиналары тәкъдим итәләр, әмма Мукаш атыннан да

төшми, елык-ялык килеп торган машиналарга әйләнеп тә карамый икән. Мостафа агай менә шул Каракүзне кичләрен су буена алып төшәргә Рушанга ышанып тапшыра, чөнки, урак өсте башланып, Мукаш үзе куна-төнә кырда-басуда була — аңарда ат кайгысы калмый иде.

Рушан китәр алдыннан гына Мукаш аларга кайгылы хәбәр белән килеп керде. Әнисе сыер сава, ә йокыдан иртә торган Рушан сыерны көтүгә куарга ниятләгән иде — соңгы көннәрендә картларга ни беләндер булса да ярдәм итәсе килә иде аның.

— Әти үлде...— диде бер көндә ничектер каралып, ябыгып калган Мукаш. Һәрвакыт шат күңелле, чибәр егет Мукашның кайгылы хәбәре өй борынча чыгып китте.

Әнисе ирен уятырга өйгә юнәлде. Рушан Таҗйолдыз кушаматлы сыерны көтүгә куып кайтып кергәндә, Исмәгыйль абзый ишегалдында ике көрәген кайрап тора иде инде. Шунда ук җирдә ломы да ята. Мостафа агайның каберен казышырга Рушан да барырга булды.

— Бар, улым, бар,— диде Гөлсем апа, улына өчлекбишлекләрдән торган егерме сумлап акча биреп.— Бар, безнең соңгы картларыбызны син күреп, хәтерләп калырга тиеш. Әтиең белән яшьтәшләр иде бит... Тагын кайчан кайтырсың әле... Аксакаллар белән хушлашып кал... Акчаларны дога кылганнан соң өләшерсең, йоласы шулай, улым. Мостафа агай бик кешелекле, бик әйбәт кеше иде, урыны җәннәттә булсын! — дип, сөйләнәсөйләнә, Рушанны капка төбенә кадәр озатып калды ул.

Тыкрык-урамнардан чокыр аръягы зиратына таба көрәктер-ломдыр күтәргән кешеләр агыла башлады. Аксакаллардан кемдер Мостафа агайның кабере урынын тәгаенләгән, каберне казый башлаганчы, картларның намаздан чыгып килүләрен көтәләр икән. Әле мулла абзый да,— элекке бухгалтер, пенсионер Миңлегали бабайны шулай дип йөртәләр,— ул да килеп җитмәгән. Кем генә булмасын, ничек кенә яшәмәсен, кешене тын гына, шау-шуларсыз гына, оркестр-музыкаларсыз гына җир куенына салу кирәк — Мартукның мөселман аксакаллары бердәм шул фикердә иделәр.

Зиратка җыелган картларның — кичәге көнлекчеләр, төрле эштә йөрүчеләр, көтүчеләр, ерак-еराклардан Семипалатка ит комбинатына мал куучыларның һәммәсе дә Аллаһыга ихластан ышанадыр дип әйтеп тә булмый. «Мулла абзый» Миңлегали бабай да бер-ике догадан артыгын белмидер, анысын да, иң укымышлы кеше итеп, җәмәгать үзенә шул вазифаны тапшырганнан соң гына ятлап алгандыр әле.

Каберне яшь-таза егетләр һәм ир-атлар казыды. Эшне тиз тоттылар, чөнки халык күп җыелган иде. Кабер авызын алганда гына, картлар, йола өчен дип, иң җиңел көрәкләр белән берәр көрәк җир алган булдылар. Рушанга да, кабер янында ук торса да, күп казырга туры килмәде.

Исмәгыйль абзый яңа казылган кабер янында укылган догаларның бетүен көтеп тормады, улына көрәк-фәләннәрне алып кайтырга кушып, тын гына китеп барды — аның эшкә чыгасы бар иде. Рушан азакка кадәр булды, Мостафа агайның ак кәфенгә төрелгән гәүдәсен Мукаш белән бергәләп, аска төшеп, кулларына алды, ләхеткә иңдерде, махсус такталар белән томалап куярга булышты.

Барысы да таралып беткәч тә, Рушан зиратта тоткарланып калды. Мөселман зиратлары артык тәртибе-пөхтәлеге белән аерылып тормый, гомер итәргә дучар булып калган туганнарына бик авырга килгәнгәме, үлгәннәрне артык кадер-хөрмәтләү дә юк шикелле. Нигездә, буялган тимер чардуган, яки гадел вә акыл иясе Барый абый Шакиров исән чагында ул ясаган, бушлайга куя торган бетон кабер ташы булыр иде.

Зират үзе дә чәчәк-ниләрсез, гадәтләнелгән яшел агач-куакларсыз, котырынып үскән көлсу төстәге әрем һәм чәнечкеле шайтан таягы белән капланган. Рушан, кабер ташларындагы язуларны укып, таныш исем-фамилияләргә тукталыбрак, үзләрен дә хәтерләргә тырышып, шактый озак йөрде. Инде чыгып барганда, янтаеп-иңеп калган бер ташка күзе төште, бәлки, килеп карар кешеләре дә юктыр, дип, аны төзәтеп куймак булды.

Бик кыенлык белән булса да, ташны турайтып, кабер өстен тигезләп-рәтләбрәк куйгач, уелып-коелып беткән бетон өстендәге язуны кыенлык белән генә укыды. «Кашаф Вәлиев. 1923—1949 ел.», аз гына астарак тагын әле «Онытмагыз безне...» дигән язуы да бар иде. Хәзер инде утызга җиткән Рушан белән чагыштырганда нибары егерме алты ел гына яшәп дөньядан үткән бер егет гүя Рушанга дәшә иде: «Онытмагыз безне...»

Кашаф Вәлиев... Кашаф... Рушан сугыштан исән-сау кайткан өч егетнең берсен шунда ук исенә төшерде. Димәк, Кашаф та, бәхетле көннәр күрә алмыйча, үлеп киткән икән, сугышларда йөреп, исән-сау кайтканнардан хәзер нибарысы икәү генә — үги әтисе белән күрше Васятук кына калган икән... Әйтерсең лә еллар аша моңсу, сагышлы күзле Кашаф илереп кычкыра иде: «Онытмагыз безне... Онытмагыз безне...»

Кичләрен Рушан белән үги әтисе уллары үзбәкчәләтеп ясап куйган айванда — урысча әйтсәк, беседкада утыргалыйлар, аны Рушанның ясаганына үги әтисе белән әнисе гаҗәпләнеп һәм куанып бетә алмаган иделәр. Үги әтисе, сиздермәскә тырышса да, эштән бик арып кайта: көне буе аяк өстендә — уенмыни сиңа! Ни әйтсәң дә картлык — шатлык түгел шул инде. Бу үзбәк айваны бик кулай булып чыкты — әтисе баш астына бер кечкенәрәк мендәр салып, арзанлы «Прима» сигаретын мөштегенә утыртып, шунда ятарга ярата иде. Аның тартуы да картларчарак, тәтенен суыра да уфылдатып чыгарып өскә өрә. Шундый мизгелләрдә Рушанның күңелендә әле моңарчы булмаган хисләр кузгала. Аның, үги әтисе янына килеп, ниндидер ягымлы-җылы сүзләр әйтәсе яки берәр яхшылык эшлисе килә башлый иде.

Ул электән, Исмәгыйль абзыйның һәрвакыт ирләрчә горур булып, озын хезмәт юлында үз абруен югалтмыйча, тамчы да түбәнсенми-тезләнмичә яшәгәнен аңламаган да, ул хакта уйлап та карамаган булган икән. Үзе дә түбәнсенмәгән, мөмкин булса, башкаларны да түбәнсетергә юл куймаган ул.

Бу кайтуында әнисе Рушанга моннан бер ун еллар элек булган бер вакыйганы сөйләп алды. Ул елда печән ягы бик начар булган икән — сәбәбе корылык-фәләннән генә түгел, колхоз үз вакытында әзерли алмаган: эшләргә кешеләре җитми, ә өлешкә — пайга кереп чабарга рөхсәт юк икән, печән бәяләре бик тә үсеп киткән. Кем яшьрәк тә, кемнең транспорт-фәләне бар, шулар күрше район һәм өлкәләрдән алып кайтып әзерләгәннәр ул печәнне. Шул чагында Рушанның әнисенә кемдер: «Син военкоматка язып кара әле»,— дип киңәш биргән. Нәкъ шул елларда фронтовикларга ниндидер өстенлек — льготалар була, дигән сүзләр чыккан чак була бу. Әнисе язган инде, шулай да шулай, күп орденлы фронтовик, хәзер инде сәламәтлеге дә нык какшаган карт кешегә ярдәм итә алмассызмы, янәсе. Әлбәттә, бу хакта Исмәгыйль абзыйның үзенә — ләм-мим инде! Чөнки әнисе белеп тора, әйтсә, тегесе: «Мин льготалар белән печән алыр өчен сугышып йөрмәдем, туган илемне якладым»,— дип кенә җибәрәчәк, картның талканы коры.

Күпмедер көннәр үткәч, кичләтеп боларга бер капитан килеп керә, хәрби комиссариатның яңа хезмәткәре икән. Әлбәттә, өстәлгә җырлап торган самовар да менеп кунаклаган инде. Капитан Исмәгыйль абзыйдан, әнәсеннән җебенә чаклы төпченеп, барысын да сораштыра икән: ничек яшисез, ничек эшлисез, улыгыз кайда, нин-

ди бүләкләрегез бар? Һәм башкалар, һәм башкалар... Исмәгыйль абзыйның кәефе күтәрелеп киткән, Гөлсем апага бөркет булып кына карый икән: күрдеңме, карчык, янәсе, мине ничә елдан соң да онытмаганнар. Кунак капитан сүз арасында гына сыер-печән якларын да сораштыра икән. Карт белән карчык, бу игътибарлылыктан биһуш булып, икесе беравыздан әйтеп ташлаганнар: «Ул сыерга хәзер печән өчен машинасына өч йөз илле сумны каян алып чыгарып бирмәк кирәк!» — дигәннәр. Шунда капитан әйтә: «Телисезме, без Ташкент хәрби комиссариаты аша сезнең улыгызны кысыйк, эти-әнисенә ярдәм итсен, дип, эш урынына хат җибәрик»,— ди. Бу «ярдәмче» капитанның ни өчен килгәнлеген Исмәгыйль абзый шунда гына аңлап ала. Хакимият башындагыларга хөрмәт белән карарга өйрәнгән булып, үзен кулда тота алса да, бу юлы ул түзеп кала алмаган, аптырашта калган капитанның өстенә килә башлаган һәм ишеккә ымлаган: исән чакта чыгып кит! Хәтта теге адәмнең эчеп бетерелмәгән чәйле пиаласын да кулыннан йолкып алган. Шуннан соң әнисенә әләккән сүзләрне сөйләп бетерерлек түгел инде — шуңа да ул бу пенсия эшләрен дә бик саклык белән генә кузгаткан булган икән...

Исмәгыйль абзыйның пенсия мәсьәләләре ничек хәл ителеп беткәнен көтмәстән, Рушанның китеп барасы килми иде, шуңа күрә, ул эш урынына берничә көнгә тоткарланачагы турында телеграмма да җибәрмәкче иде, әмма өйлә вакытында Исмәгыйль абзый бик әсәрләнеп-куанып кайтып керде. Өстәл янына ашарга утыргач, ул, суыткычка таба ымлап, берәр нәрсәң бармы, әнисе, дигәндәй, баш какты. Әнисе баштарак аңышмый да торды: ире алай эш вакытында бер дә эчми иде ләбаса! Шуңа күрә мунча көннән калган «Пшеничная» аракысы шешәсен китереп куйганда, шуны искәртергә кирәк тапты.

— Әнисе,— диде Исмәгыйль абзый, дәртле-шук елмаеп,— бетте! Эшемне бетереп кайттым. Шабаш! — Ул шешә төбендә калганын рюмкаларга бушатты.

Шул бар булганын тотып, күтәреп куйгач, тәмләп сөйләп бирде: нәкъ әбәт алдыннан аны кадрлар бүлегенә чакырып алганнар икән дә пенсия билгеләнүен хәбәр иткәннәр һәм аны айның икесе көнне алачагын да әйткәннәр. Димәк, тагын бер атнадан... эшләми-нитми генә... кулга акча үзе килеп керәсе икән!

— Җитмеш ике сум бит, әнисе, җитмеш ике сум! — дип куана үги әтисе.— Һәрхәлдә, Шәйхинекен төкереп салдым бит, аныкы алтмыш сигез сум гына чыккан иде... Ә безгә, әнисе, җитмеш икесе дә бик җиткән, безгә күп

кирәкми бит, шулаймы, энисе? — дип, шатлыгын кая куярга белмәгән Исмәгыйль абзый һаман да карчыгына кабат-кабат сөйләнә иде.

Өйләдән соң, шул ук күтәренке күңел белән, Исмәгыйль абзый эшенә китеп барды, соңгы эшләрен бетереп, үзендәге эш коралларын тапшырып кайтасы бар иде аның. Картлач шулай да эт булып арыганлыгын һәм пенсиясенә бик шатланганлыгын әйткән иде. Рушан, әнисенә күз кысып, чемоданын тутырырга, алып китәсе китапларын рәтләргә кереште. Ташкентка иртәнге поезд белән үк китәсе итте. Әнисе исә күршеләргә ярдәмгә йөгерде — кичкә кунаклар җыеп, әтиләренең озак көтеп алган пенсиясе хөрмәтенә дә, улы китү сәбәбе белән дә утырасылары бар иде.

Алдагы көндә кибеттән сорап алган Болгария шәрабыннан бушаган картон тартмаларга алып китәсе китапларын рәтләп тутыра-тутыра, Рушан кинәт уйга калды: ни өчен әле үзенең шундый истәлекле көнендә үги әтисе Шәйхинең пенсиясен искә төшерде икән?

Рушан Исмәгыйль абзый белән Шәйхи арасындагы астыртын көндәшлекне, әлбәттә, ишетеп белә иде. Дөресен әйтергә кирәк, бу көрәш тигезсез иде: алар икесе ике дәрәҗәдәге баскычта торалар: үги әтисе шикелле үк башлангыч белемле генә булса да, кесәсендә партбилетлы Шәйхи гомере буе «түрә кисәге» булган, Исмәгыйль абзыйның эшенә «бәһа биргән», «тикшергән», «карап торган» һәм аны «эшкә алган» кеше, имеш.

Гомере буена бер эшнең рәтен-чиратын белмәгән, акылга таманрак Шәйхи җирән Исмәгыйльнең алтын кулларына һәм зиһенле башына гел көнләшеп яшәгән. Ул, Исмәгыйль менә-менә сыгылыр-сынар, чал башы белән бер цехтан икенчесенә яңа һөнәргә өйрәнеп йөрмәс, эчүгә сабышыр, менә шунда «эчкече һәм эш калдыручы» мөһере сугып, артына тибеп куып чыгарырга хыялланган Шәйхи. Шундый «ярамаган эшләрне» карый торган комиссиянең җитәкчесе дә булган әле ул. Үзе чукраграк, надан булса да, «партийонный» бит... Әмма, юк, Исмәгыйль солдат зарланмаган, түрәләргә чабып йөрмәгән, кайда гына куйсалар да, эшләвен белгән.

Ә шул ук Шәйхи Исмәгыйль абзый теккән ничәмәничә кепканы, ул баскан ничәмә пар итекне йә «өченче сортлы» дип, йә бөтенләй бракка чыгарып утырган бит әле. Исмәгыйль баш иеп килер, явызланма дип, ялварып-үтенер, кызган мине дип, аяк астына тезләнүен көткәндер. Күпме пар итек-башмак, кепка-бүрек, янәмәсе, тикшерергә дип алынган да, шулай юкка чыккан,

аларны Шәйхинең туган-тумачаларында күреп, үзе теккән нәрсәләрне алганын Исмәгыйль абзый үзе генә белә. Әмма үги әтисе ул кабихнең йөзенә бәреп, бервакытта да «карак» яки «жулик» дигән сүзләр әйтмәгән. Ләкин Шәйхи үзе Исмәгыйльнең пычрак эш тузанына баткан, арыпталып кызарынган күз карашларыннан һәрвакыт бер үк сүзләрне укыган: кабахәт, надан, карак син... Шуңа күрә дә явызлыгының чиге булмаган тегенең.

Бары бер генә мәртәбә Исмәгыйль абзый аның өстеннән җиңү хисе кичергән, әмма бу җиңү бик кыйммәткә төшкән аңа.

Ул вакытта Рушанның үги әтисе тегермәндә эшли, төгәлрәге, икмәк киптерү-тартуда — кечкенә генә тегермән кисәге кожзавод белән янәшә иде. Шунда колхоз икмәген киптерәләр дә, тарталар да, аерым хуҗалыклардан килгәннәрен дә кире борып җибәрмиләр. Мескен халык еш кына тегермәнгә бер-ике пот ашлыгын күтәреп килә, берәр капчык белән килүчеләре бик сирәк була иде. Тарттырып биргән өчен бер өлеш онны хөкүмәт исәбенә басып та калалар бит әле.

Ничектер бервакыт, олы улларын ияртеп, тегермәнгә Шәйхи дә килеп керә. Әлбәттә инде, юньле кешеләр кебек, беркем белән дә исәнләшеп тормый, ни «исәнмесезе», ни «әссәламәгаләйкеме» юк — бу хәл Яңа ел алларыннан булып, шактый озын чират тезелгән икән, Шәйхи ул чиратка күз дә салмаган, алга үткән. Һәркем бодаенмазарын бункерга үзе сала, лардан агач соскы белән җылы онны капчыгына тутыра. Исмәгыйль абзый тартылган онны тикшереп-күзәтеп тора, тегермән ташларының тизлеген йә киметә, йә арттырып җибәрә, квитанцияләр дә язып бирә, милиция урланган-фәлән түгелме дип бәйләнмәсен өчен инде монысы, тарттырган өчен өлеш онын дәүләт ларына да сала бара.

Чираттагы берәүнең барлы-юклы бодае тартылып бетүгә, Шәйхи аның артыннан торган казакъ агаенең капчыгын читкә кагып кына җибәрә дә, малайлары бункерга авыр капчыкларны бушатып та куялар. Рушанның үги әтисе, чираттагы квитанция кәгазен язып торган арада, ул, әлбәттә, тегеләрнең кыланмышларын күрә, ә чиратта торучылардан ник берәрсе сүз әйтсен! Шәйхи капчыкларын да үлчәтеп тормыйча, бункерга аударттыра бит, квитанция дә яздырттырмый, димәк, билгеле инде, оннан хөкүмәткә тиешле онны да чыгарырга уйламый.

Ярар, бодае салынган, тегермән ташлары матур гына әйләнә, он да әйбәт кенә ага, тартылуы да менә дигән. Тук-симез йөзенә канәгатьлек чыгарып, Шәйхи елмаеп

тора, малайлары капчыкларга он салырга дип, аларны әзерләп тотканнар, этиләре, һаман авызын җыя алмыйча, ашыгып-ашыгып соскы белән капчыкларына он тутырырга тотына.

Исмәгыйль абзый бу очракта көчсезлегеннән гаҗиз булып, бу хурлыкка үзе өчен дә, башкалар өчен дә гарьләнеп утыра, аның ут булып янып чыккан кызыл йөзен бары тик он тузаны гына каплап тора. Менә ул өстәле яныннан кузгала, кемнеңдер капчыгын үлчәп куйган була, аннары әкрен генә өскә менеп китә. Анда нәрсәнедер караштырган-төзәткән кыланып төшә дә, яңадан өстәле янына утырып, язуларына иелә. Он тигез генә, куе булып ага тора. Кинәт ниндидер шытырдау-шыгырдау тавышы һаваны яра, бункердан тегермән ташы өстенә шунда ук калган бодай бөртекләре коела, он урынына малларга ашатырга яраклык кына ниндидер катнаш, аңламаслык нәрсә ага...

Шуннан соң! Әлегә кадәр тегермәндәге халыкка бер кәлимә сүз дәшми торган Шәйхи Исмәгыйль абзый өстенә карчыга шикелле ташланмакчы була, кычкырынырга-акырынырга керешә, йодрыкларын төйнәп, яный башлый, зыянны түләргә боерып азапланмакчы була. Исмәгыйль абзый түләргә риза булганлыгын әйтә, башта Шәйхи квитанциясен күрсәтсен, күпме капчык алып килгән дә аңа нәрсә түләргә кирәк икән?

Шәйхи, шулай итеп, үз гомерендә беренче мәртәбә авызы пешеп кайтып китә, шул бодайларын Исмәгыйль абзыйга бик озак исенә төшереп йөри әле ул. Үги этисенә исә Яңа ел бәйрәмендә тегермән ташларын яңадан көйләп-төзәтеп йөрергә туры килә.

Рушан бу хәл-әхвәл бик күптәннән булган, шунлыктан инде онытылгандыр дип уйлаган иде, юк икән — онытылмаган, Исмәгыйль абзыйның үзегенә үткән теге юньсез Шәйхи белән көрәше дәвам итә, кем белә, аны әле Рушанга да үги этисе эстафета итеп тапшыргандыр, бәлки. Әле күптән түгел генә дус-ишләреннән кемдер Шәйхинең бер улы Ибрайның, комсомол райкомы секретаре булып эшләгәндә, авыл китапханәләрен талап-урлап бетергәнлеген, чирәм җир колхоз-совхозларына да, хәтта иң ерак казакъ авылларына да кулы сузылгалаганын сөйләгән иде. Менә шундый «мәгърифәтче» икән ул Шәйхи малае!

Ярар, буласы булган, тузасы тузган дигәндәй...

Иртәнге кояш белән үк өчәүләп вокзалга юл тоттылар. Алар капкадан чыгуга, никель рамнарын һәм төрле төсле буяуларын ялтыратып, үги этисенең теге хәсрәтле

көндә юкка чыккан «Диамант»ын хәтерләтеп, Украина урамыннан боларны бәреп егардай булып, чылбыр кебек тезелешкән велосипедчылар узып китте. Рушан ачынып-сызланып, тагын бер мәртәбә, бәлки, соңгы мәртәбәдер, үги әтисенең, Зәйнәп әбине җирләргә кирәк булгач, зәңгәр трофей «Диамант»ын каядыр илтеп сатканын исенә төшерде.

Поезд озак көттермәде, аның тукталышы өч кенә минутлык булганлыктан, Рушан әйберләрен тиз генә вагонга кертеп куйды. Аннары тамбурның ачык ишегеннән карап тора башлады: әнисе әле, Аллага шөкер, карты янәшәсендә калкурак та, нык та, яшьрәк тә күренә, ә үги әтисе Рушан бүләк иткән ачык төстәге свитердан, кыска бобрик — керпе итеп алдырган чал чәчләре белән яшүсмер шикелле генә, ярдәмчесез-яклаучысыз бер кеше булып күренә иде. Ирексездән Рушанның тамагына төер утырды, күзенә яшьләр бәреп чыкты...

Станция кыңгыравы, гадәтенчә, поезд кузгалып киткәнсен белдереп, кагып куйды, ә состав ни өчендер кузгалмый тора иде. Шунда кинәт кенә Исмәгыйль абзыйның артындагы ташландык станция бакчасы ягыннан моңсу күзле Кашафның эте өреп куйды. Әйтерсең ул тонык тавыш «Онытмагыз безне... Онытмагыз безне...» дип кабатлый иде.

Тепловоз дерт итеп тартылып куйды, поезд шунда ук йөрешен тизләтте. Рушан тамбур ишеге тоткасына ике куллап ябышып, гәүдәсен яртылаш чыгарып сузылды да, көпчәкләрнең көчәеп килгән дөбердәвен басарга теләгәндәй, әтисен соңгы мәртәбә күргән шикелле, гаҗизләнеп кычкырып җибәрде:

— Әти!.. Әти!..

Ничәмә-ничә еллардан соң йөрәк түреннән үзе дә сизмәстән бәреп чыккан сүзләр иде бу... Һәм әтисенә соңгы эндәшүе иде...

## XXVII

Үткән тормышында казына-казына Рушан шундый ачыш ясады: язмыш дигәнең кешеләргә очраклысын да, күптөрле иш-тиң килүләрне дә бик юмарт өләшә икән.

«Ул кеше үз урынында түгел» дигән сүзләр дә мең төрле булырга мөмкин, анысы да хәзер Рушан өчен бик кызыклы. Иң өстә яткан гап-гади төшенчәсе бу сүзләрнең шулдыр: бу урында башка кеше булырга тиеш, яки бу кеше башка кеше урынын биләп, үз тормышы белән яшәми. Яки мисалга: кемдер бик тар даирәдә, тар мо-

хиттә бөтерелә, хәзер бу сүзләргә, әлбәттә инде, «элита» дигәнен дә өстиләр, ягъни сайлап алынган, иң шәп шәхесләр инде, әмма ул кеше үзенә бер зыянсыз, кимсетүләрсез, башкаларга да зыян китермәслек булып, ул «элита»-га кермәскә дә мөмкиндер бит. Ә кемгәдер ул даирә, ул «элита» мохите һава кебек кирәк, аңа ул зарури, үзе теләгәненә ирешер мөмкинлеге булмагач, аңа сулыш җитми башлый, ул буылган кебек була.

Җитмешенче еллардагы Ташкент яшеллеккә төрелгән, күбесенчә бер катлы кечкенәрәк кенә йортлардан тора, базарда әйбер гаҗәп арзан, халкы искиткеч киң күңелле иде, миллионер шәһәр булу өчен аңа әле үсәргә дә үсәргә кирәк иде. Яшь-җилкенчәк берсен-берсе белә, бер үк урыннарда ял итә, күңел ача, бер үк паркларга, концерт залларына йөри. Алар яшь, әле өйләнешмәгән, барысының да бер уртак мавыгуы бар — футбол, шуңа күрә алар еш, көн саен диярлек күрешә иде.

Һәр юньле-рәтле шәһәрдәге шикелле, Ташкентның да шау-шуы, гөрләп торган тормышы белән җәлеп итә алырлык «Бродвее» бар иде. Ул Революция бакчасыннан башлана. Анда үз заманында Сталинга Азиядә куелган иң зур һәйкәл күтәрелеп торган, аннан ары, подноска салынган кисекбаштай, Карл Маркcның сакаллы-чәчле зур башы булган. Алар урынында хәзер горур кыяфәттә аргамакка атланган Бөек Аксак Тимер һәйкәле, аны элекке заманнарда рәсми даирәләр «илбасар» дип кенә йөрткәннәр. Урам сузыла-сузыла киштәләре товарлардан сыгылып торган дүрт катлы универмаг яныннан, аннары нэпманнар заманыннан ук атаклы «Солей» һәм «Арс» кинотеатрлары яныннан уза,— алары хәзер, һәркайдагы шикелле, стандарт исемнәргә алыштырылган: «Чаткы» һәм «Яшь гвардия». Аларны артта калдырып, урам «Мәскәү» һәм «Фирганә» кафеларын буйлый. Шунысын да әйтеп үтик: болары тирәсенә Ташкентта тәки тернәкләнеп китә алмаган шәраб автоматлары куелган иде, аларны ватып-җимереп бетерделәр, ә урамның каршы ягында кичләрен балкып-яктырып торган галәмәт зур гастроном кибете иде. Төп ташкентлылар ул кибетне, мәскәүлеләр кебек үк, «Иске Елисеев кибете» дип кенә искә алалар. Кибетнең балык бүлегендә мичкә-мичкә уылдык — карасы да, кызылы да өзелмәгән, затлы балыклар да торган. «Бродвей», шулай килә торгач, «Ташкент» кунакханәсенә төртелеп туктый, анда әле тагын беренче даруханә дә бар, анысында Рушанның тагын бер танышы эшли — Нариман. Опера театры исә алгы ягы белән фонтанлы мәйданга карап тора. Атаклы архитектор Бу-

латов проекты белән төзелгән «Ташкент» кунакханәсе янына футбол көннәрендә галәмәт күп халык җыела, алар «Пахтакор» командасының чираттагы көндәшләре стадионга барасы автобуска чыгып утырганны көтәләр. Хәзер мондый күренеш берәүне дә дулкынландырмый инде, хәзер: «Кара, кара — Воронин!.. Месхи! Метревели! Стрельцов! Хөсәенов!..» — дигән сокланулы тавышларны да ишетмисең.

Хәзер инде ни универмаг, ни бер кварталга кадәр шоколад-кофе исләре аңкытып утырган гастроном, ни шәраб автоматлы «Мәскәү» белән «Фирганә» кафелары, ни «Солей» белән «Арс» кинотеатрлары, ни Нариман эшләгән беренче даруханә юк. «Чаткы» кинотеатры белән «Фирганә» кафесы арасында почмактагы менә дигән комиссион кибетләр дә, «Бродвей» үзе дә, аның башланганбеткән урыннары да юк. Һәммәсен дә бер көндә — 1966 елның 26 апрелендә — коточкыч дәһшәтле җир тетрәү йотты аларның...

Җир тетрәүдән соң Ташкентта күп нәрсәләр — барыннан да бигрәк, үзенә генә хас рухы-җаны, Шәрык шәһәрләрендә генә була торган европача мәдәният катнаш аерым бер зыялылык та юкка чыкты.

Мәңгегә кире кайтмаска «Бродвей» да югалды, ул үзенә күрә теләсә кем кереп йөрерлек, шул ук вакытта билгеле бер абруй-дәрәҗәле клуб шикелле иде һәм анда күздән югалган кызны да һәрвакыт эзләп табып була иде. Рушаннар заманындагы кызлар: «Сезне кайда очратырга мөмкин?» — дигән сорауга: «Бродвей»дан эзләгез»,— дип кенә җавап бирәләр иде. «Арс» белән «Солей» кинотеатрларында киносеанслар алдыннан уйный торган оркестрлар да гомер кире кайтмастыр инде, аларның берсендә хәзер танылган җырчы Роксана Бабаянның әнисе Сәйдә Бабаева җырлый иде. Бүгенге кинотеатрларның идәннәре төкерек-какырык белән тулган булыр, фойелары шакшы, шуңа күнеккән хәзерге буын тамашачылар элекке хозурлыкларны күз алдына да китерә алмый. Ләкин Рушаннар яшь, үзләренә бик тә ышанган буын иде, алар элеккесеннән дә гүзәлрәк шәһәр төзиячәкләренә ихластан ышанып-инанып яшәделәр. Шулай булып чыкты да, әмма ул инде,— исеме Ташкент булып калса да,— башка шәһәр иде, ул башка кешеләр өчен булды.

Ә үз заманнарында алар көн саен диярлек «Бродвей»-да очраша, бихисап кафе-ашханәләрнең ачык верандаларында кәеф-сафа корып утыра, «Ак мусалас», «Баян Ширей», «Хосилот» дигән бик затлы, үзе искиткеч арзан ак

шәраблар гына эчә, Үзбәкстан дәүләт эстрада оркестрының яңа программасы турында кызып-кызып бәхәсләшә иделәр. Анда ул елларда үзенең кабатланмас «Гарәп тангосы» белән танылган атаклы җырчы Батыр Закиров җырлый, хәзер дә джаз музыкасы иҗат итүче мәшһүр композитор һәм дирижер Анатолий Кролл эшли, Ташкент урамнары буйлап ул аклы-каралы сәер «Волга»сында гына чаба иде.

Яшьләр «Пахтакор» футбол командасының шул көннәрендә булачак уенын түземсезләнеп көтә, көндәшләре өчен дәһшәтле пар Красницкий — Стадник, искиткеч оста капкачы Коля Любарцев, бик үҗәт-ябышкак уң сакчы Ревал Закировлар өчен җаннарын бирергә әзер иделәр. Горький паркында әле ул вакытта яшь шагыйрь Александр Файнберг оештырган шау-шулы шигърият кичәләре үзләре генә дә ни тора иде!

Рушан ниндидер бер мәҗлестә, очраклы рәвештә генә, Мәскәүнең Театр сәнгате дәүләт институтын (ГИТИСны) тәмамларга әзерләнүче һәм шәһәр опера театрында үзенә диплом спектаклен куярга йөрүче Ибраһим Юнысов белән таныште. Диплом спектакле — Кара Караевның «Яшен сукмагы» балеты икән. Балет труппасының төп биючесе һәм шул ук вакытта спектакльне куючы да Ибраһим белән шулай тиз генә башланып киткән дуслык Рушанга театрга арткы ишектән генә кереп йөрү мөмкинлеген дә бирде, ә мондый форсат ул кырыс заманнарда бик әзләргә генә эләгә иде. Ул бик күп репетиция, спектакльне буеннан-буена куып карау — прогон дигәннәрен, аны абруйлы комиссиягә тапшыруларны күрде, спектакль премьераларын сөйләп тә торасы юк инде. Рушан ул репетицияләргә махсус йөрмәде, билгеле, ул дусты Ибраһимның эшенә килә дә аның бушаганын көтеп утыра. Әлбәттә, бер елдан ул бөтен балет труппасын, бигрәк тә кордебалеттагы кызларны исемләп белеп, алар белән танышып та өлгерде, Нариман белән икәүләп, Ибраһимга сиздерми генә, кызларны Нариманнарга кофе эчәргә чакыра иделәр. Нариман театрга янәшә генә Үзбәкстан урамындагы бер карт яһүднең иске генә йортында бер бүлмәдә тора, ишегалдында су колонкасы, аның янында һич тә кибә белмәс күлдәвек тә бар иде. Хәзер ул урында Дәүләт банкының саркофагка охшаш шөкәтсез мәрмәр бинасы кукраеп утыра.

Кайвакытларда Рушан Ибраһимны эзләп Педагогика урамындагы балет училищесына да барып кергәли иде, чөнки дусты анда дәресләр алып бара, бу училище хәзер илдә иң өлкәннәрнең берсе санала. Хәтерендә әле, Ру-

шан анда шулай бер тапкыр иртәрәк килде дә, балет сыйныфында дәреснең ахырына кадәр утырды — аңа яшь кенә бер кыз бик ошап калган иде. Ул кызга бөтенләй башка максатлар өчен алынган чәчәкләрен бүләк иткәнен сизми дә калды, аңа зур сәхнә йолдызы — балерина язмышы юрап, кызны кызартып оялткан да иде.

Ул кыз Киров шәһәре балетының булачак йолдызы Валя Ганнибалова иде. Күп еллар үткәч, үзенең туган шәһәренә гастрольгә кайтып, ул Рушанны хәтерләвен, күрәзәлек кылуының рас килүен, балерина буларак беренче чәчәкләрне аның кулыннан алуын сөйләп, Рушанны да куандырды.

Бәлки, балетны шулай сәхнә артыннан күрүе, биюче гүзәлләрнең репетицияләрен йотылып каравы Рушанның рәссам Дег картиналарын ярата башлавына сәбәпче булгандыр да әле. Юк, ул, танылган архитектор Шусев проекты белән сугыштан соң әсир японнар салган гүзәл театр бинасына рәхәтләнеп йөрсә дә, балетоман булып китмәде. Аңа спорт залларына охшаш репетиция заллары ошый, декорация исләре ошый, театр рәссамнары һәм костюмерларының эшләре ошый — читтән күзәтеп торучылар булса, ул аларга, мөгаен, узып ашкан театр сөюче булып күренгәндер.

Ул елларда Арам Ильич Хачатурян «Спартак» балеты музыкасын язып танылган, кайчандыр Ибраһим стажировка үтеп йөргән Григорович исә аны Зур театрда куеп та өлгергән иде инде. Ибраһим да шул уй белән яна башлады. Ул Мәскәүгә дә берничә мәртәбә барып кайтты, тәки композитордан үз музыкасына балет куярга хәерфатихасын алды.

Әйтергә кирәк, «Бродвей»да очрашулар ул заманнарда «Спартак» балетын кую эшләренең ничек барышын сөйләшүдән башлана иде. Спектакльнең бизәлешен Ереваннан килгән атаклы рәссам Мирзоян эшләде. Рушан да бу вакытта Мәскәүдә булып, Григорович куйган балетны карап кайткан һәм андагы спектакльгә рәссам Сулико Вирселадзе ясаган гаҗәп матур декорацияләргә, артистларның костюмнарына сокланып туймаган иде. Ибраһим үзенең кордебалеты кечкенә булганга бигрәк тә көенә, Григоровичтагы шикелле төп сәхнә күренешләренә ярашлы матур бизәлеш юклыктан зарлана. Рушан белән Нариман, бер-берсен аңлап, карашып алалар — алар да кордебалетны икеләтә-өчләтә арттырырга кирәк дип исәплиләр! Анда бит шундый гүзәл кызлар бии! Аларны соңыннан Нариманга кофе эчәргә чакырырга да була.

Бөтен шәһәр булачак премьераны көтеп яши башла-

ды, маэстро Хачатурян үзе дә киләчәк иде. Ибраһим, якын дусты буларак, Рушанга танылган композиторны һәр җирдә озатып йөрү бурычын йөкләде — алар премьерадан соң булган банкетта да Хачатурян белән янәшә утырдылар.

Язмышның менә шундый капма-каршылыклары һәм борылышлары да була икән: прораб белән балетмейстер, кордебалет белән аптекарь, маэстро Хачатурян һәм Сулико Вирселадзе эшләре...

Тормыштагы, язмыштагы мондый көтелмәгән борылышлар — бетмәс-төкәнмәс уйлануларга азык, ул борылышлар сине теләсә кайсы якка алып китәргә дә мөмкин: зурлыкка да, хурлыкка да. Менә әле күптән түгел генә газетлардан укып, Мәскәүдәге актерлар йорты, ягъни икенче төрле ВТО (Всесоюзное Театральное Общество — Бөтенсоюз Театр җәмгыяте) дип йөртелә торган йорт янганын белгәч, Рушан аны торгызу фондына зур гына сумма акча да җибәрде, фамилиясе янына үзенең һөнәрен дә язып куйды — прораб.

Бу зур сумманы алгач, Мәскәүдәге кешеләр гаҗәпләнгәннәрдер: прораб һәм Актерлар йорты, аларны нәрсә берләштерергә мөмкин? Ә менә һаман да шул язмыш шуклыгы — кайчандыр Рушан да ул йортның бусагасын атлап кергән, аны матур итеп, киң күңеллелек белән каршы алганнар, ул анда бик тә истәлекле кич үткәреп чыккан иде... Менә ни өчен, егерме биш еллап вакыт үткәч, шундый җавап ясалды, кем әйтмешли, яхшылыкка — яхшылык...

Хәзер генә ул «барлык флаглар да бездә кунакта» булуга ничектер күнегеп киттеләр: Италиянең «Ла Скала»сы да, «Штутгарт» балеты да, «Кабуки» театры да, Лондон симфоник оркестры да, Шекспир король театры да... Ә бит барысы да теге чакта ук, анда да әле бик кыюсыз гына, алтмышынчы еллар уртасында башланып киткән иде. Менә ул чагында, чынлап та, һәммәсе дә беренче тапкыр иде: Мәскәүдә «Ла Скала» да, Герберт фон Кароян да, данлыклы мим Марсель Марсо да һәм тагын бик күп, бик күп данлыклылар, мәшһүрләр...

Бервакыт шулай алар Ибраһим белән икәүләп «Ташкент» кунакханәсенең җылы барында Нариманны көтеп утыралар иде, кинәт Ибраһим, һәрвакыттагыча кайнарланып, әйтеп ташлады:

— Сиңа иң кызыклы яңалыкны әйтергә онытканмын. Мәскәүгә француз балеты килә,— диде.— Берәр пәрдәле ике спектакль алып киләләр: «Ак сюита» белән «Коппелия»не. Театр белән минем институттагы курсташым

Вера Бокадоро да килә икән, аңардан телеграмма алдым.

— Барасыңмы? — дип сорады Рушан.

— Бармыйча соң! Гомергә бер тапкыр француз балетын күрү мөмкинлеге ич,— дип җанланып китте Ибраһим. Аннары бер-бер артлы тезә башлады: Петипа, Фокин, Дягилев... Рудольф Нуриевны да телгә алды, анысы ул вакытта Көнбатышта торып калган иде инде.

Бернинди күчешсез-нисез Ибраһим сорап куйды:

— Ә син Мәскәүгә командировка ала алмыйсыңмы соң?

Рушанның бәхетенә, Мәскәүгә бару ихтыяҗы бар икән, ул бер авырлыксыз гына «Минмонтажспецстрой»га командировка алды, үзенә «Пекин» кунакханәсендә урын калдырылачагын да Ташкентта чакта ук тәгаенләде. Бер көннән соң алар салкын Мәскәүгә очып килеп төштеләр, бер калдырылган урынга кунакханәгә дә икәү бергә урнаштылар — Ибраһимның балетмейстер булуы һәм килү максаты «Пекин» администрациясенә аңлаешлы иде.

Спектакльдән соң Ибраһим сәхнә артына үтеп керә алды һәм, үзенең курсташ француженкасы янына тагын кордебалетта биюче бер кызны да ияртеп, килеп тә чыкты. Алар атлый-йөгерә Зур театрдан Столешников тыкрыгы аша Пушкин мәйданына — әлеге дә баягы ВТОга юл тоттылар. Аларны суык кына кумый, Мәскәүне яхшы белгән Ибраһим да ашыктыра, чөнки тиздән театрдан тарала башлаячаклар һәм ярты сәгатьтән соң Актерлар йортына эләгеп булмаячак иде. Алар өлгерделәр һәм Рушанның күңелендә гомерлеккә уелып калган гаҗәеп матур кичне шунда үткәрделәр. Барысына да өстәп, шуны да әйтергә була: нәкъ менә шунда ул беренче һәм соңгы тапкыр француз шампаны «Гордон Верт» эчкән иде.

Ул кичтә Рушан бик күп сәхнә йолдызларын «тереләй» күрде: актерлар, режиссерлар, эстрада җырчылары, дирижерлар, киночылар дисеңме... Аннары аларның өстәле янына да байтак кына танылган шәхесләр килеп-килеп киткәләде — Ибраһимны бу йортта да яхшы беләләр иде. Кунакчыл йорттан алар ярты төн узгач кына китеп бардылар. Әле күңел ачуны дәвам иттерү өчен тагын каядыр юнәлделәр. Рушан хәтерли, Актерлар йортыннан ул, француз кызлары хөрмәтенә дип, тагын бер шешә шампан да кыстыра чыкты. Ул вакытта «Гордон Верт» — «Яшел Тасма»ның бер шешәсе ничә сум тора иде дип сорагыз? Җиде сум! Ышана торган түгел! Чынлап та, искиткеч заман иде ул...

Ибраһим, ташкентлылар француз балетын күрми калалар инде, дип борчылды. Алай да төп биючеләре Клер Мотт белән Пьер Бонфуны, Ташкентка килеп, үзенең «Жизель» балетында төп партияләрне биеп китәргә күндерә алды. Әлеге биючеләр икенче сезонда Ташкентка килделәр һәм балет сөючеләрне куандырып, биеп тә киттеләр. Шулай итеп, ике яшь егетнең Мәскәүгә барып кайтулары Терпсихорага табынучылар өчен бәйрәмгә дә сәбәпче булды.

Үткән вакытларны исенә төшергәндә, Рушан әллә кайчангы вакыйгаларның тонык кына гөрелтесен, онытылган тавышларның аңлаешсыз пышылдаштыруларын ишеткәндәй була, аның өчен бүген алар һәммәсе дә кадерле һәм әһәмиятле. Бәлки, шунлыктандыр да, аның күңелендә тигез-тәңгәл булмаган, кемнәр өчендер әһәмиятсез күренгән хәлләр-вакыйгалар яңара. Аннары ул бит артта калган, бер генә төрле булмаган вакытларның барысын да колачлап бетерергә җыенмый да, моңа аның көче дә җитмәс иде. Ул бит, меңнәрчә башкалар шикелле, билгесез бер төзүче генә, аның танышларын, дусларын-туганнарын да язмыш иркәләп тормаган — менә шуларга һәм үзенә кагылышлы нәрсәләрне генә хәтерендә тергезеп, сөйләп бирә алса да, ул Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтле булыр иде...

## XXVIII

Күңеленнән үзенең студентлык чорына һәм Актүбәдә яшәгән беренче елларына кайтып, Рушан тагын бер адресны читләтеп үтә алмый: Почта урамы, 72 нче йорт. Бер Яңа ел кичендә шәм яндырып багу баккан, аллыгөлле чигән шәлле, яшел күзле кызны озата киткәч адашып йөргән Роберт исемле егет шул йортта яши иде.

Кызыл шампан шәраблы ул Яңа ел төне исенә төшкәч, Рушан «юраганы юш килгән» тагын бер нәрсәне хәтерендә яңартты. Тамара бер-бер артлы һәрберсенә дә бер үк төрле юрамышлар әйткәч, үткен телле Вуккерт төрттереп әйтеп куйган иде: «Син, мадам, мөгаен, юрый белмисеңдер»,— дигән иде. Тамараның хәтере калды, ул гөлт итеп кабынып китте, күзләре шикле ялтырый башлады. Кулындагы кәртләрен бер читкә атып, шәмнәрен сүндерде дә еламсырап әйтте: «Сезнең һәркайсыгызга да ерак юллар, иртәләгән сагыш чыкканга мин гаепле түгел...» — диде.

Вакыт ул яшел күзле кызның күрәзәлек итә белүен раслады.

Робертларның кунакчыл өендә Рушан Дасаев икенче курстан башлап, техникумны тәмамлап чыкканчыга кадәр еш кына була иде. Робертның фамилиясе европалылар, аерым алганда, урыслар колагы вә теле өчен бик авыр яңгырашлы-әйтелешле — Телиумөхәммәтов. Әтисе — эре гәүдәле, чал чәчле, картаеп баручы казакъ, әнисе — татар кызы, әтисенең икенче хатыны иде. Аларның яшь аралары шактый икәне дә, иренең хатынына карата игътибарлы булуы да сизелеп тора. «Мәхәббәт булса — матур балалар туа»,— ди борынгылар сүзе. Менә аларның уллары да күрекле бала булып үсте, тышкы төс-кыяфәте белән генә түгел, холкы-табигате белән дә алдырган иде ул.

Робертка Ходай Тәгалә спортчы һәвәслеген вә осталыгын кызганмаган, егет ул заманнарда әле яңарак мавыгу булган баскетболны да шәп уйный, Рушанны бокска тартучы да ул булды. Иң кызыгы шул — Роберт кечкенә Актүбәдә беренче һәм озак вакытлар бердәнбер стиляга — гайре табигый фырт киенеп йөрүче дә иде. Хәзерге киемсалымда һәм әхлактагы иркенлек-«ялангачлык» чорында моны аңлау шактый кыен, әлбәттә. Әмма дөресе шулай.

Биредә шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, Телиумөхәммәтовлар гаиләсе Актүбәгә күптән түгел генә Урал якларыннан күчеп килгән иде. Үзләре элек яшәгән Магнитогорск шәһәре, Робертның сөйләүләре буенча, Рушанга озак еллар әле ниндидер Чикаго сымаграк булып күзалланып торды, чөнки сүз гел генә джаз музыкасына барып бәйләнә иде. Илленче елларның урталарында, илгә беренче мәртәбә рок-н-ролл үтеп кергәч, яшьләр аңа шундук гомерлеккә гашыйк булдылар. Алар Армстронг, Эллингтон, Дези Гилеспи, Глен Миллер исемнәрен сихерләнгәндәй кабатлыйлар иде. Рок-н-ролл кайчан да булса үләчәк, дип, аларны ул вакытта беркем дә ышандыра алмас иде һәм бүген, бу музыка икенче кат туып, аның әлеге беренче табынучылары инде пенсиягә китәргә җыенганда, рок-н-роллны аларның балалары һәм оныклары биегәнне-тыңлаганны күргәч, алар, соңлап булса да, яшьлек мавыгулары белән горурланалар иде. Дөнья кичә генә яратылган дип уйлый торган берәр мышык борын яшүсмер әтисеннән Элвис Пресли исемен ишеткәне бармы-юкмы икәнен сораганда, әтисе эчке бер горурлык белән тыныч кына җавап бирә: «Әйе, улым, моннан утыз еллар элек ишеткән идем»,— ди. Әйе, дөньяда һәрнәрсә кабатлана...

Үз заманы турындагы күңелендә йөрткән «мәңгелек китап»ка нәрсәләр кертергә теләгәннәрен уйланып утырганда, Рушан, чынлап та, дөньяда һәрнәрсәнең кабатлан-

ганын, үзенең бернинди дә яңалык әйтә алмаячагын төшенде. Һәммәсе дә ышанмаслык дәрәҗәдә гап-гади. Һәммәсе дә аңа кадәр дистәләрчә-йөзләрчә мәртәбә булган, аңардан соң да булачак, теләсә кайсы китапның эчтәлеге берничә сүзгә сыеп бетә: зәңгәр бантик-«күбәләк»ле яки «күбәләксез» генә нindидер бер кызга нindидер бер малай гашыйк була. Һәм, гадәттәгечә, андый мәхәббәт җавапсыз кала — бәхетсез мәхәббәт... Аннары һәр икәүнең вакытлары, борынгы сәгатьләрдән ком агып беткән шикелле, агып беткәндә генә, тормыштан арыган-талчыккан, картаеп әбигә әйләнгән хатынга вакыт галиҗәнапләре соңлап кына бер хакыйкатьне раслаячак: шул синең илаһи көчләр иңдергән бердәнбер мәхәббәтең булган, ә бердәнбер шаһзадәңне һәм әкияти дәрт-ымсынуларыңны эзләвең — мәгънәсез, нәтиҗәсез буш хыял гына.

Американың атаклы әдибе Курт Воннегут юкка гына: «Барлык китаплар да бары тик бер хатын-кыз хакына гына языла»,— димәгән. Шулай, яки якынча шулай. Әлбәттә, башка вариантлар да булырга мөмкиндер. Боларның һәммәсе аралыгында Россиянең, һәрвакыттагыча, рәхәте-бәхете булмаган тормыш, ягымлы җылы карашларсыз, бары тик салкын һәм шыксыз, үтеп йөри алмаслык сукмак-юллары гына булган һәм шул юл-сукмакларга гомерең буе түгелгән иртәләгән һәм соңлаган сагыш-моңнарың гына тулган булыр...

Бу ачыштан башта Рушан Дасаев күңел боеклыгына, кайгы-хәсрәткә тарды, ул күпмедер вакытка үзенең үткәннәрдә казынуын куеп торды. Әмма күнегелгән ул шөгыльдән алай җиңел генә котылып, аны ташлап калдырып яки онытып булмый иде шул. Ул бөтенесен дә онытыр, хәтерендә яңартмас, шул чагында инде аның үткәннәре бөтенләй онытылыр-үләр дигәндәй, шул ук үткәннәре бүгенге көн аша үҗәт бер әрсезлек белән кайтып керә тора. Әйе, әйе, шулай үҗәтләнмәсәләр, барысы да үләр, тормышның һәр көне узган шикелле, эреп бетә барыр. Шуннан соң Рушан яңадан хатирәләренә әйләнеп кайтты, күңелендә уелып калган һәрнәрсәне бөртекләп җыя, исенә төшерә башлады...

Рушан бу тормыштан сизелерлек эз калдырмыйча китеп барачагы белән килешкән-ризалашкан иде инде — аның хезмәте һәрвакыт коллектив белән берлектә булды һәм бер дә алай күренекле түгел иде. Мисалга, ул бит, Заркент кургаш-цинк комбинатын төзедем, дип әйтә алмый, чөнки аны меңләгән эшчеләр, йөзләгән прорабдлар бергәләп төзеде. Рушан да шулар арасында бер ком бөртеге генә иде. Ком бөртеге генә...

Әмма аның, Рушан Дасаев дигән шәхеснең, үз шәхси тормышы да бар иде: ул да сөйде, хыялланды, көтте — менә шул тормышка ашкан һәм ашмаган өмет-хыялларның һәммәсе хакында да сөйләп калдырасы килә, алар аның белән бергә юкка чыкмасыннар иде. Шуңа күрә ул, бераз өзелеп торганнан соң, кичләрен яңадан озаклап тәрәзә буенда басып тора башлады, башы да, азагы да булмаган «мәңгелек китабын» бер үк вакытта укый да, яза да барды, ул китапта барысы да дөньяның үзе кебек үк иске, анда һаман да кулына ноталар папкасы тоткан зәңгәр бантик-«күбәләк»ле кызга бер күрүдә үк авыл малае гашыйк була...

Ах, беренче мәхәббәт хисе, җавапсыз калган мәхәббәт хисе! Нигә син шулай татлы да, газаплы да икән, нигә гомер буе йөрәкне өзгәләп, сызып-сызланып яшәргә дучар итәсең икән?!

Почта урамындагы 72 нче йортта исә Рушан укуының соңгы ике елында, Роберт белән бик якынаеп киткәч, бигрәк тә еш була башлады. Ихтимал, үзен тәрбияләүдә, дөньяга карашларын калыплауда, тормышны танып-белүдә бу йорт аз роль уйнамагандыр. Ә инде спортны, джаз музыкасын яратуы, зәвыгы һәм үз-үзен тотышы-рәвеше өчен ул, әлбәттә, Робертка бурычлы булды.

Робертның әнисе йорт эшләрен генә алып бара, кияүгә чыкканчы әдәбият укыткан булса да, хәзер эшләми иде. Өй эче ялт итеп тора, тәрәзә төбендәге гаҗәеп матур, сирәк очрый торган гөлләр кунакларны таң калдыра, әмма барыннан да бигрәк Рушанның хәтерендә пирог исләре калган. Мартукта ачлы-туклы үскән бу яшүсмергә ни кирәк тагын? Боларда һәрвакыт нәрсә булса да пешерәләр-төшерәләр. Өй эченә кем генә килеп кермәсен — иң элек барысын да өстәл янына утырталар: күрәсең, Робертның әти-әниләре дә үзләренең ач студентлык елларын бер дә онытмаганнардыр. Күп кенә бәйрәмнәр, туган көннәр дә шушында үтә, сәбәп белән дә, сәбәпсез дә яшьләр гел шунда җыела иде. Йортта бәхәсләр тынып тормый, яңгыратып көлү тавышлары ишетелә һәм, әлбәттә, иртәдән кичкә кадәрле диярлек музыка уйнап тора. Джаз музыкасы. «Бу Армстронг дигәнегез безгә бөтенләйгә күчеп килгән бугай»,— дип шаяртыр иде Робертның әтисе Бертай әкә. Ул үзе дә еш кына яшьләрнең бәхәсләренә кушылып китә, әмма бервакытта да үзенең абруе белән аларны кысмый, үзенең яшенә-тәҗрибәсенә яки белеменә таянмый, юкса ул сугышка кадәр үк Ленинград университетын тәмамлап, кандидатлык дәрәҗәсен дә якларга өлгергән кеше иде инде.

Бертай әкә улының джаз белән фанатикларча мавыгуын өнәп бетерми, шулай да аның теләкләренә каршы да килми иде. Ә Рушаннар, Робертның буржуаз культура белән мавыгуы өчен, әтисен партиянең шәһәр комитетында бер генә тәпәләмәгәннәрен беләләр иде.

Үзләрен шәһәрнең аталары итеп тоючы кемсәләр ул заманнарда барлык стилягаларның да чәчләрен ялтыратып кырып алу турында хыялланалар иде! Шәһәрдә башка прокурор булса, мөгаен, кыркыган да булырлар иде...

Рушан кайвакытларда, бигрәк тә курс эшләрен тапшырырга бик күп сызымнар сызып иртәнгә кадәр утырырга туры килгәндә, аларда куна да кала иде. Бервакыт ул Бертай әкәнең төн уртасында: «Кылычларыгызны — кынысыннан! Эскадрон, һөҗүмгә!» — дип кычкыруыннан сискәнеп китте. Рушанның гаҗәпләнеп зур ачылган күзләренә карап, Роберт аңлатырга кирәк тапты: аның әтисе гражданнар сугышында атлы эскадрон командиры булган икән, шул вакыттагы дәһшәтле сугышлар һаман да аның төшенә керә икән. Менә шулай итеп, картаеп барган кешенең төнге кычкыруы егетләргә кинәт кенә тарих сулышы булып тоелды.

Соңрак, улының дуслары гражданнар сугышы турында сөйләткәндә, Бертай әкә, кылыч сугышында җайдак сугышчылар, ягъни ат менгән сугышчылар гына сугышмый, хәтта атлар да бер-берсен тешләшә-сугыша, дип сөйләгән иде.

Күп еллар үткәч, кайсыдыр бер җирле профсоюз санаториенда ял иткәндә, бервакыт Рушан кинәт куркынып кычкырган һәм дөбердәп урындык ауган тавышка уянып китте. Сикереп торып, ут яндырса, күрше тимер караваттагы өлкән яшьләрдәге абзый бәрелгән аягын уып утыра. Абзый, гаебен сизеп, акланып алды:

— Гафу ит, энекәш. Янә сугыш төшкә керде. Патроннарым беткән, имеш тә, мин күн итекләрем белән тибә-тибә сугыша башлаганмын...

Менә шулай, соңлап булса да, ике сугышның кайтавазы кушылып, Рушанның тормышында чагылып үткән иде. Шул чагында Рушан беренче мәртәбә уйга калды: аңа, сугышлар күрмәгән кешегә, нинди куркыныч төшләр керер икән картлыгында? Бала чагыннан тулысынча татыган озын ипи чиратларымы? Әллә үлгәнче бер-берсенә каршы торган балаларга тәки тәтемәгән каһәрләнгән ташкүмер өемеме? Әллә энисенең кушучына немец Тилковски кесәсеннән бушаттырылган бер кушуч бодаймы? Шуның өчен Тилковски унбиш ел утырып кайткан иде бит!

Ә бәлки, өметсезлек-гаҗизлектән үз илен ташлап китәргә мәҗбүр булган кешеләрнең Көнбатыш илләренең илчелекләре янындагы чиратларда торганда күрелгән хәсрәтле күз карашларымы?

Бертай әкә эштән бик соң кайта, еш кына арыган, үртәлгән була,— ә ни-нәрсәләр өчен үртәлеп кайтып керә ул, анысын үзеннән башка кем белә? — әмма, өйдәге егетләрне күрүгә, шундук үзгәрә, ачылып китә, йөзе яктыра. Хатынына ул, шаяртып, еш кына:

— Йә, кадерлем, бу йортта джаз-клуб ябылып, бөркетләребез төрле якларга очып таралышкач, тынычлап яшәрбез әле бер! — дияр иде.

И Бертай әкә, шул джаз музыкасын сагынудан киләчәктә синең кабергә керәчәгеңне ул чакларда кем уйлаган?!

Бертай әкәнең әлеге шаян сүзләре, уннарча вариантларда кабатланып, йортта шул ук усал телле яшьләр тарафыннан гел сөйләнә торган булып китте. Ул гынамы, хәтта киләчәктә — яшьләр таралып беткәч, өйдә урнашачак тынлык өчен тостлар да әйткәлиләр иде.

Ах, ул чакларда бу бер кайгысыз-уйсыз яшьләр, уенкөлкеле тостларның нинди фаҗигагә китерәчәген белгән булсалар икән! Әмма... юк шул, язмышны алдан язып куеп булмый...

Студентлык еллары бик тиз үтеп китте, чыгарылыш кичәсе дә шаулап-гөрләп узды, кичәгә,— алар группасындагы барлык яшьләрне дә диярлек белгәнгәме,— Робертның эти-әниләре дә килгән иде. Ничәмә-ничә еллар Уралын сагынып яшәгән Роберт, диплом алып өч көн үтүгә, Магнитогорскига китеп барды, ниһаять, Почта урамындагы 72 нче йортта сәер тынлык урнашты.

Бервакыт Рушан Робертның әнисеннән хат кисәге алды, һәр җөмлә аралаш диярлек бер үк сүзләр кабатлана иде: әле киткәнегезгә, төрле шәһәрләргә таралышканыгызга берничә ай гына бит, ә без инде сезнең барыгызны да бик сагынабыз...

Техникум тәмамлаганнан соң Рушан тимер юлда, Кызыл Ордага якын гына булган Кара Үзәк станциясендә эшләде. Яңа елга аның бер атналык ял көннәре җыелган иде. Ленинград театрының элеккеге костюмеры тегеп биргән смокингын да алып, бәйрәм көннәренә,— юк, Мартукка түгел! — Актүбәгә кайтып китте. Аягы шунда тартты... Әлбәттә, беренче эше итеп, ул Почта урамындагы 72 нче йортка юл тотты, әмма йортта бәйрәм кәефе юк иде — прокурор Бертай әкә йөрәк өянәге белән хастаханәдә ята икән.

Өй эче искитәрлек булып үзгәргән, элеккечә ялт итеп, һәр җирдә тәртип булса да — бу йорттан тормыш киткән шикелле... Юк, бу — Рушанның үз сүзләре түгел, Робертның әнисе әйтте бу сүзләрне: «Йортыбыздан яшәү яме китте...» — диде.

Соңыннан ачыкланганча, Бертай әкәгә тынлык ярамый икән, ул аны күтәрә алмаган, авыруга сабышкан. Менә сиңа Армстронг... Бертай әкә эштән кайта икән дә, бер максатсыз бүлмәдән бүлмәгә йөри икән, аннары кухняга хатыны янына кереп, гел бер сорау белән тинтерәтә: хәзер безнең балалар нишләп ята икән? Юк, ул Робертын истә тотып кына әйтми — Юра Лаптев, Петя Мандрица, Ефим Ульман, чечен Лом-Алиларны да һәм, билгеле инде, Рушанны да истә тота бу очракта.

— Бервакыт,— дип сөйләде Робертның әнисе,— төн уртасында куркынып уянып киттем, колагыма, бөтен көченә кычкыртып, Армстронг трубасы уйнаганы ишетелде. Чынлап та, шулай икән... Мин йокылы-уяулы килеш шатланып, Робертыбыз кайткан икән дә безгә шул музыка белән аваз сала икән, дип уйладым. Әмма ялгышканмын... Йокысызлыктан интеккән Бертай, сагыштан үзенә урын таба алмаганга күрә, бераз гына булса да элекке тормышыбызны хәтерләтсен дип, уйната икән ул патефон тәлинкәсен... Уйналып беткәч, мин барып уйнаткычны сүндердем дә караңгыда иремнең караватына килеп утырдым. Бертай күз яшьләрен яшермичә елый иде...

Аннары Робертның әнисе Бертай әкәнең төннәрен улы бүлмәсенә кереп, Эллингтон яки Элвис Пресли белән Джонни Холлидей рок-н-ролларын уйнатып, иртәнгә кадәр коньяк йоткалап утыруына күнеккән. Шундый утыруларының берсендә иренең йөрәгенә бәргән.

Тагын ярты елдан, җәй көне Бертай әкә үлгән. Аның җеназасына кайткан Рушанга Робертның әнисе: «Аның йөрәге сезне сагынуны күтәрә алмады, сезнең бәхәсләрегезне юксынды ул, сез уйнаткан музыкаларны бик яраткан икән...» — дип сөйләде.

Шул кайгылы матәм көнендә алар Роберт белән соңгы тапкыр очраштылар. Соңрак Роберт Мартуктагы бер әйбәт татар гаиләсеннән Клара исемле кызга өйләнде. Әмма Рушан алар белән ни Актүбәдә, ни Мартукта кабат очраша алмады. Соңыннан ишетеп кенә белде: Роберт аерылган икән. Әнисе озакламый, йортын сатып, улы янына Магнитогорскига китеп барган. Шулай итеп, аларны бәйләп торган соңгы җепләр дә бөтенләйгә өзелде...

Кайчакларда кайткалап йөргәндә, Рушан Актүбәнең мөселман зиратына бара, джаз яраткан прокурор Бертай әкә кабере янында басып тора, Почта урамындагы 72 нче йортта үткән бәхетле көннәрен исенә төшерә иде.

Соңгы кайтуында ул үзе өчен көтелмәгән ачыш ясады. Күзе Бертай әкә кабере янәшәсендәге күркәм һәйкәлгә төште — прокурор күршесендә кәрт уены шулеры, законлы карак Шамил Гомәров ята икән. Йа Хода, тәкъдиреңне белеп бетерерлек түгел шул!

Рушанга әле илле тулмаган булса да, кызганыч ки, ул инде бик күп өметләрнең сүнүенә, язмышларның сынуына шаһит иде. Һәм кешеләрнең генә дә түгел. Аның хәтерендә — юкка чыккан шәһәрләр, кварталлар, яраткан биналар һәм вокзаллар... Мартук тирәсендәге казакъ авыллары һәм урыс бистәләре дә әллә кай арада эределәр дә беттеләр. Аларның исемнәре генә дә җанга якын иде: Кызыл күл, Ак хатка, Покровка. Аның балачак елгасы Илек тә харап булып ята. Кая аның искиткеч комлыклары, биек яр өстендәге лалә чәчәге басулары? Шау печәнле болыннардагы чикерткәләре ник сайрамый? Күбәләкләре, энә караклары ник уйнаклап очмый? Кәрәкә балыклы, энҗе чәчәкле күлләре ник корыды? Көзләрен ул күлләрдә үрдәк атып йөрүче аучылар ник күренми?

Кая карама — югалтулар, нәрсә турында уйлама — һәлакәт... Ул манаралары киселгән мәчетләр, җимерелгән чиркәүләр турында ни-нәрсә сөйләмәк кирәк? Хәзер яңадан иманга кайта башладылар шикелле башлавын: мәчетләр калка, чиркәүләр төзекләндерелә, яңа гыйбадәтханәләр ачыла. Әмма болары да бер мавыгу, шаукым гына булып калмасмы? Изгелеккә, иманга күңелеңдә ихтыяҗ тумаса, ул синең калбең өчен зарури булмаса, монафикъ дөньяви хаҗәтләрең белән генә Аллаһы йортына аяк басма...

## XXIX

«1905 ел» урамында яшәүче кыз укыган мәктәп кичәләрендә Рушан еш була. Анда үзеннән бер-ике яшькә өлкәнрәк Жорик Стаин барысыннан да аерылып тора иде. Дасаев беренче барган кичтә үк аны, Исмәгыйль бәкнең туганы, дип, Стаин белән таныштырдылар. Жорик та Татар бистәсендә тора, Исмәгыйль бәк исеме аның өчен буш аваз гына түгел, үзенең дә аңа мөрәҗәгать иткәләгәне бар иде. Шунлыктандыр, бик якын дуслар булып китмәсәләр дә, Рушан белән мөнәсәбәтләре тиз урнашты

һәм һәрвакыт әйбәт булды. Әмма кечкенә шәһәрдә аларның юллары еш кына кисешә дә иде...

И-и, ул ерак шәһәрчектә үткән яшьлек елларында Жорик Стаин иң атаклы шәхесләрдән санала иде. Аның мажаралары турында әллә ничаклы хикмәти риваятьләр сөйлиләр, ә күпсанлы җан дуслары, аның җирле философ данын күпертеп, ул әйткән-сөйләгән сүзләрне һәр җирдә китереп кыстыралар. Хәзер ничек кенә көлке тоелмасын, яшьләр арасында үз-үзеңне тоту рәвешендә «а ля Стаин» дигән нәмәрсә таралган иде. Стаинның шаушу кузгаткан һәр адымын яшь-җилкенчәк шәһәрчектәге эчпошыргыч күңелсез тормышка үзләренең дә протесты итеп карый, яшьләр генәме соң, бервакыт Жорик Стаин бөтен шәһәрне үзе турында сөйләргә мәҗбүр итте.

Күпләрнең, шул исәптән, Жорикның үзенең дә гаҗәпләнүенә карамастан, институтка ул беренче талпынышыннан ук кереп китә алмады — күрәсең, үз-үзенә артык ышанып масаюымы, йә булмаса, имтиханда киртәгә сыймаслык берәр кыланышымы комачаулагандыр, әмма бу кешеләр өчен гомерлек сер булып калды, ул әти-әниләренә дә ни өчен имтихан бирә алмаганын аңлатып торырга теләмәде. Ә мәктәптә Стаин менә дигән итеп укыган иде, аның хәтере искиткеч яхшы иде.

Жорик Стаин атаклы модельер булырга хыяллана, мөгаен, хыялына ирешкән дә булыр иде — зәвык дигәненнән Ходай аны мәхрүм итмәгән, тегү машинасында да кызлар көнләшерлек итеп тегә, әмма анысы турында бик сөйләнеп йөрергә яратмый: көяз-фырт киенгән Стаин — бер хәл, ә тегүче Стаин — бөтенләй икенче. Һәрхәлдә, ул вакытта бу ике төшенчәнең буталуы-кушылуын Жорик теләми, ә фырт-көяз исеме белән ул бик горурлана, аны тырышып саклый иде. Шулай бервакыт мәктәп кичәсендә ул, бер гүзәлкәйнең үзенә сокланып карап: «Бу Жорик матур да киенә инде!» — дигән сүзләренә каршы бер сыйныфташ егетнең саксызлык белән: «Тегүче дә киенмәгәч...» — дигән сүзләрен ишетеп, тегене кыйнап ташлаган иде.

Әле мәктәпне тәмамлаганчы, тугызынчы сыйныфтан ук, күпләр Стаинның тормыш программасын белә иде инде: башта барып укырга, ә соңрак, ирләр киемнәре модельеры булып, үзе яулап алырга җыенган Ленинград аның теленнән төшми иде. Ул җәйге каникулларын да ике мәртәбә Питерда үткәреп кайткан иде. Һәм кинәт кенә — бөтен хыяллары, планнары җимерелсен әле! Аның — үзенчә мәшһүр һәм үз-үзенә чамадан тыш ышанган кешенең! Үзе гашыйк булган Төньяк башкала-

сында калырга да була иде аңа — зур заводлар берсеннән-берсе уздырып эшкә чакырып торалар. Ләкин андый хезмәт юлы Стаин өчен түгел иде шул, ул бу хакта уйлый да алмый, шунлыктан әле бер ай элек кенә, ничек тизрәк ычкынырга дигән шәһәренә кире әйләнеп кайтты.

Шунда ук һәр җирдә: «Стаин кайткан! Стаин кайткан! Жорик кайтты!» — дигән сүзләр таралды. Бу хәбәр бигрәк тә кызларны куандырды.

Рушан шул кичтә ук Стаинны үзәк урамда очратты, ул урамны шул ук Жорикның җиңел кулыннан «Бродвей» дип йөртә башлаганнар иде, шуннан бирле яшьләр телендә ул — «Бродвей». «Бродвей»да күптәннән үзенең көязлеге белән аерылып торган Жорик ул көнне барлык пижон вә стилягаларның һушларын алырлык итеп киенгән иде: тар балаклы аксыл-сары чалбар, вак шакмаклы көрән-сары твид пинжәк, ул бер капламлы һәм киң җилкәле, тар кайтарма якалы һәм бер генә төймәгә каптырылган, калын ак каучук табанлы, бер кырына ялтыр тимер аел куелган туфлиләр... Бу купшы көязлекне караңгы-куе чия төсендәге күлмәк һәм пальма янындагы маймыл алдында акшарланган-бизәнгән, сары чәчле ярым ялангач кыз рәсеме төшерелгән алтынсу-сары галстук тулыландырып тора иде.

Әйтергә кирәк, озын буйлы, килешле гәүдәле, шуның өстенә бик тә пөхтә һәм кигән киемнәрен иркен-ирекле йөртә белә торган Стаин өстендә бер әйбер дә карикатурачылар ясарга тырышканча ямьсез-гарип булып күренми иде. Ә бит Жорик ул заманнарда бик популяр булган һәртөрле сатирик листокларның даими яраткан мишене дә иде. Шәһәрнең чит буржуаз модаларга каршы галәмәт зур көрәше дә Стаин булганга күрә генә шундый югарылыкта тора иде. Рушан, ничә еллар үтсә дә, әле хәзер дә шәһәр паркының үзәк аллеясындагы төсле буяулы «Сатира тәрәзәләре»н күз алдына китерә. Шуларның берсенә җирле рәссам Жорикны коточкыч ямьсез акшарланган кызый белән зур патефон тәлинкәсе өстендә рок-н-ролл биегән итеп сурәтләгән. Астына, җитмәсә, хурлап шигырь дә чәпәгәннәр:

Жора, Фифа ял иткәндә
Әй бииләр буги-вуги!
Кигәннәре бик килбәтсез —
Буржуаз мода кием бугай.

Жорик парктан ерак булмаган Татар бистәсендә яши иде, шунда ук — гомер-гомердән шәһәрнең башкисәр ышпаналары, алар үзләренең начар гадәтләрен буыннан-бу-

ынга мирас итеп тапшыра торалар, шунда ук Рушанга хәзер туган тиешле абыйлы-энеле Гомәровлар — Шамил белән Исмәгыйль бәк гомер сөрә. Бистәнең өлкәннәре: итчеләр, тиречеләр, казылык пешерүчеләр, сабын кайнатучылар һәм башкалар — һәммәсе дә шәһәрнең иң зур предприятиесе булган ит комбинатында эшли, аның директоры Маркел Осипович Стаин иде. Комбинатта эшләү дәрәҗәле санала, ә өлкән Стаинны хөрмәт итә иделәр. Шуңа күрә горур Татар бистәсенең бер сугуда үгез үтерердәй ир-атлары да Жорка белән беренче булып исәнләшә, кеч-кенә Стаинны җәберләмәскә, аны якларга, аның белән дус булырга өйрәтеп, үз малайларының колакларын бора иде. Жорка үзе дә, әгәр дә табигате шундый булмаса, ваемсызлыгы белән юмарт һәм бистәдә шуның өчен аны яраталар, кесәсендә һәрвакыт акчасы бетеп тормый, аны кызганып тотмый, белгәннәрен дә кызганмый — сыйныфта кем сораса, шуңа күчерергә дәфтәрләрен дә бирә, син белмәгәндә, арттан пышылдап әйтеп тә утыра иде. Ә инде үсә төшеп, «Спартак» командасында футбол уйный башлагач, тиз арада иң яхшы уенчы, иң күп туп кертүче дә булып танылгач, Татар бистәсенең олысы-кечесе аңа табына башлады, аның даны тагын да артты.

Стаинның бер кырын карап алуы җитте, шул кичне үк парктагы теге шигырьле карикатура юкка чыкты. Ләкин Жорка үзенең шәһәрдә шундый гаугалар белән танылуына көлебрәк кенә карый иде шикелле, шуңадырмы, парк администрациясенең чираттагы шедеврын ут төртеп яндырырга тәкъдим иткән башкисәрләрне тыеп калды:

— Ә нигә? — диде ул ялкау гына.— Торсын эленеп. Кызганыч, кызы гына минем зәвыкта түгел, ә болай ярыйсы. Һәркемгә яшәргә кирәк бит: миңа — рок-н-ролл биергә, комсомолга — Көнбатышның чит һәм черек йогынтысыннан көләргә. Французларча әйтсәк — се ля ви яки тагын да гадирәк: һәркемгә үз өлеше. Бу — тормыш диалектикасы...— Шуннан соң ул, үзенә табынучыларның югалыбрак та һәм сокланулы да карашлары астында ваемсыз гына атлап, бию мәйданчыгына таба китеп барды...

Ленинградтан борылып кайткач, сентябрь башларында Стаин дусларын һәм сыйныфташларын шул ук паркның җәйге ресторанына чакырды. Кече Стаинга ярарга тырышып, чабыша-чабыша, официант кызлар аяктан калдылар, әле, җитмәсә, залның аргы башында үзенең фикердәшләре белән өлкән Стаин да кәеф-сафа корып утыра иде.

Мәҗлес Дасаевның исендә калды. Кунакларның һәммәсе дә көтелмәгән хәл килеп чыкканын, Жорканың Ленинградта яшәү хыялы чәлпәрәмә килгәнен аңласалар да, Стаин үзе бер дә алай борчылган яки югалып калган шикелле күренми иде.

Беренче тостны Жорик янында утырган дуслары хөрмәтенә күтәрде, җирле мединститутка укырга кергән кайберәүләрне котлады, көлемсерәбрәк кенә, булачак табиблар аның сәламәтлеге турында кайгыртырлар, ул-бу була калса, харап итмәсләр, дигән өметтә калганлыгын әйтте — кыскасы, һәммәсе дә бик күңелле һәм шаяру катыш иде. Мәҗлес азагына якынлашып килгәндә, әле берсенең дә китәргә теләге юк, чөнки күпләрнең, менә шушылай зурларча итеп, шәһәрнең иң яхшы ресторанында утырганы, аларның һәр теләген шунда ук үтәргә атлыгып торган официант кызларны күргәне юк иде әле. Күп эчсә дә, исермәгән Стаин кинәт кенә ярып салды:

— Беләсезме, минем тагын бер тостым бар, дуслар! Мин катгый рәвештә карар кылдым: дөнья ыгы-зыгыларыннан ваз кичеп, духовная семинариягә укырга керергә уйлыйм... Ләкин аңа чаклы әле бер ел бар һәм мин шул вакыт эчендә тормыштан бөтенесен дә алып калырга телим... Бөтенесен дә! Әйдәгез, типтереп күңел ачу һәм кызларның елмаюлары өчен күтәрик әле! — диде.

Өстәл тирәсендә гаҗәеп шау-шу күтәрелде! Һәммәсе дә, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә, Жорикка шаяртып киңәшләр бирергә тотынды: үзеңне тегеләй ит тә болай ит, догаларыңны яхшы ятла һәм башкалар, һәм башкалар... Көтмәгәндә генә дин турында кызып киткән бу кайнар бәхәс ни-нәрсә белән беткән булыр иде икән — билгесез, әмма кемдер кинәт шаркылдап көлеп әйтә куйды:

— Соң сез Жорикны руханиларның озын җиңле җиләнен — рясасын кигән итеп күз алдыгызга китерә аласызмы?

Башкалар да көлешә башладылар, чынлап та, священниктыр-поптыр килеш-килбәте Стаинга һич ябыша торган түгел шикелле иде. Шуңа күрә барысы да Жорикның бу хәбәрен дуамаллыкларга хирыс шаталак күңеленең чираттагы юләрлеге дип кенә кабул иттеләр.

Стаинның Ленинградтан кайтуы хөрмәтенә ясалган мәҗлескә җыелган кунаклар аның киләсе көздә духовная семинариягә укырга керергә җыенуы турында, һичшиксез, шунда ук оныттылар да. Әле таралышканчы ук оныттылар, аны үткен һәм кызык бер шаярту дип уйладылар. Ләкин бер атнадан шәһәрдә төрле имеш-мимеш

хәбәрләр таралды: гаепләп тә, сокланып та, хуплап та, хурлап та сөйләнделәр Стаин турында. Кыскасы, гаугасы җитәрлек булды...

Әле язын ук, Стаинның Ленинградтан хурлыклы кайтуына ярты ел кала, алар шәһәренә, төгәлрәге, чиркәү мәхәлләсенә кинәт кенә үлеп киткән поп урынына яңа священник билгеләнгән иде. Дөресен генә әйткәндә, ни ул чиркәү, ни Татар бистәсендәге мәчетнең шәһәр тормышында бер әһәмиятләре дә юк, алар тын гына, сиздермичә генә көн күрәләр, аларны бары тик дини бәйрәмнәрдә кайберәүләр генә искә ала иде. Анда да гыйбадәтханәләргә карт-коры гына җыелыр иде...

Ни чиркәү, ни мәчет үзенчәлекле архитектур бизәлешләре белән дә аерылып тормый, тарихи кыйммәтләре юк, шуның белән булса да үзләренә игътибарны җәлеп итә алмыйлар. Икесе дә бер үк вакытта диярлек, гасыр башында ук калкып чыккан бу биналарны бары тик нык һәм ышанычлы булганнары өчен генә мактарга мөмкин иде. Ә урыс чиркәвенең төп мактанычы: архитектураның бар кагыйдәләренә туры китереп тирә-ягына утыртылган зур гына бакча-паркы иде.

Элекке атакай күбрәк бикләнеп яшәде, аны шәһәрдә кем дә булса күрүче-белүче булдымы икән, сирәк-мирәк карт-корылар булса гына инде. Шәһәр ыгы-зыгысыннан ул таза таш койма белән аерылган, авыр челтәрле чуен капкасы елга бер-ике мәртәбә генә кунакчыл ачыла, ә башка көннәрдә чиркәүгә биек коймага уеп ясалган имән ишек аша гына йөриләр, ишек артында һәрвакыт төксе кыяфәтле тәбәнәк кенә бөкре карт тора. Элекке священникны махсус бакчачы һәм мәхәллә халкы карап-тәрбияләп торган бакча-паркы да шатландырмый, ул аның кызгылт ком сибелгән күләгәле аллеяларында хәтта озын, матур җәйге кичләрдә дә бик сирәк йөри. Изге атакай яшереп кенә эчә, шунлыктан кешеләр белән артык аралашмый, дип сөйлиләр иде. Атакайның шундый булдыксызлыгы болай да аз санлы мәхәллә халкын ишәйтми, чиркәү көннән-көн үлеп-бетеп бара иде.

Һәм менә яңа священник килде. Ул яшь, мөгаен, аңа утызлар тирәседер, шуннан артык булмас. Әлбәттә инде, руханиларны көрәк кадәр чал сакаллы, балавызлар тамып, катып-пычранып беткән, итәкләре үкчәсенә кадәр төшкән сутана кигән һәм һәрвакыт калтырап торган кәҗә тавышлы хәлсез картлар итеп күз алдына китерергә күнеккән халык өчен бу яшь атакай сәеррәк тоелгандыр. Ул озын буйлы, спортчыларча төз гәүдәле, берәр кинофильмда священник ролен башкаручы артист кыя-

фәтле иде. Куе кара сакалы аңа зыялы төс бирә, эчтән һәрвакыт тел-теш тигезмәслек чиста ак күлмәге күренеп торган утыртма якалы кара муар сутанасы-җиләне дә кичке фракны хәтерләтә. Бу тәэсирне бик модалы тар балаклы буй-буй чалбары белән елык-елык килеп торган озын кунычлы кара туфлиләре тагын да көчәйтә иде.

Кайбер көннәрдә яшь атакай яланбаш йөри, аның бераз гына чал керә башлаган куе чәчләрен хәтта шәһәргә көнчыгыштан, кайнар казакъ далаларыннан килеп кергән җил дә туздыра алмый. Әмма ешрак ул киң кырлы йомшак кара эшләпә кия, эшләпә аның, тазалыгы күренеп торса да, ак чыраена бик килешә. Йөзенең аклыгы, бәлки, шуңа да күзгә ташланадыр әле, аның кызларча озын керфекләр белән каймаланып алынган зур күзләре ниндидер эчке ут белән янып тора һәм ирексездән игътибарны үзенә тарта иде. Бу төс-кыяфәтне, килеш-килбәтне атакайның кулында һәрвакыт була торган, бик матур бөгелгән озын муенлы көмеш ат башлы топкалы, сирәк очрый торган күп ботаклы агачтан эшләнгән таягы тагын да тулыландырып тора. Кайчандыр ниндидер байныкы булганлыгы шиксез, бик оста зәвык белән ясалган ул таяк та рухани кешегә ятышмый шикелле үзе.

Кыяфәт кыяфәт белән, әмма яңа атакайның тормыш тәртибе дә башкаларныкыннан бик нык аерылып тора иде. Ялтырап торган кара лакка яңа буялган чуен челтәр капка якшәмбе көннәрендә киереп ачып куела, иртәнге тынлыкта борынгы чаң авазы яңгырый: даң-доң, даң-доң!.. Дөрес, бик үк төзек булмаган бакыр чыңы әллә ни еракка китә алмый, чөнки карап тәртиптә тотыла торган бакчаның агачлары илле елдан артык вакыт эчендә мәһабәт үсеп, аларның ябалдашлары күптән инде иң биек чиркәү манарасын да узып киткән, шунлыктан чаң авазы, тумас борын шул ябалдашларга егылып төшә дә, шунда бакча эчендә үк тына, мәхәллә халкына барып ирешә алмый кала.

Шимбә, якшәмбеләрдә атакай көне буе үзенең биләмәләрендә була, ә менә башка көннәрдә... Нәкъ иртәнге сәгать унда бөкре карт түбәнчелек белән имән янкапканы ача, атакай ашыкмый гына, дәрәҗәсен белеп кенә атлап чыга да шәһәр бакчасы ягына юл тота, ярты сәгатьтән ул инде «Бродвей»да була, үзәккә юлны кыскартып, кешесезрәк, таррак-тынычрак урамнан барып булса да, ул һәрвакыт медицина институты яныннан үтеп йөри.

Баштарак руханиның урамнарда йөрүен кызыксынып күзәтәләр иде. Атакай, адымнарын бутамыйча, ашыкмый

гына тигез атлап, як-ягына карамастан, үз уйларына чумган төсле итеп, аны дәшми-тынмый кызыксынып күзәтүче шәһәр халкы яныннан узып китә. Әмма аны баштарак кына шулай каршы алалар иде — тиздән аның бу иртәнге йөрүләренә күнектеләр һәм аңа игътибар итми башладылар.

Бәлки, ул укыган семинария яки духовная академиядә актер осталыгы шикеллерәк фән дә укытыладыр, иллә дә мәгәр ул үзен теләсә нинди артисттан да остарак тота иде. Аңа беренче гаҗәпләнүләр вакыты узды, үтеп-сүтеп йөрүчеләр ялгыш бәрелеп киткәндә дә һәрчак түбәнчелек белән гафу үтенми башладылар, әмма тыштан атакай боларга берничек тә әһәмият итми иде. Аны тирән уйларыннан бернәрсә дә аерып ала алмас шикелле, бары тик бик игътибарлы кеше генә кайчакларда аның авыр таягын кысып тоткан көчле кул бармакларының агарынганын күрә алыр иде. Ул үзәк урам буйлап эреле-ваклы кибетләр, киосклар яныннан уза, бер вакытта да аларның берсенә дә кереп чыкмый, ни киосклардан, ни лотоклардан бернәрсә дә сатып алмый, Орджоникидзе урамына җиткәч, һәрвакыт сулга, базар ягына борыла.

Татар бистәсенә илтә торган урам буйлап күтәрелгәндә, базарга якынрак тыкрык чатларында хәерчеләр очрый башлый, атакай аларның һәркайсына — носаримы ул, мөселманмы икәненә карамыйча, сүзсез генә көмеш тиен суза һәм адымнарын әкренәйтми генә юлын дәвам итә. Базарда ул шулай ук сүзсез-нисез, бернәрсә дә сорашмыйча, бәяләрен белешмичә һәм сатып алмыйча, рәтләрне карап йөри, хәтта суелган кош-корт ите һәм сөт азыклары сатыла торган ябык бинага да кереп чыга, әйтерсең лә санитар табибы, тик кулында бер әйбере дә юк. Базарның бөтен почмакларын йөреп чыккач, шәһәр эчкечеләре җыелып тора торган чәйханә янында гына адымнарын әкренәйтә төшеп, ул китеп бара. Атакайны күрүгә, исерекбашлар җәлт кенә чәйханә эченә шылалар, хәтта ишекне үк ябып куялар, юкса ул анда кереп торырга һич ниятләми инде.

Мөгаен, бу яңа рухани, һәрбер яшь кеше шикелле, зур планнар корадыр, ә бәлки, хәтта масаючан, дан сөючәндер, шуңа күрә, бөек казакъ далаларыннан җил себереп китергән комга әкрен генә күмелеп баручы шәһәрчекне тулаем үз мәхәлләсе итеп саныйдыр, якшәмбе көннәрендә дә чиркәүгә йөрүчеләрнең бар булганы бакча эчендә югалып бетәрлек кенә булганга пошынадыр. Шулай көн саен ул ышанычлы адымнар белән шәһәрне әйләнеп чыга, әйтерсең шәһәр аның чиркәү биләмәләре,

әйтерсең ул үзенең чиркәвенә гыйбадәткә йөриячәк мәхәллә халкын күзәтә һәм аларны өйрәнә.

Шунысы сәер, еш кына иртәнге шул йөрүләрендә атакайга гел бер урында җирле драматик театрның баш режиссеры очрый, менә ул инде үзенең тамашачылары саны ягыннан чиркәү белән ярыша алыр иде.

Дөрес, кыйшаеп-тапталып беткән ботинкалы, майланып каткан чалбарлы, тормышта инде шактый кыйналган һәм еш кына иртәннән үк салмыш бу режиссер — Мельпомена хезмәтчесе тышкы кыяфәте белән һич тә үзендә көч һәм ышаныч ташып торган атакайга тиңләшә алмас иде. Ләкин очрашкан минутларында икесе бөтенләй ике төрле бу кешеләрнең башларына: «Бу минем шәһәрем, мин аны яулап алачакмын! Вакыт кына бирегез! Сез әле, рухи чистарыну тоеп, рәхмәтле күз яшьләрегезне коячаксыз!» — дигән бер үк уй кермидер дип әйтеп булмас иде. Һәм, бәлки, һәркайсы үзенең алтарен, театрга да, чиркәүгә дә битараф шәһәрнең икесе ике башында торган изге йортларының киерелеп ачылган ишекләрен, шыгрым тулы залларын күрәдер.

Шулай йөргән вакытларында изге атакай бер мәртәбә дә туктап, беркем белән дә сөйләшмәс, бары тик хәер бирер дә, бик сирәкләрне генә чукындырып китәр иде.

Ул арзанлы үгет-нәсихәтләр укымый, чиркәүгә йөрергә өндәми, әмма аның үз-үзен тотышы, бар кыяфәте әйтеп тора шикелле: «Мин сезнең рухи атагыз, мин килдем, мин сезнең ничек яшәгәнегезне, ни-нәрсәләр өчен шатланганыгызны, сезнең өчен бәхет ни-нәрсә икәнен күзәтәчәкмен...»

Үзенең вәгазьләрендә дә ул чиркәүгә юлны онытучыларны шелтәләми, үзегез белән күршегезне дә ияртә килегез, дип үгетләми, ләкин аның нотыкларында ниндидер хикмәт бар, күрәсең, юкса карт-карчыклар гыйбадәт кылырга ишелеп-ишелеп йөри башламаслар иде, ә атакайның яшь, чибәр икәнлеге турындагы хәбәр еракларга таралгач, якшәмбе көннәрендә якын-тирә авыллардан да шәһәр чиркәвенә халык агыла башлады...

Изге атакайның иртәнге якларда ялгызы гына йөрүләренә күнеккән шәһәр халкы, аның көннәрдән бер көнне урамда Стаин белән йөргәнен күреп, шаккатты. Әйе, әйе, Жорик белән! Шаккатарсың да, кодагый! Алар атакайның гадәтләнгән юлы белән базарга бардылар, анда бераз озаграк торып, һәрвакыттагыча, медицина институты яныннан әйләнеп кайттылар. Алар, очраган кешеләрнең гаҗәпләнеп карап калуларына да игътибар итмичә, күптәнге дуслар шикелле, нәрсәдер турында бик җанлы

сөйләшеп кайталар иде. Алар авызларын ачып катып калган халык төркеме аша уздылар. Хәтта үсмер малайлар да ерактан үртәп: «Поп, поп — акылың юк»,— дип кычкырып калмады. Шәһәр Жорик Стаинның кем икәнен яхшы белә, шуңа күрә берәүнең дә аның белән бәйләнешәсе килми иде.

Әгәр дә җирле театрның баш режиссерын үз актерлары һәм шәһәр комитеты мәдәният бүлегеннән башка күреп танучы булмаса, Никанор атакайның кем икәнен әйтеп торуның хаҗәте юк иде инде — шәһәргә бик тә үзенчәлекле яңа рухани килгәнлеген һәркем ишетеп белә иде.

Никанор атакайның хәзер һәр көнне Жорик Стаин белән йөрергә чыгуы аңа карата булган кызыксынуны яңадан уятып җибәрде. Илленче еллар азагы иде, чынлап та, йокымсырап яткан бу шәһәр кисәгендә мөһим вакыйгалар сирәк була, шунлыктан шәһәргә яңа рухани килү буш кызыксыну булса да тудырмый калмады. Бер үк вакытта бер үк юлдан һәр көнне иртән шулай йөрүләре, аларның башка яшьләрдән нык аерылып торулары, әлбәттә, игътибарны тарта иде. Стаин белән Никанор атакайны һәр иртәдә очраткан режиссер ирексездән тәкәллефле генә итеп исәнләшеп уза, мөгаен, артларыннан карап калганда, пошынып уйлыйдыр: «Их, аларны безнең театрга тартасы иде, халык агылып кына торыр иде...»

Жорик Никанор атакай янында бер дә аңардан ким күренми, аңа хәтта руханидан артык аерылып тормас өчен дә бик көчәнергә туры килмәде, чуар галстук урынына ак күлмәк астыннан муенына кара яулык кына салды, тәти егетлегенең бердәнбер билгесе булып ак оекбашлары белән ялтыр кара мокасин туфлиләре генә калды. Бер-ике атна чәчтарашка бармый торган иде, Жорикның дулкын-дулкын куе чәчләре җилкәсенә төшеп тә җитте, ул яшь семинаристларга искиткеч охшый башлады.

Икәү шулай йөргәндә, Стаинның бөтен үзен тотышы-кыяфәте үзгәрә: ул атакайны бик игътибар белән тыңлый, буйсынучан, итагатьле, юаш, басынкы, сабыр... Әмма кичкә аның бөтен тышкы кыяфәте сәер рәвештә яңадан элекке Жорикка әверелә дә куя, көзге алдында берничә минут бөтерелеп, тегеләй-болай итсә, басынкы семинаристтан җилләр исә — үз-үзеннән бик канәгать, чибәрлегымлы йөзен бозып һәрвакыт елмаю кунган пижон, стиляга егет була да кала иде ул. Режиссер аңа юкка гына игътибар белән карамыйдыр шул — Стаинда, мөгаен, гаҗәп талантлы актер үлгәндер.

Жорик Стаин үскәндә үк үсмерләргә хас килбәтсез-килешсезлекләрсез, ябыкмыйча-суырылмыйча, битен бетчәләр басмыйча үсә торган егетләрдән булды. Унҗиде яшендә ул инде коеп куйган килешле гәүдәле чибәр егет иде, аның ничә яшьтә икәнен дә әйтеп бирерлек түгел, ә ул чорда әле ничек тә өлкәнрәк буласы килә һәм Жорик шулай күренергә бик тырыша иде.

Ул сыйныфташларыннан беренче булып киногa кичке сеанска керде, беренче булып кырына башлады, беренче булып, коймa тишегеннән түгел, ә билет алып, парктагы бию мәйданчыгына йөри башлады. Кыскасы, ул һәрнәрсәдә беренче иде, юкса өлкәнәя төшкәч, аңлыйсың — бию мәйданчыгына яз йөри башладың ни дә, көз ни, киногa соңгы сеанска үҗәтләнеп майда ук бардың ни дә, июльдә ни — барыбер бит, ә менә егет булып килгәндә барыбер түгел шул, беренче адым иң әһәмиятлесе, дәрәҗәлесе шикелле тоела.

Аңа, кемнәрнедер кара яндырып көнләштереп, һәрчак беренче булу ошый иде. Әлбәттә, ул яшьтәшләреннән иртәрәк тарта башлады: өлкән Стаинның өйдәге «Казбек» капларын санап бетерешле түгел, берсен алсаң, кем дә сизми. Мөгаен, эчүен дә беренче булып башлагандыр, тәгаен раславы кыен-кыенын, әмма анда да аның башкалар белән чагыштырганда үз өстенлекләре бар иде.

Элек икътисады бөтенләй бетәшмәсен өчен һәр өлкәгә үз аракы заводы булдырырга рөхсәт ителә иде. Аракы эшләп чыгару катлаулы нәрсә түгел, бик гади генә, шуңа күрә ул заводлар һәркайда гөмбәләрдәй калкып чыкты. Жорик беренче сыйныфка укырга кергәндә, алар шәһәрендә дә шундый завод пәйда булды, җирле сыра заводы җитәкчесе булган әнисен аракы заводы директоры итеп күтәрделәр. Стаиннарның подвалында аракының бетәсе юк иде һәм ул кибеттәге ише генә дә түгел, әнисе еш һәм даими кунакларына мактанганча, чистартылганы иде.

Өйләрендә исәп-хисапсыз булган аракы өлкәннәр тормышына тизрәк керергә ашкынган Жорик өчен иң көчле пропуск иде: паркта болганып йөргән башка яшүсмерләргә беркем дә игътибар итми, аларны беркайда чакырмый торган бер заманда Жорикка һәркайда ачык йөз иде.

Егетләр өчен, биюләр башланганчы, кафеның җәйге верандасында сыра эчеп яки берәр стакан шәраб салып утыру дәрәҗә санала һәм ул егетләр Жорикны еш кына сыра белән сыйлыйлар, чөнки аның җавапсыз калмаячагын беләләр иде. Соңга табарак ул үзе дә, паркка

килгәндә, газетка төреп, бер-ике шешә аракы белән бер түгәрәк ысланган казылык кыстырып килә башлады, килә дә Татар бистәсенең җиткән егетләре арасына кыю гына кереп тә утыра иде. Мондый күрелмәгән дорфалыкны хәтта, шешә кыстырып килеп тә, һәркем булдыра алмас, тәвәккәллеге җитмәс иде, әмма Жорик Стаин аерым бер шәхес иде шул. Татар бистәсенең иң башкисәр атаманы — күкрәгенә тушь белән канатларын җәйгән бөркет татуировкасы ясалган Исмәгыйль бәкнең кайвакыт биюләрдән соң: «Жорик, коткар, бер шешә тап!» — дип үтенүе аның күңеленә бик хуш килә. Жорик, әлбәттә, коткара, чөнки горур Исмәгыйль нәрсәне булса да сирәк үтенә, ә аның сүзе һәм абруе кире каккысыз иде...

Бик күп кешеләрнең ял итүе, күңел ачуы гел генә шәраб һәм аракы белән буталып бетүенә Рушан бик гаҗәпләнә иде, әле бит шул ук вакытта әллә ниләр кыланалар, башсыз бер кыюлык белән, купшы-фырт итеп эчә белү дәрәҗә санала. Бервакыт Жорик паркка өч шешә аракы алып килгән, мөлдерәмә тутырылган стакандагы аракыны кем дә кем кулы белән стаканга кагылмыйча, тамчысын да түкмичә төбенә кадәр эчеп бетерә, шуңа — бер шешә, ди икән. Һәм үзе шунда ук мисалга эчеп тә күрсәткән, тамчысын да түкмәгән. Аннары стакан төбен үпкәч, пакеттан тозлы кыяр алып чәйнәп куйган — моның барысын да ул ашыкмый гына, елмаеп эшләгән. Кыскасы, Стаин югары класс күрсәткән.

Тончыкса да, бушка эчәргә теләүчеләр, әлбәттә, табылган.

Әгәр дә башкаларны ничек тә мыскыл итмәсә, Жорик Жорик буламы соң?! Ул бер дә шунда ук аракы салып бирергә ашыкмаган, ә су кранына күрсәтеп, башта су эчеп күнегүләр ясарга кушкан. Газлы су сата торган киоскыдан стаканнар алып, әй тотынганнар барысы да түгә-түгә, тончыга-тончыга Стаин алдында осталыкларын күрсәтергә! Ә Жорик шаркылдап көлә-көлә, мыскыллап, булдыра алмаганнарны сүз белән чыбыркылап утыра икән.

Ул кичтә берәү дә бушка аракы эчә алмаган — үз егетләре белән Исмәгыйль бәк килеп чыккан да: «Аракы белән кәмит ясап утырма, әйдә, башка эшең булмаса, безнең янда утырырсың...» — дип, Жорикны шешәләре-ние белән ияртеп алып киткән.

## XXX

Көн саен бер үк вакытта Стаин Никанор атакай белән сөйләшеп йөрүләрен дәвам иттерә. Рухани — тирән гыйлемле, күп укыган кеше, Стаинга семинариядә һәм ду-

ховная академиядә укыган еллары, философия, теософия буенча сирәк очрый торган китаплары булган китапханәләр турында сөйли, Киевтагы тормыштан алган тәэсирләре белән уртаклаша.

Бу яшь егетнең үзен шулай бирелеп тыңлавы Никанор атакайда ышаныч тудыра, бу Ходай каргаган алласыз мәхәлләдә үзенә уң килде дип саный. Семинариядәге рухи остазларын шушы бик сәләтле егетне чиркәү канаты астына алуларын үтенеп язган үзенең хатын тегеләр куана-куана укыган кебек күз алдына китерә. Яшь рухани Никанор аңлый: яхшы гаиләдә үскән, шәһәрдә бер дигән егетнең, дөньяви вәсвәсәләрне җиңел генә ташлап, дин юлыннан китүе синодта иң өметсезләр рәтеннән саналган үз мәхәлләсе өчен уңай нәтиҗәләр бирүе мөмкин — килеп беренче ел эшләвендә үк семинариягә үзе әзерләгән шундый егетне җибәрүе остазларының өметләрен аклавын искәртергә тиеш.

Жорик атакайның нотыкларын тыңлавын тыңлый, ләкин, шулай булса да, һәр кичне шәһәр бакчасына биюләргә йөри, үзен тотышында һәм тышкы кыяфәтендә дә үзгәреш күренми шикелле, бары тик изүләре ачык кызыл күлмәге астыннан күкрәгендә бик сирәк очрый торган авыр алтын тәре артты, ул тәре кызыл рубин эмаль белән аркылы-торкылы ырмаулап та алынган әле — Никанор атакайның юмарт бүләге иде бу. Жорик кызып китеп, аерым бер дәрт белән рок-н-ролл биегәндә тәре һәркемнең күзенә ташлана иде.

Бер атнадан чиркәүдә дистәләрчә еллар тузан җыеп яткан арзанлы бакыр тәречекләрне кырып-себереп алып бетерделәр, бию мәйданчыгына җыела торган яшьләрнең яртысы аларны күрсәтеп, көязләнеп йөри башлады. Кайберәүләр бронзадан яки җиздән кисеп, бизәкле һәм авыр тәреләр дә ясарга өйрәнде. Күп еллар үткәч тә әле, яшьләрнең муенында асылынып торган тәречекләрен күргәндә, Рушан, беркатлыланып, бу шаукым Жориктан чыкты, дип уйлый иде.

Шәһәр комсомол комитетында, билгеле инде, көтмәгәндә килеп туган бу дини тайпылышлы хәлгә җавап бирүне кирәк таптылар һәм шәһәр бакчасында яңадан Стаинга карикатуралар пәйда булды: берсендә ул сутана-җилән кигән килеш буги-вуги бии, икенчесендә Никанор атакай белән тәүфыйклы гына сөйләшеп йөри. Карикатураларның астына кыска гына, әмма киная белән язылган иде: «Карагруһчылыкка юл» һәм «Бу юл түгел».

Никанор атакай шәһәр хакимиятенә барып, үзенең шәхесен хәкарәтләү, мәсхәрә итүләре турында зарланды,

шуннан соң аңа бүтән кагылмадылар. Ә Жорик мыегын да селкетмәде, карикатуралар янына дуслары белән килеп, рәссамнарның эшләренә көлешә-көлешә бәя биреп кенә узды. Дөрес, «Карагруһчылыкка юл» дигәнендә аны артык кыска аяклы итеп ясаганнарына тузынган булды, ул рәсем гадәттәгедән азрак эленеп торды.

«Бу юл түгел» дигәнендә Стаин бик мәһабәт итеп сурәтләнгән, әйтерсең рәссам алдында үзе басып торган диярсең — киеменең һәр өлеше бик җентекләп ясалган. Дуслары Жориктан: «Рәссамга бер-ике шешә аракы куймагансыңдыр бит? Бигрәк тырышкан»,— дип сорыйлар. Әмма ул аларның сүзләрен расламый да, кире дә какмый, бары тик серле итеп елмая гына, шуның белән үз шәхесен тагын да томанга төрә төшә. Шунысын да әйтергә кирәк, бу рәсем шәһәр бакчасында тиешле вакытын эленеп торгач, юкка чыкты һәм тиздән кыйммәтле рам эчендә Жорикның бүлмәсендә пәйда булды, ә соңрак Стаин аны Дасаевның бер курсташ кызына туган көнендә бүләк итте.

Стаинны комсомол шәһәр комитетына да чакырып карадылар, ул ялындырмады, бер дәшүдә үк барып җитте. Инде шул чагында ук конституцион ирекләр һәм гарантлар турында сөйләшкәндә демагоглыкта шомарып-каешланып беткән, шуның өстенә, җитмәсә, идеологик бәхәсләрдә тәҗрибәлерәк атакайдан да күп нәрсәләр өйрәнгән Жорик, ихтимал, бу очрашу-сөйләшүгә бик җитди әзерләнгән булгандыр, сүзләрен бер-бер артлы тезә-тезә, ул пропаганда бүлегендәге кызларны тәмам тирләтеп-кызартып бетерде. Ул хәтта аларга, семинарияне тәмамлап кайткач, һичшиксез, шушында калачагын, менә шул чагында яшьләр өчен комсомол белән дә тиешенчә көрәшәчәген әйтеп, янап та куйды. Жорикның бу оятсызлыгы да шәһәр халкына билгеле булды.

Стаинның гаугачыл җәнҗалчы булып танылуы ул көздә үскәннән-үсә барды. Бервакыт Стаин медицина институтында ел саен үткәрелә торган кичәгә бара икән, юлда аны бер кибешеп беткән карчык очратып, Жорикның алдына тезләнгән: «Фатихаңны бир, атакай!» — дип такмаклый башлаган. Жорик бер дә югалып калмаган, тыныч кына һәм бик эшлекле кыяфәт белән карчыкны чукындырып киткән, имеш. Моны бик җитди итеп, ышанып сөйлиләр иде.

Бертуктаусыз озын-озак көзге яңгырлар башланып, аннары яңгыр кар буранына әйләнеп, кыш кергәнче, Жорик белән Никанор атакай көн саен иртән йөрүләрен дәвам иттерделәр, әмма хәзер алар еш кына юлларын

үзгәртәләр, бары тик мединститут яныннан үтү генә шул килеш кала бирде.

Стаинның әти-әниләренә дә уллары өчен эшләрендә күңелсезлекләр булганын, аларны кайларгадыр чакыртып, аңа чара күрүләрен таләп иткәннәрен Рушан белә иде. Өйдә Жорик белән кат-кат сөйләшеп карыйлар, җитди итеп тә, күз яшьләре белән дә, әмма бернәрсә дә үзгәрми, ул һаман рухани белән очрашуларын дәвам итә, аңардан еш кына бүләкләр — изгеләр тормышына багышлап, бик зиннәтле итеп чыгарылган китаплар күтәреп кайта. Ул бигрәк тә көмешләр куеп эшләнгән кыйммәтле күн тышлы Тәүрат китабын кадерләп саклый — сирәк очрый торган ул фолиантны Никанор атакай белән йөргәндә кайвакытларда кулына да тотып йөри.

Кыш кышлыгын итә, шәһәр тормышы тына төшә, яшьләрнең күңел ачып йөрүләре дә сизелерлек басыла. Кыш бу юлы бик карлы, салкын, кешеләрне кайчакларда аяктан егардай көчле җилле-буранлы килде. Шәһәр уртасында бакчадагы юкә, тупыл агачларының ябалдашлары шәрәләнеп-каралып калды, бию мәйданчыгын һәм җәйге кафены кар күмеп китте, шуңа күрә бакча шәһәр уртасында бер зур кар өеме кебек булып күренә башлады. Соң яктыра, иртә караңгылана, кышкы йокының игечиге булмас төсле.

Алай да, салкын һәм бураннар булуга карамастан, кичке тормыш дәвам итә, бары тик аны яхшы шәйли белергә генә кирәк, ә моны һәркем дә булдыра алмый. Джазоркестрлар белән мавыккан Рушан кышын да һәр вакыйгадан хәбәрдар иде.

Кыш көне институтлардагы кичәләрнең бәһасе бермәбер арта, программалары озаклап, җентекләп әзерләнә, яшереп торасы юк, уку йортлары бер-берсе белән ярыша, бер-берләренә көндәш була, шунлыктан андый кичәләргә эләгүе дә бик җиңелдән түгел. Нинди генә концертлар куелмый, нинди генә оркестрлар ничек кенә тырышмый! Атнага ике тапкыр, шимбә һәм якшәмбе кичләрендә, шәһәр Мәдәният йортында джаз музыкасына биюләр оештырыла, анда саксофончы Эдди Костаки котырына. Зур булмаган зал керергә теләүчеләрнең яртысын да сыйдырмый, ләкин, шуңа карамастан, анда һаман да гел шул бер үк егетләр-кызлар җыелыша иде.

Башка төрле аралашу мөмкинлекләре дә бар,— хәзерге яшьләр өчен кафе, дискотека, яшьләр йортлары ише урыннар күп булганлыктан, алар белми дә инде,— теге заманнарда, берәр сәбәп тапкан булып йә гел сәбәпсез дә, кемнең дә булса квартирында яки йортында үзара акча

җыеп йә кем ни-нәрсә алып килә, шуңа риза булып, мәҗлесләр үткәрәләр иде. Андый кичләр яшьләр телендә «бәлешкә» дип йөртелә һәм еш кына алдан уйланмыйча, үзеннән-үзе оеша иде.

Институтларның кереп булмастай кичәләренә дә, мәдәният йортына да, иң кызыклы «бәлешкә» дә Стаинга юл ачык, аны һәркайда көтәләр, һәркайсына билеты, пропускысы, чакыру кәгазе бар.

Биюләр арасындагы тәнәфесләрдә, оркестр ял иткән арада, Стаин еш кына сәхнәгә менеп, яңа җырга заказ бирә яки яңа композиция уйнау турында сөйләшеп төшә. Кайвакытларда оркестр төн уртасына кадәр репетицияләр ясый, нәрсәдер яңаны әзерли, андый урыннарда Рушан да еш була, Жорик исә буш кул белән килми инде, бер-ике шешә аракы һәм әйбәт казылык күтәреп килә — оркестрда уйнаучы студент халкы аппетит юклыктан зарланмый.

Әмма ул кышта Стаин еш кына музыкант дусларына дәгъва белдерә: эчпошыргыч күңелсез сезнең янда, Никанор атакай янына барыйм әле, рухым-җаным өчен файдалырак кич үткәрим, дигән була. Шунда ук фойедагы телефоннан руханига шалтырата, тегесенең төннәр буена утыра торган гадәте барын белә, рөхсәтен алгач, хушлашып, чиркәүгә китеп бара.

Стаинның кайгы-хәсрәтсез, ваемсыз кышы шулай әкрен генә тәгәри тора. Аның хәзер инде сәер карарыннан кире кайтуын берәү дә үтенми, һәммәсе дә шуңа күнеккән һәм, дөресен әйткәндә, җилкуар Стаинны кызганалар гына иде. Дөрес, аңа сокланып караучылар да бар, ә инде болай да алар алдында уңыш казанган Жорикка шәһәрнең гүзәл кызлары Аллаһының хак юлында газапларга да әзер изге җан итеп карыйлар иде.

Өйләрендә дә тынычландылар шикелле, һәрхәлдә, эти-әнисен шәһәр комитетына чакыртып борчудан туктадылар. Георгий Стаинны Киев духовная семинариясенә кабул итү мәсьәләсе карала, дигән рәсми кәгазь дә килде.

Алай да Жорикны милиция бимазалап тора: ни өчен шундый сау-таза егет беркайда да эшләми? Никанор атакай ярдәмгә килде — Стаин чиркәүдә хуҗалык эшендә эшли, дигән белешмә язып бирде. Стаинның чиркәүдәге бар «эше» төннәрен Никанор атакай белән сөйләшеп утырудан гыйбарәт иде, ләкин хезмәт хакы вакытында килеп тора, аны дьяк айга бер мәртәбә биреп бара. Акча алган көннәрендә Жорик аеруча юмартланып типтерә, үз хәләл акчама кәефләнәм, дип көлә генә.

Никанор атакай белән төннәрен озаклап сөйләшеп утырулар, көндезләрен икәүләп урам әйләнүләр, дини әдәбият һәм теология буенча сирәк очрый торган китаплар уку Стаин өчен файдасыз үтмәде. Әле алкоголь тарафыннан җимерелеп өлгермәгән яшь хәтере һәммәсен дә йотып кына барды, Жорик, бернинди авырлыксыз-нисез, Тәүратны бите-бите белән яттан сөйли иде. Ул шулай ук чиркәү тәгълиматына һәм мистицизмга тартым философик әдәбият белән дә мавыга башлады.

Бию залларында, кичәләрдә яки репетицияләрдә булганда да, ул һәрвакыт бик урынлы гына итеп берәр изгенең яки дин галименең хикмәтле сүзен кыстырып куя, яттан Тәүратның берәр шигырь юлын укый, аның кайсы бүлектән, нинди шигырьдән икәнен әйтеп бирә. Бәлки, Жорик үзенә кирәк булганда, теге яки бу шигырьнең берәр сүзен төшереп калдырып йә аңа үзеннән берәр сүз өстәп, эчтәлегенә зыян да китерә, яңа мәгънә төсмере бирәдер — тик аны кем тикшерә ала да, кем кире кага ала? Андыйлар юк иде бит.

Стаин теләсә нинди сөйләшүгә — кызлар турында булсын, музыка, джаз турында булсын, мода турында — кыскасы, һәркайсына шундый оста итеп өзекләр, хикмәтле сүзләр, мәкальләр-әйтемнәр китереп кыстыра ки, тәҗрибәсез яшьләр ирексездән аның рухи өстенлеген, белеменең тирәнлеген тоялар. Хәтта кемнедер эчәргә мәҗбүр иткәндә дә, ул һәрвакыт берәр төрле дини эчтәлекле дәлил таба, аңа каршы торырга мөмкин булмый, юкса чиркәү бер дә эчкечелекне хуплап тормый инде. Хәтта аның бик кыю, үткен әйтелгән тостлары да дини мистицизм белән өртелгән була башлаган иде.

Исмәгыйль бәк компаниясеннән алып, саксофончы Эдди Костакига кадәр даирәдә иркен аралашып яшәп, юмарт рәвештә тел тегерменен әйләндерә белү үзенең нәтиҗәләрен бирми калмады: шәһәр яшьләре арасында, хәтта еллар үткәч тә, чиркәү сүзләре, Тәүрат, Инҗил кебек изге китап сүзләре бик еш кулланыла, ул югары дәрәҗәдә зыялылык, яхшы гамәл саналып килде. Жорикның сүз боткасы бигрәк тә кызлар халкына искиткеч тәэсир итә, аларга, оста сайлап әйтелгән сүзләрнең эчтәлегеннән бигрәк, егетнең артистларча матур итеп әйтә белүе ошый иде, ул елларда һәрбер кыз-кыркын истәлек дәфтәре тота, ул дәфтәрләрдә, башка төрле акыллы-хикмәтле сүзләр арасында, алдый-җолдый Стаин авызыннан чыккан Тәүрат-фәләннән өзекләр, дини кануннар да бардыр әле, мөгаен.

## XXXI

Шәһәр озын һәм авыр кыштан тәмам арый-талчыга, тәүлекләр буе мич ягулардан җык була — ул заманнарда йортларның өчтән бере төрле-төрле шәхси йортлар иде бит әле, кайчакларда өйләдән үк эңгер-меңгер башланып китә торган кыска көннәрдән халык туя, гыйнвар-февраль буе котырынган җил-давыллы бураннардан гарык була, рәтле-юньле транспорт булмаудан җәфа чигә — кырыкмаса-кырык ямалган иске автобуслар сирәк йөри, шәһәр халкы аңа бик өметләнми дә, шунлыктан, бик тә ихтыяҗы төшмәсә, озын юлга сәфәр чыкмый иде.

Әнә шул кырыс кышны түземлек белән үткәргәннәренә бүләк булып, ул төбәкләрдә яз искиткеч матур килә. Ашыкмый килә яз: җепшетә, тамчылар тама башлый, анда-санда сулар тибеп чыга, җылы җилләр исә. Шулай килә дә, кыштан үрнәк алыпмы, шактый озак тора, бары тик май ахырларында гына, сирәк-мирәк булган бакчаларда алмагачлар чәчәк атып бетергәч, шау сиреньнең хуш исләре яшьләрне исертми башлагач, шунда гына, анда да ашыкмыйча гына, вәкаләтләрен җәйгә тапшыра. Һәркемнең тизрәк авыр-калын, уңайсыз-килбәтсез кышкы киемнәрен салып ташлыйсы килә, төрле төстәге шәлләр чишелә, теләсә кайда йонын коеп калдыра торган куян бүрекләр салып ыргытыла. Иң көяз кызлар да кышын кимичә котыла алмаган киез итекләр киләсе кышка кадәрле мич башына йә чоланга ук чыгып кунаклый.

Март азакларында даладан искән дымлы җилләрдән көртләр иңә, шәһәр бакчасы өстендәге кар өеме астыннан исән-сау кышлаган куак ботаклары күренә башлагач, үзәк урамга — Карл Либкнехт урамына урам себерүчеләр чыга, үзләренең озын кыш буе эшсез ятуларыннан аклангандай, җәһәт-җәһәт кенә, тырыша-тырыша, калган кар белән «сугыша» башлый алар. Әгәр дә көтмәгәндә мул гына кар явып китмәсә,— март аенда аны-сы да була,— бер атнадан шәһәрдә бердәнбер булып, әлеге урам чистартылган асфальт юллары һәм тротуарлары белән каралып, күзгә бәрелеп тора.

Кыштан туйган шәһәр халкы үзәк урамның чокыр-чакырларын, уемты-сикәлтәләрен күрми дә — асфальт чыккан, димәк, яз һөҗүм итә, яздан сәлам килгән.

Апрельдә әле чиркәү бакчасы эчендә кар ята, аллея-сукмаклар иртәнге якта юка боз белән каплана да көндез эреп, күлдәвекләргә әверелә, менә шундый көннәрдә Никанор атакай белән Стаин яңадан шәһәргә чыгып йөри

башладылар, аларның юллары әле күз күңелләрдән кыскарак, чөнки Карл Либкнехт белән алар элек йөргән күрше урамнарда үтеп чыкмаслык пычрак әле.

Язгы салкынча һава торгангадыр, Никанор атакай җиләне өстеннән дөньяви тегелешле кара кастор пәлтә киеп куя. Стаин шулай ук кара, ике капламлы, җилкәләренә үк менгән биек якалы, пинжәкнеке шикелле тышкы күкрәк кесәле яңа демисезон пәлтә киеп, көязләнеп йөри, күкрәк кесәсеннән ак кулъяулык күренеп тора. Аның башына киң кырлы, кара велюр эшләпә дә менеп кунаклаган, ул аны кигән саен яңача кия. Руханидан башка гына йөргәндә, эшләпә бигрәк тә фырт киелә иде.

Алар бер-берсен шундый тулыландырып, тутырып тора, әйтерсең бербөтеннәр, әйтерсең Стаин хуҗалык эшчесе түгел, ә чиркәү рухание. Шуңа күрәдер, Жорик урамга шулай киенеп ялгыз гына чыкса, юлында очраган карчыклар тукталып кала, әгәр дә Стаин шундый кырыс һәм буй җитмәс күренмәсә, аны уратып алырлар, йөрергә дә ирек бирмәсләр иде. Әмма Жорик кирәк чакта ара саклый белә. Ул берәр әби җитәкләп барган баланың башыннан сыйпап үтәргә мөмкин, әмма шуннан артыгы — юк, аның ул гамәле мәрхәмәтлелек итеп кабул кылына, аннары аны ниргә буйларында утырган карчыклар тәмләп сөйлиләр. Әлбәттә, шулай да булгалый — берәр карчык, хәер-фатиха алырга теләп яки кулын үпмәк булып, аңа ташлана, әмма Жорик андый уңайсыз хәлләрдән дә абруен саклап кына чыга белә, ул карчыкларның берсенә дә үзенең дини бернинди дәрәҗәсе дә юклыгын, хәер-фатиха бирергә хокукы булмавын әйтеп тормый. Ул кешеләргә нәрсәнең булса да эчке мәгънәсе, асылы кирәкмәгәнен, тышкы рәвеше килсә, шул җиткәнен тиз аңлап алган иде. Шуңа күрә дә аларның шул зәвыкларын канәгатьләндереп тә килде. Халыкның көен күрә белү, халыкка ярый алуда ул әллә нәрсәләр уйлап таба ала, чөнки табигать аңа күпне биргән иде.

Шәһәргә чыгып йөрүләрне тиздән туктатырга туры килде — үзәк урам көннән-көн җанлана бара, халык ишәя, аларны ерып үтү, базардагы кебек этенеп-төртенеп йөрү бер дә рәхәт түгел, гафу үтенергә, уй-фикерләреңне ташлап торырга мәҗбүр буласың. Шуңа күрә Стаин белән Никанор атакай чиркәү бакчасының инде кибеп өлгергән түп аллеясында гына йөри башладылар.

Шул ук язда шәһәрне яңадан шаулаткан хәлләр булды.

Май аенда кышның эзе дә калмады. Иртә яздан йөреп хасил булган уемты-сикәлтәләрне ямаштырып куйдылар, җыелып торган сулар кибеп бетте — рәхәтләнеп йөр дә

йөр генә! Чәчәк атып утырган юкә, тупыл, зәңгәр сиреньнәрдән аңкыган хуш исләр теләсә кемне тыелгысыз рәвештә урамга тартып чыгара иде. Карл Либкнехт урамында, бигрәк тә эштән соң, кичке якта халык шулкадәр күп була, әйтерсең лә 1 нче Май бәйрәмендәге демонстрациядән кайталар диярсең. Инде шәһәр бакчасы да ачылган, кысан биналардан иркенгә чыккан труба, тромбон, саксофон шашынып-шашынып уйный-кычкырта — шәһәр елның иң матур фасылына керә, елмая-көлә, өметләнә-хыяллана.

Бу берьюлы дәррәү уяну шаукымы белән актүбәлеләр ничектер сизмичәрәк тә калдылар бугай, Стаин Никанор атакай белән шәһәргә чыгып йөрми башлады, рухани үзе дә язгы урамнарда байтактан бирле күренми иде. Моңа сәбәп тә бар шикелле: май аенда урысларның уразасы, ә ай азагында — Пасха, чиркәү тормышында иң зур вакыйга. Бу — яңа мәхәлләдә Никанор атакай өчен беренче Пасха...

Стаинның үзенә дә әллә нәрсә булды, юкса ничек яшәсә, шулай яши бирә иде кебек. Сезонда беренче футбол матчында уйнап, «Локомотив» капкасына өч туп «сылады», моңа кадәр Бразилия торсидасы белән Италия тиффозилары турында ишетеп тә карамаган Татар бистәсе ул шимбә кичендә шәһәр бакчасына ишелеп төште һәм төн уртасына кадәр типтерде дә әйттерде. Кафеның һәм җәйге ресторанның һәр өстәле тирәсендә кәефләнүчеләр, бакчадагы утыргычларда урнашып, өеннән алып килгән кабымлыкларын чәйни-чәйни, ашарга җитмәсә, аяк астында чуалган малай-шалайны яңадан өйдән нәрсә дә булса алып килергә куа-куа эчүчеләр бихисап иде. Һәм һәркайда, һәркемнең телендә бер генә сүз: «Стаин... Стаин... Жорик...» Жорик бию мәйданчыгында һаман да элеккечә игътибар үзәгендә булды, үзен урап алган яшь-җилкенчәк аның һәр сүзен йота бара иде. Ул элеккечә үк купшы-көяз киенгән, бары тик кинәт кенә чәчен китәргән — алай бик кыска итеп тә түгел үзе, әмма карчыкларның күңелен эретә торган, попларныкыдай озын ялы җилкәләреннән юкка чыккан, шунлыктан егетнең йөзе тагын да сөйкемлерәк күренә иде. «Футбол уйнарга уңайлырак булсын өчен чәчен алдырган»,— дип фаразлады кемдер, Стаин моны кире кагып тормады.

Көннәрдән бер көнне, атна уртасында, Жорик оркестр музыкантларына үзенең иртәгә китәсен әйтте.

— Киевкамы? — дип сорадылар, аның тормышы-язмышындагы көтелмәгән борылышларга күнеккән музыкантлар.

— Юк, Кырымга, җәй буена ял итәргә,— дип җавап бирде Стаин һәм теләр-теләмәс кенә өстәп куйды: — Дин белән араны өздем, туйдырды...

Музыкантларга уйнарга кирәк иде, сүз шунда өзелде. Әмма, алар уйлаганча, Стаин хушлашырга яңадан килеп тормады һәм икенче көнне, чынлап та, юкка чыкты. Җәй буена күренмәде.

Ә бер атнадан җирле газетта телгә керердәй, истә калырдай бер мәкалә басылып чыкты. Аның исеме озын һәм дәгъвалы иде: «Чиркәүдән йолып алынган тагын бер яшь язмыш». Мәкалә үзе дә бик озын-буталчык, анда Стаинның үзе белән әңгәмә дә кыстырылган, ул исә чиркәү һәм дин турында сафсата сата, хәзер инде цитата һәм хикмәтле сүзләрне башка чыганаклардан, нигездә, марксизм-ленинизм классикларыннан алган иде. Әле бер ай гына элек чиркәү кануннарын нинди кайнарланып-дәртләнеп яклаган булса, хәзер шундый ук кайнарлык белән аларны җимерергә тырышкан иде ул. Әмма Стаинны якыннан белүчеләр бу мәкаләдәге һәр сүзгә дә ышанып бетмәделәр, аның ихласлыгына, инанып сөйләнүләренә ничек ышансыннар ди — һәр юлыннан мыскыллы елмаеп Жорик үзе карап тора шикелле ич! Мәкаләсен йомгаклап, журналист яшь егеткә үзенең шәхесен раслау өчен шундый авыр-катлаулы юлында уңышлар тели, кешеләр һәм оешмалар аның гадәти булмаган язмышын аңларга тырышырлар, дигән ышаныч белдерә. Шулай итеп, Жорик Стаин мәкерле чиркәүнең корбаны һәм, үзен богаулаган чылбырларны өзеп, дин сазлыгыннан котылып чыккан герой булып танылды.

Әгәр дә, Пасхадан соң бер ай үткәч, Никанор атакайны биредән чакыртып алмаган булсалар, бу мәкалә дә, башкалары шикелле үк, тиздән онытылган да булыр иде. Шәһәрдә янә имеш-мимеш сүзләр таралды: әллә Никанор атакай Жорик белән бергәләп ниндидер акчаларны туздырып, чиркәүнең зиннәтле әйберләрен югалтып-таратып бетергән, әллә аларны Стаинга кәрт уенында оттырган ди шунда. Аннары, кышкы озын кичләрдә рухани янына Жорик һәрвакытта да берүзе генә барып йөрмәгән икән, аның белән Татар бистәсенең атаклы шулеры, колакка саграк Шамил Гомәров та булгалаган ди. Стаин артыннан утка-суга керергә әзер кызлар да баргалаган ди әле анда. Соңгы фаразлауларга нигез дә бар шикелле: Рушан Дасаевның курсташы, чибәр, әмма җиңел-җилбәзәгрәк Ниночка Кабанова, Никанор атакай китеп барганнан соң ук,

кинәт кенә техникумнан документларын алып, билгесез тарафка китеп югалды. Менә шул рәвешле, ирекледәнме-ирексездәнме, Стаин торгынлыктан чыгып, аякка басып килә торган чиркәү мәхәлләсен яңадан егып салды, алар шәһәрендә хәзер чиркәү беркемне дә кызыксындырмый инде.

Техникум тәмамлап, берничә ел үтте, Рушанның юллары Стаин белән аерылгач, ул, очраклы гына туры китереп, «Крокодил» журналыннан бер фельетон укыды. Анда Аллага табынучыларның яшерен тәүбә серләрен үз мәнфәгатьләрендә оста файдаланучы ниндидер бер бозык рухани турында язылган иде. Бу руханиның күпсанлы корбаннары арасында Нина Кабанова исеме дә телгә алына, атакай аны, укуыннан аерып, элекке мәхәлләсеннән алып киткән дә, сөяркәсе иткән, ә соңрак үз афераларына ярдәмче ясаган икән.

Рушан Дасаев җәй көне бию мәйданчыгында оркестр музыкантларыннан ишеткән сүзләрен исенә төшерде: исерек Шамил аларга Жорик белән икесенең ничек итеп Никанор атакайны кәрт уенында бик нык «шартлатканнарын» мактанып сөйләгән, бу эшне ул үзе түгел, Стаин башкарып чыккан икән, руханиның ачылмаган борынгы кәрт колодасын сиздермичә генә алып киткән дә, Шамилгә тоттырган, ә инде аның өчен кәртләргә үзләре генә аңларлык тамгалар салу: тишкәләү, юкарту пүчтәк кенә. Менә шул тамгалы кәртләр белән уйнап янган да инде изге атакай — мәхәлләсез калган. Әмма бу сүзләр музыкантлардан ары китмәде, Шамилнең кыланмышлары турында шәһәрдә бик сөйләнеп йөрү гадәте юк иде.

Шулай итеп, Рушан ирексездән Көнбатыш Казакъстанның Акбүтә шәһәрендәге чиркәү мәхәлләсенең яңарып терелүенә һәм озакламый түбән тәгәрәвенә шаһит булды, әмма ул вакытта бу вакыйгага ни ул, ни өлкәнрәк буын кешеләре артык әһәмият бирмәде — партиянең каты кулы белән кертелгән дәһрилек — атеизм җимешләре көчле иде.

Чиркәүне хурлыкка калдырганы өчен Стаинга рәхмәтле кешеләр дә булмый калмагандыр, бигрәк тә өлкә һәм шәһәр комитетларында: аларны, чынлап та, Никанор атакайның абруе арта баруы борчый, дин белән ачыктан-ачык намуслы көрәштә үзләренең көчсезлеген тою гаҗиз итә иде — һәм кинәт шундый уңыш! Димәк, тыелгысыз-йөгәнсез дәрт-теләкләргә ия җилкуар Жорик Стаин, телиме-теләмиме, дәүләт аппаратына әйтеп бетермәслек зур хезмәт күрсәткән булып чыга...

## XXXII

Рушан Дасаевның, дөрестән дә, иҗат сәләте бардыр, юкса аны мондый сораулар, мөгаен, борчымас иде. Үткәннәрен уйлап утырганда, ул үзенең балерина Валентина Ганибаловага язмышын алдан әйтеп бирә алганын исенә төшерде, әмма үз тормышын һәм кайбер эшгамәлләрен башкачарак яктыртырдай шундый ике очракны онытып җибәргән булып чыкты.

Алтмышынчы еллар уртасында ул Ташкенттан ерак түгел, бер сәгатьлек юлда, әле исеме танылып та бетмәгән Заркент шәһәрендә химия, соңрак металлургия комплекслары төзүдә эшләде. Белгечләр өчен салынган «Яз» кунакханәсендә айлар буе яшәде.

Шәһәр зурдан кубып салына, проектлаучылар фикеренчә, ул социализм маякларының берсе булырга тиеш, шунлыктан аның бина-фәләннәре һушларыңны алырлык итеп эшләнә иде. Мәсәлән, шлак сибелгән юллы, ул вакытта Уфадан кала илдә икенче, үз мототреклары бар иде. Язларын анда атаклы узышчылар, исемнәре дөньяга танылган осталар җыела: Борис Самородов, Игорь Плеханов, Юрий Черканов, Фәрит Шайнуров һәм легендар Габдрахман Кадыйров — спидвей буенча унике мәртәбә дөнья чемпионы. Бу спортчылар да озаклап «Яз» кунакханәсенә туктала иделәр.

Рушанга ул чагында Заркентның рухи тормышы шул абруйлы кунакханә тирәсендә кайный төсле тоела иде. Яңа шәһәрләр ниндидер романтика белән өртелгән, аерым бер кызыксыну уята, аларга багышлап шигырьләр языла, җырлар җырлана, яңа совет кешесенең гармоник шәхесен тәрбияләр өчен бөтен шартлар тудырылган, киләчәк шәһәрләренең өлгесе, дип мактала торган Заркентка сугылып китү мөмкинлеген Ташкентка килгән мәшһүр артистлар да ычкындырмыйлар иде.

Төзелеш биниһая колачы һәм киңлеге белән таң калдыра: шәһәрдә менә дигән спорт заллары, җитмәсә, пайтәхетле калалар да көнләшерлек бик шәп Спорт сарае бар, гаҗәеп бай итеп зиннәтләнгән ике заллы Сәнгать йорты да аңардан калышмый. Заркентка еш килүче атаклы артистлар да шул «Яз» кунакханәсен яратып өлгерде — талантлы архитекторлар, сынчылар, рәссамнар, химия һәм металлургия өлкәсендә күренекле белгечләр, төзелешләрнең яшь җитәкчеләре оясы иде ул кунакханә. Җитәкчеләр бигрәк тә күп булып, алар үзләрен социалистик яшь шәһәрнең хуҗалары итеп тоялар иде.

Төзүчеләр арасында андый иҗади күтәренкелекне Рушан башка беркайчан да, беркайда да очратмады, юкса үз гомерендә ил буйлап күп йөрде, күп төзеде. «Яз» кунакханәсе чын мәгънәсендә яз, яңару билгесе булды. Аның тәрәзәләре таңга кадәр балкып тора, ресторан яки барда башланган әңгәмә-бәхәсләр бүлмәләрдә дәвам итә — нәрсәләр турында гына бәхәсләшмиләр дә, ничек кенә хыялланмыйлар иде анда!

«Яз» кунакханәсендә даими торганлыктан, Рушан шул чорда бик күп танылган спортчылар һәм журналистлар, актерлар һәм эстрада йолдызлары, хәтта киләчәк шәһәрен күрергә ашкынып килгән язучылар һәм шагыйрьләр белән дә танышып өлгерде.

Шәһәр халкының гомуми мавыгуы спидвей ярышлары булды. Башка бик күпләр шикелле, Рушан да Габдрахман Кадыйровка мөкиббән иде, аның кызыл шарфы һаман күз алдында тора һәм гомер онытылмастыр, мөгаен. Соңрак ул җирле футбол командасы «Металлург» өчен «авырый» башлады, ул командада Ташкент «Пахтакор»-ыннан күчеп килеп соңгы елларын уйнаучы атаклы Станислав Стадник, грузин «варяглары» Джумбер Джешкариани, Роберт Гогелия һәм Тамаз Антидзелар бик оста уйный иде.

Эше тыгыз булуга карамастан, Рушан күп укыды, чөнки тирә-юньдә даими рәвештә театр һәм китаплар, кино һәм музыка, рәсем сәнгате һәм архитектура, музей һәм күргәзмәләр турында сүз алып баралар — хәзерге күзлектән караганда, менә шундый иркен-хөр, хыял канатлы сәер заман иде ул. Каттан катка, бүлмәдән бүлмәгә журналлар, китаплар, хәзер «самиздат» дип тамгаланган кулъязмалар кулдан-кулга күчеп йөри, кайда барма «Ә син укыдыңмы әле?.. Ә син күрдеңме әле?..» кебек сораулар явып кына тора иде.

Китаплар тирәсендә илдә туып килгән ыгы-зыгылы шаукым ул якларга әле барып җитмәгән, теләсә нинди китапны итәк астыннан түгел, ә кибетләрдән иркен сатып алып була, ирекле сатуда бик сирәк очрый торган, хәзергечә әйткәндә, раритет басмалар да булгалый иде.

Әгәр дә ахырына кадәр хакны сөйләсәк, китаплар белән шулай мавыгуда өстенлек чит ил әдәбиятына бирелеп килде. Рус әдәбиятының матурлыгын һәм көчен, барыннан да бигрәк Бунин иҗатының тәмен Рушан соңрак аңлаячак иде әле, Бунин шуннан соң бик озак кына калган байтак язучыларны томалап торды. Әдәбият белән кызыксынуның аннан соңгы чираттагы әйләнешендә ул совет авторларына юлны үзе эзләп тапты, аларга күп ке-

шеләр кул селтәп кенә карыйлар иде бит, ә Рушанның өстәленә Катаев, яшь Казаков, Распутин китаплары озакка менеп кунаклады, ул үзе өчен Битов һәм Фазыл Искәндәр, Тимур Пулатов һәм Грант Матевосян, Белов һәм Можаев, Трифонов һәм Макашин исемнәрен ачты... Кызганыч, бу исемлектә бер генә татар язучысының да исеме юк, чөнки Рушан алар иҗатыннан бихәбәр иде...

Ничектер эштән кайтышлый, ул урам чатындагы сатучыдан бик матур итеп чыгарылган калын бер китап сатып алды — «Условия человечского существования» («Кешенең яшәү шартлары»). Бу роман исеме аңа таныш булмаган япон язучысы Дзюнпей Гомикаваныкы булып чыкты, юкса Рушан шундый ук исемдәге башка бер китапны белә, анысының авторы танылган итальян язучысы иде. Әлеге мең битле диярлек калын романны (Аллага шөкер, хәзер андыйларны язмыйлар инде!) ул берничә көндә төн йокыларын калдырып укыды һәм тәки җиңеп чыкты. Китап аны тетрәндергән иде, ул әле хәзер дә төп геройның исемен хәтерли — Кадзи.

Шактый вакытлар узгач, әдәбиятыбызда социалистик реализмның уңышлары һәм уңышсызлыклары турында матбугаттагы әдәби бәхәсләргә килеп төртелгәндә,— ә ул бәхәсләргә югары уку йортлары студентлары гына түгел, хәтта мәктәп укучылары да тартылган иде,— Рушанның күз алдына ирексездән әлеге калын китап, аның рәссам тарафыннан самурай кылычларына охшатып, шул ук вакытта иероглифларга да тартым итеп, көмешсу фольга белән басылган озын исеме килә һәм ул совет әдәбиятында социалистик реализм ысулы дигән нәмәрсәне уйлап чыгарган яңа идеология тарафдарлары һәм ил җитәкчеләре, мөгаен, нәкъ менә шундый тулы канлы, сыгылмас, принципларга һәм идеалларга турылыклы, үрнәк булырлык герой турында хыялланганнардыр, дип уйлый иде. Әгәр дә аның үзеннән: «Соцреализм калыбына туры килердәй идеал геройны нинди итеп күрәсез?» — дип сорасалар, ул, һич икеләнүсез, япон китабының баш герое Кадзи исемен атар иде. Япон язучысы ул романын бернинди идеологик тышауларсыз, нинди дә булса сыйнфый карашларсыз безнең гасыр башында ук язган, ихтимал, шунлыктандыр аның герое барлык чорлар һәм барлык халыклар өчен дә ярашлы чын герой булып чыккан.

Ул китап Рушанның исен китәргән иде, һәм ул аны барлык дусларына-танышларына укырга тәкъдим итеп йөрде, әмма, ни сәер, роман берәүне дә ул кадәр сокландырмады, дәртләндермәде. Янә бер егерме еллар үткәч,

поездда кемнәндер алып торган «Иностранная литература» журналының бер санында «Культура и искусство» дигән бүлектән Рушан Кояш чыгышы иле — Япония язучылары ассоциациясе Дзюнпей Гомикаваның «Кешенең яшәү шартлары» дигән романын егерменче гасырдагы иң яхшы япон китабы дип таныганлыкларын укып белде. Ул үзенең яшьлектәге сизгерлегенә шул чакта бик куанган иде, дөньяда иң күп укый торган ил СССР түгел, ә барыбер Япония икәнен дә белә иде инде.

Ә тагын бер биш елдан соң, ул әлеге китап белән бәйле янә бер шатлык кичерде — «Советская культура» журналыннан япон телевидениесенең шул роман буенча егерме серияле фильм төшергәнен, аны инде дистәләрчә илләр сатып алганлыгын укыды. Әмма сатып алучылар исемлегеннән Рушан үз дәүләтенең исемен юкка гына эзләп маташты — алар арасында СССР юк иде.

Бәлки, кайчан да булса, гадәттәгечә бик соңлап, бер ун елдан әлеге фильм безнең телевизор экраннарында да күренер, әнә төшерелүеннән соң илле ел үткәч һәм бөтен дөнья сокланып туйгач, «Унесенные ветром» фильмын сатып алдылар бит. Менә шул чакта, мөгаен, нинди дә булса пенсионер карт моннан кырык еллар элек Заркентта Рушан исемле яшь прорабның әлеге романны укырга тырышып, кайнарланып йөргәнен исенә төшерер: «Аңарга кул гына селтәп караганнар иде, алай итәргә кирәк булмаган икән»,— дияр.

Барысы да булырга мөмкин, бернәрсә дә эзсез узмый, һәрнәрсә үзара бәйле, иртәме-соңмы ул билгеле була, барысы да үз урынына утыра, моның дәлиле — илебез тарихы, безнең бөтен тормышыбыз. Әле күптән түгел генә, чирек гасыр үткәч, Рушан яшьлегендә исен китәргән әлеге романның яңа басмасына тап булды. Һәрнәрсә кабатлана...

Җәйге бию мәйданчыгында Валя Домарованы чәчен сарыга буяткан марҗа итеп күргән җәендә, Рушан инде мастер булып эшли һәм Мартукка беренче хезмәт ялын үткәрергә кайткан иде. Ничектер әбәт алдыннан урамда йөреп керергә чыкты да райүзәк өчен шактый бай булган китап кибетенә барып керде, шунда «Егерменче гасыр чит ил романы» сериясендә чыккан йомшак яшел тышлы юка гына бер китап сатып алды. Китап өч ел элек чыгарылган, хәзер бәясе төшерелгән һәм нибары егерме тиен тора иде. Ни китап авторы Фрэнсис Скотт Фицджеральд, ни романның исеме «Великий Гэтсби» («Бөек Гэтсби») Рушанга бернәрсә дә сөйләми, бары тик сериясе һәм китапны чыгарган «Художественная лите-

ратура» нәшрияты гына таныш түгел исемгә ышаныч тудыра иде.

Китапны ул өенә кайта-кайта ук укый башлады, аннары сатып алганнан соң ике сәгать эчендә укып та чыкты. Шул көнне үк Рушан кибеткә яңадан килде һәм, сатучы кызларның шатлыгына, китапның калган барлык нөсхәләрен алып бетерде — нәкъ ике дюжина, ягъни егерме дүрт данә иде.

Ташкентта ул китапларны әдәбият сөюче дуслары һәм танышларына бүләк итеп таратты. Япон китабы белән булган шикелле үк, янә беркем бер сүз әйтмәде: ни мактаучы, ни яманлаучы булмады. Бу романны да «оныттылар». Ләкин Фицджеральдны, Гомикаваны көткән кебек, егерме ел көтәргә туры килмәде Рушанга: бер дүрт елдан соң аның «Назлы төн» романы басылып чыккач, ә бәлки, башка сәбәптәндер, илдә Фицджеральд китапларына ябырылдылар, аңа кадәр Хэмингуэйга шулай ябырылган иделәр. Шуннан соң «Бөек Гэтсби»ны үзе бүләк иткән байтак дуслары, романны соңлап булса да укып чыккач, Рушанга ул китап өчен рәхмәт әйттеләр...

Менә шундый сәер генә хәлләр килеп чыга тора аның тормышында. Гомерем бушка узды, ачышларсыз-эзсез узды, дип уфтанган авыр минутларда шундый юк кына нәрсәләр дә күңелгә бер юаныч була. Үткән гомеренә шулай йомгак ясый-ясый, Рушан тагын бер җавап табылмастай сорау белән газаплана: ни өчен ул Гомикава, Фицджеральдлар һәм хәтта Германиянең берләшәчәге хакында алдан күрә килде дә, ни өчен Лом-Али Хәкимов белән бергәләп Эллочка Изместьеваны киләчәктә прокурор һөнәре үләчәк, безнең җәмгыятьтә хокук органнарына эш калмаячак, дип ышандырып маташты һәм... бик каты ялгышты?

Ихтимал, шунлыктандыр гадәт буенча «Ленин, Сталин балалары» дип йөртелеп килгән алар буыны яшь социалистик реализмның барлык күңелсез яклары — караңгы капиталистик үткәннән калган мирас, тирә-юньдәге барлык тискәре күренешләр, шул исәптән, җинаятьчелек тә чит идеологияне онытып бетермәгән өлкән буын китеп бетү белән үзеннән-үзе бетәчәк, дип ихластан ышана иде.

Рушан бервакытта да сәясәт белән артык кызыксынмады, нинди дә булса идеологиянең колы булмады. Әлбәттә, башкалар шикелле, ул да пионер, комсомол булып йөрде, әмма сәясәт аны мавыктырмады, үсеп җиткәч, һәрнәрсәне үзе уйлап хәл итәргә өйрәнде, бик тырышып үгетләсәләр дә, партиягә кермәде, кесәсендә партия билеты йөртмәде.

Хәзер күпләр, КПСС әгъзасы булмасаң, ни фәнгә, ни сәнгатькә, ни башкасына үрләп булмый иде, дип расларга тырышалар. Ахыр чиктә, үз буыны турында Рушан прорабларча туп-туры ярып әйтә ала: карьера ясар өчен, түрә булып, җылы кәнәфидә утырыр өчен керәләр иде партиягә. Сиңа партбилет тоттырырга теләүчеләр дә артык тел яшереп тормый, ачыктан-ачык әйтәләр иде: начальник буласың килсә, чит илләрдә эшләп кайтырга теләсәң — партиягә кер! Рушан кермәде, түрә булмады, чит илләргә чыгып «акча сугып» йөрмәде, әмма гомере буе прораб булып калуына тамчы да үкенми иде.

Рушан Дасаев эчке бер тоем белән сизенә: кешенең җирдәге бурычы — нәрсәгәдер, кемгәдер аркаланып-ышыкланып яшәү түгел, ә үзең кемдер булу, иҗтиһат итү, бар итү — әнә шул табигый ир-егетлек башлангычы аны дөньяны үзгәртеп кору, җирдә иң гадел җәмгыять төзү, гармоник шәхес булырлык яңа кеше тәрбияләү дигән купшы шигарьләр белән «өлкәннәр уены» уйнаучыларга кушылып китүдән тыеп тора да иде. Һәр почмакта, һәр рәсми бинаның маңгаенда чекерәеп торган атаклы Ленин сүзләрен акылы булган кешеләр партиягә пародия итеп кенә кабул итәләр иде бит. Чынлап та, көлке түгелме, кешелек дөньясы туплаган барлык белемнәрне үзләштереп бетергәч кенә коммунист булырга мөмкин, имеш. Мөмкин эшме соң бу?! Нишләптер тормышта бер генә андый хикмәтле коммунистны да очратканы булмады әле Рушанның. Рәсми саннар буенча коммунистлар илдә егерме миллионга якын дип исәпләнсә дә, юри җыйган кебек, аңа гел генә томаналары, наданнары, явызлары, алдакчылары очрап торды. Бәлки, сәясәткә карата нәфрәт хисе дә нәкъ шул Ленин сүзләрен укыганнан соң тугандыр әле. Рушан күзенә ул сүзләр бик иртә чалынды һәм ул аны ниндидер ялган-ясалма, тормышка ашмастайны чынбарлык итәргә теләү дип кабул итте.

Мөгаен, ни Ленин, ни партия турында Рушан исенә дә төшереп тормас, ничек булса да, аларсыз да яшәр иде әле, әмма бүген җәмгыятьтә шундый таркалу барганда, һәрбер җирдә сүз-бәхәсләр бары тик партия һәм аның юлбашчысы яки юлбашчылары тирәсендә генә бөтерелә — алардан һич качып котылып булмый...

Үзгәртеп коруның беренче юбилей елында,— аны да хәзер бишьеллыклар белән генә исәпли башладылар! — Рушан профсоюз санаториендә ял итте. Бер өстәлгә җитди ир-атлар туры килде. Арада иң яше Рушан, калганнары инде күптән илледән узган кешеләр иде. Һәм,

әлбәттә, бар сөйләшкәннәре партия, үзгәртеп кору, Горбачев, Ленин, Сталин, бүгенге чын һәм ялган лидерлар-җитәкчеләр турында булды. Дасаев бу усал һәм буш әңгәмәләрдән бик тиз туйды, шуңа күрә ашарга алданрак та, соңга калыбрак та килеп карады, әмма көн саен була торган әлеге бәхәсләрдән котыла алмады. Җитмәсә, Рушаннан калганнар һәммәсе дә коммунистлар булып чыкты. Шуларның көнгә өч мәртәбә үз партияләрен ничек итеп әрләгәннәрен күрсәгез-ишетсәгез икән сез! Рушан берсендә түзмәде, сүзгә кушылды:

— Мин партия әгъзасы түгел,— диде.— Аңа мәхәббәтем-фәләнем дә юк, тормышыбызда партияне тиргәрлек җитәрлек җирлек булса да, мин аны каһәрләмим. Ләкин сезгә ачыктан-ачык әйтәсем килә: гомеремдә дә үз оешмасын сезнең кебек зәһәр күралмаучы кешеләрне очратканым булмады. Ни өчен соң сез, аны яратмыйча, аны мәсхәрәләгән хәлдә, һаман да партия әгъзасы булып торасыз? Ихтимал, сезнең берегез дә партия билетын тапшырмагандыр әле? Партия үзен күралмаучы, аның карашларын уртаклашмаучы кешеләрдән торганга күрә куркыныч та, миңа шулай тоела. Ул авыру партия, аны йә дәваларга, йә аңа тынычлап үләргә мөмкинлек бирергә кирәк...

Бу кайнар нотыгыннан соң Рушанга икенче өстәлгә күчеп утырырга туры килде.

> ...Ике иякле ленинчылар,
> үлгәч тә кушылмам мин сезгә...

Кара әле, шагыйрьләр бу хакта да язганнар икән шул инде.

## XXXIII

Совет дәүләтенә нигез салучы юлбашчының һәйкәлләрен илнең төрле почмакларында ваткан-җимергән көннәрдә, Рушан Ленинның тууына йөз ел тулу уңаеннан булган бер вакыйганы исенә төшерде. Көнбатыш Украинада ничек итеп юлбашчының мәһабәт һәйкәлен кыйратканнарын телевизордан карап утырганда хәтеренә килгән иде ул вакыйга. Ә телевизор экранында коточкыч күренеш: муенына корыч элмәк кидерелгән таш Ленин, ә тирә-якта — куаныч, шатлык һәм... юлбашчыны яклап сүз әйтүче ник бер коммунист булсын!

Шул вакытта Рушан сәер бер халәт кичерде: әлбәттә, әлеге кыланмыш чеп-чи ясалма бернәрсә иде, ләкин шул ук вакытта күңел түрендә нindидер зур фаҗига эшләнгәнен тою хисе дә бар иде. Гадел, хак җәмгыять төзү мөмкинлегенә булган иман-ышанычның җимерелү фа-

җигасе иде бу. Шулай ук андый җәмгыятьне төзеп булмый микәнни? Янә вә янә юлбашчыларны бәреп төшереп, һәйкәлләрен шулай кыйратырга туры килерме? Менә шулай уйланып утырганда, Рушан моннан ун еллар элек булган вакыйганы исенә төшерде дә инде.

Мең тугыз йөз җитмешенче ел. Юбилей елы язы — Советлар дәүләтенә нигез салучы бөек юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленинның тууына 100 ел тула. Йөз ел — зур юбилей! Рушан эре бер төзү-монтаж идарәсендә эшли иде. Күрәсең, яшь булгангамы, аны профкомга сайлап куйдылар, сан булсын өчен генә эшләнгән гамәл иде бу, чөнки Рушан гел генә командировкаларда йөри иде. Менә шул чагында, юлбашчының юбилее алдыннан аңа җәмәгать эше йөкләделәр...

Профком җитәкчесе, бергә читтән торып укып йөргән курсташы Фарух Зарипов иде, Ташкент егете. Дасаев аңа коридорда очраклы гына килеп төртелде.

— Ә менә безгә кирәкле кеше үзе дә! Куян сунарчыга таба чаба, диләрме әле? — дип, шатлыклы тавыш белән сөйләнә-сөйләнә, бер читкә тартты аны Фарух.— Тыңла әле, Рушан, тресттан бик дәһшәтле телефонограмма бар: Ленинның туган көне хөрмәтенә күргәзмә агитация материаллары кирәк, диләр...

— Юк, мин ни яза, ни рәсем ясый белмим,— диде Рушан, профком рәисенең шатырдатып кысып тоткан кулыннан ычкынырга тырышып.

Фарух елмаеп куйды:

— Ә мин синнән андый корбаннар сорамыйм. Партком кирәкле адресын да бирде: бөтен республика өчен стендлар-күргәзмә такталар ясый торган үзәкләштерелгән оешма бар икән.

— Ә фирма себеркеләр бәйләмимме? — дип үчекләп алды Рушан.

— Син ничек дип уйлаган идең? Партия бер эшне дә үз агымына калдырмый,— дип җитди җавап бирде Фарух.— Анда зур чираттыр әле, әзергә бәзер бер без генә түгелдер, блатсыз гына эш пешмәс. Дөрес, мине ул остаханә директорының фамилиясе шатландырды: Гольданский. Хәтерлисеңме, ул элек «Регина» ресторанында Хәлил белән бер оркестрда барабаннар сугып утыра иде, син бит яшьлегеңдә шәһәрнең барлык джазменнары белән аралаша идең, Кашгар егетләрен дә беләсең. Менә шулар майтара икән анда эшне. Марик Гольданский, җир тетрәгәнче, Үзбәкстан урамында — синең дустың Нариман белән бер ишегалдында яшәгән бугай. Кыскасы, бөтен өмет синдә. Юбилейга бер атна калды, табып алып

кайт шул тактаны — беләсең бит, андый эшләр өчен таләп катгый. Шуны булдырып чыксаң, бурычның мөһимлеген истә тотып, үзеңә беренче чиратта диңгез буена юллама булыр...

Ничек баш тартмак кирәк? Марикны да күрәсе килә, «Регина» ресторанын, Хәлилне, Үзбәкстан урамындагы ишегалдын искә төшереп утырасы иде — шул ишегалдында атаклы футболчы Геннадий Красницкий да үскән бит әле...

Әлеге остаханә өлкә Офицерлар йорты каршындагы кайсыдыр ишегалдында булырга тиеш икән. Түр ишекләре мәрмәр баганалы, зиннәтле заллары, салоннары, рестораны булган бу мәһабәт бина кайчандыр Төркестан Дворяннар җыеныныкы булып, анда еш кына кичләрен Николай Икенче галиҗәнапларының туганнан туганы, бөек кенәз Николай Константинович бильярд уйнарга йөргән, анда бик еш бал-кичәләр үткәрелгән, дәрәҗәле кунаклар кабул иткәннәр.

Рушанның яшьлек елларында өлкә Офицерлар йорты атаклы бакчасы, матур чәчәк клумбалары, галәмәт зур розарие, ачык һавадагы җәйге рестораны һәм бию мәйданчыгы белән дан тота, анда җитди, абруйлы халык җыела, якшәмбе көннәрендә оркестр уйный иде.

Элекке Дворяннар җыены йортында хәзер ни рәсемнәр галереясы, ни кайчандыр залларга, коридорларга, баскыч араларына күпләп тезеп куелган, сирәк очрый торган мәрмәр һәм бронза сыннар да күренми. Зал диварларын бизәп торучы гобелен келәмнәрнең уналтысыннан бары тик берәү генә сакланып калган, анысы да ике-өч җирдән тәмәке уты төшеп яндырылган. Аяныч күренеш, әлбәттә...

Мондагы бильярд залына революциягә кадәрле үк йөргән, күпне күргән бер карт сөйләгән иде: биредә гаҗәеп бай китапханә булган, кунаклар кабул иткәндә һәм бәйрәм көннәрендә өстәлләргә өч йөз кешелек фарфор һәм көмеш сервизлар — савыт-саба куела торган булган. Әмма хәзер юк тек юк инде, ярый әле, фоторәсемнәре сакланып калган. Шулай таланып, туздырылып беткән булса да, бу йорт илле елдан соң да сокланырлык иде әле, Рушан монда килергә ярата иде.

Остаханәгә барышлый ул, әле бер, әле икенче оешма һаман да җирен кишәрлекләп кисеп ала торгач, елдан-ел шигрин күн шикелле кечерәя барган бакча аша узды.

Ә бит элекке Дворяннар җыены йортының бу бакчасы Ташкентта атаклы бер рус ландшафт архитекторы, бакча-парклар белгече проекты буенча нигезләнгән бердәнбер бакча булгандыр — хәзерге ярлы тормышыбыз

андый сүзләрне дә, андый һөнәрләрне дә белми инде. Бернәрсәне дә рәтле-юньле төзи, иҗат итә белмәгән килеш, элгәрге буыннардан калган бай мирасыбызны, алгаартка карамыйча, вәхшиләрчә җимерә, юк итә барабыз — күңелсез хәл...

Җир тетрәүдән соң әлеге йортның роза түтәлләре каршысына ук килбәтсез бер галәмәт бина салып куйдылар — янәсе, милли ашлар ашханәсе. Урыны, әлбәттә, уңайлы: Алай базары янәшәдә генә, бер квартал аша — Революция скверы. Рушан, пыяла һәм бетоннан ясалган, теләсә кем кереп-чыгып йөри торган бу тартма ашханәгә карый да, мондагы элгәрге биек мәрмәр болдырларын таш арыслан саклап яткан ике катлы кызыл кирпеч йортны күз алдына китерә. Халык училищелары смотрителе яшәгән ул йортта гимназист Александр Керенский үскән, В.И.Ленинның йөзьеллыгын бәйрәм иткән көннәрдә ул карт Парижда мөһаҗирлектә соңгы көннәрен көтеп ята булыр хәзер. Элек Сталин урамы булган, аннары ташкентлылар буталып бетәрлек итеп, тагын берничә мәртәбә исемен алыштырган урамдагы, еллар үтү белән зур мәчегә охшап калган шул арысланлы йорт яныннан үткән саен Дасаев ничектер дулкынлана, элекке Дворяннар җыены йорты каршындагы кызыл кирпеч йортта үскән Керенскийның Бөек Октябрьгә катнашы булган шикелле, үзен дә шул чор тарихына катнашы бар кеше кебек тоя иде.

Рушан үзенә кирәкле остаханәне һәм Марикны эзләп йөргәндә, тагын шул ук ишегалларының берсендә кайчандыр шагыйрь Максимилиан Волошин да тукташтыргалаганын хәтереннән үткәрде. Рушан Дасаев Ташкентны ярата, аның тарихы белән кызыксына һәм аның күләгәле урамнарында йөргән, уңайлы-тыныч чәйханәләрендә утырган күренекле кешеләр турында шушы көнгә кадәр бер китап та булмавына гаҗәпләнә иде. Кыскасы, Марик Гольданскийга ул юлбашчының юбилее тарихи мөһим икәнлеген аңлап, әмма күңеленнән, кызыл кирпеч йортта үсеп, иленнән качарга, картлыгының соңгы көннәрен читтә үткәрергә мәҗбүр булган малайны — Керенскийны да кызгана-кызгана барды.

Бүлмә ишеге шар ачык, каралар түгелеп, тырналыпкыршылып беткән өстәл өстендә тәмәке төпчеге төтенләп ята, хуҗаның әле күптән түгел генә монда булганлыгы күренә, әмма хәзер генә Гольданский урынында юк иде. Остаханә үзе күптән юылмаган биек тәрәзәле иркен генә ике бүлмәгә урнашкан икән. Диварлары һәм түшәмнәренә

караганда, бу бинаның бер утыз еллап ремонт күрмәгәнлеге аңлашыла. Бүлмәләрнең ишекләрендә «Студия № 1», «Студия № 2» дигән язулары да бар. Ләкин ул бүлмәләрнең берсендә дә Марик юк иде.

Бүлмәләр рамнарга тарттырылып куелган киндерләр белән тулган — кайберләре инде грунтланган, калганнарын ашыга-ашыга грунтлап маташалар, кипкәннәренә исә оста гына итеп тиз-тиз квадрат шакмаклар сызалар, шунда ук рәссамнарга охшашлыклары бик аз булган ир-атлар ул шакмакларга буяу сала да баралар. Зал буйлап чабышып йөрүчеләрнең күбесенә рәсемнәрнең зур булмаган аерым өлешләрен: пинжәк, галстук, күлмәк ишеләрен генә буярга рөхсәт ителә, ә юлбашчының шул пинжәкләренә тоташкан башын, шулай ук квадрат шакмакларга бүлгәләп, бердәй пычранып беткән берет кигән дүрт рәссам ясый, аларның берсенең муенында хәтта күбәләк-галстук та бар иде. Зал буйлап әрле-бирле чабышып йөрүчеләр белән беретлы кешеләр арасында ниндидер каршылык бар иде, күрәсең, алар үзара сөйләшмиләр иде. Аеры-чөере ишетелгән сүзләреннән Рушан шуны аңлап алды: юлбашчының костюмын буяучылар үзләренең күбрәк эшләгәнлекләрен исбатларга тырыша һәм түләве дә артыграк булуны таләп итә бугай.

Рушанга әйләнеп карауч да булмады — конвейер өзлексез үз эшен эшли бирде, шунлыктан Рушан тәмәке тартып алырга җыенган күбәләк галстуклы остага мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булды, бу гамәлгә калганнары өнәмичә генә караштырып алдылар. «Марк Натанович кайда?» дигән сорауга оста аның күрше тыкрыктагы «Михнәт» спорт залында икәнлеген әйтте, ул залны болар өч айга арендага алганнар икән.

«Михнәт» җәмгыятенең спорт залын Рушан яхшы белә иде: Ташкентка килгән беренче елларында ул бокс буенча күнегүләрен яңартырга тырышып карады, әмма ничектер бер сәбәпсез рингка күңеле суынды, һәм ул бокс пирчәткәләрен чөйгә элеп куйды. Аркылыга өч волейбол мәйданчыгы иркен урнашырлык бу спорт залының көтмәгәндә генә ни өчен Гольданскийга кирәге чыкканын ул берничек тә аңлый алмады. Шау чәчәкле сирень куаклары котырып үскән ишегалдында яз хөкем сөрсә дә, чәчәк исләрен келәй исе басып киткән иде. Рушанның башыннан бер уй чагылып үтте: җир тетрәгәннән соң эзе дә калмаган «Регина» ресторанының атаклы оркестры барабанчысы Гольданский әллә соң берәр яңа төр келәй әзерләү цехы ачып җибәрдеме икән?

Рушанның спортзалда күренүе андагыларга да, үзенә дә шулкадәр көтелмәгән хәл булды ки, аны бары тик «Ревизор» спектакленең ахырындагы классик күренеш белән генә тиңләргә мөмкин иде. Һәрхәлдә, Рушанга югалып калырлык та бар иде: зур спортзалның бөтен мәйданын тутырып, ашык-пошык кына ясалган кузлаларга озын-озын идән такталары сузып салынган, алар галәмәт зур өстәл-конвейер хасил иткәннәр, шул өстәл тирәсендә башкаланың Рушанга таныш та, таныш булмаган да иң күренекле хатын-кызлары — гранд-дамалары әрле-бирле йөреп тора. Колакларында бриллиант алкалар, башларындагы чәчләре ул заманда «хала» дип йөртелгән, яхшылап өелгән биек прическалы, әле яңа гына модага кереп бара торган гаҗәеп кыйммәтле әкәмәт экстравагант итек-оеклар... Бу гүзәлләр матурлап буялган-маникюрланган, йөзекле-балдаклы нәфис бармакларын кызык кына тырпайтып, зур картон щитларга фоторәсемнәр ябыштыралар, ул картоннар биек булып ишек янында ук өелеп тора иде.

Рушан шәхсән бу гранд-дамаларның белсә дә бик азын белгәндер, алай да берничә таныш йөз күренә, ул аларны театр премьераларында, ешрак «Регина» ресторанында, сирәгрәк концертларда һәм ул заманнарда киң таралган шау-шулы зур туйларда очраткалый иде. Бер үк урыннарда очрашып йөргәнлектән, алар да, әлбәттә, аны таныдылар, аннары шәһәрдәге азмы-күпме зыялы һәрбер кеше балетмейстер Ибраһимны белә, ә Рушан һәркайда аның белән була иде. Ибраһимны белмәгәннәре чибәр Нариман аптекарьны белә булыр, аның шундый атаклы әйтеме дә бар: «Даруханә аша һәркем үтә». Аның белән дә Рушан төрле җирләргә бергәләп йөри иде.

Гольданский үзе залның түрендә, ишеккә аркасы белән басып тора иде, әмма янындагыларның йөзләрендәге үзгәрешне күреп, шунда ук нәрсәдер булганлыгын, көтелмәгән куркыныч янаганлыгын аңлап алды һәм кискен борылып карады. Ишек төбендә аптырашта калган Рушанны күргәч, хатын-кызларның ни өчен тәшвишкә төшүләрен аңлады һәм көлеп җибәрде, шуның белән киеренкелекне дә бетерде:

— Эшләгез, тыныч кына эшләгез,— диде.— Бу ОБХСС-тан түгел, хәтта фининспектор да түгел, минем дустым Рушан бу — Балерун белән Аптекарьның да иптәше...

Дасаев янына килеп, ул аны иңеннән кочып алды да тиз генә ишегалдына алып чыгып китте.

— Бу гөлбакчаны ничек җыя алдың син? — дип шаяртып сорады Рушан.

— Вакытлыча, вакытлыча... Теләсә кемгә шундый зур акчалар тарата алмыйм бит инде мин, моны Ташкентта беркем дә аңламас иде. Ә сине нинди җилләр ташлады? Кассиус Клейны рингка чакырырга җыенасыңмы, әллә минем бу залны арендага алганны белеп килдеңме?

— Мин сиңа йомыш белән, Марик... Коткар. Сине юлбашчының туган көненә йөз ел тулу уңаеннан ясала торган күргәзмә агитация материалларының республика күләмендәге монополисты, диләр... Безнең конторага өстән телеграмма килеп төште: табарга, элеп куярга, урнаштырырга...

— Афәрин, егетләр! Шәп эшлиләр,— дип җанланып көлеп җибәрде Марик. Күрәсең, ул шәһәр яки район комитетының идеология бүлегендә эшләүче берәрсен күз алдында тоткандыр.— Бары тик бик зур блат белән генә, иске дус итеп кенә. Анда да акчасын чек кенәгәсе аша түләсәң генә, безгә аны алуы җиңел булсын өчен, дим.— Марик ачыктан-ачык әйтеп бирде шул.

— Чек тек чек, парторгка әйтермен, ул бухгалтерияне мәҗбүр итәр. Син соң хет күрсәт инде, без нәрсә өчен акча чыгарып салырга тиеш булабыз?..

Гольданский өстәлләргә картон таратып йөрүче үсмер малайны чакырып алды да әзер продукцияне китерергә кушты.

Берничә минуттан стенд Рушанның күз алдында иде инде. Аның «Ленин — безнең юлбашчыбыз һәм остазыбыз» дигән баш сүзләре юбилей уңае белән менә дигән шома ак кәгазьгә басылган ун тиенлек плакаттан кисеп алынган. Астарак ваграк хәрефләр белән, шулай ук плакаттан, әмма башкасыннан алынган язу: «В.И.Ленинның тууына 100 ел тулу уңаеннан». Бу плакатларның әле ачылмаган рулоннары өстәл-конвейерларда тау-тау өелеп ята иде.

Стендның сул ягын юлбашчының атаклы рәссам Андреев ясаган, чынлап та, бик әйбәт портреты бизи, ул алтынсу-саргылт төстә, әмма монысы да яхшы ак картонга миллионлаган тиражлар белән басылган һәм гел юк кына бәя торган изопродукция. Бу портретларның өеме дә плакат рулоннары белән янәшә куелган иде. Ике квадрат метрлы стендның калган өлешенә күпсанлы фоторәсемнәр ябыштырылган. Аларны җентекләбрәк карап чыгу өчен, Рушан иелә төште.

Ленин бала вакытында, Ленин әнисе тезендә утыра, Ленин абый-сеңелләре белән, Ленин — гимназист, Ленин террорист абыйсы Александр белән, мәктәп медале һәм мактау кәгазьләре, Ленин — студент, Ленин эмиграция-

дә, Ленин велосипедта йөри, Ленин шалашта, Разливтагы шалаш үзе, Ленин броневикта, Ленин ниндидер крестьяннар белән, Ленин Луначарский белән, Ленин Крупская белән, Ленин Горкида коляскада, Ленин табутта...

Фоторәсемнәр бик начар сыйфатлы, Ленинны юньләп танып та булмый, бигрәк тә кышкы киемнән ул кысык күзле юлбасарга охшаган, аның белән рәсемгә төшкән башка кешеләр турында сөйләп тә торасы юк иде.

— Начар фоторәсемнәр, юбилей көнендә табутта яткан Ленин да кирәкмәстер,— диде Рушан, Гольданскийның иҗат җимешен карап бетергәннән соң.

— Ә мин әйбәт дип әйтмим дә. Кызганыч, дәүләтебез яхшы фоторәсемнәр буклеты бастырырга уйлап җиткермәгән, без шуларны ябыштырган да булыр идек. Борчылма, Рушан, бәхәсләшә алам — аларны синең кебек җентекләп беркем дә карап тормаячак, табутына да игътибар итмәячәкләр. Табут мәсьәләсендә син хаклы, әлбәттә, уйлап бетермәгәнмен...— Марик сүзен бүлеп, ачык ишек ягына кычкырды: — «Ленин табутта»ны тиз генә алыгыз, «Ленин Шәрык хатын-кызлары арасында»ны куегыз. Шулай иткәндә сәясирәк тә, урынлырак та булыр.

Марик, Рушанга борылып, бүленгән сүзен дәвам иттерде:

— Бер әрҗә коньякка бәхәсләшә алам: үземнең бала чагымда чүлмәктә утырган фоторәсememне куйсам да — кем дә булса игътибар итәрме икән? — Аннан кинәт кенә күчешсез-нисез сорап куйды: — Майлы буяу белән ясалган зур портретын телисеңме, нибары мең сумга, дуслык хакына гына?

— Шакмакларга сызып эшләнгәненме? — дип көлемсерәде Рушан.

— Шакмаклымы, әллә буйлымы — анысы әһәмиятле түгел. Кемне ясаулары һәм һәр кабинетта кем эленеп торуы мөһим. Кипренский, Рокотов яки безгә ят ниндидер Гейнсборо ясаган рәсемнәр түгел ич, Айвазовский, Куинджи пейзажлары да түгел. Үзебезнеке! Син, кадерлем, сәяси өлгермәгән икәнсең әле, мөгаен, шуңа күрә прорабльикта төртелеп калгансыңдыр да.

— Бу галәмәт эштер-өштер иттерүне үзең уйлап таптыңмы? — дип, турыдан-туры сорады Дасаев. Әйтергә кирәк, аны Гольданскийның колачлы «предприятиесе» таң калдырган иде. Аптырабрак өстәп әйтте: — Идеология шушылай юмарт ашатырга мөмкиндер, дип уйламаган идем...

— Бары тик идеология, бары тик партия генә туйганчы ашата да инде, мыегыңа чорнап куй, иптәш прораб...

Гольданский канәгатьлек белән кулларын уып алды һәм, сабый балага аңлаткандай итеп, Рушанга аңлата башлады:

— Мондый зур чаралар йөз елга бер генә була. Мин аны озак көттем — ике ел алдан Ленинга багышланган символикаларны, плакатлар-рәсемнәрне күпләп сатып алып җыя башладым. Идеясе-фикере, уйлап табуы — минеке, ләкин боларны сезгә сатып алырга мәҗбүри таккан, бары тик Гольданскийдан гына алырга кирәклеген өйрәткән кешеләрсез бу идея сукыр бер тиен дә тормас иде. Хәзер төшендеңме инде, ни өчен шәһәрнең иң кәттә гүзәлләре миндә вакытлы эштә икәненә? Бер атнадан бу синекура* тәмамланачак, алар туган илебезнең иминлеге-муллыгы хакына «иҗтиһади» хезмәтләре өчен шундый сумманы кесәләренә салачаклар, кайсыдыр ки, мөгаен, премия вә артыгын эшләгән өчен өстәмә түләүләреңне дә кушып, синең ярты еллык хезмәт хакыңны каплап китәдер. Акыллы кешеләрнең акчаны ничек ясаганнарын төшендеңме инде?..

Дасаев төшенде: «Ленин табутта», «Ленин Шәрык хатын-кызлары белән» ише фоторәсемнәрне бер ай чамасы ябыштырып утырганнары өчен партноменклатураның хатыннары вә сөяркәләре Рушанның төшенә дә кермәгән ярты еллык хезмәт хакына бәрабәр акчаны кесәләренә матур гына салып куйганнар икән бит! Андый акчага, аларның мөмкинлекләре һәм танышлыклары белән, «Волга» автомобилен дә,— ул нибары 5600 сум тора иде,— шул чама ук бәягә өч бүлмәле кооператив квартир да, әле өстәп, өч бүлмәгә җитәрлек мебель-йорт җиһазлары да алырга була иде ул заманнарда.

Хәзер, менә-менә пенсиягә чыгам дип торганда, шымытыр байлыгы да булмаган Рушан кайбер аерым сөйләшүләрне, сирәк-мирәк укылган мәкалә-фәләннәрне исенә төшерә. Алар һәммәсе дә ничектер юлбашчының шул юбилее белән дә, бүген Ильичның һәйкәлләрен җимереп кенә түгел, социализмның барлык билгеләрен, шул исәптән бронзадан һәм металлдан коелган, гранитка һәм мәрмәргә уелган «Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!» дигән лозунг-шигарен дә вәхшиләрчә кырып-себереп, коммунизм идеяләрен бар дөньяда кире кагуга бәйләнгән булып чыга. Рушан, үз тормышының-яшәешенең төп өлеше хезмәт белән, төзелеш белән бәйле

* Синекура — күп хезмәт куюны сорамый һәм яхшы түләнә торган вазифа. *(Тәрҗемәче искәрмәсе.)*

чагында, андый вак-төяк вакыйгалар, аеры-чөере күренешләр көнделекдә эз калдырмый узган икәнлеген аңлый, ә менә хәзер, кара әле син, ул җепнең очы шул заманнардан ук сузылып килә икән ич...

Рушан кайдандыр укыган иде: Фридрих Энгельсның әнисе,— югары зәвыклы, тирән белемле, бай һәм данлыклы гаиләдә тәрбияләнеп үскән ханым,— марксизм белән мавыгып киткән һәм Карл Маркска финанс ярдәме күрсәтеп торган улына үзенең бер хатында, аналарча йомшак кына, хәтер калдырмаслык кына итеп яза: *«Фред, сөйкемлем, миңа син кирәкмәгән нәрсә белән шөгыльләнәсең шикелле тоела...»*

Карл Маркс үзенең «Капитал»ын эшләп утырганда, нәширеннән янаулы хат ала: *«Хөрмәтле Маркс әфәнде! Әгәр дә Сез килешенгән вакытка «Капитал» дигән хезмәтегезне китереп җиткермәсәгез, без аны язарга башка авторга заказ бирәчәкбез...»*

Ә Бисмарк, кирпеч калынлыгындагы фундаменталь «Капитал»ны укып чыккач, титул битенә язып куйган: «Кешелек бу бухгалтер белән изаланачак әле...»

Кызганыч, бөек юлбашчы һәм фикер ияләренең экспериментлы уйлап табылган җирендә тормышка ашырыла башламаган, ә Россиягә килеп төртелгән. Коммунизм идеясе Европада, башкалаларның уңайлы-тын кафеларында, кунакханәләрнең, китапханәләрнең бүлмә-залларында туган, ә ул «ботканы ашарга» хәзергә хәтле башка халыкларга туры килә.

Бәлки, кайчан булса да, ул сер дә чишелер: ни өчен андый тәҗрибәне Россиядә үткәрергә булдылар икән? Бәлки, халкы һәрвакыт беренчелекне яраткангадыр, гаделлеккә һәм тигезлеккә сусау көчле булгангадыр? Россиядә яшәүче халыкларның күпчелеге урыслар тарафыннан яулап-басып алынган, ничәмә-ничә гасырлар изелеп-җәберләнеп килгән халыклар бит. Гаделлек-тигезлеккә алар сусамый кем сусасын тагын?

Коммунистларның үзара идеологик бәхәсләре аркасында Рушанга икенче өстәлгә күчеп утырырга туры килгән санаторийда тагын бер вакыйга булган иде.

Рушан анда бик тәкәббер бер карчыкка игътибар итте. Карчык үзен ачу китерерлек дорфа тота, теләсә нинди бәхәсләргә ярсып катнашып китә иде. Күршеләре Горбачевны ачыктан-ачык яманласалар, үзгәртеп коруны тиргәсәләр — әбекәй риза, ул бөтен бәлаләрне хәбәрдарлык һәм демократиядән күрә, шуларны пыр туздыра. Ә инде Горбачевны яклаучылар булса — бетте! Түзеп кенә тор әбекәйнең әче теленә!

Рушан үзен дәвалаучы табибтан кызыксынып: «Ни өчен карчык бернинди үзгәрешләрне дә кабул итми икән?» — дип сорады.

Бөтенесе дә бик гади булып чыкты: баксаң, әбекәй сынчы-скульптор икән, гомере буе Ленинны ясаган, юлбашчының бюстларын аннан да оста коючы булмаган икән, кепкалысынмы, яланбашлысынмы, бүлмә өстәленә куярлык кечкенәләренме, мәйданнарны бизәрлек мәһабәтләренме — һәммәсен дә коеп кына куя торган булган икән. Юлбашчының кибетләрдәге канцтоварлар бүлекләрен тутырып утыручы бронзадан, гипстан, чуеннан, мәрмәрдән эшләнгән кечкенә генә кулсыз статуэткалары да әлеге карчыкның иҗат җимеше икән, дип шаяртталар иде ял итүчеләр. Ничәмә-ничә еллар бу әбекәй һәртөрле күргәзмәләрдә һәм вернисажларда призлар вә медальләр алып килгән һәм кинәт, көннәрдән бер көнне, барысы да юкка чыксын әле — спецзаказлар, спецмашиналар, спецфәләннәр... Үзгәртеп коруга ярсып ташланмый хәлең дә юк. Сызгырырсың, кодагый!

Күптән түгел генә Рушан өлкә Офицерлар йорты яныннан узган иде — акшарлары кубып-кубып төшкән диварлар, күптән буявы яңартылмаган авыр бронза тоткалы ишекләр, ул тоткалар кайчандыр Дворяннар җыены йортына килеп, кичләрен бильярд уйнарга яраткан бөек кенәзнең кул җылысын да саклыйлардыр кебек әле...

Рушанның күңелендә юлбашчының портретын, шакмакларга сызып, меңсумга ясап бирә торган остаханә калкып чыкты. Социалистик дәүләткә нигез салучы Ленинның грандиоз юбилеена Ташкентның кәттә хатынкызлары «иҗтиһади хезмәт» куеп, мәш килеп «акча сугып» яткан «Михнәт» спорт залы исенә төште.

Болар берсе дә хәзер юк, гаип булды, эреп бетте, онытылды. «Су күмгәндәй, вакыт күмде һәммәсен дә...» — Монысын да кайсыдыр шагыйрь әйтеп калдырган.

Моннан утыз еллар элек бу хәлләр булган урында хәзер Үзбәкстан энергетика министрлыгының мәһабәт бинасы күккә үрләгән, Ташкентта Марк Натанович Гольданский да юк — ул күптәннән инде Нью-Йоркта яши, Брайтон-Бичтагы рус ресторанды (!) «Одесса» оркестрында уйный, «Регина» ресторанындагы шикелле, яңадан бәрмә уен коралларына кайтып төшкән, барабан суга, имеш, дип сөйлиләр.

Ихтимал, кайчандыр балалар бакчаларыннан башлап һәр учреждениене мәҗбүри «ленинчылаштырырга» күрсәтмәләр биреп, дәһшәтле телеграммалар җибәреп, ә хатыннары һәм сөяркәләре Ленинның 100 еллыгыннан

файдаланып, «акча сугып» утырган түрәләр дә күптән үз кабинетларыннан башка җылы урыннарга очканнардыр яки шул ук кабинетларда, исемнәрен генә алмаштырып, утырып калганнардыр. Янә дә бер сызгырырсың, кодагый!

Теге «кәттә марҗаларның» берәрсен дә күргәне-очратканы юк Рушан, дөресен генә әйткәндә, үзе дә сирәк чыгып йөри, күбрәк кичләрен тәрәзә буенда уйланып уздыра ул: кая бара бу дөнья?..

## XXXIV

Үткән елларын һәм үзе белән аралашкан кешеләрнең язмышларын искә төшереп утырганда, Рушан кайвакыт гел дә әһәмиятсез булып тоелган хәлләргә барып юлыга, әмма ул хәлләр көтмәгәндә генә, кинәт алар буынының тормышында хәзер дә чагыла, һәммәсенә дә башкачарак карарга мәҗбүр итә.

Күптән түгел генә эшкә китешли, ул баскыч төбендә кемдер төшереп калдырган егерме тиенлек акча күрде. Акча ике бетон плитә арасындагы ярыкта, аны алыр өчен берәр чыбык-мазар кирәк, аның ише нәрсәләр чүпле-пычрак ишек төпләрендә аунап ята.

Күп квартирлы йорт ишек төбендә яткан шул егерме тиен көмеш мең тугыз йөз алтмыш беренче елгы акча реформасын искә төшерде. Берләшкән Милләтләр Оешмасының Генераль Ассамблеясында ботинкасы белән өстәл төеп, дөньяны таңга калдырган генсек Никита Сергеевич Хрущев, акча реформасының сәбәпләрен аңлатып, үзенең гадилеге белән трибунадан бик ышандырырлык дәлил китергән иде: «Һе, симерделәр, юлда бер тиен ятса — иелеп алучы юк. Ә менә хәзер, без аның бәясен ун тапкыр арттыргач, берәү дә узып китмәс...»

Башка бик күп нәрсәләрдә ялгышкан шикелле, бу юлы да ялгышты Никита Сергеевич. Бәясе ун тапкырга арткан егерме тиенлек тә күптән инде беркемне дә кызыктырмый — ә бит ул девальвациядән* соң утыз ел узды. Инде яңасы, тагын да явызрагы ишекне какты һәм, түргә узып, халык өстенә шундый көч белән килеп төште ки, тын алырлык та хәл калмады.

Девальвация... Арзанаю... Акча арзанаю белән генә бетсә икән әле! Кая карама — девальвация... Хисләрдә,

---

*Девальвация — яңа акча кертү юлы белән яки кулланышта булган акчаның рәсми курсын төшерү, арзанайту юлы белән үткәрелә торган акча реформасы. *(Тәрҗемәче искәрмәсе.)*

мөнәсәбәтләрдә, бурыч тойгысында. Бер нәрсәнең дә бәһасе юк хәзер — кеше язмышларының да, тормышның үзенең дә.

Узган гомеренә нәтиҗә ясап, Рушан тагын шуны күрде: соңгы елларда аның аралашып йөри торган даирәсе-мохите бик нык тарайган икән бит. Билгеле, биредә яшь үткән саен була торган югалтулар да бар, телисеңметеләмисеңме, бер йодрык булып укмашкан төркемнәр таркала, дуслар каядыр югалып бетә, нәкъ атаклы шигъри юллардагыча: «Берәүләр юк инде, ә берләре ерак…»

Профком рәисе Рушанны, дөнья пролетариаты юлбашчысының юбилеена стенд табып кайтырга, дип, Марик Гольданскийга җибәргәндә әйткән иде: «Син яшьлегеңдә Кашгар егетләрен яхшы беләә идең, алар шунда эш майтарып яталар».

Кашгар Ташкентның атаклы яһүдләр төбәге иде, җир тетрәп ул гомерлеккә юкка чыкты. Кашгарда сатира театры артисты Роман Ткачук туып-үскән, кинорежиссер Юнгвальд Хилькевич та, Ленинград шагыйре һәм актер Владимир Рецептер да, Роксана Бабаян да шуннан иделәр. Кашгар илдә танылган күп кенә спортчыларны, ни өчендер боксчыларны гына үстергән: Иосиф Будманны, ул хәзер Нью-Йоркта яши, Володя Огороновны, хәзер рингта рефери вазифаларын үтәүче Тимер Гулямовны. Мюнхен Олимпиадасында Абу Нидаль террорчылары тарафыннан үтерелгән Илья Люксембург та Кашгардан иде. Кашгарның үз Мишка Япончигы — Фима Боднеры, хәтта үз Мюллеры бар иде — актер Леонид Броневой да тумышы белән Кашгардан бит. Теләгәндә, бу исемлекне чиксез сузарга да була…

Кашгар Ташкент өчен Одессаның молдаванкасы кебегрәк урын иде. Әйтергә кирәк, шәрыкныкымы, гарәпнекеме, әллә Кавказныкымы — мәсәлән, Баку яки Тифлис — көчле яһүд катламы булган шәһәрләр, андый диаспора булудан ота гына, аннан һәрвакыт рухи һәм эшлекле тормышның куәтле агымнары бөркелеп тора.

Әйе, Рушан андагы егетләрне яхшы белә, ә аның җеп очы Үзбәкстан урамындагы колонкадан аккан суы мәңге кипмәс ишегалдыннан башланган булгандыр. Шунда, Гольданскийларга күрше булып, аның аптекарь дусты, чибәр Нариман яши иде. Бүген, барлык халыкларның да милли хисләре көтмәгәндә генә кабынып китеп, бер-берләренә урынлы да, урынсыз да дәгъвалар белдерә башлаган заманда, Рушанның яшьлегендә исә паспорттагы бишенче графа — «милләт» графасы ташкентлылар тормышында бернинди дә әһәмиятле роль уйнамага-

нын, кешеләрнең бөтенләй башка сыйфатлар буенча дуслашу-аралашуын, якынаюын күз алдына китерүе дә кыен.

Менә алар өчлеген генә алыйк: Ибраһим — балалар йортында үскән Коканд үзбәге, Нариман — бакулы, Рушан үзе Оренбург татары, тумышы белән Көнбатыш Казакъстаннан.

Кемгә генә төртмә, алар янында уралучылар да шундый иде. Шәһәрдә мәгълүм бертуган Рожковлар — Славик белән Гера — урыс фамилияле булсалар да, чынлыкта нинди милләттән икәнлекләрен үзләре дә белми, рок-н-роллны искиткеч оста биюче Юра Толстой — урыс, Ваган Адамян, Урта Азиядәге бик күп әрмәннәр шикелле, тамырлары белән Карабахтан булса да, үзе ташкентлы әрмән. «Регина»ның атаклы саксофончысы Хәлил — үзбәк, «Пахтакор» футбол командасының легендар һөҗүмчесе Берадор Абдураимов (Абдерәхимов) Григорий Федотов исемендәге бомбардирлар клубындагы бердәнбер үзбәк... Бүген аның белән янәшә һәрвакыт сөйкемле, бик җанлы йөзле һәм акыллы карашлы Тайванец кушаматлы үсмер искә төшә. Ул малай футболны шулкадәр ярата, Берадорны Алла урынына күреп, аңа шулкадәр табына иде ки, Абдураимовны Мәскәү «Спартагы»на чакырып алгач, ул аңа ияреп китеп барган иде. Рушан аны үсеп егет булгач бер генә күреп калса да, искә төшүе юкка түгел иде.

1971 елның кара көзенә ике футбол клубы — Мәскәүнең «Динамо» һәм ЦСКА командалары ил чемпионатында очколар саны буенча тигез булып чыкты. Алар арасында өстәмә уен булырга тиеш иде һәм бу командалар очрашу урыны итеп Ташкентны сайлап алдылар, аларга кадәр Мәскәү «Торпедо»сы белән Тбилиси «Динамо»сы да шулай эшләгән иде.

Уен гаҗәп зур, күрелмәгән ажиотаж, шау-шу тудырып, «Пахтакор» стадионы камалышта булды. Ләкин Рушан, уенны карарга эләкте генә түгел, ә, гадәттә, командаларның икенче алмаш — дубль составы һәм команданы озатып йөрүче күпсанлы кемсәләр генә кертелә торган матбугат ложасына үтеп керә алды. Ул вакытта Берадор Абдураимов ЦСКАда уйный, ә үсеп җиткән Тайванец шул клубның ниндидер хуҗалык эшләрен башкаручы вазифасына билгеләнгән иде инде. Ничектер шулай килеп чыкты, Рушан ложада Алик Тайванец белән янәшә утырды.

Уен армиячеләр өчен уңышсыз башланды: тәнәфескә алар инде 0:2 исәбенә оттыралар иде, мондый дәрәҗәдәге

уен өчен нокаутка тиң исәп. Матбугат ложасында «Динамо» өчен янучы-көючеләр дә бар — алар командага ияреп, шәһәрдән шәһәргә күчеп йөрүче, поезд тәрәзәләрен кырып төшерүче яшь фанатлар түгел, билгеле, ә җитди һәм хәлле-бай меценатлар иде, андыйлар хәзер бөтенләй юкка чыкты. Тайванецны белгән бу кемсәләр, «Динамо»ның җиңүе хөрмәтенә «Ташкент» ресторанына банкетка алдан ук заказ биреп куйганнар икән. Алар Аликны «кыздырырга» керештеләр. Уен барышыннан күзен ала алмаган Алик аларга ул елларда акылдан язарлык суммага — ун мең сумга пари-бәхәс тәкъдим итте: ЦСКА җиңәчәк, диде. «Динамо»га табынучылар аңа шунда ук банк кәгазе дә ертылмаган йөзлекләрдән торган бер төргәк акча суздылар. Алик, эчке күкрәк кесәсеннән шундый ук төргәк акча алып, икесен дә Рушанга тапшырды — йоласы шундый, акча битараф кеше кулында булырга тиеш. Шуннан соң ложадагыларның уенны нинди кызыксыну һәм дулкынлану белән карап утыруларын күз алдына китерергә мөмкиндер!

Төп вакыт эчендә армиячеләр исәпне тигезләделәр: 2:2. Өстәмә тайм алдыннан, Тайванец маңгаена бәреп чыккан тирләрен сөртеп, әйтеп куйды: «Ну, хәзер безнекеләр егып салачаклар...»

Шулай булды да! Бу финал уенының герое элекке легендар бомбардир Григорий Федотовның улы Владимир Федотов иде. Ул хәлиткеч ике тупны кертеп, үзенең тормышында иң яхшы уенын уйнады, ә бит бу сезон аның футбол карьерасында соңгысы иде инде.

Рушанның хәтерендә Тайванец менә шундый комарлы футбол белгече булып сакланып калган да. Әмма аның искә төшүе футбол уены яратканы өчен генә түгел һәм хәтта пари-бәхәс аркасында гына да түгел.

Шактый вакытлар үткәч, Рушан аның Мәскәүдә атаклы итальян мафиозие дон Карлеоне шикеллерәк «абруйлы» кеше булып танылуын, башкаланы үз кулында тотуын һәм ташкентлыларга ярдәм итүдән бервакытта да баш тартмавын ишетте. Бервакыт «Лотос»ка кергәч, Аликның бер кичтә, кәрт уйнап, бер миллион сум отканын да әйттеләр. Әле менә күптән түгел генә, үзгәртеп коруның кызган — әллә котырынганмы? — бер чорында «Правда» газетыннан укыды: безнең ил мафиясе киң фронт белән халыкара аренага чыккан һәм Көнбатышта шактый йогынтысы бар икән. Мәкаләдә Тайванец исеме дә телгә алынган иде. Алик хәзер Германиядә, зиннәтле-бай виллада яши һәм Мюнхенның «Бавария» футбол командасына үлеп гашыйк, шуңа табына икән.

Шулай итеп, Дасаевка кирәкмәсә дә, тагын бер сер, футболны бик тә яратучы үсмер малайның сере ачылды.

Әйе, Кашгар егетләре футбол ярата иделәр. Шагыйрь әйтмешли: «Ил корабын җил өрә...» Әмма ул елларда җилләр безнең җилкәннәргә уңайрак иде шикелле, шуңа күрә футбол белән мавыгучылар да күп иде. Бу мавыгу, танылган спортчыларны шулай ярата белү — шул заманны аңларга, шул заман кешеләрен аңларга ачкыч түгелме?

Рушан тагын бер хәлиткеч финал уенын хәтерли, анысы Тбилиси «Динамо»сы белән Мәскәү «Торпедо»сы арасында булган иде. Андый шау-шуны, андый ажиотажны, шулкадәр кунакларны Ташкент аңа кадәр дә, аннан соң да күрмәде. Ихтимал, футбол сөючеләрне Грузиядән Үзбәкстанга көнгә дистәләрчә самолет яллап ташу,— моны «чартер рейсы» диләр,— илебез тарихында беренче тапкыр булгандыр, ике республика арасында хөкүмәт элемтәсе өзелеп тормады.

«Без шәһәрне грузиннарга өч көнгә бирдек»,— дип шаярттылар ташкентлылар. Һәркайда грузинча сөйләшүләр ишетелә, һәр җирдә аларның ул заманнарда бик тә модалы «аэродром» кепкалары шәйләнә. Шәһәр халкының үзенә ул көннәрдә ни бер ресторанга, ни бер кафега керергә мөмкинлек юк — һәммәсендә дә кунаклар кәеф-сафа кора, күңел ача иде.

Уен буласы көнне аэропортта хәлләр хәйран иде. Кайдан гына самолет очып килмәсен — Мәскәүдәнме, Киевтанмы, Бакуданмы, Ереваннанмы, Ростовтанмы, Минеральные Водыданмы, Симферопольдәнме, Адлерданмы — пассажирлар гел генә грузиннар булды: шулай урау юллар белән булса да, яраткан командаларының уенын карарга Ташкентка килгән иде алар. Андый уенга керү билетының нинди бәя торуын күз алдына китерүе кыен түгел иде, бигрәк тә футбол тирәсендә бихисап «коңгыз-кортлар» кайнашкан шәһәрдә...

«Пахтакор» стадионына тәпиләп барганда, ун минутлык арада булган «Ташкент» кунакханәсе янында, әле уен башланырга сәгатьтән артык вакыт булса да, инде сөйләп биргесез ыгы-зыгы башланган. Илнең төрле якларыннан җыелган репортерлар, фотохәбәрчеләр, тележурналистлар, дәрманчы-табынучылар, грузин футболын сөюче үзбәкстанлылар, Казакъстанның һәм Таҗикстанның якын-тирәдәге шәһәрләреннән килүчеләр, меңләгән грузиннар үзләренең кумирларын — иң яраткан футболчыларының кунакханәдән чыкканын көтеп торалар.

Ишекләрен киң итеп ачкан зур һәм матур «Икарус» автобусы да мәйданда иде инде. Көтеп торучыларны тагын да кыздыру ниятеннәндер, күрәсең, төп төркемнән шактый алданрак өч уенчы күренде, болар сакчы Гурам Петриашвили, Джемал Зейкеншвили һәм Гурам Цховребов иде. Хәзерге шикелле аунап-таушалып беткән спорт костюмнары кимәгәннәр, ә галстук таккан, чәчләрен әйбәтләп тараган егетләр иде алар.

Көяз-купшылар, үз-үзләренә ышаныч белән атлыйатлый, алар тәрәзәләренә пәрдә тартылган чия төсендәге автобус эченә тиз генә кереп югалдылар.

Рушан белән аның дуслары милиция чылбырлап алган тере коридор аша карап тора, менә-менә бөтен команда килеп чыгарга тиеш, шул чагында, милиция сафын кысыла-кысыла ерып, Володя Огоронов үтеп китте, әмма ул стадион ягына түгел, ә Нариманның даруханәсе ягына таба атлады.

Огоронов белән Будман күптән түгел генә бокс буенча СССР халыклары Спартакиадасында чемпион исеме яулаган, илнең җыелма командасына кертелгән һәм Ташкентта зур шөһрәт казанган иделәр. Мөгаен, аны таныганга күрә, милиция кордоны үткәреп җибәргәндер дә. Рушан янындагы кемдер, Ибраһим булды, ахрысы, аңа дәште:

— Володя, футболга бармыйсыңмыни?

Огоронов кунакханә алдындагы мәйданда туктап калды, таныш тавышка әйләнеп, беркатлы-самими генә итеп сорады:

— Ә кемнәр уйный бүген?

Җыелган халык шаркылдап көлеп җибәрде, шул вакытта кунакханә ишегеннән килеп чыккан грузин командасы бу көлүнең сәбәбен тәки аңлый алмый калды.

## XXXV

Хәзер инде Ташкентта Кашгар егетләреннән Рушанга танышлары аз калды. Язмыш җиле аларны дөнья буйлап таратты. Кайвакыт Дасаевның почта тартмасында, күршеләрнең күзен кыздырып, бик зиннәтле-матур открыткалар күренә, алар йә Тель-Авивтан, йә Хайфадан, йә Лондон белән Амстердамнан, Сан-Франциско белән Гамбургтан була. Дусларының илдән үз ирекләре белән һәм таза-тук тормыш кына эзләп китмәгәнлекләрен һәр күршегә аңлатып йөреп булмый. Кашгар егетләренең монда да майлы ипиләре бар иде. Кайберләренең чит илләрдә күптән инде үз виллалары, «мерседес» машина-

лары бар, әмма алар һаман да Кашгардагы уңайлыклары булмаган фатирларын, тәрәзә буендагы сирень куакларын, шау-шулы Алай базарын һәм үзләренең бәхетле көннәрен сагына. Балачак урамнарын бернәрсә дә алмаштыра алмый, сагынган минутларында аларның тамакларына төер утыра.

Яшьлегендә Рушан дуслашып йөргән Кашгар егетләре буыны шулай ук этисезлектән иза чикте, аларның да күпчелеге югары белемне Рушан шикелле читтән торып алды. Аларның төзелеш факультетындагы группалары интернационал булса да, өчтән бере яһүдләр иде, тагын өчтән бере — греклар белән немецлар, соңгыларына кереп укуны шактый кысканлыктан, аларга бердәнбер мөмкинлек читтән торып уку булды. Башка курс-факультетларда да чама белән шундыйрак нисбәт иде. Рушан укуын тәмамлап килгәндә, корея милләтеннән булган студентларның нык артуы күзгә ташлана — аларның күпчелеге теләсә кайсы инженерлык эшендә дә әһәмиятле анык аналитик фикерләүгә сәләтле кешеләр иде. Ни өчендер ул елларда Үзбәкстанның төп халкын төзүче-инженер һөнәре кызыксындырмый, алар күбрәк юридик, сәүдә, халык хуҗалыгы, автомобиль юллары төзелеше белгечлекләренә омтыла иделәр.

Рушанның яһүдләр, греклар, немецлар арасында дуслары күп булды, ул немецча аңлый һәм аңлаша да ала — Мартукта Вуккерт белән дуслыгы эзсез калмаган икән.

Соңгы елларда, үзгәртеп кору дигән нәмәрсәнең көткән өметләрне акламавы һәм тупикка барып төртелүе бәхәссез икәне күренгәч, милли мөнәсәбәтләр бик кискенләшеп китте. Рушанның күп кенә институтта укыган, Кашгардан аралашып йөргән танышлары һәм алар гына да түгел, башкалар да илне ташлап китә башлады.

Алтмышынчы елларда Ташкент бик нык үсә, һәркайда төзиләр һәм, дөресен әйтергә кирәк, барлык эре трест һәм идарәләрнең дә диярлек башлыклары яһүди инженерлар иде. Опера театрының гаҗәеп матур бинасын атаклы архитектор Щусев проекты буенча әсир японнар кулы белән Пикман күтәртте, театр алдындагы мәйданны төзетте, татар Булатов проекты буенча «Ташкент» кунакханәсен җиткерде. Сугыш башланыр алдыннан гына Ташкентның иң матур Нәвои урамы төзелә башлаган, ул төзелешне Крайзман җитәкләгән. Ташкентның су белән тәэмин ителеше бик камил уйланып эшләнгән, ә сугару системалары, заманча элемтә челтәрләре, республиканың металлургия һәм химия предприятиеләре төзелешләренә хезмәт күрсәтүче беренче «Спецмонтажстрой» тресты ба-

шында Горенштейн тора, атаклы «Ангреншахстрой»да — Терман, «Высотстрой»да — Каменецкий. Ә Рушан эшли башлаган беренче идарәне Марикның әтисе Гольданский оештырган. Бу исемлекне чиксез дәвам иттерергә булыр иде, әле бит тагын сәламәтлек саклау, югары белем бирү, авыр машина төзелеше кебек тармаклар да бар...

Рушан төзелеш мәйданнарында, планеркаларда очрашып-аралашып йөргән байтак кешеләрнең бик азы гына торып калды, күбесе китеп бетте шул. Аңа һаман да күңелсез хәбәрләр килеп ирешә — фәлән китеп барган, фәләннәр китәргә җыена, фәләннәр виза көтә... Әйтерсең кемдер аның тирә-юньдәге дусларын-танышларын чалгы белән чаба...

Америка илчелеге, башка илләрнең илчелекләре алдындагы озын-озын чиратларда — нигездә, яһүдләр белән әрмәннәр. Бик күңелсез, хафага төшерерлек күренеш иде бу. Рушан хәзер үзенә ни өчен? ни сәбәпле? кебек мәгънәсез сораулар бирми инде. Чөнки белә: яхшы тормыштан яки алда көткән рәхәтлекләрдән качмыйлар, берәү дә үз-үзенә, балаларына һәм оныкларына дошман түгел. Ул әлеге бөек таралуның төп сәбәпләрен аңларга гына тырыша. Сумгаитта әрмәннәрне үтерәләр — яһүдләр кача, Үзбәкстанда месхет төрекләрен үтерәләр — яһүдләр кача, элекке союздаш республикалардан күпләп урыслар китә — янә дә шул ук хәл: яһүдләр кача...

Рушан үзенең үткән тормышын кинотасма шикелле артка табан сүтә-сүтә дә, балачагына, сугыштан соңгы ярлы Мартукка барып төртелә...

Поселокта төрле милләт кешеләре җитәрлек иде, әмма яһүд гаиләсе берәү генә булды. Хәер, ул вакытта бишенче графа турында сүз дә юк, чөнки күпчелек халык сталинчыл билгеләмәгә туры килә — нацменнар. Рушан укытучы апаның, нindidер рәсми кәгазьләр тутырганда, һәр баланы бастырып, нинди милләттән икәнлеген сораштырганын хәтерли. Җавап: чечен, ингуш, татар, башкорт, немец, чуаш, мордва. Укытучы, дәфтәрдән башын күтәрми генә, кыскача гына раслап тора: «Димәк, нацмен»,— ди.

Аннан соң күп еллар үтте, хәзер Рушан ул кыскартылган кушма сүзнең мәгънәсен аңлый инде: нацмен — национальное меньшинство, ягъни милли азчылык. Сыйныфтан бары тик өч бала гына «нацмен» категориясенә керми калды — урыс, украин һәм казакъ. Калганнар балаларча беркатлы үзара мөнәсәбәтләрендә әнә шул көтелмәгән туганлыктан файдаланалар: «Син дә нацмен бит»,— дип кенә җибәрәләр. Сыйныфтагы

бердәнбер яһүд малае Лева Бернштейн да шул категориягә керә иде.

Үсә төшкәч, алар милләтнең ни-нәрсә икәнлеген аңлый башлаганнар иде инде, әмма аннан да элгәре үзләренең нинди диннән булуларына төшенделәр, чөнки чиркәүнең дә, мәчетнең дә авылда үз йогынтысы бар иде. Мартуктагы бик күпләр шикелле Рушан да сукыр Мәмлиева әбинең еш кына: «Әгәр дә чеченнәр безнең дин кардәшләребез булмасалар, кырык бишенче елның кышында туңып үлеп беткән булырлар иде»,— дип әйткәнен хәтерли.

Бәлки, әби-бабайларның тырыша-тырыша балаларга иман нуры иңдерүләре сабыйлар күңелендә якыныңа, тирә-юньдәге һәр җан иясенә рәхим-шәфкатьлелек булып шытып чыккандыр да әле.

Хәзер бар әшәкелеге белән өскә калыккан мәрхәмәтсезлек, әдәпсезлек, әхлаксызлык һәрвакытта да шундый иде, дип, Рушанны беркем дә ышандыра алмас. Әйе, алар, ул сыйфатлар да һәр заманда булган, әмма бу кадәр киң таралып, халыкның барлык катламнарына да үтеп кермәгән, хатын-кызларга исә бөтенләй диярлек кагылмаган. Ул вакытларда кемнән нәрсә көтәргә икәнен чамаларга мөмкин иде. Җәмгыять рәхим-шәфкатьлелек белән, берберсенә ярдәмчеллек белән яшәде, шулай итеп кенә сугыш елларында исән калды, сугыштан соң тернәкләнеп китте. Моның ачык мисалы — яһүд малае Лева иде.

Лева Бернштейн чибәр, күрекле егет булып үсте, ләкин үҗәт-кире, күкерт кебек кабынып китүчән, әгәр дә ачык кына әйтсәк — ызгыш-талашсыз яши алмый иде. Авыр тормыш җәмгыятьне дә кырыслыкта тәрбияли, Мартукта һәркем үзен-үзе яклый ала, шунлыктан тәкәббер Лева еш кына һәм бик урынлы кемнеңдер йодрыгын татымый калмый иде.

Аны кайчан да булса бер, бигрәк тә мәсьәлә кызларга кагылганда, үтергәнче кыйнап ташларлар иде инде, ләкин бик кызып сугышып киткәндә дә, кемдер:

— Җитәр, ул бит бездә бердәнбер яһүд,— дип әйтеп куяр иде.

Никадәр сәер тоелмасын, шул сүзләрдән соң сугыш туктала, «яһүд» сүзенә бернинди мәсхәрәле мәгънә дә салынмый, ә тиз һәм күп гашыйк булучан Лева моннан оста файдалана да иде бугай әле — әгәр җиңелә башласа, коткарачак сүзләр яңгыраячагын белә: «Ул бит бердәнбер...»

Техникумда Рушан белән бер группада Ефим Ульман укыды, алар хәтта бер бүлмәдә ике ел бергә яшәделәр дә.

Ефим детдом егете, үзенең кайдан икәнлеген, әти-әниләренең кемнәр булганлыгын белми иде. Аның укуы да шәптән түгел, уртачадан түбән һәм ул Рушаннар группасына курсыннан күчми калган укучы буларак килеп кушылды — детдомныкы булмаса, аны, мөгаен, техникумнан чыгарган да булырлар иде.

Ульманның ни өчен йомыкый, көтмәгәндә генә усалланып-ярсып китүчән, һавалы, үтә тәкәббер булганлыгын хәзер аңлый Рушан. Күрәсең, үзенә уку авыр бирелгәнне егет бик тирән кичерә торган булгандыр. Анысын да аңлап була: тимер юллар төзү аның күңеле тарткан эш түгел, күңеле аның башкага омтыла-ымсына иде. Ә балалар йортында, ихтимал, егеткә һөнәр биреп, киләчәк тормышында ышанычлы икмәге булсын дип тырышканнардыр: ул елларда тимерьюлчы иң отышлы һөнәр санала иде бит.

Тулай торакта гитара — гомер-гомердән беренче уен коралы. Рушаннар белән дә гитарада оста уйнаучы байтак кына егетләр яши иде. Ульман кинәт кенә гитарага чат ябышты, озакламый һәр компаниядә аның уйнавын үтенә башладылар, ул шундый чакларда бөтенләй үзгәреп китә иде.

Рушаннарга электротехника курсын Петербургтан килгән карт профессор Глузман укыды. Аларның гапгади шул техникумнарында укытучыларның төп өлешен исемле кешеләр, Казакъстанга сөрелгән профессорлар тәшкил итә иде.

Һәркем белән бик тәкәллефле сөйләшә торган Глузман, еш кына кәефсезләнеп, Ефимга:

— Ульман, мин сезне шулкадәр тинтәк булырсыз дип көтмәгән идем,— ди.

Бу сүзләрне беркем дә җитди итеп кабул итми, йөрәгенә якын алмый иде. Рушан хәзер генә аңлый, Ефимга никадәр рәнҗеш, кайгы-хәсрәт китергәндер карт профессорның әлеге сүзләре.

Бер укытучы гына түгел, группадаш иптәшләре дә кимен куймый. Кайчакларда, Ульманның югары математикадан яки сопроматтан берәр эше барып чыкмаса, егетләрдән кем дә булса берәрсе әйтеп ташлый:

— Ә җитмәсә, яһүд әле...— ди.

Ефим кызлар белән мөнәсәбәтләрендәге уңышсызлыкларын да бик авыр кичерә, юкса ул вакытта алар группасыннан кем дә булса мәхәббәт фронтындагы уңышлары белән мактана алыр идеме икән әле?

Дүртенче курста укыганда, язын, диплом алды практикасы башланыр алдыннан, Ефим поезд астына ташла-

ныргa итеп караган, әммa машинист уяу булган, егетнең нервлары соң минутта түзә алмаган — Ефим рельслар арасыннан сикереп чыккан.

Бер бүлмәдә яшәгәч, Рушан белән Ефимның бер-берләреннән яшерерлек әллә ни серләре юк, ул чорда һәркемнең тормышы уч төбендәгедәй күренеп тора, хәтта мунчага да төркем-төркем йөриләр иде. Ефимның үз-үзен үтерергә җыенуының сәбәпләрен берәү дә әйтә алмады. Әммa шул вакыйгадан соң һәр ике тулай торак — кызларныкы да, егетләрнеке дә — үзара сөйләшеп тормастан, аны шефлыкка алды, Ульманны вак-төяк өчен шаяртып үртәштерүдән дә туктадылар. Рушанга Мартуктан ук таныш: «Ул бит безнең бердәнбер...» — дигән тылсымлы сүзләр монда да үз эшен эшләде.

Рушан, ялга кайтып, джаз яратучы прокурор кабеленә беренче мәртәбә килгән елны очраклы гына белеп калды: Ефим тәки поезд астына ташланып һәлак булган, профессор Глузманга оныкь тиешле кызга гыйшык тоткан, тегесе моны яратмаган икән, дип сөйләделәр.

Инде утыз ел үткәч, курсташы Ефим Ульманны искә төшергәндә, Рушан ахыр чиктә үзе өчен яһүдләрнең ни өчен илне ташлап китүләренең сәбәпләрен ачыклады шикелле.

Яһүдләр ирексез яши алмый. Һәрнәрсә чикләнгән җәмгыятьтә үзләренә катгый билгеләнгән урын кысаларына сыешып яши алмый алар — бу очракта хакимият тә, партия дә көчсез, яһүдләр күңелләре ни тели, шуның белән генә шөгыльләнә ала.

Ефимның язмышы — моның ачык мисалы, аңа тимерьюлчының ышанычлы тук-имин тормышы кирәкмәгән булып чыкты. Аның, мөгаен, гитарада уйныйсы һәм Глузманның оныгын сөясе килгәндер... Күңеле кабул итмәгәнне яратырга, күңеле ятмаганны эшләргә теләмәгән ул, аңа мондый тормыш кирәкмәгән һәм шуның өчен ул үз тормышы белән хушлашкан да.

Яткан туфрагың мендәр булсын, Ефим! Профессор Глузманны һәм, сопромат белән машина детальләрен аңларга көчең җитмәгәндә, сине рәнҗеткәннәрне гафу кыл... Күңелеңнең андый белемнәргә ихтыяҗы булмаганга күрә, син аларны кабул да итә алмагансың, сине башка нәрсәләр ымсындыргандыр...

Нигезенә үзләре дә байтак чи кирпечләр салган яһүдләрнең СССРдан фаҗигале рәвештә күпләп китүләрен Рушан шулай гына, бары тик шулай гына аңлата ала.

Безнең бөтен тормышыбыз бер үк төрле стереотиплардан-калыплардан тора, мондый караш Рушанны по-

шаманга сала — дөньяны яңача корып, һәркемгә тигезгадел мөмкинлекләре булган җәмгыять төзергә, җәмгыять мәнфәгатьләрен шәхси мәнфәгатьләрдән өстен куя алучы, идея дигәндә, үзенең иң хәләленнән дә ваз кичә белүче яңа гармоник шәхес тәрбияләргә тырышып караганнарның бушка көчәнүләрен өйрәнгән очракта, менә кайда ул киләчәк философлар өчен бетмәс-төкәнмәс тема!

Шундый стереотип карашларның иң киң таралганы — яһүдләр үзләрен яклый алмый, аларны куркыту җиңел, дигән караштыр. Бу әкиятне үзләре шулай күрергә теләүчеләр генә сөйли.

1987 елны, үзгәртеп коруның иң кызган бер мәлендә, Ташкентның «Ереван» ресторaны янында үзенең кулдашы һәм тән сакчысы белән бергә Нарик Каграмянны атып үтерделәр. Ул шәһәрдәге кооператорларга гына түгел, көн саен диярлек зур ришвәтләр алып яшәүче дәүләт хезмәткәрләре һәм партноменклатурага да үз ясагын салган, чын-чынлап шәһәр хуҗасы булып алган иде. Һәркем ачулангандай кылана, Нарикны да, шәһәрдә нәрсәләр эшләнгәнен белмәмешкә салынган хакимиятне дә каһәрли, ләкин ясакны һәммәсе дә төгәл түләп килә. Бары тик яһүдләрнең генә түземе төкәнде, хакимият кешеләре, Нарикка күзләрен күтәреп карарга да курыккан бер заманда, яһүд егетләре әлеге дәһшәтлеявыз мафиозины халык күзалдында атып үтерде.

Хакимиятне үз кулларында тотучылар зурлыгы белән Рәшидовныкыннан аз гына калышырдай галәмәт җеназага җыелып килделәр. Әле бүгенгә кадәр көн дә чәчәк салынып тора торган Нарик һәйкәле кебек бер ун һәйкәл илдә табылырмы икән? Хакыйкый хак хакимият үзенең каһарманнарын зурлый, хөрмәт итә белә...

Мафиози Каграмянның үлеме Рушанның ирекле яһүдләр рухы турындагы фаразын тагын бер тапкыр раслады: оятсызлык, кабахәтлек дәрәҗәсе аларның абруен түбәнсетерлек чиккә җиткәч, яһүдләр, башкалар түзгән шикелле, түзеп тора алмады.

Халыклар аңында нык урнашкан тагын бер тотрыклы ялган стереотип караш бар: имештер, кавказлы милләт кешеләре, үзләренең шәхси абруйларын бик хөрмәт иткәнлектән, артык хисчән һәм күңелләре тиз яраланучан булганлыктан, иреклелекне гадәттән тыш зур бәһалиләр һәм кешене түбәнсетергә юл куймыйлар.

Әмма совет-партия режимы елларында кешенең абруе беркайда да Кавказдагы кебек оста мәсхәрәләнмәс һәм аяк астына салып тапталмас иде, түрәләргә тәлинкә тоту, ялагайлану анда шулкадәр мәгънәсезлекләргә,

көлкеле мәзәк хәлләргә барып җитә иде ки, Кавказ ул яктан караганда үзенең Гогольләрен һәм Салтыков-Щедриннарын көтә әле. Партия җитәкчеләренең андагы кебек үзбелдекклеләнеп дуамалланулары, башбаштаклыклары, кешедән көлүләре булса да тагын Урта Азиядә генә булгандыр. Ә бит, үзләренең җиңел яраланучан булуларына һәм нәзакәтлелекләренә карамастан, яшәгәннәр, түзгәннәр, түрәләрнең ботинка бауларына чаклы бәйли торган булганнар, кешенең абруен түбәнсетүче-мәсхәрәләүче феодал байларча мөнәсәбәтләрдән котылырга бигүк атлыгып та тормаганнар.

## XXXVI

Искә төшерергә теләгәннәрен хәтереннән үткәреп, заман, дуслары һәм сөйгәннәре, үзе һәм туганнары, әнисе һәм үги әтисе турындагы хатирәләрне әлеге дә баягы «мәңгелек гомер китабы»на теркәп калдырырга уйланып утырганда, Рушан таң кала: ничек итеп сәясәт һәрнәрсә өстеннән шулай идарә итә ала? Безнең бөтен тормышыбыз биләүдән үк диярлек ни өчен шулкадәр сәясиләштерелгән, идеология белән сугарылган? Ә бит ул үзенең язмаларында заманның исен һәм төсен, чәнечкеле шайтан таягы аралаш зәңгәр күзле күкбашлар чәчәк атып утырган, үлән арасындагы каен җиләкләре, юа-балтырганнары, кузгалагы-какылары белән балаларны куандырган басу-болыннарын, күбәләкләр, энә караклары, чикерткәләр, коңгызлар, тургайдан алып бөркеткә кадәр һәртөрле кошлар үз йорты иткән даланы сурәтләмәкче булган иде.

Ләкин хәтердә гел-гел генә якты, матур истәлекләр яңарып тормый шул. Әллә никадәр үлем-китем дә искә төшә.

Поезд астына ташланып, сукыр Мәмлиева әбинең оныгы Хәлил белән детдом баласы Ефим Ульман һәлак булды, самовар күмере өчен тарткалашып, берничә малай шулай ук үз үлемнәрен тимер юлда тапты. Үткәннәреннән якты сәхифәләр эзләп, Рушан күңеленнән елга, урман, далаларны айкый, яңадан Мартукка әйләнеп кайта.

Шулай да үги әтисенә «әти» дип әйтеп калырга өлгерде ул. Исмәгыйль абзыйның үлеменнән соң кайткан тагын бер вакытын исенә төшерде Рушан. Комбайнчы күршеләре соңгы еллардагы уңышлары өчен халык хуҗалыгы казанышларының Бөтенсоюз күргәзмәсендә бүләккә «Волга» машинасы алган икән, Рушанның Оренбургка барып кайтырга җыенганын белгәч, ул аңа, яңа

машинаны юлда сынап карау ниятеннән, машина белән барырга тәкъдим итте. Оренбургка барып җитмәсә дә,— анысының үз сәбәпләре бар иде,— бу юл Рушанның күңеленә озакка кереп калды.

Мартукның бер чите урман полосаларына барып чыга, шул полосалар буеннан Оренбургка илтә торган юл сузыла. Рушан мәктәпкә йөри башлагач утыртылган агачлар үсеп җитеп, хәзер чын урман булган иде инде. Билгеле, Себер киңлекләрендәге яки Белоруссиядәге ише карурман түгел, әмма далалы як өчен — чын урман. Рушанның яшьлегендә, урман әле менә-менә күтәрелеп килгәндә, анда әле җәнлек-җанварлар да, каргадыр, чыпчык-күкедер кебекләрдән башка кош-кортлар да юк иде. Ничектер мәктәптә: «Керпе күрдем»,— дип сөйләгән иде, аңа берәү дә ышанмады.

Ә хәзер куян-төлкеләр дә, бурсык-бүреләр дә, борындыклар һәм хәтта кабан дуңгызлары, пошилар да бар, дип сөйлиләр. Ә бит аларны беркем дә үрчетергә дип махсус җибәрмәгән — үзләре бар булганнар һәм вәссәлам! Табигать табышмагы...

Урман да түзеп булмаслык эсселектән әлсерәгән шикелле тоела иде. Юл читенә койма булып тезелешеп баскан агачлар иксез-чиксез казакъ далаларыннан искән коры челлә җилләрен тоткарлый, әмма үзләренең яфраклары кибеп-куырылып, шыштырдап тора. Хәтта кошлар тавышы да ишетелми — үле тынлык. Кечке салкынны, тереклекнең җанлануын көтүче тынлык. Рушан, машинасын урман авызында кинәт кенә туктатты да, агачлар арасына кереп китте, үләннәре тапталмаган, кечкенә генә чиста яшел алан табып, курткасын салып ташлады һәм шуның өстенә хәл алырга утырды.

Алда, ике-өч разъездга җитәрәк, шаулап килгән поезд тавышы ишетелде. Бу дөбердәп-шалтырап килгән состав түгел, ә иксез-чиксез киңлектә, гаҗәеп тынлыкта, артында дистәләрчә-йөзләрчә чакрымнар калдырып һәм алда да шулай булачагына ышанып, кешеләр далага таралып яшәгән яклардан чабып килүче поезд тавышы иде. Ул тавыш кечкенә авыл-фәләннәрдә яшәүчеләрнең йөрәкләренә үтеп керә, үзәкләрен өзә, чөнки аларның тормышка ашмаган яшерен хыяллары һәм кыюсыз өметләре шул юлга бәйләнгән, бу тавыш күңелләрдә тәгаен анык кына булмаган, әмманиндидер куанычлы үзгәрешләр көтү тойгысын уята.

Зеңләп торган урман тынлыгы, килгән-киткән поездларның әнә шул тигез һәм чиста тавышлары, бихисап агачларга бәрелеп, галәмәт бер органда ниндидер моңлы

көйгә әверелә сыман һәм ул Рушанны тагын сагышлы истәлекләргә алып китте: йомыкый балачагына, шәһәрдәге ышанычсыз, ярлы студентлык елларына кайтарды. Мартук шикелле вак-төяк авыл-поселоклардан килгән аның ише егетләрне, укып чыкканчы диярлек, «колхозник» дип кенә йөртәләр иде. Берәүләр бу сүзне төрле төсмерләрдәге мыскыллау рәвешендә әйтә, икенчеләре исә гадәтләнелгән буенча дип әйтик, болай гына ычкындыра, ләкин барыбер һәр ике очракта да күңел рәнҗи — «колхозник»...

Хәтерендә, беренче курсны тәмамлап кайткач, Рушан, кызарына-бүртенә, ничектер уңайсызланып һәм бик буташтырып, бу хакта үги әтисенә сөйләгән иде. Әмма Исмәгыйль абзый аңлап алды. Ул Рушанга текәлеп карап торды да, гадәттә ачуы килгәндә генә һәм риза булмагандагыча итеп, мыегын еш-еш сыпыргалап, тыныч кына әйтте:

— Монда, улым, сезгә беркем дә ярдәм итә алмастыр. Егет кешегә, чын егет кешегә берәү дә, бервакытта да мыскыл сүзе әйтмәс. Ә сез әле беркем дә түгел. Сез әле борын асты кипмәгән чебешләр генә...— диде. Аннары, бераз тынып торгач: — Кайда, кайчан тууың, нинди милләттән булуың тормышта бер өстенлек тә, ышаныч та бирми. Кеше үзендә булганны үзе тәрбияләп үстерергә тиеш, кеше җирдә эше-шөгыле белән генә танылып ала, менә шунда инде туган җире дә, туган елы да, хәтта милләте дә истә тотыла...— дип өстәде.

Шул чагында, әллә Исмәгыйль абзыйның ышанып, басым ясап әйткән сүзләреннән, әллә кабатлап сораган булып, «колхозник» сүзен әвәләвеннән Рушан югалып калды, үги әтисенең әйткәннәрен аңлаудан битәр оялды шикелле, чөнки «колхозник» сүзе аңа «Дасаев» булып ишетелде...

Урман тынлыгында озаклап утырып булмады — юл алга дәшә иде. Сагарчинны үтеп, Куандыкка якынлашкач, Оренбургның үзенә дә кул сузымы гына калганда, күпер күренде. Аны төзәтеп-ремонтлап азапланалар иде. Мөгаен, язгы ташкыннарда зыян килгән булгандыр. Дасаев машинасының тизлеген киметте. Ярымачык тәрәзәдән балачак елгасы Илекне хәтерләтеп, су исе бәреп керде. Рушан күпердән сак кына чыкты да ирексездән машинасын туктатты.

Алда, күз күреме җирдә, яшел ярлар арасыннан, елан шикелле бормаланып-сырмаланып, иртәнге тын елга агып ята иде. Сай урыннарда әкрен генә чылтырап, сирәк култыкларда кара-кучкылланып, бөтерелеп, сазлыклардагы

камышларны кыштырдата-кыштырдата, ашыкмый гына ага иде ул. Кайбер урыннарда су өстеннән ара-тирә, күзгә күренер-күренмәс иртәнге томан сызылып күтәрелә, ә тар урыннарында биек яр өстеннән салынып торган йөзьяшәр карама агачларының күләгәсе җемелдәп ялтырап яткан су өстен зонтик кебек каплап-караңгылап тора иде. Елганың тәбәнәк икенче як ярын куе таллык каплаган, таллардан ары болын башланып китә — күрәсең, язларын елга шул болыннарга киң булып ташып җәеләдер. Елганың һәр борылышын борыла-сарыла кабатлаган тугайлыклар еракларга сузыла, әмма Рушан аның аргы башын барыбер күрә иде.

Болынны күптән түгел генә чапканнар, анда да, монда да зур булмаган печән кибәннәре күренә, ә үлән яшелләнеп яңадан үсеп-күтәрелеп килә — елганың якынлыгы һәм юмартлыгы сизелә.

Тып-тын, бер кеше әсәре күренми, бары тик, Мартуктагы шикелле булып, ерактагы поезд тавышлары гына шәйләнә, ул тавышлар, уянып килгән иртәнге елга өстендә яңгырап, күңелдә матур, саф хатирәләрне уята.

Аста җәйрәп яткан болыннарга карап, Рушан бала чагында төнгелеккә ат сакларга барганнарын, тышаулы атларны, шаян колыннарны, атаклы чабышкыларның пошкыруларын һәм бияләрнең түземсез кешнәүләрен исенә төшерә, төнге учак ялкыннарын күрә шикелле иде. Тик, күрше казак станицалары һәм казакъ авыллары малайлары арасында үзен күрсә дә, тегеләрнең кем кайдан икәнен анык кына хәтерли алмый, чөнки болын барысы өчен дә уртак, кешеләргә тагын бер болын бүләк итәргә Илек суы артык кечкенә иде шул.

Юк, хәзерге транзистор-магнитофонлы малайларны төнге тынлыкта ат саклаган рәвештә күз алдына китерә алмый ул. Юкса станица һәм авылларда атлар әле дә бетеп җитмәгән, һәр язда, җәй башында казакъ һәм татар авылларында Сабантуйлары үткәрелә, көзләрен казак станицаларында уңыш бәйрәмендә ат чабышлары, ат өстендә кылыч айкап йөрү ярышлары уздырыла. Ул бәйрәмнәргә һәркайдан, хәтта шәһәрләрдән дә бихисап халык җыела иде. Ә ат өстендә нинди егетләр генә үзләренең осталыкларын күрсәтми, нинди егетләр генә егетләнми! Һәм алар һәммәсе дә төнге ат саклау мәктәбен үткән егетләр булыр иде.

Җир йөзендә атлар бетмәгәндә, төнге ат саклаулар да бетмәячәк, чөнки алар балачак, үсмерчакның иң матур, иң дулкынландыргыч чоры бит, димәк, җирдә асыл

егетләр дә бетмәячәк. Мөгаен, хәзер башка заман — башка төрле куна барулардыр... Мөгаен... мөгаен...

Рушан биек яр өстеннән агымсуга, иркен болыннарга озак карап торды, биредә хәтердә гел якты истәлекләр генә яңара, ул әле үткәненә әйләнеп кайта, әле киләчәгенә дә үрелеп карый шикелле иде. Шул сурәтләр күз алдында алмашынып тора. Менә ул күтәрелеп килгән яшь үлән арасында беленеп торган атлы печән чапкыч эзен күреп алды, карашы белән аны озата барып, болынга төшә торган юлны да шәйләде. Кузгалып, Оренбургка китәсе килми иде.

Карамалар үскән биек яр артында казак станицасы барлыгы сизелә иде. «Бүген якшәмбе, базар көне, әле җитешермендер, мөгаен»,— дип уйлап алды Рушан, үзенең шактый ачыкканлыгын тоеп. Ул, машинасын борып, авыл юлына чыкты да шул биек яр буйлап бара башлады, кайдадыр авылга борылып кергән юл булырга тиеш иде.

Бу казак станицасында Рушанның булганы бар, үги әтисе аны базарга бер генә алып килмәде, ә бервакыт Исмәгыйль абзый станица тегермәнендәге тузып беткән, иске «әгелчән» двигателен төзәткәндә, алар икәүләп юлаучылар йортында бер атна торган иделәр. Рушан ул чагында аңлый алмый интекте: болар һәммәсе дә, Мартуктагы күршеләр шикелле, урысча сөйләшәләр, бары тик яше-карты елтыр козыреклы кызыл кырпулы фуражка киеп йөри иде. Ә ни өчен «казаклар» дип аталалар — шайтаным белсенме? Әле тагын станица гел генә ап-ак акшарланган йортлары — казакча «хаталары», чия бакчалары белән истә калган, Мартуктагы кебек иске-җимерек ник бер генә йорт булсын!

Аннары үги әтисенең, тегермәндә эшен бетереп, Мартукка кайткач әйткән сүзләре хәтерендә, күрәсең, авылдашлары казакларның тормыш-көнкүреше турында сорашканда әйтелгәндер инде:

— Казакларда тәртип кырыс: урманны сакла, елганы сакла, болыннарны сакла — шуңа күрә алар әйбәт яшиләр,— дигән иде Исмәгыйль абзый.

Ул вакытта әле борын асты юеш малай елганы, урманны, болын-кырларны ни өчен сакларга кирәклеген аңламый иде. Алар бит гомер-гомердән булган, бар һәм булачак шикелле — ә кешенең монда нинди катнашы бар?

Бер ун минуттан барып кергән станица моннан утыз еллар элек булган казак станицасын хәтерләтми иде инде. Хәзер ул Мартукка охшап калган, вакыт дигәнең

үзенекен эшли шул, үзенә генә хас сыйфатлары югалып беткән диярлек. Анда-санда күренгән эленмә такталарга карап, Рушан станицаның хәзер райүзәк булганлыгын чамалады.

Кайчандыр, беркемнән дә сорап тормастан, ничек кирәк алай асфальт салынган, хәзер инде чокыр-чакырланып беткән тузанлы үзәк урамыннан, даңгыр-доңгыр дөбердәп узып, базарга барып чыкты ул. Әкренләп тарала башлаган, инде комарлыгы һәм җегәре беткән базар гына балачактагы станицаны бераз хәтерләткәндәй булды.

Базар коймасы буенда әле олаулы-тарантаслы, ачык арбалы атлар тора, хәтта пар ат җигелгән, чикылдашыпчинашкан ике-өч айлык дуңгыз балаларын сатып торучы ябык фургон да бар иде. Рушан машинасын төрле төсләр белән ялтыр-елтыр килеп торган «Жигули»лар рәтенә куйды да базар эченә кереп китәргә ашыкты. Әмма, ничек кенә ашыкмасын, дала аргамаклары кимереп бетергән борынгы араталар яныннан адымнарын әкренәйтмичә генә үтеп китә алмады. Тагын кайда һәм кайчан мондый урынны күрә аласың әле? Мөгаен, бүгенге балалар, хәзер автомобильләр һәм велосипедлар куярга махсус урыннар булган шикелле, элек аргамак атларны бәйләп куя торган урыннар да булганлыгын уйлап та карамый торганнардыр.

Араталарда үткән-сүткәннәргә куркынып караштыргалаган һәм нечкә аяклары белән борчулы-тынычсыз таптангалап торган бер унлап ат бар иде. Аларның икесенең сыртында зиннәтле, борынгы казак иярләре, бөтен дирбияләре каралтылган көмештән булганлыктан, алар бик тә авырдыр шикелле күренә, хәтта югары күтәртеп тарттырылган өзәңгеләренә кадәр көмешләнгән иде.

«Мондый атлар һәм аларны шулай тәрбияләп тоту бары тик атларны чынлап яраткан асыл казакларга гына хас, кызганыч, алар да бетеп бара шул инде...» — дип уйлап алды Рушан. Аның уйларын раслагандай, шулчак бер алмачуар ат янына кечкенәрәк буйлы, ябык бер карт якынлашты. Ат, хуҗасын танып, аңа ирене белән үрелде, бер урында таптанып-биеп алды, «мин сине көттем, юксындым» диюе булды бугай. Күзләре дымланып-җылынып киткән хуҗасы:

— Йә, йә, акыллым, тынычлан,— дип, атның аркасына җиңелчә генә сугып алды. Тавышына караганда, ул шактый өлкән яшьтә иде булса кирәк.

Кайбер төшләре тәмәке уты төшеп яндырылганмы, әллә булмаса, пулялар тишкәләгәнме, буш газырлы,— газыр дигәнең чикмән күкрәгендәге патроннар тезеп куя

торган кесә була инде,— яшь егет чагындагы чикмән-черкескасын кигән, фырт хром күн итекле һәм башына яңа казак фуражкасын егетләрчә кырын салган карт үзе дә әле әйбәт кенә күренә. Кинәт кенә ул атлар тирәсендә кайнашкан Рушанны үзенең карчыганыкыдай үткен күзләре белән күреп алды — аның бу сынаучан карашында яраткан аты өчен гомер-гомердән килгән курку хисе чагыла иде. Ул әйтерсең яшь егет чакларында ат карагы чегәнне бер ялгышусыз сизенгән кебек булды. Карт бу юлы да ялгышмады — Рушан нәкъ менә аның чаптары белән кызыксына иде.

— Ә, җәяүле татар икән,— диде карт, сүрелеп һәм йөзендәге борчылу хисен җуеп. Аннары үртәгән һәм шелтәләгән шикеллерәк итеп өстәде: — Кара, кара, соклан. Хәзер сездә мондый чибәркәйләр юк шул инде, хәзер татарлар да башка...— дип көрсенде. Бераз тынып торгач, тагын өстәде: — Казак та хәзер элеккеге түгел...

Картның тавышындагы ихлас пошаманлыкны аңлап алган ат, аның көтелмәгән сүзләрен бүлдерергә теләгәндәй, хуҗасына таба атлап куйды. Карт аның матур башыннан кочып алды, Рушанның бар икәнен дә онытып, сөеклесенең яраткан иреннәреннән үбә-үбә: «Терек... Терек, сөеклем...» — дип сөйләнергә тотынды, атның муенын сыйпаштыручы картларча нечкәреп калган кулында казак камчысы селкенгәләп тора иде.

Дасаев беренче мәртәбә фотоаппараты булмаганга һәм фотога төшерә белмәгәненә үкенеп куйды.

Базарда азык-төлек сата торган берәүдән ул куба ромыннан бушап калган тартма сорап алды. Базардагы тавыш, шау-шу, ыгы-зыгы, көлешү тавышлары, шаяртып, кычкырып сөйләшүләр аны әсәрендергән, базардагыча комарландырган иде. Ул тирә-ягындагы башка кешеләр кебек үк, күңелле шаярткалый-шаярткалый, тиз генә әллә никадәр ашамлык сатып алды. Сөт рәтләренә тукталып, бер банка өй катыгы эчеп куйды, бер кисәк атаклы казак брынзасы алды, шунда ук янәшәдән бер дистә йомырка өстәде. Инде беренче кыяр-помидорлар да чыккан икән, бәяләре «тешли» торгандыр, алучылар бик күренми, шунлыктан сатучы марҗалар Рушанга бик сөенде. Базардан чыгышлый, ул йомшак-җылы бербөтен ипине дә эләктерде. Авыл пекарняларына әле автоматлаштыру кереп җитмәгән, ипиләре өйдә пешергән күмәчтән берничек тә аерылып тормый иде.

Базар янындагы күперне исенә төшерүгә, Рушанның башында, кара уылдык һәм берәр кырпы балыгы сырты аласы иде, дигән яшерен өмет баш калкытты. Үги этисе

станица тегермәнендәге әлеге дә баягы двигательне төзәтеп йөргән заманнардан күңеленә уелып калган бер күренеш исенә төште, ул аны дусларына еш кына сөйләсә дә, аңа ышанучылар аз иде.

Исмәгыйль абзый, эшлисен эшләп бетереп, тегермәнне хутка җибәргәч һәм сынамактан беренче онны үзе тартып биргәч, тегермән хуҗасы,— станицада төшеп калганнардан түгел! — шунда ук тегермәндә сый-хөрмәт оештырырга булды. Станица халкының шатлыгына тегермән озак эшләсен, дип, бер тәкә суйдылар.

Тәкәне мөселманча суеп, тиресен тунаучы да Исмәгыйль абзый үзе булды. Мәҗлескә тегермәнче ниндидер хөрмәтле картларны һәм, рәсми исеме булмаса да, казаклар арасында абруйлы старостаны да чакырган иде. Менә шул тегермәндә Рушан беренче мәртәбә кара уылдык татып карады, аны кунаклар юкәдән эшләнгән тирән табаклардан зур агач кашыклар белән умырып-умырып ашадылар, башта Рушан ниндидер гомер күрмәгән иткә охшаткан симез, кызыл тәмле балык кисәкләре дә зурзур, калын-калын киселгән иде. Урдылар гына...

Барысы да үги әтисенең эшен мактады, шунда ук өстәл янында аңа тиешле бәясе дә түләнде. Тегермән ишегалдында аларны Мартуктан алып килгән җигүле пар ат тора һәм шуның белән үк илтеп куярга да җыеналар иде. Исмәгыйль абзый китәргә кузгалгач, тегермәнче аяклары бәйләнгән тәкәне күтәреп чыкты да:

— Монысы сиңа, оста, шәхсән үземнән,— дип, тәкәне яңа чабылган печән арасына иплəп салып та куйды.

Староста дигәннәре, ат тотучыга нәрсәдер пышылдап, серле елмаеп, аның янына менеп утырды да кузгалырга кушты. Кайдадыр авыл читендә тукталдылар, староста Исмәгыйль абзыйларны күзгә бәрелеп тормаган бер подвалга кереп чыгарга чакырды.

Ике катлы калын бүрәнәләр ябылган тәбәнәк озын подвалда караңгы иде, староста белән ат йөртүче шунда ук ике керосин фонаре кабызды. Подвалда боз булмаса да, боз салкынлыгы бар — күрәсең, ерак та түгел җир асты сулары үтә торган булгандыр.

Сүрән генә лампалар атлаган саен караңгылыкны куып яктыртып тора, шунда Рушан тимер ыргакларга эленгән, баштүбән сузылган үзе кадәр һәм әле үзеннән дә зуррак балыкларны күреп алды. Сүрән ут яктысы җиткән арада һәркайда — балык... балык... балык... Кырпы балыклары. Староста аларга кагылгалап, һәрберсен иснәштергәләп караган шикелле итеп узды. Үзенә ошаган берсе янында тукталып, күн итек кунычыннан

киң генә пычак суырып чыгарды да, җитез-оста хәрәкәтләр белән балыкның сыртыннан озын-озын калын өч кисәк телеп алды һәм аларны сүзсез-нисез генә Исмәгыйль абзыйга сузды. Аннары ул, ян диварга якынаеп, фонарен киң агач киштәгә куйды. Ике рәт итеп ясалган бу киштәләр караңгылыкка китеп югала, алар өстендә футбол тубы зурлыгындагы түгәрәк кара йомарлаклар ята иде. Ат йөртүче әллә кечкенәрәк агач чиләк, әллә мичкә сыманрак савыт бирде, староста кулындагы шул ук пычак белән бер кара түгәрәкне, йомарлам май кискән шикелле генә итеп, урталай ярып җибәрде дә, шул савытны тутырып салып та куйды, аны исе киткән Рушанга тоттырып:

— Бу сиңа, оста, җәмәгатьчелектән, казаклардан,— дип, үги әтисенә башын иде…

Ләкин бу юлы, Рушан никадәр генә эзләнмәсен — базарда ачыктан-ачык та, яшертен дә ни балык, ни уылдык сатучылар күренмәде. Ә бу якларда аларның бихисап булуын ул үз күзләре белән күргән иде бит. Менә хәзер, соңлап булса да, үги әтисенең сүзләре хәтеренә килде: елганы сакларга кирәк…

Кара уылдык эзләп йөри торгач, Рушан чегәннәргә барып юлыкты — юк, ат каракларына түгел, аларны хәзер казакларның соңгы атлары бик кызыксындырмыйдыр да инде. Чегәннәр әллә кайда еракташы әмеркәнски «Монтана» тамгасы тегелгән ялган, ясалма свитер һәм пуловерлар сатып йөриләр икән.

Рушанның сатып алган бөтен әйберләре теге тартмага сыеп бетте, ә ипи сатучы кыз аны, бик тиз генә итеп, клиндер бавы белән бәйләп тә бирде. Рушан ашыкмый гына, алган әйберләреннән һәм базардан канәгать булып, яңадан да теге ат бәйләү араталарыннан узып бара иде, анда башын түбән иеп торган бердәнбер ала-кола бияне генә күрде, тукталып тормыйча, машинасын куйган җиргә ашыкты. Үз машинасын түгәрәкләп урап алган кешеләрне ерактан ук күреп-абайлап борчылды: «Берәрсе чыгышлый бәрдереп уздымы икәнни»,— дип уйлап куйды.

Җыелган халыкны авырлык белән ырып-ерып үткәч, кулындагы тартманы машина капотына куйды да кесәсеннән ачкычларын чыгарды.

— Син хуҗамы? — дип, бер бик әсәренгән казак аны җиңеннән тартып туктатты һәм тыр-тыр сөйләп китте:
— Мин беренче, мин беренче алучы, мин иң алдан килдем…

Казакны бүлдерүче юк, әмма таза гына ике ир-ат, Дасаевның игътибарын үзләренә җәлеп итәргә теләп, теге

бәндәне сүзсез-нисез генә кысрыклыйлар иде. Ләкин казак та тиз генә бирешә торганнардан түгел, ахрысы, Рушанның беләгеннән йолкып ала алмаслык итеп кысып тоткан.

— Нәрсә сатып алмакчы соң син? — дип аптырап сорады Дасаев, терсәген тартып алырга тырышып. Аңа бу гамәлендә теге таза ике ир-ат та ярдәм итмәкче булып азаплана иде, кыяфәтләреннән күренә — алары монда яшәүчеләр түгел, ә читтән килгәннәр булса кирәк.

— Син, туган, шаян кеше икәнсең! — дип, аның беләген ычкындырмый гына, үрсәләнеп көлеп куйды дулкынланган казак.— «Волга»ңны, кадерлем, менә шушы чибәреңне!

Булышучылары белән бергәләп, ниһаять, беләген аңардан ычкындыра алган Дасаев, аңга килеп әйтте:

— Ә кем сезгә аны сатыла, диде әле?

— Әллә син психмы? Базарның иң күрекле җиренә парадка чыгардай итеп ялтыратып куйгансың да, хәзер «сатылмый» димәкче буласыңмы? Ай-яй, хәйләкәр икәнсең, туган! Бәясен күтәрмәкчесеңме? — дип тузына ук башлады казак. Җыелган халык та шаулашырга тотынды.

Рушан шунда гына машинасын еректан караганда автотукталыш кебек күренгән урынга — машиналар сатыла торган төшкә куеп киткәнлеген аңлап алды. «Ат базары, печән базары, кош-корт базары, ә менә хәзер автобазар икән. Һәр заманның үз җыры булган кебек, үз базары да бар»,— дигән кирәкмәс уй башыннан чагылып үтте.

— Гафу итегез, минем үтеп барышым иде. Белмәдем. Машинам сатылмый,— диде ул, үртәлеп.

Халык әкренләп тарала башлады.

Дасаев машинаның багажнигын ачты, аның уң ягыннан да, сул ягыннан да теге таза ике ир-атның башы тыгылды. Алар аның тартмасын җайлап куярга булышкан кебек кылана иделәр.

— Булдырдың, акыллы икәнсең, шырдый-бырдыйларны куып тараттың. Машинаңны без алабыз, безгә бик тә ошады, мөгаен, экспортка — чит ил өчен эшләнгән булгандыр,— диде аларның берсе.

— Юк,— диде Рушан, багажнигын ябып.— Чит ил өчен түгел, ә махсус эшләнгән.

— Алайса бигрәк тә! Махсус эшләнгән икәнлеге бер чакрымнан күренеп тора,— дип шатланып гөлдерәште таза ир-атлар.— Вакланмыйбыз, утыз мең бирәбез. Машинасы да, хуҗасы да күңелебезгә хуш килде. Йә, килештекме?

— Әйттем бит инде, машина сатылмый,— диде арыган кыяфәт белән Рушан һәм машинасының ишеген ачып кереп утырды.

«Волга» акрын гына кузгалып китте. Ярым ачык тәрәзәдә үҗәт ирнең башы күренде:

— Утыз биш мең, кадерлем! Соңгы бәям! — дип, рульгә ябышты ул.

— Сатылмый,— диде Рушан һәм тизлеген кинәт кенә арттырды, тирә-якта җыелган халык чәчелеп китте.

Бары тик станицадан чыгып, күпергә җитәрәк кенә тизлеген киметте ул. Шунда, болында туктап, көнен су буенда үткәрергә булды, бик арыган иде. Башыннан базарда күргәннәре китмәде: Монтана штатының кайда икәнен дә, мөгаен, белмәгән һәм шундый сәер шөгыльгә тотынган чегәннәр, Терек исемле матур ат хуҗасы, катлаулы тормыш юлы үткән карт казак һәм автомобиль базарындагы тарткалаш тынгы бирми йөдәтте.

— Утыз биш мең...

Бу санны кычкырып әйткән иде, аның гаҗәп зур сумма булуын, кайберәүләрнең гомер буена да андый акчаларны эшләп ала алмаслыгын аңласа да, күңелендә бер тойгы-хис тә тумады.

Рушан печән чапкыч үткән эздән болынга төште дә, үзенә җайлы урын эзләп, яр буенча шактый озак барды. Матур урыннар күп, шунлыктан сайлавы да кыен иде. Тиздән ул бер аланны күреп алды, печән чапкан вакытта печәнчеләрнең ял урынына охшаган булганга күрә, шунда тукталырга булды. Ватык кирпеч кисәкләре белән аралап казып куелган зәгыйфь кенә чишмәсе дә бар иде бу урынның. Илне аркылы-торкылы күпме генә йөрмәсен, менә шушындый казып чокырчык ясалган чишмәләр бары тик алар ягында гына очрый иде шул.

Әллә ни ерак та түгел, кемнәргәдер кат-кат хезмәт иткән иске учак урынын да күреп алды. Якын-тирәдәге таллык арасыннан эзләштергәләп, өчаягы белән корымланып беткән кечкенә казанны да табып алды, шунда ук станицадан алып киленгәнлеге күренеп торган утын да бар иде, әмма Рушан аларны кузгатмаска булды. Вакыты күп иде, елга буйларыннан, таллыклар арасыннан коры-сары, чыбык-чабык җыеп алды.

Елга ягыннан, болынга табан сизелер-сизелмәс кенә булып, су исе, юеш яр исе килгән дымлы йомшак җил искәне сизелә, ә чәчәкләргә күмелгән болында куе булып үлән исләре, эссе җәй исләре аңкып тора, Рушан тукталган шушы чишмә чокырчыгы янында әйтерсең лә шул елга-су һәм болын исләре бергә кушылган да,

башларны әйләндерерлек, исертерлек кабатланмас бер бөтен хуш искә әверелгән — биредән беркая да китәсе килми иде. Кояш шактый югары күтәрелгән, көн уртасы җиткән, әмма биредә, су буе болынында, әлсерәткеч эсселек сизелми — ашыкмый гына тирә-юньне күзәтергә мөмкин, ял итәргә дә рәхәт, җылы-ягымлы бер талгынлык кына бар иде.

Кечкенәрәк бер учак ягып, Рушан табып алган казанда берничә йомырка пешереп алды да аларны тәмләп ашап куйды. Аннары, анадан тума чишенеп, озаклап-рәхәтләнеп су коенды, Паланганы хәтерләткән комлыкларында кызынып ятты, шунысы гына бар — бу елганың исемен-атын кешеләрдән дә сораштырмаган иде, үзе дә хәтерләми.

Кояш төшлеккә авышкач, печән кибәннәреннән сәер-сәер күләгәләр озынаеп сузыла башлады. Бу җәннәттәй урынны ташлап, бер дә кузгалып китәсе килми иде. Рушанның күптәннән инде мондый рәхәтлекне татыганы юк иде бит, ул үзе тукталган җирдәге бер печән кибәнен ачкалады да машинасында утыргыч өстенә ябылган иске одеялны алып, шуны җәеп салды, шуңа рәхәтләнеп сузылып ятты.

Печән кибәненең хуш исе иске йортларында кышкы салкыннар, кар-бураннар малайларны куып менгезә торган печәнлекне хәтерләтте. Шул печәнлектә печәнгә чумып-җылынып, алар бер-берсенә сихерче-тылсымчылар, җен-пәриләр һәм тагын әллә нәмәрсәкәйләр турында куркыныч-хәтәр хәлләр сөйләрләр иде. Иң гаҗәбе шул: тузга язмаган ул хикәятләр бик озын гомерле һәм һаман да дәвамлы була торган иде. Шуларны уйлап ята торгач, Рушан, үзе дә сизмәстән, йокыга талган...

Бары тик төн уртасында гына уянды ул. Нәкъ аның баш очында, җәйге биек күктә бихисап йолдызлар җемелдәшә иде — мондый күкне, берьюлы бу кадәр күп йолдызларны аның инде күптәннән күргәне юк иде. Төн бик җылы булгангамы, ул туңмый-нитми бик озак карап ятты әле. Зур Җидегән йолдызлардан һәм Киек Каз Юлыннан башкаларының исемнәрен белмәгәнлектән, аратирә төнге күкне ярып, якты сызыклар калдырып атылып төшкән йолдызларны озак кына күзәтте ул. Әй дөнья! Нинди иксез-чиксез бит син... Ул җем-җем җемелдәшкән йолдызлардан күзен ала алмады, алардан аңа рәхәт бер талгынлык-тынычлык, наз-иркәләү агыла иде шикелле.

Рушан ниндидер бер эчке куаныч, әсәренү белән урыныннан сикереп торды, төн уртасы булуга карамастан, үзендә әйтеп бетергесез көч һәм дәрт тойды. Яңадан учак үрләтеп җибәрде, казан асып, бөтнекле чәй кайнатты —

төнгелеккә ат сакларга йә балыкка барганда алар шулай итә торган иделәр.

Мөгаен, аның төнге учагы әле гашыйклары таралып бетмәгән биек яр өстеннән дә, ә бәлки әле галәмнең үзеннән дә күренеп торгандыр. Юкка гына, башыңны күтәреп карасаң, сине космонавтлар да күреп ала, дип сөйләнмиләрдер. Гагарин галәмне иңләп төшкәч, бигрәк тә аның Казакъстан далаларыннан күтәрелгәнен белгәч, мондый сүзләр үзеннән-үзе таралган иде. Рушан, галәмгә сәлам җибәрергә теләгәндәй, учак күмерләрен актарып-таратып ташлады, меңләгән очкыннар, җир йолдызлары булып, күккә күтәрелмәкче булдылар да сүнеп югалдылар. Әгәр дә Рушанны чынлап та югарыдан космонавтлар күзәтсәләр, алар, мөгаен, аңа көнләшеп карар иде: төн, тынлык, хәтта чикерткәләрнең сайрашулары да ишетелми, бары тик ара-тирә төнге су өстендә йокылы-уяулы берәр зур балыкның сикереп-чупылдап куйганы, ул-бу булмагае, дип сискәнеп, берәр төнбоекның киң һәм уңайлы яфрагыннан куркынып суга чумган бака тавышы гына ишетелгәләп ала, күзләреңне учак яктысы сихерли, ул сине утның гомер-гомердән килгән мәңгелек серләренә алып китә шикелле...

Учакка ташланган коры-сары янып бетеп килә, ут сүнә-сүрелә бара иде, әмма Рушанның һаман да китәсе килми, шуңа күрә ул су буена төшеп китте. Ә елга, тирә-юньдәге бар тереклекне өркетеп уятудан үзе куркыпмы, үзенең суын тын гына Урал-Җаек ягына табан куып ятуында иде. Бары тик елгага буйсынмас, йокы белмәс шаян җил генә яр буе камышларын кыштырдатып куя: ботакларын суга хәтле салындырган, елгадан үзләренә яклау эзләгән һәм шуны үтенгән арыган талларны йокыларыннан уятмак булып, исеп-исеп ала иде ул. Төнгә суынып өлгергән яр буе комлыгы Рушанның яланаягын иркәли, ашыкмый гына як-ягына каранып, йөреп килергә чакыра төсле иде — мондый хозурлыкны тагын әле кайчан күрерсең, шул төшеңдә күрсәң генә инде.

Рушан, озын җәйнең бар җылысын үзенә җыйган суны ера-ера,— ә ул су көндезгедән дә җылырак-ягымлырак тоела иде,— яр буе сайлыгыннан барды, барды да, түзмәде — тиз генә чишенеп ташлады һәм сак кына, тын гына йөзеп китте, төнге тынлыкны бозу ниндидер ярамаган, мыскыллы гамәл булып тоелган шикелле иде.

Печән кибәне янындагы машинасына да болын исе сеңгән иде. Еракка төбәлгән алгы утларын кабызып, төнгә йокымсырап башларын игән чәчәкләрне, ятимсенеп утырган ялгыз кибәннәрне яктырта-яктырта, ул әкрен генә

олы юлга барып чыкты. Күперне үткәч, радиоалгычын кабызып-көйләп җибәрде — машина эче төрле тавышлар белән тулды, Рушан үзенә кирәкле дулкынны бик тиз тотып алды: аның кебек йокысызлар өчен төнге концерт тапшыралар иде. Юл таныш булып, каршыга килүче бер генә машина уты күренмәсә дә, үзе уйлаганча, ажгыртып, тиз генә китеп бара алмады ул.

Пестицид-гербицид ише агулар белән кат-кат агуланган, кирәксә-кирәкмәсә дә кат-кат сөреп ташланган, аулак юллар белән дә, автострадалар, тимер юллар белән дә аркылы-торкылы чуарланып, бензин-мазут исләре сеңеп беткән, Оренбург якларындагы нефтепромыселлар төтенендә тончыгып, арбалар, трейлерлар изеп бетергән, җир астына салынган нефть һәм газүткәргечләр челтәре, телеграф-телефон чыбыклары һәм башка шуның ишеләр белән уратып-чолганып алынган дала үзенең кызганычмескен тормышы белән һаман да яшәп ятуында иде әле.

Ара-тирә төнге юлны кисеп чыгучы еланнар, тузбашлар, бака өерләре күзгә чалынып кала. Яки ут яктысыннан сукырайган җир куяннары, кушаяклар, кая барырга белмичә, сикеренгәләп-чәчелеп югала иде. Йоннарын коя башлаган ябык төлкеләр дә ике мәртәбә ерактанрак кына юлны кисеп үтте. Әле бер мәртәбә туктап торырга да туры килде Рушанга: мөгаен, су эчәргә диптер, яшь бәрәннәрен ияртеп, юл аркылы сайгаклар көтүе үтте. Кызганыч ки, бу мескен җәнлекләргә браконьерларның машина утлары бик таныш булганлыктан, Рушан, үзем дә төнге даланың куркыныч юлында сайгак бәрәннәрен тагын да куркытып, таратып бетермим дип, машина утларын сүндерде дә юл читендә озак кына туктап торды.

Юлда куяннар бигрәк тә күп очрый иде. Алар, күрәсең, юл тирәсендә яшәргә ияләшкән-күнеккәннәр, машинадан да курыкмыйлар шикелле. Әмма әгәр дә машина уты яктысы өсләренә төшсә, шул ук кушаяклар кебек, болары да кая барып бәрелергә белми, юлда әрле-бирле чабыша башлый икән. Тимер юл буйлап сузылган урман полосаларында керпеләр дә бик еш очраштырып торды. Анда да тизлекне киметергә туры килә иде. Бер тапкыр юл читендәге оясы янында бурсыкны да күреп алды Рушан — теге куркып, бер дә оясына чуммады, симез артын сикерткәләп, ашыкмый гына урман ягына кереп китте. Бодай басуларына килеп чыккач, Рушан әрләр патшалыгына тап булды — менә кемнәрне пестицид та, гербицид та алмый, симерүләрен һәм бихисап үрчүләрен генә беләләр, чукынчыклар! Шунда ук, бодай басуы буенда аңа зур, ялкау, картайган ябалаклар да очрады.

Гаҗәп инде, әле шул ук юлдан көндез үткәндә бернәрсә дә күрмәгән-абайламаган иде, ә төн аңа кешеләр күзенә күренмәстәй көтелмәгән дөньяны ачты да салды. Искиткеч сихри төн иде бу!

Яктырып килә, йолдызлар дәррәү сүнә башлады. Әле менә-менә генә бәрхет-кара күк йөзе, күз алдында соргылтланып, якты йолдызларын сүндерә бара, таңның беренче нурларыннан, җәйгә хас булганча, ачык зәңгәр төсләре белән җәелергә җыена иде.

Рушан Мартукка үги әтисе җирләнгән иске мөселман зираты ягыннан кайтып керде.

Мөселман зиратлары бик гади, гадәттә, күзгә күрексез була, анда зиннәтле-бай һәйкәлләр дә юк. Хәтта күбесенчә зират сакчысы да булмый. Әмма транзисторлы бу заманның башларын кая куярга белмәгән акселератлары — буйга сузылып үскән, акыллары буйларыннан шактый калыша торган яшүсмерләр дә ул зиратларга кереп, нәрсәдер кыланып йөрми, чөнки күптән билгеле хакыйкать бар: андый әшәкелекләр эзсез үтми, гафу үтенүләр һәм акланулар игътибарга алынмый.

Зират вакытлар үтү белән бик нык иңгән, язгы-көзге яңгырлар урыны-урыны белән юып-ишеп бетергән балчык үр белән әйләндереп алынган — шулай булса да, мал-фәлән кереп, таптап йөрерлек түгел иде әле.

Ниндидер казакъ көтүчесе үзенең үлеме алдыннан, зиратны яңа койма белән тотарга дип, бик зур сумма акча васыять итеп калдырган булган икән дә, әмма балалары, менә икенче ел инде, әтиебез үз акылында түгел иде, дип, судлашып йөриләр, туган-тумачаларыннан кала, бу гөнаһлы эшкә шаһит булып бер генә күршеләре дә бармый икән. Моны Рушанга әнисе сөйләгән иде.

Зиратның элек-электән үк капка-фәләне юк, бары тик дүрт ягыннан да балчык үр аша кереп йөрерлек итеп ачык урыннар гына калдырылган. Мөселманнарда мәетне, зират никадәр ерак булса да, кәфенләп, махсус кабыкка салып илтәләр, зиратка бернинди машина-мазар керми, анда ир-атлардан башка беркемгә дә аяк басарга рөхсәт ителми.

Рушан машинасын юлда калдырып, балачактан белгән, күңелендә калган догаларын эченнән генә укый-укый, зират эченә үтте. Мөгаен, кем булып үсеп җитүенә, нинди генә белем алуына карамастан, һәр мөселман кешесе ул догаларны яттан беләдер һәм, кирәге чыкканда, кабатлый торгандыр.

Инде яктырган иде. Йолдызлар урынына күкне каплап алган төтен сыман җиңел-аксыл болытлар да җәйге

эссе кояшның беренче нурларыннан ук эреп бетәр. Иртәнге саф-салкынча күк йөзе тоныкланып, әлсерәп калыр төсле иде. Чык төшкән, зиратның төп үләне булган соргылт әремнәр дымланган, сукмаклардагы аяк астында тапталган вак-төяк үләннәр, җәйге эсселектән кибеп, шыгырдап тормаса да, зур зиратның төрле ягына таралып-тармакланып киткән сукмаклар тузанлы түгел иде. Менә шундый тын-тыныч иртәләрдә, мөселманнарның бәйрәм көннәрендә, бигрәк тә, картлар зиратка килә, фани дөньядагы тормышларын төгәлләп, бирегә килеп ятканнарның рухына багышланган иртәнге намазларын укый.

Рушан да үги этисе Исмәгыйль абзыйның каберенә изге сәгатьләрдә килгән булып чыкты. Тирә-юньдәге башка каберләр арасыннан ул аның каберен бик тиз эзләп тапты, колхоз тимерчелегендә койдырган чардуганы бизәкле челтәрләре һәм биеклеге белән башка каберләрдән ышанычлырак булып аерылып тора. Аннары ул кап-кара лак белән дә ялтыратып буялган иде. Соңгы кайтуында Рушан алып килгән, кадерләп кабер өстенә салган зур роза чәчәкләре шиңгән, кипкән икән инде.

Рушан чардуганны ачып эчкә үтте, кибеп корышкан чәчәкләрне бер читкә алып куйды, кабернең баш ягында әле яңарак кына төртеп чыккан зәгыйфь шайтан таягы куагын күреп алды. Иң нечкә, иң озын сабагы, бәлки әле бүген генәдер, алсуланып, чәчәк атып азаплана иде. Җир-ананың зәгыйфь, әмма яшәү көче сизелеп торган соңгы шул бүләге әкрен искән күзгә күренмәс җилдә тирбәлеп, «тыныч йокла, Исмәгыйль абзый» дип әйтә төсле иде. Алтын куллы, батыр сугышчы Исмәгыйль абзыйның кабереннән ерак та түгел Сания апасының кабере. Ул бик иртә, егерме яше тулар-тулмас үлеп китте. Рәтлерәк тормышта яшәсә, үпкә авыруын да җиңгән булыр иде, бәлки, нихәл итәсең — язмыш... Нихәлләр итәсең...

Рушан, үзен шулай иртә калдырып киткән якыннары белән тагын бер кат хушлашып, үзе яши торган зур шәһәргә юл тотты...

## XXXVII

Ташкентны Рушан Дасаев бер күрүдә үк һәм гомерлеккә яратты, хәзер еш кына башкалага килгән көннәрен исенә төшерә. Һәм һәрвакыт күз алдына Чыгытайдагы чәйханә килеп баса — ул аңа, мөгаен, Шәрыкның рухын аңларга мөмкинлек биргәндер, үз-үзен ничегрәк тотарга кирәклеген дә өйрәткәндер.

Шәһәрдә сүтәләр дә төзиләр, сүтәләр дә төзиләр иде...

Хан заманнарыннан калган кәкре-бөкре урамнар, чокыр-чакырлы, тузанлы тыкрыклар, чатлар юкка чыкты, ишегалларын чит-ят күзләрдән яшереп торган биек балчык дуваллы тулы квартал — мәхәлләләр сыпырып алгандай булды.

Шәһәрнең борынгылыгы китә иде. Бөтенләйгә, мәңгелеккә китә. Тын гына да, шау-шу белән дә, шатланып та, кайгырып та китә...

Бөтен тирә-як шулай җимерелә барганга күрә, кемнеңдер хәтерендә маяк кебек юл күрсәтеп торган нинди дә булса чинар агачына ничә яшь икәнен бер Аллаһы Тәгалә генә белсә beләдер, менә ул мескен агач та ничектер кечерәеп калган шикелле.

Еллар үтә тора, әнә үзеңә дә фәлән яшь булды, ә ул куәтле чинар, синең хәтереңдә тирә-юньдә иң биек булып, мәхәлләнең бер бизәге һәм горурлыгы булып, галәмәт ябалдашы белән рәхәт салкынча талгынлык таратып, һаман да үсеп утырган көнендә әле. Тагын күпме утырыр ул шулай? Колач җитмәс кәүсәсе тупасланып-яргаланып беткән булса ни дә, кояш өткән зур-зур тамырлары бүртенеп җир өстенә чыгып торса ни — син дә бит инде зифа тупыл сынлы, кара кашлы егет түгел хәзер.

Вакыт галиҗәнаплары һәрнәрсәгә үзенең тамгасын сала тора, беркем дә, бернәрсә дә аның келәймәсеннән котылып кала алмый. Әмма вакыт дигәнең тирә-юньдәге ни-нәрсәләрнең асылын үзгәртеп торса да, хәтернең дә билге-тамгалары шактый күп бит.

«Чыгытай, икенче тупик...» Дасаевның күз алдында шунда ук Сагбан борылышы ачылып китте, Чыгытай урамы боргаланып-сыргаланып шунда агып төшәр төсле.

Әгәр дә ике арба хуҗасы бер-берсенә хөрмәт белән сак кына юл сабарлык, тар гына, елан кебек боргаланучы Чыгытай урамыннан өскә күтәрелә калсаң — шәһәр сәүдә үзәгенең элекке складларына барып чыгасың, аларны иске гадәт буенча кәрвансарай дип йөртәләр. Кәрвансарайның шау-шулы, шанлы вакытлары күптән узган инде, мөгаен, Җунаид ханның соңгы шпионнарын тотып алганнан бирледер, ә менә тузанлы, анда-санда гына тәрәзәле складларга тәки шул кәрвансарай исеме ябышып калган.

Бу урамның һәр ике башыннан да эчкәрәк кереп китеп, аркылы-торкылы буталып беткән лабиринттай урамнардан ике мәчет манарасы күренеп тора. Берсе — биегрәге, күркәм генә күренә, ул шактый озын, зифа. Аллансызлар буыныннан булган яшьрәкләр, бигрәк тә турист-фәлән ишеләр бу манараны юк кына берәр котельный

яки фабрика морҗасы дип кабул итәләр, әмма бер ун еллар чамасы элегрәк аның иң очына ләкләкләр оя коргач, берниндидә морҗа түгеллеге, манараның бөтенләй башка максатлардан чыгып төзелгәнлеге ачыкланды.

Чәйханәнең түр башында гына утырырлыгы калган, дөнья белән башка алыш-биреше беткән бер аксакал ул язда манарага карап:

— Аллаһыныкы дөнья эшләренә кысылып буталмасын өчен кирәк ул манара,— дигән, имеш.

Манараның ишек-тәрәзәләре аркылы-торкылы кадакланган, ул берәүгә дә комачауламый, мөселманнарны иртәнге намазга чакырып, аның текә баскычларыннан азан әйтергә мәзин күтәрелгән заманнарны хәтерләсә — теге карт чинар гына хәтерлидер дә, калган гомерләрен чәйханәдә үткәрүче берничә карт кына искә аладыр.

Икенче манара яңа чагында да әллә ни искитәрлек булмаган, артык биек тә түгел, чи кирпечтән берниндибизәксез-нисез генә өйгәннәр дә куйганнар аны, бер дә күзгә ямь бирми инде. Әллә вакыты җиткәнме, әллә башка берәр сәбәп беләнме, ашыгып ага торган сай гына инеш ягындагы чокырга табан шактый авышып та тора әле ул манара. Кайберәүләр аны, бик белдеклеләнеп, Авыш манара дип йөрткән булалар һәм ниндидер Италия шәһәрен искә төшерәләр иде. Мәхәллә халкы исә, бик гади генә итеп, Бөкре Мөхәммәт Хуҗа дип атый аны. Бөкре рибачы, ягъни әҗәткә акча биреп торып, соңыннан зур процентлар алучы, Мәккәгә барып хаҗ кылып кайтса да, саран һәм бик гаугачыл Мөхәммәт акчасына төзелгән манара, Корбан бәйрәме үткәннән соң ук, шулай ава-янтая башлаган, дип тә сөйлиләр.

Әлеге сай гына инешкә таба янтайган манара әйтерсең лә саран Мөхәммәтнең, төзүчеләргә тиешлесен түләп бетермичә, аларны алдавына сүзсез ишарә булып тырпаеп тора иде. Хуҗа манараны турайтырга тау-тау акчалар вәгъдә итсә дә, ни өчендер ул эшкә алынучылар табылмаган. Бу имеш-мимешләр риваятькә әйләнгән, саран Мөхәммәтнең дә исе-эзе калмаган, ә манара һаман ава, әмма һич кенә дә авып төшә алмый әле.

Ә янәшәдәге шадра дувал артында, үткән-сүткән кешеләргә тузан бөркеп, Чыгытай урамыннан җирле минераль су төягән көмеш сыман рефрижераторлар чабыша, юк юк та, бормаланып сузылган урамнан чия төсендәге «Икарус» автобусы, мәхәллә малайларын куандырып, тавыш-тынсыз гына узып китә. Ул әле әйбәт кенә уйный, әле түбәнгә тәгәри торган билгеле бер футбол командасын йөртә.

Посып торган урынын көн саен алмаштырып, урамның аулаграк бер читендә карап торышка йокылы күренгән юан ДАИ лейтенанты яшеренгән. Ул, үзләрен бик оста һәм тиз йөрүчеләр дип, тыз-быз чабышкан машина хуҗалары каршына, җир астыннан калыккан кебек, көтмәгәндә генә килеп чыга да, таягын ялкау гына уйнатып, юан гәүдәсе белән ярты юлны каплап куя:

— Чыгытай урамында берьяклы гына хәрәкәт! Штраф түлә! — ди.

Бу урамда әнә шул рәвешле иске белән яңа, кичәге белән бүгенге, үткән белән киләчәк үрелеп беткән, әмма мәхәллә өстендә киләчәк тирбәлә инде...

Дасаев бу мәхәлләгә беренче тапкыр утыз еллар элек килеп чыккан иде. Эшенә соңга калган бер көзге иртәдә, бара-барышлый эссе урам тузанын йотып, Чыгытай буйлап өскә таба элдерә иде ул. Россиянең җылы-йомшак төсмерләренә күнеккән күзе ут янып торган якын кояш яктысында чинарны да, манараларны да, тагын әллә нәрсәләрне абайлап алды.

Әле моңа кадәр күрелмәгән яңалык хисе, беренче тәэсирләре, яшь инженерның тормышында алда булачак матур үзгәрешләрне сиземләве аның күңеленә гомерлеккә үтеп керде шикелле. Шуңадыр, ихтимал, шактый вакытлар үткәч, зур башкаланың инде икенче районында эшләгән чорында, шәһәрнең бу иске мәхәлләсенә килеп чыгарга туры килгәндә, кинәт кенә күңел күтәренкелеге тоя, яшьлегендәге шикелле, ниндидер анык кына булмаган, әмма шатлыклы үзгәрешләр көтәдер кебек, һәрвакыт матур җылы бер хис уяна иде.

Эшендә аны иптәшләрчә җылы каршы алдылар. Беренче мәртәбә Чыгытай урамыннан күтәрелгәндә, ул, үзенә кирәкле тыкрыкны күзләре белән эзли-эзли, гаҗәпләнеп тә куйган иде: бу коелып-шадраланып торган биек дуваллар арасында берәр төрле хезмәт конторасы бармы икәнни? Адресын буташтырмадыммы икән, дигәнрәк шик тә кузгалып алган иде әле.

Төзү-монтаж идарәсе, дөресрәге, ул урнашкан бина, көнчыгыш төбәкләрендәге башка күп кенә нәрсәләр төсле, Рушан өчен гадәти түгел, хәтта бераз сәеррәк тә иде.

Җирдә маскхалат челтәре төсле чуар күләгәләр ята, Рушан килеп кергән ишегалды тулысынча йөзем куаклары белән сарылган, хәтта кояш та күренми иде. Тагын бер сәгатьтән Дасаев үзенә тәгаенләнгән аерым эш бүлмәсендә утыра иде инде. Нәфис гарәп хәрефләре белән оста итеп бизәлгән биек түшәм өрлекләренә исе китеп карап торды ул: «Шәһрезадә әкиятләре диярсең, валлаһи!»

Бу бина шау-шулы Чыгытай урамыннан читтәрәк бер тыкрыкта, калкурак урында иде. Тәрәзәнең тимер челтәрләрендә, ишек өсләрендә һәм бинаның маңгаенда «1911 ел» дигән язуы да шәйләнә.

Үз вакытында бина биек дуваллар артыннан тәрәзәләре урамга карап торган бердәнбер йорт булган. Хәзер Истанбулның төтенле каһвәханәләренә китеп эзе югалган йорт хуҗасы Әхмәтхан сәүдәгәрнең, мөгаен, үз компаньоннары арасында бик тә алдынгы карашлы булып күренәсе килгәндер... Шуңа күрә дә ул йортының тәрәзәләрен урам якка каратып уйган.

Тәрәзәләрне уюын уйган, әмма аларга корыч пластинкалардан тезеп ясалган жалюзи куярга да онытмаган. Бу корыч пәрдәләр эчке яктан эленеп, әле һаман да булса хезмәт итәләр иде. Йортның тимер фурнитураларында һәм коеп эшләнгән чуен бизәкләрендә көтелмәгән язуы бар «Одесса, г. Лемманъ». Әйе, ерактан китертелгән булган болар...

Көннәр, атналар бер-бер артлы ага торды. Дасаев килгән ерак Казакъстан якларында бәрәңге-яшелчә бакчаларыннан уңышны күптән җыеп бетергәннәрдер инде, каралып чыккан камыллы буш калган басу-кырларга иртәләрен кырау төшәдер, күңелсез, эчпошыргыч көзге яңгырлар явадыр. Ә биредә, алар идарәсенең ишегалдында куакларын сыгылдырып, авыр йөзем тәлгәшләре эленеп тора, кипкән яфраклар арасыннан йомшак кына саркылып төшкән кояш нурлары, озын җәйдән арыган шикелле, тын гына җылысын сибә, бу рәхәтлекнең чиге булмастыр кебек...

«Кирәк бит! Бигрәк җылы... Сахара...» — дип, еш кына уйлый иде Рушан, укып бетергәннән соң юллама белән кырысрак-салкынрак якларга эшкә җибәрелгән дусларын да исенә төшерә иде. Алар инде җиләндер-пәлтәдер кигәннәрдер, свитер-бүрекләре дә өсләренә менгәндер, ә биредә әле һаман да пинжәктән генә йөриләр...

Рушан Чиланзардагы тулай торакта яши иде. Күбесенчә бер катлы йортлардан булган шәһәр ул вакытта бик зур мәйданнарны биләп тора, әйтерсең озакламый гөрләп үсеп китәчәген белгәндәй, күбрәк урын алып калырга тырышкан иде.

Һәр көнне иртән троллейбус белән Хадырыга кадәр эшкә йөрү Дасаевка күрелмәгән чит-ят якларга сәяхәт шикелле булып тоела. Ул еш кына салонның арттагы тузанлы тәрәзәсе буена барып баса да ашыкмый гына үзенең өзек-төтек уйларына чума, шул ук вакытта кондукторның ялкау гына тавышын музыка тыңлагандай тыңлый: «Биш Агач... Караташ... Алзамар...»

Һәр тукталыш музыка кебек кенә яңгырамый, ә тагын ниндидер серләр дә саклый иде төсле: «Сәмәрканд — Дарбаза... Домрабад... Әхмәт-Даниш...»

Дасаев Хадырыда троллейбустан төшеп кала һәм җәяүләп кенә Чокырсайга таба юл тота, анда туристлар өчен чыгарылган матур, төсле буклетлар-проспектлар, маршрутларда да билгеләп куелган базар яныннан үтеп, Чыгытайга барып чыга. Төнгә суынып өлгергән тротуарлардан атлаганда, аяк астындагы юка асфальт аша да ишегалдына керә торган юл өстенә электән түшәлгән йомры ташларны тоя иде.

Арыклар иртәнге якларда мул сулырак була һәм күңеллерәк челтериләр шикелле, бәлки, шулайдыр да. Капкалары киң итеп ачып куелган уң яктагы бакча эченнән иртәнге дымлы саф һава йөзгә бәрелә. Чәчәк атып утырган люцерна белән үрелеп-уратылып алынган тимер рәшәткә коймалар аркылы кызгылт ком сибелгән кешесез аллеялар күренә. Рушан белә иде инде: Вавилондагы шикелле күптелле шәһәрнең бу бакчасында ешрак татарча сөйләшүләр ишетелә — татарлар бу тыйнак бакчаны күптәннән ошатып, сайлап алганнар, шунда үзләренең иске дә, яңа да бәйрәмнәрен үткәрә иделәр.

Рушан базарда озаклап тукталып тормый. Тандыр миченнән әле генә чыккан, күпереп торган кайнар күмәч, тагын бер көмеш акчасына — берәр тәлгәш йөзем, ә кайвакытта ике шәфталу яки сутлары сыгылып торган груша ала, әмма күзе күбесенчә кызлар бите төсле нәфис алсу Кандиль алмасына төшә иде. Шунда ук базар эчендәге иртәнге якта ярым буш күпсанлы чәйханәләрнең берсенә сугыла, гадәттә, Шәрыкта эчелә торган бер чәйнек яшел чәй алып, тәмләп ашап-эчеп чыга. Кызыксынып, чәйханәләрнең әле берсенә, әле икенчесенә керә, һәркайсында диярлек бер үк төсле алсу роза чәчәкләре төшерелгән калай подносларга күмәчләрен, юылган җимешләрен куя.

Беренче карашка барлык чәйханәләр дә бертөсле күренсәләр дә, алар төрледән-төрле иде. Берәүләрендә, як-якларына каракларча карангалап, пышылдап кына сөйләшеп, энә өстендә утыргандай, алыпсатар сәүдәгәрләр утыра, чәйләренә кагылып та карамаганнар, үзләре шәһәр шау-шуыннан аптырабрак калган авыл дехканнары булып кыланалар.

Икенчеләрендә тәкәббер-эре кыяфәтле, кычкырып-кычкырып сөйләшүче такыр башлы итчеләр булыр. Аларның эше җиңелдән түгел — уникешәр килограммлы зур-зур балталар белән көне буена ит чабып кара да, бер-

ничәшәр потлы түшкәләрне әйләндереп кенә өлгер! Ә көндез чәйханәченең үсмер энекәшләре ит рәтләренә, бер китексез иң матур чәйнекләр һәм пиалаларны подносларга тезеп, чәйханәдән чәй илтәләр — базарда гомергомердән итчеләр иң кадерле, хөрмәтле кешеләр санала.

Рушан казакъча гына сөйләшеп утыра торган чәйханәгә дә тап булды — казакъ җирләре көнбатыштан шәһәргә үк килеп тоташа иде.

Бервакыт томанлы һәм юеш кышкы иртәдә ул эшенә ашыгып китеп бара иде. Күптән түгел генә алып кигән яңа пәлтәсенең куен кесәсендә тәнен рәхәт җылытып торган ике кайнар нан — икмәге дә бар. Гадәтенчә кереп иртәнге чәен эчеп чыгарга күнеккән чәйханә ни өчендер ябык булып чыкты — ул вахтер янына гына кереп, капкалап алмакчы булды, кыш көннәрендә тегенең плитәсендә һәрвакыт чәе кайнап торыр иде.

Рушан, куенындагы йомшак нанның җылысын һәм исен-тәмен тоя-тоя, юеш Чыгытай буйлап бара, нанның берәр кисәген сындырып кабасы килеп китте, ирексездән адымнарын әкренәйткән иде, шунда кинәт аңа дәштеләр:

— Иптәш инженер, хәерле иртә! Көн юеш-дымлы, чәйханәгә кереп, берәр пиала чәй эчеп чыгыгыз.

Ачык ишек яңагына сөялеп, мех камзул кигән зур гына гәүдәле бер ир кеше басып тора, кулы белән ишарәләп керүен үтенә иде.

Эчкә кергәч, Рушан янып торган лампочканы һәм авыр куе-кызыл келәм эленгән диварны күреп алды. Аның йөзенә җылы килеп бәрелде, агач күмере һәм шәрыкчә күп итеп эленгән келәмнәр исе дә борынын кытыклап куйды. Үзләренең идарәсеннән ерак та булмаган бу чәйханә Чыгытай урамында урнашкан. Рушан аны күптән шәйләп алган, аның мәхәлләнеке булуын да белә, ул инде сиңа базар чәйханәсе түгел, монда мәхәллә халкы белән даими килеп йөрүчеләр генә керә ала иде.

Рушан, ишек төбендә тукталып, керергәме-юкмы дигәндәй, бераз уйланып торды да, чәйханәченең юмартихлас елмаюын күреп, керергә булды.

Шуннан соң ул биредә еш була башлады, бигрәк тә кара көздә һәм кышкы иртәләрдә керергә ярата иде. Пычрак-юеш яки салкын эңгер-меңгердә, саран ягылган мангал җылысыннан иске шәһәр теләр-теләмәс кенә йокысыннан уяна. Рушан, пәлтә якасын күтәреп, базар аша гына әлеге чәйханәгә ашыга. Тандыр миче кайнар пар бөркеп торган күмәчче, аңа иске танышы итеп, кадерләпсайлап кына ике нан суза. Рушан, адымнарын киметмичә генә, каршысына очраган, җылы киемнәренә төренеп

бөгелә төшкән кешеләргә юл сабып үтә яки үзе алдыннан баручыларны узып та киткәли, базарга хас булмаган ниндидер акрын гына сөйләшкән тавышлар ишетелеп кала. Сәер, көн уртасында, гадәттә, төрле телдә сөйләшүчеләрнең тавышын үз тавышы белән басып, кычкырып үтә торган арбакеш та иртәләрен гаҗәеп тын, шауламыйча гына уза. Шәрык... Табышмак...

Рушан һәр көнне, Сагбанга борылуга, ерактан ук мәхәллә чәйханәсенең яктырып торган тәрәзәләрен күреп ала. Ул тиз килүдән тирләп чыккан маңгаен сөртеп куя да, бусага төбендә үк куеныннан җылы наннарның берсен чыгарып, ишекне киереп ача.

Гадәттә бу вакытта чәйханәдә кеше булмый әле. Рушанның сәламенә каршы чәйнекләре-самовары янында кайнашып маташучы Мәгъсүм әкә дәртле һәм күңелле итеп җавап кайтара:

— Ә-ә-ә, сәлам әлейкүм, инженер, мәрхәбә, уз әйдә тизрәк,— ди.

Төсләре тоныкланып яшелләнә төшкән галәмәт зур җиз самоварлардан җылы бөркелә. Әле килүчеләр булмаганлыктан, ишек өстендә бер генә лампочка яна, караңгылыкка китеп югалган диварларга кара келәмнәр эленгән шикелле, бары тик урамнан узып баручы берәр машинаның гына утлары тәрәзәне яктыртып ала да бер мизгелгә генә диварлардагы кан-кызыл төстәге келәмнәр күренеп кала.

Соңрак, шәрык тәм-томнары булган набат һәм парварда капкалый-капкалый чәй эчеп, Мәгъсүм әкә белән тәмләп сөйләшеп утырганда, ишектә тагын бер кеше күренә.

Гадәттә ул күрше йорттан берәрсе булып чыга. Мамыктан сырган, үкчәләренә кадәр төшеп торган озын чапанына өйдәгечә генә төренгән була ул, тәмле телле, тәкәллефле генә итеп чәйханәче белән матурлап исәнләшә, хәл-әхвәл сораша, түрдәрәк утырган Рушанны да күреп алып, аңа да елмаеп эндәшә:

— Хәерле иртә, иптәш инженер...— ди.

«Инженер»... Бу кушамат мәхәлләдә Рушанга тәки ябышып калды бит, аны хөрмәтләп-зурлап әйтәләр иде, әйтерсең кладовщик Миргаяз әкә бөтен мәхәллә халкы белән махсус репетицияләр үткәргән диярсең.

«Инженер» сүзе ул елларда әле хөрмәтләнә һәм Дасаевка аны ишетү рәхәт иде.

Бәлки, хезмәттәшләре арасында да тиз хөрмәт казануы, мәхәллә халкының да аңа үз итеп караулары сәбәпче булгандыр, бервакыт чәйханәгә төш вакытында барып

кергәч, ул кинәт кенә шундый карарга килде: «Калам... үзбәк җирендә тамыр җибәрәм... өйләнәм...» — диде.

Миргаяз әкә аның белән бер өстәлдә утыра иде, Инженерның йөзе үзгәрүен күреп, ашыгып сорап куйды:

— Нәрсә булды, Рушан?

Дулкынланудан бер генә мизгелгә агарынып киткән Дасаев, күз карашы белән залны сөзеп алды да, гүя бөтенесен дә яңа гына күргән шикелле итеп, кладовщикка күңелле генә әйтеп салды:

— Өйләнергә уйладым, Миргаяз әкә! — диде.

Ә бит әле шул мизгелгә кадәр мондый уйның башына да кереп караганы булмаган иде.

— Бәрәкалла! Мәйлең, мәйлең... Бик хуп эш...— дип куанды Миргаяз әкә дә.

«Өйләнәм» дигән сүз ул әле иртәгә үк берәр чибәркәй белән загска чабачак дигәнне аңлатмый иде. Ул «калам» дигән сүзенә: «Озакка, җитди итеп, гаиләм-йортым... балаларым белән...» — дип әйтүе иде Рушанның.

Әлбәттә, аның сөйгән кызы бар иде. Ул бар яктан да усал җилләр искән, салкын җәяүле бураннар себереп торган далалы яктагы бер шәһәрдә яши. Рушанның барлык уйлары да әнә шунда, зәгыйфь сәрби куаклары чорнап алган «1905 ел» урамындагы йортка юнәлтелгән, кайвакыт ул аны күңеленнән генә «кәләшем» дип тә атый иде. «Кәләшем...» Нинди татлы сүз!..

«Өйләнергә кирәк» дигән карары тышкы яктан аңа бер үзгәреш тә кертмәде, әмма тормышында кискен борылыш булды шикелле: Рушан кинәт аңлап алды, ул моңа кадәр һәрнәрсәгә тыштан гына, килгән кеше күзе белән генә карап йөргән, ә хәзер барысын да булачак тормышына чамалап, төпченеп, асылына төшенеп карарга һәм күзалларга тырыша иде. Буш вакытларында ул сәгатьләр буе китап кибетләрендә йөри, еш кына концертларга бара — гастролер артистлар бер исеме белән генә дә ниндидер сер вәгъдә иткән җылы, икмәкле бу шәһәрне яраталар иде. Юкка гына «Ташкент — икмәкле шәһәр» дигән гыйбарә телгә кермәгәндер.

Рушан, мәхәлләдә арзан гына хакка аерым бүлмә тәкъдим итсәләр дә, һаман әле шул тулай торагында яши бирә иде. Ләкин ул мәхәлләгә күчәсе итмәде — көн саен килеп-китеп йөрү рәхәтеннән баш тартасы килмәде аның. Кайвакытларда ул юлын бераз үзгәртеп тә куя: Хадырыдан сулга борылып, Чорсу мәйданына чыга, аннары базарны үтеп, яңадан Чыгытай урамына таба атлый иде.

Ул шәрык кешеләренең ыгы-зыгы, ашыгучанлык-кабалануны өнәмәгәннәрен бик тиз аңлап алды, шуңа күрә

ашыкмаска тырыша иде. Рушан тирә-юньне һәрвакыт игътибар белән карап-күзәтеп йөри, элегрәк күзе төшмәгән нәрсәләрне дә күреп ала. Борынгы шәһәрнең төс-буяуларын, тавышларын, хәтта тузанын да, эсселеген, күптеллелеген, килүче-китүчеләрнең тыз-быз килеп йөрүен, шәһәр халкына гомер-гомердән хас салмак сабырлыгын ләззәтләнеп үзенә сеңдерә бара. Һәм, еш кына, кәефе килгәндә, үз-үзенә бер биргән карарын кабатлый: «Әйе, мин шушында яшәргә тиеш...» — ди.

Иртән идарәгә эшкә барышлый ул бик күпләр белән баш иеп исәнләшеп үтә иде. Аңа да кулларын күкрәк өстенә куеп, якты елмаеп җавап кайтаралар. Бары тик инде хәлсезләнгән, агарынып калган карт бохара яһүдләре генә баш кагып исәнләшеп китә. Рушан яшьлеге белән аңлап бетерә алмый — бу бабайлар әллә тәкәбберлектән, әллә хәзер инде һәр хәрәкәт авыр бирелгән көчсезлектән шулай эшлиләр иде. Ә бәлки, изге китап Тәүрат гамәлендә инде без, сүзләргә караганда баш кагып узу абруйлырак-дәрәҗәлерәк, дип уйлыйлармы?

Рушанга бу тыныч бохара яһүдләре дә берсүзсез ошый. Шау-шулы нэпман заманнарыннан, яшьлектәге уңышлы елларыннан ук калган ак чесуча тукымадан тегелгән пөхтә костюмлы әлеге картлар аңа йә язларын, йә көзнең озын җылы көннәрендә генә очраштыра. Пычракларда, салкыннарда, җәйге эсселәрдә алар биек дувал артларына кереп яшеренә иделәр.

Иртән кошлар базары яныннан тиз-тиз үтеп киткән чагында, Дасаев аларны әтәчләр рәтендә очрата. Картлар бары тик тере кошларны гына сатып ала һәм кош-корт белән күз бууча гипнозчылар яки сихерчеләр кебек эш итә. Әле бер минут кына элек кыдрачланып-гайрәтләнеп бар базарга «кикрикүк» дип оран салган әтәч егетләре үзләренең кабыргаларын санап, капшап торучы картларның хәлсез куллары астында кинәт кенә тынып, юашланып кала.

Шунысы сәер, бу карт яһүдләрнең һәрберсе һәрвакыт бер генә төсле әтәч сатып ала: яки уттай җирән-кызыллны, яки ап-акны, яки чуар, беренче көз чебешләрен генә. Аларны аякларыннан күтәреп, баштүбән алып китәләр, әтәчләр шунлыктанмы — үзләрен гаҗәп тыныч тота. Рушан, картаеп, бер-берсенә охшап калган яһүд бабайларын бары тик кемнең нинди төстәге әтәч алганына карап кына аера иде.

Шәһәрне яхшырак белә барган саен, Дасаевны мәхәллә чәйханәсе үзенә ныграк тарта. Чәйханәнең язылмаган канун-тәртипләрен Миргаяз әкә аңа бер кичтә аңлатып

бирә алган булыр иде, ләкин Рушанның һәммәсенә дә үзе төшенәсе килде.

Кичләрен ул еш кына эшендә тоткарлана, ә кайтышлый чәйханәгә керә дә, гадәтенчә, бер-ике партия шахмат уйный. Чираттагы йөрешләрен ясаган араларда ул халык күп җыелган залны игътибар белән күзәтә, кичке якта киереп үк ачып куелган тәрәзә аша урамдагы айваннарның да тулганын күрә. Анда Мәгъсүм әкәнең ирекле ярдәмчеләре, чиләкләрен шылтырата-шылтырата, ишегалдына арыктан су сибәләр, агачларны резин шланглардан коендыралар — шуннан соң, яңгыр явып үткән кебек булып, җир исе, бакча исе аңкый.

Кичке тынлыкта Дасаев еш кына: «Клуб — ир-ат җыела торган урын гына»,— дип уйлый иде. Биредә үткен сүзлелек, тапкырлык, кешеләр белән таныша-аралаша белү, ягымлылык һәм мәхәллә тормышында катнашу аеруча бәяләнә. Ул ишегалдына һәм агачларга таксопарк директорының башкалардан ешрак су сиптереп йөргәнен абайлап алды, чөнки ул бу эшне барысыннан да остарак эшли: тузан да туздырмый, артык пычратмый-чупырдатмый да, аның шөгыленнән соң җирдә әле бик озак гади шланг белән ясалган бизәкләр ярылып ята. Ул директорның чәйханәгә кышлык күмер һәм утын китерткәнен дә, ремонт буяуларын кызганмаганлыгын да белә, әмма директор боларны үзенә ниндидер аерым мөнәсәбәт булсын дип эшләми, Рушан монысын да күреп тора иде.

Соңрак Рушан үзе дә чәйханә өчен игелекләрне аз эшләмәде, әмма мәхәллә халкының аңа булган мөнәсәбәте үзгәрмәде, һаман да элеккечә хөрмәтле, тигез булып калды. Аны һаман да һәрвакыттагыча «инженер» дип, бу сүзгә һәрчак зурлау мәгънәсе салып атап йөрттеләр.

Японнарча кысан ишегалларында элекке бакчалардан берәр чикләвек яки өрек агачы, алмагач яки ялгыз тут агачы гына утырып калган иде, ә уртада — кечкенә генә чәчәк түтәлләре. Тәрәзәләре ишегалдына караган, икенче катларында балханасы — балконы булган бу йортларда, читтән килгән кешенең исен китәрмичә, ят күзләрдән яшерен тын гына тигез тормыш ага.

Рушанны чәйханә әнә шул гадилеге, нәрсә дә булса күрсәтеп шаккаттырырга омтылмавы белән үзенә тартып тора. Аңа беркая язылмаган тәртип кагыйдәләре дә ошый: мәсәлән, чәйханәгә исереп килеп кермиләр, ачыктан-ачык эчеп тә утырмыйлар. Өлкән генә җитди кешеләрнең, мәхәллә хуҗаларының дип әйтергә дә була, үзләренә пылау китерер алдыннан чәйнеккә яшереп кенә

аракы салып, шуны пиалаларга агызгач, дастархан янында утыручыларга өләшеп чыкканнарын да күргәләгәне булды. Юкса нәрсәсе бар инде — куй шешәңне уртага, стаканнар җитәрлек, шаулаш, матур-матур тостлар әйт, кем гаепләп сүз итәр? Юк, кечкенәдән үзләштерелгән кагыйдәләр алай эшләргә ирек бирмиләр — ярамый, чөнки бер генә тапкыр вәсвәсәгә бирел, аннары әкренләп барлык гореф-гадәтләрне, ата-бабалардан калган йолаларны нигезенә кадәр җимерергә мөмкин.

Яшьләр дә монда үзләрен тыенкы тота. Бервакыт шәһәрнеке түгел икәнлекләре әллә каян күренеп торган, базардан килеп, очраклы гына чәйханәгә кергән ике яшь егетнең үзләренә гомер онытмаслык сабак алганнарының шаһиты булды Рушан.

Чиста-пөхтә чәйханәнең диварлары буендагы келәмнәр өстенә тагын курпачлар да — сырылган тар гына юрганнар да җәелгән иде, егетләрнең берсе йомшак юрганга рәхәтләнеп сузылып ятты, икенчесе аның янына утырды, алар, чәйханәдәге башка кешеләргә игътибар да итмичә, кычкырып көлә-көлә, кызып-кызып нәрсәдер турындадыр сөйләшүләрен дәвам иттерделәр. Алар дивар буена урнашкан, беркемгә дә комачауламыйлар иде шикелле, ләкин дисбесен сүзсез генә тартып утырган Мәгъсүм әкә, башкаларга сиздерми генә тегеләр янына килеп, егетләрнең колагына гына, йомшак кына ярым пышылдап, нәрсәдер әйтте. Аның шул бер сүзе җитте, егетләр, оятларыннан кып-кызыл булып, урыннарыннан сикерешеп тордылар.

Мәгъсүм әкәнең артындагы самовар янында кулдан язылган шундый язу бар иде: «Башкаларны хөрмәт ит — сине дә хөрмәт итәрләр».

Шахмат уйнап бетерер алдыннан, шәһәр өстенә төтенле эңгер-меңгер төшкән мәлдә, кайвакыт Рушан чәйханәгә килеп кергән балаларны күрә. Алар сүзсез-нисез генә үзләренә кирәк кешене эзләп табалар да, аның колагына нидер пышылдап, тавыш-тынсыз гына юкка чыгалар. Шуннан Дасаев киләчәктә дә үзенең кичләрен мәхәллә чәйханәсенә шахмат уйнарга яки ачык верандада утырып чәй эчәргә йөриячәген, шунда аны да, өйгә ашарга кайтырга чакырып, улы яки кызы йөгереп киләчәген күз алдына китерә. Ул, үзе дә сизмәстән, тәмле итеп елмая.

Әлбәттә, андый чакларда ул булачак балалары, хатыны турында хыяллана. Хатыны ниндирәк булыр икән, тормышлары матур булырмы икән, дип уйлана. Дөрес, кулына нота папкасы тоткан кызчык вакыт еракłыкла-

рында эри бара, менә-менә аның образы, төсе-кыяфәте бөтенләй эреп бетәр шикелле була, ләкин, яшьлекнең сыек рәшәсендә томаннарга өретелеп калган ул ерак мәхәббәтне сызып ташлап булмаса да, күңелгә яңа мавыгулар, яңа хисләр кабына иде.

Андый чакларда Рушан һәммәсе дә үзе уйлаганча булачагына шикләнми иде. Тормыш аңа соңыннан гына төрле көтелмәгән хәлләр әзерләгән булып чыкты, алар арасында йөрәк әрнеткечләре дә, куркынычлары да бар иде...

## XXXVIII

Рушан үзенең хәтер китабын актарганда, нәрсә турында гына уйламасын, Глорияне искә алмыйча калмый. Глориянең үз язмышыннан аерылгысыз язмышы рәхим-шәфкатьсез заманның иң җуелмас тамгасын салып калдырган иде шул.

Бервакыт эңгер-меңгердә, гадәтенчә, тәрәзә буенда истәлекләр киченә бирелгән бер мизгелдә, ул көндез актарып утырган иске хатлар өеме арасыннан бер зур фоторәсемнең почмагын күреп алды. Актүбә тимер юл техникумының 1960 елгы чыгарылышыдыр, дип уйлап, рәсемне алып карады. Кемне күрергә теләде икән Рушан? Роберт Теләүмөхәммәтовнымы? Лом-Али Хәкимовнымы? Ефим Ульманнымы? Лидочка Журавлеванымы?

Ялгышты. Профессионал кул төшергән фоторәсем үз вакытында байтак газетларда басылып чыккан фоторәсем булып, анда СССР чемпионатының бишенче зонасында «Б» классының җиңүчесе — «Металлург» футбол командасы сурәтләнгән иде. Заманында илдә спорт буенча әнә шундый әллә нинди квалификацияләр дә бар иде шул. Рәсемнең аскы ягына, сул як почмагына кыеклатып, каты картон өстенә ачык итеп, кызыл карандаш белән матур һәм табигый каллиграфик почерклы мондый сүзләр язылган иде «Рушан Дасаевка — «Металлург»ның беренче хуплаучысына, дустыбызга — җиңүләребез истәлеге, яшьлегебез истәлеге». Һәм команда капитаны Джумбер Джешкарианиның казначейларча эре имзасы ярылып ята.

Рушан рәсемнең артын әйләндереп карады. Анда футболчыларның төрле төсле култамгалары сырланган булып чыкты.

«Металлург»ны көндәше куып җитмәслек чемпион иткән уеннан соң ук төшерелгән фоторәсем иде бу. Чәчен матур итеп тараган, футболкасын пөхтәләп кигән Джумбер беренче рәтнең иң уртасына елмаеп чүгәләгән, ә аның

тирәсендә — бер дә арымаган-талчыкмаган, бәхетле командасы.

Еллар үтү белән безнең гадәтләребез, яраткан шөгыльләребез әллә ничек кенә үзгәрә дә бетә! Кем дә булса берәрсе, Рушан Дасаев берәр вакыт футболдан бизәр, уеннарга йөрми башлар, дисә — шаркылдап көлерләр генә иде. Җиде төн уртасында уятып сорасаң да, ул, балалар санамышы шикелле генә итеп, «А» классы командаларының теләсә кайсысының алмаш составына кадәр исемләп әйтеп бирер иде, инде төп состав турында сорашып та торасы юк. Кайвакыт кышын, бернинди футбол уены турында сүз алып бармаганда да, төннәрен кинәт кенә аның колагына Синявский яки Озеровның репортажы ишетелгәндәй була, ул, караваты янындагы тумбочка өстеннән «Спидола» транзисторын алып,— бу транзисторлар әле яңарак кына чыккан сирәк әйбер иде,— шуның «колагын» боргаларга тотына: соң, ул бит трибуналардагы тавышларны, судья сыбызгысының череллдәвен дә бик ачык ишетте, очып килгән тыгыз тупны да күргәндәй булды ич...

Тиз мавыгып китүчән Глория дә футбол карарга ярата иде. Ул тормышта күп нәрсәләргә мөкиббән һәм, нәрсәгә тотынса да, зур дәрт белән, теләк белән тотына, футбол уенына да ул искиткеч гашыйк кеше, аңа онытылып табына иде.

Ул Рушан белән бергәләп яки «Металлург» командасына ияреп, Ташкентка «Пахтакор» уенын карарга барырга ярата иде. Ул елларда футбол кырында атаклы уенчылар: Красницкий, Стадник, Абдураимов, Искәндәр Фазылов, Ревал Закиров кебекләрне күрергә була иде. Глориянең дәртләнеп-шашынып уенны каравы искиткеч тәэсирле, аны үз күзләрең белән күреп, ишетеп торырга кирәк. Юк, ул урыныннан да сикереп тормый, тамаклары карлыкканчы кычкырып та утырмый, әче итеп сызгырырга да тотынмый, әмма бер ун минуттан аның тирәсендәге кешеләр дә дәртләнә-кыза иделәр. Ул уенны тирәнтен тоя, алдан күрүчәнлеге, сизгерлеге гаҗәеп, шуңа күрә прогноз-фаразларында бик сирәк ялгыша торган иде.

Үзләрендә — Заркентта уйнаган «Металлург» командасының җиңүләренә аның кебек куанган, җиңелүләренә аның кебек уфтанган тагын берәр кеше булдымы икән? Уңышсыз уеннан соң пычраныгі-тирләп беткән Джумбер, Дасаевны чишенү бүлмәсендә күрсә, яктырып китә, әмма барыбер:

— Рушан, зинһар, Глорияне алып чыгып кит әле! Мондый уеннан соң аның күзенә карарга оят,— ди иде. Ә

инде җиңсәләр, алар шундый да бәхетле, шундый да горур атлыйлар! Егет белән кызның даими урыннары булган трибуна яныннан узганда, һәр уенчы әйтерсең җиңүче гладиатор шикелле, Глория аягы астына җиңүен ташлагандай итә, ә кыз җавабында юмарт итеп, куанып елмая.

Команда читтәге уеннарын оттырып кайтканда, Глория шелтә сүзләре әйтсә, Джумбер, шаяртып:

— Глория, син бит безнең тылсымыбыз-талисманыбыз! Анда уенны кемгә багышларга да белмәдек. Әгәр дә аны бүләк итәр кешең булмаса, ир-атка җиңү нигә кирәк? Менә иртәгә үзебездә уйныйбыз, син килсәң, егетләр тырышачак, әлбәттә...— ди.

Ә инде, буш көннәре булып, Глория команда белән бергә якындагы казакъ шәһәрләре Чимкент белән Җамбулга барып, анда «Металлург» көндәшләрен пыр туздырып, тар-мар итеп кайтканда, аның ничек куанганын күрсәгез икән! Футболчылар — ырымнарга ышанучан халык, алар Глориянең командага уңыш китерәсенә ихлас ышана иделәр.

Рушан фоторәсемгә карамаса да була, ул кояшлы, якты, көздән бигрәк язга тартым көнне бик яхшы хәтерли, хәер, таулардан кыш алды салкыннарының сулышы сизелә иде инде, алар төзеп яткан зур комбинатның морҗаларыннан да төтен чыкмый әле. Глория белән аны команда белән бергәләп рәсемгә төшәргә никадәр генә кыстасалар да, Глория нык торды:

— Бу сезнең җиңүегез, егетләр,— дип, дулкынлануын һәм күз яшьләрен тыя алмыйча, аларның юеш-пычрак битләреннән берәм-берәм үбеп чыкты, үзенең яраткан ак күлмәге Джумберның футболкасы кебек пычранганына да игътибар итмәде...

Рушанны Глория белән шул футбол таныштырган да иде. Дөресрәге — Джумбер. Хәер, болар икесе бер үк нәрсәләрдер.

Заркент...

Шәһәрнең исемендә Рушанның үзе генә аңлый ала торган музыка ишетелә шикелле. Искә төшереп телгә алганда, кинәт кенә сискәнеп китеп, эчендә нәрсәдер өзелеп төшкәндәй тоела, бер мизгелгә исертерлек, баш әйләндерерлек, үзең генә белгән-яраткан шәһәрең була да кала Заркент. Андый шәһәр һәркем өчен теләсә нинди булырга мөмкин — зур йә кечкенә, иске йә яңа, атаклы-данлыклы яки бөтенләй исеме ишетелмәгәне, әмма хикмәт анда түгел — ул синеке, ул синең йөрәгеңнең бер өлеше булырга тиеш. Һәм, мөгаен, соңыннан

үзәкләрне өзеп: «Ә хәтерлисезме, безнең шәһәрдә...» — дип искә алмас өчен, синең соңгы көннәрең дә шунда төгәлләнергә тиештер. Һәм ул, бер генә кешесе булса да, синең яшьлегеңне, уңышларыңны исендә тоткан, шуларның шаһиты булган бердәнбер шәһәр булып калырга тиеш. Бер генә мәртәбә булса да: «И-и-и, син бит бөркет идең! Синең шундый гүзәл сөйгән кызың бар иде! Хәзер андыйлар юк шул инде...» — дип әйтерлек булсын.

Әмма... әмма...

Тормыш кырыс, язмыш явыз — алар сине шул бердәнбер шәһәреңдә генә калдырмый шул: дуңгәләк шикелле иттереп, ил буенча куып йөртә, шәһәрләреңне дә алмаштырырга мәҗбүр буласың... Менә Рушанның да Заркенттан соң яраткан шәһәре Ташкент иде. Хәзер анысы да «иде» дип сөйләргә генә калды шул...

Ә Заркент Рушанның яшьлек шәһәре, яшьлек мәхәббәте. Кемдер ышанмаска да, хәтта кимсетеп елмаерга да:

— Заркент? Анысы тагын нинди башкала? — дияргә дә мөмкин.

Әйе, торак мәйданнарын алыштыру турындагы белешмәлекләрдә ул бик түбән урында тора. Хәер, нәрсәдер аңлатырга, акланырга тырышу кирәкме икән? Үз шәһәре булмаган кеше кызганыч — ул барыбер йортсыз-җирсез яшәргә дучар ителгән шикелле...

Ул заманнарда Заркент өч йөзләп күтәрү краннарын эссе Азия күгенә төбәп, урман кебек булып утырыр иде, шәһәр көн-төн төзелә, әле кичә булмаган нәрсәләр, берсекөнгә күтәрелеп-калкып чыгарлар иде.

Рушан килгәндә, шәһәрнең аерым өлешләре шәйләнә башлаган иде инде. Үзәктәге зур булмаган табигый калкулыкта, зур үзәк урамның шау-шуыннан бераз eрактарак, кечкенәрәк кенә бакчалы һәм фонтанлы «Космос» кинотеатрының мәһабәт бинасы күтәрелгән. Бу урын — шәһәр халкының иң яраткан урыны һәм әле озак еллар буена, шәһәр үсеп, башка менә дигән биналар да калкып чыкканчыга кадәр гашыйкларның очрашу урыны да булып калды.

Әмма Заркентның аерым горурлыгы стадион иде. Аңа урынны шулай ук үзәктән ерак түгел җирдә, зур парк-бакча зонасында тәгаенләгәннәр. Ул бик яхшы проектлаштырылган һәм оста, сыйфатлы итеп төзелгән, җиңел, нәфис. Кышкы спорт заллары да, су спорты сарае да бар — ул уртача яшьләре егерме дүрттән бераз гына артыграк булган шәһәр халкын үзенә тартып тора. Иртә язда бу стадион үзәк матбугатта, бигрәк тә спорт газет-журнал-

ларында еш кына телгә алына. Эш шунда ки, ул илдә шлак сибеп ясалган ярыш юллары булган икенче генә стадион иде, сезон башланыр алдыннан иң атаклы узышчылар, күбесенчә Уфадан, Заркентка күнегүләр үткәрергә җыела.

Әле бит тагын аларның ярышлары да була! Кайсы гына исемне алма, күп тапкырлар СССР чемпионы, һәр фамилия алдында спортчы өчен бик тә кадерле өч хәреф язып куела: ЗМС — заслуженный мастер спорта, ягъни атказанган спорт мастеры. Мондый афишаларны башкала шәһәрләрендә дә бик еш күрә алмыйсың. Бөтен дөньяга танылган мотоциклчы Габдрахман Кадыйровның кызыл шарфы Заркентның язгы җилләрендә бер тапкыр гына җилфердәмәде ул елларда. Соңгы хәлиткеч узышта Игорь Плеханов, Борис Самородов, Габдрахман Кадыйров һәм тагын дүртенче берәү чабышканда, стадион ниләр генә кыланмый да, нинди генә шау-шу тудырмый! Бу ярыш бит, чынлап әйткәндә, әнә шул дүртенче узышчы өчен уздырыла да. Дүртенче булып күбрәк тректан, ягъни спорттан бер китеп, бер кире кайтып йөргән, шулай ук атаклы, әмма картаеп килүче Фәрит Шәйнуров яки әле бөтенләй яшь, гаять кыю-тәвәккәл, мотоциклын арт көпчәкләренә күтәреп чабучы Юрий Черканов катнашыр иде. Заркентта аны, яратып, Чика дип кенә йөрттеләр.

Әле яшьлеген җуймаган Борис Самородов ешрак җиңүче булып кала. Кызлар кебек оялчан Габдрахман Кадыйров исә, тамашачылар алдында гаепле кешедәй елмаеп, кызыл шарфын муеныннан сүтеп ала — барып чыкмады бу юлы дигәндәй, акланган шикелле итә. Юкса икенче урыннан да түбән төшми үзе, көмеш медаль язмышын да фотофиниш белән генә билгеләгән чаклары да күп була.

— Түзегез инде, кыш көне мин үземнекен алырмын, сынатмам,— дип өметләндерә Габдрахман кызларны, алар сузган кулъяулыкларны алмыйча. Шлак тузанын хуш исле кулъяулыклар белән генә сөртеп бетереп буламыни? Чабышкан-узышкан чакларында, спидвей ярышларында, бозда узышта аңа тиңнәр булмады, ул спорттан, җиде мәртәбә дөнья чемпионы, унике мәртәбә СССР чемпионы исемнәрен яулап, җиңелмичә китте, спидвей короленең кызыл шарфын Европаның күп кенә башкалалары ареналарында озак еллар искә төшереп тордылар.

Соңрак Глория ничектер Рушанга Яшьләр йортының яңа бинасындагы фойэның зур диварын «Мотоциклчылар» дигән мозаик панно бизәп торсын иде, дигән теләк

белдерде. Юк, беркем танымаган абстракт спортчылар түгел, ә нәкъ менә тормыштагыча, чын-чынлап ярыш барышында вираж-борылыштан беренче юлга ашкынып килүче Самородов — Кадыйров — Плехановлар булсыннар иде алар, уртада — легендар кызыл шарфы җилфердәп торган Габдрахман, әлбәттә.

Яшь шәһәрнең кумирлары — яраткан каһарманнары спортчылар булуына һич тә гаҗәпләнергә кирәкми. Мотоциклда узышучылар бер хәл әле. Алар, тылсымлы шапито циркында шикелле, күн комбинезоннары, тимер дагалар сугылган күн итекләре, атаклы фирмалар эшләгән ачык-матур төстәге шлемнары белән мираж кебек кенә булып, өермәдәй узалар да китәләр, узалар да китәләр, йөзләрен дә юньләп күрми каласың, ә көннәрдән бер көнне, кыйммәтле машиналарын төяп, стадионда бензин һәм шлакның татлы исен генә калдырып, юкка да чыгалар. Яшьлек дәрте-җегәре юмарт ташып торган шәһәрнең иркәләре, чын кумир-каһарманнары футболчылар иде, билгеле. Алар Глориянең дә кумирлары булды. Чөнки алар үзебезнеке, Заркентныкы!

Глория...

Рушан аның фоторәсемен эзләп табарга теләде дә, аннары кире уйлады: нигә кирәк? Теләсен генә — ул һәрвакыт аның күз алдына килә дә баса.

Рушанга кинәт кенә Заркентның язгы җил исе тоелгандай булды, бу шәһәрнең җиле дә үзенә генә хас үзенчәлекле — Заркент таулар белән уратып алынган, бары тик Архангаран белән Ташкент ягына таба гына киңиркен дала сузыла. Ә тауларда язларын алсуланып, миндаль һәм чикләвекләр чәчәк ата, карт алма бакчалары, мул кар күмеп киткән шикелле, ак күбеккә батып утыра, бу күренеш шактый гектарларга шулай сузыла. Шау чәчәктәге миндаль һәм алмагач исләре, күкрәп яшелләнгән тау битләреннән искән җил белән аралашып, шәһәр өстенә ишелеп төшә, болай да кайнар йөрәкле яшьләрне тәмам исертә.

Әйе, алар Глория белән язда танышканнар иде. Рушан ул чакта өлкән прораб булып эшли иде инде. Ул эш көне булган шимбәләрне яхшы хәтерли — бишкөнлек эш атнасы турында ул вакытларда әле сүзләр генә йөри иде.

Идарә башлыгы, төзелеш эшендә карт бүре, шимбәләрдә шелтәләп-туздырып ташлаулар белән мавыкмый, моның өчен һәр көнне мәҗбүри була торган планеркалар да җитеп ашкан. Киңәшмә азагында башлык, ачык тәрәзәләр аша карашларын урамга ташлаштыргалап

утырган мастерларына һәм прорабларына карап, канәгатьсезлек белдергәндәй итеп әйтеп куя:

— Күрәм, күрәм: уегызда яз, футбол да, теге... ничек әле... спидвей... Бөтен шәһәр акылдан шашкан, безнең стадионда кычкырышкан-акырышкан тавышлардан хәтта Ташкент зарлана, ди. Бетердем. Барыгыз, йөгерегез, бәлки, тавышларыгыз Мәскәүгә хәтле ишетелерлек булыр... Безнең гозерләргә дә колак салырлар...— ди. Ул үз кул астындагы халыкны гадәттәгедән кырык минутка алданрак җибәрә. Барысы да, малайлар шикелле, ишеккә ташлана, берсе өстенә берсе өелешеп, ишеккә сыймыйча тыгылышып кала, кайсыдыр бер түземсезе хәтта тәрәзәдән генә урамга сикерә...

Рушан ул истәлекле көнне чит төзелеш-монтаж идарәсе машинасына эләкте, «Яз» кунакханәсенә кайтып җитеп туктар-туктамастан, кузовтан сикереп кенә төште дә, өчәр баскычны берьюлы сикерә-атлый, үз катына очып менде. Аның күңеле дә, бүген тормышында ниндидер бик мөһим, гадәттән тыш хәл буласын сизенгән шикелле, уйнаклый-очына иде. Яшьлектә барысы да гади: душка кереп юынып чыктың, чиста-пөхтә күлмәк, үтүкләнгән костюм кидең, көзгегә бер карап, чәчләреңне тараштырдың да — син әзер, йончыткан тыгыз эш көне дә, үз яшеңә һәм вазифаңа караганда шактый күп уй-борчылуларың да гүяки бөтенләй булмаган.

Һәр чорның үз стиле, үз килеш-килбәте, үз модалары. Әгәр дә Рушаннан үз яшьлек чорын кыска гына сыйфатлап бирүне сорасалар, ул, уйлап та тормыйча, болай дип җавап бирер иде:

— Пөхтәлек-төгәллек һәм, мөгаен, һәрвакыт яхшырак булырга омтылудыр.

Көньяктагы шәһәрләрнең һәр урам чатында аяк киемнәре чистартучылар утырыр иде, хәзер елдан-ел аларның будкалары юкка чыга бара, элек алардан башка шәһәрләрне күз алдына да китереп булмый иде. Ә бит көзгедәй ялтыратып кигән аяк киеменә үтүкләнмәгән чалбар, керләнгән күлмәкләр бөтенләй ятышмый...

Аларның яшь шәһәре Заркентка иң соңгы модалы киемнәр киеп футболчылар — Тбилиси, Мәскәү, Ташкент егетләре килә. Команда футболга җаны-тәне белән бирелгән, менә дигән оста уенчы, һәрвакыт бик пөхтә, грузиннарга тумыштан ук салынган нәзакәтлелеккә һәм зәвыкка ия булган үз капитаныннан үрнәк ала. Хәзерге халыкара уеннарда да кырынмаган, гетр-оеклары сыдырылып төшкән, бөгәрләнеп-таушалып беткән футболкалы уенчы гадәти күренешкә әйләнде, ә Джумберның ко-

мандасыннан гап-гади уенга да пычрак бутсы-ботинкалар киеп бирәү дә чыкмас иде...

Радиоалгычын кабызып җибәреп, күңелле музыка тыңлый-тыңлый, Рушан ашыгып киенә башлады һәм кинәт кенә үзләре эшләп бетереп килә торган төп бинаның түшәмен штукатурлаучы кызларны исенә төшерде. Озын көн буе эшләп арыгач, бер теләгең дә калмаган, тизрәк тулай торакка кайтып караватка авасы гына килгән булырга тиеш, ә юк, яшьлек үзенекен итә, кызлар көн азагында да тыпырдап биештерә-биештерә, үзләре уйлап чыгарган ниндидер күңелле бер җырны җырлый-җырлый эшлиләр, җырларының кабатланып килгән кушымтасы да шаян-шук иде: «Әй шимбәкәй! Әй шимбәкәй-чибәркәй!..»

Ә урамда шимбә киче үзенең хокукларын яулый бара: бакча ягыннан музыка яңгыраганы ишетелә, урам фонарьлары кабына. Рушан да ашыга төшә. Аның үзе яратып ял итә торган урыннары бар иде. Шуның өстенә ул шәһәргә мотоциклчылар килгәнен дә белә — афишалар иртәгә зур ярышлар-узышлар буласын вәгъдә итә, анда атаклы кунакларны да күрергә мөмкинлеген чамалый иде.

«Энҗекәй»гә якынлашып килгәндә, ул музыкантларның уен коралларын көйләү тавышларын ишетте, идәннән өскә таба көчле утлар белән яктыртылган һәм, чынлап та, ачып куелган галәмәт зур энҗе кабырчыгына охшаш сәхнә, алсу-нәфис мәрҗән төсе белән ялтырап, ерактан ук сиңа бәйрәм күңеллелеге вәгъдә итеп тора.

«Энҗекәй»нең әнә шулай утлар яктысында матур төсләр белән уйнаклап торуы архитектор табышыдыр, мөгаен. Кафе башта ук архитектор тарафыннан күп кешелек итеп уйланылган, аерым сайланган катлам өчен генә булмаган, чөнки шәһәрдә — тулай торак өстендә тулай торак дигәндәй, ә Заркентта тугыз ай җәй, менә дигән матур саф һава тора, ни өчен әле халыкны тимер-бетон читлекләргә һәм пыяла аквариумнарга куып кертү кирәк?

«Энҗекәй»нең гигант кабырчыгы кафедагы урыннарның өчтән берен дә капламый. Зур идәне, төрле калынлыктагы бакыр пластиналар батырылып, секторларга бүленгән, ялтыратып шомартылган ул пластиналар идән өстендә ачык алтын сызык булып сузыла. Һәр секторга үзенә аерым бер төстәге мәрмәр вагы тутырылган һәм ул шомартып катырылган, сектор уртасында шул ук алтын сызыклардан үзенә генә хас экзотик чәчәк ясалган. Өстән караганда ул алтын кушып тукылган зур келәмне

хәтерләтә, келәм өстендә — дүрт ачык кызыл түгәрәк, шулар арасына төрле формадагы һәм төрле зурлыктагы өстәлләр төрлечә итеп тезеп куелган, һәр секторның аерым бию мәйданчыгы да бар. Сирәк кенә була торган явымлы көннәрдә яки көтелмәгән язгы яңгырларда энҗе кабырчык астына сыймый калган кунаклар нәүмиз булмасын өчен, һәр секторның аерым бер урыныннан, мәрҗән кабырчыкның үзе шикеллерәк, гаҗәеп тропик агач «үсеп» чыккан, аның зур-зур әкәмәт кызык яфраклары калган барлык өстәлләрне дә каплап тора.

Рушан ишек янында тонык кына яктыртылган мәйданчыкта тукталып калды һәм өстәлләрне күзли башлады — бүген монда аның байтак танышлары булырга тиеш иде. Кинәт аңа дәштеләр:

— Рушан, кил безнең янга! — Экзотик агач астындагы бер өстәлдән аңа Джумбер, Тамаз Антидзе, Роберт Гогелия — «Металлург» командасының кырый һөҗүмчеләре чакырып кул изи иделәр.

Дасаев елмайды, чакыруларын кабул итеп, кулын күтәреп сәламләде. Өстәл янына якынлашкач, ул Роберт каршысында үзенә аркасы белән утырган кызны күреп алды. Кызның аккошныкыдай озын ак муены менә-менә сынып китәр төсле, авыр чем-кара чәчләре тыгыз һәм матур итеп баш артына өеп куелган иде.

— Сез таныш түгелмени? — дип гаҗәпләнеп сорады Джумбер, Рушанның кызга кызыксыну белән караганын сизенеп.— Глория, гафу ит, таныш бул: Рушан — безнең дустыбыз һәм бер үк вакытта зур начальнигыбыз да, тормышта андый хәлләр сирәк була,— дип шаяртып таныштырды.

— Глория.— Кыз, урыныннан күтәрелә төшеп, бераз кызларга хас чытлыкланыбрак, тар өстәл аша Рушанга кулын сузды, егет, аның йөзеннән күзләрен алырга кыймыйча, кулының нечкә беләзеге тирәсеннән үбеп алды. Кызның йөз чалымында кемгәдер охшашлык бар иде шикелле.

Рушан аңлап алды: кыз Тамарага искиткеч охшаган иде, әйтерсең лә табигать аңа гомерлеккә югалткан кадерлесен кайтарып бирергә теләп, шаяртырга уйлаган иде.

— Димәк, сез футбол тренеры, командагызның ничек ял иткәнен карарга кердегезме? Хәбәр итәм: Тамаз бишенче сигаретын кабызды инде, менә төпчекләре барысы да тәмәке көллегендә ята. Бәлки, сез килгәч, бераз тыела төшәр, юкса «БТ» сигаретын кабы бушаганчы тартып бетерүе бар...

— Шундый чибәр, акыллы да, диләр үзеңне, ә баксаң — гап-гади әләкче икән,— дип елмаеп, кызны бүлдерде Тамаз һәм кабыннан тагын бер сигарет тартып чыгарды.

— Мин тренер түгел, Глория...

— Джумбер, тагын шаярттыңмы? Син бит ачык итеп әйттең, Рушан — безнең начальник, дидең...

— Кадерлем, ул безнең, чынлап та, иң зур начальнигыбыз. Туендыручыбыз син безнең...— дип, Джумбер белән Тамаз, сөйләшеп-нитеп тормастан, уен уйнагандай итеп, икесе ике яктан Рушанны кочып алды.

Хәзер инде үзен өчәүләп шаярталардыр, дип шикләнгән кызның аптырап калуын күргәч, Рушан, ул үпкәләмәсен өчен, ашыгып аңлатуны кирәк тапты:

— Бер яктан караганда, мин аларның башлыгы да кебек. Үзләрен бик еш күрмичә, бары тик шушында яки «Космос» кинотеатры янында һәм, билгеле инде, уеннарын караганда гына күрсәм дә, һөҗүмчеләрнең айлык хезмәт хакларына нарядларны мин ябам. Бу өч бөркет минем төзелеш участогымда эшлиләр булып санала. Джумбер — алтынчы разрядлы балта остасы, ул капитан, лидер. Тамаз белән Роберт бишенче разрядлылар, бераз түбәнрәк, аз туп кертәләр...

Гомуми күңеллелеккә кушылып, ул да шаярта башлады һәм янә Глориягә генә карап:

— Әгәр алар үзләрен бүген әйбәт тотмаса һәм яныбызда утырган бердәнбер кызга тиешле игътибарны күрсәтмәсә, мин аларның разрядларын, һичшиксез, төшерәчәкмен. Безнең башлык әйтә, иң нәтиҗәле сугу — кесәгә сугу, ди. Ә сез, капитан, мәкерле штраф туплар тибү остасы, ничек уйлыйсыз?

— Глория, күзләрегездә яшьләр күрәм, кирәкми, еламагыз, безне вакытыннан алда кызганмагыз әле. Рушан әйбәт кеше ул, футболны да бик ярата, андый әшәке адым ясамас, безгә этлек эшләмәс...

Джумберның бу шаяртуына да өстәл тирәсендәгеләр дәррәү көлеп җибәрделәр.

Мыштым Роберт Джумберның артыннан официант кызга нindидер ым-шымнар ясап алды, официант Рушанга бокал һәм зур вазага таудай өелгән куе-кызыл, дымлы черешня китереп куйды.

— Димәк, сез төзүче? — дип сорады Глория, ни өчендер шатланып.

— Әйе, өлкән прораб.

— Ә без сезнең белән бераз коллегалар икән бит, мин — архитектор. Ләкин мин төзүчеләр белән гел сугышып

торам, тыныч кына эшләп булмый. Алар миңа: «Утыз яшьтә инфаркт сугачак сезне...» — диләр...

Ул кинәт Тамаздан урыннарын алышып утыруны үтенде, Рушан янәшәсенә күчкәч, хыялланып, сүзен дәвам иттерде:

— Әгәр дә мин шәһәребез өчен үтә дә шәп ниндидер гадәти булмаган берәр нәрсә иҗат итеп, сез шуны төзеп бирсәгез, нинди шәп булыр иде! Сез мине инфарктка ук җиткермәссез, аңларсыз кебек тоела,— дип чытлыклanыбрак, кулын Рушанның җилкәсенә салып, сүзен тәмамлады ул, әмма Рушан ни өчендер аның күзләрендә моңсулык күрде.

«Сәер кыз...» — дип уйлады ул.

Алардан ерак түгел күрше секторда, берничә өстәлгә таралышып, мотоциклчылар һәм атаклы спортчыларны озатып йөрүче техник хезмәткәрләр утыра иде.

— Миңа Кадыйровны күрсәтегез әле,— дип үтенде Глория.

— Әнә кара, «китлар» аерым утыра — оркестр янәшәсендә,— дип әйтеп куйды әлегә кадәр сүзсез утырган Роберт.

Зур банкет өстәле тирәсендә җиде кеше иде. Өлкәнрәкләре — костюм-галстуклардан, яшьрәкләре джинсы чалбардан һәм атаклы спорт фирмаларының кычкырып торган эмблема-тамгалары сугылган пуловерлардан, Карденның бертөсле күлмәкләреннән иде. Бу мода әле тагын унбиш еллардан соң гына безгә керәчәк. Боларның дөньяны күргәннәре сизелеп тора. Артык шаулашмый гына, үз дәрәҗәләрен белеп кенә утыралар.

Оркестр уйнап җибәрде. Тамаз, иптәшләреннән гафу үтенеп, күрше өстәл янындагы бер кызны биергә чакыра китте, аның үзен ул өстәлгә кич буе дәшеп утырган иделәр.

— Мин Кадыйров белән биер идем. Мин ырымнарга ышанам — кайчандыр ишеткәнем бар: күренекле кешеләр белән аралашу уңыш китерә икән,— диде кинәт Глория. Күрәсең, уйлары белән ул «Энҗекәй»дә түгел, әллә кайларда иде инде.

— Биергә теләсәң, чакыр соң,— диде Джумбер, тыныч кына, кызның сүзләренә артык әһәмият бирмичә.

— Ә кире какса? — дип куркынып әйтеп куйды Глория.

Аның бу сүзләреннән Рушан тагын да гаҗәпкә калды.

— Синеме? — дип ышанычсызрак һәм гаҗәпләнебрәк сорады Джумбер һәм киң итеп елмайды: — Глорияне кире каккан егетне күрергә теләр идем мин!

— Әй, ни булса, шул булыр! — диде кыз.

Аның әле генә кыюсызланып, икеләнеп-шикләнеп утырганына да ышанасы килми иде.

Бер минуттан Джумбер Рушанга дәште:

— Кара әле, Рушан, ничек матур бииләр, иске дуслар кебек ничек чөкердәшәләр! Глорияне Габдрахманнан озынрак дип әйтеп буламы әллә? Искиткеч әдәплелек, гүзәллек-нәфислек, партнерны кимсетмәү тойгысы, ә?! Ничек шулай булдыра, диген? Ә чибәрлеге... Кара, Рушан, гашыйк булып куя күрмә, мондый кыз без егетләр өчен — бәхет тә, һәлакәт тә, туган... Үзенең сөйкемлелеге өстенә, ул әле үтә дә талантлы, син моңа үзең дә ышанырсың әле, сез коллегалар бит...

Алар кичнең калган өлешен ике өстәл бергә кушылып үткәрделәр, Глория бердәнбер кыз булып кала бирде. Кунакларны кунакханәгә кадәр бергәләп озатып куйдылар, тегеләр юл буе Глорияне: «Иртәгә кем өчен янарсың-көярсең?» — дип интектереп бетерделәр. Ә кыз, уйлап та тормый, елмаеп:

— Заркенттагы барлык кешеләр кебек, мин дә Габдрахман өчен,— дип кенә җавап биреп барды.

Бу соклангыч кызның мөлаем ягымлылыгыннан югалып калган, болай да тартынучан Кадыйровны шул җавабы белән тагын да каушата иде Глория.

Кунакханә янында теләмичә генә саубуллаштылар — мотоциклчыларны иртәгә авыр көн көтә иде. Джумбер Рушанга мөрәҗәгать итеп үтенде:

— Рушан, зинһар, Глорияне озатып куй инде, мин бүген тренер урынына калган идем, үзем отбойга соңга калсам — яхшы түгел, иртәгә бик иртә күнегүләр дә бар. Йоклап калмасаң — кил, бергә туп тибәрбез...

Рушан җае килгәндә аларның күнегүләренә йөргәли, икегә бүленеп уйнауларына катнаша иде...

Егет белән кыз кешесез урамнардан атлап китте. Глория кинәт сорап куйды:

— Сиңа «Энҗекәй» ошыймы? Мин архитектурасын, интерьерын күздә тотам.

— Сүз дә юк, искиткеч кафе, яшьләргә фарт килде.

— Нигә соң син алай булгач, кич буе мине котларга да теләмәдең? — дип көйсезләнебрәк сорады кыз.

— Нәрсә белән? — дип аптырап калды Рушан.

— Син бер ай элек «Энҗекәй»нең ачылу тантанасына килмәгән идеңмени?

— Минем икенче сменам башланып килә иде, бара алмадым шул, ул вакыйганы ишетүен ишеткән идем.

— Ә, менә эш нәрсәдә икән,— диде Глория.— Архитекторы кем икәнен ишеттеңме соң?

— Ишеткән кебек идем, ниндидер әрмән фамилиясе бугай.

— Кароянмы?

— Нәкъ шулай! Җитди фамилия, яңгырый да, мөгаен, танылган архитектордыр.

Кыз барган җиреннән туктап калды, шаяртыбрак бөгелә-сыгыла кулын сузды:

— Танышырга рөхсәт итегез: мин — Глория Кароян,— диде.

— Димәк, син шул архитекторның кызы? Әтиеңне чын күңелдән минем исемнән котла — сокланырга лаеклы эш.

— Рушан, тагын бер рәнҗетсәң — мин бөтенләй китеп барам, син гомергә дә минем бәхилләвемне ала алмаячаксың.

— Син... «Энҗекәй»нең архитекторымы?! Шундый...— Рушан хәтта адымнарын буташтырып алды.

— Дәвам ит, дәвам ит... җитди түгел, димәкчесеңме? Их, бу ир-атлар, бигрәк тә төзүчеләре...— дип, тагын көйсезләнеп, әмма Рушанны шаккаттырганыннан канәгать калып, сүзен дәвам итте ул:

— Сиңа өстәмә мәгълүмат: Кароян, бәлки, әрмән фамилиясен хәтерләтәдер дә, әмма миндә әрмән каны юк, бик күп каннар катнашкан катнашуын: венгр, урыс, күбрәк немец каны. Минем ерак бабаларым — Европада танылган төзүче архитекторлар, Россиягә бер гасыр ярым элек килеп төпләнгән булганнар һәм менә хәзер, уннарча буыннардан соң, ихтимал, миндә аларның геннары уянгандыр, хәер, бу гасырда безнең ыруда архитекторлар булмаганы төгәл билгеле.

Рушан исе-акылын җыя алмыйча басып тора иде, бары тик:

— Ничек булдыра алдың моны, Глория? — дип кенә сорый алды.

— Сиңа, дөрестән дә, кызыкмы минем язмыш? — Глория аны култыклап алды: — Алайса тыңла... Мин биредә ярты ел диплом алды практикасында булдым. Шәһәр миңа, архитектор буларак, ошады: һәммәсе дә буш җирдә нульдән башланып ята иде, үземне күрсәтергә сирәк мөмкинлек туды. Миңа шәһәр ошаган булса, мин «Градострой»га ошаганмын икән. Практиканы шунда үтә идем. Институтны тәмамлагач, Заркентка килүемне үтенделәр. Безнең буынны, мөгаен, биюче буын дип йөртерләрдер, үзем дә биергә бик яратам... Сине хәлдән таидырмадыммы әле?

Глория Рушанның йөзенә күтәрелеп карады да бүленгән сүзен дәвам итте:

— Минем борынгы австро-венгр бабаларым заманнарында бию салоннарына биергә йөри торган булганнар, анда Штраусның үз оркестры уйнаган. Ләкин минем максатым башка иде: хәзер инде юкка чыгып, бетеп бара торган гадәти бию мәйданчыгы белән салонны берләштереп, нindидер алтын уртасын табасым килде, юкса салон мине бию араларында утырып ял итәргә, әңгәмәләр корырга мөмкинлек бирә торган өстәлләре һәм бәйрәмчә рухы белән генә кызыксындырган иде. Төп фикер-идеяне миңа шәһәр үзе бирде: аның климаты-һавасы, җиләк-җимешләр муллыгы һәм хәтта сусау — газлы һәм минераль суларга, туңдырмаларга даими мохтаҗлык... Нәкъ менә минем өчен генә әзерләп куелган шикелле буш урынны табып алгач, чын-чынлап комарым-дәртем кузгалды, менә шул төп этәргеч булды да инде. Кич саен мин шул ташландык буш җиргә киләм, күңелемнән кафены күз алдыма китерәм, әмма берсе дә әле ул түгел, мин теләгән түгел... түгел иде... Әгәр дә берәрсе күңелемә ошаса да, өсте-өстенә өелгән зур һәм авыр булып, кыйммәтле булып килеп чыга. Мин белә идем: корылма арзан булырга һәм ярты ел эчендә төзелеп бетәргә дә тиеш. Әйтәм ич, мин анда көн саен барып йөрдем — иртә таңда, кич кояш баеганда, көн уртасында, эңгер-меңгердә, әмма хәзер син кереп йөри торган «Энҗекәй»-не күрмәдем. Әле исеме дә юк иде.

Шул ташландык буш җирдә башыма тагын бер бик мөһим фикер килде. Шәһәр миңа аның ни-нәрсә буласын, нинди хезмәт башкарасын күңелемә салган булса, сайлап алган урыны хыялымның тормышка ашардай булуына ышаныч бирде. Мин кем соң әле? Менә шулай уйладым мин. Син елмайма, Рушан, миндә еш кына икеләнү-шикләнүләр була тора... Кем минем проектымны карар? Кем аны хуплар? Кем аны төзелешләрнең титул исемлегенә һәм кайсы елга кертер? Бертөрле генә һәм ышанычлы итеп мин бу сорауларның берсенә дә җавап бирә алмый идем. Әмма шуны беләм: иң яхшы очракта да боларны чишәргә күп еллар кирәк булачак иде. Ә миңа үземне хәзер үк күрсәтергә кирәк, көтеп тормыйча, менә шундый иҗат шаукымымы, дәртеме бар иде миндә. Мин аңлап алдым, проектны җәмгать башлангычы итеп эшләячәкмен, түләүсез, бушлай, ул минем шәһәргә бүләгем булыр. Мин үз эшемне комсомол шәһәр комитеты хөкеменә, яшьләр хөкеменә тапшырырга карар кылдым, ә нинди дә булса әйбәт, игътибарга лаек нәрсә эшләячәгемә шигем юк иде... Әйдә, бәя биреп карасыннар!

Төнге урам чатында көтелмәгәндә кабынып киткән кызыл светофор алдында тукталып, Глория сүзен шаяртуга борып әйтте:

— Менә шундый шөһрәт яратучан, үзсүзле кеше инде мин, Рушан! — диде.

Һәм яңадан сөйләп китте:

— Бу фикерләремне мин практика җитәкчем белән уртаклаштым. Билгеле инде, бу сөйләшү бик яшерен сер итеп тотылды. Миңа аерым бүлмә бирделәр, шунда иртән кереп бикләнәм дә төн уртасына кадәр утыра идем. Беркем комачауламый, фикерләремне чуалтмый-таркатмый — баш архитектор барысына да минем махсус эш белән утыруымны гына әйтә.

Китәремә бер атна калганда, баш архитектор мине комсомол шәһәр комитеты секретаре белән очраштырды. Ул синең кебек үк төзүче булып чыкты. Монысы минем эшемне тагын да җиңеләйтеп җибәрде. Мин аны үземнең идеям белән кабызып җибәрә алдым. Секретарь миннән бары тик шәһәр комсомол активы алдында да шулай янып-ялкынланып, ышандырырлык итеп сөйли алу алмавымны гына сорады. Мин теләсә нинди югары дәрәҗәле урыннарда да фикерләремне ярып салырга әзер икәнлегемне әйттем. Секретарь егет алдында батырайсам да, очрашу алдыннан ике көн буена бик нык дулкынланып йөрдем. «Градострой»дагы яшь коллегаларым күргәзмә стендларны ясарга булыштылар, бу эшкә аларның тәҗрибәсе җитәрлек иде. Әмма мин шунысын да белә идем: күрсәтеп бирү генә җитми, ышандырырга, исбат итәргә кирәк булачак. Мин чыгышымны кәгазьгә төшердем — машинкада бастыргач, ун бит килеп чыкты ул. Үз проектымдагы һәрнәрсәнең үзлегеннән генә тумаганын, ә менә нәкъ Заркент өчен, Урта Азия шартлары өчен исәпләп эшләнгәнлеген аңлатырга тырыштым.

Җыелышны мин проектымнан бигрәк, ышанычлы итеп, белеп сөйләвем белән үземә караттым шикелле. Бик күп сораулар бирделәр, залда бит күпчелеге төзүчеләр утыра иде, ә мин сораудан сорауга кыюланып җавап биреп тордым. Мин хәтта төзелешкә акча туплау өчен ничә якшәмбе өмәләре үткәрергә кирәк булачагына хәтле белә идем. Әлбәттә, җыелыш эскизларымны да, макетымны да ошатты. Шул очрашуда Джумбер белән дә таныштым. «Металлург» командасы «А» классындагы командалар белән буласы язгы контроль уеннарыннан җыелган керемне тулысы белән яшьләр кафесы төзелешенә бирәчәген беренче булып ул әйтте шикелле.

Мин бик бәхетле идем, канатланып кайтып киттем. Төзелеш штабыннан Ленинградка ел буе шалтыратып тордылар: эшлекле сөйләшүләр, киңәш-уңаш итешүләр иде бу. Кышкы каникулда комсомол шәһәр комитеты мине үз хисабына Заркентка яңадан чакыртып алды, мин сызымнарны карап имза салдым, проектны төзелеш буласы урынга бәйләдем-яраклаштырдым. Ә институтны тәмамлап килгәч, хәтта соңгы бизәкләү-бизәү эшләренә автор буларак күзәтчелек итәргә дә өлгердем. Менә бөтен тарихым шул. Бәлки, мин кайчан булса да бер, «Энҗекәй»не бөек төзүче Рушан Дасаев беләи танышу өметеннән иҗат иттем, дип тә сөйләрмен әле,— дип, Рушанны үртәп, сүзен тәмамлады Глория.

Ләкин Рушан аның шаяртуына артык игътибар да итеп тормады. Нинди сәләт, нинди зирәклек, булдыклылык икән бу кызыйда! Һәм ул Глориягә беренче күргәндәй итеп яңадан бер карап алды: чибәр, көяз, нәфис, искиткеч сөйкемле, эшлеклегенә ишарә итәрдәй бер чалымы да юк, үзенең башкалардан аерылып торуы, өстен булуы йөзендә берничек тә чагылмый. Ничек шулай булдыра ала, диген?!

Рушанның кыздан аерыласы килми, һаман аның сөйләгәннәрен тыңлыйсы килә, чөнки ул эше турында гына түгел, үзе турында да сөйли иде бит.

— «Энҗекәй» синең диплом эшең булдымы?

— Юк. Мин аны Ленинградта телгә дә алып тормадым. Менә якын көннәрдә Ташкенттан төсле фоторәсемнәр төшерүче оста фотограф килергә вәгъдә иткән иде. Ул «Энҗекәй»не төрлечә төшереп биргәч, мин ул рәсемнәрне институтыма җибәрәчәкмен. Анда укып чыккаииарның эшләрен куя торган заллар бар. Ә диплом эшемне актуаль түгел, кирәксез дип таптылар, көч-хәл белән генә якладым мин аны.

— Нәрсә кыландырган идең соң? — дип кызыксынды Рушан.

— Әй, анысының тарихы кыска. Сиңа, мөгаен, минем очышларым-ачышларымны гына түгел, егылышларым-ялгышларымны да белү кирәктер, юкса эреләнеп-тәкәбберләнеп китәрмен йә! Тик шунысын исеңдә тот: бу хакта минем әле беркемгә дә сөйләгәнем юк иде...

— Институтта мин бераз волейбол уйнаштыргалап йөрдем, хәтта бервакыт, өченче курста укыганда, җыелма командага да эләктем. Миңа фарт килде — командабыз студент уеннарына Ташкентка барасы булды. Бу минем беренче зур сәяхәтем иде, әле үзе Урта Азиягә тагын. Билгеле, безгә Бохара белән Сәмәркандны да

күрсәттеләр. Менә шул чагында мин Үзбәкстанга гашыйк булып кайттым, шуңа күрә практикага да Заркентны сорап алдым. Мондагы күп нәрсәләрнең искиткеч икәнлеген сиңа сөйләп торасы да юк инде. Рушан, көлмәм, дип сүз бир. Бирәсеңме?..

Шуннан шул... Булачак архитектор күзлегеннән карaганда, Үзбәкстандагы сәяхәттә мине иң сокландырганы нәрсәләр булды соң? Гүр Әмир, Биби ханым, Сәмәркандның Җәмигъ мәчете, Бохара әмиренең җәйге резиденциясе, «Күкелдаш» мәдрәсәсе яки Ташкенттагы Иске-Жува базарымы? Юк, боларның берсе дә түгел. Минем исем киткән әйбер... үзбәк наны, үзбәк көлчәсе булды. Әйе-әйе, гаҗәпләнмә, гап-гади көлчә. Шуннан матур әйберне гомеремдә күргәнем, шуннан тәмле ризыкны гомеремдә ашаганым булмаган икән. Үзе кайнар, үзе бераз кызарып пешкән, өстендә сипкел-сипкел кыздырылган көнҗет орлыклары, үзе ак, күпереп тора, ә исе, исе — һушларыңны алырлык! Могҗизаның нәкъ үзе инде менә! Шәрык базарында иң тотрыклы, иң көчле ис нәрсә исе дип уйлыйсың? Үлән-сәлән, тәмләткеч-фәләннәр яки җиләк-җимеш исләреме? Юк, белмәдең, мин сынап карадым — әнә шул нан-көлчә исләре! Теләсә кайсы базарга барып керсәм дә, кайда икәнлеген сорап тормастан, көлчә пешереп саткан урынны табачакмын мин. Исеннән.

Шулай исем-һушым китеп йөргәч, ул көлчәләрне ничек пешергәннәрен беләсем килмиме инде! Минем кызыксынуым шулкадәр ихлас булгандыр, мөгаен, мине көлчә сатучыларның берсенә кунакка чакырдылар. Шунда мин беренче тапкыр тандырны — көлчә пешерә торган мичне күрдем. Аны утка чыдам махсус кызыл балчыктан эшләнгән зур чүлмәккә охшатырга буладыр. Ул тандырны хәзер дә әле вак һөнәрчеләр генә ясый икән, үзе, күп булса, бер квадрат метр гына урынны алып тора, һәр үзбәкнең ишегалдында бар икән ул.

Әмма көлчә пешерүчедән осталык, уңганлык, җитезлек-өлгерлек сорала. Хәер, һәр эштә дә кирәкле сыйфатлар инде болар. Гомумән, яхшы хезмәт, җиренә җиткереп эшләү сокландырмаска, ә гадәти көндәлек эш булырга тиеш, юкса бик ерак китә алмассыңдыр...

Нан-көлчә, тандыр, Ташкент мине диплом эшен үземчә бер кызыклы темага багышларга этәрде: «Пекарня-кибетләр» дип атадым мин аны. «Энҗекәй» белән чагыштырганда, моны эшләр өчен минем дөнья кадәр вакытым бар иде һәм мин әллә ничә вариант уйладым, үземчә иң яхшы дигәнен дә кире кактылар... Булмастай хыял гына бу, тормыш ихтыяҗларына җавап бирми, имеш. Бигрәк

тә соңгы сүзләре кимсетә иде: «Совет кешесенең тормыш ихтыяҗларына җавап бирми». Ә мин французлар өчен тырышкан идемме?

Күрәсең, диплом эшен исенә төшерүе Глорияне нык дулкынландырган иде. Рушан аның әле рәнҗеше-үпкәсе һаман да үтмәгәнен, күңелендә шырпы кебек кадалып торганын чамалап алды.

— Беләсеңме, Рушан, архитектор буларак нинди йомшак ягым бар минем? Үлсәң дә, белә алмаячаксың. Ихтимал, мин бервакытта да гүзәл сәнгать әсәрләре — шедеврлар иҗат итә алмамдыр, чөнки мин ирексездән гел үз эшләремнең киң катлам халык өчен булуын телим. Моның ачык мисалы — шул ук «Энҗекәй». Миндә хезмәткә менә шундый сәеррәк социаль мөнәсәбәт тамырланыр дип һич тә уйламый идем. Мин, мәсәлән, бөтен күңелемне салып орган залы яки шуңа охшаш берәр нәрсә эшли алмас идем, юкса орган музыкасын аңлыйм да, яратам да үзем. Әти-әниләрем белән Рига култыгында, диңгез буенда ял иткәндә, Домский соборда үткәрелә торган бер генә концертны да калдырмый идем... Моның бик отышлы эш буласын да беләм: орган концертларына йөрүче халык теләсә кем түгел бит, минем эшемне лаеклы бәяләрләр, исемем телдә булыр иде. Ләкин андый заллардагы тар мохит, аерым элита рухы, сайланган зыялы катламга минем яраклашырга тиешлегем, үземне ачып салып, өлешчә булса да, иҗатчы буларак үз зәвыгымны сеңдерә алмавым күңелемне кайтара. Юкса бу минем танылган, күренекле шәхес буласы килү теләгемне һич кенә дә юкка чыгармый. Беләсеңме, «Энҗекәй»не бизәкләү-бизәү эшләре бетеп килгәндә, мин кинәт кенә шуны аңлап алдым: анда ял итәргә йөрүчеләрнең берсе дә, беркайчан да: «Кем эше икән бу?» — дип сорамаячак бит. Бу ачыш мине бер дә пошаманга төшермәде, чөнки мин «Энҗекәй»гә кергән яшь кешенең, күбрәк провинциал кешенең, гаҗәпләнгән, югалып калган һәм шул ук вакытта сокланулы шатлыклы карашы минем хезмәтем өчен бүләк булыр, ә иҗатым аңа тәүге эстетик дәрес шикеллерәк тәэсир ясар дип ышана идем. Мин сиңа үземнең тормышка булган карашларымны сөйлим, нәкъ шул карашларым аркасында диплом эшем харап булды да бит. Хәер, аңа әйләнеп кайтыйк әле...

Шулай итеп, Ташкентта күргән ун тиенлек нан-көлчә минем исемне китәргән иде. Теләсә кайсы үзбәк чәйханәсендә бер чәйнек чәй — биш тиен. Әгәр дә якында чәйханә булса, Үзбәкстанда кешегә тамак ялгап алырга унбиш тиен җитә. Менә шундый уйлардан соң, кечкенә

пекарня-кибетләр эшләү фикеренә килгән идем дә инде мин. Аларны мин күңелемнән студент тулай торакларында, стадионнарда, зур кинотеатрларның фойеларында, вокзалларда, аэропортларда һәм хәтта аерым кварталларда булыр дип күрә идем. Билгеле бер сәгатьләрдә шул пекарня-кибетләр кайнар нан-көлчә, ләвәш, хачапури, чурек, икмәк,— хикмәт исемендә түгел, ә җисемендә,— кыскасы, шундый ризыклар пешерәләр. Мичтән генә чыккан кайнар ризыктан авыз итүчеләргә, әлбәттә, кайнар чәе дә булсын. Һәр җирдә шулай булса, ипине сакларга, яратырга кирәк, дип, акыл сатуның да хаҗәте калмас иде.

Менә шул унбиш тиен, аннары безнең галәмәт иркен-мул кылануыбыз харап итте дә инде мине, Рушан. Мине вакчылланууда, халкыбызның һаман саен үсә барган ихтыяҗларын аңламауда һәм мөмкинлекләребезнең асылын белмәүдә гаепләделәр. Диплом кабул итү комиссиясен бигрәк тә минем, соңыннан чыгып, көлчәле чәй янына атаклы Вологда маен һәм кара уылдык та өстәргә мөмкин бит, дигән искәртүем чыгырыннан чыгарды. Югыйсә болары бөтенләй башка җыр иде инде. Мин бит икмәк пешерү промышленностен юкка чыгарырга җыенмаган идем,— оппонентларым мине хәтта шулай дип тә гаепләделәр,— мин кешеләргә бәйрәмчә тәмле икмәкләр пешерү турында гына хыялланган идем, ә бәлки, минем Даша түтәйле яки Кодрәт әкәле кечкенә пекарня-кибетләрем ипи пешерүче зур завод-фабрикаларны да үз эшләренә яңача карарга өйрәтер, ипи-ипекәйгә булган караш алардан гына тормаганын, ипине саклап тотарга кирәк, дип пропаганда алып бару — акчаны җилгә очырту гына икәнен аңларлар дип уйлаган идем.

Менә шундый җиңелү ачысын татыдым мин, Рушан. Шундый фиаско... Ләкин борынгы бабаларым минем өчен кызармаслар иде, дип уйлыйм мин, сынатмадым, сынмадым, үземнең хаклыгыма бер минут та шикләнмәдем һәм хәзер дә шикләнмим. Мөгаен, әле вакыты гына җитмәгәндер, бары тик шул гына. Ә бәлки, шундый пекарня-кибетне син төзерсең, Рушан?..

Глория гадәти блоклардан салынган йортның бер ишек төбендә тукталып калды.

— Ә без синең белән бу кварталны алты мәртәбә урап әйләндек инде,— диде.— Менә шушында яшим мин, икенче катта. Керергә чакырмыйм, соң инде, синең күнегүләргә соңга калуыңны теләмим. Уртак дусларыбыз булуы бик әйбәт. Сау бул, танышуыбызга бик шат мин, Рушан...

Һәм ул, ашыгып хушлашып, ишек караңгылыгына кереп югалды. Рушан, икенче каттагы бер тәрәзәдә ут кабынып, шул ут яңадан сүнгәнче китмәде, басып торды.

Ул Заркентның кешесез, йокылы урамнарыннан, бүгенге гаҗәеп кич, көтелмәгән танышу турында уйлана-уйлана, атлады да атлады. Шулай уйланып йөри торгач, үзенең яңадан «Энҗекәй» кафесы янына килеп чыкканын да сизми калды.

Тонык ялтырап торган идәннәрне сүрән генә яктыртып, анда-санда гына сирәк фонарьлар яна иде. Рушанга бер мизгелгә генә, моннан берничә сәгать элек булган шикелле, музыка һәм көлү тавышлары ишетелгәндәй булды. Ул киртәләп алынган койма аша эчкә үтте һәм «Энҗекәй»не хәзер бөтенләй башка күз белән караштыра башлады.

Шунда ул, биюләр өчен калдырылган кызыл түгәрәкне алтынсу сызыклар белән каймалап алып, ниндидер экзотик чәчәкне хәтерләткән бизәкнең хәзер бераз сәеррәк, ничектер серлерәк булып күренгәнен күрүдән битәр, эчке бер сиземләү белән тоемлады. Аннары Рушан, гомуми охшашлыклары булуга карамастан, һәр дүрт түгәрәк биюләр мәйданчыгының төсләре төрлечә икәнен абайлады. Игътибар беләнрәк карый торгач, шул төрле төсләрдән ясалган дүрт сызыкка, криптограммадагыча итеп, ике хәрефле монограмманың — «Г» белән «К»ның бик оста яшерелгәнен дә аңлап исе китте: «Глория Кароян...»

## XXXIX

Истәлекләргә бирелгән көнне Дасаев таң алдыннан гына йокыга китте һәм, ничәмә-ничә еллардан соң, беренче мәртәбә үзләренең туен төшендә күрде. Төсле слайд-рәсемнәр караган шикелле итеп, ул үзенең үткән тормышын карый башлады...

Глория Әдрән диңгезе буендагы Дубровник курортыннан, яшь архитекторларның халыкара конкурсыннан кайтып кына төшкән иде. Туй сәяхәтендәге яшь гаиләләр өчен диңгез буенда салыначак отель проекты Югославиядә Гран-при алган, Европаның конкурсны оештыручы атаклы төзелеш фирмалары, Европа архитекторлар ассоциациясе Глориягә әле тагын конкурста катнашучыларның иң гүзәле булганы өчен махсус приз да тапшырганнар иде.

Бер итальян фирмасы шунда ук проектны сатып алуга контракт төзеп, имзасын салды. Әрсезрәк итальяннар:

— Мондый гаҗәеп отель проекты иҗат итәргә сезне нәрсә, нинди уйлар этәрде? — дип сорадылар.

Глория:

— Мин үземнең туй сәяхәтемнең дә диңгез буендагы шундый отельдә төгәлләнүен теләр идем,— дип җавап бирде.

— Исемегез ничек сезнең? — дип кинәт сорап куйды фирма вәкиле. Аның башына ниндидер уй-фикер килде булса кирәк.

— Глория.

— Глория? — дип кабатлап сорады итальянлы һәм кинәт куанып кычкырып җибәрде: — Глория! Отель өчен моннан да матур исем табып булмастыр, менә дигән исем! Мондый отельгә шуннан да ятышлырак нинди исем булыр тагын? Ышаныгыз, сеньорина, без Италиядә һәм Франциянең Зәңгәр диңгез яры буенда дистәләрчә шундый отельләр төзербез, проектыгызның бер сызыгын да үзгәртмәбез...

Фотоаппаратлар черт тә черт итә, итальяннар шул мизгелдә үк эшләнгән фоторәсемнәрен сузып, Глориянең култамга-автографын куюны үтенәләр.

Фирма вәкиле дә фоторәсем сузгач, Глория әйтеп куйды:

— Отель минем исемемне йөртәсе булса, мин сезгә бик рәхмәтлемен, әмма аның кайсы төшендә булса да минем монограммамны күрсәтергә булмасмы икән? — Ул шунда ук фоторәсемнең артына «Энҗекәй»дә яшертен ясалган монограммаларының берсен фломастер белән язып та бирде.

Эшлекле фирма вәкиле шунда сорады:

— Бәлки, сеньорина отель маңгаена куелачак язулы такта үрнәген дә күрсәтеп бирер?

Кемдер кызга альбом һәм фломастер сузды.

Глория, уйлап та тормыйча, гадәти булмаган латин хәрефләре белән исемен язып та куйды. Исеменең сул ягына монограммасын өстәде.

— Ә төсе? — дип түземсезләнеп сорады фирма вәкиле. Алар арасында һөнәри сөйләшү бара иде.

— Куе кызылга алтын хәрефләр белән, ә монограмма — ак белән карадан. Ул яхшылык һәм явызлык символы булыр, хәрефләрнең кайсысын сайласагыз да ярый.

Бу гамәл шулкадәр тиз, бер минут эчендә башкарылды ки, хисчән итальянлы гаҗәпләнүеннән хәтта сызгырып куйды...

Шул төндә үк Рушанның кунакханәсенә халыкара телеграмма китерделәр, мөгаен, Заркентка бик үк еш килмидер андый телеграммалар. Глория дүрт кенә сүз язган иде: «Рушан, сөеклем, мин җиңдем!»

Өч ел таныш булып йөреп, аның әле бер тапкыр да Рушанга болай эндәшкәне юк иде.

Рушан Глорияне Ташкент аэропортында каршы алды, кызның мондый бәхетле чагын аның бүтән бервакытта да күргәне булмады. Глориянең уңышын «Энҗекәй»дә билгеләп үттеләр. Кафедан чыгып, төнге урамнарда йөргәндә, Рушан моңарчы әйтергә базмаган сүзләрен ярды да салды:

— Глория, чык миңа кияүгә! — диде.

Кыз өчен бу көтелмәгән тәкъдим булды, ахры, кайчандыр «Энҗекәй»дә Габдрахман Кадыйровны биергә чакыргандагыдай, бер мәлгә югалып калды. Әллә Рушанның тәкъдимен үлчәп-исәпләп, әллә, гадәтенчә, хыялларына бирелеп, озак җавап бирми торды.

— Рушан, сөйкемлем,— диде ул аннары, кинәт кенә моңсуланып, аның күзләрендә яшьләр күренде. Рушан искәрде: кыз «сөеклем» димәде. Глория дәвам итте: — Мин кирәкме икән сиңа? Йә, кара әле миңа яхшылабрак, нинди хатын, нинди хуҗабикә чыксын инде миннән? Дуамал, холыксыз, архитектурасы белән җенләнгән бер кеше бит мин. Син бит минем белән җәфаланып бетәчәксең, бөтен йөрәгем белән сине дә, үземне дә бәхетле итәргә теләсәм дә, мин моны булдыра алмаячакмын. Безнең гаиләнең бәхетле булырына мин бик-бик тә шикләнәм. Ләкин, ни генә сөйләсәм дә, хәзер мин бәхетле, әле миңа моңа кадәр беркемнең дә тәкъдим ясаганы юк иде... Башкалар синнән акыллырактыр шул...

Аның аптырап-югалып калуы тиз үтте, ул яңадан ирония күләгәсе артына яшеренде.

Рушан моны тоеп, үз сүзен әйтте:

— Син миңа җавап бирмәдең,— диде.

— Әй, булса-булмаса! — дип, яраткан сүзләрен кабатлады Глория, ул шунда ук үзгәреп, күңелләләнеп китте.— Инде син үз һәлакәтеңә үзең атлыйсың икән, менә минем шартым: әгәр бер атнадан, шимбә көнгә кире уйламасаң, тәкъдимеңне кабатласаң — мин сиңа кияүгә чыгарга риза. Мин сиңа котылу мөмкинлеген калдырырга тиештер бит инде, Рушан...— Шулай дип, ул кинәт кенә егетне үбеп алды да торып йөгерде.

Рушан аны куып җитәргә тырышмады, аның үз уйлары белән ялгыз каласы килә иде.

Атна авыр булды: градирняны — кайнар суны суыта торган яки тозлы суны парга әйләндерә торган корылманы тапшыралар, шуңа күрә өч смена эшләргә туры килә иде. Шимбәсе дә җиңелгә килмәде. Глория кайтып төшкәннән соң, алар әле кабат бер дә очрашмаган иделәр.

Шимбә көнне, идарә башлыгындагы киңәшмәнең озак-карак сузыласын чамалап, Рушан Джумберга шалтыратып алды. Капитанга ул үзенең уй-ниятләрен әйтеп тормады, бары тик «Энҗекәй»дә бәйрәмчәрәк әзерләнгән өстәл алып куярга һәм анда кемнәрне чакырырга кирәклеген генә исемләп әйтеп чыкты, кунаклар арасыннан Глория исеменә дә басым ясамады. Джумбер артык төпченмәде: «Грузинчамы?» — дип кенә сорады. Алар телендә ул, базардан үлән-сәлән, брынза, җиләк-җимеш, яшелчә ишесен дә алып, бай өстәл әзерләү, дигән сүз иде.

Рушан:

— Грузинча,— дип раслады.

Рушан «Энҗекәй»гә бераз соңлап барды, әмма киңәшмә аркасында түгел, ә чәчәкләр алып йөрүе аркасында. Кичке базарда ак розалар табылмады, чәчәк үстерүчеләрнең өенә барырга туры килде, чәчәкләрне аңа куагыннан кисеп алып кына бирделәр — ак розалар озын сабаклы, төнгә ябылган тыгыз-нәфис, зур төймәләләр булды, нәкъ шундыйларны Глориягә еш бүләк итә иде Рушан.

Ул кафега килеп кергәндә, кичә башланган иде инде. Аларның утырырга гадәтләнгән секторында зур банкет өстәленә ап-ак эскәтер җәелгән, гадәттә, «Энҗекәй»дә кабул ителгән нәрсә түгел иде монысы, дуслары барысы да җыелып өлгергән һәм күңел ача башлаган икән. Өстәлгә күз төшереп алгач ук, Рушан Джумберга карап, рәхмәт хисләрен сүзсез генә аңлатырга теләгәндәй, киң итеп елмаеп куйды.

Алар үзләренең кечкенә генә шатлык-уңышларын да шушылай билгеләп үтәләр, бу утыру да беркемне дә гаҗәпләндермәде, бүген бары өстәл баерак һәм бәйрәмчәрәк иде.

Глория Джумбер белән янәшә утыра, аның кояш алмый торган искиткеч ак тәне белән Белградтан алып кайткан бик матур ак күлмәге генә йөзенең башкалар күзенә чалынмаган борчулы-дулкынланулы аклыгын яшереп тора иде. Рушан моны шунда ук күреп алды. Глория янына килеп, аңа чәчәкләрен сузды. Чәчәкләрне кабул итеп алганда, кыз, башкаларга сиздерми генә, рәхмәт хисе белән аның кулын кысты һәм шау-шу арасында: «Рәхмәт, сөеклем!» — дип пышылдады.

Менә ич! Тагын «сөеклем» сүзе чыкты Глория авызыннан. Рушан эченнән генә куанып куйды: «Ярата ул мине... ярата...»

— Тагын бер уңышлы проектмы әллә, Глория? — дип сорады аларны күзәтеп утырган Тамаз.

— Син үзең тупларны шулай еш кертә алсаң икән,— дип, аңа җавапны Джумбер бирде, кунаклар көлешеп алдылар.

— Беләсем килә, нинди уңай белән болай матур утырабыз әле? Рушан, идарә башлыгы булдыңмы әллә? Яки безне Заркентта югары хезмәт хакы алучы рекордчы Силкиннар бригадасына яздыра алдыңмы? — дип сорады Джумбер, үзенең бүген ни сәбәпле шулкадәр тырышканын аңларга теләп.

— Картаясың, капитан, син: «Иң мөһиме — түземлелек, сабыр булу. Капкага таба тиктомалдан туп тибүне юләр дә булдыра ала, кайчан һәм кайда тибәргә кирәклеген оста уенчы гына белә», — дип әйтә идең түгелме соң? Син миңа кирәк чагында гына тибәргә бирмәдең бит инде болай булгач. Хәер, минем үземнең дә әйтәсе сүземне тизрәк әйтәсем килә...

Шул сүзләрдән соң Рушан торып басты, өстәл өстеннән күз йөгертеп алды да сүзен җитди генә дәвам иттерде:

— Дусларым, мин Глориягә тәкъдим ясадым, бүген без сезнең белән туй көнен кайчангарак билгеләргә икәнен киңәшмәкче идек, — диде.

Кунаклар шау-гөр килеп шаулаша башладылар. Хәтта оркестр да бер мизгелгә тынып торырга мәҗбүр булды. Роберт әйтерсең лә футбол кырындагы шикелле, яшен тизлеге белән өстәл яныннан атылды, кемдер: «Шампан шәрабы!» — дип кычкырган арада, ул инде шампан шешәсен күтәреп килеп тә җиткән иде, килә-килешли, әле оркестрга да нәрсәдер пышылдап өлгерде, оркестр, уйный торган көен бүлеп, туш уйнап җибәрде. Өстәлдән өстәлгә хәбәр тәгәрәде: «Рушан өйләнә... Глория кияүгә чыга...»

Глория өстәлнең Рушанга каршы ягында, Тамаз янында утыра иде, гашыйкларны янәшә утыртырга теләгәч, Тамаз киреләнергә тотынды:

— Бүген үтерсәләр дә, сине янымнан беркая да җибәрмим. Без Рушан ханны беләбез, ул яңадан һичкайчан да гүзәл кыз белән утырырга бирмәячәк. Ичмасам, ул безгә йә йолым, йә калым түләсен, аны бит күренекле архитектор белән без таныштырдык. Глория, шулаймы, әйт әле?

Глория җавапка кесәгә кереп тормады:

— Шуның өчен дә Рушан белән без сезне — Джумбер белән икегезне загста шаһитлар, ә туйда кияү егетләре булырсыз дип хәл итеп куйган идек, — диде.

— Алай булса, бирелəм, — диде Тамаз.

Дуслар урыннарын алыштырып утырдылар.

Таныш та, таныш булмаган кешеләр дә килеп, Рушан белән Глорияне котлый башладылар, туйлары кайчан буласын сораштырдылар. Тамаз ул сорауларга җавапны үзе биреп утырды:

— Кичке газетларны караштырып барыгыз, экстрен чыгарылыш булырга мөмкин...

Котлаулар бетеп, өстәл тирәсендә чагыштырмача тынлык урнашкач, Джумбер Рушаннан сорады:

— Шулай да туегыз кайчан?

Рушан, анык кына әйтә алмыйча, җилкәсен генә сикертеп куйды.

Шулчак мыштым Роберт мәҗлесләрнең алыштыргысыз, гомерлек тамадасы булган Джумбердан сүз бирүен сорады. Рөхсәт алгач:

— Минемчә, туй киләсе шимбәдә булса — нәкъ өстенә генә басачак,— дип сөйләп китте ул.— Аңлатам: беренчедән, сузып-нитеп йөртерлек сәбәп юк, икенчедән, чәршәмбедә безнең уеныбыз бар, беренче әйләнештәге соңгы уен, аннары — ике атналык тәнәфес-ял. Димәк, без, Рушан, синең күпчелек дусларың, тренердан һәм җәмәгатьчелектән шөлләмичә-шикләнмичә генә, иркенләп туегызда күңел ача алабыз. Мин, бүген шушында утыручыларның һәммәсен кертеп, туй штабы сайларга тәкъдим итәм, ә үземне штаб башлыгы итеп билгелим — гомеремдә бер булса да, түрә булып карыйм әле! Көзен мин сеңелемне кияүгә бирдем, тәҗрибәм бар. Джумбер, Тамаз, раслагыз сүзләремне... Рушан, Глория, безнең арадан сез беренче өйләнешүчеләр, сезнең туегыз калганнарыбызның һәркайсына өлешчә үз туена репетиция булыр. Туйны кайда үткәрү турында, ышанам, ике төрле фикер булмастыр — шушында, кәләшнең баласы «Энҗекәй»дә...

— Усал телләр, Глория «Энҗекәй»не үзе өчен махсус төзеткән икән, диячәкләр,— дип бүлдерде аны Тамаз.

Әмма Глория, гадәтенчә, аның авызын бик тиз япты:

— Юк, Тамаз, «Энҗекәй»не мин бары тик Рушан белән шушында танышыр өчен генә иҗат иткән идем,— диде.

— Бүлдермәгез әле,— диде Роберт.— Болай да тирләп чыктым. Кияү белән киленгә бер үтенеч: туйга чакырыласы кунакларның исемлеген сишәмбе көнне штабка тапшырасыз. Йомгаклап, игълан итәм: туй штабының киләсе утырышы чәршәмбедә, уеннан соң шушында булыр. Ул вакытка күп нәрсәләр ачыкланыр...

— Роберт, кадерлем, минем дә сиңа бер үтенечем бар: миннән алда өйләнә күрмә, яме. Минем туемда да синең начальник булуыңны телим,— дип, Тамаз дустын кочып алды.

...Туйдан соң ике көн үткәч, барысы да Глориянең өендә яңадан җыелдылар, Рушан кунакханәдән шунда күченгән иде инде. Музыка тыңладылар, туйдагы күңелле, кызыкмәзәк хәлләрне искә төшереп утырдылар. Глория, үзен урамда таныш-белешләре котлаганда берәр атаклы кешегә

карагандай итеп, артыннан кемдер карап калганда уңайсызлануын әйтте. Шунда Джумбер тәкъдим кертте:

— Сезгә туй сәяхәтенә чыгып китәргә кирәкмиме икән? Берочтан мондагы эсседән дә, игътибар итеп йөдәтүчеләрдән дә котылырсыз,— диде.

— Мин уйлыйм,— дип сүз кыстырды Тамаз,— итальяннар отель төзеп өлгермәгәннәрдер әле. Глория бит кайтуга ук Рушанны бәхетле итәчәген әйтеп, аларны искәртеп куймагандыр.

Джумбер елмайды:

— Синнән аермалы буларак, Тамаз, мин акыллы киңәшләр генә бирәм, шуңа күрә мин алтынчы разрядлы балта остасы-штукатур, ә синеке бишенче разряд кына. Дөресме, Рушан? Димәк, болай... Безнең алдагы уеннарга кадәр ике атналык ялыбыз бар, мин Гаграга, диңгез буена барып кайтырга җыенган идем. Анда миңа туган тиешле абзый яши, ике катлы йорты яр буенда ук. Әгәр шунда бергә китсәк, ничек булыр? Мин үз көннәремне бетергәч кайтып китәрмен, ә сез теләгәнчә яки ялыгыз беткәнче кала аласыз...

Шул рәвешле, яшь кияү белән кәләш диңгез буена барып чыктылар, шунда икееллык ялларын үткәрделәр, аларның бергә торган чакларының иң бәхетле көннәре булды ул.

Студентлык елларында каникулларын Гаграда үткәргән Джумбер шәһәрне яхшы белүе өстенә, тирә-яктагы барлык кечкенә шәһәрчек-курортларны да белә, өчесе бергә чакта Гаградагы бөтен дуслары белән дә таныштырып өлгерде, күп җирләрне күрсәтте.

Рушан белән Глория үзләре өчен Пицунданы, Джумбер китеп баргач, очраклы гына ачтылар. Ул елларда Гагра янәшәсендәге Пицунда борынында зур төзелеш эшләре башланып кына килә, хәзер бар дөньяга билгеле курорт нигез ташларыннан калка гына иде әле.

Глория булачак төзелешнең колачын шунда ук аңлап алды. Дөрес, әле проектта гына булган уналты катлы биналар аны артык шатландырмады — бик гадәти һәм бик бертөрле, аның карашынча, күз тукталыр нәрсә юк. Аның каравы урынын бик белеп, матур сайлаганнар, дип тапты.

Ял итү зонасын тулаем диңгез җилләре үтәли өрдереп тора, борынгы нарат урманы йортларга ук килеп терәләчәк. Аллеялар-сукмаклар, юл чатларындагы, мәйданнардагы сыннар, җәйге ресторан-кафелар сокландырды Глорияне. Әлбәттә, болар барысы да кәгазьдә һәм макетларда гына иде әле.

Ул Тбилисидән килгән архитекторлар белән бик тиз уртак тел тапты, еш кына кичләрен бергәләп Гаграда үткәрә башладылар. Ачык төсләрдәге ялтыравык йөгертелгән глазурьлы, гадәти булмаган гипсокерамик әкияти аждаһалар, сигезаяклар, сугышчан кыяфәтле әтәчләр, горур оҗмах кошлары, йокылы ябалаклар, тылсымлы тирмәләр, тау куышлары, саклялар корылып ята иде инде — Гаградан Пицундага кадәр булган арадагы автобус тукталышларына куелган бу эшләр ул вакытта ук танылган Зураб Каргаретелиныкы иде.

Кайвакыт кичләрен алар шул оста белән генә үткәрәләр, беренче танышкан көннәреннән үк Глория аның белән дуслашып өлгерде, алар ешрак калганнар бик аңлап та бетерми торган архитектура телендә сөйләшәләр иде.

Соңыннан грузин архитекторлары белән кәеф-сафа корып утырулары Рушанның төшенә дә кереп йөдәтте, тегеләр ни өчендер кинәт кенә: «Ачы! Ачы!» — дип кычкыралар, имеш тә, Рушан белән Глория, «Энҗекәй»дәге туйдагыча итеп, үбешәләр, имеш...

Кайбер кичләрдә, мәҗлеснең иң кызган чагында, Зурабның башына ниндидер уй-фикер килә, ул кабынып китә, аны инде бернинди көч белән дә тыеп калып булмый, иртәнгә чаклы калдыру турында сүз дә юк. Шунда ук машинасы табыла тагын, һәм ул төн уртасында Пицундага чыгып чаба, күңелендә кузгалган иҗади фикерен урынга барып тикшереп карау ихтыяҗы шулай йөртә аны.

— Шаукымлы ул,— ди Глория Рушанга Каргаретели турында һәм, әлбәттә, архитектор бары тик шундый булырга тиеш дип уйлый иде.

Алар Заркентка Тбилиси аша кайттылар. Икесенең дә Грузиядә беренче тапкыр булулары иде, киткәндә йөрәкләрендә бу искиткеч гүзәл якка, аның кешеләренә карата чиксез мәхәббәт хисләре алып киттеләр. Бик күп вакытлардан соң да, тормышта ваемсыз битарафлык белән очрашканда, Глория һәрвакыт:

— Грузиядә мондый хәл булмас иде,— дип кабатларга ярата иде, чөнки, аның карашынча, ваемсыз-битараф грузин — сирәктән дә сирәгрәк күренеш, табигатьнең гайре табигый аномалиясе... Моның шулай икәнлегенә Глориянең иманы камил иде.

## XXXX

Өйләнешкәннән соң өч ел дәвамында Глория, «Градострой»дагы төп эшеннән тыш, Заркент өчен Яшьләр йортының аерым проектын әзерләү белән мәшгуль булды.

Бу эш аңа бик авыр бирелде, вариант арты вариант яраксызга чыгарыла, аларның һәрберсе көчне суыра һәм дөнья кадәр вакытны ала иде. Каргаретелига һәм аның дус архитекторларына эшләрен күрсәтергә дип, ул ике мәртәбә Тбилисигә дә барып кайтты. Ул аннан канатланып кайта, грузин коллегаларының киңәшләрен, рекомендацияләрен язып тутырган блокнотларын күрсәтеп: «Аллага шөкер, таптым, ахрысы!» — дип куана. Әмма эшләнеп беткән эше бер атнадан яңадан яраксызга чыгарыла, киңәш-уңашлар соңлап әйтелгән, беркатлы булып күренә, блокнотлар да чүп чиләгенә ыргытыла.

Архитектураны шигърият белән, җыр белән тиңлиләр, ләкин ул әдәбият түгел, аны миллионнар күз алдында даими тәнкыйтьләп, тикшереп торып та булмыйдыр. Әһәмияткә ия әдәби әсәрләр кешеләрнең игътибарын бик тиз яулап ала, кайнар бәхәсләргә, фикер алышуларга сәбәпче була. Архитекторлар арасында да үз эшләре хакында шундый ук кайнар бәхәсләр булып тора, ләкин шунысын да әйтергә кирәк — ул бәхәсләр ябык ишекләр артында, тар мохиттә, тар даирәләр тарафыннан гына үткәрелә, кызганыч ки, архитекторларның иҗаты бик азларга гына билгеле булып кала.

Глория шуны аңлап алды: Заркент аңа үзен күрсәтергә мөмкинлек бирә бирүен, әмма иҗатчыга кирәкле мохиттән аера икән бит. Илнең танылган архитектура үзәкләрендә ниндидер бик җитди үзгәрешләр бара — ул моны, көтмәгәндә киң билгеле булып, шул рәвешле үрнәк өлге итеп алырлык яңа проектлар белән соңлап танышкач кына белде. Таулардагы коеп яуган язгы яңгыр ташкыны шикелле, бик тиз көч-куәт ала барган бу яңа архитектура алымнары Глория өчен искәрмәстән, капылт килеп чыккан хәл булды. Ул, үрсәләнеп-үртәлеп, бер үк сүзләрне кабатлый башлады:

— Талантсыз... төссез-йөзсез... стандарт тартмалар...

Эшеннән ул, Рушан кебек үк, соңарып кайта, еш кына тавышы карлыгып беткән була — архитекторлар югарыдан көчләп тагылган «кыйммәтле күрсәтмәләрне» алай тиз генә «ләббәйкәләп» күтәреп алырга тормыйлар, хәл кадәри тартыша-сугыша иделәр.

— Рушан, бәгырем,— дип кайнарлана Глория.— Яңа кварталларда төзеләчәк торак йортларның түшәмнәрен ике метр ярым гына калдыруны таләп итәләр бит, шундый проектны мин ничек итеп раслый алыйм ди? Заркентта болай да суларга һава җитми. Җәйләрен эсселек хәттин аша, кырык градуска кадәр менеп китә бит. Ә ванна белән санузелны бер кечкенә почмакка сыйдырырга тырышу,— Урта Азиядә күп балалы зур гаиләләрдә

ванна бүлмәсе әле кер юу урыны да булганлыгын искә-исәпкә алмау,— бу бит тулы мәгънәсезлек, абсурд!

Глория, ашавын да онытып, тагын ярсый башлый:

— Ә сез, төзүчеләр, нәрсә әйтерсез? Архитекторлар акылдан язган, диярсезме? Чынлап та, үз акылыбыздамы соң без? Үз акылыбызда, әмма файдасыз — ул проектка мин кул куймасам, икенче берәү рәхәтләнеп имза сала.

Глориянең язмышын бик нык үзгәрткән «архитектура артыклыклары» дигән гыйбарәне Рушан шул вакытларда хәтеренә сеңдереп калды да инде.

Үзбәкстанда берничә ел яшәп, Глория Урта Азия өчен эшләгәндә мәҗбүри булган үз принципларын, үз карашларын булдырган һәм үз ачышларын Рушан белән кайта-кайта уртаклашкан иде. Ул үз корылмаларының берсен дә яшеллексез күз алдына китерә алмый, юк, һәр проектка көчләп кертелгән шөкәтсез клумбалар һәм «Зеленстрой»ның агач-фәләннәренә яраклашмый ул, аларга йөз тотмый, вакытлар узгач та, үз корылмаларын Азиядәге иң җимергеч көчләрдән — ком-тузаннан һәм өтә торган эсселектән саклап калырлык, тирә-юньдә кирәкле микроклимат — җитәрлек дым, саф һава, салкынча рәхәтлек бирерлек бакча-парк архитектурасы булдыру турында хыяллана.

Үз иҗат җимешләрен Глория сусыз да күз алдына китерә алмый — фонтаннар, арыклар, каналлар, балалар чупырдарлык күл-буалар, эчә торган сулы фонтанчыклар булырга тиеш. Дөрес, ул бу очракта суны борынборыннан изге санаган һәм архитектура элементы итеп таныган традицион шәрык төзелешләренә таяна иде. Бу мәсьәләләрне үзе өчен гомерлеккә һәм берәгәйле хәл итү максатыннан,— ә Үзбәкстанда ул гомере буе яшәргә һәм эшләргә җыена иде,— Глория архивларда казына, Хива, Сәмәрканд, Бохараларны гына түгел, Китаб, Коканд ише бик үк билгеле булмаган шәһәрләрне дә йөреп чыкты, аксакаллар белән сөйләште-киңәште, аларга күрсәтә-күрсәтә, хәзерге бассейннарга охшаш, әмма үзенчәлекле-оригиналь хаузларның эскиз-рәсемнәрен ясады — ул хаузлар мәчет һәм сарайларның эчке ишегалларын бизәп торырга тиешләр иде.

Глория уйлаган фонтаннары һәм хаузлары булган ял итү бакча-паркларында күпсанлы уңайлы урыннар булыр: эсседән әлсерәгән кеше дә, кызыксынып кына йөрүчесе дә һәм, әлбәттә, гашыйклар да — һәркайсы үзенә кирәкле почмакны табар. Утыргычлар, айваннар, чәйханәләр, ачык һавадагы лавка-кибетләр — бер кешелек, ике кешелек, берничә кешелек һәм зур төркемнәр өчен дә булыр алар... Глория аларны бетмәс-төкәнмәс хыялы,

кыюлыгы белән дәртләнеп иҗат итә, алар формалары, материаллары белән генә түгел, оста урнаштырылулары белән дә сокландыралар, исне китәрәләр иде. Аның иҗат җимешләре җир астыннан гөмбәләр шикелле, нәкъ менә шушы урында гына, табигый рәвештә үсеп чыгалар иде бугай.

Шәрык кешеләренең фонтаннарга мәхәббәтен белгән Глория чәчрәгән су тамчылары килеп җитмәслек ераклыкта, фонтаннар тирәсендә кисәкләргә бүлгәләнгән таш бөҗра утыргыч-эскәмияләр уйлап тапты. Берәүгә дә комачауламыйча, шул утыргычларда су янында түгәрәкләнеп ял итеп утырырга мөмкин булачак. Әмма барыннан да бигрәк аның гашыйклар өчен тәгаенләгән чатырлары һушны алырлык иде. Челтәр сыман җиңел, язларын йөзем куаклары, үрмә гөлләр белән чорналып-үрелеп яшеллеккә күмелгән, тирәсендә алсу-кызыл, аксары роза чәчәкләре янып утырган бу чатырлар, әйтерсең лә шәрык әкиятләреннән җиргә иңгән иде. Андый чатырларны Глория ун вариантта эшләде, аларның һәркайсысы җир өстеннән күтәрелебрәк тора — берләре биегрәк, икенчеләре тәбәнәгрәк. Чатыр-беседкага борма-борма җиңел челтәр баскычтан күтәрел дә, шәһәрнең биналарын, мәйданнарын, фонтанлы бакчаларын хозур кылып, чөкердәшеп утыр. Биредә гашыйкларга беркем дә комачаулык итмәс.

Глория илдә бакча-парклар культурасы буенча белемле архитекторларның булмавына уфтана, үзенә, кайчан да булса, чын-чынлап нинди дә булса берәр бина тирәсендә скверлар, бакча-парклар ясарга җитди, зур эш бирсәләр, ни кызганыч, кая барырга, кем белән киңәшергә, кемнәрне бергәләп эшләргә чакырырга икәнен дә белмәве өчен борчыла. Җае туры килгәндә хыялланып та куя: әле шәһәр күтәрелгән арада, кайдадыр бер читтәрәк буш урында шәһәр яны бакчасы ясыйсы иде, ул тыныч кына үсеп җиткәндә, шәһәр үзе дә барыбер аңа килеп терәлер иде. Кирәге чыгарына ышанып, үзе өчен генә булса да, бакча-парк серләрен дә өйрәнә иде ул. Еш кына Ташкентка бара, андагы ботаник бакчада, Шредер институтында була, Урта Азиядә үсә торган агач-куакларның, чәчәк-гөлләрнең үзенчәлекләрен өйрәнә — үзе төзеткән бина тирәсендә нинди үсемлекләрнең ничә елдан соң күрер күзгә күркәм булып үсеп җитәселәрен, йөзенә кызыллык китермәслекләрен ачыклый иде.

Ләкин Глория зур әһәмият биргән агачлар да, су да төп максатка — бинаның үзенә интерьер хезмәтен үтәргә тиешләр. Яшьлегенә, эшләрендә чагылып-чагылып киткәләгән хатын-кызларча романтик хисләренә кара-

мастан, аңарда ир-атларча аек акыл, һәр нәрсәне дөрес исәпли белү тойгысы да бар — болары, мөгаен, борынгы бабаларыннан ук килгән сыйфатлардыр.

Бервакыт Гаграда җыелышып утырганда, Зураб Каргаретели болай дип әйткән иде:

— Авторы билгесез теләсә нинди проектка бер күз төшерү белән мин аның кемнеке — ир-атныкымы, хатын-кызныкымы икәнлеген ялгышмыйча әйтеп бирә алам...

Зурабның архитектор дуслары шунда көлешеп куйдылар, андый сиземләү тойгысының бер аңарда гына булмаганлыгын әйттеләр.

Ә Глория, нинди дә булса эшләрен архитектура буенча берәр конкурска җибәрсә, аңа гел ир-атка мөрәҗәгать иткәндәй итеп хат язалар иде. Конкурс жюриенда да, мөгаен, ир-ат эшен хатын-кыз эшеннән авырлыксыз аера алуларына шикләнмәгән кешеләр утырадыр югыйсә...

Глориядә ирләргә хас сыйфатларны Рушан беренче танышкан кичләрендә үк, «Энҗекәй» турында мавыгып сөйләгәндә тотып алган иде. Соңыннан да моның шулай икәнлегенә кабат-кабат инанды ул. Ә инде өйләнешкәч, Рушан хатыны мәнфәгатьләре белән яши һәм архитектураны кайбер дипломлы белгечләрдән дә артыграк белә, аңлый башлады — Глориядә педагоглык сәләте дә бар: ул акыллы, ни-нәрсәнең асылын, төп фикерен кыска гына итеп ачып бирә иде. Менә шунда Рушан аңлап алды: хатынының проектларында бер генә талантлы ир-ат та булдыра алмаган сыйфатлар һәрвакыт булачак — аның кабатланмас хатын-кыз нәфислеге, ягымлылыгы-сөйкемлелеге, искиткеч зәвыгы гел генә чагылып торачак иде. Юккамыни ул ирен, гаиләсен, йортын — кыскасы, бар дөньясын онытып, җаны-тәне белән эшкә бирелә? Аңардагы рациональлек, җаваплылык тойгысы, астыртын исәп-хисапның булмавы, бер минутлык файда артыннан куа белмәве Глориягә үзенең төп эш принципларын, төп карашларын чарларга ярдәм итте дә инде, һәм ул аларга хыянәт итмәскә тырышачак.

Урта Азиядә аерым проектлар белән төзелә торган биналар, шәһәрнең йөзен билгеләүче корылмалар өчен кояш һәм ком-тузан тәэсиренә бирешми торган төзү материаллары кирәклеген Глория тиз аңлады. Биредә бары тик югары сыйфатлы аксыл-сары кирпеч, шомартылган-ялтыратылган таш, металлардан — юка кызыл бакыр, цинк, кургаш, алюмин калайлар һәм шуларның эретелгән катнашмасы гына яраклы. Әле санап кителгән материалларны мөстәкыйль, аерым-аерым да кулланырга була, әмма Глория аларның барлык төрләрен дә аралаштырып

эшләүне отышлырак саный иде. Эшләгәндә ул җирдән аерылып, җиде кат күкләргә ашып йөрми, көндез чыра яндырып эзләсәң дә табып булмастай нәрсәләрне проектларына кертми, әле әйтелгәннәрнең, сыйфатлы кирпечтән кала, һәммәсе дә Урта Азиянең үзендә җитәрлек. Ә илебез архитектурасына әлегә хас булмаган төсле металлны Глория киләчәктә киң кулланылышта булачак дип саный, бу металл Заркентның үзендә җитештерелгәнлектән, нинди генә кытлыкта да шәһәр үз сарайлары өчен резерв чыганаклар табачак, дип ышана иде.

Кайвакыт, кәефсез чакларында, Глория, пошынып, үзенең архитектурада бер ун елга соңга калганлыгы турында сөйләнә. Яшьләр йортын проектлаштырган чакта ул, әлбәттә, хәзер блоклы төзелеш, бетон, яңа тышлавыч материаллар, пыяла заманы, серияләп-калыплап төзү, йортлар салу комбинатлары чоры икәнен белә иде. Белгәнгә күрә, еш кына кулына карандаш алып яза-сыза, беренче карашка арзанлы күренгән төзү материалларының бары тик бүген генә файда биргәннәрен, ә иртәгә аларга ремонт өчен генә дә әллә никадәр артык чыгымнар китәчәген исбатларга тырыша иде. «Саран ике тапкыр түли». Бу әйтем нәкъ менә архитектурага кагыла дип исәпли иде Глория.

Пыяла турында ул үзенең бер мәкаләсендә турыдантуры ачык итеп язды, кайнар кояшлы Урта Азия өчен ул яраксыз, диде. Аннары башка климат шартларында беренче куанычлар тиз үтәчәк, биналарны җылыту мәсьәләсе бөтен кискенлеге белән килеп басачак, ә пыяла биналарны җылыту — шул ук урамны җылыту белән бер. Аның фикеренчә, пыяла аквариумда эшләргә дучар ителгән кеше гап-гади психологик көчләүгә тап була — ул барлык күзләр өчен дә ачык, шәрә калган кеше шикелле була...

Мәкаләсе басылып чыккач, Глория өчен күңелсезлекләр башланды: Архитекторлар союзы аны шәһәр төзелешенең хәзерге заман куйган бурычларын аңламауда һәм архитектураның киләчәге булган яңа материалларның мөмкинлекләрен бәяләп бетермәүдә гаепләде. Глория җавапка бер генә җөмлә язды: «Барлык заманнарда да архитектор алдында бер генә бурыч торган һәм торачак: матур, сыйфатлы һәм озын гомерле итеп төзү бурычы». Ләкин Рушан, бу хатны почтага илтеп салырга алынса да, җибәрми калды, чөнки белә иде инде: яшьләрнең дорфалыгын беркайчан да гафу итмиләр.

Инде менә хәзер, еллар үткәч, хатынының Урта Азия архитектурасына булган үз карашларын яклап көрәшкән чакларын искә алып утырганда, Рушан аның никадәр

хаклы булганлыгын аңлый, хәер, ул вакытта да хатынының фикерләре дөреслегенә һич кенә дә шикләнми иде ул.

Рушан, җир тетрәгәннән соң, Ташкентта төзелгән күп кенә биналарның ниндидер бер ун ел эчендә бетоны, тышлау материаллары кояшта янып купканын, җимерелә барганын, картаеп-тузып килгәнен күреп яши — аларга хәзер бернәрсә белән дә ярдәм итеп булмый инде. Ә үз вакытында кызыктыргыч арзанлы материаллар белән тышланган күп кенә биек-биек биналарның бүген тышлавыч плиткалары кубып-убырылып төшә тора. Хәзер ул галәмәт биеклектәге бер плитканы алыштыру да йөзләрчә сумга баса һәм, асылда, ул хәл ителмәслек мәсьәлә: чираттагы плитканың кубып төшкәнен көтеп, бөтен бинаны төзелеш басмалары белән уратып тотып булмый ич!

Глория Заркентның Яшьләр йортын эшләргә, өйләнешкәч — туйдан соң ук алынган иде. Хатыны ул проект белән чиләнгән өч ел гомер эчендә аларның өендә дуслары белән очрашулар бер генә мәртәбә дә шул проект турында сөйләшүләрсез тәмамланмый иде.

Яшьләр йортына Глория ташның күпкырлысын да, шомартылганын да «салды», аннары югары сыйфатлы кирпеч, Заркенттагы барлык металларны да, бигрәк тә кызыл бакырны күпләп өстәде. Ул бакырны Шәрык мәгъдәне, дип саный иде. Бу чорда ул инде Үзбәкстанны аркылыга-буйга йөреп чыккан һәм беркайда да диярлек җәйләрен кешеләр янып-пешеп утырмаслык, заманча биналарны күрмәгәнлеген сөйли иде. Ул заманнарда хәзер һәр рәсми оешма яки учреждение тәрәзәләренә эленгән кондиционерларның исе түгел — исеме дә юк иде әле. Андый биналарга ничек итеп салкынча-саф һава бирү мәсьәләсе Глорияне барыннан да битәр борчый. Ул, ачынып, болай дип шаярта: «Хәзер, мәсәлән, концерт залларын кабул иткәндә, комиссия идәннәргә, түшәмнәргә, баскычларга — кыскасы, һәр вак-төяккә игътибар итә, ә иң әһәмиятле, иң кирәклесе — ишетелеш-яңгыраш ягы, акустикасы «онытылып» кала. Шуңа күрә дә «яңгыравык тавышлы» заллар ил буена бармак белән генә санарлык, җырчылардан сорагыз әнә». Глория Рушанның игътибарын тагын бер нәрсәгә юнәлтте: хәзерге архитектурада тулы бер элемент — түбә юкка чыгып бара икән. Хәзер инде яшелгә буялган калай түбәләрне гомерлеккә югалта барабыз бугай...

Төзелештә «онытылып» калган түбә Глорияне тагын бер фикергә этәрде. Баштарак ул кояш нурларын көзгедәй кире кайтарып тора торган, хромланган гапгади цинк калай түбә ясарга уйлаган иде. Әмма Яшьләр

йортын ул романтик бер бина итеп күзаллый, үзенә тартып торырга тиешле, тышкы күренеше белән үк яшьләрне ымсындырырдай бина булырга тиеш дип саный, шуңа күрә ул гадәти түбәдән баш тартты да инде. Ә икенче бер фикерне аңа Рушан бирде: ә ни өчен түбәдә кафе ясамаска, ди әле?

«Энҗекәй»дән дә кызыклырак кафе проектын Глория кәгазьгә бик тиз төшерде, иң мөһиме шул булды — ул кафе өстенә чатыр түбә уйлап тапты, димәк, шуның белән бөтен бинаны каплап куйды. Кафены ул янә дә шәрыкчә итеп эшләде: хромланган җиңел цинк чатыр түбә бик матур бизәкләрне үзбәк милли алымы белән сырлап-уеп — ганча стилендә эшләнгән күпсанлы баганаларга ятып торырга тиеш. Глория бу элементны Сәмәрканд мәчетендә күзе төшкән бер бизәк үрнәгендә эшләгәнен яшереп тормады. Аның уйлавынча, бу түбә берьюлы ике мәсьәләне хәл итә: беренчедән, кояшның иң эссе, туп-туры төшә торган нурларын кире кайтара, икенчедән, бина өстендә һава агымы даими алмашынып тора һәм салкынлык бирә.

Кафеның исеме дә шуннан чыгып туды — «Җилкәй», ә эссе якларда җиләс җил, һай, бик тә кирәк ул. Глория моның белән генә тынычланып калмады, янә дә Рушанның тәкъдиме белән, диварларның калынлыгын нормативтан шактый арттырды, дивар эчләренә торбалар суздзы, җәен ул торбаларда салкын су йөреп, бинаны суытып торачак иде. Интерьер, баскычлар, ут-яктырту ишеләр Глориягә бик җиңел бирелде — аның хыялының чикчамасы юк иде шикелле. Үзенең көтелмәгән ачышларын ул Рушан белән бүлешә, ә тегесе, хатыныннан яшереп кенә, барысын да язып-теркәп бара, соңыннан ул язуларның кирәге бер генә тапкыр чыкмады. Шул чагында Рушан бер нәрсәне аңлап алды: архитекторның уе-фикере, хыял очышы шигъри юл шикелле икән — вакытында язып куймасаң, кайтарып ала алмыйсың, югалтасың.

Холлның зур диварын «Мотоциклчылар» дигән зур мозаик панно бизәргә тиеш иде — Глория шлак җәелгән юлда мотоциклчыларның җан-фәрман узышып ярышуларын онытмаган иде әле. Ул панноны тизлеккә битараф булмаган Зураб Каргаретели үзе эшләп бирергә булды. Рушанга хатынының проекты ошый иде: түбә астындагы кафе да, концерт залы да, әмма барысыннан да бигрәк ул холлны яратты: анда икенче каттан астагы кантар-кантар ташлар өстенә шарлавык ага, зәңгәрсу хауз читендә фонтан челтери, ә үтә күренмәле кабиналы лифтлар астан өскә, өстән аска тавыш-тынсыз гына йөреп

тора, алар кунакларны холлдан «Җилкәй»гә — кафега күтәрәләр.

Элек, «вакытында туу кирәк» дигән гыйбарәне ишеткәндә, Рушан аңа бернинди әһәмият бирми иде, ул гыйбарә еш кына кирәксә-кирәкмәсә дә әйтелә һәм йә мушкетер буласы, йә Чапаев белән рәттән ат өстендә кылыч айкап чабасы килгән романтик яшүсмер чакларга, ә кызлар зиннәтле сарайлардагы балларда бию, алар өчен дуэльләрдә атышу, иртәләрен мәгъшукларының кәрҗин-кәрҗин чәчәк җибәрүе турында хыялланган вакытларга гына кагыла төсле иде. Хәзер Рушан аңлый инде, үз вакытыннан соңлап туган кешеләр бихисап һәм алар моңардан һич кенә дә иза чикмиләр, үз вакытыннан алда туучылар исә берән-сәрән генә, аларны йә бөек язмыш, йә, әгәр дә аларны аңлап, ярдәм итүче булмаса, фаҗига көтә, хәтта вакыт та аларның онытылган исемнәрен һәрчакта да тарихка кайтарып бирә алмый.

Глориянең Яшьләр йорты проекты да шундый язмышка дучар булды, ул, айсбергка барып бәрелгән кораб шикелле, әле яңарак кына хөкүмәт чыгарган «Архитектурадагы артыклыклар турында» дигән карарга бәрелеп, челпәрәмә килде. Соңыннан билгеле булды: бу карар озын гомерле түгел иде. Әмма ул үзенең кара эшен эшләп өлгерде. Нихәлләр итәсең?..

Әле исеме аз билгеле булган яшь архитектор тәнкыйтьнең беренче көчле утларын түземлек белән кабул итте. Бу тукмакның нәкъ үзенә төшүе очраклы икәнен Глория аңлый, биредә ул кемнәрнеңдер явыз нияттән казынуларын күрми — гап-гади язмыш иде бу. Әлбәттә, яңа агым күзлегеннән караганда, аның проектында «артыклыклар» җитеп ашкан иде.

Кыю, купшы, матурмы? Болар барысы да комиссия өчен бары тик артык бай зиннәтлелек булып кына күренә, хәтта бу сыйфатлар үзләре дә ярамаган, тыелган нәрсәләр итеп кабул ителә. Ә бинаны суыту нияте, гомумән, бариннарга хас иркәлек, эрелек, тәкәбберлек кебек кенә карала. Лифтлар, шарлавыклар, ишегалдындагы хаузлар, фонтаннармы? Яшьләр йортындамы? Заркенттамы? Әле исеме картага да төшерелмәгән шәһәр дә... Һәммәсе дә, фикер алышып тормастан, аяк өсте генә кире кагыла торды.

Ничек кенә сәер булмасын, иң күп бәхәсләр «Мотоциклчылар» панносы тирәсендә барды: ә биредә — металлурглар шәһәрендә мотоциклларның, узыш-ярышларның ни катнашы бар?

Глория тизлек, узыш-ярышлар, бәйгеләр — яшьлек билгесе, заман, чор билгесе, дип аңлатырга тырышып ка-

рады. Жюри әгъзаларының берсе дә ни Кадыйровны, ни Плехановны, ни Самородовны танымады, ә бит бу спортчыларның рәсемнәре ул елларда газет битләреннән төшми иделәр — ни әйтсәң дә, күп мәртәбәләр дөнья чемпионнары, совет спортының горурлыгы...

Комиссия җитәкчеләреннән берсе киң күңелләнеп: «Панно — төп мәсьәлә түгел, аны үзгәртүе кыен булмастыр»,— диде һәм, үзенчә бик «кыйммәтле фикер» бирде: бөтен буена бастырып, кулына кисәү агачы тоттырып (нәкъ шулай диде!), таза бер металлургны ясарга, ә янәшәсендә — ут булып агып торучы бакыр елгасы... Шушы юмарт әйтелгән «акыллы» сүзләреннән соң, җитәкче куанычыннан үзе дә Заркент бакыры төсле кыпкызыл булып кызарып-янып чыкты. Глория түзеп тора алмады, моңа каршы тезеп китте:

— Бу сезне ванна янына кулыгызга чебен үтерү өчен чапалак тоттырып кую белән бер булачак, чөнки Заркентта бакырны химик юл белән, гальваник ванналарда «кайнатып» алалар, ул ванналар сезнең йорт ваннасыннан бераз зуррак зуррагын, төпләре дә, чуенны эретмәсен өчен, винипласт белән капланган, шулай итеп, бакыр эретүнең бер батырлыгы да юк, зәңгәрсу төстәге эремәсе, карап торуга бик матур күренсә дә, бик агулы да...

Бу сүзләрне Глория бертын белән, пулеметтан аттырган кебек аттырды.

Комиссия рәисе атаклы скульптор, кәйлә-чүкеч тоткан ир-ат, ишкәк яки чиләк тоткан хатын-кыз сынна-рын күпләп коеп торучы автор иде. Аның «кыйммәтле киңәшен» колагына да элмәгәне Глориягә бик кыйммәткә төште: аны мөмкин булган барлык гөнаһларда гаепләделәр...

## XXXXI

Аларның туйларыннан соңгы дүртенче еллары уңышсыз башланды. Иртә язда, футбол сезонының башында ук, алар төркеменең якты-юмарт җаны, шук-шаян такылдык Тамаз, аягын сындырып, бик каты имгәнде. Ташкенттагы травматология институтында өч ай ятканнан соң, аннан гарип булып чыкты. Ябыккан, таякка таянган Тамазны күргәч, барысының да йөрәкләре әрнеде, табиблар аңа, гомер буе шул таяк кирәк булачак, дигәннәр.

«Энҗекәй»дә аны озату кичәсенә җыелдылар. Һәркем күңеллерәк булырга тырышса да, өстәл тирәсендә куе томан шикелле таралмас сагыш-моң тирбәлә иде. Тамазны озаткач, үзләренең кайчандыр дус төркеме озакламый бөтенләй таркалачагын, яшьлекнең китеп барганын,

тормышның яңа, кырыс баскычына басканнарын, алда инде якты өметләрнең, ымсынып көтүләрнең аз булачагын, иң якын дусларның ихтыярсыздан сирәгәячәген, төнге юләр шалтыратучылар бетәчәген, әле кичә башка да кермәгән, керсә дә, бер сагышсыз-авырттырусыз чыгып очкан хисләр белән артка борылып карауларсыз гына яшәүләргә чик куелачагын һәммәсе дә аңлый, шул авыр тойгы аларның күңелләрен баскан иде.

Тамаз үзе, кәефе башкаларныкыннан күпкә төшенке булса да, шушы шәһәрдә яшьлеге бергә үткән дусларының күбесе белән соңгы мәртәбә күрешкәнен аңласа да, әле шаяртырга тырышып карады:

— Яхшылыксыз яман булмый, дуслар,— диде ул.— Ниһаять, минем футболны ташлаганыма өйдәгеләр шатланачак, мин бит юрист, калган көчемне Фемидага хезмәт итәргә бирәчәкмен... Иң әүвәл бюрократ түрәләрдән үземнең пенсиямне яулап-даулап алырга туры киләчәк, мин бит исереклек белән түгел, ә дистәләрчә мең халык күз алдында имгәндем. Димәк, юристлык практикасы өчен берәр ел бар да бар инде. Үтенәм, дуслар, куып таратыйк йөзебезгә кунган сагышны! Шушындый бәлагә тарысам да, футболга иң матур яшьлек елларымны биргәнем өчен тамчы да үкенмим. И, футбол — зур дәрт-теләкләр! Глория, гүзәлем, минем өчен футбол — синең өчен архитектура кебек иде, син моны аңлыйсыңдыр дип ышанам...

Икенче көнне иртә таң белән Тамаз Грузиягә китеп барды, шуннан соң алар беркайчан да элекке кебек барысы бергә җыела алмый башладылар. Очрашу өстәле яныннан әкренләп, берәм-берәм сәер генә юкка чыга баралар, әйтерсең лә чоңгылга төшеп югалалар иде...

Шул ук елда гигант комбинатның соңгы — өченче чиратын тапшырасылары бар иде, гадәттәгечә, көнне төнгә ялгап эшләделәр. Комбинатны файдалануга тапшыру — дәүләт күләмендә әһәмиятле вакыйга, ул көнгә төзүчеләр генә түгел, ә бөтен шәһәр әзерләнде.

Әле кияүгә чыкканчы ук Глория Рушанның үз улы турында хыялланганын, Дасаевлар ыруының, үзендә туктәлып калмыйча, дәвамчысы булуын теләгәнен белә иде. Әмма иренең бала булдыру теләген никадәр уртаклашырга тырышса да, хыялларын эш каплый да тора. Ул иренә:

— Түз инде, җаным, Яшьләр йортын эшләп бетерүгә, сиңа менә дигән хуҗабикә булам, әни булам, тупырдап торган бер малай табып бирәм, эшемне ташлап торам...— ди иде.

Проектын якларга киткәндә, ул үзенең көмәнле икәнлеген әйтте.

Ташкенттан Глория җиңелеп кайтты. Монысы бик

шикле булса да, җиңелүе белән ризалашкан кебек булган иде. Рушан аны тынычландырырга тырышты:

— Менә бер-ике атнадан, комбинатны эшләтеп җибәрәбез дә, озаклап ял итәргә Гаграга китәрбез, алдагысын күз күрер тагын...— дип сөйләнде.

Ләкин кайтып ике көн үтүгә, Глория, көтмәгәндә ял алып, Мәскәүгә барачагын белдерде, комбинатны тапшыру бәйрәменә, һичшиксез, кайтып җитәчәген вәгъдә итте. Рушан аны бармаска ни үгетләп караса да, тыеп кала алмады — хатыны соңгы мөмкинлеген ахыргача сынап карарга теләде.

Ниндидер зур кунаклар килүен көтеп, комбинатны җибәрү ике мәртәбә кичектерелде. Глория кайтмый да кайтмый, сирәк шалтырата, хәбәрләре куанычсыз иде. Дәүләт комиссиясенә төзелешен тапшырмыйча торып, Рушан берничек тә, күпме теләсә дә, хатыны янына китеп бара алмый иде.

Заркентка Глория ай ярымнан соң гына кайтып төште. Ябыккан, бетерешкән, бик борчылган, телеграмма-нисез генә кайтты да керде. Аның бар кыяфәте эшенең шәптән түгеллеген әйтеп тора иде. Бусагадан ук иренең муенына ташланып, ачы күз яшьләре белән үксеп-үксеп еларга тотынды ул. Озак елады, горурлыгы Мәскәүдә җебеп төшәргә ирек бирмәгән иде, өендә хисләренә ирек куйды. Аның температурасы күтәрелә башлаганын тоеп, Рушан Глорияне диванга илтеп салды, хәлсезләнгән хатыны аның кулында йокыга китте. Төн уртасында ул, бөтенләй йокламаган да шикелле, кинәт сискәнеп уянды, гасабиланып, ачынып әйтте:

— Рушан... мин... Мәскәүдә... синең улыңны... үтердем...— диде һәм янә елап җибәрде.

Рушан ниндидер төзәтеп булмаслык зур бәла, хәсрәт килгәнен бөтен йөрәге белән сизенде, төн уртасында бөтен йортны күтәрерлек, ниндидер аңлатып булмаслык кыргый тавыш белән кычкырып җибәрәсе килде, әмма көчхәл белән булса да, үзен тыеп калды, ачы әрнүдән буылабуыла, истерика өянәге кузгалып, бәргәләнеп яткан авыру хатынын тынычландырырга азапланды. Йончыган, авыруга сабышкан, өметсез гаҗиз хатынына шул сәгатьтә бер генә авыр сүз дә әйтмәгәне өчен гомере буена язмышына рәхмәт укыды ул. Глория өч көн урын өстеннән тора алмады, чыгып йөрмәде — Рушан гел аның янында булды. Глория бераз торып йөри башлау белән диңгез буена китәргә булдылар. Икесенең дә хәлләре хәл иде...

Гаграда алар Джумберның кунакчыл абзыйсы Дато Джешкарианиларданерактарак булган бер фатирга керделәр, үзләренә яхшы мөгамәләдә булган кешеләр күзенә

бу хәлләрендә күренеп йөрмәскә булдылар. Кеше күп катнашкан шау-шулы урыннардан да качарга тырыштылар. Кайчандыр бу якларда шат һәм бәхетле үткәргән көннәрен бер дә искә төшермичә генә, көннәр буе комлыкта яттылар, тирә-якта матур урыннар күп булса да, беркая да чыгып йөрмәделәр, Пицунда турында хәтта авыз ачып сүз дә кузгатмадылар. Фатирларының хуҗабикәсе официант булып эшли торган ресторанга кичләрен ашарга гына барып киләләр — шундагы террасаның бер почмагында үз өстәлләре бар, кичке сменада эшләүче официантлар ул өстәлгә гел «буш түгел» дигән язу куя иделәр.

Сәер, элек күңел ачып, кәеф-сафа корып утырганда гына вакыт тиз үткән шикелле иде, шуңа да андый чакларда «вакыт үткәрдек әле», «вакыт үтердек әле» дип сөйләнәләр дә бит, ә менә хәзер дә, шат күңеллелек ташып тормаганда да, күрше террасада яңгыраган музыка тыпырдап бию дәртен кузгатмаса да, кичләр сиздермичә үтә тордылар. Һәр икесенең дә эчтә нәрсәләредер өзелде-сынды кебек, алар, ике хәлсез карт-карчык төсле, берберсенә ярдәм итешергә, булышырга, таяныч-терәк булырга тырыштылар. Сөйләшкәндә дә, үз тормышларына кагылмыйчарак, саклык белән генә, әһәмиятсез нәрсәләр турында гына сөйләштеләр.

Ул җәйдә, һәр кичне террасадан диңгезгә кояш баюын манзара кыла-кыла, әдәбият турында бигрәк тә күп сөйләште алар. Дөресрәге, Глория сөйли, ә Рушан, теге чакта «Энҗекәй»дә беренче күргәндәге шикелле итеп, аның яңадан җанланып килгән матур йөзеннән күзен ала алмыйча тыңлап утыра.

Алар өйләренә сентябрьдә генә әйләнеп кайттылар. Заркентта әлсерәтә торган эсселек сүрелгән, Үзбәкстанда елның иң матур фасылы булган җылы, озын-озак көз кергән иде инде. Берәүгә дә әйтеп тормастан, тын гына кайтып керделәр, элекке төсле утыру турында уйлап та карамадылар, ни өйдә, ни «Энҗекәй»дә кайту хөрмәтенә кунаклар җыелмады...

Ничектер бер төнне телефон шалтырады. Павлодардан Джумбер шалтырата икән. Ир белән хатын төн уртасындагы бу хәлгә бик тә шатландылар, мөгаен, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, берәр сәгать сөйләшкәннәрдер, югыйсә бер куанырлык хәбәр дә юк иде үзе. Әле кересенчә... Джумбер Робертны ашыгыч рәвештә «Пахтакор» командасына алачакларын әйтте, тегеләрнең уң як һөҗүмчеләре җәрәхәтләнгән икән дә, тренерлар советы «Металлург» һөҗүмчесенә тукталган икән. Команда Павлодардан көннең икенче ягында кайтып төшәчәк, Робертның Заркентта бердәнбер буш киче булачак — ул икен-

че көнне үк «Пахтакор»ның Тбилиси «Динамо»сы белән уенында катнашырга китеп тә барачак икән.

Шулай итеп, дуслар тагын бер иптәшләрен югалталар дигән сүз. Джумбер озату кичәсе оештыруны үтенде.

Түрәләр теле белән әйткәндә, Роберт югары үрләсә дә, мәҗлес бик күңелледән булмады — Роберт үзе дә, калганнар да бу «үрләтү»нең нык соңарганын аңлый иделәр. Бердәнбер куанычы шул: өч көннән егет туган шәһәре Тбилисинең футбол кырында уенга чыгачак,— теләсә кайсы грузин футболчысының иң изге хыялы шул бит. Ләкин, яшереп торасы юк, әгәр дә үз клубы өчен уйнаса, ул тагын да бәхетлерәк булыр иде.

Шуңа күрәдер, мөгаен, Робертның бу уены аның «соңгы җыры» кебек кабул ителде дә. Уенны Дасаевларда телевизордан карап утырган Джумбер күз яшьләрен тыя алмады.

Үзенә таныш булмаган «Пахтакор» командасында беренче тапкыр гына уйнавына карамастан, Роберт могҗизалар күрсәтеп, илһамланып уйнады, ул мөмкин булмаганнарны да булдыра алды, ни-нәрсә теләсә, шуны эшләде. Тәҗрибәле иптәшләре бу яңа егетнең уенына илһам фәрештәсе кунганын тоеп, гел тупны аңа бирә тордылар. Роберт керткән ике туп грузиннарны аякка бастырып, ярсытып җибәрде: каян килеп чыккан соң әле бу егет? Мөгаен, ул көннәрдә Тбилисидә Тамаздан да бәхетле кеше булмагандыр, чит-ят җирләрдә, чит-ят командаларда уйнап йөрүче грузин футболчылары турында сөйли-сөйли телләре калмагандыр.

Джумбер исә, дусты Робертның уенын карагач, кыска гына итеп үз фикерен әйтте:

— Безнең һәркайсыбыз туган җирдә — Грузиядә уйнаудан мәхрүм ителгән грузин, анда кайткач, уенга бары тик җаның-тәнеңне биреп кенә, нәкъ менә Роберт шикелле уйнарга тиешбез. Яки футбол кырында егылып үләргә...

Ул кичтә саубуллашканда, иртә чалара башлаган капитан ачынып әйтеп куйды:

— Тирә-якта дөнья тулы кеше, ә миңа шәһәрдә без өчәү генә калганбыздыр төсле тоела...

Күңелсез вакыйгалар Глория белән Рушанны бер-берсенә тагын да якынайтты, аларның уртак тормышына гаилә төсмере иңә башлады — өйләнешкәннәренә биш ел дигәндә, мондый сүзләрне ишетү сәердер, мөгаен, әмма чыны шулай иде.

Бер көн кебек үтеп киткән ул еллар аларның һәркайсысы өчен гел эш белән тулган, як-якка баш күтәреп карарга да вакытлары җитмәгән икән. Кайчакларда, башына

берәр фикер килсә, Глория төннәрен дә торып кульманы янына барып баса, ә Рушанның эшендә урын-җире җәюле раскладушкасы тора иде. Ул раскладушкаларны ни уйлап шундый тиз ватылучан итеп чыгара торганнардыр? Мөгаен, эштә йончылган, төннәрен дә тыныч йоклый алмаган прорабларга исәпләнмәгәннәрдер шул алар. Рушан да, әнә берничәне алыштырды инде. Ә инде буш вакытлары килеп чыкканда, дуслары белән аралашырга тырышырлар, кунак чакырырлар, мөмкин булган саен Ташкентка барып кайтырлар иде. Менә шулай яшәлгән инде.

Рушан студентларча яшәргә күнеккән, ашау-эчүдә нәзберек түгел, талымсыз, өй ашлары, уңайлыклар таләп итми, ул Глориясен аңлый, аның белән горурлана, эшенә-иҗатына зур ихтирам белән карый һәм күңеленнән генә улының да, һичшиксез, әнисе шикелле архитектор булачагы турында хыяллана иде.

Глорияне архитектурадан суынды, күңеле бизде дип әйтеп булмый, юк, ул бары тик эштән башкалар кебек үз вакытында кайта башлады. Алгы яктагы кульман белән дистәләрчә сызымнар, планнар, эскизлар һәм төрле рәсемнәр дә каядыр җыеп куелды, бүлмә, проект институтының остаханәсен хәтерләтүдән арынып, гадәти бүлмәгә охшап калды, иркенләп киткән төсле булды. Гөлләр, сингапур розалары пәйда булды. Эштән кайтышлый, Глория базарга да сугыла, ире кайтып кергәндә, кухнядан тәмле-тәмле исләр килә башлады. Хатынының телеңне йотарлык тәмле ризыклар пешерә белүен күреп, Рушанның исе китте. Глория элекке кебек өйгә дә эшләрен күтәреп кайтмый иде инде.

Рушанның да көне башкачарак үтә, ул да эштән вакытында кайта башлады. Ниһаять, балконына рамнар ясап куйды, такта идәннәр җәйде. Еллар буе сузылып, калып килгән эш бер атна дигәндә төгәлләнде дә. Шуңа икесе дә шаккаттылар. Шуннан соң фатирга үз көчләре белән ремонт ясарга ниятләделәр, Глориянең күзләрендә яңадан шашкын утлар кабынгандай булды.

Рушан комбинат төзелешендәгечә үлә-ята эшләрлек көче калмаганын тойды, башка күп кенә коллегалары шикелле, тынычрак объект алырга кирәклеге турында да уйлана, әмма әлегә Глориягә әйтми тора иде. Ташкентта да ешрак була башладылар. Ул язда алар яңа орган залына концертка йөрергәияләшеп киттеләр һәм, әлбәттә, «Пахтакор»ның бер генә уенын да калдырмыйлар, Роберт өчен янып-көеп утыралар иде.

— Сезнең трибунада икәнегезне белгәч, мин дә үземне уенда ышанычлырак тотам,— ди иде Роберт Гогелия, уеннан соң.

Шул җәйдә дуслар бөтенләй таралышып беттеләр.

«Металлург» командасы нык яңарды: буыннар алмашыну бара, элекке чемпионнардан бары тик икәү генә соңгы елларын уйныйлар — алыштыргысыз капитан белән капка сакчысы гына. Тренерлары да алышынды, ул үзе белән ярты команда яңа уенчылар ияртеп килде. Джумберның беренче көннәрдән үк ни тренер белән, ни яңа уенчылар белән борчагы пешмәде — аларның футболга мөнәсәбәтләре үк башкача булып чыкты. Менә шуннан соң инде Заркентта уен кырында беренче мәртәбә таралмаган озын чәчле, гетр-оеклары сыдырылып төшкән, футболкалары трусиклары өстенә чыгарып салынган футболчылар күренә башлады, аларның һәркайсының муенында берәр мәгънәсез нәрсә асылынып тора, ул аларның тылсым-талисманы, тагын да ямьсезрәк итеп әйтсәң, бөтие, имеш...

Тизлеген-җитезлеген югалтса да, Джумберга уены өчен сүз әйтерлек түгел иде әле, уен тәҗрибәсе арткан, тактик тоемлавы үткенләнгән, ә иң мөһиме — ике канаты — Тамаз белән Роберт булмаса да, әле күп туп кертә. Шулай булуга да карамастан яңа яшь һөҗүмчеләр аңа туп биреп торырга бигүк ашыкмыйлар, монда инде ул яшьләрнең генә түгел, тренерның да мәкерен сизенә иде. Күрәсең, чынлап та шулай булгандыр, Рушан белән Глория, ни әйтсәң дә, футболны аңлап карый иделәр бит.

Үзләрендәге чираттагы бер уенда, икенче таймның иң кызган чагында исәп команда файдасына иде инде, Джумбер көндәшләре капкасына тагын бер туп кертте, тренер шул вакытта уен кыры читенә килеп, куллары белән ишарә ясады һәм Джекарианины алыштырырга җыенганын белдерде. Джумбер башта аңламады — аны алыштырамы? Ни өчен? Рушан белән Глория утырган секторга якын гына булды бу хәл, алар Джумберның үлек кебек агарынып киткәнен күрделәр. Шул мизгелдә үк ул кыр читенә йөгереп килде дә тренерны якасыннан әләктереп алды, хырылдап әйтте:

— Кыланып кына кара, кыланып кына! — Аннары, борылып та карамыйча, уенга йөгереп кереп китте.

Рушаннардан һәм запас уенчылардан кала, нәрсә булганын берәү дә аңлый алмый калды бугай...

— Менә, дуслар, миңа да футбол белән хушлашырга чират җитте,— диде капитан, уен беткәннән соң.

Моңа кадәр башкаларга купшы озатулар һәм каршы алулар оештырып йөргән Джумбер «Энҗекәй»дә озату кичәсе үткәрүдән баш тартты. Аның китүен Рушаннарның әле яңа гына ремонтланып беткән өйләрендә өчәүдән-

өчәү генә билгеләп үттеләр һәм таң атканчы утырдылар. Алай да әле сөйләшеп сүзләре бетмәде. Джумбер китеп барганнан соң, әле бик озак Заркент ничектер тоныкланып калган төсле булды.

Заркентта футболның юкка чыгачагын Джумбер алдан ук сизенгән иде, күрәсең. Көзгә «Б» классын бетерделәр һәм шуннан соң инде бу шәһәргә чын футбол беркайчан да әйләнеп кайтмады.

Язларын мотоциклда узышучылар да килүдән тукталды, әмма монысы бик гади аңлатыла: илдә шлак сибелгән юллы трекларны теләсә кайда ясый башладылар, шунлыктан әллә кая җәһәннәм читенә килеп йөрүнең кирәге калмаган иде.

Айлар арты айлар тәгәри генә тора, аларның бер җайга салынган гаилә тормышында вакытның үткәне сизелми дә кебек. Рушан гаиләсе өчен куанып, Глориясенең, ниһаять, тынычланып калганына сөенеп дигәндәй яши, әмма башында бер уй бөтерелә иде: «Тулы бәхет өчен бер улыбыз да булса...» Ләкин бу хакта ул Глориягә беркайчан да әйтмәде, аның да шундый уйларда булуын сизенә дә иде юкса. Ул аның табибларга ешрак барып йөри башлавын да белә иде. Вакытлар үтә торды, әмма Рушан хатынының оялчан да, куанычлы да итеп: «Безнең бәбиебез булачак...» — дигән сүзләрен тәки ишетә алмады.

Бервакыт ул төнлә Глориянең үзенең җилкәсенә борынын төртеп, мышкылдап елап ятканын тоеп уянып китте. Рушан уянганын сиздермәде: «Бәлки, төшенә берәр нәрсә кергәндер»,— дип уйлады. Ләкин бу хәл икенче, өченче мәртәбә дә кабатлангач, ул аны тынычландырмакчы булган иде, хатынының истерика өянәге кузгалды. Үзен-үзе белештермичә, йөрәген ашаган ачы хәсрәттән шашынган хәлдә, Глория кычкырынырга тотынды:

— Мин синең улыңны үтердем, нигә соң син мине куып чыгармыйсың? Нигә кумыйсың, ә?! Мин бит синең тормышыңны җимердем, синең беркайчан да миннән улың булмаячак, Рушан! Беләм бит, син аның турында көн-төн хыялланасың. Куып чыгар мине! Ку!!! — дип тыелгысыз үкседе ул, иренең аяклары өстенә авып төшеп.

Рушан, аны шашкан күзләреннән үбә-үбә, булдыра алган кадәр тынычландырырга тырышты, бу минутларда үзенең аңа кайчандыр улы турында, үзен бурычлы итеп тойган Дасаевлар ыруының дәвамчысы турында каткат сөйләгән сүзләре өчен ихластан үкенде. Хәзер ул хатынының күңелендә тынычлык урнаштыру хакына үзенең булачак ун улыннан да баш тартырга риза иде, Глориясе тынычлансын гына, тынычлансын гына... Ру-

шан тоеп тора бит — хатыны сызып-үлеп бара... Һәлак була...

Бу хәлләрдән соң Рушан Глориягә карата тагын да игътибарлырак булырга тырышты, төнге сменаларга эшкә йөрми башлады — ул хатынын төнгә йөрәген өзгәләгән, күңелен җәфалаган уйлары белән ялгыз гына калдырырга курка иде.

Бу дөньяда аның өчен сөекле Глориясеннән кадерлерәк беркем дә, бернәрсә дә юк — хатынының шуны аңлавын җаны-тәне белән тели иде Рушан! Кайвакытларда бу теләгенә ирешкән дә кебек була, Глория тынычланып кала, бер-ике ай күңелле генә эшләп йөри, кием-салымнар сатып ала, һәр шимбә саен диярлек Ташкентка баралар.

Ялларын Болгариядә үткәрделәр. «Албена» дигән яңа курортта ял иттеләр, Глориягә диңгез яры буендагы отельләр бик ошады. Ул биредә янә күпләп эскиз-рәсемнәр ясый башлады, болгар архитекторлары белән дуслашып алды.

Рушан Глориядә кабаттан архитектура белән кызыксыну уянганын күреп куанды. Ул көйләнгән гаилә уңайлыкларыннан да ваз кичәргә әзер, фатирлары яңадан проект институты остаханәсенә әверелсен, бары тик хатыны төннәрен еламасын гына, үзен гаепле тоеп изаланмасын гына...

Ул вакытта Болгариядә дискотекалар байтак иде инде, ресторанпарда менә дигән оркестрлар уйный. Глория, кайчандыр «Энҗекәй»дәге шикелле онытылып, һәр кич саен ләззәтләнеп-рәхәтләнеп биеде. Ә Варнадан Одессага теплоходта кайткан чагында, өске палубадагы бию залында, ял итүчеләрдән кайсыдыр Рушанга көнләшеп карап әйтеп куйды:

— Карагыз әле, хатыныгыз нинди шат, бер кайгысыз сезнең!

Рушан бу кешенең сүзләрен кире кагып тормады, эченнән генә шатланып уйлап алды: «Аллага шөкер, Глория үз асылына кайтты бугай».

Болгариядән кайтып, бер атна үткәч, Рушан эшеннән чәчәкләр күтәреп кайтып керде, кайтса — өстәл өстендә бер язу ята иде.

*«Рушан, сөеклем, мине эзләмә. Безнең тормыштан бер яхшы нәрсә дә килеп чыкмаячак, барысын да яңабаштан башлап карарга тырыш. Синең бер гаебең дә юк, барысы өчен дә сиңа бик-бик рәхмәтлемен. Әгәр булдыра алсаң, гафу ит... Хуш. Үбеп, Глория».*

Рушан, язудагы сүзләрнең мәгънәсенә төшенә алмыйча, аны бер дә, ике дә, өч тә укыды — әгәр дә үзенә

таныш, кадерле кулны танымаса, моны берәрсенең усал шаяртуы диеп уйлар иде. Өй эчендә бернәрсә дә үзгәрмәгән: һәммәсе дә чиста, җыештырылган, чүлмәкләрдәге гөлләр юылып, өсләренә су бөркелгән, кухнядан әзер кичке аш исе килә...

Рушан барып, гардероб ишеген каерып ачты, үзенең әйберләре белән аралаш Глориянең ике иске күлмәге һәм плащы эленеп тора. Чемодан юк та, хатынының яраткан юл сумкасы юк. Ул акчалар һәм документлар саклана торган шкатулкага ташланды — Глориянең паспорты юк иде. «Акча да алмаган ичмасам...» — дип уйлап куйды шикелле, аннары, әле хатынының исен саклап торган тахтага барып капланды да елап җибәрде. Бала чагыннан, бик күп еллардан бирле еламагандай, үкереп-үкереп елады ул.

## XXXXII

Бер ай үтте, ике ай...

Рушан Глориянең үзен ташлап киткәнен берәүгә дә әйтмәде, хәер, әйтер кешесе дә юк иде — соңгы вакытларда алар кешеләр белән бөтенләй диярлек аралашмый башлаганнар иде инде.

Ул әле бу хәлгә үзе дә ахырынача ышанып бетми, аңа Глория янә ниндидер шашкын хисләрдән соң, үзен-үзе белештерми ычкынып киткәндер, барысы да җайланыр, бераздан кайтып керер кебек тоела иде. Кайгы-хәсрәттән һәм йокысыз төннәрдән кара янып чыккан хәлендә ул эштән соң өенә йөгерә, һәр көнне Глория кайткандыр дип өметләнә. Эштә тоткарланасын белсә, ишектә язу калдыра: *«Глория, мин фәлән-фәлән вакытта өйдә булырмын...»*

Берсендә, баскычтан менгәндә үк, ишектәге язуның юкка чыкканын күреп алды да, шатлыгыннан сулуы кабып, чүт тончыкмады. Әмма шатлануы юкка булып чыкты — язуны, мөгаен, малай-шалай шаяртып алгандыр. Төннәрен аңа кайвакытта кыңгырау шылтыраган кебек ишетелә, ул шатланып сикереп тора да ишеккә ташлана, аннары, нәүмизләнеп, иртәнгә кадәр йоклый алмый ята.

Беренче айларында аны хурлыкка-оятка калдырудан курыктымы шунда, Рушан Глорияне эзләп табарга азапланмады. Ә бәлки, һичшиксез, әйләнеп кайтырына ышанганга күрә эзләмәгәндер.

Өченче айга киткәч, ышанычы эреп юкка чыкты һәм ул, ашыга-кабалана, таныш адреслар буенча хатынын эзләргә тотынды, әмма күңел юатырлык хәбәрләр юк иде. Кичләрен Рушан өйдән чыгып йөрмәс булды — аңа ха-

тыны кинәт шалтыратыр яки үзе Глория турында хәбәр итәргә кушкан кешеләр шалтыратыр төсле тоела иде.

Бары тик кара көздә генә, бер ел чамасы үткәч, көтмәгәндә Норильскидан ике-өч сүзле генә телеграмма килеп төште *«Газаплама үзеңне, эзләмә мине»*. Бер атнадан Рушан Норильскида иде инде, бөтен шәһәрне актарып чыкты, милицияне аякка бастырды, әмма Глориянең эзләрен таба алмады. Бәлки, ул бу җир читенә килеп тә йөрмәгәндер, берәрсенә шуннан телеграмма сугарга гына кушкан булгандыр? Барыннан да битәр, шулай булгандыр, кеше печән кибәнендәге энә түгел бит, ул елларда әле Норильск та зур шәһәр түгел иде...

Ике ел үтте...

Глориянең соңлап ачылган мавыгуы булган гөлләр, чүлмәкләрендә килеш утырып, көеп-үлеп беттеләр, шатлыклы көлү тавышларының һәм күңелле мәҗлесләрнең шаһиты, кайчандыр бәхетле йорт телдән калган кебек булды, ябык ишекләр артында шомлы тынлык хөкем сөрә иде.

Ярты елга бер мәртәбә, сирәк кенә Рушанның фатирында әкрен генә музыка яңгырый: Гайдн, Вивальди, Стравинский, Барток — Глориянең яраткан композиторлары. Бары тик үзенә мохтаҗ эш һәм шул эш өчен кангa сеңгән җаваплылык тойгысы гына Рушанда тормышка кызыксыну тудыра, аны тышкы дөнья белән бәйләнештә тота иде.

Дасаевны эшендә үстерү-күтәрү турында хәзер инде сүз алып барылмый, «сынды мужик» кына диләр. Аннары яңа объект — көнкүреш химиясе заводы да комбинатның үзен төзегәндәгедәй күп көч, киеренкелек сорамый, шуның өстенә Рушан үзе дә, башлыклары әйтергә ятратканча, «шомарган биш тиен» иде инде.

Әмма көннәрдән бер көнне бар нәрсә Глорияне искә төшереп тора торган бу шәһәрдә үзенә бик авыр икәнен, һава җитмәгәндәй, нәрсәнеңдер үзен буып торганын тойды ул, ә хатынының фатирында яшәү көннән-көн газаплырак була бара иде. Ул элеккечә үк һәр очраклы кыңгырау тавышына сискәнеп китә, нинди дә булса шатлыклы хәбәрне ишетми калудан куркып, кичләрен өеннән сирәк чыга. Әмма Глориядән һаман да хәбәр-хәтер юк иде. Ул нәрсәдер эшләргә кирәклеген дә аңлый, ләкин Глория китү белән аның бар көчен-җегәрен суырып алдылар, ихтыярын сындырдылар төсле иде.

Ничектер бер кичне Рушан эшендә элеккечә тоткарланды да, кайтышлый «Энҗекәй» кафесы янындагы тукталышта төшеп калды — өйдә суыткычы буш иде, шуңа күрә кая булса да кереп, капкалап аласы итте.

Яшь төзүчеләрнең үзара сөйләшкәндә «Энҗекәй»не гел генә телгә алып торганнарын ишетеп йөрсә дә, үзенең кафеда булмаганына бер дүрт ел бардыр инде. Элеккe официант кызлар алышынып беткән, аны элекке кебек елмаеп каршы алмадылар, чәчләре чаларган шушы ирне — кайчандыр грузин егетләре гүзәл Глория белән таныштырган, аннары һәр кичне диярлек шау-шулы компаниядә шушында утыра торган Рушан Дасаевны хәзер тануы да кыен иде инде.

Беренче минутлардан ук Рушан вакыт дигәненең кафены да кызганып тормаганын аңлап алды. Элек «Энҗекәй», Глория уйлап эшләгәнчә, бәйрәмчә күңелле кичке кафе иде. Официантлар эшкә ял итеп, дәрт-җегәрләре ташып торган хәлдә килә, залны тәртипкә китерә, шланглардан су сиптереп, идәннәрне юып чыга, өстәлләргә чәчәкләр куя иде, бөтенесе дә ялт итеп тора һәм сәгать кичке җидедә кафе кунакчыл ишекләрен ачып җибәрә иде. Хәзер исә «Энҗекәй» иртәннән ачыла икән, официантлар, заводтагы шикелле, бер көн эшли, ике көн ял итә — шунлыктан Заркент эссесендә кичкә сыгылган лимон төсле булып калалар икән. Еш кына көнлек планкерем инде үтәлгән була, кичке кунаклар булса ярый, булмаса ярый шикелле генә икән.

«Энҗекәй» ремонт шаукымын да кичергән: элекке нәфис мәрҗән алсу кабырчыкны аңлаешсыз тонык көрән буяуга катырганнар, кызыклы архитектур табыш булган утлар балкышы юкка чыккан — мөгаен, электр энергиясенә экономия кампаниясе вакытындадыр инде. Туңдырма һәм тәмле сулар да юк, алар урынына кыйммәтле коктейльләр һәм, стаканнарга бүлеп, коньяк саталар.

Гадәттә, дуслары белән утыра торган өстәл буш иде, Рушан шунда барып, үзенең күнегелгән урынына утырды да, як-ягына каранып, күзәтә башлады. Халык элеккечә үк күп иде — кафе, картаеп, гүзәллеген җуеп барса да, әле шактый даны калган иде.

Кинәт Рушан бер нәрсәгә игътибар итте, моны Глория күрсә, шиксез шатланыр иде, ә бәлки, ул аның вакытлар үтү белән шулай булачагын күз алдына китереп эшләгән булгандыр да. Глориянең яраткан материалы — кызыл бакыр белән сары җиз, ничектер яңача күренеп, күзне иркәләп тора иде. Традицион Шәрык бизәкләре коеп эшләнгән кызыл бакыр биек койма, вакытлар үткәч, урыны-урыны белән яшькелт тутыкка өртелгән һәм шулай итеп бик откан, ул әйтерсең лә борынгы заманнардан калган һәм тузанланган бер кадими әйбер, бик чекерәеп тормаса да, күзгә ташлана иде. Ә элек Рушан Шәрыкны, борынгы кадими заманнарны хәтерләткән

бу бизәкләргә, бу матур коелмаларга игътибар да итми иде шикелле. Һәр көнне йөзләрчә куллар тота торган бакыр култыксалар, барның мәрмәр өстәлләрен каймалаган сары җиз, бизәкләп-сырлап эшләнгән авыр ишек тоткалары шомарып беткәннәр дә алтынсыман ялык-йолык килеп торалар.

Оркестр күңелле, шатлыклы көйләр уйный, куәтле көчәйткечләр аша ишетелгән музыка «Энҗекәй»нең галәмәт зур, буш залында колакларны тондырырлык булып яңгырый. Глория, ихтимал, музыканың шулай электрон үсеш-очышын да алдан күргән булгандыр.

Оркестрга төрле яктан, «тегене уйна», «моны уйна» дигән теләкләр белән, төрле суммадагы акчалар ява, аны, бирәүдән дә яшереп тормыйча һәм хәтта әле бераз масаеп-мактанып та, музыкантларга сузалар, аннары бөтен залга: «Безнең кадерле дустыбыз Әхмәт хөрмәтенә башкарыла...» — дигәнрәк сүзләр яңгырый. Димәк, ниндидер Әхмәт бу кичтә зурдан кубып кәеф-сафа кора, типтерә. Рушаннар заманында болай кыланучылар юк иде.

Әлеге билгесез Әхмәтнең юмартлыгыннан кинәнгән оркестр бер минутка да туктап тормый, залның дүрт секторында да яшьләр дәртләнеп бииләр. Вакыт-вакыт биючеләр сирәгәйгән арада исән калган көчле юпитерларның яктысы бию түгәрәкләре өстенә төшә дә, Глориянең йөзләгән аяклар ышкып шомарткан-ялтыраткан чәчәкләре тирә-юньгә алтын балкыш сибеп ала иде.

Бераздан Рушан өстәленә бер кызның туган көнен ашыгыч кына билгеләп үтәргә җыелган яшь-җилкенчәкне утырттылар. Рушан әле ул кызны кайсыдыр төзелештә күргән дә шикелле иде бугай. Кунакчыллык, тиз уртак тел табып аралашып китү — Шәрыкның шиксез матур сыйфаты, синдә ул электән булмаса да, бирегә килгәч йокмый калмый — һәм менә инде биш минуттан Рушан бу мәҗлеснең гүзәле, бүген туган көнен үткәрүче яшь кыз исәнлегенә бокал күтәрә.

Әхмәтнең чираттагы, бу юлы бигрәк тә купшы музыкаль заказы яңгырый башлады, яшьләр, дәррәү кубарылып, биергә кереп киттеләр. Рушан каршысында биисе килгәне йөзенә чыккан бер кыз гына утырып калган иде, кыз чибәрләрдән түгел, ләкин барыбер Рушан аны биергә чакырмый булдыра алмады.

Биегәндә Рушан ирексездән аяк астына карап-карап ала, моны сизенгән кыз сорап куйды:

— Әллә берәр әйберегезне югалттыгызмы?

— Менә бу чәчәк сезгә сәеррәк күренмиме? — дип, сорауга сорау белән җавап бирде Дасаев.

Кыз, игътибар беләнрәк караштырганнан соң:

— Әйе, ниндидер сере бар шикелле моның,— диде.

— Ә сез тагын да игътибарлырак булыгыз әле...

— Чәчәкнең менә бу каймалары үзара үрелгән «Г» һәм «К» хәрефләрен хәтерләтә шикелле. Әйе, әйе, хәзер мин ул хәрефләрне ачык күрәм! Сезгә алар нәрсә булса да сөйлиме, нәрсәнедер искәртәләрме әллә? — диде борчыла төшкән кыз.— Сез шулкадәр дулкынланасыз...

— Юк, мин дә ул монограмманы сез укыган төсле укыдым гына. Ихтимал, оста үзеннән истәлек калсын, дигәндер, аны таптап бетерә алмаячаклар...— дип җавап бирде Рушан, аның кайтып китәсе килә башлады.

«Энҗекәй»дән күптән таныш юл буйлап Глориянең йортына кайтып барганда, Рушан күңеленнән генә Заркент белән хушлашты — ул төзелеш осталыгы серләрен үзләштерә башлаган яшьлек шәһәре Ташкентка китәргә катгый карар кылган иде, анда аның Балетмейстердан алып Аптекарьга кадәр байтак дуслары да калды бит...

## XXXIII

Гомерләр үтә торды, ә Глориядән бернинди хәбәр-хәтер дә булмады. Вакыт-вакыт Рушан аны үлеп сагына һәм яңадан шашынып эзләргә керешә: хатлар яза, телеграммалар суга, таныш-белешләренә кат-кат шалтыратып чыга. Ул «Архитектура» журналын махсус яздырып ала башлады, андагы мәкалә арты мәкаләләрне игътибар белән укый, берәрсендә Глориянең исем-фамилиясен очратмаммы дип өметләнә иде. Әмма бөтен тырышлыклары бушка гына булып чыга.

Ә бервакыт, Ташкентка күчеп кайтканнан соң беренче ялы якынлашып килгәндә, ул төшендә диңгез күрде, Гаграны, шунда Глория белән бергә үткәргән бәхетле көннәрен күреп куанды. Көне буе шул матур төшен хәтереннән үткәреп йөрде ул. Имеш, Зураб Каргаретели аны бик үтенеп Пицундага чакыра, тормышка ашкан проектларын күрсәтмәкче була, имеш, серле елмаеп, әле җитмәсә, көтелмәгән бер куаныч та вәгъдә итә...

Батып баручы саламга ябыша дигәндәй, Рушан башына кереп утырган бу фикердән һич арына алмады, киресенчә, аңа тагын да ныграк ябышты: әгәр дә бу төш алдан хәбәр бирүче, күрәзә төш булса, язмыш булса? Хет багучыга йөгерерсең...

Берәр атна шулай изаланып йөргәч, ул диңгез буена китәргә карар кылды: ялы да зыян итмәс, ә иң мөһиме, аның күңелендә яңадан өмет уянды — ә кем белә?..

Ул Адлерга иртән килеп төште. Әле бик иртә булуга

карамастан, һәр җирдә җанлылык хөкем сөрә иде. Кояшта кызынып ял иткән кешеләр, Кара диңгез буен ташлап, моңсу гына кайтып баралар, ә яңа килүчеләр әле диңгез кояшында каралмаган тәннәре белән генә түгел, бигрәк тә түземсез ашкынулары, ымсынулы дәртләре белән алардан аерылып тора — тизрәк диңгезгә, кайнар кояш астына!

Шундый түземсезләр ташкыны Дасаевны Гаграга бара торган беренче автобуска алып чыкты.

Безнең көннәрдә шәһәрләр үзләренең йөзен-кыяфәтен бик тиз үзгәртә, аларны кайчакта танып бетереп тә булмый, бары тик үз йөзен, үз чалымын борын-борыннан ук тапкан курорт шәһәрчекләре генә еллар басымына бирешми, аларда һәр чор үзенең берәр билгесен калдыра килсә генә инде: духаннар — чәйханә, чәйханәләр — буфет, буфетлар — кафе, кафелар — бар, барлар — дискотека һәм шулай һич очына чыга алмастай исем алышынулар булып тора, әмма асылы һаман да бер булып кала бирә.

Ә бәлки, бу шәһәрчекләрнең гүзәллек серләре дә шундадыр: сезоннан сезонга тышкы бизәнүләрен үзгәртеп торсалар да, алар кипарислар ышыгында, мәгарәләр тынлыгында, тар гына тау сукмакларында, вак чуерташлы, шау-шулы комлыкларда борынгы серләрен саклап, һәрвакыт үзләре булып кала алудадыр. Әгәр дә кемдер: «Сезнең эзләрегезне диңгез күптән ялмап алган, бәхетле көлү тавышыгызны кайтаваз тауларга таратып югалткан-йоткан»,— дисә — ышанмагыз, кире кайтыгыз, һәммәсе дә нәкъ элеккечә, сез кичә, өченче көн, күп еллар элек ташлап киткәндәгечә саклана... Бары тик яңадан килергә генә, күрә белергә генә кирәк!

Рушанга да Гаграда бернәрсә дә үзгәрмәгән шикелле тоелды. Хәер, яңа сәүдә нокталары ишәйгән — ул аларны шәйләми калмады, әмма андый нәрсәләр ничек пәйда булса, шулай сиздермичә генә юкка да чыгучан булалар.

Тиз генә кереп, аяк өсте генә капкалап яки йөз граммазар төшереп чыгарга көйләнгән, халык телендә «забегаловка» дип йөртелгән бу нокталар, тыштан караганда күркәм генә, атаклы курорт шәһәрчегенә лаеклы булып күренсәләр дә, тәҗрибәле төзүче күзе аларның вакытлыча икәнлеген тиз абайлап ала — көчлерәк җил иссә, аларның эзе дә калмаячак иде...

Әле Джумбер белән беренче кайтуда ук шәһәр яхшы ук өйрәнелгән, йөреләсе йөрелгән булганга күрә, Рушан бормалы текә урамнардан бик ышанычлы, кая барганын белеп атлый, күңеленә хуш килерлек фатирны да бик тиз тапты — үзәк ял паркыннан да ерак түгел, кайдан кайтсаң да, җәяү генә кайтырлык җирдә иде ул.

Диңгездә су коенып, ял итеп алгач, кичен Рушан беренче килүләрендә Глория белән икәүләп йөрергә яраткан урыннарны манзара кылып кайтырга булды. Көзгедән үзен караштыргалаганда, соңгы бер ел эчендә чәче тагын да чалара төшкәнлегенә игътибар итте, әмма моңа эче пошмады, бу якларда иртә чалару сирәк күренеш түгел икәнлеген белә иде. Әйе, чал чәчләр грузиннарга үз тамгасын иртә һәм мәрхәмәтсез сала, әйтерсең лә юмартлыклары һәм киң күңеллелекләре, шук-шаян һәм тормыш сөючән булулары өчен ясак ала.

Телеграф янышнан узып барышлый, Рушан ирексездән тукталып калды. Тбилисигә телеграмма гына сук, дусларыннан берәрсе — Джумбермы, Тамазмы яки Робертмы хәзер килеп җитәчәк бит. Аның аларны бик тә күрәсе, элекке кебек грузинча әзерләнгән табын янында сөйләшеп утырасы, яшьлекләрен, Заркентны, «Металлург» командасын искә аласы килә. Ләкин... Рушан алдында әйтерсең лә кичеп булмаслык упкын тора: дусларына ул Глория турында нәрсә әйтер иде? Аһ, югалды, тотып кала алмадым, саклый алмадым, эзләп таба алмадым, яклый алмадым, дипме? Аның әйтер сүзе юк, моңа бернинди аклану табып булмый — шундый кешеңне югалт әле! Рушанның дуслары өчен дә Глория дус кына түгел, тагын да кадерлерәк бер кыз — тормышларының, яшьлекләренең бер өлеше, тылсым-талисман иде. Дуслар белән очрашу шатлыгы нинди көчле булмасын, хатынының язмышын белгәннән соң, кайгы-хәсрәтләре дә шуннан ким булмас иде... Шуңа күрә ул телеграфка кермичә, бөрешә төшкәндәйрәк итеп алга атлады.

Глория белән бергәләп грузин архитекторлары арасында ачык һавадагы җәйге кафеларда утыра торган иделәр, ул кафеларның кайберләре бөтенләй юкка чыккан, ә кайберләре, әле бик популяр булсалар да, хәзер тоныкланып-сүрәнләнеп калганнар, Дасаев һәр заманның үз күңел ачу урыны булганлыгын тагын бер мәртәбә билгеләп узды. Шул кичтә ул, әгәр дә Глория кинәт кенә диңгездә ял итәргә теләп, Гаграга килгән булса, аны да әнә шул яңа урыннардан эзләргә кирәклеген аңлады.

Ял көннәре бик тиз эреп юкка чыга барды. Рушан Глория белән беренче килгәч тукталган йорт яныннан да берничә мәртәбә үтеп китте. Капка янында Джумберның абзасы малайларын да күрде, малайлар үсеп, егет булып киләләр иде инде. Ул аларның һәркайсының исемнәрен хәтерли, әмма дәшәргә кыймады. Бер тапкыр Дато абзыйның үзен дә күрде, абзый һаман да элеккечә төз гәүдәле, авызында һаман да шул алыштыргысыз сигареты иде. Дато Вахтангович, машинасына кереп утырыр

алдыннан бер генә мизгелгә Рушанга карап та алды, ләкин хәзер үз йортында сөекле яшь хатыны белән ширбәт ае үткәргән Дасаевны алай тиз генә танырлык түгел иде шул инде. Бер-берсенә эндәшешмичә шулай аерылыштылар.

Икенчесендә, кич белән соң гына кайтып барганда, Рушан янә бу йорт яныннан сугылып узды. Ялт итеп яктыртылган ишегалдында, аның истәлекле көннәрендәге шикелле, мәҗлес шаулаша, аңа хәтта арада Джумбер тавышы да ишетелеп киткәндәй тоелды. Ярым ачык калган капкадан табын тирәсе әйбәт күренә иде, Рушан шулай да үрелеп карады — табында Джумбер юк иде.

Көннәр көнләшерлек матур тора, диңгез тыныч, фатиры да уңайлы туры килде, хуҗалары да кунакчыл, ләкин көннәр, Рушанның соңгы өметен өзеп, бик тә тиз үтә иде шул. Кайсыдыр бер кичтә, диңгез буендагы ресторанда ашап утырганда, ул залда буш урыннарның күплегенә игътибар итте, юкса ял сезонының иң кызган чагы бит, официантка шул хакта әйткән иде, тегесе:

— Күпчелек ял итүчеләр кичләрен күңел ачарга Пицундага китәләр,— дип җавап бирде.

«Пицунда! Әлбәттә, Глория дә Пицундада!» — дип уйлап алды Рушан, дулкынланып, сүнеп барган өмет чаткысы яңадан дөрләп кабынды да куйды.

Икенче көнне иртүк Пицундага китеп тә барды. Зураб Каргарителиның әкияти автобус тукталышларын тынычлап карап бармакчы булып, автобуска утырды, ул Зурабның эшләрен бер өлеше эшләнеп яткан чагында, бер өлешен кәгазьдә проект һәм рәсемнәрдә күргән иде инде. Рушан егерме дүрт тукталыш санады һәм алар берсе-бер кабатланмый, хыял байлыгы белән күзләрне иркәләп, күңелне кытыклап тора иделәр. Юл буенда котырып үскән субтропик яшеллек арасына тезелгән сихри әкият каһарманнары, юл йөрүчеләрне эсседән һәм кар-яңгырдан саклап-ышыклап, кабат килүчеләрне дә үзләренең матур ачык төсләре белән таң калдырып торалар. Бу каһарманнар шулкадәр күп, кемнең дә булса башына, аларны бер кеше генә эшләгәндер, дигән уй һич кермидер, әмма Рушан җирдә шундый матур эз калдырган останың кем икәнлеген дә белә һәм аның өчен күңеленнән генә горурлана да иде.

Пицунда белән очрашуга Дасаев әзер иде. Аңа, төзүче кешегә, сызым-проектларда бер күргәнен җанландырып күз алдына китерүе берни тормый, композиторга яңа партитура күрсәтсәң — ул оркестрсыз да аның музыкасын ишеткән шикелле, Рушан да үзенә тиешлесен «ишетә» ала. Киң булып сузылган яр буеннан барганда,

ул Глориянең шушы манзараны күреп сокланганын хәтерләде: төзүчеләр борынгы нарат урманын саклап калганнар, урман яр буенда биек булып күтәрелгән йортларга ук килеп терәлгән иде.

Юл чатындагы бронза скульптураны караганда: «Әгәр диңгез буенда ял итә торган булса, мин Глорияне бары тик шушында, Пицундада гына очратачакмын»,— дигән карарга килде Рушан.

Кич үз көченә кереп бара. Киенгән-ясанган, шат-көләч кыяфәтле кешеләр яр буйларына чыгалар, тар урман сукмакларында йөриләр, һәркайдан музыка ишетелә.

Пицундада җәйге рестораннар, кафе-барлар, дискотека-варьетелар шулкадәр күп булып чыкты ки, Дасаев югалып калды: кая барырга, кайда очратырга мөмкин ул үзенең Глориясен? Кайбер җирләргә тиз генә барып керерлек тә түгел икән — озын чират торырга кирәк.

Һәр биек йортның проектында иң өстә, түбәдә үк ачык һавада җәйге кафе планлаштырылганлыгын исенә төшерде Рушан. Аннан диңгез өсте күренеше һәм бөтен Пицунда борыны манзарасы ачыла, һәммәсе дә яхшы күренеп торырга тиеш. Ул, күп уйлап тормыйча, якындагы күпкатлы йортның ишегеннән кереп тә китте. Тиз йөрешле лифт аны уналтынчы катка күтәреп тә куйды, әмма монда да чиратка басарга кирәк булып чыкты — түбәдәге кафега керергә теләүчеләр дә хәттин ашкан иде.

Кафе галәмәт зур, «архитектура артыклыкларысыз» гына эшләнгән икән, Глория булса, «моннан да гадие булмас» дияр иде. Ләкин ял итүчеләрне бирегә күз алдында җәйрәп яткан манзара — саф диңгез һавасы җәлеп итә, башка урыннарда кысанлык, ә монда бию мәйданы да иркен. Буш урын эзләп йөргәндә, Рушан аңлады, күңеле белән тойды — Глория монда юк, була да алмый, ул аның зәвыгын яхшы белә иде. Бу уй борчуга да салды һәм шул ук вакытта сөендерде дә — ахыр чиктә, башка күпкатлы биек йортларның түбәләренә менеп, эзләнеп йөрергә кирәк булмаячак.

Буш урын түбә читенә эшләнгән рәшәткә — парапет янында табылды. Рушан диңгезгә карап урнашты, хәзер залдагы тамаша аны кызыксындырмый иде инде, ул хәтта торып чыгып китәргәме әллә, дип тә уйлаган иде, ләкин кичкелекне ашап чыгар өчен тагын кайда булса да озын чират торырга туры киләчәген күз алдына китереп калырга булды, шуның өстәвенә официант та бик тиз килеп җитте һәм яңа тотылган форель балыгы тәкъдим итте.

Кояш, барлык билгеләре белән иртәгә матур көн буласын вәгъдә итеп, әкрен генә диңгезгә төшеп бара. Катерлар, кечкенә теплоходларның кайсылары диңгез эченә

таба юл тота, кайсыларыдыр Пицунда причалына кайтып туктый, кайчандыр шушы яр буена, ә бәлки, шушы ук култыкка — Колхидага алтын сарык йоны эзләп килгән аргонавтларның кораблары туктала торган булгандыр. Сүз уңаеннан әйтеп үтик, «причал» сүзе үзе төрки сүз «чал, чалып куй» дигәненнән ясалган икән, ягъни «корабыңны арканлап чалып куй» — монысын Рушан әле күптән түгел генә белде.

Кинәт кенә һәрнәрсәне төн төреп алды — йолдызлы, үзенчәлекле Колхида төне. Еракта, нейтраль сулар артында ук, зур Яңа ел чыршыларыдай булып, дәррәү тезелеп киткән утлар кабынды: бәйрәмчә утларын төнге диңгез өстенә балкытып, өч палубалы галәмәт зур чит ил теплоходлары үтеп бара иде. «Төрекләр», «греклар», «шведлар»,— безнең портларга керүче чит ил корабларын диңгез буе шәһәрләрендә яшәүчеләр һәм диңгезчеләр шулай гына атап йөртә,— менә шуларның, тезелешеп, безгә — Ялтага килеп ятулары.

Җәй, диңгез, сәяхәт, бәйрәм...

Рушан хәтта ерактагы чит кораблардан яңгыраган музыканы да ишеткәндәй булды, әмма бу шулай тоела гына, аның колагын үз артындагы — залдагы оркестрның көчле тавышы тондырган иде.

Салкынайта, диңгездән сизелерлек булып җил исә. Дасаев туңып, калтыранып куйды. Залда күңел ачу әле кызып кына килсә дә, ул үзен уңайсыз тоя башлады. Официант белән исәп-хисабын бетергәч, ул түбән төшеп китте.

Гөлт итеп яктыртылган аллеяларда ял итүчеләр ашыкмый гына йөренә, шушы күпкатлы йортларда һәм кунакханәләрдә яшәүчеләрдер, мөгаен аларның беркая ашыгасылары юк. Һәркайдан үзенә чакырып музыка ишетелә, ресторannарның пыяла диварлары аша ачык төсләрдәге җәйге киемле биючеләрнең шәүләләре шәйләнә, кая карама — бәйрәм. Тыштан карап торуга канәгать ял итүчегә охшаса да, Рушанның күңелендә бәйрәм хисе юк иде. Ул ашыкмый гына курорт зонасыннан чыгып китеп бара иде, инде чыгып җиттем дигәндә — машиналарын туктатып, ял итү биләмәсенә керер өчен рөхсәт кәгазе күрсәтүләрен таләп итә торган шлагбаум янында кинәт музыка уйнап җибәрде. Инде күңел ача торган бар урыннар артта калды, дип уйлаган Рушан ялгышкан — монысы Пицунданың иң баш рестораны «Алтын руно» икән, оркестр тәнәфестән соң кичәнең икенче бүлеген башлаган булып чыкты.

Ресторан кичке, әле өч сәгать элек Рушан биредән үткәндә, ул ябык иде. Җиңел, нәфис корылма,

өстәлләрнең бер өлешен, урман аланындагы шикелле итеп, агачлар астына ук куйганнар, барлык верандалары да куе субтропик яшеллек белән үрелеп алынган ресторан үзе дә бик килешле, бик матур күренә. Бакчадагы өстәлләрдә стильләштереп эшләнгән «керосин фонарьлары» янып тора, верандага анда-санда бик пөхтә итеп эшләнгән сарык тиреләре дә эленгән, алар, ихтимал, «алтын руно» символы булырга тиештер инде. Матур киенергә яратучы хатын-кыз затлары аларга кызыгып карыйдыр әле, бер иләнгән тунга таман гына булыр иде, дип ахылдыйлардыр. Ләкин тиреләрне бик игътибар белән саклыйлар булыр, әкияттәге «алтын руно»дан да болайрак итеп саклыйлардыр, моны тик бирегә даими кереп йөрүчеләр генә беләдер.

Ресторанның үз йөзе бар, аны проектлаштыручылар да, төзүчеләр дә тырышканнар, шуңа күрә Рушан «Алтын руно»га килеп кергәнен сизми дә калды.

Сүрән яктыртылган сәхнәдә оркестр шашына, ул болай да кызышкан залны тагын да кыздыра төшә, кысан мәйданчыкта якын өстәл хуҗалары бии, башкаларга көнләшеп, үз сәгатьләрен көтәргә генә кала, ә ул чират җитмәскә дә бик мөмкин. Рушан, буш урын эзләп, өстәлләр арасыннан үтә башлаган иде, кинәт үзенә дәшкәннәрен ишетте.

— Рушан, безнең янга кил!

Дасаев шып тукталды: «Ялгыш ишетелде, ахрысы»,— дип уйлап өлгермәде, чакырулы тавыш янә кабатланды:

— Рушан, кадерлебез, кил безнең янга!

Бу тавыш бик зәгыйфь кенә шәм янып утырган өстәл яныннан ишетелә иде, үзләре шаулашалар-көлешәләр дә шикелле.

Рушанның аяклары тотмас булды, бер мизгел эчендә башыннан мең төрле уй йөгереп үтте: кем булырга мөмкин бу? Джумбертмы, Тамазмы, әллә Робертмы? Иске архитектор дусларымы?

Аны, әлбәттә, грузиннар дәшә, акцентларыннан сизелеп тора. Ул, шау-шулы өстәлләрне әйләнеп уза-уза, әкрен генә атлый, әмма күңеле инде шунда, көтмәгәндә чакырып дәшкән тавыш ягына очты... Ә бәлки?..

— Рушан, безнең монда караңгырак, әллә син инде шәп кенә сыйланып та алдыңмы? Безне танымыйсыңмы? — дип елмаеп сорады Тенгиз, үзе тукталган фатир хуҗабикәсенең улы.

Тенгиз янында тагын аларның беренче каттагы зур бүлмәләрен алып торган өч кыз белән егетнең дусты Заури да утыра иде. Кайбер көннәрдә кичләрен кайтып килгәндә, Рушан аларны бакчада күргәли иде, берсендә

хәтта алар белән ярты төн уртасына хәтле сөйләшеп тә утырган иде.

— Утыгыз, чынлап та, кечкенәрәк икән шул,— диде арыган сүрән тавыш белән Рушан.— Ә сыйланып алу дигәндә... Мин бүген сыйланып бетерә алмадым әле, сезне очратуым ярады. Берәр бокал шәраб булса, әйбәт булыр иде...

Официант Тенгиз артына килеп баскан иде инде.

— Ишеттеңме, дустыбыз Рушан нәрсә диде? Ут һәм шәраб...

Озак еллар буена риза була алмаган, килешергә мөмкин булмаган усал чынбарлыкны Рушан менә хәзер генә тулысынча аңлады, аның бар асылына төшенде. Шаушулы «Алтын руно» залында, шушында кайсыдыр бер мизгелдә миен ярып, ап-ачык бер уй йөгереп үтте: «Глория гомерлеккә югалды...» Ул, наркоздан айныган авырудай, барысын да ап-ачык күз алдына китереп бастырды, әнә хатынының бердәнбер телеграммасы «Эзләмә мине...»

Әллә ни күп калмаган соңгы ял көннәрен Рушан күршеләре белән бергә үткәрде, бу көннәрдә ул Гагра белән хушлашып йөрде, чөнки белә иде: ул бирегә яңадан беркайчан да килмәячәк — чын-чынлап бәхет татыган җиренә бервакытта да кире кайтырга кирәкми...

* * *

Өч ел элек ул Глориядән хат алды, Гамбургтан. Глория инде күптән, бер ун еллар булыр, Германиягә китеп барган икән.

Глория Советлар илендә үзенең һөнәрен, сәләтен беркайчан да таныта алмаячагын, ниһаять, аңлаган, туган илендә яшәргә чыдар хәле калмаган аның, ул ватанында үзен нәрсә көтәчәген алдан сизенгән, шуңа күрә чыгып китәргә мәҗбүр булган. Боларның барысын да бик ачынып-өзгәләнеп язган иде ул.

Фоторәсемнәр дә җибәргән Глория — төсле рәсемнәр. Ерак Ниццада, Зәңгәр яр буенда ял иткәндә төшкән рәсемнәре. Рушанның ул якларга бөтенләй барганы булмаса да, алгы ишеге төбендә Глория басып торган отель аңа бик таныш шикелле иде. Хатыннан аңлашылды — Глория яшьлегендәге уңышлы иҗат җимеше булган отель янында төшкән икән. Аның архитектор, өйләнгән яшьләр өчен Европада данлыклы отельләр проекты авторы икәнен белгәч, «Глория» отеле хуҗалары үзен ай буена бик зурлап кунак итеп, бушлай яшәткәннәре турында язган иде ул. Тагын әле ул Заркенттагы Яшьләр йортын про-

ектлаштырганда бөтен җанын салып эшләгән хезмәте бушка китмәгәнен, шуның нигезендә Кувейтның бер бай шәехенә гүзәл сарай төзетеп биргәнен дә язган.

Чит җирдә Глориянең эшләре уңган, үз архитектура остаханәсен булдырган, эш бирүчеләрнең чуты-саны юк икән. Әмма Гамбургтан нинди генә матур, зиннәтле, төсле фоторәсемнәр җибәрмәсен, Глориянең хатларыннан әйтеп бетергесез тирән сагыш саркый: бернинди уңыш та, тукрәхәт тормыш та алмаштыра алмый торган нәрсәдер Ватанында гомерлеккә торып калган иде — Рушан моны шулай ук яхшы тойды, эчке бер әрнү белән кабул итте.

Яшьлегендә Рушанга Аллаһы Тәгалә дә кайдалыгын оныткан ерак Мартукта берәрсе:

— Дусларың, сөйгәннәрең дөнья буйлап таралып бетәр, кайсысы Парижда, кайсысы Лондонда, кайсысы Гамбургта булыр...— дип күрәзәлек кылса, ул мәсхәрәле елмаер һәм, кайчандыр Саня Вуккерт яшькелт күзле Томочка Солохога әйткән кебек:

— Син бага белмисең, мадам...— дип кенә әйтеп куяр иде.

Көннәр үтә — күңелсез, авыр, сагышлы көннәр чиратларда торып, салкын фатирларда яшәп үтә, алда шатлыклар көтәренә ышануы бик-бик тә кыен. Вакыты-вакыты белән гомер бөтенләй бушка үткәндер кебек тоела.

Әмма... әмма...

Күптән юылмаган, тузанланып беткән тәрәзәсе аша карап торганда, каршы яктагы йорттан кулына нота папкасы тоткан зәңгәр бантиклы кызчык чыгып килгәнен күргәч, Рушанның йөзенә елмаю куна: юк, бернәрсәгә дә карамастан, тормыш дәвам итә, чөнки әле Җир йөзендә мәхәббәт бар, әле хәтер тутыкмаган, тонықланмаган.

Ә хәзергә, мәхәббәт һәм хәтер — кешене биеклекләргә аккошлар шикелле күтәрүче шул тылсымлы ике канат әле сындырылмаган-имгәтелмәгән вакытта, тормыш чишмәсе кипмәячәк, төтендәй эреп бетмәячәк, таңдагы томандай очып юкка чыкмаячак...

Кипмәс... бетмәс... юкка чыкмас...

*1991*

# ИГЪЛАН БУЕНЧА ТАНЫШУ

**Повесть**



Адресы өйнеке күрсәтелсә дә, телеграмманы эшләгән җиренә китерделәр. Эчтәлеге алай ашыгыч тапшыруны таләп тә итми, аннары район үзәге Хлебодаровка почтасында хатын-кызлар гына эшләвен искә алганда, аның инде, кулдан-кулга йөреп, кат-кат укылуына шик-шөбһә юк иде. Әкрәм абзый шул җилкенчәкләрнең яшьлек шуклыкларын әле дә хәтерли, кызлар да аны әйбәт беләләр: ул аларның ярәшкән егетләре белән сугыш кырына китеп барган иде, әмма үзе генә исән-имин әйләнеп кайтты.

Почта ишегалдындагы кечерәк кенә казна флигелендә яшәп яткан, бала-чагасы ишле Дарья Сташова егерме еллардыр инде поселокта телеграмма тарата. Күп нәрсәдән хәбәрдар, җор, тел бистәсе Сташова бер телеграмманы да теленә салынмый гына тапшырмас. Бу юлы исә дәшми генә бирде. Кызыксынуы күңелен кимерде кимерүен, әмма авыл халкы кушуы буенча ук булмаса да, һәрхәлдә, почта һәм телеграф хезмәткәрләре исеменнән, сөйләнми генә, нәфрәтләнеп, протест нотасы сыманрак итеп тапшыруы хак. Телеграф кагыйдәләре кушканча, телеграмманың алынуына имза да куйдырды әле, элегрәк шуның өчен вак-төяккә вакытын исраф итми торган иде.

*«Газизем Әкрәм Галиевич,—* дип башлана өч тәңкәгә төшкән саллы гына телеграмма.— *Сезне Көньяк Сахалиннан Наталья Сергеевна Болдырева бимазалый, һич уйламаганда газетта басылган игъланыгызга күзем төште. Миңа калса, без бер-беребезгә тиң булырбыз. Көтмәгәндә ял бирделәр — самолетта очам. Якшәмбе көнне төштән соң сездә булырмын. Күрешкәнчегә хәтле.*

*Наташа».*

Әкрәм Галиевич хат ташучы Сташованы кабинет тәрәзәсеннән күреп калуга хатыма бик тиз җавап бирерләр дип өметләнми дә, дала Хлебодаровкасы кебек ерак бер авылга атлыгып торучы, аның кебек пенсия яшенә аяк баскан провинция нотариусы белән кызыксынучы берәр хатын-кыз табылуына бик үк ышанып та җитми иде.

Сахалин тикле Сахалиннан көннәренә хәтле саныйсаный самолетта очып килергә ниятләгәннәр икән, димәк,

ничек кенә кызыксыналар әле. Шул горурлык хисе бер мәлгә аны Сташова һәм аның телеграмм белән кызыксынуы-кызыксынмавы хакындагы уйларын оныттырып торды.

Сташова чыгып киткәч, Әкрәм Галиевич утыз елдан артык утырып эшләгән нотариаль конторасының кысан кабинетында ишекле-түрле йөренеп алды.

Авыл нотариусы өчен эшнең иң кызу чагына, ягъни мәктәпләрдә чыгарылыш имтиханнарына хәтле бер атналап вакыт бар. Шуңа күрә йомыш белән килүчеләр юк — Хлебодаровка халкы авыл советыннан һәм нотариустан белешмә яки бүтән берәр кәгазь-мазар алу өчен иртәнге якта йөрергә гадәтләнгән. Бүген дә аның янына ике әбекәй генә килде — өйләрен оныкларына мирас итеп калдыралар икән. «Авызларында ана сөте дә кибеп җитмәгән, шулай да үзләрен күчми торган милек иясе итеп күрәселәре килә»,— дип кашларын җыерды Сабиров, әлбәттә, ишетелерлек итеп берни дә әйтмәде, эш урыны риясыз булырга мәҗбүр итә иде аны. Балигълык яшенә җитмәгән үсмерләр өчен әллә ниндиләрен дә рәсмиләштерергә туры килгәләде аңа.

Әкрәм абзый, телеграмманы янә әйләндерә-әйләндерә:

— Наталья Сергеевна... Наталья Сергеевна...— дип тәкрарлавын абайламый да калды. Исеме һәм атасының исеме ошый иде аңа.

Кулындагы телеграмманы әйләндерә-әйләндерә, ирексездән кат-кат укуын дәвам итеп: «Әлбәттә, танышуны башлап җибәрү өчен иң әүвәл хат кына язып салса да яраган буласы да бит»,— дип, нәрсә эшләргә кирәклеген күңеленнән уздырып, уйланып утырды.

Шундук белмәгән-күрмәгән Натальясын яклап та куйды — шултикле ерак җирдән килергә ниятләгән ич, хатны, мөгаен, самолеттан самолетка, поездан поездга бишәр мәртәбә күчереп йөртә торганнардыр, югалып калуы да ихтимал. Андый ышанычсыз хатка караганда, ашыгыч телеграмма сугуы хәерлерәк тә. Хатның почта ящигында атналар буе ятуы яки берәрсенең мәнсезлеге аркасында югалуы да бар, андый хәлләр хакында газетларда азмы язалар. Аннары телеграммада әйтелгәнчә, ялы да көтелмәгәндә бирелгән...

Әкрәм абзый үзенең «яклыйм», «каршы киләм» дигән дәлилләрен һәрьяктан исәпләгәннән соң, ашык-пошык кына хәстәрлек күрүне, гомумән, өнәп бетермәсә дә, Наталья Сергеевнаның килергә ниятләвен хуплады. Димәк, алда әле бер атналап вакыт бар. Һәрнәрсәне кабат күздән кичереп чыгарга була.

Әкрәм абзый эш сәгате беткәнче калган вакытын, күршесе һәм якын дусты, райпотребсоюз бухгалтеры Җолдас агага шалтыратасы, күңелен кытыклап торган яңалык белән уртаклашасы килеп, кыбырсып уздырды.

Әмма ул хакта сүз башлауны хуп күрмәде: бөтен гомерен диярлек ут күршесе һәм дусты Җолдас кулы астында райпотребсоюзда эшләп уздырган хәләл җефете Вера Федоровнаны җирләвенә ел да тулмаган. Верочканы (баш бухгалтер аның хатынын шулай дип йөртә иде) Җолдас ага үз итә, тырыш хезмәткәр дип исәпли, ел саен ялга киткәндә яки авырган чакларда үз вазифаларын аңа гына тапшырып калдыра иде. Уен эшмени — бухгалтерның һәр имзасы акча яки матди байлык белән бәйле.

Хлебодаровкада, үзен хөрмәт иткән һәр кеше кебек, мәрхүм-мәрхүмәләрнең елын да уздырмый һәм соңгы кадер-хөрмәт күрсәтү йоласын да үтәми торып, өйләнү яки кияүгә чыгу хакында сүз кузгату да гөнаһ санала. Якшәмбе көнне ниндидер бер Наталья Сергеевна килеп төшә дип сөйләп бирсә, күршесе һәм мәрхәмәтле дусты Җолдас та аңламас иде аны. Әкрәм Галиевичка нотариаль контораның кысан бүлмәсенең бакча ягына ачылган тәрәзәсеннән аны белгән һәм белмәгән кешеләрнең: «Кабер туфрагы басылып та җитмәгән, ә ул өйләнергә ашыга, сабырлыгы төкәнгән»,— дип сөйләшкәннәре ишетелгән кебек тоелды.

Юк, Ырынбур ягындагы район үзәге Хлебодаровкада да монафикъләр, икейөзле бәндәләр түгел, бәлки гап-гади кешеләр яши. Алар үлгәннәрне рәнҗетми, исәннәрнең хокукларын һәм күңел ачуларын кысмый торган гади һәм гадел тормыш кагыйдәләре, йолалар булдырганнар. Әкрәм Галиевич Хлебодаровкадагы тол һәм ялгызак хатыннарның аңа игътибар итүләрен, күз атуларын тоя, сизенә иде. Бәйрәмнәрдә яки берәр тантана көннәрендә дуслары, авыл советы һәм райбашкарма комитетындагы хезмәттәшләре чакырган һәр җирдә, үзен теге яки бу ханымга таба саклык белән әкрен генә этеп җибәрүләрен сизми, белми идемени? Ә кичләрен ара-тирә Җолдасларга самовар чәе эчәргә дип кенә кергәндә, бишбармактан авыз итәргә чакырганда, кунакчыл күршеләренә очраклы килеп кергән үзенә иш, тиң ханымнарга тап булмадымыни? Әлеге ханымнарның берсе дә, дуслары да өйләнү хакында чынлап яки шаяртып кына булса да сүз кушарга җөрьәт итмәделәр бит, кешенең кайгылы-хәсрәтле чагы, сөйләшү сәгате сукмаган әле дип уйлаганнардыр. Аның Хлебодаровкадагы тормыш-көнкүреше төрле имеш-мимешләргә урын калдырмый иде.

Танышу игъланы бастыруы белән дә бик нык ашыккан булып чыкты, күрәсең. Август аеның беренче якшәмбесендә Вера Федоровнаның елы, ай ярым диярлек вакыт калган, ә ул инде хатын сайлый-күзли башлаган.

Көннәрдән бер көнне Сабиров, эштән кайтышлый, автостанция янәшәсендәге базарга сугылырга булды.

Юл уңаендагы Хлебодаровка әллә ни зур булмаса да, теләсә нинди картадан эзләп таба алмасаң да, аның базарына мондагы халык өчен ят саналган яшелчә, җиләк-җимеш сатучылар агылып кына тора. Сөйләшүләрендә һәм үз-үзләрен тотышларында югары белемгә ия икәнлекләре сизелгән яшь кенә ике корея кешесе җирле колхоздан арендага яки, хәзергечә әйтсәк, подрядка алынган Хлебодаровка җирендә суган һәм карбыз үстереп саталар. Үзбәк карты туфрак каткан җиләк-җимеш, бу якларда үсми торган төрле тәм-том, аш тәмләткечләр сата. Алма-Ата тирәсендәге алма оясы Тюкульбастан килгән апорт алмасы кебек алсу йөзле чая гына бер ханым да алма сату белән мәшгуль. Иртә өлгерә торган алмалардан аңкыган хуш ис көнчыгыш тәм-томнарының да ачы исен басып китә.

Хлебодаровка әллә ни табыш та китерми, халык та төрле-төрле тәм-том, яшелчә, жиләк-җимеш ише нәрсәләргә әвәс түгел, бәяләр дә юнь генә, шулай да алу-сату бик сүлпән бара. Кайберләре балаларына, кайсылары авыру янына бару, өченчеләре кунак өчен дип кенә ала.

Әкрәм абзый да, тәмлерәк алма сатып алырга дип, базарга керде. Ул үзен танышы кебек кабул иткән алсу йөзле, уңган, чая ханымнан еш кына алма сатып ала иде. Ханым ерактан ук нотариуска елмаеп карап алды, ләкин чакырып тормады, бу вакытта аның тирәсендә күз чагылдыргыч полиэтилен пакетлар тоткан промкомбинат кызлары кайнаша иде. Әкрәм абзый алма алып та тормыйча җәһәт кенә базардан чыгып тайды. Шушы алма сатучы гына игълан буенча танышуыма сәбәпче, дип уйлады ул.

Еш кына тормыш тәҗрибәсе туплаган, һич тә җилкуарга охшамаган кешеләрнең дә кылган эш-гамәлләрен, уй-фикерләрен аңлый алмый хәйран каласың! Андый кешеләр үз бәхетсезлекләрен теләсә нәрсәгә — һава торышына, дүшәмбе көнгә, унөч санына, гадәттән тыш хәлләргә сылтап калдырырга әзер, бары тик алдын-артын уйламый кылган эш-гамәлләре өчен җавап кына тотмасыннар.

Бу хәлләр аның үзе белән пакеты да, сумкасы да булмаган көннән, сатучының аңа алмаларны «Вечерняя Алма-Ата» газетына төреп бирүеннән башланды: анда нотариус шаккатарлык игъланнар урнаштырылган. Андый игъланнар илебездәге өч-дүрт газетада гына басылса да, авыл аулак өйләренең шәһәрчә төре «Утыздан узганнар» клубы кебек таныш һәм мәгълүм иде.

Баштарак киң җәелеп киткән клублардагы эш бик тиз сүрелде һәм юкка чыкты: хатын-кызларның аеруча актив өлешенең тырышлыгы һәм гайрәте белән оешкан андый клублар, ихтимал, үз бурычларын хәл иткәннәрдер, ә калганнарының кулларыннан килмәгәндер. Клублар юкка чыкты, әмма игъланнар кала бирде, алай гына да түгел, хәтта Хлебодаровка кебек ерак авылларга да барып иреште.

Бәхетсезлеккә тарыган хатын-кызларның бер өлеше үзләре яшәгән шәһәрләрдә танышу игъланнары бирелмәгәнгә, кызыклы очрашулар клубы оештырылмаганга, кияүләр «җитмәү» кытлыгы килеп туганга, үзәк радио һәм телевидениене, танышу проблемаларын хәл итү өчен бөтен куәтен тулы җегәренә җигүне таләп иткән, «Маяк» радиостанциясен, илебездә берничә сәгать поясы булганлыктан, һәр ике-өч сәгать саен яртышар сәгатьлек танышу игъланнары тапшырып барырга, вакыт аермасы ун сәгать тәшкил иткәнгә, Магадандагы кияү егете, Карпат аръягындагы кәләше турында ишетеп калырга тиеш дигән киңәшләре теркәлгән хатлар белән күмеп ташлаганнар, дип сөйлиләр. Ә Үзәк телевидениегә кәләшләрнең иң шәпләрен бөтен гүзәллекләре белән күрсәтеп бару өчен шимбә көнне бер канал бирелсен, шул чибәрләрнең игелекле эшләрен сөйләгән язмаларны, әлбәттә, матур-аһәңле тавышка ия Василий Лановой тәэсирле итеп укысын, Вячеслав Тихонов үзе укыса тагын да әйбәтрәк булыр иде, дигән тәкъдимнәрен юллаганнар. Бөтенсоюз «Мелодия» грампластинкалар фирмасын да игътибарсыз калдырмаганнар. Шундый ук игъланнарны музыкага салып язылган дисклар һәм кассеталар чыгарганда, магнитофоннар һәм проигрывательләр җитештерүчеләрнеке кебек, фирманың да эшләре гөрләп барыр иде дип, читләтеп кенә эшлекле киңәшләрен күндергәннәр.

*«Сәламәтлегем әйбәт, холкым-фигылем, килеш-килбәтем дә күңелгә ятышлы, оста хуҗабикә, кечкенә генә берәр шәһәрдә яки авыл җирендә тыныч, мәшәкатьсез генә көн күрергә ятучы, урта яшьләрдәге бер ханым илле яшьләр тирәсендәге, шат күңелле булуы мәслихәт, кеше белән аралашучан, исерткеч эчемлекләр белән мавыкмаучы ир-ат белән танышырга тели...»*

Әкрәм абзый әлеге игъланны йөз тапкыр гына укымагандыр, мөгаен. «Урта яшьләрдәге бер ханым» дигән сүзләр аның дикъкатен җәлеп итте. Чама белән ничә яшьләрдә икән соң инде ул? «Кечкенә генә берәр шәһәрдә яки авыл җирендә тыныч, мәшәкатьсез генә көн күрергә яратучы» дигәнен дә ошатты ул.

Дөрес, кәефен кырган игъланнарга да тап булды ул.

*«Миңа 47 яшь. Югары белемле, җыр һәм музыкага мөкиббән, нәфис әдәбиятны һәм сәнгатьнең башка төрләрен дә яратам. Акылы-фигыле белән миңа тиң булырдай ир-ат белән танышырга теләр идем. Матди яктан тәэмин ителгәнмен: машинам, дачам бар...»*

Җыр һәм музыкага мөкиббән ханым бер ягы белән дә аның күңелен биләмәде, игълан иясе Хлебодаровкадагы Сабировны күздә тотмаган, күрәсең.

Нинди генә адреслар һәм тәкъдимнәр юк анда! Кая телисең, кемне телисең, җаның теләгәненңне сайла!

*«Мин тол хатын. Илле яшьләр тирәсендә, таза бәдәнле, кара чәчле. Ике балам да күптән урнашты, аерым яшиләр. Кырымда йортым, бакчам бар. Эшчән, хуҗалыкчыл, бакча эшләрен һәм чәчәк үстерә белүче ир-атны кабул итәргә теләр идем. Ир-атның таза-сау һәм озын буйлы булуы мәслихәт...»*

Кулына очраклы рәвештә «Вечерка» килеп кергән көннән, авыл советында эленеп торган зур дөнья картасына карап торган кебек, Әкрәм Галиевич кичләрен шул игъланнарны укып җенләнә иде. Серле, ят шәһәр исемнәре кайбер сәяхәтченең күңелен ничек җилкендерсә, бу игъланнар да аны шулай канатландырып җибәрде. Газетның бер нөсхә икәнлегенә үкенеп бетә алмады, хәтта почтага барып алдагы айдан язылырга мөмкин түгелме дип белешеп тә кайтты. Яңа елдан башлап кына дип кәефен кырдылар.

Кайбер кичләрдә газет укый торгач, күршеләренә самовар чәе эчәргә керергә кирәклеген дә онытып җибәрә иде.

Андый көннәрдә Җолдас ага хатынына самовар кертергә кушканчы, ишегалларын аерып торган пөхтә итеп буялган тәбәнәк киртә-койма аша карап ала, гадәттә, ишегалдында мәш килүче күршесен күрмәгәч: «Верасыз күңелсез Әкрәмгә, авырткан җиренә тоз салмавың хәерлерәк»,— ди. Самоварны алып кергәч, сирәк мыек очларына таба елмаеп, шаяртып кына янап ала: «Сабыр ит, дускаем, күршем минем, өйләндерәбез без сине. Картайган көнеңдә япа-ялгыз калу күңелле түгел, әлбәттә. Барысы да кешечә булсын дисең икән, вакыты җиткәнне

көт, яшебез белән дә мыскыллап көлүдән узганбыз, аннары яшьләргә әшәке үрнәк күрсәтүдән сакланырга, үзебез урнаштырган гореф-гадәтләрне дә бозмаска тиешбез».

Бу вакытта аның дусты ничәнче мәртәбәдер: «Мин, аксыл-сары чәчле, какча гәүдәле ханым, игелекле, авыл җирендә яшәүче олы яшьтәге ир кешегә кияүгә чыгар идем...» — дип укый торгач, уйлары белән шәһәр шаушуыннан туйган, шәхси тормышында уңышсызлыкка тарыган, арыган «аксыл-сары чәчле, какча гәүдәле» ханым янына, әле Кырымда бакчасы диңгезгә таба сузылган зур гына йортта яшәп яткан «кара чәчле, таза бәдәнле» ханым катына барып кайта. Кара чәчле ханымның игъланындагы «озын буйлы» булсын дигән шарты гына сагайта төште. Әкрәм Галиевич буйга ким-хур түгел, шулай да «илле яшьләрдәге тол ханымның» нәрсәне күздә тотуын аңлый алмады. Тол ханымга, мөгаен, аның икенче як күршесе ике метр чамасындагы Иван Гаврилюк иш булыр иде. Хәтта аны үз хатыны да, күздән ычкындырмаска тырышып, кая ул Кырымга — Иванның җитәкчеләре белән ачуланышмый торып, күрше колхозларга авыл хуҗалыгы эшләренә дә җибәрмәде. Иван Кырымга, диңгез буендагы бакчалы йортка күптән качып киткән булыр иде инде, чәчәк үстерүдән кала, тол хатынның бөтен таләпләренә дә туры килә икән килүен, әмма аның тормышын кинәт кенә үзгәртә ала торган андый кадерле газеты юк шул.

Ирләр игъланы да сирәк кенә очраштыргалады. Шундыйларның берсен Әкрәм абзый бастырмас иде, андый игълан, аңынча, хатын-кызга пычрак ата, аны хурлыйдыр сыман тоелды. Бу игъланны, мөгаен, хәзерге заманның саран эшкуары биргәндер, ни өчендер яшен әйтмәгән Винница киявен 47 яшьлек, җыр-музыкага мөкиббән, машиналы һәм дачалы ханым белән таныштырасы килде.

*«Мин 45 яшьтән узмаган, эшчән, мал-туар (сыер, дуңгыз), кош-корт (күркә, каз) асрый белүче, таза-сау хатын эзлим. Винница шәһәре тирәсендә 18 сутыйлы бакчам белән кирпечтән салынган йортым, умарталыгым бар. Эчмим, тартмыйм, өйдә утырырга яратам. Биюче дә, тел бистәсе дә түгел...»*

Винница тирәсендәге «биюче дә, тел бистәсе дә түгел» кияүнең хатын-кызларга мөрәҗәгате ни өчендер Сабировка тынгылык бирмәде. Нотариуска бу таныш сыман тоелды, ул аны көрсенергә дә, елмаерга да мәҗбүр итте, ачуын да китерде. Кайбер көннәрдә аның уйлары бай утар иясе тирәсендә генә бөтерелде. Хәтта хезмәттә ча-

гында, уйламаганда, кинәт аның чын күңелдән чакыруы исенә төште.

«Шуңа охшаганрак игъланны элек кайда ишеткәнем, укыганым бар иде соң?» — дип баш ватты Әкрәм абзый, кичергән гомерен күз алдыннан уздырып. Хәер, зурдан кубып искә алырлыгы да юк — Хлебодаровкадан сугыш кырына китеп барды, соңгы утыз елдан артык гомерен беркая да чыкмый шунда уздырды, гәрчә Верочкасы туганнарының хәлен белеп кайт әле, дип кат-кат тукып торса да, Ырынбурга да барганы булмады. Уйлана торгач, Винницаның саран кияве кебек, үзенең дә өйдә утырырга яратуын икърар итте. Шулай да шуңа охшаганрак игъланны кайчан укыганы бар иде соң аның?

Көннәрдән бер көнне эштә йомыш белән килүчеләрдән берәүнең «Крокодил» журналын онытып калдыруын күрде, исемә төште дип, чак кычкырып җибәрмәде.

Андый игъланнарны укыганы бар иде шул! Илленче елларның урталарындадыр, матбугат битләрендә һәм радио тапшыруларда Америкада мәхәббәт мәсьәләләрен хәл итү белән кешеләр түгел, бәлки, электрон кодагый — кампитр шөгыльләнә икән дигән хәбәр чалынып калган иде. Белдер яки хәбәр генә ит, кемне телисең — аксыл-сары чәчлесенме, кара чәчлесенме, коңгырт чәчлесенме, юанынмы, нечкәсенме, картынмы, яшенме, нинди холыклысын, хуҗалык эшләренә сәләтлесенме — машина шундук сиңа кирәген җыеп та бирә. Шундый юл белән өйләнергә, кияүгә чыгарга ниятләгән кешеләр хакында Верочкасы белән көлешә-көлешә укыганнары әле дә хәтердә. Газета хәбәрләренә сатириклар да, карикатурачылар да кушылдылар. Ул еллардагы «Крокодил» битләренә күз салсаң, хәзерге танышу игъланнарыннан әллә ни аерылып тормаган текстларга һәм рәсемнәргә тап буласың.

Бу ачыш бер мәлгә нотариусның кәефен бозды, ул чагында американнарның әдәпсезлекләренә чын-чынлап ачуы килгән, андый игъланнарга әхлаксызлык дип караган иде. Шулай да таушалып беткән газет аны үзенә җәлеп итте.

«Вечерняя Алма-Ата» газетына игълан бирергә кирәклеге башына да килмәде. Аның уйлары Кырымдагы «таза бәдәнле» яки «аксыл-сары чәчле, какча гәүдәле, шәхси тормышында уңышсызлыкка тарыган, арыган» ханымга хат язып карау ниятеннән ерак китә алмады, аннары бигүк ышанып та бетмәде. Тартынмыйча эч серләрен сөйләүләре аның гайрәтен чигерде:

*«Төсем-кыяфәтем килешле генә, күпне күрдем, инде тынычлана-басыла төштем, илле яшемә җиткәндә ярык*

*тагарак янында торып калдым, хыялый, хиссиятле ир кеше мин. Гомеремнең соңгы көннәрендә булса да, баш очымда ышанычлы түшәм, тугрылыклы тормыш юлдашы табуыма өмет баглыйм. Тыныч һәм җылы учак эзлим. Бернием белән дә шаккатырырга җыенмыйм, булган нәрсәмне үзем белән йөртәм. Гитарада уйныйм, җырлыйм, Верленнан алып Вознесенскийга кадәр булган поэзияне беләм. Гаилә учагын яктыртырмын, бизәрмен дип уйлыйм...»*

Сабыр холыклы нотариусыбыз «хыялый, хиссиятле ир кешенең»: «Оятсыз, юньсез, җир бит, ата мәче»,— дип, тетмәсен тетте генә.— Ярлы ябагай, каккан казыгың да юк ичмасам, шулай да инсафлы, намуслы ханымнар кирәк! — дип, укыган саен тузынды Әкрәм Галиевич.— «Гитарада уйныйм... Верлен... Вознесенский...» Пенсиялек тә эшли алмагансыңдыр әле, төсең-кыяфәтең килешле ата чикерткә. «Тыныч һәм җылы учак эзлим!» Акылың алтын икән, кем генә теләмәс икән андыйны?..»

«Шундый кешеләр дә нәрсәгәдер өмет иткәндә, Аллаһы Тәгалә миңа үзе боера түгелме соң? — дип куйды ул бер мәлне.— Минем белән теләсә нинди ханым, хәтта какча гәүдәлесе дә юкка чыкмас, ким-хур булмас, һәрхәлдә ышанычлы түшәм белән тәэмин ителәчәк...»

«Хыялый, хиссиятле ир кеше» игъланына ачуы килүдән ашыга-кабалана «Вечерка»га мөрәҗәгать итүенең илебездәге хатын-кыз затында шулкадәр кызыксыну уята алуын каян белсен ди авыл нотариусы. Аның исеменә кеше ышанмаслык меңнәрчә тәкъдимнәр, хәтта акча җибәрүләрен әйткән хатлар явар. Назга, хыялга, хистойгыга бай игълан бирүе белән картая башлаган аферист уйлаганча булыр да әле.

Әкрәм абзый тәвәккәлләде, игъланны мәгънәле, аңлаешлы, аны ниндидер җилкуар түгел, җитди, төпле, үзүзенә нык ышанган, үз сүзләренә җавап бирә ала торган кеше язган икәнлеген сизелерлек итеп бирәсе иде шул. Әкрәм абзый үзенең эш урынын, төс-кыяфәтен, планнарын, хыялларын, тәкъдимнәрен газетта берничә сүз белән ничегрәк биреп булуын күз алдына китерә-китерә: «Кирәк дисәләр, хәтта авыл советыннан раслатып та алдырырга була, кире какмаслар»,— дип уйланып утырды.

Булмый гына бит: әле берсе мин артык дип кычкырып, бүлтәеп тора, әле икенчесе мәгънәне биреп җиткерми, «Хлебодаровка авылы нотариусы» дигән сүзләр кызганыч булып тоелды аңа. Язганын укып карады да, хатын-кызның күңелен андый сүзләр белән генә канатландырып булмавын аңлап, боегып калды.

«Ярар, теге ярык тагарак янында торып калган ябайның хатын-кызларга әйтер сүзе дә, урыс булмаган Верлен белән Вознесенскийдан гайре бирер бүтән нәрсәсе дә юк ич, ә минем әйтер сүзем дә, тәкъдим итәр нәрсәм дә бар лабаса!» — дип фикер йөртте нотариус.

Шул хакта килешле дә, мәгънәле дә, кыска да итеп әйтеп бирә алмагач, ул кичләр буе ир-атлар игъланнарын кабат-кабат укып утырды, Винница киявенекен һәм, аты коргыры, илле яшьләрдәге гитаралы хыялыйныкын, әлбәттә, искә дә алмады.

Ир-ат игъланнары бик аз басылган, алар хатын-кызлар чакырулары янында күмелеп, төссезләнеп, тоныкланып калдылар. Әкрәм абзый аларны диңгез-океаннардагы бәләкәй генә утрауларны уратып алгандай, кызыл карандаш белән түгәрәк эченә ала барды. Ирләр, күрәсең, үзләре турында әллә ни әйтә алмаганга, тәкъдимнәре дә сай, мәгънәсезрәк килеп чыккан, гомумән, ир-ат заты үзен эчпошыргыч һәм сүлпән итеп таныштырган иде.

Әкрәм абзый әлеге кызыл утраучыклардан бер генә дә акыллы, төпле киңәш тапмады, ул янә газетның бер генә нөсхә икәнлегенә үкенде. Ике-өч нөсхә булса, еллык төпләмәсен әйтмибез дә инде, ул, һичшиксез, риясызларын да, канатландырганнарын да таба алыр иде, газетка акыл ияләре, хиссиятле кешеләр: журналистлар, артистлар, музыкантлар һ.б. катнаша торганнардыр әле, мөгаен.

Булмагач булмый икән инде. «Кыш уртасында чәчәкләр үсмәгәч, аларны кызгануың да мәгънәсезлек»,— дип, күптән укыган шигырь юлларын исенә төшерде Әкрәм абзый, хәтере әйбәтлегенә янә бер сөенде. Бу сиңа, «хыялый», ниндидер Верлен белән Вознесенский гына түгел, Есенин!

«Их! Үзем һәм бу йортка үз итеп килергә теләүчем хакында да шигырь белән генә язып бирсәң икән»,— дип хыялланып та алды нотариус. Рифмага салганда эш пешмәде, ниндидер «нотариус — пенсиус» кебек мәгънәсез юллардан ерак китә алмады, бүтәненә башы да, рифмасы да җитмәде, кырыс проза белән генә язарга калды.

«Әллә берәрсеннән булышуын сораргамы,— дип уйланып торды ул.— Әйтик, шул ук Җолдастан үтенсәң, ул баланс комиссияләре өчен облпотребсоюзга әллә нинди докладлар яза... Һәммәсе дә аны бер үзе генә яза икән, дип сөйлиләр!»

Верочка да: «Безнең бухгалтер мәгълүматлы кеше, белмәгәне юк!» — ди торган иде. Аның шундый икәнен Әкрәм абзый аңардан башка да белә.

Җирле газет мөхәрририен исенә төшереп: «Редакцияләү өчен Загорулькога биреп карасаң һәм тагын өч йолдызлыны да алып керсәң...» — дип фикер йөртте ул.

Әлбәттә, ул чагында уңышлы чыгачагына шикләнмәскә була, ни генә әйтмә — бер баш әйбәт, ике-өч баш тагын да яхшырак, ышанычлырак та. Әмма Әкрәм Галиевич планнарын, хыялларын бөтен Хлебодаровка халкына җиткерәсе килмәде. Җолдас, бәлки, сөйләп тә йөрмәс, ә Иван Петрович беренче сыра мичкәсенә җиткәнче генә түзәр, аннары көлеп кенә каравы да бар, журналист халкы белән бик сак эш итәргә кирәк. «Дус булсаң да, тәмәкең аерым булсын»,— дип тикмәгә генә сөйләнми торгандыр Загорулько.

Менә шушы хәлләр Сабировны чын-чынлап язу өстәленә утырырга мәҗбүр итте дә инде. Әдипләр язган юлларын унар мәртәбә шомартсалар, Әкрәм абзый иң таләпчән язучыны да уздырды — туксан җиде вариантта язды, туксан сигезенчесен «Вечерняя Алма-Ата» газетына җибәрде.

Җолдас агаларда кичен бишбармактан авыз иткәндә, гадәттәгечә, аппетит өчен бер-ике рюмка тоткач, туксан сигезенче вариантын язып ташлады. Язды да, вакыт шактый соң булуга карамастан, почтага салып та кайтты. Шулай тәвәккәлләмәсә, үзен тагын йөзенче һәм йөз илленче вариантын язып интектерәчәген белә иде ул.

Иртән, йокыдан торгач, Әкрәм абзый башкала газетына җибәргән игъланын кабат укып карамакчы иде, туксан сигезенче варианты бер утыруда, бер тын алуда язылган булып чыкты. Наталья Сергеевна Болдыреваны ашыгыч телеграмм сугарга һәм кинәт кузгалырга мәҗбүр иткән шул игъланның ничек бирелүен беркайчан да күрә алмады.

Аның игъланы, хәйләкәр, бу эштә остарып беткән коллегасы Загорулько редакцияләгәннән соң, түбәндәгечә басылып та чыкты: «*Пенсиягә чыгу алдында торган юрист шәһәрдәге тормышы белән шапырынмаучы берәр ханымны Ырынбурның тыйнак бер район үзәгенә чакырыр иде. Көчем, сәламәтлегем, тел-теш тидермәслек абруем, җәмгыятьтә тоткан урыным һәм матди хәлем гаилә корып яшәргә мөмкинлек бирә. Йорт-курам, җайга салынган хуҗалыгым, картлык көнеңне мәшәкатьсез генә уздыра, үзеңне чын хуҗабикә итеп тоя, тормыштан уңдым дип әйтә алуыгызга инандыра*».

Күзенә шул газета чалына калса, Әкрәм Галиевич редакциягә бернинди дә дәгъва белдермәс — бар да әйбәт, төпле, килешле. Аңа, мөгаен, «тел-теш тидермәслек аб-

руем, җәмгыятьтә тоткан урыным» дигән сүзләр аеруча ошар иде.

Нотариус Алма-Атага хат язып җибәрү белән ничектер кинәт боегып калгандай хис итте, газета белән кызыксынмый башлады, аны күз алдыннан ераккарак алып куйды. Ул төштән соң шул бер урында эшли башлаганнан бирле сүсәреп тузганчы кигән җиңсәсен иплəп кенә төреп сейфына салгач: «Нигә дип мәтәштердем инде мин бу эшне?» — дип көрсенде.

«Хлебодаровкада хатын-кызлар беткәнме әллә?» — дия иде ул кайчакларда, шунда ук кайберләрен: Вера Федоровнаның күптәнге дусты, райпотребсоюзда галантерея әйберләре буенча товаровед булып эшләүче Мария Петровна белән почта мөдире Мәрьямне күздән үткәрде. Егет чагында Мәрьямне шәһәр бакчасыннан берничә мәртәбә озата кайтканы да хәтерендә. Чибәр, ягымлы, мөлаем кыз иде бит!

Ырынбур якларында газ чыга башлаганнан бирле Хлебодаровкага килеп урнашкан райгаз начальнигы да соңгы вакытларда, кызыксынуын сиздереп, күз атып кала иде.

Җолдасларда кемнәрне генә очратмады ул. Казакъ мәктәбенең рус теле укытучысы Рәисә Әхмәтовнаны дисеңме, гәрчә ул Сабировтан күпкә яшь булса да, аны инде Бөркетбаевлар — күршесенең хатыны итеп күрәселәре килә иде, җирле педиатр, Җолдас ага җәмәгатенең дусты һәм коллегасы Флюра Исламовнаны дисеңме, (кырыс, боеручан ханымнан Әкрәм абзый шүрли дә иде) тагын... әллә кемнәрне очратты ул кунакчыл Җолдасларда!

Авыл советында җыештыручы булып эшләүче җыйнак, әмма вакчыл немец хатыны Фрида Яновна Грановскаяның тәкъдиме дә аның тынычлыгын алды, ул аны күптән түгел генә авыл советы ишегалдында туктатып, күптәнге танышы белән сөйләшкәндәй, уенын-чынын бергә кушып:

— Әкрәм Галиевич, минем өйдә ике сазаган кызым барын да онытмасагыз иде. Ничек диләр әле, бик үк яшь түгелләр инде, шулай да сезнең өчен бик кулай булырлар дип беләм,— дип шаяртып та алган иде. Һәм, көрсенеп, өстәп куйды:

— Кызларымның утырып калуларыдыр инде. Мартам да, Магдам да кырыкны вакладылар. Озак кына укып йөрделәр, үзегез беләсез — башта медицина училищесын, аннары медицина институтын тәмамладылар, бик озак кына сайландылар, үзсүзләнделәр, кире беткәннәр. Шоферы да, слесаре да ярамады, үзегез белә-

сез, гомер үтә. Хлебодаровкада кияү булырдай егетләр урамда аунап ятмый, ялгыштылар, хәзер риза да булырлар иде, алам диючесе генә юк шул. Кызларым әйбәт минем, эштән курыкмыйлар, беркем дә начар сүз әйтмәстер дип беләм. Истә тотсагыз икән...

Кайбер көннәрдә Хлебодаровкада күз атып йөргән ханымнар исемлегенә, кәефкә карап, үзгәрешләр кертелә, бүтәннәре өстәлә торды. Андый рәхәт мизгелләрдә үз-үзен онытып, киләчәккә планнар корып утырганда, кинәт кенә Әкрәм абзыйның газетка язып җибәргән хаты исенә төште дә кәефе кырылды. «Кирәксез ният, мәгънәсез эш»,— дип битәрләде ул үзен, хатның юлда югалуы яки барып җитмәве исенә төшкәч кенә тынычланды.

Шәһәр тормышының имеш-мимешләреннән хәбәрдар булганга: «Югалмаган тәкъдирдә дә юл бирмәсләр, редакциядә танышлык белән үзләренекен беренче нәүбәттә бастыралар»,— дип фараз итте ул. «Безгә, Хлебодаровкага, үз теләге белән килергә кем җөрьәт итсен, ди? Резин итекләр киеп ел буе саз ерырга, кышын атналар буе көнтөн мич ягарга кем риза булсын икән?» — дигән уй гына тәмам тынычландырды аны.

Хат башкалага хәвеф-хәтәрсез генә барып җитте һәм газетның игъланнар бүлеге мөхәррире өстәленә килеп керде. Авыл нотариусының туксан сигезенче вариант хаты кырыс картның да күңелен эретеп, нечкәртеп җибәрде. Әкрәм абзыйның бишбармактан соң буталчык озын хат язуын истә тотсак, мөхәррирнең чын күңелдән тырышуын әйтергә кирәк. Хатның алдагы саннарның берсенә тоткарлыксыз кереп китүендә мөхәррирнең бернинди катнашы юк: ир-ат игъланнары бик сирәк килә иде.

Алдаша белмәгән намуслы Әкрәм абзыйга бер фикер тынгылык бирмәде, бүтән берәүнең исе дә китмәс иде, газетка ул үзе турында бигүк төгәл булмаган мәгълүмат җибәргән икән ләбаса. Белемен юрист дип кенә язган бу, әлбәттә, университет белеменә ия дигән сүз.

Университет белеме ул — башкалада яки университетлы шәһәрләрдә студент тормышы, биш ел буе уку — мәдәният, спорт белән шөгыльләнү, карашларыңны, кызыксынуларыңны үстерү, баету: театрларга, музейларга, спорт залларына йөрү, башка гуманитар факультетлардагы дусларың белән якыннан аралашу ул. Кыскача гына әйткәндә, университетта укыган кеше киң белемгә, югары культурага ия булып чыга, дөньяга карашын, тормыш итү рәвешен, гадәт-күнекмәләрен формалаштыра.

Юридик хезмәткә утыз еллап гомерен багышлаган Әкрәм абзый, кызганычка каршы, андый белемгә һәм культурага ия була алмады шул, дөрес, ул фидакарьләрчә эшләде, тырыш хезмәте күптөрле бүләкләр белән билгеләп үтелде. Сугыш аның юридик факультеты булды.

Мәктәп тәмамлауга ук, сугышка хәтле, районнан Ырынбурдагы юридик курсларга укырга җибәрделәр, шуннан фронтка озаттылар. Әкрәм Сабиров та, яшьтәшләре кебек, сугышның алгы позициясенә омтылып караган иде дә, ул дигәнчә барып чыкмады. Юридик курсларда укуын искә алып, тизләтелгән стажировкадан соң, хәрби-кыр суды аппаратына канцелярия эшләрен алып баручы, ягъни эшбашкаручы итеп куйдылар. Машинкада басты, стенограф та булды, кәгазьләр белән эш итте, хатлар язды. Эшен төгәл, пөхтә башкарды. Өенә ул җәрәхәтләнеп, контузия алып, ике орден белән бүләкләнеп, офицер булып кайтып төште. Интендантларга да, табибларга да сугышта катнашырга туры килде, төрлесе булды, хәрби юристлар исә сугышның иң кайнар нокталарында, утлы мәхшәр эчендә йөрделәр.

Кайчагында ул үзен Верочкасы алдында гаепле саный, юк, өйләнергә йөргәне өчен түгел, анысы, тормышның табигый дәвамы кебек, үзеннән-үзе аңлашыла. Берәребез бу фани дөньядан иртәрәк китә калса, бер-берсенә хыянәт итешмәскә дип васыять тә әйтешмәделәр, гомумән, алар бу хакта бөтенләй сөйләшмәделәр. Вера Федоровна көтмәгәндә, көче, гайрәте ташып торган чагында — кышын гына илле яшен билгеләп үткәннәр иде; авырганы булмады, зарланмады, ә бер көнне кинәт кенә дөньядан китте дә барды. Ул үзенең игъланындагы: йорт-курам, хуҗалыгым... дигән сүзләре өчен уңайсызланды.

Әлбәттә, утыз ел бергә яшәү дәверендә алар азмы-күпме мал-мөлкәт туплаганнар иде туплавын, ә бүләр, бирер кешеләре юк. Бергә яши башлауларының беренче елларында Верочкасы врачларга, имче-томчы карчыкларга күренгәләп йөрсә дә, Аллаһы Тәгалә аларга бала бирмәде. Әкрәм абзый беркайчан да эшсез тормады, һәрвакыт хезмәттә булды, окладлы да ярыйсы гына — сугыштан соңгы елларда кеше таба алмаганда, нотариусның сигез йөз сум окладлы бик зур акча иде. Шул сигез йөз тәңкә өстенә тагын ныклы таянычы бар — бөтен районга төпләү эшен белүче бердәнбер кеше, кәгазь гасырында андый һөнәр дә ярап куя икән. Гаилә бюджетына аның керткән өлеше саллы булса да, йортны тоту Вера Федоровна җилкәсендә иде — Сабировларны белүче һәркем шулай дияр, Әкрәм абзый да шуны ук әйтер.

Верочканың кулыннан килмәгән эше юк, һәр эшне ду китереп эшләп ташлый, ут уйната; Винница кияве, мөгаен, әнә шундыйрак хатын турында хыялландыр...

Сабировлар Хлебодаровкада беренче булып йорт салып керделәр, анысы да Верочканың тырышлыгы аркасында. Әкрәм абзый булдырып чыга алуларына бигүк ышанып та бетмәгән иде.

Тәки җиңеп чыктылар бит! Агачын да, шиферын да, цементын да, тәрәзә пыялаларын да, алдан хәстәрен күреп, берәмтекләп диярлек Верочка булдырды. Ул чагында илленче елларда, хәзерге белән чагыштырганда, авыл җирендә төзелеш материалларына кытлык зур иде. Йорт салу өчен кирәкле саманны алар ике җәй буе суктылар — бил бөктеләр, каян килгәндер ул көч-гайрәт, хәзер үзләре дә шаккаталар. Калыплары берьюлы ике саман сугарлык итеп, ике катлап ясалган, һәркайсына алтышар чиләк сутлы балчык салалар, бу үзе бер центнер чамасы. Кара тиргә батканчы эшләделәр, көянтәләп су ташый-ташый иңбашлары суелып, чиләнеп бетте, һәр чиләк суны коедан кул көче белән чыгардылар, үз коелары булмаганга, күрше урамдагы уртак коега йөрделәр.

Сутлы балчык измәсенә су саласың, саласың, ул аны үзенә сеңдерә — эчә генә, эчеп туйгач, чапылдый башлый. Шуннан соң сутлы балчыкны ат кебек таптап изделәр, аяклары саламга кадалып, җәрәхәтләнеп бетте. Җәйге эссе көннәрдә Верочка оек кимичә кеше күзенә күренә алмады. Шулай итеп, өй җиткергәндә дә Верочка Әкрәмне саклау хәйләсен тапты, моны сизмәскә мөмкин идеме соң?

Верочка эштә гаярьлеге белән бергә, башын да эшләтә белде. Идән асты да, пыяла веранда да, дүртьяклы өй түбәсе кыегы да, авыл җиренә хас булмаган зур тәрәзәләр дә ул уйлаганча эшләнде.

Тормыш юлын ул райпотребсоюз бухгалтериясендә вактөяк йомышлар үтәүче булып башлап җибәрде, баштарак аңа товар-транспорт накладнойлары тутыру, инвентаризация һәм исәпкә алу үткәргәндә кирәкле исемлек төзү эшен генә тапшыралар иде. Җолдас аның бухгалтерия хезмәткәре өчен кирәкле бер сыйфатны — ачык, матур итеп язуын гына түгел, бәлки кызыксынучанлыгын, төшенергә, аңларга тырышуын күреп алды, аның белән алга таба да эшләргә туры килүен күздә тотып, биш ел чамасы үзенчә өйрәтте. Кайчагында Җолдас: «Кызганыч, хисапчы хезмәткәргә диплом бирү хокукым юк, югыйсә Верочкага, һичшиксез, кызыл диплом бирер идем»,— дип шаярта торган иде.

Табигате белән кырыс авыл кешесе кемнең кем икәнен бик тиз аера. Авыл советы көнбатыштагы кебегрәк «Кемнең кем икәнлеге турында» дигән еллык журнал чыгармаса да, кемнең яхшы укытучы, табиб, парикмахер, сатучы икәнен белә, ә кайсысын, күрмәскә тырышып, бер чакрымнан әйләнеп үтә. Вера Федоровнаны район үзәгендә шөһрәтле бухгалтер дип беләләр иде. Имеш-мимешләргә караганда, майны чит илгә чыгаручы җирле май заводына, Хлебодаровкада иң зур саналган РТСка да аны берничә мәртәбә баш бухгалтер итеп кыстап караганнар, гәрчә алар зуррак оклад һәм премия вәгъдә итсәләр дә, Верочка үзен тәрбияләгән коллективтан китмәгән.

Йорты, хуҗалыгы турында уйлаганда, Әкрәм абзый, әлбәттә, Верочканы да истә тоткан иде. Буранлы, җилле озын кышкы кичләрдә станогында эшләп утырганда, Верочкасы авыз эченнән генә сагышлы җыр сузып, мамык шәл бәйләгән чакларын күз алдына китерде, шәл бәйләүдә ул оста бәйләүче татар хатыннарыннан һич тә калышмас иде.

«Нигә ул мине саклады, кадерләп, иркәләп, назлап кына торды икән? — дип, баш ватты ул. Верочкасы исән чакта бу хакта уйлап та караганы булмады.— Шулай бик нык яратты микәнни? Әллә сугыштан соң сирәк очрый торган офицер егетнең күпләр арасыннан аны гына сайлап алуы белән исәпләшүе иде микән? Әллә мин күздә тотмаган, белмәгән, сизмәгән бүтән берәр хикмәте бар иде микән?..»

Хәзер, Верочканы югалтканнан һәм «Вечерняя Алма-Ата»дагы хатын-кызлар игъланын ятлап диярлек бетергәннән соң, шундый фикергә килде: сугышка кадәр туган хатын-кызларның күбесе гаилә өчен җаваплылык хисе тою рухында тәрбияләнде һәм яшәде, иренең тышкы кыяфәтенә карап хатыны турында хөкем йөрттеләр, ә яхшы хатынның, хуҗабикәнең җәмгыять алдындагы абруе шуннан чыгып билгеләнде, шулай тиеш дип саналды. Ә бүген хатын-кыз үзе хакында, аның килеш-килбәтенә карап кына фикер йөртәләр, ире, йомшак кына итеп әйткәндә, шапшак һәм пычрак йөри икән инде, анысы ирнең үз хәсрәте, ирнең әхлакый йөзе көяз хатынга берничек тә тап төшерми, дип уйлый.

Верочканың кайгыртучанлыгы аркасында Әкрәм Галиевич киенеп-ясанып кына йөрде. Инде икесе эшкә барганда яки эштән кайтканда, аларга сокланып карап калмаган кеше юк: икесе дә озын буйлы, чиста, пөхтә, үтүкләнгән киемнән, әллә кайдан уңган хатын-кыз кулы тигәне күренеп тора...

Бакчадагы һәр төп сирень, чия куагы турында сөйләгәндә, Верочканың исемен телгә алмый калу мөмкинме соң? Аннары газетка хатының хакында язмассың ич инде, Әкрәмнең кем булуы, нинди эш майтаруы белән ханымнар үзләре кызыксына бит.

Әкрәм Галиевич тәмам буталып, башы катып бетте, җитмәсә әле Сахалиннан телеграмма да килеп төште.

Телеграмма нәрсәдер эшләүне таләп итә. Бер мәлне: «Килеп йөрмә инде!» — дип җавап кына бирим булмаса дигән уй да үтте аның башыннан. Ләкин кая? Авылга бабайгамы? Хәтта газетка җибәргән фикереннән кире кайтуын да белдермәкче иде. Бу уе аңа мәзәгрәк булып тоелды, газетчылар телендә анысы ничегрәк дип йөртелә торгандыр. Мондый очракка туры килә торган сүзе дә юктыр әле: кире кагумы, баш тартумы, кире уйлаумы. Аныңча, хәрбиләрнең «отбой» дигән сүзе туры килә сыман иде.

Бик авырлык белән язылган танышу игъланыннан «кире уйладым» сүзе кәгазьгә төшерүне сорап тора:

«Кире уйладым. Кызганычка каршы, Хлебодаровка юристы бүтән шәһәрдә торучыларга гаилә корып яшәргә мөмкинлек бирүеннән баш тарта. Үзем яшәгән район үзәгендә туган (акклиматизация, адаптация һ.б.), илле яшьтән дә олы булмаган ханымны кулайрак булыр дип табам».

Менә шунда инде, мөгаен, хатын-кызлар бөтен илгә аның куркаклыгы, кыюсызлыгы, җавапсызлыгы өчен хурлап, мыскыллап, тирән нәфрәтләнүләрен белдереп чаң сугарлар, Хлебодаровкада да Әкрәм абзыйга кырын һәм төкереп караучылар табылыр, ул «хыялый» аферисттан да ким хат алмас, әмма ул хатларда акча гына булмас. Ләкин, ничек кенә боргаланма — артка юл ябык. «Ни булса, шул булыр!» — диде дә, кибеткә барып, ике шешә шампан шәрабы алып кайтып куйды.

Төпле кеше буларак, эшне ул Наталья Сергеевнаны каршы алу программасы төзүдән башларга ниятләде. Якшәмбе көнгә, Вера Федоровна барындагы кебек, бөтен җир «наять» булсын дип, ишегалдын һәм өй җыештыруны шимбә көнгә, атна ахырына калдырып торды. Шампан шәрабы белән дә мәсьәлә хәл ителде. Программаның «үзәген» кызыграк, үзгәрәк итеп төзисе генә калды.

Әмма «үзәк» җиңел генә табылмады, «юк, бу да түгел...» дип, әле берсен, әле икенчесен кире какты, борчылудан хәтта тирләп чыкты — башына бер юньле уйфикер килмәде. Кинәт, мунча, дип куйды ул.

Сауна белән җенләнү шау-шуы Хлебодаровкага килеп җиткәндә, аларның моннан өч ел элек кенә бакча почмагына терәп диярлек салган үз мунчалары бар иде. Әкрәм абзый аны үзенә бер төрле хәйлә-осталык белән җиткерде: телисең икән — утын як, телисең икән — вакытың яки утының булмаганда электр белән җылыт, теләсәң — урысларча, ягъни бер лакан су коя-коя, себерке белән чабын, телисең икән — финнарча рәхәтләнеп парланып утыр. Моны уйлап табучыга патент-таныклык бирсәң дә хәрәм булмас!

«Ерак юлдан килгән кеше өчен — мунча программаның үзәге инде»,— дип хәл итте Әкрәм абзый һәм мунчага таба юнәлде.

Мунча якмавына өч ай узган. Әкрәм абзый ике кичтә аны тәртипкә китерде, бер уңайдан ләүкәсен төзәткәләде, каккалады, сауна-мунча Наталья Сергеевна килүгә әзер булгач, ерак юлдан килсә дә, мунча кертү килешеп бетәрме соң дип шикләнеп тә алды. «Кара син аны, оятсыз картны, бик тиз генә мунчага чакырмакчы?» — дип уйласа? Уйлады-уйлады да программаның үзәгеннән баш тартты.

Шулай уйлана-уйлана һәм шикләнә-шикләнә хәстәрлек күрү мәшәкатьләре белән җенләнеп йөргән арада, атна уртасы да килеп җитте. Чәршәмбе көнне кичен аларга Җолдас ага сугылып чыкты.

Бухгалтер ишектән үк, дустына:

— Әссәламегаләйкем,— дип, сәлам биреп керде.— Нигәдер күңелсезләнеп-боегып калдың, керми да башладың. Мин йомыш белән кергән идем: тиздән Вера Федоровнаның елы җитә, колхоз белән сөйләшеп кайттым, ике сарык язып бирерләр, син аларны бер-ике атна алданрак алып кайт та минекеләр янына ялан абзарга илтеп яп. Ашатырбыз, симертербез, мин аның махсус ысулын беләм,— диде дә уңайсызланып, аптырап калган дустын кочаклап алды.

«Телеграмм килгәнне белә микән, юк микән?» — дип, әле агарынды, әле кызарынды Әкрәм абзый.

— Ишегалдында тыз-быз киләсең, себерәсең, мунча ягарга да ниятләгәнсең димме,— дип сөйләнде Җолдас ага.— Ялгыз башыңны кая куяр урын таба алмыйсыңдыр инде? Аңлыйм, туганкай, бик аңлыйм.

«Белми, белми икән»,— дип, тынычланды Әкрәм абзый. Рыясыз, хәйләсез мужик иде Бөркетбаев — нәрсәдер әйтергә кирәк, кеше энә түгел, кесәгә яшерә алмассың, кунак ханымны барыбер күрәчәк. Әкрәм абзый, ниһаять, әйтергә кирәк тапты:

— Җолдас, якшәмбе көнне Ырынбурдагы чыбык очы кыз туганыбызның килеп төшүе ихтимал. Буйдак ирнең ничек яшәвен күреп китәрмен дип вәгъдә иткән иде,— диде ул, икеләнебрәк кенә.

Җолдас ага:

— Кунак килү — күңелле хәл. Сөйләшерсез, гәпләшерсез, күңелең дә күтәрелер. Кунагың белән безгә дә кереп утыр,— диде дә хушлашып чыгып та китте.

Күршесе чыгып киткәннән соң, төне буе йоклый алмый интекте. Әкрәм Галиевич Верочкасының елын уздыру, сарыкларын елга аръягындагы далага илтергә кирәк булуы, бигрәк тә Наталья Сергеевна Болдырева турында уйланып ятты. Ниндирәк икән? Акыллымы, игелеклеме, эшкә оста микән? Әллә берәр җилбәзәк микән? Картаның да иң чигендә, аннан бүтән барыр урын юк — диңгез-океан башлана, шулай да Көньяк Сахалинга хәтле барып җитүен, төпләнеп калуын күр әле син аның.

Йокысыз үткәргән төндә черем итеп алган мәлдә дә өзек-өзек кенә төш күрде. Төшендә ул Наталья Сергеевнаны әллә ничә төрле кыяфәттә — әле карлыккан тавышлы, кайнар хисле, кара чәчле ханым, әле кай ягы беләндер лакланган бармакларына йөзек-балдак кигән райгаз мөдиренә охшаган, әле таза бәдәнле, аксыл-сары чәчле җитди, тәкәббер ханым итеп, әле дулкынлы океан ярында джинсы чалбар киеп басып торган яшь кенә бер хатын сурәтендә күрде...

Иртән эшкә барышлый хат ташучы Сташованы очратты, ул аңа газетлар белән бергә «Человек и закон» журналын тоттырды, аннары, нидер исенә төшкәндәй, сумкасыннан ике хат алып бирде.

Әкрәм Галиевич бик сирәк хат ала иде, шуңа күрәдер берьюлы ике хат килүе гаҗәпләндерде аны. Конвертлары матур, бик пөхтә итеп язылган, берсеннән хушбуй исе аңкый.

Хатлар Сабиров исеменә язылса да, почеркларын, кайдан килүләрен белә алмады. Ул аларны танышу игъланына бәйләнеше бардыр дип уйламаган да иде, аннары гына беренче хәбәр — җавап хатлары икәне исенә төште. Кызыксынуы хәттин ашса да, хатларны урамда укып тормады, җәһәт кенә кесәсенә салды да эшенә китеп барды.

Иртәнге якта йомыш белән килүчеләр бер-бер артлы килә-китә торды, эш белән мәтавыкланган Әкрәм Галиевич хат алуын да онытты. Хәләл җефете вафат булганнан соң, ул төшке ашка райпотребсоюз ресторанына йөри башлады, анда тәмле пешерәләр, кыйммәт тә түгел, ан-

нары аңа мөнәсәбәт тә үзгә иде. Ишектән чыгып барганда, буфетчы хатын:

— Әкрәм Галиевич, кайчанга хәтле буйдак булып йөрергә уйлыйсыз? Күз уңымда тоткан бер дус хатыным бар, теләсәгез таныштырам,— дигәч кенә, хатлар алуы исенә төште.

— Анна Ивановна, дус хатыныңнан да бигрәк үзегезнең исәбегез булса, уйлап карар идем әле,— дип җавап бирде Сабиров.

Төштән соң, гадәттәгечә, йомыш белән килүчеләр юк, ул яшерми генә хатларны кесәсеннән алды. Ачканчы, һәрберсенә алыну көнен, вакытын, кирәк була калса дип, исәп санын да язды, шуннан соң гына бер кырыеннан кайчы белән кисте.

Хатлар төрле җирдән. Берсе — Куйбышевтагы укытучыдан, ул кияүгә чыгармын дип өмет тә итми идем инде, ялгыз яшәвемне һәм хыялларымны яхшы белгән дус хатыным, мине берәр юньлерәк җиргә урнаштыру нияте белән, танышу игъланы басылган газет алып кергән иде, дип язган ул.

«... *Без икебез дә,*— дип дәвам итә укытучы ханым,— *сүз берләшми генә, сезнең игъланга тукталдык. Безгә калса, сез — хөрмәткә лаек кеше, без белмәгән ниндидер сәбәпләр аркасында кинәт кенә ялгыз торып калгансыз, дус хатыным шаяртканча, сезнең өчен тәвәккәлләргә дә мөмкин. Бөтен бәла дә шунда: мин үзем сезнең янга килергә берничек тә җөрьәт итә алмыйм, гәрчә сезнең белән бик танышырга теләсәм дә, үземне җиңәрлек көч юк. «Исәнмесез, бу мин, сезгә кияүгә чыгарга булдым»,— дип килеп керүемне күз алдыма да китерә алмыйм.*

*Кабатлап әйтәм, үзегезне белмәсәм-күрмәсәм дә, сез миңа бик тә сөйкемле күренәсез, мин сезнең гаилә корып яшәргә инандыруыгызны хуплыйм, үземне чын хуҗабикә була алыр идем дип әйтергә батырчылык итәм. Хәзер мәктәптә каникул вакыты, мин көннәр буе өйдә, сезне чын күңелемнән кунакка чакырам. Зинһар, килә күрегез, Ырынбурдан поезд белән безгә биш сәгатьлек юл. Каршы алырмын, шөһрәтле шәһәребезне, Иделне күрсәтермен. Миңа калса, шулай танышу урынлы да, каһарманнарча да булыр.*

*Ихтирам белән, Елена Максимовна*».

Сул яктагы өске өлешенә җете кызыл роза чәчәге төшерелгән, юка шома аксыл-зәңгәр кәгазьгә язылган икенче хат нотариусны тәмам шаккатырды.

Тылдан, картлардан килгән өчпочмаклы хатларны исәпләмәгәндә, шәхсән үзенә атап язган хатлар алганы

булмады аның. Аларын да әле әнисе әйтеп торып күршеләреннән берәрсе язган: картларның укый-яза белүләре чамалы. Гарәп хәрефләре белән әйбәт кенә укый-яза белгәннәр. Соңрак көч-хәл белән үзләштергән латин шрифты да юкка чыгарылды. Өченчесен, кириллицаны исә тәки өйрәнә-үзләштерә алмый интектеләр. Чит кешегә әйтеп торып күп яздыра аласыңмы соң, аннары заманы да кырыс, нәрсә яздырырга яраганын да белмәссең — солдатның кәефен кырмассың бит инде. Шуңа күрә аларның хатлары: ничек сугышасың, ничек яшисең, каһәр төшкән сугышның очы-кырые күренәме, кебек сораулардан гыйбарәт була торган иде.

Ә монда, карт көнеңдә, беренче мәхәббәт хаты килсен әле. Андый ягымлы сүзләрдән башың әйләнеп китсә дә гаҗәп түгел.

*«Сөеклем Әкрәм Галиевич,*— дип башлана иде икенче хат.— *Шулай дип мөрәҗәгать итүемне алдан ук гафу итә күрегез, алга таба да, мөгаен, үземнең катлаулы, сикәлтәле тормыш юлымда туплап, җыеп һәм саклап килгән ягымлы сүзләремне сезгә җиткерүдән тыелып кала алмамдыр.*

*Әйе, әйе, мин тел-теш тидермәслек һәм җәмгыятьтә лаеклы урын алып торган кеше очратырмын дип белә һәм ышана идем. Мин бары тик шундый кешегә генә җаным һәм тәнемне бөтен барлыгы белән бөтенләйгә бирергә әзермен. Бөтенләйгә яки юк! Нигә хисләрне вакларга, шулай түгелме? Эчәсең икән инде — шампан шәрабы гына эч, яратасың икән инде — корольне генә ярат! «Вечерняя Алма-Ата»ны мин беренче танышу игъланнары басыла башлаганнан бирле алдырып киләм. Кайберәүләр китап төпләгән кебек, мин аларны еллап төпләп барам. Шундый игълан бастырган «Ригас балс»ны да алдырам, әмма, ышанасызмы, мине бер генә игъланның да, сезнеке кебек, тәэсирләндергәне, исәрендергәне булмады. Мин шундук аңлап алдым: сез — минем язмышым! Соңыннан шигъриятле итеп: «... тормыштан уңдым дип әйтә алуыңа инандырам»,— дип дөрес әйткәнсез. Икърар итегез, сез серле шагыйрь!*

*Көзге озын кичләрдә тышта котырынып, шөбһәле, җилле, салкын яңгыр яуганда, мин тирән күн кәнәфигә утырып камин алдында күшеккән иңнәремә ырынбур шәле ябынып (хәзергә андый шәлем юк), сез яраткан «На страже социалистической собственности» дигән газетны һәм «Человек и закон» журналын (мин дә аларны яратам) кычкырып укырмын. Ә сез мәһабәт һәм көчле (мин сезне шулай күз алдыма китерәм), чал чәчле,*

*авылда закон һәм хокук тәртибе урнаштыруга бөтен гомерен биргән кеше, өстегезгә бәрхет халат киеп (аның мин үзем бүләк итәрмен), артымда басып торган хәлдә нәфис бармакларыгыз белән чәчләремнән сыйпарсыз. Каминнан җете кызыл бәрхеткә төшкән ут телләре яктысы сезнең чәчләрегезне тагын да күркәмрәк итеп күрсәтер.*

*Кадерлем минем, караңгы авылда булса да, тыныч кына закон һәм хокук, урлау һәм әрәм-шәрәм итүгә (урындагы кешеләрне күздә тотам) кагылышлы рухи әңгәмәләр корачак камин янындагы кичләребезне яратып та өлгердем инде мин, сез, юристлар бөтен кызыклы, гыйбрәтле хәлләр турында хәбәрдар кешеләр ич. Мин сезне ярата алырмын, мактауга лаеклы карт көнегездә тугрылыклы юлдаш булырмын дип беләм һәм тоям. Сезнең көзге тормышыгызны бизәп кенә калмам, бәлки ямь дә өстәрмен. Мин дә чәчемне чал төскә буятырмын да, икебез дә сокланырлык булырбыз. Дөньяны, сезнең кебек, шагыйрьләрчә күрә алучы кеше, нечкә хисле, бик тиз уалырга торган хыялый дөньямның, саф, гүзәл хисләремнең, озак елларга хәтле тугрылыклы булып калуымның кадерен белерсез, дип ышанам. Мин сезне генә көттем, мине күрүгә, тавышымны ишетүгә, күзләремә карауга, дәртле кайнар кочагыма ташлануга ук, сез моның шулай икәненә бик тиз төшенерсез, һәм, ышаныгыз миңа, мин хисләремнең кайнарлыгын гына саклап калмадым... Мин бары тик хисләр турында гына язам,— безнең киләчәк тормышыбызда иң мөһим нәрсә дә шул түгелме соң? Мин хисле хатын, хатын-кыз — серле дөнья! — дип зерә генә әйтмиләрдер.*

*Шуңа күрә үзегез килеп, икебез дә рәхәтләнеп ләззәтләник дисәгез, шул серле дөньяны ачыгыз, шул чагында, һичшиксез, үзегезнең «...тормыштан уңдым...» дигән акыллы сүзләрегезне янә бер кабатларсыз.*

*Тәмләп-тәмләп, дәртләнеп-дәртләнеп үбәм һәм кысып-кысып кочаклыйм. Көтәм, сөям. Сөеклем минем, көтә-көтә зарыгып беткән җанкаең янына ашыга күр, озак зарыктырма инде аны.*

*Синең Белла, Белочка дисәң да ярый».*

Әкрәм Галиевич дулкынлануыннан пиджәген дә салды, борчылып бүлмә буйлап йөренергә кереште. Көтелмәгәнчәрәк килеп чыкты бит әле бу хәлләр. Бер мизгелгә Наталья Сергеевна күз алдына килде, юкка да чыкты.

— Ай-һай чая хатын! — дигәнен сизми дә калды.

Верочкасы белән утыз ел яшәү дәверендә дә андый

ягымлы сүзләр ишетмәгәндер! Үзенә бер төрле серлелек сирпелә иде алардан!

«Чыннан да хисле хатын,— дип җөпләде Әкрәм абзый. «Хисләремнең кайнарлыгын», «уалырга торган хыялый дөньямның», «сезнең көзге тормышыгызны» — дигән сүзләрен искә төшереп.— Акыл да соң үзендә! «Хатын-кыз — серле дөнья»!»

Ул «гүзәл чал чәчләрен» үзе дә сизмәстән сыпыргалап алды. Чал чәчләре мактанырлык түгел түгелен, вакыт дигәнең чигә чәчен генә чаларткан чалартуын, гомумән, нотариусның чәчләренә кайбер яшьләр дә көнләшерлек.

Хатны кабат укып чыккач, кәефе тагын кырылды: «озын нәфис бармакларыгыз» дигәне дөреслеккә туры килми. Нотариусның җилдән һәм судан кызарган кыска бармаклы көчле куллары Хлебодаровка кешеләреннән ай-һай аерылыр микән, биредә һәркемгә — судьяга да, прокурорга да, эшчегә дә үзенә утын ярырга, күмер ягарга, мал-туар карарга туры килә.

Куйбышев укытучысының хаты аның күңел кылларын тибрәндермәде, шулай да өйгә кайтканда ул хатны сейфына салып калдырды, өйдә тагын бер кат тынычлап укып чыгармын дип, «Белочка»ның хатын үзе белән алды.

Кичке аштан соң Әкрәм абзый өендә күн кәнәфие булмаганлыктан, диванга барып ятты да хатны кабат укый башлады. Хат аны җәлеп итте.

«Кара син аны ничек алдырмак була, нинди генә сүзләр әйтмәгән!» — дип куйды ул, «Белочка»га сокланып, әмма трюмодан үз сурәтен күргәч, ялкынлы дәрте шундук сүрелде дә.

Шундыйрак хат бүтән берәүгә килсә, Әкрәм абзый мыек астыннан гына елмайган, елмаю гынамы әле, чын күңелдән рәхәтләнеп бер көлгән булыр иде: камин, халат, салкын яңгыр яуганда, рухи әңгәмәләр... имеш. Әмма үзеннән көләсе килмәде, шулай да «сез — минем язмышым», «мин сезнең көзге картлыгыгызны бизәрмен», «озак көттереп зарыктырма» дигән сүзләрне укуы рәхәт иде аңа.

«Безнең ишеләр белән менә ничек сөйләшергә дә була икән әле»,— дип куанып ятты нотариус. Күршесе Иван Гаврилюкка бөтен Хлебодаровканы шаулаткан хат килүен исенә төшергәч, бу куанычы да кинәт тоныкланып калды.

Бер мәлне Иванны ерак бер колхозга печән чабарга җибәргәннәр иде, монысы һәр кала кешесенә аңлашыла. Колхозда уңайлы шартлар — кунак йорты да, гомуми торак та юк, аннан соң җәмгысе дүрт кеше барган. Алар-

ны карт-корыларга, ялгыз хатыннарга фатирга урнаштырганнар. Көзен, игеннәрне җыеп алыр чак җиткәч, Иваннарга бер хат килеп төшә. Гаврилюкларга да, Сабировлар кебек, сирәк кенә хатлар килгәли, шау-шу кузгаткан хат, хатыны Катя кулына килеп керә. Катя ире исеменә язылган хатны уку килешү-килешмәвен уйлап тормый, җитмәсә әле аннан «Белочка» хаты шикелле, хушбуй исе аңкый икән, почеркы да, хатын-кызныкы икәне күренеп тора.

Иван эштән кайтып кергәнче, Катя, мөгаен, хатны ун гына кат укымагандыр, ачуыннан, гарьләнүеннән шартларга җитешкән. Иванны ул, чәнечкеле себеркесен артына яшереп, янкапка янында каршы ала, берни дә сизмәгән Иван өй тирәсенә килеп җитүгә, бөтен күршеләре алдында иренә ташлана. Катя кулына тоткан хаттан әле бер сүзне, әле икенчесен яттан сиптерә генә, өстәвенә сәнгатькярләрчә тәэсирле итеп, көнләшүдән күңеленә килгән, әйтергә ярамаган оят сүзләрне урынлы кыстыра-кыстыра бичара Иванны чәнечкеле себеркесе белән дөмбәсли генә.

Әкрәм абзый аңлап калганча, ягымлы, купшы сүзләр һәм китаптан алынган тәкъбирләр Катяның ачуын китергән икән.

— Ишетәсеңме, ул сине шулхәтле сагынган, һәр бармагыңны үбәргә әзер! — дип, бөтен урамга акырган.

Иванны әйбәт белгәнгә елмаймый булмый: авыр һәм кара эштән бирчәйгән бармакларын йодрыклавы да авыр аңа. Катя хаттагы зиннәтле тормыш һәм дәртле мәхәббәт хакындагы китап сүзләрен бөтен урамга яудыра. Алар арасында «Белочка»ныкына охшаганнары бар иде шикелле.

Хлебодаровка бичара Иваннан рәхәтләнеп көлде генә. Ирне көлдергән дә хатын, бөлдергән дә хатын, дип юкка гына әйтмиләрдер. Карандаш белән язылган хәреф хаталары тулып яткан хатны Катя үзе белән йөрткән, кибеткә, базарга барганда тыңларга теләүчеләргә аеруча дәрт кузгата торган урыннарын шәрехли-шәрехли рәхәтләнеп укыган. Катяга иренең гаебен ачу ошаган, күрәсең, әмма көннәрдән бер көнне иртән Иван хатынының концерт эшчәнлегенә чик куймаса, ул һаман да шулай йөрүен дәвам иткән булыр иде әле.

«Әгәр «Белочка»ның хаты да шулай Хлебодаровка буйлап китә калса? Гомер буена оятыңнан керер тишек тапмассың»,— дип, сискәнеп, Әкрәм абзый — шулай да хатны ертып ташларга кулы бармады — бары тик ышанычлырак урынга яшереп куйды.

Шимбә көнне Әкрәм Галиевич иртәрәк торды һәм Наталья Сергеевнаны каршы алу программасының соңгы пунктын үтәргә — бик гайрәтләнеп җыештыру эшенә керешге. Эшне ишегалдыннан башлады: чәчәкләргә, агачларга, куакларга шлангтан су сиптерде, коелган, кипкән яфракларны себерде. Бакча түрендәге бәдрәфнең янган лампочкасын алыштырды, махсус сатып алган бәдрәф кәгазен төргәге белән элде. Тактадан әмәлләнгән җәйге душтагы бакка су тутырды.

Ишегалдында эш күп түгел иде, каян килеп күп булсын ди: Верочканың вафатыннан соң, бозаулаганын да көтеп тормыйча, сыерын сатып җибәрде, калган печәнне малтуар белән тулган ябага абзарга — Җолдаска ташыды: Әкрәм абзый тора-бара казларын да, тавыкларын да бетерде, ике дуңгызын тереләтә райпотребсоюзның хәзерләүләр конторасына тапшырды — барысына да күз-колак булу кирәк, бу эшләрне Вера Федоровна башкара иде. Чәчәкләр генә калганга ишегалды бик тиз җыештырылды.

Нотариус ишегалдында эшен бетергәндә, урамнан хат ташучы үтеп китте, һәрбер авыл зыялысы кебек, көнне газет укудан башлап җибәрүче Әкрәм абзый почта ящигына ашыкты.

Шимбә көнгә газетлар да укылмый калган, чөнки янә ике хат килгән иде.

Берсе, пөхтә итеп махсус ясалган конвертлысы, казна хатына охшаганрагының эчендә катыргы сыманрак нәрсәдер бар иде, Әкрәм абзый башта шунысын ачты.

Катыргы сыманрак дигәнебез фотосурәт икән. Остаханәдә төшерелгән сурәттән Әкрәм Галиевичка сөйкемле, бераз гына сагышлы, затлы киемле көяз бер ханым карап тора иде. Егерме еллар элек бу фотосурәтне Хлебодаровкада берәрсенә күрсәтсәң, һичшиксез, артисткамы әллә? — дип сорамый калмаслар иде.— Әйе, әйе, артистка, бүтәнчә түгел — Әкрәм Галиевич башкача күз алдына китерә алмады: объектив алдында үзен шундый иркен, иркәле тота, чәчләре матур, килешле итеп таралган, киеме дә затлы. Күз карашында акыллы, тәрбияле булуы, үз кадерен, үз бәясен белүе сизелә. Әкрәм Галиевич, чибәрлеге, мөлаемлыгы йөзенә чыккан фотосурәттәге ханымнан бик озак күзен ала алмады. «Чынлап та минем игъланым шундый чибәр ханымны да кызыксындырды микәнни?» — дип сөенде дә, көенде дә ул.

«Әлбәттә, быел гына төшкән фотосурәт түгел»,— дигән уй үтте аның башыннан.

Әкрәм абзый модалар остасы яки хатын-кызларның чәчләрен ничек йөртүләренә сирәк кенә игътибар иткән

булса, фотопортретның кайсы елда төшерелүен чамалый алган булыр иде. Бәла дә шунда шул, йорттагы хуҗабикә эшләрен генә түгел, модаларны да Вера Федоровна күзәтеп бара иде.

Кала хатыннары чәчләрен, бәлки, шулай матур итеп йөртәләрдер дә, Хлебодаровка хатыннары кышын үзләре бәйләгән ырынбур шәле бөркәнеп, җәен япон яки төрек яулыгы бәйләп йөриләр. Вера шәльяулыкларны кыйбат тора дия иде, шул шәльяулык астындагы чәчнең нинди булуын бер Ходай гына белсә белгәндер.

Шунысы бәхәссез — фотосурәттәге ханымның яулык бәйләп йөрмәгәне күренеп тора.

Сурәттән күзен ала алмаган Әкрәм Галиевич Хлебодаровка хатыннарының зәвыкларына шик белдерде. Ул фотосурәтне әйләндереп бүләк итеп бирелү вакытын күрергә өметләнде — яшьлек елларында андый чакларда төрле матур сүзләр, хәтта шигырьләр язып бирәләр иде,— аның бигрәк тә бу чибәр ханымның рәсемгә кайчан төшүен беләсе килде. Әмма фотосурәт артына бүләк итеп бирелгәнлеге дә, кайчан төшкәнлеге дә язылмаган.

Шулай да күңелен ымсындырган бу «артистканың» кайчан, кайсы елда төшүен бик беләсе килә иде. Калада яшәсә криминалист белгечләргә тиз генә барып килер иде, маҗаралы детектив әсәрдә яки фильмда алар, тәмәке төпчегенә карап, кем тартуын, ни өчен тартуын, кайсы якка караган булуын, иң мөһиме — кайда яшәвен әйтеп бирәләр. Алар Әкрәм абзыйга чибәр ханымның рәсемгә төшү елын гына түгел, сәгатенә хәтле әйтеп бирерләр иде.

Нотариусны сәгате үк борчымый, ә менә елы...

«Кемгә күрсәтеп карарга икән?» — дип, баш ватты Әкрәм абзый. Ул Хлебодаровкадагы барлык хокук саклау органнарын һәм аларда кемнәр эшләвенә хәтле белә, ләкин берсе дә сихри көчкә ия түгел. Ул гомерендә беренче мәртәбә шәһәр кешеләреннән көнләшеп тә алды: аларга һәммәсе дә хезмәт күрсәтергә әзер, криминалистлар да якында гына, ә монда иза чигәсең, берни белми интегәсең.

Фотосурәткә карап сокланган Әкрәм абзый конверт эчендә юка кәгазьгә язылган хат булуын да онытa язды.

«*Хөрмәтле Әкрәм Галиевич,*— дип, ачык һәм матур итеп басылган иде язу машинкасында.— *Миңа каралырга кергән бер сырхау хатын сезнең игъланыгыз басылган газетны онытып чыгып киткән. Картайган көнендә шәхси тормышында уңышсызлыкка тарыган кеше еш кына хорафатларга ышана башлый. Мин дә моны*

*тәкъдирдә шулай язылгандыр дип кабул иттем, һәм күңелемдәге уйларымны сезгә генә бушатасым килеп, шушы хатымны язарга утырдым. Элегрәк берәрсе мине игълан буенча таныштырам дисә, моны мин үземне мыскыллау дип караган булыр идем. Аңламыйм — нәрсә үзгәрә, еллармы, әллә кешеләрме? Мөгаен, еллар да, кешеләр дә үзгәрәдер. Күп кенә әдәпсез тәкъдимнәр арасыннан, минемчә, сезнеке йөрәкне тетрәтеп ала торган эчкерсезлеге, рыясызлыгы, киң күңеллелеге белән аерылып тора. Бу сүзләрне иске тәрбия алган кеше язганлыгы күренә, һәркем бу төшенчәне үзенчә юрый. Мин ничегрәк юрадым икән соң? Сез — җитди, төпле кеше, сезгә таянырга, төгәлрәк итеп әйткәндә, сезгә үземнең язмышымны ышанып танышырга була. Минемчә, иң мөһиме дә шулдыр.*

*Хлебодаровка да мине үзенә җәлеп итә. Гаҗәпләнәсезме? Гаҗәпләнмәгез: тумышым белән мин Ырынбур якларыннан, якташыгыз. Кеше олыгая барган саен хисләргә, тойгыларга бирелүчән, аны тыелгысыз рәвештә туган яклары тарта, анда ул үзен һәрчак бәхетле булгандыр сыман итеп тоя. Бөтен бәла һәм бәхетсезлекләр туган ягыннан, атаң йортыннан чыгып киткән көннән башлануына еллар үткән саен ныграк ышана барасың икән. Һәр елны мин җәйге ялда туган ягыма кайтып киләм, сезнең яшеллеккә күмелеп утырган Хлебодаровка аша да узам, хәтта бер елны ниндидер эш белән машинада туганнарыма да барып кайткан идем. Күптән инде өйгә, Ырынбурга кайтырга ниятләнеп йөри идем. Хәзер яшәп яткан Ташкентка кендегем берегерлек, төпләнеп калырлык җитди бернинди сәбәп юк. Очраклы гына кулга килеп кергән газета, сезнең тәкъдимегез... Шәхсән миңа атап язылмаган булуы гына җәл.*

*Тәкъдирдә шулай язылгандыр дип, язмышымны хәл итәргә ниятләнүдән тыелып кала алмадым — белмәссең тагын? Мин Хлебодаровканың яртылаш татар авылы икәнен беләм. Җырларыбызны, уеннарыбызны кабат ишетәсем-күрәсем, туйларда шаян «әпипә»гә биюләрен үз күзләрем белән күрәсем, янәшәдә генә туганнарым яшәвен тоясым килә,— сезнең тәкъдимегез мин фәкыйрегездә өмет чаткылары уятты. Белмим, бүтәннәргә ничектер, мин ризалашырга булдым, каршы килә алмадым. Сезнең, игъланыгызга хәтле үк ял мәсьәләсе хәл ителгән иде инде, шуңа күрә мин алдагы шимбәдә тиз йөрешле бишенче поездда, унынчы вагонда Хлебодаровка аша узып китәчәкмен. Кирәк дип тапсагыз — каршы алырга төшәрсез, Хлебодаровкада чыгармын һәм сездә биш-алты көнләп торырмындыр. Килмәсәгез, төшеп тә тормам, бер*

*сәгать дигәндә Ырынбурда булам, анда бер ай чамасы торырга исәп. Кирәк була калса дип, телефонымны һәм өй адресымны да язам, Ырынбурда мине шуның буенча таба аласыз...*

*Ихтирам белән, Нәзифә Әгъләмова''.*

«Димәк, табибә»,— дип елмаеп куйды Әкрәм Галиевич һәм янә фотосурәткә күз төшереп алды. Ханым аның күңеленә хуш килде.

Икенче хатны ул исе китми генә, каударланмый гына ачты, анысы «Белочка»дан иде. Янә шул кәгазь, шул ук хушбуй исе, тагын да күркәмрәк һәм дәртлерәк сүзләр.

«Белочка» үзенең бөтен буш вакытын бары тик Әкрәм Галиевичны уйлап кына уздыруын хәбәр иткәч, хат аша булса да кадерле кешесе белән аралашырга, йөрәгендә ургылып кайнаган мәхәббәт хисләрен җиткерергә теләвен, беренче хатында дулкынланудан өй телефонын язарга онытуын, ә хәзер шул дикъкатьсезлеген төзәтүен язган. Әкрәм Галиевич шалтыратса һәм ул аның сөйкемле тавышын ишетсә, бик тә рәхәтләнеп китәр идем дигән. Видеотелефон юк дип зарланып алган, андый телефон игълан буенча танышучы күп кенә кешеләрнең хәлен җиңеләйтер иде, дип сүз куерткан.

Аннары «Белочка» җәмәгать эшләре белән мәшгуль кеше икәнен, танышу игъланнары басарлык газет чыкмаган, «Утыздан узганнар» өчен клублар оештырылмаган калаларда видеоэлемтәне тизрәк һәм киңрәк җәелдерү өчен Элемтә министрлыгына хат әзерләп куюын да язган. Тик бер кыенлыкка тап булган: «Белочка» үзе яшәгән калада йөз имза җыя алмаган — инде менә бер ай узгандыр, сиксән җиденчесендә тукталып калдым дигән. Элемтә министрына язган хатында ни өчен нәкъ йөз имза җыярга ниятләвен «Белочка» аңлатып тормаган.

«Видеотелефон бик яхшы нәрсә. Бу инде сиңа фотосурәт кенә түгел: ретушь ясыйсы, ракурс белән төшерәсе, яхшы итеп яктыртасы, чит илнең фотокәгазен эзләп торасы юк... Ә монда — ничек бар, шулай күренәсең»,— дип хыялланып алды Әкрәм абзый. Ләкин шундук үзен почтамтта икәне, андый телефонга аерым бина кирәклеген, югыйсә сөйләшүләрнең почта хезмәткәрләре, гомумән, кызыксынучылар алдында баруын, Сташованың икенче көнне үк дәүләт кешесе — нотариусның нинди «чәчби» яки «фифечкә» белән гәпләшүен Хлебодаровка буйлап таратып йөрүен күз алдына китерде дә, «Белочка» яклаган яңалыкны хупламады.

Уйламаганда гына стенадагы сәгатькә күз салды — төшке аш вакыты да җитеп килә, иртәнге ашның да рәте-

чираты булмады, эшлисе эшләре муеннан, иртәгә көткән кунагы Наталья Сергеевна килеп төшәчәк. «Кара син аны, хыялланып утыруын гына күр»,— дип, үзен битәрләп алды да урыныннан купты.

Фотосурәтне ераккарак алып куясы килмәде, трюмо алдына куймакчы иде дә, Наталья Сергеевна кемең бу дип сораса, кем дияргә дә белмәссең дип, кире уйлады. Ялганлый да белергә кирәк, дөресен әйтсәң хәтерен калдыруың бар. Аннан соң бу «табибә-актриса» дигәне аның өчен беркем дә түгел бит әле!

«Шулай да кайчан төшкәнен беләсе иде, егерме ел элек мин дә егетләрдән ким түгел идем,— дип гайрәтләнде Әкрәм абзый.— Кабаланасы, ашыгасы, еллык хисап бирәсе юк. Бары тик күзгә-күз очрашып кына танышырга! Бернинди дә «җанкаемнарга», видеотелефоннарга алдандым юк, бары тик күзгә-күз очрашып кына танышырга!»

Шундый кискен уй-фикерләрдән соң, Әкрәм абзыйның күңеле күтәрелеп китте, янә эшкә керешле. Кичкә бөтен эшләрне бетергәч, поселок мунчасына барып, юынып-чабынып та кайтты. Эшләгән эшләреннән, ә иң мөһиме — төпле фикердә торуыннан канәгать калып, кичке аш алдыннан бер рюмка аракы эчте дә гадәттәгедән иртәрәк йокларга ятты — алда тагын зур эшләр тора.

Иртән Әкрәм абзый бик пөхтә итеп кырынды, битенә Совет армиясе көнендә хатын-кызлар бүләк иткән кыйммәтле чит ил лосьонын сиптерде, бәйрәмнәрдә генә кия торган кәстүмен, галстугын әзерләп куйды, үз кул көче белән булдырган хуҗалыгына күз салып алды. Шампан шәрабын суыткычка урнаштырды, сүрән утка шулпа утыртты, шашлык өчен туралган суганын, яшь сарык ите телемнәрен шәраб серкәсенә манчыды, шашлык кыздыру өчен мангалны һәм шампурларны барлап куйды,— шулай да вакыт бик акрын узды.

Әкрәм абзый каладан килүче автобусларның расписаниесен алдан ук белешкән иде, Болдыреваның Хлебодаровкага кайчанрак килеп җитәсен дә чамалады. Әмма Наталья Сергеевна ул көткәннән иртәрәк килеп җитте.

Әкрәм Галиевич орденнары тагылган бәйрәм кәстүмен киеп, кунакны автостанциядә каршы алу нияте белән янкапкадан чыгып барганда, тузанлы такси капка төбенә үк диярлек килеп туктады. Матур гына киенгән бер ханым машинадан чыкты да аңа таба атлады.

— Исәнмесез, Әкрәм Галиевич,— диде дә, елмаеп, кулын сузды.

— Наталья Сергеевна,— дип каушап, аптырап калды Әкрәм Галиевич,— исән-имин генә килеп җиттегезме? Минем сезне автостанциядә каршы алырга дип чыгып барышым...

Сабырсызланып көтеп торган машина сигнал бирмәсә, ул әле, мөгаен, шулай бик озак аптырап басып торган булыр иде.

— Гафу итегез, таксины гына җибәрим инде,— дип, кунак машина янына килде.

Алгы утыргычтан күн сумкасын алды, таксистка дүрт унар сумлык акча сузды. Шофер багажнигын ачты да күз карашы белән генә Әкрәм Галиевичка юлчының әйберләрен алырга ым какты.

Машина җиңел генә борылып китеп баргач, Әкрәм абзый, түземлеген җуеп, сорап куйды:

— Кырык тәңкә! Автобус билеты ике тәңкәдән дә кимрәк. Сез Хлебодаровка тарихында таксида килүче беренче кешедер, мөгаен.

— Мин сезнең янга ашыктым,— дип җавап бирде Наталья Сергеевна һәм бермәл дәшми торганнан соң, өстәп куйды.— Тарихка керү өчен генә булса да, кырык тәңкә әллә ни зур акча түгелдер дип беләм.

Аның елмаеп җавап бирүе Әкрәм Галиевичны шундук үзенә җәлеп итте.

Бер сәгатьтән инде алар, күптәнге танышлар кебек, күңелле генә сөйләшә-сөйләшә, ит кисәкләрен шампурларга киертеп чыктылар. Әкрәм Галиевич мангалны көйләп шашлык кыздырган арада, Наталья Сергеевна верандада табын әзерләде.

Әкрәм Галиевич кызарып пешкән шашлыкларны верандага алып кергәч, табынга күз төшерүгә, гаҗәпләнүдән тәлинкәсен чак кына идәнгә төшереп җибәрмәде.

Крахмалланган ак эскәтер ябылган табын уртасында өй түрендәге бакчадан өзеп кенә алып кергән искиткеч гаҗәеп чәчәк букеты куелган чүлмәк ваза утыра. Букет янында табындагы мул ризык һәм кабымлыклар тоныкланып калган иде. Закусканың, кабымлыкларның ниндие генә юк... Наталья Сергеевна элегрәк сервантта бөтенләй диярлек кузгалмыйча яткан бөтен савыт-сабаны эшкә җиккән. Кызыл һәм кара икра, алтындай лимон телемнәре белән бизәлгән тәмле семга балыгы, осетр ите һәм кызыл балык дисеңме, яшелчә бакчасыннан өзеп кенә алынган салат һәм сельдерей яфраклары белән аралаштырылган аксыл-кызыл муксун, диңгез кысласыннан һәм тәрәч балыгы бавырыннан әзерләнгән салатлар дисеңме, диңгездә һәм җирдә үскән нигъмәтләр дисеңме, ни генә

юк иде табында. Чи иттән ыслап һәм каклап әзерләнгән колбаса исе шашлык исен дә басып китә шикелле, әмма табын диңгез нигъмәтләренең муллыгы белән аерылып тора иде.

— Сез сихерчедер, мөгаен? — дип кенә әйтә алды нотариус.

— Юк, гади генә балыкчы мин. Газетчылар теле белән әйтсәк, болар минем хезмәтемнең соңгы нәтиҗәләре. Ярты елым диңгез-океанда траулерда, ярты елым яр буенда балык заводында уза. Рәхим итеп татып карагыз,— диде Наталья Сергеевна һәм шашлык салынган тәлинкәне, Әкрәм абзый кулыннан алып, табынга куйды.

Әкрәм Галиевич суыткычтагы шампан шешәсен табынга китереп куйды. Наталья Сергеевна, иелеп, юл сумкасыннан тар озын муенлы ике шешә чыгарды.

Мондый сый-нигъмәт хөрмәтенә, бәлки, болары да ярый торгандыр? — диде ул, коньякларны өстәлгә куеп.

Нотариус «Двин», «Дойна» дип укыды. Язулары урысча кебек, әмма андый исемнәрне беренче күрүе.

«Моның бер шешәсе күпме тора икән?» — диде Әкрәм абзый үз-үзенә, чөнки теләсә нинди коньяк бәясе аның чиктән тыш ачуын китерә иде. Әмма бу юлы «Нинди уңган ханым!» дип сокланмый кала алмады.

Танышу, очрашу-күрешү хөрмәтенә, Наталья Сергеевнаның эштәге дуслары-иптәшләре, ягъни диңгезчеләр хөрмәтенә дә тотып куйдылар. Кунак шашлыкны, бакчадан гына алып кергән яшел үләннәрдән, яшелчәдән әзерләнгән салатларны мактый-мактый яратып ашады: хуҗага диңгез нигъмәтләре ошыйрак төште, чөнки Хлебодаровкада хек балыгының да сирәк күренүенә зарланган, сыңар күзле балык дип камбаладан борын чөергән заманнар бар иде, шуңа камбаланың хәтере калгандыр да юкка чыккандыр, мөгаен.

Әкрәм абзый, кыюланып китеп, букетың нишләп шулай сәер күренә, дип сорарга җөрьәт итте.

— Икебана диләр аны,— диде Наталья Сергеевна. — Японнардан кушылмый торганны бергә кушарга өйрәндек. Хәзер Сахалинда икебананың чәчәк аткан чагы, бездән японнар да көнләшә башлар әле. Менә күрерсез, ишегалдында ташлардан бакча ясарбыз, өйдә сирәк очрый торган кәрлә агачлар утыртырбыз. Ни диярсез, Әкрәм Галиевич?

— Үз өегездәге кебек эш итегез,— дип, кыю гына җавап бирде исерә башлаган нотариус һәм музыка көйләп җибәрде.

Аннары алар икесенең дә яшьлек елларын хәтерләткән, ул чакта популяр булган тангога бөтерелделәр, әйтерсең лә сөйләшенгәндәй, бер мәлгә моңаеп та калдылар. Әкрәм Галиевич бүген аерата актив һәм гайрәтле иде. Чираттагы шаян тостын әйткәннән соң, табын яңадан җанланып китте.

Наталья Сергеевна балыкчылар тормышыннан, көлдерә-көлдерә, төрле мәзәкләр сөйләде, Әкрәм Галиевич тә озак еллар эшләү дәверендә үз башыннан үткән кызыклы хәлләрне бәян итте, икесе дә рәхәтләнеп көлештеләр. Бик тә рәхәт иде аларга.

Иртә йокларга яткан Хлебодаровка халкы беренче төшләрен күргәндә, алар калган шашлыкны ай яктысында кыздырып бетерделәр, мангалдагы утлы күмер белән самовар кайнаттылар. Наталья Сергеевна, үз гомеремдә беренче мәртәбә самовар чәе эчәм, дип ышандырырга тырышты.

Чәй эчеп утырганда, Әкрәм Галиевич уйламаганда стенадагы сәгатькә карап алды — төн уртасы үтеп киткән.

Соңгы егерме елда аларның Верочка белән үзләрендә дә, кунакта да төн уртасына хәтле утырганнары булмады. «Иртәгә эшкә барасы бит дип» борчылганда, ике генә көн элек Тын океан ярында басып торган, ә бүген Хлебодаровкада, аның янында гомерендә беренче мәртәбә чын самовардан чәй эчеп утырган балыкчы хатынның аңардан сөйкемле генә итеп нәрсәдер соравы дүшәмбе эш көне бит дигән, миен телгәләгән уйларын да оныттырды.

«Вакыт аермасы, ара ераклыгы нәрсә ул!» — дип уйлады Әкрәм Галиевич һәм вакыт аермасы белән ара ераклыгы төшенчәсенең кулына танышу игъланы басылган газета килеп кергән мизгелдә бергә кушылуын аңлады. Моңарчы бөтен галәм, бөтен җиһан, юллар, ара ераклыгы аның өчен Хлебодаровка белән генә чикләнә сыман иде, кулыңны сузарга теләсәң, басу капкасыннан чыгып карасаң, җепнең очын әнә кая кадәр сузарга мөмкин икән ләбаса.

Нотариус шулай дип уйлады, үзенең башкача, киңрәк, колачлырак уйлый башлавына куанды, элегрәк андый уй башына да килмәс иде, шул чагында кәефе күтәренке Наталья Сергеевна, уенын-чынын бергә кушып:

— Йә, Әкрәм Галиевич, хатынлыкка аласызмы мине? — дип әйтеп салды. Әкрәм абзыйның артына килеп басты да, иңбашыннан кочаклап алды,— таяныр кешесе булмаган, мәрхәмәтле һәм тәвәккәл хатынның назлап иркәләвеннән аның күңеле йомшарды, күзләре чыланды, хатынның кулларын үбә-үбә, әкрен генә тын алды:

— Алам, Наталья Сергеевна...

Әкрәм абзый, гадәтләнгәнчә, йокыдан иртә уянды, Наталья Сергеевнага иртәгә җыештырырбыз, дигәнен хәтерли, әмма веранда өстәлендәге бөтен нәрсә җыеп алынган һәм урнаштырылган иде инде. Димәк, аны йокларга яткырган да, өстәлне берүзе ялт иттереп тә куйган.

«Хуҗабикә булырга ярата, уңган хатын»,— диде Сабиров, кәефе күтәрелеп китте, шулай да башы чатный. Ул, йомшак кына басып, Наталья Сергеевна йоклап яткан залга узды, ачылган юрганын рәтләп япты, уятып тормады — ял итсен, ерак юл арыткандыр, Сахалин вакыты белән төн җитеп кенә киләдер әле, мөгаен.

Чәй куеп җибәрде, иртәнге ашны өлгертте, күңеле шат, җырлыйсы гына килеп тора, гомердә дә иртәнге якта андый халәттә булганын хәтерләми ул. Күңеленнән көйләсә дә, җырлап җибәрүдән тыелып калды. Эшкә барасы булса да, бер рюмка коньяк эчте, кичә беренче мәртәбә татып караган тәмле семга кисәген алып капты.

Эшкә китешли, кирәк нәрсәләрне ничек табасын, төшке ашка кайчан кайтасын, әлбәттә, иркәләү сүзләрен дә өстәп, записка калдырды.

Бүген эш сәгате бик әкрен үтте, кичәге кебек түгел шул, йомыш белән килүчеләр шактый күп булып чыкты, Наталья Сергеевна нәрсә эшли икән анда, йокыдан торды микән әле, кәефе шәп микән, мине көтә микән, дип уйларга да ара булмады.

Төшке ашка ул ашкынып кайтты, әле ярый юлда дусишләреннән берәү дә очрамады. «Нәрсә булды? Кая ашыгасың болай?» — дигән сорауларына җавап бирергә туры килмәде. Ул үз халәтен яшерә дә алмады, аннары яшереп торуны кирәк дип тә санамады. Янкапка алдында гына тукталып тын алды — мышкылдаган, әйтерсең лә артыңнан куалар, почта ящигындагы газетларны ашыга-кабалана тартып чыгарды, хатлар җиргә коелды — берьюлы биш хат.

Әкрәм абзый сагаеп кына ишегалдына күз салды, бәхеткә каршы, Наталья Сергеевна өйгә кереп киткән иде. Ул хатларны җәһәт кенә җыеп алды, ашыгып кына пиджәгенең эчке кесәсенә салды, бәдрәфкә таба үтте, карап та тормастан, чокырга тондырды.

«Җитте, булды,— диде ул, җиңеләеп киткәндәй,— камин янындагы урын буш түгел инде». Газетка телеграмма сугарга кирәк булыр, диде дә, шаяртуыннан кангатьләнеп, елмаеп куйды. Аннары шаярту белән генә котылу килешеп бетмәс, аларга ничек тә рәхмәтле икәнлегемне дә җиткерергә кирәктер, шул газета булмаса, ул

гомердә дә шундый акыллы ханым белән таныша аласы кеше түгел иде.

Верандада кичәге шикелле үк итеп табын әзерләнгән, бары тик букет кына бүтән, тагын да матуррагы куелган. Наталья Сергеевна тәненә сыланып торган килешле халат, аягына өйдә кия торган йомшак туфли-танкетка кигән, үзен хуҗабикәләрчә сөйкемле, ышанычлы тота, Сабировка бер мизгелгә генә булса да бу хатын монда күптән яшидер сыман тоелды, үзен озак вакыт каядыр китеп торган да хәзер генә өенә кайтып төшкәндәй хис итте.

— Табынга утыр, һәммә нәрсәм дә әзер,— диде Наталья Сергеевна.

Алдына аш салынган тәлинкә килгәч, Әкрәм абзый:

— Һо, токмачлы аш! Шундый вак, нечкә итеп, бездә, татарларда, туйларда гына кисәләр, анда да әле аш-суга оста хатыннарны чакыралар,— дип соклануын белдерде.

Наталья Сергеевна, канәгатьләнеп, елмая-елмая:

— Бездә, балык заводында татарлар күп эшли, мин шулардан милли ашларыгыз хакында сораштырдым. Бәлеш тә сала беләм,— диде ул, горур гына.

— Осталыгыгыз һәм шундый табын әзерләвегез өчен берәр рюмка тотмасаң, гөнаһ булырдыр, Наталья Сергеевна, бәлки, салырсыз?

— Эшкә бармаска булдың мәллә?

— Гомер буе эшләп бер генә шелтә булса да алырга ярый торгандыр,— диде Әкрәм Галиевич һәм икесе дә күңелле генә көлешеп алдылар.

Сабиров эштән кайтышлый, газетка телеграмма җибәрергә ниятләп, почтага сугылып чыкты. Почтада да, аның конторасындагы шикелле, төшке аштан соң йомыш белән килүчеләр күренми. Аның каравы телеграмма кабул итә торган тәрәзә янында почта мөдире Мәрьям үзе утыра иде. Исәнләштеләр, Мәрьям, уңайсызлануыннан кызарып, шаярткандай:

— Әкрәм, нәрсә булды сиңа? Хлебодаровка почтасы соңгы вакытларда гел синең өчен генә эшли. Әле генә, бер минут та узмагандыр, телеграмма китерделәр. Син аны, мөгаен, зарыгып көткәнсеңдер!

Әкрәм абзый авыз эченнән генә нидер мыгырдады да, эшкә ашыгуын сылтау итеп, хәтта Мәрьямгә телеграмма өчен рәхмәт әйтергә дә онытып, дулкынланудан тирләгән маңгаен сөртә-сөртә, почта бинасыннан атыла-бәрелә чыгып йөгерде.

«Белочка»дан гына була күрмәсен... Бөтен Хлебодаровкага хур итәчәк! Наталья Сергеевнага ишеттерсәләр...» —

диде дә, чаттан борылгач кына, телеграмманы курка-курка гына кулына алды.

«Бик ашыгыч итеп Ленинградка шалтыратсагызчы, телефоным 2476465»,— дип укыды Әкрәм абзый һәм тынычлангандай булды, кинәт кенә ачуы кузгалды.

— Шалтыратам, көт менә. Кызыл кар яугач та шалтыратам! — дип пыр тузды ул, телеграмманы ертып ташлады да эшкә китте.

Кичкә таба ул тәмам тынычланды, өйгә кайтышлый, алма алырга дип, базарга керде. Тюкульбас алмасы хуҗасына рәхмәт әйтергә ымсынып күңеле кытыкланса да, аның хуш ис килеп торган өстәле тирәсендә бик күп халык җыелып торуын күрде.

«Ярар, башка вакытта әйтермен әле»,— дип, Гаджибәковның «Аршин мал алан»ыннан «Рәхмәт инде Сөләйманга...» дигән арияне җырлый-җырлый, базардан чыгып китте. Күтәренке, шат күңел белән янкапка алдына килеп басты.

Наталья Сергеевна аны өй түрендәге бакчада көтеп тора иде.

— Әкрәм Галиевич, мин ишегалды түрендә мунчагыз барын белдем, куанып та куйдым,— диде ул.— Үзе чиста, җыйнак, бөтен нәрсә дә әзер, әйтерсең лә син бүген мунча ягарга җыенгансың. Мин инде ягып та җибәрдем. Әйдә мунча керик, ул арада духовкага куелган кичке ашым да өлгерер. Ризамы?

Җавап урынына Әкрәм абзый баягы арияне бар куәтенә җырлап җибәрде.

Мунчадан соң Наталья Сергеевна, яңа сюрприз вәгъдә итеп, кичке аш әзерләгән арада, ул шул ук Сөләйман турында җырлый-җырлый ишегалдында самовар көйләп җибәрде. Киртә-койманың теге ягыннан Җолдас ага дәште.

Күршесе бик төксе күренә, Әкрәм абзый, күңел күтәренкелеген күрсәтмәскә тырышып, аңа таба атлады.

— Нәрсәгәдер көзге болыт кебек кабарынгансың? — диде Сабиров.

— Анысы синең эш түгел,— дип кырт кисте Җолдас ага.— Мин сине шуңа дәштем: бездә, мөселманнарда, туганый апаң белән мунча керү гадәте юк. Ә синең хәлдә, яшең турында әйтеп тә тормыйм, елы үткәнче үзеңне әдәплерәк тотарга кирәк — француз түгелсең һәм Парижда да яшәмисең, монда сине берәү дә аңламас...

Кинәт, аяк астына төкерде дә:

— Канәгать чыраеңны күрәсем дә килми,— диде дә китеп тә барды.

Әкрәм абзый оятыннан ни эшләргә белмәде, бер мәлгә югалып-каушап калды, күршесеннән моны көтмәгән иде. Ярый әле самовар кайнатасы булды. Дустының сүзләреннән соң, күңеле тынычланганчы, самовар тирәсендә мәш килде.

Наталья Сергеевна веранданың ачык тәрәзәсеннән самовар кертергә ишарә ясады, Әкрәм абзый күтәренке күңел белән өйгә керде. Мунчадан соң кызарган, өстенә чәчәкле яңа халатын кигән Наталья Сергеевнага карап алды, кунак аны елмаеп табынга чакыруга, Җолдас аганың ачулануын да онытты.

Табын уртасында ашъяулык белән капланган таба куелган, ишегалдында чакта ук Әкрәм абзыйның борынына бәлеш исе кергән иде. Таба янында күзгә бәрелеп торган ниндидер тартма да бар:

— Монысы нәрсә тагын? — дип сорады ул.— Сюрпризмы?

— Юк, сюрприз түгел, анысы ашъяулык белән капланган, хәзер күрерсең, бусы сиңа бүләк, гафу ит инде, кичәге ыгы-зыгыда һәм дулкынланудан бирергә дә онытканмын. Ачып кара, нәрсә бүләк итим дип бик озак уйлап йөргән идем.

Әкрәм Галиевич, кечкенә тартманы ачып, кәгазь кап эченнән матур итеп урелгән ефәк тоткалы, ирләр кия торган беләзекне хәтерләткән, ләкин аннан авыр да һәм нәфисрәк тә замша футляр тартып чыгарды.

Наталья Сергеевна аның аптырап калуын күргәч:

— Чишеп җибәр,— диде.

Әкрәм Галиевич футлярның элмәген чишүгә, уч төбе хәтле генә радиоалгыч килеп чыкты. Наталья Сергеевна аның бер ягыннан антенна тартып чыгарды, нәрсәсендер борды, концерт яңгырады. Верандага күңелле музыка тавышы таралды.

— Үзе бәләкәй генә, җитмәсә антеннасы да бар,— дип сокланды Әкрәм абзый.— Гаҗәп затлы итеп эшләнгән!

— Анысы әллә ни әһәмиятле түгел, иң мөһиме — җиде диапозоны булуда: биш кыска, бер озын һәм бер урта дулкынны тота. Синең комод өстендәге радиоалгычныкыннан күбрәк. Электр белән дә, батарея белән дә эшли, үзең генә тыңларга телисең икән, наушнигын колагыңа эләсең.

Әкрәм абзый тартмадан һәм замша футлярдан «Соня» дип укыды.

— «Сони»,— дип иплән кенә төзәтте аны Наталья Сергеевна.— Мин аны махсус «Альбатрос» кибетеннән сатып алдым. Океанда эшләгәндә безгә эш хакының бер өлешен бон һәм валюта белән бирәләр. Ошадымы?

— Шундый могҗиза кемгә генә ошамас икән,— дип уңайсызланып китте Әкрәм абзый, Наталья Сергеевнаны кочагына алды да суырып үпте...

Әкрәм абзый төн буе йоклап китә алмый ятты. Аптырагач, Наталья Сергеевнаның баш астыннан кулын җайлап кына алды, уятмаска тырышып, ишегалдына чыкты.

Тышта Хлебодаровканың үтә сизгер этләре дә йоклый алырлык сирәк була торган искиткеч төнге тынлык. Йокыга талган поселок өстендәге йолдызлы күк йөзеннән дә тынлык тарала сыман. Әкрәм абзыйның да күңеле күтәренке һәм тыныч иде. Җолдас ага белән сөйләшеп торуы исенә төште дә кәефе тагын бозылды. «Ничек тә килешү җаен табарга кирәк»,— диде Әкрәм абзый, әмма никадәр уйланса да, төпле бер фикергә килә алмады.

Дөрес, бер юлы бар барын, анысын да уйлаган иде Әкрәм абзый. Наталья Сергеевна, Карпат аръягында яшәүче энесе белән сеңлесен өч ел буе күрмәвен, шунда икәүләп барып килсәк, дип, сиздереп тә куйган иде. Шуларга үзең генә барып кунак булып, ял итеп кайт, дип тәкъдим итсәң, үзе әйткәнчә, өч ел буе ял күрми эшлисең бит дисәң, нәрсә әйтер икән? Ә ул шул арада, бик шәплəп, берәү дә сүз әйтмәслек итеп, искә алу мәҗлесен дә үткәреп алырга өлгерер иде. Менә шул чагында Җолдас белән килешер-татулашыр, Наталья Сергеевнаны да саклап калыр. Хәер, аны алырга дип Карпатка да очарга һәм аннан бергә кайтып төшәргә дә мөмкин.

«Хәтерен калдырмаслык итеп ничек әйтергә икән соң? — дип уйланды ул, төнге ишегалды буйлап йөренә-йөренә. Койманың теге ягындагы кура абзардан Җолдас аганың йокымсыраган сыерының мышнаганы ишетелә, шул чагында Әкрәм абзыйның елга аръягындагы сарыклары янына барып кайтырга кирәклеге исенә төште. «Килешү өчен бер сылтау да булыр,— диде ул.— Үзе үк, сарыкларыңны минем кура абзарга җибәр, махсус ысул белән симертәм мин аларны, дигән иде бит». Шул уйлардан күңеле күтәрелеп йокларга кереп китте.

Иртән эшкә йоклап кала язды, ярый әле Наталья Сергеевна уятты. Соңгы егерме елда аның бүгенгедәй хәлгә тарыганы булмады.

Өй җыештырылган, бөтен җир ялт итеп тора, табын әзерләнгән. Өстәлдә самовар кайнап-җырлап утыра, нотариус үзе иртән газ плитәсендә кайнаган чәй генә эчә иде. Наталья Сергеевна хәтта коймак пешерергә дә өлгергән. Коймак белән икра аның өчен ят бер ризык иде.

Әкрәм абзый өстәл янына утыра-утыра:

— Тәмле ризыкларың белән бозасың син мине,— диде, канәгать икәнлеген белдереп. Оста һәм уңган Наталья Сергеевна белән яшәве бик рәхәт иде аңа.

Аннары Наталья Сергеевна аңа чиста күлмәк бирде, галстугын бәйләргә булышты, баштанаяк күздән кичергәч, янкапкага хәтле озата чыкты, аннары, чаттан борылып күздән югалганчы, озак кына артыннан карап калды.

Әкрәм Галиевич эштә төшке аш вакытын көчкә җиткерде — аның мөлаем йөзле, ягымлы Наталья Сергеевнаны күрәсе, аннан соң бүген аны нинди тәмле ризык белән сыйларга әзерләнүен дә беләсе килде.

Наталья Сергеевнаның тәмле итеп пешергән ризыкларын, аны табынга китереп куюларын ошата иде ул. Балыкчы хатын ун ел буена сервантта тузан җыеп яткан, бәйрәмнәрдә генә кузгала торган сервизны эшкә җикте, табынга ямь кертте.

Ә өстәлдәге чәчәкләр? «Элегрәк нишләп үзебезнең башка килмәгәндер, ишегалды тулы чәчәк бит югыйсә? Вактөяк кебек, ә шулай да хәятыңны ничек ямьләндереп җибәрә»,— дип уйланды Әкрәм абзый. Аның кинәт кенә Наталья Сергеевнага яхшылык эшлисе, күңелен күрәсе, бүген үк, төшке ашка берәр бүләк алып кайтып бирәсе килде. Ул хәтта конторын да ярты сәгатькә иртәрәк япты, район универмагына сугылды, өч катны да әйләнеп чыкты, бүләккә ярарлык бер генә нәрсә дә таба алмады. Наталья Сергеевналарда булган яулыкны да, сумканы да, туфлине дә, хәтта косынкага кадәр «Альбатрос» кибетенә товарларны башка складлардан китерә торганнардыр, мөгаен. «Ярар, берәр вакыт калага барырмын әле, анда шәт берәр нәрсә очрамый калмас»,— диде дә өенә ашыкты.

Хәтта газетлары бүселеп торган почта ящигына да күз салмады, ашыгып өйгә керде. Өйдә сәер тынлык. Ул инде Наталья Сергеевнаның аның кайтуын музыка уйнатып, кухнядан тәмле аш-су исе чыгарып каршы алуына ияләнеп тә килә иде. Өй хәзер аңа бушап калган, нуры качкан сыман тоелды. Вера Федоровнаны җирләп кайтканнан соң да Әкрәм абзыйны шундый хис биләгән иде.

Әкрәм абзый, шомланып, алгы бүлмәгә узды. Бөтен нәрсә пөхтә итеп җыештырылган, бөтен җирдә хуҗабикә кулы сизелә. Калын бәрхет эскәтер җәелгән өстәл өстендә бер хат ята.

*«Сөеклем Әкрәм Галиевич,*— дип, каушый-каушый укый башлады Сабиров.— *Үземнең шушы гамәлем белән икебезгә дә күңелсезлек, кайгы-хәсрәт китерәмдер дип*

*беләм. Мин, әлбәттә, моның өчен үкенәчәкмен әле. Безне, хатын-кызларны аңлавы кыен, еш кына без аңлашылмаслык эшләр эшләп ташлыйбыз. Минем гамәлем дә шуңа охшаганрак. Акылым белән аңлыйм да: сине яратучы һәм яклаучы, картлыгымны бизәүче кеше икәнлегегезне дә беләм. Сездән уңдым дип тә әйтә алам, сезгә ошавымны да беләм, монысы минем өчен куаныч. Сез миннән берни дә сораштырмадыгыз, мин дә сөйләргә тырышып карамадым. Мөгаен, сез зирәк эш иткәнсез — шулай да? Сезне бигрәк тә киләчәк тормышыбыз — минем нинди булганым түгел, нинди булачагым борчыган.*

*Сезнең игъланыгызны күргәч тә, мин үз-үземә: җитәр Наталья, тынычлан, акылга утыр, менә сиңа да җир йөзендә тын почмак табылды, шаяруларыңнан, илебезнең бер читеннән икенче читенә алкы-салкы йөрүләрдән тукталырга вакыттыр. Безгә изге теләкләребезне күнегелгән гадәтләребез белән бәйләве бик җиңел түгел, күрәсең. Кинәт, ниндидер бер мизгелдә, мине тын һәм ышанычлы җылы учакның да җылыта алмасына, кысан буласына төшендем, минем яшьтәге теләсә нинди акыллы хатын-кыз шул хакта хыяллана түгелме соң?*

*Тыныч, салмак тормыш минем өчен түгел, күрәсең. Мин аңа әзер дә түгелмен, ничек кенә сәер тоелмасын, мул тормышта яшәүче, тел-теш тидермәслек абруйлы ирләр белән үземне ничек тотарга икәнлегемне дә белмим,— миңа үз гомеремдә бөтенләй башка холыклы ир-атлар белән очрашырга туры килде һәм мин үземнең аларга кирәгрәк булуымны аңладым. Мөгаен, мин сезгә дә кирәкмендер. Яз көннәренең берсендә, көньяктан торналар кайта башлагач, мин дә сәфәр чыгачагымны сизеп торам. Шундый чегән хатыны инде мин, Әкрәм Галиевич. Ләкин сез бик игелекле, ипле кеше, сез ташлап китүгә дучар ителерлек зат түгелсез. Хлебодаровкадагы имеш-мимешләрнең сезне харап итәчәген, җәфалаячагын да чамалыйм,— барлык кечкенә бистәләр дә бертөрле, андый авылларда яшәп караганым бар минем. Мин дә сезгә ияләшеп китүемнән куркам: аннары аерылышу хәсрәте бик ачы булачак, шуңа күрә хәзер үк китәргә ниятләдем.*

*Хушыгыз, яманлык белән искә алмагыз, бигайбә. Безнең арада булганнар, ышаныгыз, чын күңелдән иде.*

*Гафу итегез. Үбәм. Наталья Сергеевна».*

Әкрәм Галиевич берни дә аңламыйча хатны кабат укып чыкты.

Киттең дәмени? Нигә? Ни өчен? Аның китү сәбәпләре аңа бөтенләй аңлашылмады — учак ягып, палаткалар

корып, зәңгәр калаларны айкап йөрер чагы узган бит инде.

Кинәт аңа, Наталья Сергеевна бик тә кызганыч булып тоелды: тәвәккәллектән, чаялыктан, үзе дә белмәгән юмартлык һәм киң күңеллелектән тыш, ул аның сабыйларча диярлек яклаучысыз калуын һәм төпләнә алмыйча интегүен күрде.

«Эзләп табарга, артыннан куып җитәргә»,— дип, Әкрәм Галиевич автостанциягә ашыкты. Анда ул дежур ханымга Наталья Сергеевнаның кыяфәтен сурәтләгәч, күренмәдеме дип сораштырды. «Ике сәгать элек кенә китеп барды»,— дип җавап бирде дежур.

Әкрәм Галиевич гаҗиз булып эскәмиягә утырды.

Ул Наталья Сергеевнаны бөтенләйгә югалтуын аңлады. Акылы белән аңлый да, ләкин күңеленнән килешәсе килмәде, барысы да җайлы гына, кешеләрчә генә башланып киткән иде бит...

Автостанциягә каршы яктагы тар гына бер урамда урнашкан ресторан ишеге төбендә басып торган Анна Ивановна:

— Әкрәм Галиевич, өч көн төшке ашка йөрмисез, әллә инде бездә ошамый башладымы? — дип сорады.

Әкрәм абзый авыр гына урыныннан купты, төшке ашны ашамавын исенә төшереп, ресторанга кереп утырды.

— Кәефегез киткәндәй күренә,— диде Анна Ивановна, кайгысын уртаклашкандай.

Ресторанда ул шактый озак юанды, беренче мәртәбә төшке аштан соң эшкә бармый калды. Әле кичә генә шушы урамнан өйгә кайтканда: «Рәхмәт инде Сөләйманга...» — дип җырлаган бәхетле мизгелләрен исенә төшерде.

«Бүген Наталья Сергеевнаны да югалттым, Җолдас белән дә аралар бозылды, әчелешле булдым. Ни эшләргә инде хәзер?» — дип өзгәләнде Әкрәм абзый. Әмма күңелен юатырлык бер уйга да килә алмады.

Гадәт буенча хуҗалык эшләренә тотынды: мунчаның көлен түкте, чабынган себеркене чыгарып ташлады, ләгәннәрне чайкап куйды, казанда калган суны бушатты, әмма эшнең җаена төшә алмады. Мунчадагы эшләрне төгәлләмичә, бернинди максатсыз ишегалды тирәли йөренергә кереште. Элеккечә Җолдасның аны самовар чәе эчәргә чакыруын көтте, әмма Бөркетбаевлар ишегалдында беркем дә күренмәде.

Көн кичкә авышты. Бакчалар артындагы тыкрыктан, куе томан шикелле, тузан болыты күтәрелде,— соңгы

елларда шактый сирәгәйгән Хлебодаровка көтүе кайта иде. Кемнеңдер зур җирән сыеры Әкрәм абзый коймасындагы баганага бик каты ышкына башлады, киртәкойма шыгырдап китте. Әкрәм абзый кулына эләккән таяк белән койма янына ташланды. Сыерны куып җибәргәч, төшке ашка кайтышлый күрмәгән газетларга күзе төште.

Газетларны кулына алды да, тагын берәр нәрсә калмады микән дип караштыра торгач, аһ дип куйды — ящик төбендә унлап хат яткан булып чыкты.

Кичә иртән биш хатны чокырга ташлап кына тарих тәгәрмәчен әйләнүдән туктатып булмасын, бүген килгән хатлардан аның тагын да кызурак әйләнүен сизеп алган Әкрәм абзый:

— Менә сиңа кирәк булса! — дип куйды, ирексездән.

«Ә нигә әле ул тәгәрмәч әйләнмәскә тиеш? — дип, фикер йөртте Әкрәм абзый.— Газетка һаман да телеграмма суга алмадым бит әле». Хатларны актаргалап, нишлим икән инде болар белән дип, озак кына янкапка буенда уйланып басып торды, әмма ертып ташларга кыймады.

Хатларның берсеннән таныш хушбуй исе килә, әйләндереп караса — «Белочка»дан.

«Мин инде хатларны исләренә карап белә башладым»,— дип, бүгенге мәшәкатьләрен дә онытып, беренче мәртәбә елмаеп куйды.

Нишләптер «Белочка» хатын укыйсы килмәде, ул аны берничек тә тынычландыра алмастыр — күз алдында әле һаман да Наталья Сергеевна басып тора сыман.

Әкрәм Галиевич керәсе килми генә алгы якка узды. Кичә генә утлар балкып, музыка яңгырап торган өй аңа салкын һәм котсыз булып тоелды. Тынып калган өй эче караңгы сыман күренгәнгә, Әкрәм абзый ут кабызды. Ут яктысы нәрсәдер эшләргә мәҗбүр итә иде, кичке аш әзерләргә кереште.

«Ялгыз ирнең кичке ашы»,— дип, үзен чит кеше карашы белән күргәндәй, хәтерендә калган юлларны исенә төшерде. «Нигә шулхәтле өзгәләнәсең әле,— диде аңа теге чит-ят кеше.— Кәләшең икенче берәүгә киткән икән инде, әле кемнең уңасы мәгълүм түгел. Өстәлендә әнә тагын унлап хат ята, бәлки, шуларның берсе сине чынлап та бәхетле итәр»,— дигән уй күңелен ымсындырып торды.

Әкрәм Галиевич аны-моны уйламый гына табын әзерләде. Икебана букетын куйды, серванттан савыт-саба алды, ашарга утыргач кына Наталья Сергеевнаның ике көндә дә онытылмаслык эз калдыруын аңлады. Ул кал-

ган гомерендә кечке ашны шушы бүлмәдә ашаячагын белә иде инде, бәлки, өстәлдә икебана да утырыр. Наталья Сергеевна үрнәгендә әзерләнгән табындагы тәм-томнардан авыз итеп, балыкчы ханым белән рәхәт үткән көннәрен исенә төшереп, моңаеп утырды.

Өстәлдәге хатларга Әкрәм абзыйның әллә ни исе китмәде, шулай да кызыксынуын тыя алмады. Конвертларны ачмый гына башта адресларына күз салды: хатлар илебезнең төрле почмакларыннан килгән, өч хат Украинадан, Әкрәм Галиевич башта шуларны укыды. Хатларда төгәл, эшлекле, акыллы тәкъдимнәр әйтелгән, «Белочка»-дан аермалы буларак, алар һавада очып йөрмиләр. Һәрберсенең үз адресы күрсәтелмәсә, Украинаның төрле өлкәләреннән килсә дә, Әкрәм абзый аларны бер үк хатын язган дип фараз итәр иде: стиле, язу рәвеше, таләпләре, хәтта күләменә хәтле юлы юлга туры килә. Бу тәкъдимнәр аңа өлкә газетында басылган фатир алыштыру игъланнарын хәтерләтте: «Бөтен уңайлыклары булган фатирымны зурракка һәм яхшыракка алыштырырга теләр идем». Андый тәкъдимнәрдә бигрәк тә нәрсәләре барына аеруча әһәмият бирелгән — анысы аларда җитәрлек, аларга менә шундый мул, бай тормышның кадерен белгән һәм бердәнбер шарт: сәламәтлеге нык булган кеше кирәк.

Әкрәм абзый Катяның шәрехләвен исенә төшереп: «Әзмәвер кирәк аңа»,— диде. Аларга, Әкрәм абзый аңлаганча, йортка керерлек сәламәт кеше кирәк, аңа тиешле шартлар тудырырга да вәгъдә итәләр. «Беркайчан да йортка керәсем, Хлебодаровкадан аягымны да атлыйсым юк! Бүген әнә берсе, тынычлыгымны алып, ташлап китеп барды инде, гомер иткән җиреңнән күченерсең дә, берике елдан кире кайтырга туры килә калса»,— дип куйды ул һәм шундый нәтиҗәгә килде: берсенә дә алданмаска, бары тик үз янына күченеп килергә теләүчеләрнең генә тәкъдимнәрен истә тотарга. Авыл кешесенең зирәклеге, сизгерлеге җиңде.

«Бу капиталист үзенең капиталын өч мәртәбә арттыру хакына теләсә нәрсәгә барырга да әзер, безне машина, дача, саклык кенәгәсе белән кызыктыра алмассың»,— диде ул, фикерен түгәрәкләп һәм үз-үзеннән канәгать булып.

Шунысы гаҗәп, Әкрәм абзыйның яңа килгән хатларга, «Белочка»дан алган беренче хат кебек, әллә ни исе китмәде. Ул өркебрәк ачкан бердәнбер хат Кырымнан — бу хат аңа «бакчасы диңгезгә карап торган таза бәдәнле, кара чәчле ханымнан» килгәндер кебек тоелды. Әмма ул ялгышты, ул хатынның бакчасы да, йорты да юк, дүртенче

каттагы бер бүлмәле фатирда яшәп ята һәм пенсиягә хәтле аяк киемнәре фабрикасында эшлисе икән әле.

Аларның тәкъдимнәренә ничек каравы аның үзенә дә аңлашылмады: беренче урынга күчмә һәм күчми торган милекне куюларын, гомер буена мал-мөлкәт тупларга өлгермәүләрен, ничек диләр әле, ярык тагарак янында торып калуларын бәйнә-бәйнә язуларына җен ачулары чыкты.

Әкрәм абзыйның беренче мәртәбә газетадан укыган һәм күңеленә хуш килердәй ханымнардан хат аласы килде — алар аңа ничектер якынрак та, аңлаешлырак та, газизрәк тә кебек иде. Бу, күрәсең, бер күрүдә үк гашыйк булу кебегрәктер инде»,— диде һәм яттан укыгандай дәвам итте: «Мин, какча гәүдәле, уалырга торган, аксыл-сары чәчле ханым, шәхси тормышымда уңышсызлыкка тарыдым, дөнья мәшәкатьләреннән арыдым, калган гомеремне авыл җирендә уздырырга теләр идем...»

Әмма «какча гәүдәле, аксыл-сары чәчле ханымнан» да, «таза бәдәнле, кара чәчле ханымнан» да хат-мазар юк иде — алардан килә калса, Әкрәм абзый, мөгаен, игътибарсыз калдырмас иде.

«Иң мөһиме — уйламыйча эш итмәскә»,— дип тынычландырды ул үзен, чираттагы хатны ачып.

Ленинградтан ниндидер бер персональ пенсионер карчык аны утырып кына да фән белән шөгыльләнеп булуы белән кызыктыра. Ул китапханәнең фотосурәтен дә җибәргән. Китапларның шулхәтле күп булуыннан Әкрәм Галиевичның коты алынды — Хлебодаровка һәм район китапханәсендә дә, мөгаен, ул чаклы юктыр.

Калган ике хатта фотосурәтләре дә бар, әмма Наталья Сергеевнадан соң алар аңа шундый шыксыз, ямьсез, сөйкемсез күренделәр. Хәтта ул аларның хатларын да укып тормады.

«Белочка»ның укылмаган хатын да исәпләсәк, беркөнне килгән ун хат та чүплек савытына очты.

— Иртәгә әле тагын яңалары килер,— дип тынычландырды ул үзен һәм, шул уеннан канәгать калып, йокларга кереп китте.

Шулай булып чыкты да: икенче көнне тагын яңа хатлар килде, бу юлы бик ерактан да түгел, әмма бик кызыклысы бар иде. Әкрәм Галиевич, хатта әйтелгәнчә, сөйләшү өчен эш телефоныннан заказ бирмәкче дә иде, иртәгә Ташкенттан кузгалып, берсекөнгә, әгәр ул теләсә, мөгаен, монда килеп җитәчәк табибә Әгъләмованы исенә төшереп, тыелып калды. Бигрәк тә, әгәр ул теләсә, дигәне ошады.

Әлеге хатлар белән телеграммнар Әкрәм абзыйның үзүзен тотышына да тәэсир итте: ул Хлебодаровкада масаебрак йөри башлады, элек үземне бик түбәнсетеп, кирәгеннән артык тыйнак һәм күзгә ташланмый гына яшәгәнмен икән дип уйлап алды. Ленинградта, мәсәлән, аңа пенсиягә чыккач, фән белән шөгыльләнергә, юридик тәҗрибәсен гомумиләштерергә тәкъдим итәләр,— шул хатны ертып ташлавына үкенде, иң мөһиме — әһәмияте ягыннан күренеп торган дәлилләрнең берсе, ул эшләп утырачак китапханә — кабинетның фотосурәте бар иде анда.

Кич белән ул табибә Әгъләмованың фотосурәтенә озак кына карап утырды, баштарак ул аны артисткадыр дип уйлады, аннары кайчан төшкән, төшкәненә ничә ел, бүген нindирәк кыяфәттә икән дигән сораулар кабат борчыды аны. Ни генә димә, фотосурәттәге ханымны ошатты ул. Әкрәм абзый аның сурәтен трюмо алдына бастырып куйды.

Башкалар белән чагыштырганда, аныңча, Нәзифә Әгъләмованың кайбер өстенлекләре бар: бик тә чибәр, якташ та, табибә дә. «Картайган көнеңдә өеңдә табибә булу — язмыш бүләге түгелмени? Нәзифә, мөгаен, Җолдас хатыны белән уртак тел таба алырдыр, коллегалар бит»,— дип, алдан ук шатланып куйды Әкрәм Галиевич.

«Чибәр дә соң! — диде ул, фотосурәткә карый-карый.— Хлебодаровка хатыннарының кайсын аның белән чагыштырырга мөмкин...» Шулай дип уйлавына уңайсызланып та китте, аңарда үзенә бер төрле яшерен җирле патриотизм хисе уянды, әмма Мәрьям үзенең сөйкемле булуы, мөлаемлыгы, буй-сыны, зифалыгы белән артистка табибәдән бер дә ким түгел, диде. Әкрәм абзый, үзен күрмәсә дә, бәхәстә беренчелек таҗын Нәзифә Әгъләмовага бирергә булды.

Шундый уйга килүе нотариусның күңелен күтәреп җибәрде. «Каршы алырга төшәм, поезддан ук алып калам»,— дип тәвәккәлләде Сабиров.

Кунак каршылауда азмы-күпме тәҗрибә туплаган Әкрәм абзый, Наталья Сергеевнаны каршы алгандагы кебек, каушап төшмәде. Үткән якшәмбедән калган шампан шәрабы шул килеш тора. Наталья Сергеевна икраның карасын да, кызылын да берәр литрлы банкага салып калдырган иде, төрледән-төрле консервалар, суыткыч тартмасы тулы җиләк-җимеш дисеңме! Яңа икебана букетын ничек укмаштырырга икәнен дә белә, кирәк була калса дип, ничек әмәлләргә кирәклеген язып та алган иде, барып чыкмаган тәкъдирдә Наталья Сергеев-

на букетын кабатларга була. Инде бөтен җирне җыештырып чыгасы да мунча ягасы гына калды бугай...

Әкрәм абзый шимбә көн үк, тиз йөрешле «Ташкент — Мәскәү» поезды килеп җитүгә өлгерсен дип, мунча ягып җибәрде. «Тәүлектән артык юлда интегәсе, бөркү вагонда киләсе бар, җәй бит»,— дип сөйләнде ул, димәк, мунча бик кулай булачак. Ишегалдын тагын бер кат күздән кичерде, өйдән әйләнеп чыкты — кунак каршы алу өчен бөтен нәрсә әзер. Дөрес, бу юлы шашлык әзерләп тормады, Ташкент кешесенә шашлык тансык ризык түгел, дип уйлады.

Әкрәм Галиевич бәйрәмдә кия торган кәстүмен киеп, ашыкмый-кабаланмый гына автостанциягә юл алды. Хлебодаровка хәзер уңнан да, сулдан да автобуслар юлы белән тоташты, станциядә Сабировка яшьлек елларын хәтерләткән бернәрсә дә калмаган иде. Ул чакта Хлебодаровкада бөтен поездлар да туктап су алалар иде. Поездлар шул ярты сәгатькә туктап торган арада, станция, иң җанлы урыннарның берсенә әверелеп, гөжләп тора иде.

Андагы базарны күрсәң! Хәзер берәрсенә шул хакта сөйләсәң — ышанмаслар. Кичке поезд каршыларга болай гына — ял итү, күңел ачу, кешеләр күрү өчен йөриләр иде. Станция ул елларда бик чиста итеп җыештырылган булыр, поездларга кузгалып китү вакытын белдереп, уңган хуҗабикәнең самовары кебек ялтырап торган җиз кыңгырау чылтырап алыр иде. Шул тимер юллардан бүтән җирләргә, үзләренекенә охшамаган тын һәм күзгә бәрелеп тормаган башка калаларга китү мөмкинлеге белән дә станция яшьләрне үзенә җәлеп иткәндер, мөгаен. Хәзер поездда ерак җирләргә яки бик ерак җирләрдән кайтучылар гына йөри диярлек.

Төш вакыты булуга карамастан, станция бушап калган. Әкрәм Галиевичның станциягә килмәгәненә дә ун еллап бардыр, күбрәк булмаса, чөнки ул аның көн дә эшкә йөри торган юлыннан бер читтә, аннан соң сәбәбе дә чыкмады. Элекке елларга караганда станциянең шактый искерүен, шыксызлануын, ямьсезләнүен күрде.

«Тиз йөрешлене» көтеп торган арада, поездның бары тик өч минутка гына туктап торуына үкенеп тә куйды. «Озаграк торса, берәр җирдә яшеренеп, сиздерми генә күз салып алырга булыр иде»,— дип фикер йөртте ул. Аннары аның уйланып торыр арасы да калмады.

Поезд бераз гына соңарып килде. Әкрәм абзый унынчы вагонның тукталу урынын дөрес чамаламаган, шуңа күрә аңа койрыкка таба йөгерергә туры килде. Ул тамбурдан башын чыгарып караган һәм, һичшиксез, үзен

күреп калган ханымны абайлап алды, төш шунда дип, кыю гына кул болгады. Ханым аның ымын шулай аңлады да. Әкрәм абзый вагон янына йөгереп килеп җиткәндә, ханым Хлебодаровка җирендә әйберләре белән басып тора, поезд да акрын гына кузгалып ята иде.

Әкрәм абзый сулышына кабынып тын алмаса, Нәзифә Әгъләмова аның йөзендәге өметсезлек билгеләрен шәйләми калмас иде. Аның сулышына кабынуын, йөзе кызаруын табибә Әгъләмова үзенчә аңлады, иң элек галстугының төенен бушатып, күлмәк изүен ычкындырды.

Әкрәм Галиевич, еш-еш тын алып, инде тәмам гашыйк иткән, фотосурәттәге күңелгә сеңеп калган чалымнарны күрергә өметләнеп, Нәзифә Әгъләмовага дикъкать белән карап алуга, табибә — артистка дигән уй телеп үтте аның миен. Әдәпле итеп кенә күрешсә дә, кузгалып киткән поезд артыннан пошынып карап калды.

Нәзифә тезгенне шундук үз кулына алды.

— Һо, сез нинди җитез икәнсез! Мин сезне нәкъ шулай күз алдыма китергән идем,— диде ул Әкрәм абзыйга, җәтмәгә эләктерергә теләгәндәй, карый-карый.— Авыл һавасы, эшсез тормавыгыз, стресс хәлләр кичермәвегез сизелә шул. Ләкин дөрес итеп сулый белмисез. Анысын бик тиз рәтләрбез, иртән йөгерә башласагыз — ярты ел дигәндә үсмерләр кебек сулыш алырсыз.

«Картайган көнемдә шул гына җитмәгән иде»,— дип, эчтән генә нәфрәтләнде Әкрәм абзый һәм, үзенең иртән Хлебодаровка тирәли йөгерүен күз алдына китерде дә елмаеп куйды. Нәзифә монысын да үзенчә аңлады...

Чемодан да, сумка да шактый авыр иде, хәл алырга дип туктап тордылар. Әгъләмова тузанлы поселок юлындагы былтырдан калган көл эзләренә карап:

— Мин сезгә бу хакта язган идем инде. Мин, Нәзифә Әгъләмова, менә әле хәзер дә игълан буенча танышуыма, калган гомеремне ниндидер Хлебодаровкада уздырырга ниятләнүемә ышанып җитә алмыйм,— диде дә шаркылдап көлеп җибәрде.

Көлү тавышы гаҗәеп яңгыравыклы иде, бу мизгелдә Әгъләмова трюмо алдына куелган фотосурәттәге ханымга охшаган иде. Әкрәм Галиевич аның кайчандыр бик чибәр, сөйкемле булуын, әле һаман да үзен шулай дип хис итүен, бүгенге яшен истә тотмавын аңлап алды. Сирәк булса да гомер буена сабыйлыктан аерылмаган олылар да очрый, табибә дә нәкъ менә шундыйлардан иде.

Йортны да, утарны да шундук ошатты — мөгаен, балачактагы печәнлеге, яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчасы булган авыл өен исенә төшергәндер.

— Миңа монда ошый. Болай ук булыр дип көтмәгән идем,— диде ул.

Өйдәге җиһазларны гына ошатып бетермәде. Әкрәм Галиевич моны аның күз карашыннан ук сизде, ханым җайлап кына болай диде:

— Авыл зыялысының, авыл юристының өен мин башкачарак күз алдыма китергән идем, баксаң, гадәти авыл ызбасы...

Әкрәм Галиевич аның нәрсәне ошатмавын, нотариусның ызбасы күршеләрнекеннән кай ягы белән аерылып торырга тиешлеген генә аңламады. Әгъләмова олы якка, залга узгач, трюмо алдында үзенең фотосурәтен күргәч кенә, алтын тешләрен җемелдәтеп, елмаеп, Әкрәм абзыйга карап торды да:

— Мин аны өегездәге кеше күзенә күренерлек урынга куюыгызга шикләнми идем, рәхмәт, бик шәп иткәнсез,— диде. Фотосурәтне турылабрак куйды да: — Мин сезгә икенчесен — затлы рамлысын, зуррагын бүләк итәрмен,— дип өстәде.

Мунча күптән өлгергән иде инде. Әкрәм абзый кунак ханымга, ашка утырганчы дип, мунча кереп чыкмыйсызмы дияргә җөрьәт итте. Әгъләмова аңа кызыксынып кына карап алды да:

— Авыл мунчаларын җенем сөйми. Җәйге душыгыз булса, рәхәтләнеп юынып-коенып чыгар идем,— диде.

Кунакны душка кертеп җибәргәч, Әкрәм абзый, мунчаның эссесен әрәм итмәссең бит инде дип, чабынып кайтырга ниятләде. Ул, кунак барын да онытып, озак кына тәмләп чабынды — мунча бик кызу иде. Әкрәм абзый өйгә кергәндә, Нәзифә ханым, китабын кулына тотып, диванда ята, нотариуска аның чәче бер якка авышкан сыман тоелды. «Бүген авызыма да алганым юк шикелле... озаграк чабындым, ахрысы?..— дип торды Әкрәм абзый, аннары гына аңлап алды: — Парик икән бит!»

Ни генә әйтмә, Хлебодаровка хатыннары парик кимиләр иде.

«Мине исерткән, тилерткән чәченең исеме дә, җисеме дә калмаган»,— дип, күңелсез уйларга бирелде Әкрәм абзый, ләкин ишетелерлек итеп берни дә әйтмәде.

Сабиров суы салынган самоварны верандадан җәһәт кенә ишегалдына алып чыкты, ут салды. Аннары табын әзерләргә кереште, иң әүвәл иртән сәгать буе маташкан икебана букетын өстәлгә утыртты. Булышырга дип кергән Нәзифә ханым аның шундый букет әзерләвенә ышанмыйча гаҗәпләнеп торды.

Наталья Сергеевна дәресләренең нәтиҗәсе күз алдын-

да: Әкрәм абзый табынны бөтен шартын китереп әзерләгән иде.

Нәзифә ханым мул-юмарт табынга күз салып:

— Байларча яшисез икән,— дип куйды.

— Зарлансак гөнаһ булыр,— диде Әкрәм абзый, аның мунчадан соң тамагын чылатып аласы килә иде. Диңгез байлыгының кайдан килүен әйтүне ул, әлбәттә, кирәксенмәде.

Әкрәм абзый кунакка шампан шәрабы, үзенә аракы салды. Танышу, Нәзифә ханымның сау-сәламәт булуы, игелекле табибә профессиясе хакына да эчеп куйдылар.

Әкрәм абзыйның да кәефе күтәрелде, парик та үз урынында, Нәзифә ханым да ара-тирә фотосурәттәге чибәркәйгә охшап куя. Шулай да ханымның рәсемгә кайчан төшүен, ул чакта аңа ничә яшь булуын сорыйсы килеп кыҗрап утырды. Әмма кунакның хәтерен калдыруым бар дип тыелып калды.

Табындагы сый-нигъмәттән Нәзифә ханымның күңеле булды. Гомеремдә шундый да тәмле, шундый да зиннәтле ризыктан авыз иткәнем юк иде, дип сөйләнә-сөйләнә, икраның кызылын да, карасын да мактый-мактый ашап утырды.

Сабиров исә мыек астыннан гына елмая, икраның кайдан килүен дә рәтләп әйтә алмады, чөнки ул бу хакта үзе дә белми иде.

Гомумән, күңелле генә утырдылар. Ул арада самовар да кайнады, Нәзифә ханым анысына бик тә куанды.

— Мин балачакта безнең өйдә корсагы медальләр белән бизәлгән самоварыбыз бар иде,— дип исенә төшерде.— Мин аны елга комы белән ышкып көзге кебек ялтыраткан идем! Хәзер андый самоварларны күрсәң музейларда гына күрәсең.

Нәзифә ханым Әкрәм абзыйдан ничек яшәве, ни белән шөгыльләнүе-мавыгуы хакында әдәпле генә итеп, хатын-кызларга хас хәйләкәрлек белән сораштырып утырды. Аның бернинди дә хоббие юклыгын белгәч, мактап та алды, гаиләгә игътибар итәсе урында кайбер ирләр буш вакытларында төрле мәгънәсез эшләр белән мавыгалар — акылдан язалар инде, дип тә өстәде.

Аннары шулай бик тәфтишләп соравы өчен гафу үтенеп, үзе хакында менә ниләр сөйләде:

— Әкрәм Галиевич, авылда тусам да, мин шәһәрдә гомер иткән зыялы хатын. Беренче ирем олы яшьтәге хәрби иде, мине иркәләп, назлап кына торды. Югары чиндагы офицер, акчаны әйбәт ала, хезмәт иткән урынында киендерәләр-ашаталар, персональ машинасы һәрчак минем

карамакта диярлек иде, шуңа күрә мин хатын-кызлар шөгыльләнергә тиешле хуҗабикә мәшәкатьләрен белмәдем дә, белергә дә теләмәдем. Минем үз дөньям, үз мәшәкатьләрем, әйткәнемчә, ирем ярата, кадерли, мин шуңа канәгать булып яшәдем. Әлбәттә, кайчакларда кунаклар чакыра идек — җиләк-җимеш, шампан шәрабы куела. Ә инде бәлеш ише ризыкларны, таба ашларын, төрле тәм-томнарны миннән көтмиләр дә иде. Аның каравы мин фортепьянода уйныйм, рәсем дә ясап карадым, иремнең дуслары мине хөрмәт итәләр, син нәфис сәнгать өчен яратылгансың, диләр иде. Сездә андый уен коралы булмавы гына жәл, югыйсә рәхәтләнеп уйнап күрсәтер идем. Боларны мин ни өчен сөйли дип беләсез? Бары тик мине аңлавыгызны һәм сабыр итүегезне генә телим, бәлки, мин дә әле хуҗабикә булырга, табын әзерләргә өйрәнә алырмын.

Миңа монда ошый, шулай да күңелне тартып торырлык соклангыч җиһазлар алырга, зыялы кешеләр яшәвен күрсәтергә кирәк. Мин монда да сынлы сәнгать белән шөгыльләнә, тыйнак авыл күренешләрен яза башлар идем, дип уйлыйм, кала күренешләре әйбәт үк чыкмады... Бәлки, соңрак портретлар ясарга да тотынырмын. Кеше арасында сирәк булырга туры килүебез генә жәл, югыйсә мин кунакка, театрга йөрергә яратам. Җае чыкканда сорыйм әле, Хлебодаровкада мәдәният учаклары бармы соң?

— Узган елны гына мәдәният йорты ачканнар иде, каланыкыннан бер дә ким-хур түгел,— дип җавап бирде Әкрәм абзый, сөйләшү аны айнытып җибәрде.

— Мәдәният йортыгызда нинди иҗади эшләр белән шөгыльләнәләр соң? — дип кызыксынды Нәзифә ханым.

— Дөресен генә әйткәндә, мин бер дә хәбәрдар түгел,— дип икърар итте нотариус,— авылдагы мәдәни тормыштан артта калдым. Төрле түгәрәкләр эшли шикелле, һәр көнне кино күрсәтәләр, анысын ышандырып әйтә алам.— Аннан исенә төшереп, өстәп куйды: — Икенче катта китапханә, залда зур гына пианино тора. Уйнарга теләсәгез каршы килмәсләр дип беләм, рөхсәт итәрләр, барыбер тузан эчеп кенә ята.

— Бүген кино күрсәтәләрме?

— Күрсәтәләр, бүген шимбә бит. Дүшәмбедән кала һәр көнне...

— Булды гына. Ниятләдек. Кинога барабыз. Мин һәммәсен дә үз күзләрем белән күрергә тиеш...

— Кинога икән кинога,— дип килеште Әкрәм абзый, ләкин, бөтен авыл аша барырга һәм кайтырга кирәк булуын исенә төшереп, салкын тиргә батты, аннары тагын

залда дүрт йөз урын — өч йөз туксан сигез күзнең, нотариусыбыз кем белән кинога килде икән, дип кызыксынуларын күз алдына китерде.

Бармый калырга мәллә? Ничек итеп? «Иһ, ни булса, шул булыр, ул булмаса, кыз булыр» дигәндәй, табын җыештырырга кереште, Нәзифә ханым чемоданындагы кием-салымнарын актарырга тотынды.

Аннары ул трюмо алдына фотосурәте куелган алгы бүлмәгә кереп бикләнде, сәгать ярымсыз борчымаска кушты, Әкрәм абзый ни эшләргә белмичә ишегалдында әрлебирле йөренеп торды. Аңа җыену өчен биш минут вакыт җитте, бүген анысы да кирәк булмады — төшке ашка ук инде бәйрәм кәстүменнән иде.

«Каптым, нык каптым»,— дип уйлап алды Әкрәм абзый, нәрсәгәдер өмет итеп, Җолдаслар ишегалдына күз салды: бухгалтерның акыллы киңәше менә кайчан кирәк икән. Әмма Бөркетбаевлар ишегалдында берәү дә күренмәде — туганнарына авылга китеп барганнардыр, күрәсең.

«Ул ханым Әкрәмне бәхетле итүенә, үзен минем өчен генә түгел, бәлки, бөтен Хлебодаровка өчен дә бүләк дип исәпләве белән бер мизгелгә дә шикләнми булса кирәк... Ярар, аш-су әзерли дә белмәсен, ди, өстәл җыештырырга гына булыша алмас идемени, аннан соң самоварга ут салырга күп акыл кирәкмени! — дип, пыр тузды нотариус.— Кинога бер барып кайту өчен сәгать ярым бизәнепясанып утырсын әле, ничек вакытын кызганмый диген, сынлы сәнгать, портретлар ясый, имеш...— дип тузынды ул.— Ярар, теге фотосурәттәге чибәр ханымга бераз гына булса да охшаса икән, ул чагында, үзе әйткәнчә, аны иркәләүдән-кадерләүдән берәр мәгънә дә чыгар иде. Мин нәрсә, бөтен Хлебодаровкага аның яшь чагында ул менә нинди чибәр булган дип, фотосурәтен күрсәтеп йөрергә тиешмени? Яки урамга йөрергә чыкканда, вәгъдә иткән затлы рамлы зур портретын күтәреп йөрергә тиешмени? Юк, Хлебодаровкада мине аңламаслар, Җолдас дөрес әйткән, аңламаслар. Җитмәсә әле, үзебезнекеләр ярамадымыни дип сорасалар, ни диярсең. Оһ, зирәк икәнсең син Җолдас ага...»

Әкрәм абзый янә, вәсвәсәләнеп, Бөркетбаевлар ишегалдына күз салды!

«Үзен күргәч, чибәр булгандыр дип күз алдына китерүе дә кыен. Бәлки, фотосурәте дә фотосурәт түгелдер, ясалган рәсемдер әле, калада андыйга осталар, акчага теләсә кемне чибәр итеп ясап бирәләр,— дип шикләнде нотариус.— Чәчен ничек кенә кыландырмаган, Пушкинның Наталиясе диярсең, монда парик киеп килгән. Хлебодаровкада белсәләр — көлкегә калачак».

Аның кәефе торган саен кырыла барды. Ул үзен алдангандай хис итте, ни эшләргә дә, ни кылырга да белмәде,— ник кычкырып еламыйсың шунда.

«Ни өчен әле мин аңа ярарга тырышырга, төчеләнергә тиеш, әлек чибәр булганы өченме? Аның чибәрлеге һәм яшьлеге белән хозурланган, рәхәтен күргән кешеләр ахырына кадәр җиткерсеннәр дә инде. Шуарга яратасың икән инде, тартып йөрергә дә ярат, дигәндәй, югыйсә — берәүләргә өсте, икенчеләргә тамыры. Алай булмый ул... Ярык тагарак янында торып калган хыялыйга хат язмаган бит, югыйсә кичләрен, шулхәтле матур итеп уздырырлар — анысы гитарада уйнар, монысы фортепьянода дыңгырдатыр иде. Зыялылар тормышы шулайрак була түгелме соң? Бәлки, ике тавышка җырларлар да, бер-берсенә шигырьләр укырлар,— дип хыялланды нотариус.— Бәлки, аңа «хыялый ирнең» игъланын күрсәтергәдер, газеты югалмаган әле, дөмеккере...»

Нәзифә ханым да, ниһаять, киенеп-ясанып чыкты. Аягына биек үкчәле туфли, өстенә җиз кебек ялт-йолт килеп торган материядән тегелгән күлмәк кигән, муенындагы җете кызыл төстәге косынкасының төенен, кызлар кебек, кыландырып бәйләгән, күзлек кигән... Әкрәм абзыйның гаҗәпләнүен күреп, кулларын җәеп:

— Беләм, беләм, килешмәвен дә беләм, киноны мин күзлек киеп карыйм,— диде.

«Шәһәрчә, бәлки, ул матур да киенгәндер, хлебодаровкаларча — кирәгеннән артык күзгә бәрелеп тора, аннары яшенә дә туры килми»,— дип уйлады Әкрәм Галиевич, әмма бер сүз дә әйтмәде. Күзлеге белән паригы ни өчендер башына эшләпә кигән сыман биеп бара.

«Күзлек кими генә барса ярамый микәнни, кино башлангач та кияргә өлгерер иде,— дип куйды.— Авылда иң модалы күзлеккә дә исләре китмәвен белергә тиеш бит инде ул. Үкчәләрен, Ходай язмасын, безнең чокырчакырлы юлларда сындыруы да бар, менә ул чагында көлкегә калачак та калачак».

Юлга чыгуга ул аны култыклап алды — әллә инде шулай килешә дипме, әдәплелек дипме, әллә инде көтмәгәндә урам тузанына сузылып ятудан куркыпмы, аңламассың.

Бүтән көннәрдә Әкрәм Галиевичка кинога бару рәхәт кенә иде, бүген барып җитә алмый гаҗиз булды. Һәр ишегалдыннан, һәр өй түрендәге бакчадан, безнең хөрмәтле нотариусыбыз горур гына кем белән култыклашып бара икән, дип, кызыксынып карап калалардыр сыман тоелды.

Нәзифә ханым, сокланып, юл буе сөйләнеп барды, Әкрәм Галиевич таныш-белешләреннән берәрсе очрап: «Әкрәм Галиевич, бер генә минутка булса да безгә дә рәхим итегез. Бу чибәр, мөлаем ханым сезнең кемегез була? Сез аны бикләп тотасызмы, кеше күзеннән яшерәсез мәллә? Ничек оят түгел!» — дип сораштыра күрмәсеннәр тагын дип, тирә-ягына куркынып карана-карана, тыңлар-тыңламас кына атлады. Ярый әле беркем дә очрамады, сораштырып аптыратучы булмады, кинотеатрга хәвеф-хәтәрсез барып җиттеләр, туфлинең дә үкчәсе сынмады.

Кинотеатр янында халык искиткеч күп, икенче көн инде «Вокзал для двоих» дигән яңа фильм күрсәтәләр. Әкрәм абзый билетка чиратның зур булуына бер яктан шатланды да. Мәдәният йорты фасадына ябыштырылган реклам-афишалар янында Нәзифә ханымны ялгызын гына калдырып, чиратка басты.

Чират бик акрын кыймылдады, һәр яктан яңа төркем агыла, этешә-төртешә касса янына килеп бөялә торды — Хлебодаровкада бүтәнчә күз алдына китерү дә кыен — шундый этеш-төртеш арасында Нәзифә ханымның Әкрәм абзыйны күздән югалтуы да гаҗәп түгел. Әмма Әкрәм абзый аны бик әйбәт күреп торды. Ханым бар кешегә күренеп торган афиша янынарак елышкан. Берәүнең дә аңа игътибар итмәве, текәлеп карамавы сәер иде; афиша янына берьюлы берничә хатын-кыз килеп басты, Нәзифә ханым бер ягы белән дә алардан аерылмый иде.

Кинәт Әкрәм абзый, коты алынып, тынып калды. Әйтерсең лә махсус аның кәефен кыру өчен афишалар тирәсенә Мәрьям килеп басты. Алар, модалар күрсәткәндәй, Нәзифә ханым белән янәшә басып тордылар — Әкрәм абзыйның телевизордан шундыйрак тапшыруларны күргәне бар, Мәрьям аңа күз дә салмады, ә Нәзифә үз янына килеп баскан ханымга, ашардай булып, көнләшеп карап торды, нотариус монысын бик әйбәт күрде, Мәрьям бүген гаҗәеп чибәр һәм мөлаем иде шул.

Моннан берничә көн элек табибә Әгъләмованың үзен күрмичә генә почта мөдире белән чагыштырып каравына, бер дә шикләнмичә Нәзифә ханымны чибәррәк дип уйлавына Сабиров бик тә уңайсызланды. Менә хәзер киноафишалар фонында, кояш балкышы яктысында алар икесе янәшә басып торганда, бу ханымнарны берничек тә чагыштырырга ярамавын күрде, һәм ул үзе үк Нәзифә ханымга биргән мөлаемлылык, гүзәллек, чибәрлек призын ике дә уйлап тормый кире алды да, түбәнчелек белән баш иеп, аны Мәрьямгә «бирде». Мәрьям генә, кызганычка каршы, берни дә сизмәде.

Төймәсен өздереп булса да, ул, ике билет тотып, көчхәл илә чиратны ерып чыга алды.

Чиратка бүтән басмагыз дигәннән соң, касса янындагы мәхшәрне күреп торган Нәзифә ханым:

— Булдырдыгыз, егет икәнсез! — дип соклануын белдерде.— Ул фильм Ташкентта да бара иде, бик күрәсем килгән иде дә, кая ул, анда да шушы ук хәл.

Нәзифә ханым аның галстугын турылады, чәчләрен сыйпады, чытлыкланып кына өстәде:

— Рәхмәт инде, тырыштыгыз, югыйсә бик тә хәтерем каласы иде.

Соңгы звонок бирелүгә, залга ашыктылар. Зал вокзалдагы ир белән хатынны шатланып, борчылып, нәфрәтләнеп күзәтте. Әкрәм абзый гына фильмны күрмәде — экранга карамады да, янәшәдә генә кыйгачлап утырган Мәрьямнең караңгыдагы шәүләсеннән күзен ала алмады. Аңа карап утыруы рәхәт тә, күңелле дә, көенеч тә, фильм урынына әллә кайчан, көзге көннәрнең берсендә аны танцыдан озата кайтканда: «Мәрьям...» — дип әйткән мизгелләрен күз алдына китереп утырды.

Әкрәм абзый өчен фильм көтмәгәндә тәмамланды — ул Мәрьям турындагы киноның озаграк баруын, бетмәвен көткән иде.

Урамда караңгы төште, Нәзифә ханым Әкрәм абзыйның кәефсезләнүен, сөмсере коелуын күрмәде. Аны култыклаган Нәзифә ханым режиссерның теге яки бу текстка нинди мәгънә салуын һәм, гомумән, нәрсә әйтергә теләвен җитди кыяфәт белән аңлатып кайтты.

Уйларына чумган Әкрәм абзый аны тыңламады. Аның уй-фикерләре берсеннән-берсе мәгънәсезрәк иде. Кулын ычкындырып, беренче караңгы тыкрыкка кереп чуммакчы, бакчалар артыннан гына качып котылмакчы булды. Әмма кая? Кайчагында аның Мәрьям янына йөгереп барып, алдына тезләнеп, яшьле күзләрен төбәп: «Коткар мине һәм гафу ит!» — диясе килде.

Өйләренә кайтып җиттеләр, котылу өмете дә сүрелде. Ишегалдына кергәндә: «Шул кирәк сиңа, теләгеңә ирештеңме инде, карт җүләр»,— дип, Әкрәм абзый, үз-үзен битәрләп алгач, тынычлангандай булды.

Борчылудан карыны да ачты, кичке аш вакыты да узган, өйдә кунак бар бит дип, Әкрәм абзый кухняга узды. Итне юып чистартты да тизрәк кызсын һәм сүлле булсын өчен бик тырышып тапады-йомшартты.

Нәкъ шул вакытта Нәзифә ханым кухняга кереп чыкты. Өстенә спорт кәстүме, аягына кроссовка кигән.

— Йоклар алдыннан бераз гына йөгереп керәм,— диде

ул.— Монда да шул гадәтемне дәвам итәрмен, дип уйлыйм, сынымны саклау рәхәт миңа. Әзер булгач — дәшәрсең, ишегалды тирәсендә генә йөгерәм,— диде дә елмаеп чыгып та китте.

Ит кызган арада, Әкрәм абзый самовар куеп җибәрде, табын әзерләде, шулай кызу тотуына гаҗәпләнеп торды. Самоварны алып керергә дип чыкканда, Нәзифә ханым ишегалдында чәчәкләр янында иде.

— Мөгаен, мин биредә бик бәхетле булырмын,— диде ул, артисткаларча сагышлы һәм тәэсирле итеп.— Гаҗәеп саф һава, йолдызлы күк йөзе, янымда эчкерсез кайгыртучым һәм сөеклем... Мин сезнең белән бергә яшәвемне нәкъ менә шулай күз алдыма китерә идем.

Әкрәм абзый кабаланудан тирләгән маңгаен сөртеп алды да хисләргә бирелми генә табынга чакырды.

Нәзифә ханымның күңеле күтәренке, рухы, кәефе шат иде.

— Кадерлем Әкрәм Галиевич, минем игълан буенча танышу вәсвәсәсенә бирелүемә беркайчан да үкенмәслек булсын дисәк, күтәрик әле шушы бокалларны,— дип тәкъдим итте ул.

Әкрәм абзый кунакка шапман шәрабы, үзенә ялгышлык белән шампан бокалына аракы койды. Кәефе чиксез кырылуын, ирегенн тәмам югалтуын, Нәзифә ханымның йомшак, назлы куллары белән аңа муенчак кидерүен сиздe, шуңа күрә аракыны кире рюмкага салып тормады, тулы бер бокални каплап та куйды.

Нәзифә ханым тапап пешерелгән итне мактап алгач:

— Рөхсәт итсәгез, мин тагын бер тост әйтмәк булам. Сезне һәрчак инсафлы джентльмен итеп күрәсем килә. Әйтик, бүгенге кебек сез станциядә шундый канатланып, дәртләнеп йөгереп килдегез... Мин моны беркайчан да онытмам. Кино билетын да җиңел генә алып чыктыгыз... Егет икәнсез! Кадерлем Әкрәм Галиевич, сезнең өчен күтәрик! Сез минем үбүемә лаек,— дип кочаклап, Әкрәм абзыйның иреннәннән суырып үпте.

Нәзифә ханымнан «Белочка»ның таныш хушбуй исе аңкыгандай булды. Бу юлы инде ир ялгышмый гына үз бокалына тутырып аракы салды.

Хискә бирелгән Нәзифә ханым музыка көйләргә кушты, сүз уңаенда, күптән түгел генә аэробика белән шөгыльләнә башлавын да сиздерде.

Әкрәм Галиевич аэробиканың нәрсә икәнен белмәсә дә, сораштырып тормады, моның хуҗалык һәм кухня белән бәйләнеше юклыгына ышанды. Үткән якшәмбедәге кебек танго биеделәр. Наталья Сергеевна белән дә

шулай биегәннәр иде, әмма күңеле күтәрелмәде. Биюенең дә рәтен тапмады — ике бокал аракыдан тәмам мәлҗерәп төште. Нәзифәнең аягына баса-баса, фотосурәт торган трюмо янына алып килде.

— Әкрәм Галиевич, нәрсә булды сезгә? — диде ул, чытлыкланып.— Беләсезме, минем бар курыкканым сәрхуш ирләр. Алкаш ир заманыбызның яман чире ул,— дип ярсыды.— Күралмыйм мин аларны! Кулымнан килсә, бөтенесен Себергә, каторгага сөрер идем, бик тиз акылга утырырлар иде! — Ярсуын тыеп йомшак кына өстәп куйды: — Мөгаен, моңа күпмедер дәрәҗәдә без, хатын-кызлар, үзебез дә гаепле. Әлбәттә, мин үземне күздә тотып әйтмим — эчүгә сабышкан ир белән мин сөйләшеп тә тормас идем, баштан үтте, гарык.

Бу сүзләр Әкрәм абзыйны айнытып җибәрде дисезме? Юк, бөтенләй үк түгел, элеккечә үк алпан-тилпән килә. Исергән булса да сизеп алды — менә ул ханымнан котылу чарасы! Ирек алу өмете ялтырап киткәндәй булды.

Ул аягында басып торырга тырышып, ханымны нәзакәтлек белән табын янына алып килде, һәрхәлдә, аңа шулай тоелды, аннары кеше ышанмаслык аллы-гөлле сүзләрдән генә торган тост әйтте, аннан хәтта грузин тамадасы да, шуның ише тел бистәсе дә көнләшер иде, мөгаен.

Мондый тостка бер генә хатын-кыз да каршы тора алмастыр. Әкрәм абзый әлеге тостына үзенең бөтен осталыгын салды, дәрт-дәрманын җикте, күңелендә йөрткән бөтен мактау сүзләрен кертергә, нәрсәгә сәләтле икәнен күрсәтергә тырышты, бу аның өмете иде, тагын бер бокал эчеп җибәрде.

Нәзифә ханым үзенә карата купшы сүзләрне күп ишетсә дә, провинциядә яшәүче кеше авызыннан ишетүе шулай да рәхәтрәк иде. Әкрәм абзый бик тә тырышты шул. Мактау сүзләреннән хозурланган ханым уяулыгын югалтып җибәрде, Әкрәм Галиевичның бокалын тутырып салганын да абайламый калды. Тост әйткән кешене кем генә тыярга җөрьәт итәр икән?

Сагышлы тангоны дәртле бию көйләренә алыштырдылар, әмма Әкрәм абзыйга бию кыенлашканнан-кыенлаша барды — аяклары тыңламады. Янә табынга утырдылар.

Аракы эчелеп беткәч, Әкрәм абзый үзенә дә шампан шәрабы койды, хәтта әдәплелек йөзеннән ханымга бокал да тәкъдим итеп тормады, тост әйтми генә эчеп тә җибәрде.

— Әкрәм Галиевич, нишләвегез бу? — дип сорады ул, шөбһәләнеп.

— Ә-ә-ә,— дип өметсезләнеп кулын селтәде Әкрәм аб-

зый,— баш күтәрми эчү чире башлануын сизәм, хәзер инде мин өйдәген һәм күршеләрнекен дә эчеп бетерми торып, туктала-тыела алмыйм,— дип, тагын бер бокал шампан шәрабын каплап куйды.

— Нинди баш күтәрми эчү! Әкрәм Галиевич, мин сезне шаяртасыздыр гына дип торам.

Әкрәм абзый үзе дә сизмәстән, күз яшьләренә тыгылып, үксеп елап җибәрде,— чынлап та аңа үзе бик кызганыч иде. Ул, Нәзифә ханым янына килеп, тәкәллефләнеп кенә тезләнмәкче иде дә, булдыра алмады, Әгъләмова аягы астына капчыктай сыгылып төште.

Ханымның биленнән кысып кочаклаган хәлдә:

— Гафу ит, мине, бәгырькәем, эчәм шул, эчәм,— дип сөйләнде ул, күз яше аралаш.— Юаш алкаш мин, юаш, минем алкаш булуымнан берәүгә дә зыян тигәне юк. Елына өч мәртәбә ычкынгалап китәм, шуннан да артык түгел. Чын күңелемнән ант итеп әйтәм: эчүне ташлыйм, бары тик мине генә ташлап китмә, күз нурым...

Әкрәм абзый, елый-елый, «Белочка» хатындагы бизәкле ант сүзләрен мыгырдады. Камин, һичшиксез, алып бирергә вәгъдә иткән бәрхет халат хакындагы сүзләр дә бар иде анда.

Нәзифә ханым аның кочагыннан ычкынмакчы да булып карады, әмма нотариус, егылып китүдән куркып, аны бик нык кысып кочаклаган иде. Сабировның күз яшьләрен сөрткән чагын туры китереп, ханым аны этеп җибәрде дә, өстәл янына килеп басты.

— Кабахәт! Кабахәт! Кабахәт! — дип акырды ханым, аның тавышын, мөгаен, Бөркетбаевлар да ишеткәннәрдер.— Газетта эшләүчеләрне дә әйтер идем инде! Тикшерми-нитми теләсә нинди алкашның игъланын бастыралар. Каян килгән «тел-теш тидермәслек абруйлы кеше!» Судка бирер идем дә, бәйләнеп кенә йөрисем килми... Юк, бүтән мин монда аяк та басмаячакмын! Алкаш белән гомеремне әрәм итәмме соң...

— Ташлама мине,— дип өзгәләнде идәндә яткан Әкрәм абзый.

— Бик күпне өмет итәсең! — дип зәһәрләнеп җавап бирде Нәзифә ханым һәм, өстеннән атлап, бүлмәдән чыгып ук китте.

Әкрәм абзый соң гына уянды. Тәрәзәдән иртәнге кояш нурлары үтеп керсә дә, бүлмәдә ут сүнмәгән. Ханымның аяк астына ауган җиреннән көч-хәл белән генә торып басты.

Бөтен гәүдәсе ватылган, башы чатный, әмма Әкрәм абзыйның моңа әллә ни исе китмәде. Ул җыештырылмаган табын янына узды, куркып кына Нәзифә ханым

бүлмәсенең ишегенә төртте. Бүлмәнең асты өскә килгән, ханым да, әйберләре дә күренми. Нотариус хат-мазар калдырмаганмы икән, дип эзләнде, әмма күзенә берни дә чалынмады.

— Аллага шөкер! — дип, бәхетле елмаеп куйды Әкрәм абзый, хәтта җиңеләеп китте, тәне ватылуын да, башы авыртуын да онытты.

Ишегалдына чыкты, рәхәтләнеп киерелеп алды — тормыш аңа гаҗәеп гүзәл булып тоелды! Аннары краннан юынып алды, самовар куеп җибәрде, кичтән калган табынны җыештырды. Якшәмбе көнен ул файдалы итеп уздырды, эшен бетергәндә, ни кылырга кирәклеген белә иде инде.

Дүшәмбе көн иртән эшкә барышлый почтага сугылды, алдан ук әзерләп куйган телеграммны сузды. Әкрәм абзый танымаган яшь кенә бер телеграфист кыз,— өйрәнчектер, мөгаен,— каушап калды:

— Ашыгыч ук кирәкмени? Хәзер генә аппаратым чыгымчылый башлады, ни эшләргә дә белмим... Мөдирдән сорап чыгыйм әле...

Мәрьям үзе килеп керде.

— Хәерле иртә, Әкрәм. Иртүк нинди ашыгычлык ул?

— Менә телеграмм сукмакчы идем, әлбәттә, ашыгыч тапшыруларын хәбәр итеп...

«Танышу игъланымны гамәлдән чыгаруыгызны үтенәм, чөнки мин мондагы ханымга өйләнергә ниятләдем. Үземнең уйламый гына эш итүем белән борчыган өчен, һәммәгездән дә гафу үтенәм»,— диелгән иде анда.

Мәрьям, мөлаем гына елмаеп:

— Борчылма, Әкрәм, мин аны хәзер үк шәһәргә тапшырам, алар анда ашыгыч итеп газетка сугарлар,— диде.

Әкрәм абзый, гаепле кеше сыман, Мәрьямгә текәлеп карап торды һәм нигәдер почтадан чыгып китәргә ашыкмады. Нотариусның уңайсызланып торуын күргән Мәрьям ишектән аны озата чыкты.

Алар өйалды болдырына чыгып баскач, Әкрәм абзый аны-моны уйлап тормастан:

— Мәрьям, хәтереңдә микән, берзаман мин сине танцыдан озата кайткан идем?

Мәрьям, моңсу гына елмайды да әкрен генә җавап бирде:

— Хәтерлим, Әкрәм, әлбәттә, хәтерлим...

# ЭЧТӘЛЕК

Иҗат — үзе тормыш ул. *Сергей Алиханов. Марс Шабаев тәрҗемәсе*
5

Иртәләгән сагыш. *Марс Шабаев тәрҗемәсе*
23

Игълан буенча танышу. *Вакыйф Зыятдинов тәрҗемәсе*
389

Литературно-художественное издание

*Рауль Мирсаидович Мирхайдаров*

**РАННЯЯ ПЕЧАЛЬ**

**Роман, повесть**

(на татарском языке)

Мөхәррире *Ф.М.Хафизов*
Рәссамы *Н.А.Воропаева*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Ф.Р.Гыйсмәтуллина*
Корректорлары *Л.Ш.Шәфыйкова, Р.В.Сабирҗанов*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал макеттан басарга кул куелды 9.12.2002. Форматы $84\times108^{1}/_{32}$.
Офсет кәгазе. «Тип-таймс» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 23,52+форз. 0,21. Шартлы буяу-оттиск 24,78. Нәшер-хисап табагы 25,38+форз. 0,36.
Тиражы 5000. Заказ Б-732.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.